АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Татары Ульяновской области*

2-е издание

КАЗАНЬ 2021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Ульяновск өлкәсе татарлары*

2 нче басма

КАЗАН 2021

УДК 398+811.512.145
ББК 81.2=632.3+82.3(2=632.3)+85.12
М 48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

«Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2014–2019)»
ТР Дәүләт программасы кысаларында әзерләнде

**Редколлегия:**
***К.М. Миңнуллин*** *(рәис),* ***Р.В. Шәйдуллин,***
***Ф.З. Яхин, Ф.И. Таһирова***

**Төзүче һәм фәнни мөхәррир**
*филология фәннәре кандидаты* ***И.И. Ямалтдинов***

**М48** **Милли-мәдәни мирасыбыз: Ульяновск өлкәсе татарлары. –** 2 нче басма. – Казан, 2021. – 600 б., рәс. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).
ISBN 978-5-93091-345-3

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән чираттагы китап Ульяновск өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел-авыз иҗаты, сөйләш үзенчәлекләре, көй-музыкасы, җирле осталарның кул эшләре, археографик һәм эпитафик мирасы турында бай мәгълүмат бирә.

**ISBN 978-5-93091-345-3**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2018, 2021

*Тел – уйлауның коралы, уйның – калыбы...*
*Миллият бинасының нигез ташларыннан*
*иң ныклысы – тел... Телнең эчендә халыкның рухы,*
*моңы, уй һәм тойгысы яшеренгән.*

Галимҗан Ибраһимов

---

*Язык – это инструмент мышления,*
*форма мысли… Самый прочный камень*
*в фундаменте бытия нации – язык… В языке*
*сокрыты душа народа, его мысли и чувства.*

Галимджан Ибрагимов

## КЕРЕШ

Һәр төбәкнең табигать тә, анда яшәүче кешеләр дә, аларның ышанулары һәм дөньяга карашлары да йогынты ясый торган язмышы, йөзе, рухи үзәге-асылы бар. Шушы үзенчәлекне тою-аңлау өчен, әлеге төбәктә яшәү, һич булмаса, андагы тормышны өйрәнү һәм халык белән аралашу кирәк. Болар төбәкнең хәзерге хәл-халәтен күзалларга мөмкинлек бирә.

Үткән-тарих исә күпмедер күләмдә чыганакларда саклана; аларны археологик тикшеренүләр үткәреп тергезәләр; архив документларыннан һәм тарихи һәйкәлләрдән, ташъязмалардан эзлиләр. Археолог-галимнәр борынгы кешеләр турында мәгълүмат сакланган урыннарда разведка уздыра, казу эшләре оештыра һәм, табылдыкларга нигезләнеп, бик ерак тарих хакында төгәл мәгълүматлар китерә. Археологик тикшеренүләр вакытында эралар-чорлар да, шул заманнарда билгеле бер урында яшәгән кешеләрнең кайсы халыкка каравы, көнкүреше, һөнәрләре, нинди технологияләргә ия булуы, ышанулары да, күпмедер күләмдә зәвыгы, мәдәни казанышлары да ачыклана. Алар язма тарихи чыганаклар булмаган ерак заманнарны кабат күзалларга мөмкинлек тудыра, архив материаллары, документлар, эпиграфик һәйкәлләр һ.б. исә безгә якынрак чорлар хакында сөйли.

Алар да күрсәтә алмаган бик күп сәхифәләрне шәҗәрәләр һәм гаилә истәлекләре дә; төбәк кешеләре хәтерендә буыннан-буынга тапшырылып килгән мифлар һәм легендалар, җырлар һәм бәетләр дә; халыкның тел-сөйләм, әдәби фикерләү хасиятләре, көнкүреш һәм мәдәни үзенчәлекләре; матди һәм мәдәни кыйммәтләр дә үзендә саклый. Боларны күрә, аңлый, өйрәнә һәм аңлата белергә генә кирәк. Гаҗәеп күренеш: археологик һәм тарихи чыганакларда сакланмаган мәгълүматлар еш кына кешеләр хәтерендә, төбәкләрнең тормыш-көнкүрешендә яшәвен дәвам итә! Аларны

# ВВЕДЕНИЕ

У каждого региона есть свой неповторимый облик, своя судьба, особая духовная составляющая, которые формируются под влиянием местной природы, живущих там людей, их мировоззрения, привычек и верований. Чтобы понять и почувствовать это своеобразие, необходимо здесь пожить или хотя бы понаблюдать местное жизнеустройство и пообщаться с людьми. Только так можно получить представление о современном состоянии региона.

Страницы прошлого в какой-то степени раскрываются в исторических источниках, их восстанавливают посредством археологических исследований, находят в архивных документах и исторических памятниках. Ученые-археологи проводят исследования в местах, сохранивших следы пребывания древних людей, организуют раскопки и, опираясь на сделанные находки, способны представить точную информацию об очень далеких эпохах. Во время археологических изысканий выясняются возраст рассматриваемых объектов, принадлежность населения данной местности к тому или иному народу, особенности их повседневного быта, используемые технологии и ремесла, их верования, эстетические предпочтения и культурные достижения. Археологи дают возможность представить те далекие времена, о которых нет исторических источников.

Исторические источники (архивные материалы, документы, эпиграфические памятники и др.) рассказывают о ближайших к нам эпохах. Многие страницы истории, которые не получили отражение в источниках, сохранились в родословных, семейных преданиях; в передаваемых из поколения в поколение мифах и легендах, песнях и баитах, в специфике разговорной речи и литературного мышления; особенностях повседневной жизни и культуры; в материальных и культурных ценностях населения данного региона. Нужно только увидеть, понять, изучить и правильно

төрле тармак галимнәре төбәкләргә экспедиция-сәфәрләр уздырып барлый, таба, өйрәнә... Аннары бу материаллар кабат халыкка кайта, шушы урынның, төбәкнең һәм бердәм татар милләтенең тарихи-мәдәни байлыгына әйләнеп яши бирә.

Татарстандагы академик фән, тарихи, археологик тикшеренүләр белән бергә, төбәкләргә чыгып, урыннарда халыкның яшәешен, көнкүрешен, матди һәм мәдәни хәл-халәтен өйрәнү белән һәрвакыт шөгыльләнә. Мондый тикшеренүләр XIX–XX гасыр чикләрендә үк аерым татар зыялылары инициативасы белән уздырыла башлый: бик күп татар җырларын, әкиятләрен, мәкальәйтемнәрен, миф-легендаларны язып алырга, татарларның телсөйләм үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, К. Насыйри беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, тарихи-этнографик тикшеренү эшен башлап җибәрә, 1871 елдан үзенең «Казан календаре»нда фольклор үрнәкләре бастыра. Бу эшкә Р.Ф. Фәхреддин, Г.Н. Әхмәрев, Х.Б. Бәдигый, Җ.Җ. Вәлиди һ.б. бик күп фикер ияләре кушыла.

XX гасырның аерым чорларында мондый тикшеренүләрне оештыруда активлык күзәтелә. 1920–1930 елларда – бигрәк тә Гыйльми үзәк эшчәнлеге белән бәйле махсус экспедицияләр фәнни нигездә уздырыла башлый. Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Гобәйдуллина, К.С. Гобәйдуллин, С.Г. Вахиди һ.б. тарафыннан Арча, Әлки, Балык Бистәсе, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Чаллы, Чистай төбәкләрендә шундый кыр тикшеренүләре үтә; аларда этнография, фольклор, сәнгать, тарихи-мәдәни мираска караган материаллар туплана.

Мондый эшчәнлек хәтта Бөек Ватан сугышы чорында да тукталмый. 1940–1980 елларда аерым тармак галимнәренең махсуслаштырылган экспедицияләргә чыгуы киң тарала. Бигрәк тә эпиграфик (Һ.В. Йосыпов), археографик һәйкәлләрне (С.Г. Вахиди, М.И. Әхмәтҗанов, М.Г. Госманов һ.б.), диалектларны (Л.Җ. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова һ.б.), төрки-татар фольклорын (Х.Х. Ярмөхәммәтов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Мәхмүтов, Л.Ш. Җамалетдинов һ.б.) җыю-барлау максатыннан, Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче татар авыллары һәм шәһәрләрендә тикшеренүләр уздырыла.

интерпретировать эти явления. Удивительно то, что материалы, не сохранившиеся в археологических и исторических источниках, часто продолжают жить в памяти людей, в повседневном жизненном пространстве населения данной местности! Ученые и специалисты в различных областях знаний во время экспедиций в регионы находят, собирают, изучают эти особенности… А затем эти материалы, после комплексного изучения, возвращаются к народу и продолжают жить, став частью общего историко-культурного наследия татарского народа и данного региона.

Академическая наука Татарстана, наряду с историческими и археологическими изысканиями, всегда держала в центре своего внимания изучение жизни, быта, особенностей материального и культурного состояния татарского народа, проживающего в том или ином регионе. Подобные исследования проводились во время экспедиционных выездов по инициативе представителей татарской интеллигенции, на рубеже XIX–XX веков было записано много татарских песен, сказок, пословиц и поговорок, мифов и легенд; зафиксированы местные особенности татарского языка и речи. Например, К. Насыри одним из первых начал собирать материалы по устному творчеству татарского народа и по исторической этнографии; с 1871 года он регулярно публиковал образцы фольклора в своем «Казанском календаре». К этой работе присоединились Р.Ф. Фахретдинов, Г.Н. Ахмеров, Х.Б. Бадиги, Дж.Дж. Валиди и другие представители татарской интеллигенции.

В отдельные периоды XX века наблюдалась особая активность в организации подобных исследований. В 1920–1930-е годы начинают проводиться специальные научные экспедиции, что было связано с деятельностью созданного Академического центра. Подобные полевые исследования осуществляли Н.И. Воробьев, А.С. Баширов, Ф.И. Терегулов, М.С. Губайдуллина, К.С. Губайдуллин, С.Г. Вахиди и др. в Арском, Алькеевском, Рыбно-Слободском, Мамадышском, Мензелинском, Спасском, Челнинском, Чистопольском районах, собирая при этом материалы по этнографии, фольклору, искусству, историко-культурному наследию данных регионов.

Эта работа не прекращалась даже в годы Великой Отечественной войны. В 1940–1980-е годы широкое распространение

Экспедицияләрдә тупланган материал «Татар халык иҗаты» (1951, 1954), «Татар халык әкиятләре», 2 томда (1946, 1956), «Татар халык җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты», 12 томда (1976–1988), «Татар халык сөйләшләре», 2 томда (2008), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләренең атласы», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) кебек фундаменталь хезмәтләр, мәдәният-сәнгать тарихы, милли һөнәрчелек, кулъязма һәм басма китап тарихы һ.б. өлкәләр буенча күпсанлы китаплар нигезендә ята.

XXI гасыр башында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, бу эш яңа баскычка күтәрелә: һәр елны милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештырыла башлый. Комплекслы рәвештә өйрәнгәндә, тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан-буынга тапшырыла килгән авыз иҗаты үрнәкләре, бәйрәмнәре, йолагадәтләре, музыкасы, бәйләү-чигү кебек кул эшләре осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана һәм җентекләп анализлап бәяләнә. Татарстанда Актаныш (2009), Апас (2010), Кукмара (2011), Чүпрәле (2012), Мамадыш (2013), Арча, Әтнә (2016), Минзәлә, Мөслим (2017), Азнакай, Буа (2019) районнарындагы татар авыллары һәм поселокларында шундый кыр тикшеренүләре уза.

Татарстаннан читтә: Түбән Новгород, Курган, Оренбург өлкәләре (2010), Мари Илендәге Бәрәңге районы (2011), Удмуртия Республикасы (2012), Пермь краендагы Барда районы һәм Әстерхан өлкәсе (2013), Омск һәм Самара (2014), Оренбург һәм Томск (2015), Чиләбе өлкәләре, Казакъстан Республикасы (2016), Новосибирск өлкәсе, Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районы (2017), Ульяновск (2017, 2018), Иркутск, Киров (2018), Пенза, Төмән өлкәләре, Үзбәкстан Республикасы (2019) җирләрендә булып, анда яшәүче милләттәшләребезнең тел-сөйләш үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, кулъязма һәм ташъязма мирасын барлау, аларны фәнни эшкәртү, тикшерү эше җайга-системага салына.

получили специализированные экспедиции. В Татарстане и за его пределами, в местах компактного проживания татар, проводились исследования по сбору эпиграфических (Х.В. Юсупов), археографических (С.Г. Вахидов, М.И. Ахметзянов, М.Г. Усманов и др.) памятников, изучению диалектов (Л.Дж. Заляй, Л.Т. Махмутова, Н.Б. Бурганова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова и др.), образцов тюрко-татарского фольклора (Х.Х. Ярмухаметов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Махмутов, Л.Ш. Замалетдинов и др.). Собранные в экспедициях материалы легли в основу таких фундаментальных трудов, как «Татарское народное творчество» (1951, 1954), «Татарские народные сказки», в 2-х томах (1946, 1956), «Татарские народные песни» (1965), «Татарское народное творчество», в 12 томах (1976–1988), «Татарские народные говоры», в 2-х томах (2008), «Диалектологический словарь татарского языка» (2009), «Атлас говоров татарского народа», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) и многочисленных книг по истории культуры и искусства, народных ремесел, истории татарской рукописной и печатной книги и др.

В начале XXI века, благодаря системным усилиям Академии наук Республики Татарстан, эта работа вышла на новый уровень: началась организация комплексных экспедиций в регионы проживания представителей татарского народа. В ходе комплексного изучения собираются, тщательно оцениваются и анализируются все богатства духовной сокровищницы региона: язык, литература, фольклор, искусство, то есть все то, что передавалось из поколения в поколение – образцы устного творчества, праздничные традиции, обрядовая культура, музыка, искусство вышивки, убранство домов, одежда, особенности языка, эпиграфическое и археографическое наследие. В Татарстане подобного рода полевые исследования были проведены в деревнях и селах Актанышского (2009), Апастовского (2010), Кукморского (2011), Дрожжановского (2012), Мамадышского (2013), Арского, Атнинского (2016), Мензелинского, Муслюмовского (2017), Азнакаевского, Буинского (2019) районов.

За пределами Татарстана также налажена системная работа по сбору, научной обработке, изучению особенностей говоров, повседневного быта, культуры, искусства, рукописного и

Экспедициядә җыйган материалларны тикшерү, өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, шушы вакыттан Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1940–2000 елларда шул ук төбәкләргә, авылларга уздырылган экспедиция материалларын барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру башкарыла. Шул җирлектә фәнни хезмәтләр әзерләнә. Әйтик, бүген инде галимнәребез «Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгын төгәлләү алдында.

Элегрәк җыелган һәм яңа гына алып кайтылган материалларны бергә туплау «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә «Милли-мәдәни мирасыбыз» гомуми исеме астында фәнни-популяр китаплар әзерләү эшен башлап җибәрергә этәргеч була. Бу эшнең максаты – халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, аны популярлаштыру, тарихка кертеп калдыру, шушы мәгълүматлар ярдәмендә татар халкының милли үзаңын ныгыту.

Бүген инде бу сериядән 20 китап дөнья күрде, яңаларын әзерләү дәвам итә. Китапларда экспедиция үткән һәр төбәкнең мәдәни тарихы, танылган нәселләр, авыллар-шәһәрләрнең үткәне, гореф-гадәтләре һәм тел үзенчәлекләре төрле яктан яктыртыла. Шулай ук шәҗәрәләр, җирле кул осталарының эш үрнәкләре, кызыклы экспонатлар турында бай мәгълүмат бирелә.

Татар халкының рухи асылын, тарихи-мәдәни сыйфатбилгеләрен бербөтен итеп күзаллау һәм тергезүнең иң нәтиҗәле һәм ышанычлы ысулы булып фәнни экспедицияләр, кыр тикшеренүләре тора. Чөнки бу яшәеш бик борынгыдан килә, татар халкы Евразиянең гаять киң территориясендә формалашкан! Төрле табигый, тарихи, конфессиональ шартларда, төрле этник тирәлектә (төрки халыкларның төрле төркемнәре, фин, угор, славян этнослары янәшәсендә) татарларның этнотерриториаль (Идел-Урал буе, Себер, Әстерхан татарлары), субэтник (Казан, Касыйм татарлары, мишәрләр), субконфессиональ (керәшеннәр, иштәкләр, нагайбәкләр) төркемнәре барлыкка килгән. Бу төркемнәр кая гына яшәвенә карамастан, гомумтатар милли үзаңына ия. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм

эпиграфического наследия татар, проживающих в Нижегородской, Курганской, Оренбургской областях (2010), Параньгинском районе Марий Эл (2011), Удмуртской республике (2012), Бардымском районе Пермского края и Астраханской области (2013), Омской и Самарской (2014), Оренбургской и Томской (2015), Челябинской областях и Республике Казахстан (2016), Новосибирской области и Стерлибашевском районе Республики Башкортостан (2017), Ульяновской (2017, 2018), Иркутской и Кировской областях (2018), Пензенской, Тюменской областях и Республике Узбекистан (2019).

Наряду с исследованием, изучением и введением в научный оборот материалов, найденных в экспедициях, ведется работа по сопоставлению новых сведений с материалами, которые были собраны в этих местах ранее – в 1940–2000-х годах и хранятся сейчас в архиве ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. На их основе готовятся серьезные научные труды. К слову, на сегодняшний день завершается работа над фундаментальным 25-томным сводом «Татарское народное творчество».

Проведенные исследования на основе объединения всего комплекса собранных материалов позволили начать работу по подготовке научно-популярных книг под общим названием «Национально-культурное наследие» из серии «Из сокровищницы научных экспедиций». Возвращение народу духовного наследия, популяризация и сохранение его в анналах истории способствует укреплению национального самосознания татарского народа.

На сегодняшний день увидели свет 20 книг из этой серии, продолжается подготовка новых. В книгах представлены обширные сведения по истории региона, прошлом известных татарских родов, деревень и городов, а также об обычаях, традициях и языковых особенностях татар. Вместе с тем в книгах дается богатая информация о родословных, работах местных умельцев и других интересных экспонатах.

Единственно надежным и достоверным способом составления общего представления о духовных основах и историко-культурных особенностях татарского народа является организация научных экспедиций и полевых исследований. Это связано с тем, что образ жизни татар формировался с древних времен и на очень

сәнгать институты уздыра торган экспедиция материаллары нәкъ шул хакта сөйли, һәр сәфәр шушы фикерне куәтли.

Әлбәттә, уртак милли үзаңның нигезен татар теле тәшкил итә. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә караган татар теле иң борынгы телләрдән санала. Татар теленең төп лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләре борынгы төрки телдә үк формалаша. Шуңа күрә дә дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче татарларның, төрле сөйләш вәкилләре булсалар да, тел-сөйләмнәре уртак лексик, фонетик, грамматик калыпларга-кануннарга нигезләнә. Шуңа күрә без борынгы рун язулы истәлекләрне укып, эчтәлегенә төшенә алабыз, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан һ.б. төрки телләрне дә аңлыйбыз, татар теленең төрле диалектларында да зур аермалар сизмибез.

Татар милли әдәби теле исә XIX–XX гасырлар чигендә Казанда, Уфада, Оренбургта, Троицкида, Әстерханда һ.б. шәһәрләрдә һәм алар тирәсендәге авылларда гомумхалык теле булып оешып җитә. Тукай теле, Туфан теле, Еники теле – барыбыз өчен дә уртак байлык. Татар әдәби теленең үсеше барышында кайбер традицион хасиятләр һәм формалар югала, әмма алар сөйләшләрдә сакланып кала. Димәк, төрле урыннарда компактлы яшәгән татарларның сөйләшләре борынгы уртак телебезнең үзенчәлекләрен югалтмавы белән дә кадерле. Экспедицияләр материалы безгә шул хакта да сөйли.

Татарларның мәҗүси заман ышанулары ислам дине белән бәйле күзаллаулары белән беррәттән бүген дә халык арасында яши. Бигрәк тә безнең халкыбыз тарихында мең еллык урыны булган ислам диненең һәм матди, һәм мәдәни тормышка йогынтысы халыктан җыелган материалларда аермачык күренә. Каберташ язмалары, борынгы китаплар һәм кулъязмалар, шәкерт дәфтәрләре, күчереп язылган текстлар, әдәп-әхлак кагыйдәләре, йола-гадәтләр, ышанулар һәм күзаллаулар, бәйрәмнәр һәм ырымнарда татар халкының барлык этник төркемнәре өчен уртак булган мәдәни мирас чагылыш таба. Ислам мәдәнияте гадәти көнкүреш һәм кеше тормышындагы иң мөһим вакыйгаларга (туу, исем кушу, өйләнү, гаилә, бакыйлыкка күчү) бәйле йолаларда этник мәдәнияткә үрелеп китә. Вакытны күрсәткән азан тавышы,

обширной территории Евразии. Различные этнотерриториальные (татары Волго-Уральского региона, сибирские, астраханские татары), субэтнические (казанские, касимовские татары, мишары), субконфессиональные (кряшены, иштяки, нагайбаки) группы татар сформировались в разнообразных природных, исторических, конфессиональных условиях и в сложном этническом окружении (рядом с разными группами тюркских народов, финно-угорскими, славянскими этносами). Несмотря на то, что данные группы татар проживают на различных территориях, они все объединены общетатарским национальным самосознанием. Каждая экспедиция ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ и собранные материалы неуклонно подтверждают это.

Разумеется, фундаментом общего национального самосознания является язык. Татарский язык, относящийся к кипчакской группе, считается одним из самых древних языков. Основные лексические, фонетические, грамматические особенности татарского языка сформировались уже в древнетюркском языке. Именно поэтому татар, проживающих в разных местах и являющихся представителями разных говоров, объединяет единая основа – общие лексические, фонетические, грамматические закономерности. Благодаря этому мы можем понять самые древние рунические письмена, понимаем казахский, узбекский, азербайджанский и другие языки, не ощущаем большой разницы между диалектами татарского языка.

Становление татарского литературного языка в качестве общенародного происходит на рубеже XIX–XX веков в городах Казань, Уфа, Оренбург, Троицк, Астрахань и др., а также окружающих их селах. Язык Тукая, язык Туфана, язык Еники – это наше общее богатство. В ходе развития татарского литературного языка теряются некоторые его традиционные свойства и формы, но они сохраняются в говорах. Поэтому говоры татар, компактно проживающих на разных территориях, ценны для нас сохранением особенностей нашего древнего общего языка. Материалы экспедиций говорят именно об этом.

В народе и сегодня продолжают сосуществовать древние домусульманские верования татар и представления, связанные с исламом. Материалы экспедиций особенно ярко демонстрируют

намаз-догалар, җомга көнне бәйрәм дип карау белән бергә, татар халкының мәдәни хәтеренә бәетләр, мөнәҗәтләр, дини-суфичыл текстлар кереп урнаша. Традицион йолалар һәм бәйрәмнәр: Сабан туе, Җыен, Корбан гаете, Ураза гаете, өмәләр, Карга боткалары һәм Яңгыр боткалары – болар да уртак байлыгыбыз һәм татарлыгыбызның аерылгысыз билгеләре.

Комплекслы экспедицияләр вакытында төрле җирлекләрдә кием-салым, һөнәрләр, азык-төлек әзерләү рәвеше, архитектура, музыка сәнгате буенча да күзәтүләр ясала. Әйтик, төрле җирләрдә яшәүчеләрнең киемнәрендә үзгәлекләр булса да, татарларның традицион гомуммилли өс киеме Казан татарларыныкы йогынтысында формалашкан дигән фикер безнең материаллар белән дә тагын бер тапкыр раслана. Татарлар кайда гына төпләнмәсен – мәчет торгыза. Халкыбызның һәрчак белемгә омтылышы, балалар тәрбияләүгә зур әһәмият бирүе, олыларга аерым бер хөрмәт белән каравы, туган җир һәм нәсел-ыруның һәр кешене саклаучы-яклаучы көч дип санавы, шигърияткә-иҗатка тартылуы да кыр тикшеренү нәтиҗәләрендә чагылыш таба.

Республикабыздагы күтәрелеш татар дөньясының җанлануына, милли үзаң уянуга, татарларның үзләрен бердәм халык итеп тоя башлавына китерде. Хәтта элек-электән туган җирләре, ватаннары бик еракта – әйтик, Польшада яки Литвада, Әстерханда яки Иранда, Уралда яки Себердә, Кытайда яки Финляндиядә булса да, уртак тарих, уртак мәдәният һәм Казан, Татарстан татарларны берләштереп торган үзәк булып кала.

Һәр милләт булып җитешкән бердәмлек төрле мәдәниятләрнең хасиятләрен үзенә туплый. Бу – аксиома. Көчле мәдәният үз тирәсенә башкаларны тарту сәләтенә ия. Алтын Урда чорында ук «татар казаны» күп кабиләләрне кайната, шул исәптән болгарларны да татар политонимына юнәлдерә.

Татар тарихы сикәлтәле, б.э.к. III гасырдан башлап язма истәлекләрдә эз калдыра. Шул ерак гасырлар чоңгылында Бөек кытай диварыннан төньяктарак төрки телле һуннарның империясе төзелә. II гасырда ул хәзерге Казакъстан далаларына күченә. Идел һәм Урал арасында угорлар белән укмаша, IV гасырда Европага юнәлә, халыкларның Бөек күчешен башлап

влияние ислама на материальную и культурную жизнь нашего народа на протяжении его тысячелетней истории. Общее культурное наследие всех этнических групп татар ярко выражены в надгробных памятниках, древних книгах и рукописях, тетрадях шакирдов, списках литературных произведений, нравственно-этических нормах, обрядах и обычаях, представлениях и поверьях, праздниках и верованиях. В моменты самых важных событий человеческой жизни (рождение, имянаречение, свадьба, семейная жизнь, похороны) традиции исламской культуры тесно переплетаются с обрядами этнической культуры. Наряду со звуками азана, по которым определяли время, с молитвами, с обычаем считать пятницу праздничным днем и т. д. в культурную память татарского народа вошли баиты, мунаджаты, религиозно-суфийские тексты. Наши традиционные обряды и праздники: Сабантуй, Джиен, Курбан байрам, Ураза байрам, коллективные помочи (өмә), обряды вызывания дождя и встречи весны – все это тоже наше общее наследие и то, что делает нас татарами.

Во время комплексных экспедиций в различные места проживания татар изучаются одежда, ремесла, традиции приготовления пищи, архитектура, музыкальное искусство и т. д. Например, наши материалы ещё раз подтвердили мысль о том, что, несмотря на некоторые различия в одежде татар разных регионов, очевидно, что традиционная национальная татарская одежда сформировалась под влиянием казанских татар. Где бы ни селились татары, они воздвигали мечети. Стремление народа к знаниям и просвещению, большое внимание, которое они уделяют воспитанию детей, особое уважение к пожилым, почитание родной земли и своего рода – как оберегающих и защищающих сил, склонность к поэтическому творчеству – все это отражается в материалах полевых исследований.

Разумеется, современная жизнь татар, где бы они ни жили, связана с Татарстаном. Общественный и духовный подъем в нашей республике способствовал оживлению татарского мира, пробуждению национального самосознания, осознанию татарами себя как единого народа. Даже для татар, чьей родиной давно является Польша или Литва, Астрахань или Иран, Урал или Сибирь, Китай

җибәрә. Һуннарның нәсел тамгасы – казан – безнең башкалабыз Казанның да үзәгендә, Казансу буеннан милләттәшләребезне сәламли.

V гасырда Һун империясе таркала – Бөек кытай диварыннан Дунайга кадәр җирләрдә Бөек Төрки каганлык калкып чыга. Аның җимерелүеннән соң исә Болгар цивилизациясе чәчәк ата. Көнчыгышта куәтле татар халкы үзенең дан-шөһрәтен яңгырата. Алтын Урда таркалгач, аның варислары ханлыклар төзи. Бүген алар касыйм, әстерхан, себер татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр һ.б. атамалар белән исемләндереп йөртелгән төркемнәр буларак билгеле. Аларны бер тел, бер югары мәдәният – Мәрҗани фәһеме, Тукай шигырьләре, Сәйдәш музыкасы, Урманче сурәтләре берләштерә.

Татар асылын, аның рухи үзәген, татарлыкның гомуми һәм үзенчәлекле сыйфатларын аңлау-төшенү өчен, һичшиксез, тарихи барышны гына түгел, бәлки халыкның хәтерендә яшәгән рухи кыйммәтләрне дә барларга, өйрәнергә кирәк. Татарстан Фәннәр академиясе, аның институтлары, шул исәптән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре әлеге юнәлештә эшлиләр. Дөрес, татарлар элек-электән күпләп яшәгән барлык урынчылыклар да өйрәнелгән дияргә иртәрәк әле. Димәк, бу эш дәвам итәргә тиеш.

Фәнни күзлектән караганда, борынгы һәм бай тарихлы, үз әдәби теле, профессиональ әдәбияты һәм сәнгате булган бердәм татар милләте без. XX гасырда татар мәдәнияте, мәгариф һәм фән югары үсеш ала. Бу процесста төрле җирләрдә яшәгән, төрле этнографик төркемнәргә караган татарларның өлеше зур. Безнең көчебез – бердәмлектә!

* * *

Ульяновск өлкәсе Россия Федерациясенең Европа өлешенең көньяк-көнчыгышында, Идел буенда урнашкан. Өлкә 1943 елда оешкан. Мәйданы 37,2 мең км$^2$. 2010 елның статистик мәгълүматлары буенча татарлар саны 149873 кеше тәшкил итә. Өлкәдә татар халкы күпләп яшәгән 67 торак пункт бар. Татарлар Ульяновск, Димитровград, Новоульяновск, Барыш шәһәрләрендә,

или Финляндия, средоточием общей истории, общей культуры и единым связующим звеном остаются Казань и Татарстан.

Каждая общность, достигшая уровня нации, вбирает в себя свойства различных культур. Это – аксиома. Сильная культура обладает способностью консолидировать вокруг себя другие. В эпоху Золотой Орды в «татарском котле» перекипели многие племена, по той же причине название «булгары» стало татарским политонимом.

Перипетии татарской истории нашли отражение в письменных источниках, начиная с III века до нашей эры. В те далекие времена к северу от Великой китайской стены формируется тюркоязычная империя хуннов. Во II веке они переселяются в степи современного Казахстана. Сплотившись с уграми между Волгой и Уралом, они устремились в Европу, начав процесс Великого переселения народов. Не случайно родовая тамга рода хуннов – казан – сегодня приветствует наших соотечественников на берегу реки Казанки в центре Казани.

В V веке Хуннская империя распадается, и на землях от Великой китайской стены и до Дуная возникает Великий Тюркский каганат. После его распада получает расцвет Булгарская цивилизация. Могучий татарский народ во весь голос заявляет о себе на востоке. После распада Золотой Орды её наследники создают отдельные ханства. Сегодня их потомки живут как касимовские, астраханские, сибирские татары, мишари, кряшены, нагайбаки и другие группы. Их объединяют общий язык, общая высокая культура – интеллект и разум Марджани, поэзия Тукая, музыка Сайдашева, творения Урманче.

Для понимания сути народа, его духовной сущности, общих и специфических особенностей татарства, безусловно, надо изучать не только историю, но и сохранившиеся в памяти народа духовные ценности. Академия наук Татарстана, её институты, в том числе ученые ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, работают в данном направлении. Естественно, ещё не все местности и регионы исторического проживания татар охвачены и изучены. Значит, эта работа должна продолжаться.

Если судить с научных позиций, то мы – единая татарская нация с древней и богатой историей, имеющая свой литературный

шулай ук Базарлы Сызган, Барыш, Карсун, Мәләкәс, Николаевка, Яңа Малыклы, Яңа Спасс, Павловка, Радищево, Иске Кулаткы, Чынлы һәм Чардаклы районнарында тупланып яшиләр.

Ульяновск өлкәсе татарларның Себердән Кара диңгезгәчә дәвам иткән тарихи ватаны җирләренең бер өлеше булып тора. Татарлар монда борынгыдан ук яшәгән. Ульяновск өлкәсе территориясе тарихи яктан төрле чорларда Идел буе Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгы составына кергән. Халыкның соңгырак чорлардагы тарихы, бу якларда барган күчү процесслары турында мәгълүмат күбрәк сакланган. XVI гасырның икенче яртысыннан башлап Иделнең уң яры буйлап урнашкан районнарга Темников өязеннән Карсун-Сембер һ. б. чик сызыкларында хезмәт иткән йомышлы татарлар да күченеп килә башлый. XVIII гасырда татарлар Терешка елгасы буйлап, шулай ук Идел аръягында төзелә торган чик сызыклары буендагы җирләрне үзләштерәләр. Һәр чорда үз җирендә хуҗа булып, җир эшкәртеп, төзеп, бизәп, үзенең эзен калдырып яшәгән татар. Телен, динен саклап, мәдәниятен үстереп, башкаларга үрнәк булып яшәгән. Мәсәлән, XIX гасырның II яртысында – XX гасыр башында төбәкнең иҗтимагый тормышында һәм икътисадында татар җәмәгать эшлеклеләре һәм хәйриячеләр, эшмәкәр Абушаевлар һәм Акчуриннар династияләре зур роль уйный. 1853 елда Сембердә сәүдәгәр К.А. Акчурин акчасына гыйбадәт йорты төзелә (1865 елгы янгыннан соң мәчет итеп үзгәртелә). 1896 елда Мәләкәс (хәзерге Димитровград) шәһәрендә мәчет ачыла. 1859 елда Сембер губернасында 135 мәчет, 1913 елда 258 мәчет исәпләнә. 1870 елда биредә – 79, 1895 елда – 132, 1904 елда – 140, 1915 елда 218 мәдрәсә һәм мәктәп эшли.

1908 елда ярлы мөселманнарга матди ярдәм күрсәткән, мәчет һәм руханиларга булышкан, Сембердә татар кызлары өчен мәктәп тоткан Сембер мөселманнары хәйрия җәмгыяте оештырыла. 1910 елларда татар театр коллективлары эшли. 1917 елда Мөселман милли шурасы оештырыла, ул 1917–1918 елларда «Җөмһүрият» газетасын бастыра.

Совет властеның беренче елларында төбәктә татар телендә «Көн» һәм «Таң» (1918–1922 еллар), Мәләкәстә «Мәләкәс

язык, профессиональную литературу и искусство. В XX веке культура, просвещение и наука татарского народа достигли очень высокого уровня. В этом процессе незаменима роль татар, проживающих в разных регионах и представляющих различные этнографические группы. Ведь наша сила – в нашем единстве!

* * *

Ульяновская область расположена на юго-востоке Европейской части России, на берегу Волги. Область была сформирована в 1943 году. Ее площадь составляет 37,2 тыс. км$^2$. Согласно статистическим данным в 2010 году численность татар достигала 149 873 человека. В 67 населенных пунктах области татары проживают в большом количестве, это города Ульяновск, Димитровград, Новоульяновск, Барыш и села Базарносызганского, Барышского, Карсунского, Мелекесского, Николаевского, Новомалыклинского, Новоспасского, Павловского, Радищевского, Старокулаткинского, Цильнинского и Чердаклинского районов.

Эти земли – часть древней исторической родины татар, которая простиралась некогда от Сибири до Черного моря. Татары жили здесь издревле. Территория Ульяновской области в разные исторические эпохи входила в состав Волжской Булгарии, Золотой Орды, Казанского ханства. Наибольшей сохранностью обладают исторические источники более поздних эпох. Начиная со второй половины XVI века в районы правобережья Волги начали переселяться служилые татары из Темниковского уезда, несшие службу на засечных линиях Карсун – Симбирск и др. пограничных территориях. В XVIII веке татары осваивают земли вдоль реки Терешки, а также территории за Волгой вдоль сооружаемых засечных линий. В каждую историческую эпоху татары были хозяевами на своей земле, пахали, сеяли, строили, украшали, свято берегли свой язык и веру, развивали культуру и по праву могли считаться образцом для соседних народов. Например, во второй пол. XIX – нач. XX вв. большую роль в общественной и экономической жизни края играли династии Акчуриных и Абушаевых – общественных деятелей, предпринимателей, благотворителей. В 1853 году в Симбирске на средства купца К.А. Акчурина был

тавышы» (1918), «Урак һәм чүкеч» (1919–1921) һәм «Яңа авыл» (1923–1925) газеталары чыга. 1918 елда Сембердә татар китапханәсе ачыла, аның базасында драма түгәрәге эшли, спектакльләр куела, концертлар, ял кичәләре оештырыла. 1930–1950 елларда Мәләкәс (1943–1958) һәм Ульяновск шәһәрләрендә татар мәктәпләре өчен башлангыч сыйныф укытучылары әзерләгән төркемнәр оештырыла. 1931–1935 елларда – Ульяновск татар педагогия техникумы, 1943 елда Самара өлкәсенең Камышлы авылына күчерелә. Совет чорында Сембер төбәге территориясендә татарларның традицион үзенчәлекле хуҗалык итү рәвеше, көндәлек тормыш-көнкүреше үзгәрә, элекке икътисади, мәдәни һәм дини бәйләнешләр җимерелә, бу исә милли мәгарифнең түбән тәгәрәвенә, мәчетләр ябылуга китерә.

СССР таркалу, милли факторның көчәюе һәм халыкларның этник үзаңы үсү нәтиҗәсендә Ульяновск өлкәсе татарларының социаль-икътисади тормышында шактый зур үзгәрешләр барлыкка килә.

Хәзерге вакытта милли-мәдәни җәмгыятьләр эшли: «Туган тел» (1988 елдан), «Мәдәният» (1991 елдан), «Өмет» (1992 елдан, Димитровград шәһәре), «Ак калфак» (2005 елдан), өлкә татар милли-мәдәни автономиясе (1998 елдан башлап, барлык районнарда бүлекчәләре бар), татар язучылары берләшмәсе (2000 елдан), «Болгар яңарышы» иҗтимагый агарту оешмасы (2003 елдан), көрәш федерациясе (2008 елдан башлап), «Яңа дулкын» яшьләр оешмасы (2009 елдан башлап). 1995 елда фольклор концертлары, тематик кичәләр, татар халык иҗат коллективлары оештыру белән шөгыльләнә торган Татар мәдәният үзәгенә нигез салына.

Ульяновск өлкәсе татарларының мәдәнияте белән галимнәр инде берничә дистә еллар дәвамында кызыксыналар. Институтның Ульяновск өлкәсенә махсус экспедицияләре XX гасыр урталарыннан ук оештырыла.

Ульяновск өлкәсе территориясендә татар теленең көнбатыш диалектына караган хвалын, карсун, мәләкәс сөйләшләре таралган. 1950 еллар уртасыннан башлап (1956, 1960–1966, 1969, 1975, 1982, 1983, 1990) татар теле белгечләре – диалектологлар Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Г.К. Якупова, Д.Б. Рамазанова,

построен молельный дом (после пожара 1865 года был переделан в мечеть). В 1896 году в Мелекесе (ныне Димитровград) была открыта мечеть. В 1859 году в Симбирской губернии насчитывалось 135 мечетей, в 1913 году – 258. В 1870-м году функционировали 79 медресе и мектебов, в 1895-м – 132, в 1904-м – 140, в 1915 – 218.

В 1908 году был создан Благотворительный фонд симбирских мусульман, который оказывал мусульманам материальную помощь, помогал мечетям и духовным лицам, содержал в Симбирске татарскую школу для девочек. В 1910-х гг. здесь работали татарские театральные коллективы. В 1917 году был организован Мусульманский национальный совет, который в 1917–1918-х гг. издавал газету «Җөмһүрият».

В первые годы советской власти в Симбирске издавались газеты «Көн» и «Таң» (1918–1922-е гг.), в Мелекесе – «Мәләкәс тавышы» (1918), «Урак һәм чүкеч» (1919–1921) и «Яңа авыл». В 1918 году в Симбирске открылась татарская библиотека, при ней начал работать драмкружок, ставились спектакли, концерты, устраивались вечера отдыха. В 1930–1950-е гг. в Мелекесе и Ульяновске были организованы группы по подготовке учителей начальных классов для татарских школ. В 1931–1935 гг. в Ульяновске действовал татарский педагогический техникум, который в 1943 году был перенесен в д. Камышла Самарской области. В советский период истории традиционный образ жизни и хозяйствования татар изменились, прежние экономические, культурные и религиозные связи были нарушены, что, в свою очередь, привело к краху национальной системы просвещения, закрытию мечетей.

Общественно-политические процессы, начавшиеся после распада СССР, привели к усилению национального фактора и росту этнического самосознания народов. В связи с этим значительные изменения произошли и в социально-экономической жизни татар Ульяновской области.

В настоящее время в области действуют национально-культурные организации «Туган тел» (с 1988 г.), «Мәдәният» (с 1991 г.), «Өмет» (с 1992 г., Димитровград), «Ак калфак» (с 2005 г.), областная татарская национально-культурная автономия (работает с 1998 года, имеет отделения во всех районах),

Ф.С. Баязитова, З.Р. Садыйкова һәм Т.Х. Хәйретдинова диалектологик экспедицияләрдә катнашалар һәм алда санап үтелгән сөйләшләрне өйрәнәләр. Ульяновск өлкәсе татарларының тарихы, тормышы һәм көнкүреше, гореф-гадәтләре, тел үзенчәлекләре галимнәрнең күпсанлы фәнни, фәнни-популяр хезмәтләрендә чагылдырыла.

1964–1965 елларда танылган фольклорчы Х. Ярми җитәкчелегендә Ульяновск өлкәсенә фольклор экспедицияләре оештырыла. Х. Ярми, Х. Гатина, И. Надиров, Ф. Урманчеев, Х. Мәхмүтов, Т. Галиуллин, А. Йосыпов, С. Исәнбаев халык иҗаты үрнәкләрен язып алып кайталар, Институт архивын баеталар. Өлкәдә җыелган материалларның бер өлеше татар халык авыз иҗаты әсәрләренең 12 томлык җыелмасында (1976–1988) дөнья күрде. Ульяновск өлкәсе татарларыннан язып алынган җырлар, мәкальләр һәм әйтемнәр, әкиятләр, бәетләр, риваятьләр һәм легендаларга әлеге томнарда зур урын бирелгән.

2017–2018 елларда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Ульяновск өлкәсендә кабат булдылар. Коллектив тикшеренүләрнең максаты – татар халык авыз иҗаты, язма һәм музыкаль мирас, татар халкының тел үзенчәлекләрен җыю һәм өйрәнү. 2017 елда И.И. Ямалтдинов (экспедиция җитәкчесе, фольклорчы), Ф.З. Яхин (археограф), Н.Х. Нургаянова (музыка белгече), Ф.С. Баязитова, М.Р. Булатова (диалектологлар), Ф.И. Таһирова (тел белгече) һәм М.Р. Газизова (сәнгать белгече) катнашындагы комплекслы экспедиция Иске Кулаткы районының Иске Атлаш (Старый Атлаш), Муса (Мосеевка), Иске Мостяк (Старый Мостяк), Яңа Мостяк (Новый Мостяк), Урта Терешка (Средняя Терешка), Яңа Терешка (Новая Терешка), Киръявыл (Кирюшкино), Иске Зеленай (Старое Зеленое), Вязовый Гай, Зимичә (Зимницы), Иске Кулаткы (Старая Кулатка), Иске Яндука (Старая Яндовка), Карсун районының Нугай иле (Нагаево), Сакускай (Уразово), Татар Гуринкасы (Татарские Горенки), Аксу (Татарская Голышевка), Мәләкәс районының Атнагыл (Аллагулово), Мукшы Күле (Мордово-Озеро), Мөси (Моисеевка), Филип (Филипповка), Парау (Боровка) авылларында – барлыгы 22 торак пунктта эшләде.

объединение татарских писателей (с 2000 г.), общественно-просветительская организация «Болгар яңарышы» (с 2003 г.), федерация вольной борьбы (көрәш) (с 2008 г.), молодежная организация «Яңа дулкын» (с 2009 г.). В 1995 году был основан Татарский культурный центр, который занимается организацией фольклорных концертов, тематических вечеров, продвижением татарских народных творческих коллективов.

Традиционной культурой ульяновских татар ученые интересуются на протяжении нескольких десятков лет. Специализированные экспедиции ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова работали в Ульяновской области уже в середине XX века.

На территории Ульяновской области распространены хвалынский, карсунский, мелекесский говоры западного диалекта татарского языка. С середины 1950-х гг. (1956, 1960–1966, 1969, 1975, 1982, 1983, 1990) эти говоры изучали татарские ученые-диалектологи Л.Т. Махмутова, Н.Б. Бурганова, Г.К. Якупова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова, З.Р. Садыкова и Т.Х. Хайретдинова. История татар Ульяновской области, традиции повседневности, обряды, верования, особенности языка – все это нашло отражение в многочисленных научных и научно-популярных трудах татарстанских ученых.

В 1964–1965 годы в Ульяновскую область были организованы фольклорные экспедиции под руководством известного фольклориста Х. Ярми. Члены экспедиций – Х. Гатина, И. Надиров, Ф. Урманчеев, Х. Махмутов, Т. Галиуллин, А. Юсупов, С. Исенбаев – записали большое количество образцов устного народного творчества татар и существенно пополнили архив института. Часть этих материалов увидела свет в составе 12-томного собрания произведений татарского устного народного творчества (1976–1988). Песням, пословицам и поговоркам, сказкам, баитам, сказаниям и легендам, записанным у татар Ульяновской области, в этих томах отведено значительное место.

Ученые Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова побывали в Ульяновской области в составе научных экспедиций в 2017-м и 2018-м годах. Целью были сбор и изучение фольклора, письменного и музыкального наследия,

2018 елда комплекслы экспедиция составына түбәндәге 5 белгеч керде: И.И. Ямалтдинов (экспедиция җитәкчесе, фольклорчы), Л.М. Шкляева (сәнгать белгече), Г.Ф. Юнысова (музыка белгече), А.И. Әхмәтова (археограф), В.М. Усманов (эпиграфика). Алар 22 торак пунктта тикшеренүләр алып барды. Павловка районының Йәүли (Евлейка), Муратовка, Татар Шомалагы (Татарский Шмалак), Николаевка районының Татар Сайманы (Татарский Сайман), Әхмәтле (Ахметлей), Зур Чирекле (Большой Чирклей), Чардаклы районының Чардаклы (Чердаклы), Үрән (Енганаево), Абдулла (Абдуллово), Әсән (Асаново), Татар Колмаеры (Татарский Калмаюр), Кызылсу (Уразгильдино), Папау (Поповка), Иске Үрәнбаш (Старый Уренбаш), Кечкенә Үрәнбаш (Малаевка), Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер (Старый Сантимир), Урта Исәнтимер (Средний Сантимир), Өчкаен (Эчкаюн), Әбдери (Абдреево), Лабит (Лабитово), Зирекле Куак (Елховый Куст), Иске Төгәлбуга (Старая Тюгальбуга) авыллары өйрәнелде.

Галимнәр кыр тикшеренүләре барышында Ульяновск өлкәсенең 7 районындагы 40 тан артык торак пунктны өйрәнделәр. Нәтиҗәдә – тел, фольклор, сәнгать, музыка, археография, эпиграфика, шулай ук татар халкының традицион мәдәниятенә караган материаллар тупланды.

Җыентыкта экспедиция нәтиҗәсендә табылган, шулай ук басылган яисә архив материалларына чагыштырма аспектта анализ ясалган фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр, халык иҗаты үрнәкләре, Ульяновск өлкәсе татарларының археографик мирасының тасвирламалары һәм башка документлар урын алды.

Болар барысы да – халык авыз иҗатының, теленең, милли сәнгатенең, мәдәниятенең һ.б. тере яшәешен үз күзләре белән күреп, белгеч күзлегеннән бәя биреп язылган хезмәтләр. Аларда шушы төбәктән табып алып кайтылган үрнәкләр чагылыш тапкан, яңа материалларның беренчел фәнни әйләнешкә кертелүләре, нигездә, нәкъ менә шушы җыентыкта тормышка ашырыла.

Моннан тыш җыентыкта Ульяновск өлкәсендә туып үскән, хәзерге вакытта Казанда һәм Ульяновскида эшләүче галимнәрнең фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләре урын алды. Әлеге

особенностей языка местных татар. Экспедиция 2017-го года в составе И.И. Ямалтдинова (руководитель экспедиции, фольклорист), Ф.З. Яхина (археограф), Н.Х. Нургаяновой (музыковед), Ф.С. Баязитовой и М.Р. Булатовой (диалектологи), Ф.И. Тагировой (языковед) и М.Р. Газизовой (искусствовед) исследовали села Старый Атлаш, Мосеевка, Старый Мостяк, Новый Мостяк, Средняя Терешка, Новая Терешка, Кирюшкино, Старое Зеленое, Вязовый Гай, Зимницы, Старая Кулатка, Старая Яндовка Старокулаткинского района, села Нагаево, Уразовка, Татарские Горенки, Татарская Голышевка Карсунского района и села Аллагулово, Мордово-Озеро, Моисеевка, Филипповка, Боровка Мелекесского района – всего 22 населенных пункта области.

В состав комплексной экспедиции 2018 года вошли 5 специалистов: И.И. Ямалтдинов (руководитель, фольклорист), Л.М. Шкляева (искусствовед), Г.Ф. Юнусова (музыковед), А.И. Ахметова (археограф), В.М. Усманов (специалист по эпиграфике). Ими были охвачены населенные пункты: Евлейка, Муратовка, Татарский Шмалак, Павловского района; Татарский Сайман, Ахметлей, Большой Чирклей Николаевского района; Чердаклы, Енганаево, Абдуллово, Асаново, Татарский Калмаюр, Уразгильдино, Поповка, Старый Уренбаш, Малаевка Чердаклинского района; Старый Сантимир, Средний Сантимир, Эчкаюн, Абдреево, Лабитово, Елховый Куст, Старая Тюгальбуга Новомалыклинского района.

В ходе полевых исследований ученые обследовали более сорока населенных пунктов в 7 районах Ульяновской области. Собранные ими материалы – это образцы фольклора, особенности говоров, произведения искусства, образцы археографического наследия, эпиграфики, а также информация, касающаяся татарской народной традиционной культуры.

В сборник вошли научные и научно-популярные статьи, посвященные анализу образцов духовного и материального наследия, собранных во время экспедиций, описания археографического наследия татар Ульяновской области, а также архивные материалы и документы, имеющие отношение к теме.

Все это – труды, написанные специалистами, которые исследовали устное народное творчество, язык, национальное искусство,

җыентыкны тарихчы Р.В. Шәйдуллинның Ульяновск өлкәсе татарлары тарихына багышланган фәнни мәкаләсе ача.

Ульяновскида Р.К. Садыйкова өлкәдә яшәгән татарларның телен, халык авыз иҗатын, йолаларын һәм бәйрәмнәрен, Сембер-Ульяновск төбәге тарихын өйрәнү, милли кадрлар әзерләү буенча күпкырлы эшчәнлек алып бара. Р.К. Садыйкованың «Халкыбыз җәүһәрләре» (2011), «Жемчужины татарского народа» (книга первая, 2012), «Таулы-чишмәле Кулаткы ягы» (2018) китапларында Сембер төбәге татарлары, Ульяновск өлкәсе белән бәйле тарихи-этнографик эчтәлектәге фәнни һәм публицистик мәкаләләре, шулай ук өлкәнең татар авылларыннан җыелган халык авыз иҗаты әсәрләре тупланып бирелгән. Аның аерым мәкаләләре безнең җыентыкта да урын алды.

Экспедицияләр эшендә актив катнашып, халкыбызның рухи җәүһәрләрен туплауда үзләреннән зур өлеш керткән информантларга һәм әлеге игелекле чараны оештыруда зур ярдәм күрсәткән Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы, Карсун, Мәләкәс, Павловка, Николаевка, Чардаклы, Яңа Малыклы районнары җитәкчеләренә һәм җирле үзидарә башлыкларына, мәдәният хезмәткәрләренә олуг рәхмәтебезне белдерәбез.

***Ким Миңнуллин,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*мөхбир әгъзасы*

культуру, непосредственно контактируя с их носителями, в живом общении. Многие материалы, обнаруженные во время экспедиций, впервые вводятся в научный оборот.

Кроме этого в книгу вошли статьи ученых – уроженцев Ульяновской области. Сборник открывается научной статьей историка Р.В. Шайдуллина, посвященной истории татар Ульяновской области.

В Ульяновске живет и работает Р.К. Садыкова, которая ведет многогранную деятельность по изучению языка, фольклора, обрядов и праздников ульяновских татар, истории Симбирско-Ульяновского края, а также по подготовке национальных кадров. В ее книги «Народные жемчужины» (на тат. яз., 2011), «Жемчужины татарского народа» (на тат. яз., кн. 1, 2012), «Горный и родниковый Кулаткинский край» (на тат. яз., 2018) вошли научные и публицистические статьи историко-этнографического содержания, связанные с симбирскими татарами и Ульяновской областью, а также произведения устного народного творчества, собранные в татарских селах области. Некоторые статьи Р.К. Садыковой представлены и в нашем сборнике.

Выражаем искреннюю благодарность информантам, которые приняли деятельное участие в исследовательской работе ученых, а также руководителям Старокулаткинского, Карсунского, Мелекесского, Павловского, Николаевского, Чердаклинского, Новомалыклинского муниципальных районов области, главам местного самоуправления, работникам культуры за огромную помощь и поддержку в проведении исследовательской работы.

***Ким Миннуллин,***
*директор Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова,*
*член-корреспондент Академии наук*
*Республики Татарстан*

# ТАТАРЫ УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ

*Рафаэль Шайдуллин*

Причем, в первые десятилетия советской власти с введением всеобщего начального, затем семилетнего образования значительно повысился уровень образованности татар на татарском и русском языках. Это дало возможность татарам поступать не только в училища и техникумы, но и в высшие учебные заведения страны. Однако перевод в 1960-е гг. всех татарских школ Ульяновской области с татарской формы обучения на русскую и оставлением в качестве обязательно-факультативных предметов татарского языка и татарской литературы усилил процесс русификации татарского общества и рост в нем этнического нигилизма, что, в

конечном итоге, негативно сказалось на формировании татарской этнокультурной идентичности.

Современная татарская общность – это горделивое и дружелюбное этническое сообщество, которое стремится к тесному взаимному общению, к упрочению связей с другими этносами, проживающими на территории Ульяновской области. Ульяновская администрация делает многое для сохранения и развития татарской культуры, языка и национальных традиций. В 1989 г. в Ульяновске был создан Дом дружбы народов, позже преобразованный в Центр по возрождению и развитию национальных культур Ульяновской области, вышел в свет первый номер татарской газеты «Өмет» («Надежда»), а на ГТРК «Волга» начала работу передача на татарском языке «Чишмә». Центр татарской культуры внес большой вклад в популяризацию национальных культурных традиций, народного искусства, обрядов татарского народа. В 1995 г. при нем заработали коллективы художественной самодеятельности: ансамбль песни и танца «Сембер», детский хореографический ансамбль «Йолдыз», театральный коллектив, ансамбль народных инструментов «Җидегән». Ежегодно проводятся областные фестивали татарской культуры: «Сембер җыры» («Симбирская песня»), детские «Сембер кыңгыраулары» («Симбирские колокольчики»), «Шома бас» («Танцуй веселей»), а также организуются фольклорно-театрализованные обрядовые представления: «Нәүрүз», «Каз өмәсе», праздники семьи, конкурсы, встречи с интересными людьми.

С апреля 1997 г. в Ульяновске работает национально-культурная автономия татар, которая в июне 1998 г. была преобразована в Ульяновскую областную татарскую национально-культурную автономию. Первым ее председателем был избран А.Г. Курчаков, с 2011 г. новым руководителем стал Р.Ф. Сафин. Под эгидой автономии действуют татарский культурный центр «Туган тел», общество «Мөслимә», общества «Булгарское возрождение», «Ак калфак», объединение татарских бизнесменов «Сембер», национально-культурное общество «Мәдәният», молодежный клуб «Мирас», Татарский молодежный центр Ульяновской области,

просветительское общество «Өмет» (г. Димитровград), открыты 88 татарских школ и 134 факультативных кружка по изучению языка и культуры, совместно с администрацией Ульяновской области издается татарская газета «Өмет» (бессменный редактор И.Х.Халимов). В июле 2007 г. в эфире Ульяновского телеканала «2х2» вновь зазвучала татарская речь в передаче «Чишмә». Действуют 30 самодеятельных татарских театров и коллективов, 2 народных театра (в сс. Средний Сантимир, Старая Кулатка).

В консолидации татар Ульяновской области большую роль играет тесная этнокультурная связь с Республикой Татарстан. На протяжении почти 30 лет проводятся различные совместные культурно-массовые мероприятия, которые сегодня объединяют многие территориальные группы татарского народа. Постоянными участниками ульяновских татарских фестивалей являются творческие коллективы из Татарстана, среди них фольклорный музыкальный ансамбль «Сорнай», ансамбль танца «Казан». Ульяновской области республика оказывает большую поддержку при проведении различных культурных и праздничных мероприятий. Татарстанцы приезжают в Ульяновск со своими творческими коллективами, выставками изделий народных мастеров, а также привозят с собой книги и учебники на татарском языке, методическую литературу.

В свою очередь татарская делегация Ульяновской области участвовала в праздновании 1000-летия Казани. Кроме того, она является постоянным участником различных форумов Всемирного конгресса татар (в том числе Всероссийских съездов татарских предпринимателей села, Всемирных форумов татарской молодежи), Всероссийских съездов учителей татарского языка и литературы, работников образовательных организаций с татарским языком обучения и изучением татарского языка. С годами дружба и сотрудничество между татарскими сообществами Ульяновской области, Республики Татарстан и других российских субъектов крепнет, связи становятся неразрывными. Общие культурные традиции, этническое единство и тесное экономическое сотрудничество – все это имеет сегодня огромное историческое и общественное значение.

**Знаменитые уроженцы.** Из среды симбирско-ульяновских татар вышло много выдающихся деятелей, оставивших заметный след в науке, литературе, культуре и искусстве. Всем татарам широко известны имена поэтов Габделжаббара Кандалый (1797–1860, с. Ертуганово), Сагита Сюнчалея (1889–1937, с. Старый Мостяк), Хадичи Шаммасовой (1876–1948, с. Асаново), Демьяна Фатхи (Касыма Фатхетдинова) (1906–1943, д. Татарский Калмаюр), поэта, журналиста и переводчика Сахаба Урайского (1907–1957, с. Татарское Урайкино), поэта и художника Гакиля Сагирова (1938–2009, г. Димитровград), журналиста и редактора казанской газеты «Әлислах» Вафы Бахтиярова (1881–1960, с. Новые Зимницы), театральных деятелей Бари Тарханова (Гафурова) (1892–1936, г. Симбирск), народного артиста СССР Габдуллы Шамукова (1909–1981, с. Асаново), гармониста и аккомпаниатора многих популярных татарских певцов и певиц Файзуллы Туишева (1884–1958, с. Старая Тюгальбуга), организаторов народного просвещения Гакиля Ашмасова (1884–1942, с. Абдреево), Закира Кадыри (1878–1954, с. Абдуллово), Шарифа Сюнчалея (1885–1959, с. Старый Мостяк), писателя и литературоведа, доктора филологических наук, профессора Казанского государственного университета Ибрагима Нуруллина (1923–1995, с. Боровка), литературоведа, публициста, доктора филологических наук Масгута Гайнетдинова (1929–2017, с. Лабитово), доктора исторических наук Равиля Амирханова (1946–2006, с. Старая Кулатка).

Таким образом, ульяновские татары, как часть большого татарского этноса, прошли долгий путь становления через объединение различных этнических сообществ на основе общей парадигмы истории, языка и религии. У истории свои неумолимые законы, за нарушение которых она жестко наказывает. Об этом надо помнить всем, особенно слова известного американского писателя XX в. Роджера Джозефа Желязны: «Убить народ легко – достаточно лишить его прошлого».

# УЛЬЯН ТАТАРЛАРЫНА СӘЯХӘТ ЯДКЯРЕ

*Фәрит Яхин*

*Вакыйга 2017 елның 3 июленнән 15 числосына кадәр барды.*

Безнең татар хәзер Семберне «Ульян» дип, аның өлкәсенә бәйле районнарны «Ульян ягы» дип сөйләшергә гадәтләнгән инде. «Чир – китә, гадәт – китми», диләрме? Безнең өчен дә «Сембер» дә түгел, «Ульяновски» да түгел, «Ульян» булды да калды. Ә нигә, татар сүзенә тартым түгелме? «Уң як», «сул як» дигән кебек, «уң ян», «сул ян» димибезме? Һәм менә – «ул ян», «Ульян»нан аермасы да юк, татарның үз сүзе булган да куйган. Дөрес, руска да ул яңгыраштa үзгәреп килеп кергән исем, әмма нәкъ татар колагы өчен яратылган, барлыкка китерелгән.

Ульян ягын мин «Мишәрстан» буларак та беләм. Ул – мишәрләрнең башкалаларыннан берсе, Чистай, Самара, Саратов, Әстерхан, Касыйм, Рязань (Рәҗән) – саный китсәк, азмы алар? Россия буйлап сәяхәт иткәннәремдә мин моңа мең тапкырлар инандым.

*3 июнь.* Кулаткы районы.

Бик ерак юл булып чыкты бу. Иртәнге сәгать җидедә Казаннан кузгалган идек, монда кичке сәгать өчкә килеп җиттек. Аларда дүрт иде инде.

Безне Деникаева Венера Гаделхановна каршы алды. Ул – Кулаткы районының мәдәният эшләре буенча җаваплы кешесе. Артыгын

сөйләшми. Гаҗәеп дәрәҗәдә чибәр, булдыклы, дөньяны сеңереннән тотып алып баручы кеше.

Иң элек район музеена киттек. Зур, яхшы музей. Мөдире зурлап каршы алды. Әле кичә генә районда сабантуй булган, шунда экспонатларын алып чыкканнар. Менә шуңа күрә дә аларны урыннарына урнаштырып ук өлгермәгәннәр, таркау вакытлары икән.

Музей белән танышып чыккач, фондларындагы иске татар китапларын барладым. Арадан берсе үзенә җәлеп итте. Кульязма китап, 1881 елда төзелгән, – һәм бу хакта ике урында ике тапкыр язылган язмасы бар, – кызыклы күренде. Анда төрле догалар, Корьән аятьләре күчермәләре, ислам динен кабул иткән беренче яраннар хакында чәчмә белән язылган хикәят, Исмәгыйль пәйгамбәрне корбан итү хакында Ибраһим пәйгамбәр белән бәйле тагын да бер чәчмә хикәят һәм дә, алга таба – тезмәдә бер касыйдә, «Кисекбаш китабы». Барысы да күчермәләрдән гыйбарәт, бу яклар халкының күңел дөньясына ачкыч иде ул, әлбәттә. Димәк, алар – догалы, аятьләрне beләләр, Корбан гаетен өстен күрәләр, касыйдәләр укып, дастаннар белән хәтерләрен сугаралар. Менә шушылай яшәү аларның күңелләренә хуш килә, ә калганы – гадәти көнкүреш.

Икенче кульязманы ачтым. Зәңгәр кәгазьдә. Төсе әйтеп тора: XVIII гасырдан XIX йөзнең беренче чирегенәчә генә андый кәгазьне җитештергәннәр. «Российский бренд», диләрме?

Бу – «Һәфтияк шәриф», ягъни эчтәлектә Корьәннең җидедәнбер өлешеннән гыйбарәт китап, «Кече Корьән». Кульязманың алгы-арткы сәхифәләре сакланмаган.

Тагын да ике төрле китап күрсәттеләр. Берсе – шәригать гыйлемнәреннән, икенчесе – төрле басма китапларның җыйнамасы, күпчелек өлеше аерым-аерым сәхифәләрдән тора…

Аларның нинди китап булуларын музей директоры Роза Габделхәевнага аңлатып бирдем. Хәер, ул болай да белгәндер инде? Әмма игътибар белән тыңлап торды, сөйләгәннәремне исендә калдыра барды кебек.

– Аларны сукыр бабай китергән иде. Мәчеттән чыгарып биргән булганнар, – диде ул.

Вакыйганың кайсы заманда, ничек булганлыгын белешеп аптыратмадым. Шулай да фараз кылдым: «Мәгәрем Роза ханымның үз кулына китереп биргән икән, вакыйга безнең заманнарда булган!»

– Мин аларны музейга китердем, – диде директор, уйга калуымнан үзенчә фикер ачып.– Кайбер китапларыбызны тарих язучы Габделхәй әфәндегә бирдем. Вакытлыча, өйрәнеп алырга, – дип тә өстәде, бераз дулкынланып.

*4 июль,* Иске Атлаш авылы.

Халыкта сөйләнә торган беренче сүзләре шул булды:

– Борынгы китаплар бар иде. Каенанамныкы, Мәнәпова Кәшифә Усман кызыныкы. Коръәне бар иде. Укыган кеше иде. 1914 елгы. Мадьярова иде, кыз чагында… Фәүзия абыстай бар, Сәфәров Нургали, Мүлтәев Кәшаф…

Сыер савучы булып эшләгән, 1939 елгы, Халидә Байбикова шулай сөйли, клуб мөдире Сиражетдинова Разыя Якуп кызы аңа кушыла. Ул 1960 елгы. Шушында ук китапханә мөдире дә бар. 1991 елгы, Фәйзуллина Рәзинә Ринат кызы. Халыкны клубка җыйганнар.

Мәнәпова Кәшифә Усман кызыннан калган китапларны, җыйган мөнәҗәтләр дәфтәрен күтәреп киленнәре Әхмәтҗанова Рәисә Шәкүр кызы алып килгән. Ул үзе Николаевка районы Сайман авылыннан икән, 1947 елгы. Китапларны өйләрендә саклый. Коръән сәхифәләре, шәригать гыйлеменнән иске басмалардан кисәкләр һәм сәхифәләр алар. Мөнәҗәтләр дәфтәрендә язмыш авырлыгыннан зар иткәннәре дә бар.

Мәнәпова Җәүһәр Ихсан кызы, 1924 елгы:

– Китаплар юк инде, калмадылар, – диде, күңеле кителеп. – Җыйдылар инде аларны. Галимнәр килде. Алып киттеләр. Бирдек шул инде, бирдек…

1950 елгы Мәнәпова Сәйдә Асаф кызында Кодури китабының 1902 елгы басмасы бар, Мөхәммәдия китабы сәхифәләре һәм өлешләре саклана. Кулъязма китап нөсхәсенең 56 нчы битендә «Тәмам булды чәршәмбе көнне. Язучы – Минһаҗетдин Бәдретдин угылы Шәкүров. Тәммамат» дигән язуы да бар. Монда, язучы

буларак белдерелсә дә, китапны күчерүче күздә тотыла. Мондый үзенчәлек татар кулъязмаларында еш очрый, язучы дип күчерүче атала, әсәрнең авторы түгел.

Бу китапарны 1947 елгы Мәнәпов Равил Якуп улы күрсәтте. Шофер булып эшләгән.

– Чержауда яшәдек, 1974 елдан 2010 елгача, – дип аңлатты ул, Урта Азиядәге Амудәрья буендагы шәһәр хакында искә алып. – Шуннан кайттык. Кучкарев Нургали бабай, Сибгать бабай Коръәнне бик яхшы укый иделәр. Бар да шунда калды…

Хөрмәт белән саклаган төргәкләрен ачты. Алар төрле чорлардан, дәфтәргә күчермәләре дә бар, хөтбәләр, мөнәҗәтләр, башкалар… Әмма таркау сәхифәләр генә. «Гайнел-гыйлем» («Гыйлем чыганагы») китабыннан да басма битләр бар. Өч төргәктә саклый.

Аннары 1951 елгы Хәмзинә Рәисә Абдулла кызы йортында булдым. Аларда Коръән саклана. Әмма сәхифәләре таркау.

1932 елгы Хәбибуллин Якуп Әбүбәкер улына тукталдым. Хәбибуллина Бәян Әбүбәкер кызы, 1929 елгы, Иске басма Коръән һәм шәригать китаплары күрсәтте. Кадерләп саклауларын әйттеләр.

– Кодаларның исемнәре бер үк булган, – дип аңлаттылар алар Әбүбәкер кызы, Әбүбәкер улы булуларын, ягъни Якуп аганың да, Бәян ханымның да этиләре – башка, ә исемнәре бер үк төрле, Әбүбәкер булган икән. Ә мин аларны агалы-сеңелле дип уйларга ашыктым.

Хәбибуллина Халидә Әбүбәкер кызына тукталдым. Элек ашларда укып йөргән. Өч төргәк иске китаплары бар. Араларында мөнәҗәтләрдән күчермәләр дә саклана. Күп китаплары таркау хәлгә төшкән. Аларны үзе укыган. Күренеп тора, еш укылган нөсхәләр, шуңа да таушалганнар. Араларында 2005 елда Рухыя Зөлкарнәева язган бер бәет тә бар. Иске басма китапларыннан «Алты бармак» тулы хәлендә сакланган.

Мәчеткә барып кердем. Анда Гаделша кызы Рабилә абыстай, 1957 елгы, балалар укыта иде. Мәчетне Аюкаев Низаметдин Җәлалетдин улы салдырып калдырган, 1991 елда ачылган.

– Тәрбияче булдым, мәктәптә музыка дәресләре укытып йөрдем, – дип искә алды абыстай.

Атлаш авылының исеме «Гаделшаһ» исеменнән түгелдерме икән дигән фикергә килеп, шул уемнан көлеп, елмаеп та алдым.

– Хәзрәтебез Сәфәров Нургали Исхак улы, 1941 елгы, госпитальдә, – дип аңлатты абыстай, госпиталь дигәнендә больницаны күздә тотып, әлбәттә. – Мәзинебез 1939 елгы Давыдов Әхтәм Шакир улы. Безне Коръән укырга Каипова Фәүзия Зариф кызы өйрәтте. Мәктәптә немец теле укытучысы иде. Рәхманкулова Мөнирә – мәчетне карыйлар…

*Мосеевка авылына килдек.* Экспедиция галимәсе, Ульян ягының данлыклы гыйлем иясе Фәридә Таһирова әйтә: «Муса авылы, – ди, – мишәрчә, «потому-что» Муса дип әйтелә, «ма сивә» түгел!

Аның бу сүзләренең хикмәте шунда, чөнки мин Мосеевка атамасын «ма сивә» сүзеннән булса кирәк, дигән фаразымны белдерергә өлгердем. Фәридә ханым хаклы иде, әлбәттә.

Безне каршы алган хуҗалардан берсе – Әхтәмова Рухия Кәбир кызы иде, ул 1964 елгы. Китапханәче. Китапханәдә этнографик почмак ачкан. Анда «Һәфтияк» сәхифәләре һәм кисәге, бер кулъязма шәкерт дәфтәре саклана. Аңарда 60–70 битләр булыр, мөнәҗәтләр, догалар, касыйдәләр теркәлгән. 1896 елгы Алиев Идрис Абдрахман улыннан икән. Ул инде вафат. Дәфтәренә, бәетмөнәҗәтләрдән тыш, кешеләрнең туган-яшәгән елларын да язып теркәп барган.

Бу авылда әүлия зираты бар икән. Кабер ташы да, утары да саклануын әйттеләр.

Алиева Зәкия абыстайның, 1942 елгы, тумышыннан Иске Мостяк авылыннан, Сөләйман кызы, иске басма Коръәне бар икән.

– Каенатам Искәндәр Усман улы иде, 1895 елгы, шуңардан калды, – ди. Ире Иззәт исемле икән, 1939 елгы. – Җәләева Рәсимәдә булыр иске, борынгылар укыган китаплар… Каядыр киткән. Район «главасы» Ганиевта, өендә, әнисе китаплары булырга тиеш… Тәүхидә апа, Газизовада, Кәшифә Музиковада бар.

– Каенатам агасы Алиев Усман бик укымышлы булган, – дип дәвам итте ул бераздан.– Аны бик теткәннәр. Талаганнар. Сөргенгә озаталар. Качып китә Урта Азия ягына. Зиатдин бабай

Чержауга качкан, карендәше. Мәчеттә ул укыткан… Моннан чыккан Ишан бабай, Хансөярев Хәбибулла булган. Зираты Зимницада. Монда мәдрәсә тоткан. Ике мәдрәсә булган… Ишан бабай турындагы китапны Сафин Иршат Хәлил улы язды. Самара мәчете имамы. «Меңнәрнең остазы ишан Хәбибулла Хансөярев» исеме белән 144 биттә Самарада бастырып чыгарды, 2005 елда.

Аннары, мин кузгала башлагач:

– Әюпова Миңҗиһанга барып кара әле, – дип киңәшен бирде. – Тәүхидә абыстайга.

Сораштырып килеп, Газизова Тәүхидә Искәндәр кызына барып кердем. 1928 елгы икән. Гомере буе төрле эшләрдә йөргән, колхоз эшчесе булган. Олыгайгач, күңеленә һәм белеменә күрә, аны абыстай иткәннәр. Дини китаплары шактый күп. Әмма алар һәммәсе дә хәзерге, заманча басмалар, календарьлар булып чыкты.

1928 елгы Әюпова Миңҗиһан Зиатдин кызына кердем. Шулай ук колхозчы булган. Ун еллап Чиләбегә китеп, анда яшәгән.

– Язганнарым бар иде, онытылды инде. Зиһеннәр калмады, – дип зарланып алды ул.

Шушы ук *5 июль көнне Иске Мостяк* авылына килдек. Авылның исеме «Ике күпер», ягъни «Ике мостик», дигән сүзләр тезмәсеннән гыйбарәт икән. Сөйләүләренә караганда, иске заманнарда алар сазлык буйлап ике күпер төзегәннәр, шулардан авылга кереп-чыгып йөргәннәр. Ул вакыйгалар 300 еллар элек булган хәлләрдән икән. Димәк, XVII гасырларга карый.

Бу – Габдулла Тукайның каләмдәшләреннән шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй авылы.

– Аның туганнары килгән иделәр, музей ясарга дигәннәр иде, – диделәр.

Авылда муллаларның берсе – 1952 елгы Куртяков Рушан Туктар улы икән. 20 ел Дүшәмбе ягында яшәгән. Аннары Башкортстанның Мәләвезендә, Эстәрлетамагында 13 ел торган. 2006 елда монда килгән, инде 11 ел яши икән.

Авыл абыстае буларак, 1949 елгы Әхмәтҗанова Рауза Сөләйман кызына тукталдым. Ул зоотехник булып эшләгән. Яңа чор китапларыннан укый икән, борынгыларныкын үзендә сакламый.

1953 елгы Бакусова Зәкия Абдулхак кызы да дини яктан белемле. Ул Коканд шәһәрендә 20 ел яшәгән. 1992 елда Чаллы шәһәренә күчеп кайтканнар. 2000 елда монда күченеп килгән.

Түбән оч мәчетенә килдем. Аны авылда «Иске Мәчет» дип йөртәләр. Аның китапханәсендә иске басма Коръән кисәкләре саклана. Монда «Җомга дәресләре» оештырганнар, балаларны укыту-тәрбия эшләре алып баралар. «Кулаткы укулары»нда ел саен катнашалар икән.

– Казаннан Җәлил хәзрәт һәр укуларга да килә, мәҗлесләрдә «Җәлил хәзрәт вәгазьләре»ннән укыйбыз!

Авылда электә 7 мәчет булган. Бу «Иске мәчет»нең манарасын 1960 елларда кискән булганнар, трактор белән тарттырып аударганнар. Халык шунда күз яше белән елаган. Аның ае Якуб Ягрусовның бакчасына тәгәрәп төшкән. Ул аны ихатасына алып кереп яшергән, саклаган. Абдулла исемле улы ул мәчетне фотога төшереп калган. Аны сандыкта яшереп саклаганнар. Халык ул заманнарда гаетләрне зират янында укый торган булган.

Мәчет чормасын карарга иттек. Анда, иске басма китаплар белән бергә, өч кулъязма китап кисәкләре бар иде. Шәригать belеменнән – берсе, калган икесе – шәкерт дәфтәрләреннән. Аларны Институтның кулъязмалар бүлегенә тапшырдылар.

Аннары «Югары оч мәчете»нә килдем. Ул өлкәдә 19 нчы мәчет буларак 2003 елда төзелгән, 2004 елда ачылган. Аның чормасында иске басма китаплардан «Алты бармак китабы» һәм «Мөхәммәдия китабы» бар, иске басма Коръән өлешләре саклана. Аларны халык күз алдына киштәлеккә куярга тәкъдим иттем.

Мәчет имамы 1946 елгы Салихов Әкрам Мөбарәкша улы икән. Инде бишенче ел шушы эшне алып бара булып чыкты. Тегермәнче дә, мәктәптә хуҗалык мөдире дә булып эшләгән. Имамлыкка кадәр мәхәллә рәисе вазифасын башкарган.

– Иске, борынгы китаплар авылда бар иделәр алар. Аларны бирмәстән тоталар. Бабайлар динне яшертен алып килеп безгә тапшырдылар шул, – дип аңлатып алды ул.

1931 елгы Якуп Булхин белән сөйләшәбез. Гомере буе балта остасы булган.

– Минем бабай Билал булган. Аны бездә «Бля» дип йөрткәннәр, тел җаена. Шуннан фамилиям киткән – Булхин. Нәселдә танылган галим кешеләр юк. Тормышым да шул, бер үзем генә яшим.

Равил Мостафа улы Аксянов, 1948 елгы, авыл мулласы. Аксёновлар белән бер нәселдән икәннәр.

– Борынгы китаплар юк бездә. Зиратта да язулы ташлар юк! Әмма ташлар, язусызлар, бар, – дип аңлатты.

Танылган тарихчы-галим Равил Әмирхановның әнисен искә алдылар.

– Ул Атлаштан иде, укытты. Математик, – диделәр.

Бу мәчетне 1904 елда ачканнар. Ул вакытта колхоз да булышкан. Халык үз акчасына күтәргән. Тәүге муллалары 1937 елгы Азизов Җөрҗиз Идрис улы булган.

– Авылныкы дип сөйлибез инде, – диделәр.– Мисалдан, Габдрәхимов Сафиулла Хәбибулла улы. Яңа Мостякта туып яшәгән булган. Курслар бетереп, укытучылык эше алып барган. Язучы икән. Шигырьләр, әсәрләр язган, авыл тарихын өйрәнгән. Менә аның кулъязмалары бар иде. Ул әле Ленин ордены да алды. Гарәп-татар әлифба китабын төзи. 92 яшендә вафат. Китаплары гына, менә, сакланмады. Туганы – Роза исемле, Лаешта яши. Энесе малае – Габдрахманов Рәис, Кулаткыда яшәде. Икенче улы – Рафикъ, Сабада яши. «Страховой агент» булып эшли. Оныгы. Саклана була бер чемодан белән оныгы Рәистә, Казанда, Сафиулланың архивы. Югалталар. Эзләдек, очына чыга алмадык, диделәр. Әйе... Менә, тагын да, «Член-корреспондент, историк» Рашидов Фрид Айни улы, 80 яшь, Саратовта яши. Мостяк тарихын язды... Биредә Кузнецки сәүдәгәрләр Хвалынскоега йөрегәннәр. Мостяк авылы алпавыттан башлана. Исеме шуңа бәйле. Мостюков булган. Мостюковтан авыл башлана...

Шуннан соң Равил хәзрәт Институтка дип бер кулъязма китап кисәген минем кул аша тапшырды. Кулында төрек басмасы иске сүзлек бар, аны да күрсәтеп алды. Рәхмәт әйттем.

*6 июль.* Урта Терешка авылы.

Мәктәптә булдым. Хәзерге шагыйрьләренең китапларын бүләк итеп бирде Фәрдәнә ханым. Клуб мөдире Флора ханым мине шәхси китапханәләре булган авылдашларына алып китте һәм Акилә ханымнарга кертеп калдырды.

Акилә Сафа кызы Хәмзина, 1934 елгы. Язучы, журналист, шагыйрә. Мәктәптә гомере буе география фәнен укыткан. Аның тормыш иптәше шагыйрь Камил Мирза улы Хәмзин (1934– 2017). Машина белән бәрелеп, 7 ел буена авырып яткан. 17 февральдә җирләгәннәр. Тарих укытучысы булган. Парторг та, авыл советы рәисе дә булып эшләгән. Мәчетне ул салдырган. Мулла булган.

– Хаҗда булдык. 57 ел гомер сөрдек. Бик акыллы, мәрхәмәтле кеше иде, бер сукмады, бер сүкмәде, – дип искә алды ул үз ирен, күзләренә яшьләре килеп елый-елый.

Камил Хәмзин авыл халкының тулы шәҗәрәсен төзегән булган. Аны тирегә күчереп язган. Ул шәҗәрәне Урта Азиягә алып киткәннәр. Әмма кәгазь вариантын саклап алып калганнар. Ул 1967 елгы плакат артына эшләнелгән.

Камил Хәмзин – бу якларның танылган шагыйре, ике китап авторы. Аның берсен мәктәп китапханәсендә бүләк итеп биргән иделәр.

– Безнең авылның ишан хәзрәтләре Курмакаев Габделмән булган. «Абделман ишан» дип билгеле. Төркестанда укыган, – дип сөйләде Акилә ханым. 1912 елда үлгән, 1819 елда туган. Курмакаев Абделман ишан Али улы... Урта Азиядә укыган... 25 яшенәчә... Монда кайта. Ишан була. Мәдрәсә салдыра. Икенче мәчет салдыра. Өе каршында базар төзи. Кешеләр артыкларын сатсыннар өчен. Эшләп укуны алга куя! Хәләл аш ашап уку! 35 гектар урманы, тагын да җирләре була. Язын – эшләгәннәр, кышын – укыганнар. Сеңлесе дә укыткан. Әхмәт Яссәвидә ул шулай!.. Аның Волга буе ишаннарыннан аермасы да зур булган, – дип

аңлатып бирде Акилә ханым. Идел елгасын мишәрләр «Волга», диләр. Аңлавымча, бу Габделмән ишан «яссәвия тарикате» вәкилләреннән икән, нәкышбәндияче түгел, ахрысы?

Акилә ханымның шәхси китапханәсендә 27 иске басма китап саклана. Аларның барысы да авылдан җыелган икән.

– Каенанам укымышлы кеше иде. Аларның кабак өстендә мәчет булган, – диде ул, аңлатып сөйләп. Аның «кабак өстендә» дигәне «капка алдында» дигән сүз икән. – Шуннан да алгандыр? Каенанам – Хәмзина Аҗирә иде.

Китапларын карап чыгарга тәкъдим итте. «Алты бармак», «Рисаләи-Газизә», «Кыйссасел-әнбия», «Кыйссаи-Йосыф», «Мөхәммәдия китабы» һәм башкалар бар иде, арада өч кулъязма китап та бар икән. Аларны карап чыктым. Арада яхшы сакланганнары да бар. Китаплар иренең дә төсе икән.

– Мансур бабай тегермән тоткан. Зур китапханәсе булган. 72 китабы булган... Зиратта ташлар бар. Кабулдан китерелгәне дә... Ишан хәзрәт халыкны хезмәткә өйрәткән!.. Монда Фәүзия Бәйрәмова үз укучылары белән булды, китапларны җыеп китте инде, – диде ахырдан.

Хушлашып, юлымны дәвам иттем. 1942 елгы Ишуков Камил Ризван улына килеп кердем. Ул 40 ел буена мәктәптә химия-биология укыткан, шуның 20 елын мәктәп директоры булган.

– Камил Мирза улы имам булды, мин эшләп йөрмәдем имам булып, – диде ул, борынгы китаплары булмавының сәбәбен аңлатып.– Сарюков Шамил Исхак улы – хәзер имам. Борынгы бабалары – Каргалы ягыннан. Күпернең теге ягы – Биш авылында. Анда нигез салган. Ишан бабай зираты бар. 7 мәхәллә, 7 мәчет булган. Ишан бабайда «Зур мәчет» булган. Аның балалары да сәләтле булганнар... Аннары, Мансуров Әхәт бабай йортында китап юкмы? Ул – вафат, нәселе монда түгел... Үземдә бабамның Коръән китабы, «Мөхәммәдия»се, догалык дәфтәрләре бар. Әхәт, аның атасы – Абай, «Абайдулла», дибез, сез «Гобәйдулла», әйтәсез...

Юлымны дәвам итеп, бер авылны чыгып барганымда икенчесенә килеп кердем. «Ишан бабай» кабере өсте затлы итеп

эшләнелгән, чиста, күркәм хәлдә иде. Анда тукталып, догаларымны укыдым.

Кабер ташының йөзлек ягына «Һәза-әл-мәркад әл-шәрифелгалим әл-гамәл шәихел-камил әл-әсәлифәт нәкышбәндийә милла Габделмәннан ибне Корбангали ибне Муса Туфи сәнә 1333 һиҗрәти фи йәүмил әс-сани йәүми 12 мин шәһри Рамазан» дип язылган, ягъни «Бу кабер нәкышбәндия юлын тотучы камил шәех, игелекле галим, мулла Габделмәннан Корбангали улы Муса Тафи нәселеннән, 12 нче Рамазан көнендә, Һиҗри исәптә 1333 елда» дип, ә уң як кабыргасына «93 яшендә» дип язылган иде.

Димәк, ул яссәвияче түгел, нәкышбәндияче икән. Акилә ханым бераз хаталанып сөйләгән. Хәер, ул хәбәрне башкалардан алган булыр?

Юлым Шамионова Рәхилә Зиннәт кызына тукталды. Ул 1951 елгы икән. Мәктәптә рус теле укыткан, башлангыч мәктәптә белем биргән, хәзер мәчеттә дәресләр бирә.

– Бу китапларны Яңа Терешкәдән, Шиһаб муллада сакланган булганнар, Руза ханым җыештырып бирде, – дип, миңа берничә кульязма китап кисәкләрен тоттырды, арада 1898 елгы «Метрикә дәфтәре» дә бар иде.

*6 июль.* Экспедициябез Кирюшкино авылына күчте.

Мулла Нарбеков Зөфәр Зөлкарнәй улы. 1937 елгы. 25 ел буена колхозда тракторист булып эшләгән. 2005 елда аны имамхатыйп итеп сайлаганнар. Мәчетләренә манараны 1993 елда куйганнар.

– Бу бинада совет чорында тегүчеләр мастерское иде. Эш киемнәре тектеләр. Өч хатын эшләде. Аның да бер бүлмәсендә – парикмахер, икенчесендә көндәлек техниканы, телевизорын, башкасын ремонтлау мастерское иде. Әле «Приемный пункт»лары да булган икән, – дип сөйләп аңлатып алды ул.– Кирюшкино – «Кирилл авылы» дигән сүз ул. Бер рус кешесе булган. Ул китеп барган, ә исеме авылгаябышып калган. Авылга «почти» 300 ел инде. Мәчетнең манарасын 1970–1980 елларда кистеләр... Түбән очта мәчет бар иде. Аны да сүттеләр. 150 хуҗалыкка 4 мәчет бар

иде. Коммунистлар бездән мәчетләрне сүтеп-аударып киттеләр. Аңа кадәр ничек түзгәннәрдер? 1993 елда торгызып та куйдык. Авылның рухы көчле булды, рухы!

Аннары Богданов Имаметдин Кәбир улында булдым. Ул 1953 елгы икән. Үзләрендә иске басма Коръән кисәкләрен саклый.

Әхмәров Мөдәррис Мәхмүт улына кердем. Ул 1946 елгы икән. Элекләрне Сызраньда инженер булып эшләгән. Әтисе Мәхмүтнең әткәсе Шәрәф исемле булган.

– Шәрәф бабай Мәккәдә укыган. Аны монда укытырга җибәргәннәр. 1847 елгы иде. 1953 елда вафат булды. 107 яшь яшәде. Әти Мәхмүт колхозда бухгалтер иде. Аннары мулла булып торды. Ул 1905 елгы иде. 1963 елда вафат. Китаплары калмады, Коръәненнән гайре. Коръәнен Сызраньда өйдә тотам. 1905 елгы басма. Тулы.

«Шәрәф бабай» дигәннәре Николаевка ягыннан Әзмер авылыныкы икән, аның этисе исә Әхмәр исемле булган.

*7 июль.* Иске Зеленай авылына килдек. Аны «Старое Зеленое» дип тә йөртәләр икән.

Авылларындагы мәчет «23 нче мәчет» исемен йөртә. Авылның икенче мәчете. Миңа:

– Тагын да «Үзин мәчете» бар иде, – диделәр. Бу ике авыл кушылып киткәннән шулай икән. Хәзер ике авылны бер исем белән атыйлар булып чыкты. Элек алты мәчетләре булган. Аларны сүтеп «школ» ясаганнар, тегермән ясаганнар.

– Бер мәчет калган иде, аны сүтеп, мәдрәсә ясадык хәзер, – диделәр тагын да.

1939 елгы Мостафин Яхъя Усман улына килдем. Балта остасы булган.

– Әбием этисе Төхфәтулла бабай хаҗи, азанчы булган. Таһира әби – минем әбием була, аның кызы. Язган китап-дәфтәрләре бар иде, мәчеттә иде. Аны «раскулачили». Китаплары каядыр? Белмибез!..

Мәчетләрендә булдым. Аның китапханәсендә иске басма «Мөхәммәдия китабы»ның калын гына кисәге саклана.

Шәкертләр Илгиз Әлмиев белән Марат Абайдуллин дәрес белән мәшгуль иделәр. 1956 елгы Кузяев Вәли Әхмәтша улы үзе белән мәчет карты буларак таныштырды.

Ханбекова Рәсимә Мирсияф кызы, 1955 елгы, башлангыч мәктәптә укытучы булган. Кулъязма мөнәҗәтләр китабы бар икән кулында.

– Якупов Габделкаюм бабайныкылар, Мирсияфнең әтисенеке. 1928–76 елгылар... Яшьли вафат, бигрәк...

1945 елгы Үзбәкова Фирүзә Садыйк кызы, колхозчы булып эшләгән.

– Бу китап – бабаем Зөфәрнекеме, әбинең бабасы Хәсән бабайныкымы? Белмим дә, каенатамныкымы?

Фирүзә ханым аларны мәчет китапханәсенә китергән. Иске басмалардан «Мөхәммәдия китабы», Коръән иде алар.

Абайдуллина Мәүлегөл Солтан кызы, 1952 елгы. Гомере буе колхозчы булып эшләгән. Иске басма китаплары бар.

– Китаплар – Фәйзуллин Локманныкы. Үз заманында ул кеше мулла иде, – дип аңлатты Мәүлегөл әби.

Зиратларында булдым, анда борынгы ташлар табылмады.

Миңа һичшиксез Бикбаева Гөлсем Мөхетдин кызын күреп китәргә киңәш иттеләр. Ул 1944 елгы икән.

– Мәктәптә гомерем буе татар теле укыттым, – дип сөйләп китте Гөлсем әби. – 50 ел кая да китмичә монда эшләдем. Ульян өлкәсеннән, Колмаер авылы, Чардаклы районыннан тумышым. Ульянның «Биләр мәдрәсәсе»нә илттем бик күп китапларны. «За Волга»да ул, Оренбург тыкрыгында. Аларны өйрәнер өчен... Әмма шул килеш торалар булыр? Әтием, каенатам Бикбаев Ханнан, һәм каенанам Хәлимә китаплары иделәр. География гыйлеменнән, «Алты бармак» та бар иде. Методичкам, татар грамматикасы – боларын «Колшәриф»кә илттем. «Икенче мәчет мәдрәсәсе»н үзем ачтым, анда шәкертләр укыттым. «Җәвамигыль-Кәлам шәрхе»н, иске китаплар укып өйрәндем... Сөләйман хәзрәткә хөрмәтем зур! – дип сөйләде.

Үзе язган китаплары да бар икән. Галимнәргә атап, шуларның берсен Институтның «Мирасханә»сенә язып бүләк итеп тапшырды.

Данлыклы *Вязовый Гай* авылына килдек. Кызыксынып сорадым, авылны татарча, «Карамалы» дип әйтмиләрме икән? Юк булып чыкты.

Авылда мулла Бәширов Мөйәссәр Борһан улы икән, 1945 елгы. Мин аңардан абыстайлар хакында сорагач, ул:

– Алар – бар, Рәшидә, Сания, Румия, – дип санап китте.

– Ә үз хатыныгыз?– дидем.

– Үз хатыным – Фәридә Ризван кызы, 1952 елгы, мулла хатыны, абыстай түгел, – дип аңлатып бирде. – Хәзер гадәтләр искечә түгел, замана барысын да яңартты.

Миңа аның белән килешергә генә калды.

– Сиражи ишан – безнең авылныкы. Оренбург ягыннан булган. Өч мәчет, өч мәдрәсә монда булган, – диде, тарихларны сөйләүгә күчеп, иске басма китаплары арасыннан, мәчет янындагы китапханәдән Һибәтулла Салиховның «Мәҗмәгуль-әдәп» («Әдәп тупланмасы») тезмә китабын күрсәтеп.– Гобәйдуллин Исмәгыйль, мулла, Төркия ягыннан килгән булган. Аны коммунистлар аткан…

Аннары ул миңа Ибраһимов Шакир мулланың улы Мәхмүтнең 312 битле китап итеп тегеп төпләп ясаган дәфтәрләрен күрсәтте. Анда шәригать гыйлемнәре, тарихлар, төрле басмалардан алынган мәкаләләрнең конспектлары иде. Китапханәдә «Әхмәдия» китабы да бар икән. Ул Төркия ягыннан китерелгән китаплардан. Имам Мәхмүт җыеп калдырган булса кирәк? Шулай ук Хәмидинең «Коръән тәфсире»нең беренче томы, Казанда Кәримовлар тарафыннан 1911 елда бастырылганы, «Гыймаделислам» – болар Хәялый улы Мәхмүт Бәшировтан, ә менә «Мохтасар вакият»нең 1879 елгы басмасы Габдулла бине Мәсгут китабы. Китапханәдә «Алты бармак», «Әнвәрел-гашикыйн», «Тәнбиһелгафилин», «Мөхәммәдия китабы» бар. Миндә бу якларда очраган иске басма китаплардан иң бай коллекция шушында икән дигән тойгы уянды.

Авылның карт абыстайларыннан Әхмәтова Сания Сабир кызына тукталдым. Ул 1930 елгы икән. Хисапчы булып эшләгән. Аңарда иске басма Коръән һәм «Мөхәммәдия китабы», шулай ук

башка төрле басма китапларның өлешләре һәм сәхифәләре саклана булып чыкты.

*8 июль.* Яңа Зимичә авылы. Аның русчасы «Новые Зимницы» икән. Авыл документлары 1715 елдан сакланган, диләр. «Зимничә» миңа «Зим эчә», ягъни «Шифалы су эчә» дип аңлаттылар. Халык этимологиясенә ышанып бетеп булмый, анысы. Әмма кызыклы. Галимә Ф. Гарипова авыл тарихларын авыл кешеләре сөйләгән риваятьләргә таянып ачыклауны фәнгә кертте. Бу журналистик алым татар этимологиясенең йөзенә әверелеп өлгерде. Мондый алымны ничек дип тә бәяли алмыйм, чөнки аның тарафдарлары бездә бик шаулы кешеләргә әверелделәр.

Безнең экспедицияне клуб мөдире Фирүзә Алиҗан кызы Алимова каршы алды, 1970 елгы. Ишан Хәбибулла хәзрәтләре (1805–1897) шушы авылдан икәнлеген әйтте. Миңа Тугушов Габделкадыйр Кәшшаф улына, 1947 елгы, барырга киңәш итте. Шунда киттем.

Габделкадыйр бабай автомеханик булып эшләгән, әмма 40 яшендә хасталанган. Сеңерләре кибә, тартыша икән. Йөри алмас хәлгә килә.

– Хәбибулла Хансуаров ишан бабай булган. Согуд Гарәбстанында да беләләр аны. Чистайда укый. Мөхәммәтәмин бабам шул ишан бабайда укый. Пенза «область» Демин авылыннан булган. Габделкәшшаф атам ишан бабай зиратын карады, – дип сөйләде ул. Кулындагы китаплардан иске басма «Алты бармак»ны һәм 1914 елгы Казан басмасы Коръән китабын күрсәтте. Бабасыннан мирас икән.– Җиде мәчет, 1200 йорт булган безнең авылда. Син Юмангулова Фатыймага бар әле. Ул – Сафин Иршатның әнисе. Тауда яши. Урам исеме – «Тауда». Исмәгыйль кызы ул, 1944 елгы.

Мин шунда киттем. Бик матур, таза ихатада яши икән. Буялган, ясалган бар җирләре дә.

Фатыйма әби гомере буе терлекчелектә эшләгән. Ике ел география факультетында укыса да, аны тәмамламаган. Ә китаплары Самарада яшәүче улында икән. Хәмидинең «Коръән тәфсире»н җыйнап, китап итеп төзеп тегеп куйган.

Юлымны дәвам иттем. Авылның «Зимичә» дип аталуыннан фаразлар төзи башладым: «Зимичә – «зәй-мөчә» дигән сүздән булырга кирәк. «Зәе» – «елга», имеш. «Мөчә» дигәне – «чишмә» түгелме? Әлбәттә! «Мөчә сыер» дип сөйләшәләр болар, «сөт чишмәсе» дигән кебек, «чишмә кебек итеп сөт бирүче» түгелме? «Дүрт мунча» авылы бар, Татарстанның Зәй районында. Ул да «дүрт мөнчә», яки «дүрт мөчә» түгелме? Ә «Дүрт өйле» дигәне – «дүрт утар» түгелме? Хәер, анысы, утары – «йорт» дип атала икән мишәрдә. Ишек алдына чыгуны да – «йортка чыгу», диләр…»

Авыл мәдрәсәсенә килдем. Безнең экспедиция вәкилләре шушында җыелырга тиеш иделәр. Сәгате-минутында соңармаска кушылды.

Әмма безнекеләр күренмәде. Ә мин мондагы эшләр белән таныша башладым.

– Мөгаллимәбез, башлап, Тугушова Зәйнәп Абдулла кызы иде. Габделкадыйр бабай – аның абыйсы. Габделхак хәзрәтнең хатыны ул. Хәзер – ялда, аның эшен дәвам итә Әмирова Рушания Сәид кызы, 1946 елгы. Ярдәмдә Абитова Нурия Касыйм кызы, 1957 елгы, – дип сөйләделәр. Төрле җирләрдән җыелган балаларга, лагерь ясап, дәресләр бирүне, дини тәрбияне оештырганнар.– Барысы – 14 бала. Акчаны мәчет бирә. Хәзрәт үзеннән бирә. Элеккеге муллабыз 78 яшендә, Ибраһимов Нәҗип. Аны кичә алыштырдылар. Яшьне куйдылар. 50 яшьлек, яшь хәзрәт, Гафуров Рушан Мөхәммәтҗан улы.

Рушания мөгаллимәгә дә берничә сорау бирдем. Ул:

– Али бабай Абитов, Айрахман улы, үлеменә 50 еллар булыр, 50 яшьләрендә иде. Әтиемнең абыйсы иде, – диде ул һәм бер олы дәфтәр мөнәҗәтләр күчереп язып туплаган дәфтәр күрсәтте. Аны мәдрәсәгә Акилә Хәмзина бүләк иткән, бу хакта юлламасын да язган булып чыкты.

*8 июль.* Иске Яндука авылына килдек. «Старая Яндовка».

Авылның исемен «ука янды», «янды ука»дан чыгып аңлатсылар. Элекләрне, имеш, учак ягып, шуның тирәсенә җыелалар икән. Берәү укасын калдырган. Ул янган. Авыл исеме шуннан

калган. «Ендувка» – бозылып әйтелгән. Нижгарда бар ул андый исемле авыл.

Мин боларны ишеткәч, елмаеп куйдым. Ә нигә, Түбән Новгород ягында булгач, бу авыл халкы шул яклардан күчеп килмәскә тиеш? Әйтик, Мәскәүне поляклардан азат итү вакыйгаларында батырлыклары өчен шул як мишәрләренә бу яктан җирләр бүлеп биргән булсалар?

Әюпов Туктар Батырхан улы, 1950 елгы, муллалык итә, Нугаев Рәсим Каюм улы, 1940 елгы, аның ярдәмчеләреннән, икесе дә механизатор булганнар, колхозда эшләгәннәр. Хәзер мәчет аларга калган, ничек эшләргә дә белмиләр. Мәчетне Яхъя исемле кеше салдырган, 1989 елда.

– Механизатор да иде, зампред та булды, бригадир да иде, – диделәр алар. – «Просто», мәчетне салдырды.

Авылда бер борынгы китап та күрсәтмәделәр. Мәчеттә яңа басма китаплар берничә данә бар иде. Өстәл тартмасыннан минем «Иман» китабын алып күрсәттеләр. Коръән белән янәшә тоталар икән.

*9 июль.*

Ульян өлкәсе Карсун районына күчендек. Карсун – эшчеләр шәһәрчеге, монда 8 мең кеше яши икән, тарихлары 1647 елдан килә булып чыкты. Шәһәрчекне шул елда хәрби ныгытма буларак төзи башлаганнар. Мондагы татар җирләрен үзләштерү патша хөкемдарлыгын урнаштыру өчен нигезләнгән.

*10 июль.* Нугай авылы.

Татарлар булсалар да, тарихтан нугай икәннәр. Һәммәсе дә нәкъ татарча, холыклары да, уй-фикер йөртүләре дә. Бары тик әле һаман ат тоталар, ә арбалары – киң, олы, шуңа да иләмсез кебек тоела. Авыллары бик тә зур булган, урман артында урам. Йортлары бетә барып, авыл уртасында берничә урында киң болын барлыкка килгән. Анда үлән адәм биеклеге булып үскән. Аңа карап, авылның шушы хәлгә төшә баруы 1980 еллардан икәнлеген билгеләве авыр түгел. 1978 елдан паспортларны халыкның үз

кулына бирә башладылар, аларны авыл советына җыеп алып, сейфка салып кую бетерелгәннән соң, авыл йортлары бушый башлады. Кешеләр берән-сәрәнләп шәһәргә җәяүләде. Икенче тапкыр сүтелү 1990 елларга туры килде. Колхозлар таралып, авылда эш бетте, күпләр үз тормышын яңача шартларда корып җибәрә алалмый интекте. «Җәбе килсә – сабы булмады, сабы булса – җәбе килмәде», дигәндәй, ниндидер мәгънәсезлек дәвере иде ул. Халык тырышмады түгел, ашкынды хәтта. Юләрлекләрнең чиге юк иде кебек.

Вәлиуллова Таибә Кәшап кызы, 1942 елгы. Гомере буе авылда яшәгән. «Әниләрдә мөнәҗәт-бәет китаплары бар иде, – ди, – таралып бетте».

Мурсалимова Таифә Хәнәфи кызына килдем. 1923 елгы. Бөек Ватан сугышы вакытында, 7 сыйныф бетереп, мәктәптә укытучылык итә башлаган. Укыган вакытында ук аны мәктәп китапханәсенә китапханәче итеп билгелиләр. Авылда икмәк цехы булып, анда да эшли, икмәк тезә. Шул вакытта мәктәп директоры сугышка китеп бара. Аның урынына Бәдриҗамалны куялар. Әмма тиздән авыл советына җитәкчелеккә күчерәләр. Ә Таифәне, яшь кызны, мәктәпкә укытучылыкка күчерәләр. Мәктәптә эшләү тәҗрибәсе булмый. Аны башка мөгаллимнәр дәрес бирү серләренә төшендерәләр.

– 1944 елда аяксыз, каты яралы күрше егете сугыштан кайтты. Аны җәлләп, аңа кияүгә чыктым. Тугыз бала үстердем… Бер «ызба»га чыктык. «Школ»да паек бирәләр иде. Колхозда «труддень»нәр язучы счетовод идем башта, окоплар казырга йөрдек. Сөт ташырга җибәрә иделәр. Үгез бирә иде, ат җигеп бирәләр. Маслозавод дүрт чакрым ераклыкта иде, сөтне шунда илтә идем…

Зур булмаган китапханәсе дә бар икән. Андагы китаплары арасында иске басма «Тәнбиһел-гафилин» («Наданлыктан арындыру») әсәренең тәрҗемәсе, «Кыйссасел-әнбия» бар икән. Аларны хәзер инде укымый, әмма изге нөсхәләр буларак саклый, һичкемгә бирергә теләми икән.

– Гөлсылуга бар әле син! – диде ул миңа.– Шалтыратып, әйтеп куярмын үзенә!

Гөлсылуны эзләп киттем. Таптым. Матур, яшел өй иде. Әмма ул өендә булмады.

Мәчеткә килдем. Әүвәлдә – мулла йортына бардым. Бик яхшы ихата белән, төзек йорт-җирдә, мул яши икән. Хатыны-мы, ишек артыннан гына торып сөйләште. Ачмады. Өйләре тулы кешеләр сөйләшкәне-шаулашканы ишетелә иде. Мин дә күренеп тормадым. Идиятуллов Наил Шәфигулла улы икән мулла. Ульян-да, диделәр.

Мәчеткә кердем. Тәһарәтемне яңартып, ике рәкәгать мәчет на-мазы укыдым. Өйлә намазына ерак иде әле.

Мәчеттәге китаплар киштәлегенә килдем. Анда бик яхшы сыйфатта бастырылып чыгарылган китаплар тезмәсе нурлана иде. Араларында иске басмалар күренмәде. Татар китабы зәгыйфь сурәттә бит ул.

Мәчетләре ачык тора, һәркем, һәр юлчы кереп, намаз укып чыгарлык.

Мәктәпкә килдем. Директоры Миннебаев Илдар Камил улы, 1971 елгы икән. Юсупова Равия Котдус кызы, 1963 елгы, Вәликова Фәтхыя Фиткулкадыйр кызы, 1948 елгы, татар теле һәм әдәбияты укытучылары икән. Гаҗәеп матур, якты, шат күңелле мәктәп булып чыкты.

Экспедиция юлын дәвам иттерде. Уразовка авылына килдек. Аны «Сакускай авылы» дип тә йөртәләр икән. Хактырмы-юктыр-мы, бу авыл 1240 елдан бирле үз тарихын белә, имеш. «Хәсән бабай» дигән кешене искә алып сөйләделәр, ул үзенең 12 буын нәселен белгән, диделәр. Клуб мөдире Диаров Сәид Таһир улы, 1951 елгы, гаҗәеп кызыклы кешеләрнең берсе булып чыкты. Аксу ягыннан Рамазанова Сәрия Абдулбари кызы, 1969 елгы, монда укытучы булып эшли, «Садик»та тәрбияче – Хәкимова Разыя Бари кызы, 1971 елгы, шушы авылныкы. Мәктәп директоры Ра-мазанова Галия Макадес кызы, 1960 елгы. Алар авылның мәдәни активлыгын югары тоту өчен тырышлык итәләр икән.

Мәчетләре 1884 елдан имин калган. Аның манарасын да ха-лык кистермәгән. Абделмәнов Сабирҗан 60 ел буе монда имам-лык итеп, мәчетне яптырудан саклаган. Мәчетләре матур булып,

«Сөембикә манарасы»н хәтерләтеп, агачтан төзелгән, югары баскычлар белән эшләнелгән, чишмә янында. Аның янында гына ике катлы бай йорты булган. Аны «Якуб бай» ихатасы дип йөртәләр.

Мәчет китапханәсендә Халидинең 1907 елгы «Коръән тәфсире» басмасы, тагын башка китаплар бар. Арада Әхмәт Ясәви хикмәтләре басмасыннан кисәкләр, Коръән, «Тәнбиһел-гафилин», җәгърәфия, хисап китаплары, «Һәфтияк Шәриф тәрҗемәсе», кулъязмалардан гарәп телендә мантыйк китабы, ахыры юк, тагын да «Һидаят» китабы, «Йосыф китабы» һәм башкалар очрый. Аларны Сәет Дияров күрсәтеп бакты. Аннары үзләренә алып китте. Китапханәсе иске басма китапларга бик тә бай икән. Алар белән таныштырды. «Гайнел-гыйлем шәрхе», «Әгъраби китабы», «Муллаҗамал», «Мифтахел-гыйлем» һ.б. калыннар, тулылар, яхшы сакланышталар. Солтангата Габәшинең 1909 елда басылган «Тарихы кауме-төрки» («Төрки халыклар тарихы»), Риза Фәхретдиннең «Имам Газали» китаплары…

– Болар – Сабирҗан бабай китаплары, – дип аңлатты Сәет әфәнде Дияров.– Менә монда Саусканиның кулъязма китабы да бар… Күп өлеше күчермәләрдән, аларга мөнәсәбәтле фикерләреннән гыйбарәт. «Вәлиев Мәмәд», «Мөхәммәт» дигән язуы да бар. Самарадан булган ул кеше… Китаплар үземдә торсыннар, саклыйм мин аларны! Кирәге булыр!

Авылда мөнәҗәтләр һәм бәетләр язучы Диярова Мәгъфүрә Исмәгыйль кызы да бар икән. Ул 1952 елгы. Язмаларын дәфтәрләрендә тота, аларны халык алдында укый, хәтта газеталар да чыгара икән.

Сафиуллин Котдус – язучы. Ул да шушы авылдан икән. Инде аның вафат икәнлеген әйттеләр.

Бу авыл үзенең чисталыгы, матурлыгы, тәрбияле булуы белән бик тә сокландырды. Матур итеп, тату тормыш белән яши беләләр икән!

*11 июль.* Татар Гуринкасы авылы.

Авылларның авыры була, җиңеле бар. Фәкыйре бар, бае бар, дигән кебек. Авылның нинди булуы аның халкыннан тора. Әмма

фәкыйрьлек һәр авылда үзенчә. Ә менә байлык – һәркайсында бер үк төрле. Муллалары да шундый. Алар, кайда гына булмасыннар, эредән, мин-минлектән торып сөйләшә беләләр.

«Горенка» дигәннәре «Татарские Горенки» булып чыкты, «Татар Гуринкәсе» икән чынлыкта, рус авылы «Русские Горенки» белән янәшә урнашкан. Туры урамлы. Иске, җимерек, янган йортлары урам буйлап килгәндә анда-санда, рәттән очрап торалар.

Муллаларына кердем. Кәбир хәзрәт, диделәр. Хатыны таякларда иде. Ахирәт хатынымы, күршедән, йөгереп кереп җитте. Заманы шундый, әллә кемнәр йөрергә мөмкин, караклар, чегәннәр булырга мөмкин.

Ә менә борынгы китаплары – юк.

Мәчетләренә киттем. Ике рәкәгать мәчет намазы укыдым. Манарасы, җилдәнме, ыңгырашып куйгалый икән.

Аннары Азизуллова Фәйрүзә Хәсән кызында булдым. 1941 елгы икән. Иске басма китапларын күрсәтте.

– Болар – каенанам Азизуллова Мәстүрәнекеләр, – диде.

Мәстүрә Гайнулла кызы 1903–2001 елларда яшәгән, Шушы авылныкы. Аның китаплары «Фәррух-намә» («Җиңү китабы»), «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр кыйссалары»), «Мәҗмәгыль-әдәп» («Әдәп тупланмасы»), «Мөхәммәдия китабы», «Кисекбаш китабы», «Мөстафадел-әхбар» («Кыскача хәбәрләр») һәм башкалар иделәр. Иске басмалар, кайсылары тетелгәннәр, кисәккә генә калганнар. Арада төзекләре дә бар. Күп укылганнар. Арада Һ. Салихов һәм Ш. Мәрҗани китаплары да булу бу якларда XIX гасырда суфичылык белән бергә, бер рәттән җәдитчелекнең дә алгарыш алган булуы хакында күзалларга мөмкинлек бирделәр. Бу авыл заманында шактый бай булып, ахырда (советлар чорындамы) таланганлыгын да аңламаслык түгел иде.

Юлым Абдрахманова Нәзирә Исмәгыйль кызына китерде. Ул 1940 елгы икән. Моннан 15 чакрымлап булыр, Стрельниково саласында туган. Гомере буе төзелештә эшләгән.

– Каенанам Наилә Ибраһим кызы, әнием Алеева Мәрьям Айнаулла кызы. Бу – аларның китаплары, – диде ул, үзләрендә сакланган борынгы китапларны күрсәтеп.

«Кыйссасел-әнбия», «Рәхәте-дил» («Җан рәхәте»), «Мәҗмәгыль-әдәп», «Нәсыйхәт», Р. Фәхретдиновның берничә иске басма китабы, шәригать гыйлеменнән төрекчә басма һәм башкалар минем күңелдә Татар Гуринкәсе авылы халкының тарихта зиһен һәм акыл ягыннан куәтле булганлыгын төшенергә ярдәм иттеләр. Китапларын хуҗаларында калдырдым. Болар – аларның байлыгы.

Аксу авылына килдек. Аны «Татарская Голышевка» диләр икән. Бу авыл Сура елгасы буена урнашкан.

– Соры елгасы ул, русчалатып «Сура» әйтәбез, – диделәр.

Безне:

– Лекман Джигангирович Зиннуров! – дип үзе белән таныштырган авыл җирле администрация башлыгы каршы алды. Ак сакаллы, 1958 елгы. Хаҗи әфәнделәрнең берсе икән. Инженер, юрист.

Ул мине Хисаметдинов Искәндәр Борһан улына алып килде. 1937 елгы икән.

– Тарихларны ул сөйләр, ул белә! – диде.

Йортлары – зур, тормышлары – мулдан. Әмма борынгы китаплар хакында сүз дә ачмадылар. Ул хакта сорасам да, анда булыр, бу кешедә бардыр белән генә нокталадылар.

– Авылны башлап, ике гаилә килгән. 1640 елда, – дип сөйләп китте Искәндәр бабай, – ике «брат». Беловодкада кыскач инде, монда килгәннәр. Беловодка – «Аксу» инде ул. Руска борылган. Тау башына килеп утырганнар. Иске кабер бар анда. Әмма мордвалар куганнар үзләрен. Алатырь – чиста татар ул. «Коновал»лар булганнар, ат печүчеләр. Балта осталары булган бу авылда. Кызау үреп ясаганнар, каз оясы инде ул – «кызау», козерлы чаналар, боларын – «кашевка» да диябез...

Аннары ул «Алты бармак» китабын киштәлек өстеннән алып күрсәтте. Тулы, яхшы сакланган иде. Фәйрүзә ханым, 1940 елгы, аның хатыны икән. Ул үзләренең януларын, әле яңа тернәкләп күтәрелеп килүләрен аңлатып сөйләде.

Мәчеттә булдым. Намаз укыдык. Мәчетне 1992 елда ук салганнар икән. Анда имам 1935 елгы Хуҗаев Мансур Якуп улы икән.

– Кафиятов Усман салдырды мәчет бинасын, – диде ул.– Үлде инде. «Заготовитель» иде... Картларны мәчеткә дәшә иде... Элек Әкимов Зариф бабай мулла иде. Алар йөрде «молитвенный дом»га. Аны мәчет иттеләр дә инде. Абделбари Хусаин улы Әлаутдинов мулла булды бер ара...

Юлым Әдһәмова Мәсрурә Хәлил кызына китерде. 1942 елгы икән.

– Китапларым бар, ник булмаслар икән! – диде ул горурлык белән. – Алар Шәриф Гафуров китаплары. Өеннән чыгарганнар. Мулла булып... Сигез бала белән муллалыкка Гафур бабай килә. Без – аның оныклары. Шәриф бабай аның баласы иде. Казан ягында да туганнарыбыз бар. Шәриф бабайга биреп калдыра китапларын...

Менә алар! Арада кулъязмалары да бар. Шәригатьтән, тулы булмаган кулъязма, 1921 елгы дәфтәр, метрика дәфтәре өлеше. Мәсрурә әби аларның барысын да Институтка тапшырырга теләмәде, кайберләрен үзләренә кирәк булыр дип алып калды. Мине кулъязмалар гына кызыксындыруын сиземләп:

– Аларны нишләтәләр?– дип сорады.

– Тарих өчен саклыйлар, – дидем мин.– Өйрәнәләр, халыкның белем, аң дәрәҗәсен шуларга карап билгелиләр... Борынгылар язган китаплар югалмый сакланырга тиешләр!

*12 июль.* Экспедициябез үз юлын дәвам итте, Ульян өлкәсе Мәләкәс районына, ягъни Дмитровградка чыкты.

Атнагыл авылы. Монда шагыйрь, тәрҗемәче, җирле тарихчы Ринат Басыйр улы Илькин белән таныштым. Ул 1947 елгы икән. Китапханәсен күрсәтергә өйләренә алып китте.

– Әтием Эстәрлетамак ягыннан, – диде ул. Үзе язган, бастырып чыгарган китапларыннан берничәсен Институтка бүләк итте.

Аннары авыл буйлап йөрдек. Ахырда мәчеткә килдек.

2006 елдан монда имам Хәбибрахманов Рафикъ Лотфулла улы хәзрәт икән. Ул 1939 елгы булып чыкты. Башта электрик булып эшләгән, аннары – колхоз рәисе ярдәмчесе, ахырда – «управляющий». Имамлыкка кадәр 2 ел мәзинлек иткән. Мәчетләре 1990 елдан эшләп килә.

– Авылда иске китаплар юк, монда китерәләр барысын, – диде хәзрәт.– Төзекләрен Ульянга алып китеп баралар. Мәдрәсә өчендер инде...

Киштәлекләрдән алып иске басма Коръән, хикәят китаплары, «Кыйссасел-әнбия», «Мөхәммәдия китабы», «Коръән тәфсире» күрсәтте. Мин бу авылның белемле булганлыгына сокланып, аларны актарып карап чыктым. Хәзрәткә кайтарып бирә тордым. Шуннан ул 8 кулъязма дәфтәр тәкъдим итте, арада берничәсе хат иде.

– Хатлар һәм кулъязмалар – туган абыем Әсгадулланыкы, Хәбибрахманов, Лотфулла улы, 1920 елгы иде, хатыны – Таһира, Хәлиулла кызы, 1919 елгы, кызының дәфтәрләре һәм хатлары, – диде ул. Сезнең Институтта саклансын. Бәлки кирәкләре чыгар?..

*13 июль.* Мөси авылы. Авылны «Муса» дип тә, «Моисеевка» исеме белән дә йөртәләр икән.

Клубларында җирле музейлары да бар. Анда иске басмалардан һәм кулъязмалардан шәригать гыйлеме, фикъһе гыйлеменнән бәхәс китаплары, Коръән бар. Шулар белән танышканда сөйләп тә алдылар:

– Безнең авылда Фәнис хәзрәт Сәмигуллов имам булды. Күп китапларны ул алып китте. Хәзер дә мәчеттә, Дмитровград үзәк мәчетендә имам булып эшли. Сөйләштек телефоннан. Аларны саклыйм, диде...

Мәчеткә киттем. Авыл имамы Әхмәтов Радик Абделваһап улы, 1990 елгы, монда иде. Китапханәсендә иске басма Коръән саклана икән, шуны күрсәтте.

– Башка андый борынгы һичбер китап юк, – диде. Тиз генә Дмитровградка шалтыратып алды. Аңлавымча, Фәнис хәзрәт белән сөйләштеләр.

Авыл буйлап йөреп, Сафиуллина Гөлфия Исхак кызында булдым. Ул 1952 елгы иде.

– Борынгы китаплар бар иделәр алар... Бирдем, күмдем, – диде.

Аннары Сәлахов Әнвәр Каветдин улына тукталдым. Ул 1930 елгы.

– Башлангычларны укыттым. 1948–1950 елларда Кулаткы якларында, Яңа Кулаткыда укыттым, укытуны шунда башладым. Армиягә алдылар. Аннары Мөси авылына җибәрделәр. Монда татар теле һәм физкультурадан укыттым. Бер ара ана телен бетереп тордылар. Анда хезмәт укыттым. 46 ел укыткач, 1994 елда пенсиягә киттем. Хатыным гади «рабочий» иде. Иҗат итмәдем. Иҗат итүчеләр укучыларым арасында да булмады. Ставрополь районы иде бу. «Самарский» идек. Кулаткы – Пенза өлкәсе иде. Безне соңрак кына Ульянга куштылар...

*13 июль.* Филип авылы.

Авылның мәчете дә эшли, мәдрәсәсе дә бар.

Вәлиәхмәтов Фуат Әхмәтзәки улы, 1939 елгы. Колхозчы-механизатор булып эшләгән. Өйләрендә «Мөхәммәдия китабы»н саклый, 1909 елгы Казан басмасы. Эчендә имтихан шәһадәтнамәсе дә бар. Саклау өчен таслап куелган. Аның Галия Гыйрфан кызына бирелүе язылган. Мөгаллимәсе – мулла Мөхәммәтсадыйк Шаһиев кызы Галия. Мирас буларак сакланучы бу «Мөхәммәдия китабы» тулы, бозылмаган.

Нуруллов Насыйбулла Шаһдәзли улы, 1951 елгы. Элек шофер булып эшләгән.

– Әтием Шаһдәзли Нурулла улы бик тә белемле кеше иде, – ди.

Насыйбулла агай – намазлы кеше, кулында төрекнең басма шәригать китапларының кисәкләрен саклый.

Якупова (Хәсәнова) Рауза Зиннәт кызы, 1956 елгы.

– Әти 1908 елгы иде, Зиннәт. Мөси авылыннан. Бу тугыз китап – аныкылар, – дип күрсәтте. Арада иске басма Коръән, бер хәдисләр җыентыгы, Мөгаллим Габделәхәт Мусинның «Кызлар дәресе» китабы (1916 елда Казанда «Өмид» нәшрияты бастырган), Шәһәр Шәрәфнең «Гасрыл-сәгадәт» (Сәхабәләр чоры тарихыннан «Бәхет гасыры» китабы, Казанда, 1916 елда, «Мәгариф» нәшрияты бастырган) һәм башка нөсхәләр бар иде.

Вәлиев Нурәхмәт Нурани улында булдым. Ул 1960 елгы, мәчеттә мәзин булып эшли. Өй кыегы астында китаплары бар

икән, шуларны менеп карадык. Арада кулъязмалар юк иде. Иске басмалар арасында Коръән, «Кыйссасел-әнбия», «Мөхәммәдия китабы» бар икән.

– Төрле эшләр башкарам инде, коммерсант та, – диде ул, үз тормышы хакында. Йорты – яхшы, тормышы – бай.

Абдуллин Фәрит Солтангали улына кердем. 1966 елгы. Колхозчы икән. Кулында бер иске төрек басма китабы бар, гарәп телендә.

Абдуллина Лилия Рафикъ кызы, 1967 елгы. Әнисеннән калган «Рәхәте-дил» («Җан рәхәте») китабын һәм башка иске басма китапларның кисәкләрен мирас буларак саклый.

Лотфуллова (Хәйретдинова) Рауза Фәсхи кызы, 1946 елгы, колхозда эшләгән.

– Бу китаплар каенанам Лотфуллова Мәниганыкылар, 1912 елгы иде. Каенатам Хәйрулла иде, Ватан сугышында үлгән. Болар – аларның язмалары, – дип иске язмалар күрсәтте. Кулъязмалар буларак, Институт «Мирасханә»сенә алдым.

Мукшы Күле авылына килдек. Рәсми рәвештә «Мордово-Озеро» дип атала икән.

Авыл мулласы Хисмәтуллов Гыймран Госман улына килдем. 1946 елгы. Ул эш арасында иде. Кибән очлый. Болытлапкаралып яңгыр ишелеп килеп маташа. Җитмәсә, мин борчып йөрим...

Гыймран Госман улы башта мәктәп директоры булган, тарихтан укыткан. Саратов партия мәктәбенә укырга җибәргәннәр. «Ирек» колхозына, шушы авылга, парторг булып кайткан.

– Районга яшьтеләр, бармадым! – диде ул. – Совет рәисе булдым. Филипта. Мәктәп – сигезьеллык иде. «Опорная школа»га әверелде татар телендә укытуда. «Татар движениесе» җитәкчесе булдым районда... Иске китаплар – юк! Хәйдәр абый Сәлимов, Казанда яши иде, псевдонимы «Үзе» булган. Балалар өчен язган. Совет чоры кешесе. Колхозга исемне ул биргән. Нindидер карга турында шигыре бар иде, ничек иде әле, хәзер... Монда китап җыючылар булды инде. Элеккеге Коръән бар иде, бер мөнәҗәтләр китабы бар иде. Алып киттеләр...

Бераздан ачылып китте. Аның әнисе Хисмәтуллова Гөлҗиһан Мингали кызы (1918–2008) авылда остабикә булган икән. Ерак түгел аның яшәгән йорты, ихатасы, яңгырлар сеңеп череп, җимерелеп бара. Эченә керергә куркалар. Шулай да анда өстәлдә бер тартма барлыгы шәйләнде, китап булырга кирәк иде. Анда кердек. Арадан берничә кульъязма дәфтәрен, сакланганнарын, үзем белән алдым.

«Остабикәнең язмалары» булырлар, шулай дип исем кушарбыз, – дидем.

Гыймран ага бик яхшы рәссам да икән. Олы-олы кысаларга затлап, йорт эче диварларына элеп куйган пейзажларны күреп, мин дә сокландым.

*14 июль,* Парау авылы.

Габделҗәббар Кандалыйның гүзәл Сәхипҗамалы шушы авылдан инде!

Авылның исеме «пар аучы» сүзеннән, имеш. Бу – халык иҗатына карый, анысы. Әмма халык фантазиясенә сокланырга була!

Бу авыл аша борынгыда «Калмык юлы» узган, Болгар чорына нисбәтле борынгы шәһәрчек калдыгы да бар икән алардан ерак түгел генә. Аннары, «Ишаннар каберлеге» дип аталучы, өч ишан җирләнгән зират та бар булып чыкты.

Авылда иске басма һәм кульъязма китаплар табылмады. Экспедиция шушы авылда тәмамланды. Юлыбыз Казанга алып кайтып китте.

## УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ РАЙОННАРЫНДА ТАБЫЛГАН КУЛЪЯЗМАЛАРНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

*2017 елның 3–14 июльләрендә уздырылган комплекслы экспедиция йомгакларыннан.*

№ 1.

1. Шәмионова Рәхилә Зиннәт кызы (1951) биргән кулъязма. Яңа Терешка авылыннан Шиһаб мулланыкы, диде. Рәхилә ханым Урта Терешкада яши. Бу ике авыл кушылып, хәзер бер авыл хасил итәләр икән.

2. Кулъязма 1898 елның 31 июнендә төзелгән, үлем-җитем хакындагы справка-белешмәләрдән гыйбарәт. Аларны рус телендә Яңа Терешкә имамы Гомәр Ибраһимов язган. Икәү. Икесе дә үзара тегелгән. Артларына гарәп графикасында болай дип язылган: «Саулыкта үлгән Гафур Габдрахмановның мөҗер яшь бала 1898 ел».

«Саулык» – «больница» дигән сүз.

3. Сәхифәләр 11,0×18,0 см зурлыкта, 1а–4б биттә. Кара кара белән язылган.

№ 2.

1. Хат. Гарәп графикасында, татарча.

2. «Язылды 23 апрельдә 1955 елда», диелгән. Сәгади абыйсына язылган. Ахыры юк.

3. Битләр 16,5×20,5 см зурлыкта. 4 сәхифәдән гыйбарәт.

№ 3.

1. Кулъязма китап, XIX йөз. Шәригать мәсьәләләре хакында, гарәп телендә.

2. Ахыргы битендә «Ошбу китап мулла Хәсән Вәлид Мөхәммәт бай мәзин Умыртаулави» дип язылган. 1851 һ.б. ел күрсәткечләре белән кешеләрнең вафаты даталары тезелеп төшкән.

3. Сәхифәләре 17,0×20,5 см зурлыкта. Кара каләм белән язылган. Тышлыгының ахыргысы бар, ул иске кәгазьләрдән, аларны үзара ябыштырып, катыргы итеп эшләнелгән.

№ 4.

1. Кулъязма китап. XIX йөз урталарына карый. Гарәп телендә.

2. Коръән уку, мөселман булу, шәригать мәсьәләләрен яктырта.

3. Башы-ахыры – юк. Начар сакланган.

4. Сәхифәләре 17,0×20,5 см зурлыкта.

№ 5.

1. Кулъязма китап. Фарсы телендә. Хәдисләргә аңлатмаларга, әдәп мәсьәләләренә бәйле. Алгы битләре бар. Тышлыгы да алгы яктан бар. Әсәрнең башы да бар. Аңа, алдына, кулъязма китап тегелгән. Әмма анысының читләрен таракан ашаган. Мондый язуы күренә: «Мең дә сигез йөз дә туксан икенче… Гыйнварның утызынчы йәүмендә, чәршәмбе көн тәмам», алдарак: «Китап Әхмәт Шаһи-Әгъзам Фәтхулла Җар Әхмәтҗан Ибраһим угылының», диелгән. Алга таба да аның кулъязмасы булырга кирәк. Икесе – ике төрле, әмма язу рәсемнәре – охшаш.

2. Сәхифәләре 16,0×20,5 см зурлыкта. Тышлыгы – калын. Кулъязма кара кара белән язылган.

№ 6.

1. Дамилла Мөхәммәтҗан ахун әфәнде хәзрәтләренә аңлатма хат нөсхәсе, 1898 елның 26 июнендә язылган. Ахырында мулла Мөхәммәтгали бине мулла Бәхтияр мөһере сугылган, метрика дәфтәренә язылган никах хакында. Бер сәхифәдә.

2. Сәхифәнең зурлыгы 17,0×21,5 см зурлыкта.

3. Иске Кулаткы районы Урта Терешка авылында Хәмзина Акилә Сафа кызы (1934) тапшырды.

№ 7.

1. Беренче Бөтендөнья сугышы солдаты Дебердеев Касыймның кулъязма дәфтәре. Урта Терешка авылында Акилә Хәмзинада сакланган.

2. Бәетләр тупланган. Дәфтәрнең башы-ахыры юк. Сакланган сәхифәләренең беренчесе «Дүртенче. Сала көенә» дип башлана, аның артыннан «Сак-сок бәете» килә.

3. 2 б. биттә «Яхшы шигырьләр» дип куелган. Мәктәп салуны сорап язылган шигырь килә.

4. 6 б. биттә татарлык хакында шигырь килә, аны «татар угылы татар» булу хакында дип белдергән:

«Инсан улан өстенә таг
Төшсә дә хәвеф итмәс,
Итмәсен батыйна хәвеф,
Итсә – итсен заһирә.
Бел ки, тәмам»

5. 10 а. биттә «Уян шәкерт будыр» дип куелган, «Уян шәкерт» гимны сүзләре килә. Ахырында «Ошбу дәфтәр мулла Касыйм Әхмәди» диелгән.

6. 10 б. биттә шәхси тугра-мөһере бар.

7. 11 а. биттә татарча «Салават шәриф» язылган.

8. 11 б. биттә Якуб һәм Йосыф пәйгамбәрләр хакында кыскача хикәя килә.

9. 12 а. биттә хәзрәте Исхак галәйһиссәлам хакында хикәят килә, алга таба бүтән пәйгамбәрләр хакында хикәятләр бирелә.

10. 13 б. биттән шигырь күчермәләре башлана.

11. 14 б. биттә «Яхшы шигырьләр» диелгән. Арада «Сугыш бәете» дә бар.

12. 18 б. биттә өстәмә язылган: «Дневник участника Первой Мировой войны Добердеева Косыйма 1914–1918 г.».

13. Ахыры бар. Тышлыгы юк. Дәфтәр итеп тегелгән.

14. Сәхифәләре 17,0×21,0 см зурлыкта.

15. Сәхифәләрдә дәфтәрнең хуҗасы үзенең Касыйм Әхмәт булуын язма рәвештә күрсәткәләп барган. Анык булуына шунлыктан шик уятмый.

№ 8

1. Яңа Мостяк авылыннан Җирҗис хаҗи Газизовтан, 1937 елгы. Аның аңлатуынча: «Имамчылык итеп йөри башлагач, мондый китапларны авылдан җыя идем. Моны Вәлиев Муса Билал улыннан алган идем, 1913 елгы булса кирәк ул. Бу китапны каян алуын әйтмәде. Үз авылларында чормалар төзәтеп йөргән чагында тапкан».

2. Дәфтәрнең башында әрвахлар белән бәйле фәлсәфәле хөтбә килә. Татарча. Аларның могҗизалары тасвирлана. Суфичылык иктабы булуы аның эчтәлегеннән аңлашыла. Монда суфи шәехләрнең тарихлары мистик эчтәлектә ачыла.

3. Алга таба фарсы телендә «Нуры максуд» дип башланган поэма килә.

4. Аннары «Әл-лэтаиф» («Мәсәлләр») бүлеге килә, аерым китап буларак төзелгән, имам Баһави белән бәйле, кальб, рух һ.б. мәсьәләләргә бәйле фәлсәфәләр, тарикать гыйлеме хакында фарсы телендә трактат урнаштырылган.

5. Калын. XIX йөз башы китабы. Кара кара белән яхшы шома кәгазьгә язылган.

6. Сәхифәләре 11,0×17,5 см зурлыкта. Башы бар, ахыры юк.

№ 9.

1. Иске Мостяк авылы Түбән оч мәчетеннән мулла Рөстәм Куртяков тапшырды, клуб мөдире Рауза Әхмәтҗанова да шунда иде.

2. Сәхифәләрдән гыйбарәт, алар 17,0×25,5 см зурлыкта.

3. Суфичылык, тарикать гыйлеме хакындагы китаптан.

№ 10.

1. Шәкерт дәфтәре. Башы-ахыры юк. Калын. XIX йөзгә карый.

2. Сәхифәләре 17,0×21,5 см зурлыкта.

3. XX йөз башы кульъязмасы.

№ 11.

1. Кульъязма китап. Башы-ахыры юк. XIX йөзгә карый.

2. Иске Мостяк авылы Түбән оч мәчетеннән.

3. Сәхифәләре 17,0×21,5 см зурлыкта.

4. Гарәп телендә. Уртача сакланышта.

5. Шәригать гыйлемнәренә багышланган. Кара кара белән язылган.

№ 12.

1. «Мәүлет китабы»ннан күчерелгән, аерым битләрдән гыйбарәт касыйдәләр. Өч сәхифә, сызыклы дәфтәр битләренә зәңгәр кара белән күчереп язылган.

2. 1970–80 еллар ядкяре.

3. Иске Зеленай авылыннан Ханбикова Рәсимә бирде.

4. Сәхифәләр 16,5×21,0 см зурлыкта. Касыйдәләр төрки-татар телендә.

№ 13.

1. Рисаләи Фарзы-гайн һәм дәгъват» («Табигый фарызлар һәм дәгъватлар язмасы») китабы, 1902 елгы, аңа өстәп кулдан күчермәләр эшләнелгән, шул рәвешле әсәр тутырылган. Бу берничә сәхифә кулъязма советлар чорында эшләнелгән. Дини китап төпләү культурасының советлар чорына хас үзенчәлекле чагылышы.

2. Зәңгәр кара белән 1960 елларда күчерелгән сәхифәләре белән кызыклы.

3. Сәхифәләр 11,0×17,3 см зурлыкта. Гарәп һәм төрки телләрдә.

№ 14.

1. 1961 елгы кулъязма дәфтәрдән сәхифәләр. Дини шигырьләрдән тора, ахырда истәлек язмасы да бар. Анда дәфтәрне төзүче үзе хакында Рабига Хәмзиева булуын, 4 сәгать буена юлда килеп, 1961 елның 19 июлендә Караганда шәһәренә кунакка барып җитүен яза.

2. Кулъязма татар телендә, зәңгәр кара белән язылган, укучылар дәфтәрендә. Ахыры югалган.

3. Сәхифәләр 17,0×20,5 см зурлыкта.

№ 15.

1. «Мөселманнарның мәркәзе диния нәзарәтеннән» 1934 елгы карары. Ташбасмада эшләнелгән. Карарның ахырында казыйлар кулларын куйганнар.

2. 2 сәхифәле, зурлыклары 22,5×35,5 см форматында.

3. Начар сакланышта.

4. Татар Гуринкәсе авылыннан Газизуллова Фәйрүзә Хәсән кызы (1941 елгы) Институт «Мирасханә»се өчен дип тапшырган. Әбисе Мәчтүрә саклаган булган, ул Аксу авылында яшәгән.

№ 16.

1. Төрки телендә гакыйдә кулъязма китабы сәхифәләре. XIX йөз башына карый. Кара каләм белән язылган. Ачык һәм матур язулы.

2. Сәхифәләр 15,0×20,0 см форматында.

3. Аксу авылыннан Мәчтүрә әбинең китаплары, тапшыручысы – Газизуллова Мәчтүрә Хәсән кызы (1941 елгы). Табылу урыны: Татар Гуринкәсе авылы.

№ 17.

1. Шәригать китабы кулъязмасы, башы-ахыры юк, XIX гасырның ахырына карый. Кара каләм белән язылган. Урыны-урыны белән аңлатмалары да бар. Гарәп телендә.

2. 17,5×22,0 см зурлыктагы сәхифәләрдән тора. Яхшы сакланганнар.

3. Аксу авылыннан Мәчтүрә әбинең китаплары, тапшыручысы – Газизуллова Мәчтүрә Хәсән кызы (1941 елгы). Табылу урыны: Татар Гуринкәсе авылы.

№ 18.

1. Догалык һәм бөтилекләр җыентыгы, 1960 еллар ядкяре. Укучы балалар дәфтәре битләренә язылган. Теткәләнгән, тышлыгы юк.

2. Сәхифәләре 16,5×20,5 см зурлыкта, ахыры юк.

3. Соңгы урыны: Яңа Зимичә авылында авыл мәдрәсәсендә сакланган.

№ 19.

1. Мөнәҗәтләр дәфтәре. 1970–1980 елларда тупланган. 5 нче биттән башлана. Тышлыгы – юк. Укучы балаларның гомуми дәфтәренә гарәп графикасында язылган, зәңгәр ручка белән, сызыклы битләрдә.

2. 16,5×20,0 см форматта.

3. Яңа Зимичә авылы мәдрәсәсе – соңгы саклану урыны. Күчерүчесе – билгесез.

№ 20.

1. Хатын-кызлар әдәбенә багышланган мәкалә, 1960 елларда төзелгән, шакмаклы дәфтәр битләрендә. Башы бар, ахыры юк. Тышлыгы юк.

2. Сәхифәләре 14,5×20,0 см форматында.

3. Яңа Зимичә авылы мәдрәсәсеннән тапшырганнар.

№ 21.

1. Иман догалары, мөнәҗәтләр, көндәлек догалар тупланмасы сәхифәләре. 1960–1970 еллар арасында төзелгән. Мәктәп дәфтәре битләрендә.

2. Сәхифәләр 16,5×20,5 см зурлыкта.

3. Филип (Филипповка) авылының (Мәләкәс районы) Лотфуллова Рауза Фәтхи кызында саклаган.

№ 22.

1. Мөнәҗәтләр дәфтәре. Авторы – Хисмәтуллова Гөлҗиһан Мингали кызы (1918–2008). Мукшы Күле авылыннан.

2. 96 биттән гыйбарәт гомуми дәфтәрдә. 1990 елларда төзелгән, текстлар ручка белән язылган.

3. Сәхифәләр 16,5×20,0 см форматында. Тышлыгы бар, эчендә кайбер битләре юк.

4. Иске, ташландык, җимерек өендәге өстәл өстенә өелгән китаплары арасыннан алып чыктым.

№ 23.

1. «Коръән тәфсиренең мәгънәләре. Казан мөселманнары телендә. 1910 елда басылган. Әүвәл Коръән». Күчерүчесе – Хисмәтуллова Гөлҗиһан Мингали кызы, Мукшы Күле авылыннан.

2. 96 сәхифәдән гыйбарәт гомуми дәфтәргә 1990 елларда күчереп язылган, язмасы ручка белән башкарылган. Тулы, тышлыгы бар.

3. Сәхифәләр 16,5×20,0 см форматында.

№ 24.

1. Мөнәҗәтләр дәфтәре. Авторы – Хисмәтуллова Гөлҗиһан Мингали кызы. 1990 еллар дәфтәре. Мукшы Күле авылында язылган.

2. 96 сәхифәле гомуми дәфтәргә гарәп графикасында язылган. Дини хисләр белән сугарылган.

3. 15,0×20,0 см форматындагы сәхифәләрдән гыйбарәт. Текстлар яшел ручка карасы белән язылганнар. Дәфтәр – тулы, тышлыгы бар.

№ 25.

1. Дин өчен көрәш тарихларынан Әбу-Җәһил һәм Рәсүл, Муса пәйгамбәр һәм Фиргавен һ.б. риваяти вакыйгаларны яктырткан аерым-аерым, мәдәни күрсәткеч ядкяре буларак әһәмиятле дәфтәр. Күчерүчесе – Хисмәтуллова Гөлҗиһан Мингали кызы (1918–2008). Мукшы Күле авылында яшәгән. Кульязма 12 шәр битле дәфтәрләрдән җыйнап тегелгән.

2. Текстларның иске басма китаплардан күчерелгәнлеге күчерүченең хатасыз язуыннан күренә. Зәңгәр каралы ручка белән башкарылган. Арада догалар да очрый, мөнәҗәтләр дә бар.

3. Сәхифәләр 17,0×20,5 см зурлыкта.

№ 26

1. Төрле эчтәлектәге язмалардан гыйбарәт, аерым сәхифәләр җыелмасы. Хисмәтуллова Гөлҗиһан Мингали кызының язмалары һәм күчермәләре. 1990 елларга карыйлар.

2. Эчтәлекләренә караганда – мөнәҗәтләр, догалар, бәетләр, өйрәнчек язмалар.

3. 17,5×20,0 см форматтагы мәктәп дәфтәрләре сәхифәләреннән гыйбарәт.

№ 27

1. Гаруз гыйлеменә һәм поэтика гыйлеменә багышланган трактат. Гарәп телендә. XIX йөз кульязмасы.

2. Янганнан калган. Башы-ахыры юк. Шәехләр һәм аларның тарикатьләре хакында да бүлекләр бар.

3. Сәхифәләре 17,5×21,0 см форматында. Калын китап.

4. Вязовый Гай авылы мәчете имамы Бәширов Мөйәссәр Борһан улы (1945 елда туган) тапшырды.

№ 28.

1. Тәһарәт һәм иман кульязма китабы. Фарсы телендә. Вязовый Гай авылы мәчете имамы Бәширов Мөйәссәр Борһан улы тапшырды.

2. 1а биттән – тәһарәт фарызлары хакында фарсыча бүлек.

3. 4а биттән – иман мәсьәләсе хакында.

4. 4б биттән – намазда каим мәсьәләсе хакында.

5. 9а биттә кириллицада, русчалап исемлек бирелә:

1. Абдрахмань,
2. Хисаметдинь,
3. Абдулъ Каримъ,
4. Татар Шамсити,
5. Шерефетдин,
6. Асьметь,
7. Фетхулла,
8. Айнюкь,
9. Мефьтехдинъ,
10. Исхакъ,
11. Муберкъ.

6. 9б–10а битләрдә – хикәят күчерелгән.

7. 10б. биттә «1879» датасы бар. Алга таба мондый язу очрый: «1879 елын нояберенең 27 нче көн берлә зөһер Габдерахман Галиәкбәр угылы яздым ошбу китапны ноябрьнең 27 көн берлә тәмам булды, язып, кулым куйдым».

8. 11а биттән «Мәсьәлә» мәкаләсе язылган.

9. Кулъязма 1а биттән 13б биткәчә дәвам итә, сәхифәләр 10,5×18,0 см зурлыкта.

№ 28.

1. Усманов И.Х. дәфтәре. Бер битендә «28/V–51 г.» датасы бар. Дини мәсьәләләргә багышланган мәкаләләрдән, татарча күчермәләрдән гыйбарәт.

2. Сәхифәләре – таркау. Язма битләре дәфтәр тышлыгы эчендә. Башы-ахыры юк. Дәфтәр тышлыгында «Вельшин Рафик» дигән язуы да бар.

3. 17,0×21,0 см форматында. Зәңгәр кара белән язылган.

№ 29.

1. Дин әдәпләре, кагыйдәләре, риваятьләре һәм хәбәрләре кулъязма җыентыгы. Калын. Тулы.

2. Вязовый Гай авылы мәчете имамы Бәширов Мөйәссәр Борһан улы тапшырды.

3. Тышлыгы бар. 1950 еллар башы китабы. Төзүчесе урындагы бер мулла булса кирәк. Шәхесе ачыкланмады.

4. Сәхифәләре 16,0×20,0 см форматында. Зәңгәр каралы һәм каләм-карандаш язулы сызыклы дәфтәрләр үзара тегеп эшләнелгән.

№ 30.

1. Төрле китаплардан җыйналма күчермәләр җыентыгы. «Хасияте догаи-хәбиб» белән башлана. Алга таба төрле догалыклар урнаштырылган.

2. Атнагыл авылы мәчете имамы Рафикъ хәзрәт тапшырган.

3. Зәңгәр кара белән язылган, 1980–1990 еллар күчермәсе. Тегелгән, тышлыгы юк.

4. Сәхифәләре 13,5×20,0 см форматында.

№ 31.

1. Хөтбәләр җыентыгы. Куен дәфтәре итеп төзелгән. Тегелгән. Тышлыгы юк. Ахыргы битендә «1914 елның 1 нче ноябре, җомга» дигән язуы бар. Ручка белән язылган. 1980–1990 еллар күчермәсе.

2. Атнагыл авылы мәчете имамы Рафикъ хәзрәт тапшырган.

3. Сәхифәләре 15,0×16,5 см форматында.

№ 32.

1. Хизбулла Габделмәгыйзев хатлары. 1985 елда язылганнар. Гарәп графикасында. Казаннан. Фотосы да бар.

2. 5 хат.

3. Мәктәп укучысы дәфтәре битләрендә язылганнар.

№ 33.

1. Дини нәсыйхәтләр, «Исме-әгъзам» («Аллаһының бөек исемнәре») китабы күчермәсе.

2. Шартлы рәвештә билгеләгәндә, 1975 еллар тирәсендә төзелгән. Текстлар зәңгәр кара белән язылган.

3. Атнагыл авылы мәчетеннән.

№ 34.

1. «Бәкарә» сүрәсе (Коръәннән) күчермәсе. Ешлык сүзлеген төзү өчен эшләнелгән, эш процессын ачык күрергә була.

2. 1950 еллар дәфтәре.

3. Атнагыл авылы мәчетеннән.

№ 35.

1. «Коръән тәфсире»ннән күчермә. Куен китабы. Тулы. Башында «Иман шарты» бирелә. Тулы. Тышлыгы бар.

2. 1980 елларда төзелгән.

3. Атнагыл авылы мәчетеннән.

4. Сәхифәләр 10,0×16,0 см форматында.

№ 36.

1. Хәдисләр җыентыгы. 1970 елларда төзелгән. Тышлыгы бар. Тулы.

2. Блокнот. Сәхифәләре 9,5×14,0 см форматында.

3. Атнагыл авылы мәчетеннән.

№ 37.

1. Хатыннар әдәбенә багышланган китап. Тышлыгында «Шиһабетдин бабай кызы Иләлия» дигән язуы да бар.

2. 4 дәфтәр бергә бербөтен итеп тегелгән. Дини тәрбиягә багышланган.

3. 1979 еллардан соң төзелгән булырга тиеш.

4. Сәхифәләре 17,0×20,5 см форматында.

5. Атнагыл авылы мәчетеннән.

№ 38.

1. «Коръән тәфсиреннән бик кирәкле. Бик хасиятле. Безнең телдә язылгандыр» дигән аңлатмалы кулъязма китап.

2. 1970–1980 елларда төзелгән, яхшы итеп тышланган.

3. Сәхифәләре 17,5×20,5 см форматында. Текстлар кара ручка белән язылган.

# ТАТАРСКИЕ ЭПИГРАФИЧЕСКИЕ ПАМЯТНИКИ УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ

*Венер Усманов*

История изучения кабрташей «Симбирской губернии» имеет почти двухсотлетнюю давность. «В 1833 году в журнале «Заволжский муравей» появилась статья неизвестного автора о надмогильных камнях из села Татарский Калмаюр»[1]. Некоторые важные сведения об этих эпитафиях имеются в публикациях Ф. Хакимзянова[2]. Кроме этого, ведущим эпиграфистом Д.Г. Мухаметшиным в 2010, 2016 гг. были исследованы эпитафии Старокулаткинского, Павловского, Николаевского, Чердаклинского, Старомайнинского, Мелекесского районов, которые в настоящее время находятся на стадии научной обработки.

Со 2-го по 13-ое июля 2018 года была организована научная комплексная экспедиция ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова в Павловский, Николаевский, Чердаклинский и Новомалыклинский районы Ульяновской области. В результате этой поездки в 24-х населенных пунктах исследовано 35 старинных кладбищ и зафиксировано 20 арабографических надмогильных камней. В данной статье эти артефакты рассматриваются как историко-культурный

---

[1] *Мухаметшин Д.Г.* Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Серия «Археология евразийских степей». Вып. 6. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 6, цв. вкл. I.

[2] *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. – М.: Наука, 1978. С. 169, 194.

источник. На этой территории сохранились стелы двух периодов истории татарского народа, первая группа – 7 плит (а всего их было зафиксировано предшественниками – 11), относящаяся к эпохе Золотой Орды, а вторая – конец XIX – нач. XX вв.

Из семи ранее зафиксированных калмаюрских стел, ныне на прежнем месте осталось – 5 (точнее – 6), один из них (верхняя фрагментарная часть памятника) находится в областном краеведческом музее г. Ульяновска. Остальные кабрташи (фрагменты), относящиеся к периоду Золотой Орды, в настоящее время находятся на территории села Енганаево. Сведениями об эпитафиях с. Матвеева мы не располагаем.

По мнению Д.Г. Мухаметшина, здешние Золотоордынские кабрташи относятся к Болгарской школе и выполнены местными мастерами[1]. Наличие древних плит говорит о том, что здесь находился один из многочисленных феодальных центров. И вероятнее всего, для изготовления «калмаюрских», а также и других «симбирских» эпиграфических памятников, использовался привозной материал – известняк или песчаник.

На территории Симбирского края одним из коренных (основных) народов являются татары, в частности, этническая группа мишари. Как показывают исследования, у них не наблюдается ярко выраженная традиция установления эпитафийных памятников на могилах усопших. По нашему мнению, это явление объясняется, в первую очередь, отсутствием в местах их проживания карьеров легкообрабатываемого камня.

«В этих краях широко распространено оформление краев могилы большими камнями, добываемых на местах. Некоторые из них достигают одного метра и более. Над могилой насыпается привозной грунт, в отдельных случаях насыпь могилы превращается во внушительное сооружение. У изголовья в обязательном порядке ставится большой необработанный камень без подписи. Ареал распространения данной традиции широк – село Старая

---

[1] *Мухаметшин Д.Г.* Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. С. 33

Кулатка Старокулаткинского района Ульяновской области и до села Средняя Юлюзань Чаадаевского района Пензенской области... Традиция ограждать могилы камнями в XIX в. начала уступать новым традициям по общемусульманским канонам, внесенным мусульманскими духовными деятелями»[1]. С бурным ростом экономики и с развитием транспорта в конце XIX – в начале XX веков снова возобновились культурные связи провинциальных татарских деревень Симбирской губернии с мусульманскими центрами, в частности, с Казанью. Именно этим объясняется наличие высокохудожественных работ столичных авторов в некоторых сельских кабрстанах Симбирского уезда.

## Чердаклинский район, с. Татарский Калмаюр (всего 5+1=6 стел)

«В окрестностях села Татарский Калмаюр – три курганные группы (предположительно бронзовый век). Третья группа находится в 3-х км к востоку – северо-востоку от села на территории старого, полузаброшенного мусульманского кладбища»[2].

Мазарстан включает в себя и болгарский могильник XIV века. «Болгарские надгробия, из которых, очевидно, лишь отдельные находятся на месте могил, – это прямоугольные плиты с врезанными и рельефными куфическими надписями. Из 5 надгробий 3 сохранились целыми, 1 распалась на 2 части, от другого остался лишь фрагмент, шестая плита хранится в Ульяновском областном краеведческом музее. Калмаюрское надгробие – подлинное произведение искусства, а могильник – уникальный для Ульяновского края археологический памятник»[3].

### *1. Надмогильный памятник Туйжи сына [Куддуса]*

---

[1] *Мухаметшин Д.Г.* Юсупов и проблемы татарской эпиграфики // Поволжская Археология. 2014. С. 24.

[2] *Ахметов А.* История возникновения и развития села Уразгильдино Чердаклинского района Ульяновской области (1905–1990 гг.). Ульяновск, 1991. С. 3.

[3] Там же.

Форма верхней части стелы прямоугольная, со стрельчатой аркой с плечиками, выполненная способом стесывания пространства вне арки. По классификации ведущего татарского эпиграфиста Д. Мухаметшина, этот кабрташ относится ко II типу надмогильных памятников первой половины XIV века. Эта эпитафия с первой частью формулы «Он живой, который не умирает» в тимпане входит в подтип «А». Из орнаментации эпитафии нужно отметить виноградную лозу, отделяющую основной текст от заглавной формулы. В данном случае, она заменена широкой рельефной полосой, которая выполняет декоративную функцию[1]. Далее продолжение коронической формулы «Всякая душа вкусит смерть».

На лицевой стороне текст написан рельефным и врезанным способом, куфическим шрифтом и почерком насх.

| Текст | Перевод |
|---|---|
| هوالىالذىلايموت | 1) Он живой, который не умирает, |
| وكل نفس ذايقة الموت | 2) а все живущее умрет. |
| .................. | 3) [Куддуса … сын] |
| تويجا زيارتى ترور | 4) Туйджи могила. |
| رحمة الله عليه رحمة | 5) Да будет милость Аллаха над ней милостью |
| واسعه تاريخ يتى يوز | 6) обширною. По летоисчислению |
| ايليک توقوزدا شوال ايحى | семьсот пятьдесят девять лет, шавваля месяца |
| ..................... | ........................... |

Боковые рельефные надписи стерты до неузнаваемости. В качестве опорных «точек» мы можем избрать только несколько ключевых слов и наборы букв, которые читаются более или менее уверенно. Но, однако, таких слов в тексте очен мало. Для реконструкции этих устойчивых выражений требуется участие хороших специалистов по арабскому языку.

---

[1] *Мухаметшин Д.Г.* Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Серия «Археология евразийских степей». Вып. 6. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 28 – 29.

На правой стороне плохо сохранившиеся куфические надписи (т.е. отдельные отрывочные слова и буквы):

عوا    لا ر    فيها وان
لا    ر    و

На левой стороне плохо сохранившиеся куфические надписи (слова и буквы):

للعبا    سو    الـ    وس    مزن    لـ
و ان هفو هفو    الرب غفار

Размеры памятника: 21×63×136 см.
Координаты: N 54°12. 891′
E 048° 58. 394′

### *2. Надмогильный памятник Инабека сына Байкары. XIV век*





Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| بایقرا اوعلی | 1) Сына Байкары |
| اپنه بك زپارتي | 2) Инабека могила |
| رحمة الله عليه | 3) Да будет милость Аллаха |
| رحمه واسعه | 4) милостью обширную |
| …………… | 5) …………….. |

Размеры памятника: 17×41,5×75 см.

Координаты: N 54°12. 923′
E 048° 58. 391′

## *3. Надмогильный памятник Кутлугтимура сына Кутлугбека. 1356 год*

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| .....له | 1) ...... |
| الحم لله | 2) Суд принадлежит Аллаху |
| قو تلوغ بك | 3) Кутлуг-бека |
| اوعلى قوتلوغ | 4) Сын Кутлуг |
| تمور... | 5) Тимур ... |
| تاريخ پتىپوز | 6) По летоисчислению семьсот |
| پلپك سپكزدا دا | 7) пятьдесят восемь |
| عرسپر ا پردى | 8).............. был |

Кабрташ естественным образом разломан минимум на две части. Шрифт надписи – врезанный полукуфи-полунасх.

Размеры памятника: 21×51×(69+73) 142 см.

Координаты: N 54°12. 923′
E 048° 58.394′

### *4. Надмогильный памятник сына Йори Кюча Ар-Ходжи. XIV век*

Лицевая часть

| Текст | Перевод |
|---|---|
| هوالیالذیلایموت | 1) Он живой, который не умирает, |
| و کل حی سیموت یوز | 2) а все живущее умрет. Йори |
| کوج اول ارخواجه | 3) Кюча сына Ар-ходжи |
| زیارةی | 4) место погребения. Да будет ми- |
| رحمة الله علیه رحمة | 5) лость Аллаха |
| واسعه | 6) над ним милостью обширною. |

На оборотной стороне имеется семилепестковый цветок изображенный в круге. Плита ( чуть правее от середины ) отколота на двое, разделяя эпитафию на две половины.

Размеры памятника: 20×58×100 см.

Координаты: N 54°12. 931′
E 048° 58. 439′

Источник: *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. М.: Наука, 1978. С. 168.

### *5. Неатрибутированный памятник № 1. 1353 год*

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| ………………… | ……………………………………….. |
| تاریخ یتی یوز الیك | По летоисчислению в семьсот пятьдесят |
| تورت دا محرم ایی | четвертом в месяце мухаррям |
| | ………………………………………….. |

Эпитафия сильно повреждена под воздействием отрицательных природных факторов. Реконструкция верхней части ориентировочная. В тимпане изображен шестилепестковый цветок бадьяна. Шрифт надписи – врезанный насх.

Размеры памятника: 25×60×108 см.

Координаты: N 54°12. 881′
E 048° 58.388′

### *6. Надмогильный памятник сына Шаба-билека. XIV век*

(Хранится в областном краеведческом музее г. Ульяновска)

Кабрташ представляет из себя композицию с розеткой в тимпане с килевидной формой арки с «плечиками». Во внутреннем кружочке «цветка бадьяна» изображена шестилепестковая розетка меньшего размера. Видимо, основной текст написан врезанным способом, почерком насх.

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| الحكم لله العلى الكبير | 1) Верховный суд принадлежит Аллаху Всевышнему, Великому |
| شبا بيلک اول...... | 2) Шаба-билека * сын …….. |
| ايح...... | 3) ……… месяца …….. |
| ............ | 4) …………………………….. |

Вариант: Шабайбек (?)

### Чердаклинский район, с. Енганаево

### *1. Неатрибутированный памятник (фрагмент, нижняя часть основания плиты)*

Каких-либо надписей не сохранилось.

Размеры памятника: 22×67×66 см.

Координаты: N 54°25. 793′
E 048° 53. 568′

### *2. Неатрибутированный памятник*

*(фрагмент, нижняя часть эпитафия)*

Текст был написан на протоболгарском языке.

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| جال...... | 1)………….. лет |
| ات | 2) было. |

Шрифт надписи – врезанный полукуфи-полунасх.
Размеры памятника: 19×44–50×71 см.
Координаты: N 54°25.820′
E 048° 53. 570′

### *3. Неатрибутированный памятник (фрагмент). 1888 г.*

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| اعوذ نا الله من الشيطان الرجيم | 1) Прибегаю к защите Аллаха от проклятого шайтана. |
| بسم لله الرحمن الرحيم | 2) Именем Всевышнего, Милостивого, Милосердного. |
| محمد رسول الله وفات بولدى | 3) Нет бога кроме Аллаха, Мухаммад пророк его.Умер |
| طوقصان ياشنده١٨٨٨نجى يلده | 4) в девяностолетнем возрасте в 1888 году. |

Размеры памятника: 7×36×42 см.
Координаты: N 54˚ 25. 632′
E 048˚53. 318′

## Николаевский район, с. Татарский Сайман

### *Неатрибутированный памятник. 1856 год*

Эпитафия имеет сильные повреждения природного характера. Материал – известняк.

Тексты на лицевой и на левой боковой сторонах стерты до неузнаваемости, а на правой – видны еле заметные условные изображения минарета мечети.

Оборотная сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| ............* | 1) ................................. |
| ............ | 2) ..................................... |
| على المسجد | 3) ................. |

| | |
|---|---|
| و منع قو عن | 4) мечеть …………… |
| اوزون اشد پا وقت | 5) …………………………….. |
| العروس بلغ عمره٦٣ | 6) …………в 63-х летнем возрасте |
| توفى نصف رمضان١٢٧٣سنه | 7) скончался (скончалась) в середине месяца рамадан 1273 года (по хиджри). |

Размеры памятника: 16×32–36×103 см.
Координаты: N 53°17.509′
E 047°06.048′

## Павловский район, с. Евлейка

### *1. Неатрибутированный памятник*

Материал – местный «дикий песчаник».

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| لااله الا لله محمد | 1) Нет бога кроме Аллаха, Мухаммад |
| رسول الله | 2) Пророк его |

Размеры памятника: 11×40–55×100 см.
Координаты: N 52°13. 905′
E 047° 13. 930′

### *2. Неатрибутированный памятник*

Материал – местный «дикий» песчаник.

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| لااله الا لله محمد | 1) Нет бога кроме Аллаха, Мухаммад |
| رسول الله | 2) Пророк его |
| عزيز سيت اوعلى | 3) Газиз Саида сын |

Размеры памятника: 10–20×20×70 см.
Координаты: N 52°43.909′
E 047°13.931′

## Павловский район, с. Татарский Шмалак

### *1. Надмогильный памятник Джофар-бикэ Джагфара дочь. 1889 год*

На лицевой и боковых сторонах текст написан врезанным способом, казанским каллиграфом, почерком насх и сулс, с выдержанными пропорциями и параметрами букв, слов и строк.

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| هوالحی‌الباقی | 1) Он живой, вечен |
| الذی لایموت ابدا | 2) который не умирает …. |
| شمالاق قریه سنده | 3) Из деревни Шамалак |
| جفاربکه جعفراحتم اوغلی نك | 4) Джофар-бике Джагфара сына Ахтяма |
| قزی‌عبدالکریم حواجه احمد او | 5) дочь, Габдулкарима Ходжа-Ахмеда сы- |
| علی نك زوجه سی ۱۸۸۹ سنه ده | 6) -на супруга, 1889-ом году |
| ۸۵ یاشنده وفات بولدی | 7) в 85-и летнем возрасте умерла. |

На правой стороне (врезанная надпись)

| Текст | Перевод |
|---|---|
| علا متدن مرادم بردعادر | Прошу молитвы (у посетителей могилы)……… |

На левой стороне (врезанная надпись)

| Текст | Перевод |
|---|---|
| بوکون بکا ایکان یارین سنکادر | Сегодня (очередь) моя, а завтра тебе |

Размеры памятника: 20×39×105 см.
Координаты: N 52°44.051′
E 047°00.158′

### *2. Надмогильный памятник хаджи Хусаина сына Габдулкарима. 1910 год*

На лицевой и оборотной сторонах текст написан врезанным способом, казанским каллиграфом, почерком сульс, с выдержанными пропорциями и параметрами букв, слов и строк.

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| حاخ | 1) Хаджи |
| الحرمين حسينعبدالكريم | 2) Хусаин Габдулкарима |
| اوغلى سنه ١٩١٠م ١٠ نويابرده | 3) Сын, в 1910-ом году по григорианскому летоисчислению 10 ноября |
| ٧١ نجى ياشنده وفات ايدوب | 4) В возрасте 71 год скончался, |
| بوقبره دفن ايدلدى | 5) Погребен в этой могиле. |
| رحمه الله رحمة واسعة | 6) Да будет милость Аллаха над ним милостью обширною. |

Размеры памятника: 16,5×38× 119 см.
Координаты: N 52°44.130′
E 047°00.137′

### *3. Надмогильный памятник Габдулкарима сына Ходжа-Ахмеда. Конец XIX века*

На лицевой и боковых сторонах текст написан врезанным способом, казанским каллиграфом, почерком насх с выдержанными пропорциями и параметрами букв, слов и строк.

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| يا غفارالهم | 1) Да простит Аллах его грехи. |
| المتوفى | 2) Покойный |
| عبدالكريم | 3) Габдулкарим |
| حواجه احمد اوغلى | 4) Ходжа-Ахмеда сын |
| ٦٠ ياشنده ١٨ سنه ده | 5) В 60-летнем возрасте в 18 ….* году. |

* Габдулкарим скончался в конце XIX века. На эпитафии после цифр 18 (т.е. после даты: «тысяча восемьсот») оставлены пустые места для дальнейшего дописания. Эта деталь нам говорит о том, что кабрташ был заказан хозяином ещё при жизни.

На правой стороне

| Текст | Перевод |
|---|---|
| سن عتاب ایلاکل یامستعان | Не упрекайте нуждающегося в помощи |

На левой стороне

| Текст | Перевод |
|---|---|
| مرقد ک صاحبنه مر زمان | (Ведь) у хозяина могилы тяжелое время |

Размеры памятника: 16×32×72 (120) см.
Координаты: N 52°44.059′
E 047°00.154′

### *4. Надмогильный памятник Гайши дочери хаджи Хусаина*

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| و محی لا یموت | 1) ….(Аллах) не умирает |
| حاجیه عائشه ثابت | 2) Совершившая поломничество в Мекку Гайша Сабита дочь |
| حاجی حسین کریموف | 3) Хусаина хаджи Каримова |
| اهلیه سی میلادی١٩١٨نجی | 4) Супруга, по григорианскому летоисчислению в 1918 |
| یلده٢٠نجی اوعوستده ٨٠نجی | 5) году умерла, в этой могиле |
| یاشنده وفات ایدوب بوقبرده | 6) похоронена. Да будет милость |
| کوملدی رحمها الله رحمه وسعة | Аллаха над ним милостью обширную. |

Размеры памятника: 18×33×104 см.
Координаты: N 52°44.137′
E 047°00.133′

## Новомалыклинский район, с. Баткак

### *1. Надмогильный памятник муллы Хасанджана ал-Кизляви. 1951 год (Первоначальный кабрташ)*

Лицевая сторона (врезанная надпись)

| Текст | Перевод |
|---|---|
| لااله الا لله محمد رسول الله | 1) Нет бога кроме Аллаха, Мухаммад пророк его. |
| صاحب هذه القبرملا حسن جان بن‌ملااحمد | 2) Хозяин этой могилы мулла Хасанжан бин мулла Ахмад |
| | 3) Ал-Кизляви по григорианскому календарю 1866 [-ом году] |
| وفات١٩٥١يلده روميه ١٣٦٨ | 4) Скончался в 1951 году по византийскому (летоисчислению), в 13[6]8 (-ом году) |
| هجر يه‌ماه رجب ٢٤ ابريل٣٠ ده | 5) По хиджри в месяце раджаб 24 (-го), в апреле 30-го, |
| واصل وطنى كيزلودان باتقاق قريسينه | 6) Родом из (аула) Кизляу*, в деревню Баткак |
| هجرت ١٩٣٤ نجى يلده | 7) Переселился в 1934-ом году |

* Относилась к Самарскому уезду.

### *Обновленный (второй) кабрташ*

Оборотная сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| لااله الا لله محمد رسول الله | 1) Нет бога кроме Аллаха, Мухаммад пророк его. |
| صاحب هذهالقبر | 2) Хозяин этой могилы ……… |

| | |
|---|---|
| المريد ين مربى فى الطريقة النقشبنديه | 3) Мурид воспитанник религиозного направления ан-накшбандия |
| المرحوم الشيخ مولينا داملا حسن | 4) Покойный шейх ….. дамулла Хасан |
| الكيزلوى ثم قدس الباتقاقى سره | 5) Ал-Кизляви, потом (приехал жить в деревню) Баткак |

Размеры памятника: 17–42×53×55 см.
Координаты: N 54°09.036′
E 050°08.229′

## Новомалыклинский район, с. Лабитово

### *Надмогильный памятник имаму Хамадию сыну Амира. 1869 год*

По манере исполнения кабрташ изготовлен Оренбургскими (Каргалинскими) резчиками .

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| مرحوم المعفور | 1) Покойный прощенный |
| امام المسلمان | 2) Имам мусульман |
| حمدى امير ا | 3) Хамиди Амира с- |
| وعلى وفات | 4) -ын скончался |
| احتمال | 5) Возможно |
| ٣٦ياشنده | 6) На шестьдесят третьем году жизни |
| روحنه فاتحه | 7) Помолитесь за его душу |

На оборотной стороне

| Текст | Перевод |
|---|---|
| سنه ١٨٦٩ نجى | 1) 1869-ый год |
| هجريه ١٢٨٥ يازلدى | 2) по хиджри 1285, заказчик |
| اوعلى | 3) сын – |

| | |
|---|---|
| حماد | 4) Хаммад |
| بوجهاند ه كر سلتان جاهى | 5) В этом мире если даже ты султан высокопочтенный, |
| اخرى معزول اولب قبره كررسن سن غريب | 6) В конце определена могила, ты будешь изолирован как чужой. |

На правой стороне (снизу вверх)

| Текст | Перевод |
|---|---|
| قبرم نى زيارت ايد ن احوان دين | Обращение посетителям моей могилы |

На левой стороне (снизу вверх)

| Текст | Перевод |
|---|---|
| اولاسزازگو دعا معين | Прочитанная вами святая молитва будет помощью мне |

Размеры памятника: 14×25,5×114 см.
Координаты: N 54°02.118′
E 050°02.560′

## Новомалыклинский район, с. Старая Тюгальбуга

### *Надмогильный памятник Биби Накии дочери Фатхуллы. 1892 год*

Лицевая сторона

| Текст | Перевод |
|---|---|
| ١٣١٠ سنه هجريه ربعالخر | 1) В 1310 году по хиджри (в месяце) рабигуль-ахир |
| نده ببى نقيه فتح الله قزى | 2) Биби Накия Фатхуллы дочь, |
| كمال الدين زوجه سى٤٤ ياشنده | 3) Камаледдина супруга, в 44-летнем возрасте |
| وفات ١٨٩٢ نجى يلده اعوست ٢٠ نده مدفونه | 4) Умерла в 1892-ом году, в августе 20-го похоронена. |

Оборотная сторона

| Текст | Перевод |
| --- | --- |
| رحمها رحمة الله واسعة | Да будет милость Аллаха милостью обширною |

Размеры памятника: 10×45×87 см.
Координаты: N 54°01.991′
E 050°02.598′

Татарский народ имеет богатое культурное наследие, в том числе и эпиграфическое. К сожалению, эти произведения каллиграфии и камнерезного искусства, созданные на протяжении веков из местного известняка, под воздействием абиотических факторов интенсивно разрушаются и находятся под угрозой полного исчезновения. И поэтому есть настоятельная необходимость тщательного исследования и фиксации всех эпитафий (включая оставшиеся фрагменты и архивные фотоматериалы) с последующим изданием книг-каталогов.

# УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНДӘ ТАБЫЛГАН АРХЕОГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘР ХАКЫНДА

*Айгөл Әхмәтова*

Татар халкы борынгыдан белемле, китаплы халык булган. Бүгенге көнгә кадәр сакланып килгән кулъязма һәм басма мирасыбыз моңа ачыктан-ачык дәлил.

2018 елның җәендә ТӘһСИ тарафыннан Ульяновск өлкәсенә комплекслы экспедиция оештырылды. Дистәләгән фольклор материаллары, борынгы, болгар чорына караган кабер ташлары, кульязма һәм басма китаплар табылу зур куаныч тудырды.

Авылларда бүгенгә кадәр мәчетләр эшләп килә, мәдрәсәләрдә дини белем бирәләр. Халык үзенең тарихы белән кызыксына, өйрәнә, мәгълүматлар туплый.

Археографик табышларга килгәндә, барлыгы 54 берәмлек материал тупланды һәм Мирасханәгә тапшырылды. Шуларның 28е – кулъязма китаплар (тулы һәм тулы булмаган), 6 кулъязма дәфтәр, 19 – басма китап. Гомумән алганда, китаплар татар һәм гарәп телләрендә, араларында фарсы телендә язылган шигъри юллар да очрый.

Борынгы китапларга бай урын – Павловка районы Йәүли (Евлейка) авылы булып чыкты. Авыл мулласы Хаитов Алиаскәр Аллям улы (1936 елда туган) тарафыннан Мирасханәгә 19 берәмлек кулъяма материал, 4 берәмлек басма китап тапшырылды. Араларында күпчелекне гарәп телен өйрәнү грамматикасы, фикъһе, суфичылык темаларына караганнары тәшкил итә. Шулай да,

берничәсе аеруча игътибарга лаек. Шуларның берсе – хикәятләр, робагыйлар, бәетләр мәҗмугасы. Татар һәм гарәп телендә язылган бу җыентыкта атаклы Мәүләна Руминың да шигъри юллары очрый. Сигезенче биттә «кәтибе Мөхәммәдҗан Гафарулла» дип тә әйтелеп үтелә. Палеографик билгеләренә караганда, кулъязма XIX гасырга карый.

Икенче бер мөһим мәҗмуга – мантыйк темасына караган булса да, күпчелек битләрен атаклы дамулла Әхмәтҗан бине Мөхәммәд әл-Мусави Пильдәнкәви турында тәзкирәләр тәшкил итә. 143 биттән торган бу кулъязмада Төхвәтулла, Габделгафур бине мулла Рәхматулла Узави, Мөхәммәд Дибирдиевларның истәлекләре урын алган. 26 битендә «1861 нче елда мартның ун йиденче йәүмендә, Рамазан Шәрифнең 17 нче сәнәдә сабах намазындан соң хаҗ кылдым вә һәм рәсүл салиаллаһу галәйһи вәссәләмнең зиаратына зиарәт кылдым» дигән язмалар бар. Аңа кадәр берничә бите кисеп алынган. Шушы язуларны истә тотып, кулъязма XIX гасырга карый дип әйтеп була.

Кулъязмалар белән беррәттән мөһим, төрки халыклар арасында киң таралыш алган «Әхтәри кәбир» (1906 елгы басмасы, Истанбул), «Һада китаб маният-л-мусалля» (1883 елгы басмасы, Казан), 1901 елда нәшер ителгән Әбел-Хәсән бине Мөхәммәд бине Җәгъфәр бине Хәмдан әл-Кодури әл-Хәнәфи әл-Багдадиның «Мохтасар аль-Кодури» китабы һәм башкалар да бар.

Николаевка районы Чирекле авылында шулай ук кыйммәтле һәм кызыклы материаллар табылды. Археографик табышлар арасыннан иң борынгыларыннан берсенә дә шушы авылда юлыктык. Якынча XVIII гасыр азагы – XIX гасыр башында язылган, шәригать буенча сату-алу мәсәләләренә караган шактый зур (32,5×21,5 см), күләмле җыентык тулысынча гарәп телендә башкарылган.

Тарих ягыннан әһәмиятле икенче мәҗмуга Зур Чирекле авылында яшәүче Ногайбәкова Әнисә ханым саклап килгән материаллар арасында табылды. Эчтәлеге ягыннан бай кулъязма җыентык төрле темаларга караган материалларның татар

теленә тәрҗемәләрен тәшкил итә. 139–145, 199 битләрендә «6 нчы номерлы Кувшинников ширкәте»нә караган су билгеләре күренә, шулай ук 213, 217 битләрендә – «4 нче фабрика» су билгесе төшерелгән. Язуны Фәтхетдин Бикбаев дигән кеше алып барган дип уйларга кирәк (104, 154, 164 сәхифәләрдә аның автографы очрый). Кулъязманың 220 битендә Саратов губерниясе, Хвалын өязе Иске / Яңа Кулатка авылы указной мулласы Мөхәммәдшакир Бикбаев исеме дә аталып үтә. Икенче бер язмада (178 б.): «1892 нче елда, 2 нче майда дамелла Габдрахман Шәмселатыйф сәфәр кылды» дип язылган юллар да бар. Бәлки, әлеге кулъязманы өйрәнү киләчәктә бу муллаларның тормыш юлына, тарихка ачыклык кертер дип уйлыйбыз. Палеографик билгеләре буенча, XX гасырга карый. Китап әйбәт сакланган, әмма тулысынча түгел, карандаш һәм кызыл, коңгырт кара белән язылган. Сызыклы дәфтәрдән гыйбарәт. Кәгазь форматы 22,3×18 см. Кустодлар (ягъни тыныш билгеләре) куелган. Пагинация тасвирлау вакытында куелды. Кәгазь битенең читенә чыгарып искәрмәләр язу күренешләре дә очрый. Кулъязма күн белән тышланган.

Беренче бүлек сарыф кагыйдәләренең гарәпчәдән тәрҗемәсе белән башланып китә. Китапның бу өлеше үз эчендә тагын 11 дәрескә бүленгән. Кәтиб укучысын «тасриф»[1] һәм «тәгъриф»[2] төшенчәләре белән таныштыра, аларның мәгънәсенә төшенеп, сарыф кагыйдәләрен өйрәнүне төп таләп итеп куя, мөһимлеген ачыклый, тәрҗемә ителгән китапның гарәп телендә булуын әйтеп үтә. Текст татар телендә булса да, соңгы ике дәресе тулысынча фарсы телендә бирелә.

Икенче бүлек «Шәмсия» китабының татар теленә тәрҗемәсе булып тора.

[1] *Тасриф* – сүз төрләндерү.

[2] *Тәгъриф* – билгеләү.

Өченче бүлектә кульязма авторы атаклы дин галимнәренең берсе булган имам Газалиның[1] «Әл-җам әл-гәвам әл-мункыйзу мин әд-даляль» исемле әсәрен тәрҗемә итүгә керешә (124–134 б.). Мөкаддимәсендә бу мәкаләләрне тәрҗемәгә алыну хакында әйтеп үткәндә болай ди: *«Мөстәгыйнән билләһ[2] кәнди кимчелегемне белә торсам да, зиянымызда[3] төрле шөбһәләргә багыйс булыб[4] кешеләрнең күңелен болгаткан мәсьәләләрдән, мәсәлән, тәсаувыф, гыйльме каләм, мантыйк хакында төрлечә сүзләр булыб бу тугрыда үз фикеремне сөйләсәм дә игътибарга алыначак улындыгымдан хаҗәт әл-Ислам имам Газали хәзрәтләренең «Әл-җам әл-гәвам әл-мункыйзу мин әд-даляль»[5] исемле китабларының бу мәсьәләләргә мөттәгаликъ булган[6] бераз мәкаләсен тәрҗемә кылырга батырчылык кылдым»*. Сүзен дәвам итеп, кәтиб әл-Газали хәзрәтләренең сүзләренә кушылып, атаклы суфи Аллаһияр, Бакыргани хәзрәтләре хакында дөрес булмаган, ялган сүзләр чыгарып, халык арасында гайбәт таратучы кешеләрне тәнкыйтьләп чыга, дәлилләр, мәсәлләр китереп, аларны яклап чыгу юлын эзли. Кешеләрне «нисбәт биреб[7], аларны гаебләү белән ни файда итәрбез», дигән сорауны мәйданга чыгара. Гомумән, кәтибнең татар халкында киң таралыш алган суфичылык, тәсаувыф[8] хакында шәхсән үзенең уй-фикерләре шушы бүлектә урын таба: *«Әйтсәгез әйтерсез, син ишанларны*

---

[1] Имам Газали – (тулы исеме Әбу Хәмид Мөхәммәд ибне Мөхәммәд әл-Газали әт-Туси (1058 – 19.12. 1111) – атаклы ислам дине, хокук белгече, философ. Суфичылыкка нигез салучыларның, атаклы галимнәрнең берсе. Имамның эшчәнлеге күпчелек очракта суфичылык буенча системалы һәм киң кырлы белем бирү нигезләрен формалашытруга юнәлтелгән.

[2] *Мөстәгыйнән билләһ* – Аллаһдан ярдәм сорап.

[3] *Зиянымызда* – кимчелегебезгә каршы.

[4] *Багыйс булыб* – сәбәп булып, сәбәпче булып.

[5] *«Әл-җам әл-гәвам әл-мункыйзу мин әд-даляль»* (الجام العوام المنقذ من الضلال) – «Ялгышлыктан / хаталыкдан коткаручы / арындыручы китап».

[6] *Мөттәгаликъ булган* – бәйле булган, мөнасәбәтле, караган.

[7] *Нисбәт биреб* – чагыштырып.

[8] *Тәсаувыф* – нәфесне тазартып тәрбия итү, Аллаһының хозурындагы бер кол булу юлына ирешү гыйлеме.

*бик яклый икәнсең, диб. Дөрест, асылына инкяр кылмыйм*[1], *әмма бу мөрафәгам дә мотлакка түгел*[2], *заманыбызда булган мөтәсаувиф мөтәшәйехләрне*[3] *һичкем яклаб мөрафәга кылмас*[4]. *Хосусан бу заманда түгел, бу заман – үткән заман шәехләрендән Бакыргани хәзрәтләре мөтәшәйехләр хакында әйтәдер: белеменә куәһ чалыр, үзене кеше санар, горсатында уфтаныр, ахырзаман шәйехләре әл-Әмин диб әл кылыр*[5], *мөгамәләне мал кылыр, иссез гомерен йил кылыр*», – ди кәтиб.

Тәрҗемәгә күренекле ислам дине белгече һәм фикер иясе әл-Газалиның бу китабын сайлауның да төп сәбәбе – имамның суфичылар дөньясында, татар халкы арасында зур урын алып торуында да. Ул – йөгерек телле, искиткеч белемгә ия, хикмәтле чагыштырулар ярдәмендә зур гомумиләштерүләргә ирешкән фикер иясе. Күпчелек китапларында борынгы грек фәлсәфәсенең нечкәлекләрен үзләштереп, дөрес булмаган җирләрен кире кага, фәйләсуфларның тик үз акылына таянганнарын, нык ялгышканнарын, тәсаувыфны исә, тик аять кәримәләргә һәм хәдис шәрифләргә таянып, хак иманга һәм әбәди сәгадәткә кавышканнарын белдерә[6].

Имамның «Әл-җам әл-гәвам әл-мункыйзу мин әд-даляль» әсәренең тәрҗемәсенә килгәндә, кәтиб әсәрне тематикасы ягыннан аерып, өч мәкаләгә бүлә:

• Беренче мәкалә имамның тәсаувыф хакында булган назары. Бу бүлекне Газали хәзрәтләре һәрбер фән белән шөгыльләнеп, һәркасыйсының хакыйкатенә ирешүнең әһәмиятен ачыклауга багышлый, озак еллар Багдад, Шам, Дәмәшк, шәһәрләрендә белем туплап, кешеләр белән аралашып, Мәккә вә Мәдинәгә хаж

---

[1] *Инкяр кылмыйм* – кире какмыйм.

[2] *Мотлакка түгел* – һич шартсыз түгел.

[3] *Мөтәсаувиф мөтәшәйехләрне* – шәехлык итеп маташучы суфи шәехләрне.

[4] *Мөрафәга кылмас* – яклап чыкмас, каршылыкны чишмәс.

[5] *Әл кылыр* – аталыр, исем йөртәр.

[6] Просветительские традиции Ислама в Урало-Поволжье: Первые Фахретдиновские чтения. http://www.idmedina.ru/books/materials/?1238. 22.05.2019

кылып, һәрвакыт гыйбадәт юлында булып тәсаувыф юлына кайтуы турында бәян итә: *«Багдад шәһәрендә өч йөз кадәр таләбәгә*[1] *дәрес иткән хәлдә һәрберебезнең хакыйкатен тикшердем. Җибилли*[2] *табигатем улдыгындан һәрбер фәннең хакыйкатен, мәсәлән, тәсаувыф, гыйльме каләм, фәлсәфәи табигиять кеби каләмәләрнең асылын эзләб, тикшереб, һәр каюсының гыйльмен белдем һәм тәсаувыфның хаклыгын белгәч, бөтен мал-мөлкәт, бала-чага, хәтта укыта торган дәресләремне ташлаб Шам шәрифкә барыб гозләткә керешдем*[3]*. Дәмәшк мәсҗиденең манарасына бикләнеб зикер тәсбих белән мәшгуль булдым. Моның соңында Бәйтелмөкаддәстә булыб*[4]*, мондан соң хаҗ кылыб рауза мөтаһһәрәгә зиядәт белән мөшәррәф булу өчен*[5]*, Мәккә Мөкәрәмәгә, Мәдинәи Мөнавәрәгә барыб, беренче еллар үтеб, Ватаныма кайтудан халык өмедләрен кискәч, Ватанымны сөйдем һәм бала-чагаларымның ундави җәзеб кылыб*[6]*, тәкрар Ватаныма кайтдым, ләкин кайтсам да һаман гозләтдән аерылмай идем, ләкин дөнья һәм бала-чага кирәк бераз шифаландыра иде. Шулай да булса гозләткә иҗтиһад кылыб*[7]*, мәзкүр рәвештә ун ел үткәрдем. Бу ун ел эчендә булган хәлвәт араларында*[8] *шул кадәр нәрсәләрнең хакыйкатенә төшендем ки, санаб бетү дә мөмкин түгел иде. Шундан соң шиксез белдем, бу суфияләр Аллаһ Тәгаләнең юлында икәнен һәм бу юл тугры һәм күркәм бер юл икәнен, холыклары күркәм, хөкемәләренең хөкеме, галимләрнең гыйлеме җыелса, боларның холыкларын үзгәртүгә, боларның юлындан изге юлга алыштыруга һичбер җәһәтдән юл табмаслар иде, чөнки боларның барча йөреш-торышлары, эчләренең-*

[1] *Таләбәгә* – шәкертләргә.

[2] *Җибилли* – тумыштан, яратылыштан булган.

[3] *Гозләткә керешдем* – ялгызлыкка бирелдем.

[4] *Бәйтелмөкаддәстә булыб* – Иерусали (Кодс) шәһәрендәге изге гыйбадәт йорты.

[5] *Рауза мөтаһһәрәгә зиядәт белән мөшәррәф булу өчен* – пакь уразаны кадерләп каршылар өчен.

[6] *Җәзеб кылыб* – үземә тартып.

[7] *Иҗтиһад кылыб* – тырышып, керешеп.

[8] *Хәлвәт араларында* – ялгызлык вакытында.

*тышларының нуры дар да нөбүвәт нурдан алынган*[1]*, боларның юлларының саналган ни әйтерсең, әүвәлге шартлары Аллаһдан башкалардан – күңелемне паклаб, әһлякларын төзәтү, ахыргы шартлары – фәттахи Аллаһ булудыр*[2]*».*

• Икенче мәкалә шәрифләрендә имам игътикад җәһәтендән булган[3] назары белән уртаклаша. Бу бүлектә ун ел тәсаувыф юлында булып, тәкърар дәрес бирүгә, гыйлем тарату эшенә кайтуның сәбәпләрен ачыклый. Гыйлем алу фәкать имамнар эше, дигән кешеләрнең сүзләрен тирән тәнкыйтькә бирә. Шулай ук бу бүлектә «Китаб гаҗәиб әл-хавас»тан алынган бер ырымнан да өзек китерелә, имам астрологларга карата үзенең фикерен яза, аларның күрәзәчелегенә ышанмаска өнди, аңлатма бирә:

| | | |
|---|---|---|
| ٤ | ٩ | ٢ |
| ٣ | ٥ | ٧ |
| ٨ | ١ | ٦ |

| | | |
|---|---|---|
| د | ط | ب |
| ج | ه | ز |
| ح | ا | و |

*«Йөкле хатын тулгак авыр булыб, бала туу мөшкил булса*[4]*, бу ике шәкелне ике кисәк су тимәгән чүпрәккә языб, йөкле хатынга күрсәтеб, икесен ике аягы астына куелса, филхаль*[5] *бала туар. Бу хасыятьнең имкянын икърар кылдылар*[6] *һәм «Китаб гаҗәиб әл-хавас»да яздылар. Инде ни әйтерсең боларга? Шушы*

[1] *Нөбүвәт нурдан алынган* – пәйгамбәрлек (пәйгамбәрләргә хас) нурдан алынган.

[2] *Фәттахи Аллаһ булудыр* – Аллаһка (Аллаһның диненә) юл ачучы булудыр.

[3] *Игътикад җәһәтендән булган* – чын күңеленнән булган.

[4] *Мөшкил булса* – авыр булса.

[5] *Филхаль* – шундук.

[6] *Бу хасыятьнең имкянын икърар кылдылар* – бу үзенчәлекнең мөмкин булуын таныдылар.

*нәрсәләрне тасдыйк кылалар*[1]*. Моның соңында гакыллары сыйдырмый шул нәрсәләрне растлауга. Мәсәлән, иртә намазы ике рәкагать, өйлә намазы – дүрт, ахшам намазы – өч рәкагать булулары бер хасыять булганлыгы өчен, ул хасыятьнең булуга караганда гайре мәгъкүл булганлыгы*[2] *өчен ул намазларның да болай булуларының сәбәбе – бу вакытларның төрлечә булганлыгыдыр. Бигрәк дә беленә бу хасыятьләр нөбүвәт нуры белән. Гаҗәбемез сүзебезне мөнәҗҗимләргә әйләндерсәк, ул вакытда беләләр бу вакытларның мөхтәлиф икәнлеген*[3]*. Әнә шулай булса, без әйтербез талигъның хөкеме*[4] *мөхтәлиф булмыйдыр иде. Кояш күкнең уртасында булыб я туган, я байган вакытлары белән мөнәҗҗимләр үзләренең йөреш-торыш һәм гомерләренең тәфаветын*[5] *шул вакытларның үз каравына бина кылыб хөкем иткәнләр иде. Күб кешеләр аны растламакда иде. Ни аерма бар иде? Кояш күкнең уртасында булыб туган яки байган вакытлар арасында һәм ниндәй юл бар? Моны растлауга һич юл юк. Мәгәр мөнәҗҗимләрнең сүзләре генә шаядкә ялгыш һәм ялганлар йөз мәртәбә тәҗрибә кылыб ишеткән һәм белгәндер. Шулай да булса аларның сүзен растлаудан кире тормыйлар. Әгәр дә бер мөнәҗҗим әйтсә – һәр кайчан кояш күкнең уртасында булыб, кояшка фәләнче йолдыз караса да булса, шул сәгатьдә ике кием кисә, шул кием белән үлтерелер дип тәхкыйк*[6]*. Ул вакытда ике кием кимиләр. Шулай ук каты суык кар-буранларында шул мөнәҗҗимләрдән ишетелгән сүзгә кыяс кылалар*[7]*. Инде ни әйтим? Бу кешеләргә шушы хикмәтләрне кабул итүгә гакылы сыйдыра һәм икрар кылуга мозтар булалар*[8]*.*

---

[1] *Тасдыйк кылалар* – дөреслеген таныйлар.

[2] *Мәгъкүль булганлыгы* – аңлаешлы.

[3] *Мөхтәлиф икәнлеген* – төрле-төрле, бәхәсле икәнен.

[4] *Талигъның хөкеме* – туган кояш, ай, йолдызларның офыктан күк йөзенә чыгуы.

[5] *Гомерләренең тәфаветын* – гомерләренең төрле булуын.

[6] *Тәхкыйк* – шиксез.

[7] *Кыяс кылалар* – үрнәк итеп куялар.

[8] *Мозтар булалар* – мәҗбүр булалар.

*Гәрчә мөнәҗҗимләрнең сүзләре ничә мәртәбә ялган чыкганын күрә торса да, инде бу шәригать әмерләрендә булган хикмәт вә хасыятьләрне белү пәйгамбәрләрнең мөнәҗҗимәсе икәнлегенә инкар кылалар».*

• Өченче мәкалә имамның мантыйк һәм гыйлеме каләм хакында булган назары.

Имам Газали бу мәсьәләне «кешенең башын ваткан, күңелен болгаткан»дан дип саный. Сүз арасында әйтеп үтә: *«Коръәннең дәлилләрен ачык гына йөртүгә маил кылыб*[1]*, заһирынча гына һәркем аңлагандай әйтеб, чуалтыб, төрле бәхәсләргә әйләндерми чукалыб, тәхәкъкыйклим диб*[2]*, тирән фикерләргә чуммый гына карау тиешле».*

Бу сүзләргә дәлил итеп, сүзенең ахырында имам Газали Гомәр р.г. турында риваять китерә: *«Бер көн хәзрәти Гомәр хәлифә заманында бер кеше килеб сөаль кылган «Коръән мәхлүкмы*[3]*, түгелме?» – диб. Шул вакытда хәзрәти Гомәр бу кешенең соравындан бик гаҗәбкә калыб, кулындан тотыб йитәкләб хәзрәти Галигә алыб килде дә, әйтде: Йә, бил хәсән*[4]*, менә бу кешенең сүзен ишетеб ни әйтә икән, диде. Хәзрәти Гали әйтте: «Йә, әмин әл-мөэминин, бу кеше ни әйтә соң дигәч, баягы кеше әйтде – Коръән мәхлүкмы, түгелме, диб әйтдем диде. Шул вакыт хәзрәти Гали гаять ачуындан чыраен сытыб түбән карады, моның соңында башын күтәреб әйтде: бу ахырзаман хәбәре. Тиз үк озакламый шундый сүзләр чыгар диде.* Дәвам итеп, имам бу ике ирнең Ислам динендә һәм гомумән Пәйгамбәребез өчен нинди зур ихтирамлы кеше булганнарын исбатлый, һәм шул риваятьне истә тотып, динне, Коръәнне өйрәнүдә хата ясамаска өнди.

Һәр бүлек башында кәтиб шулай ук үзенең кереш сүзен әйтеп үтә, бу яки теге мәсьәләгә караган уй-фикерләрен җиткерә, кыскача анализ бирә.

---

[1] *Маил кылыб* – тартым ясап.

[2] *Тәхәкъкыйклим диб* – дөреслим дип.

[3] *Мәхлүкмы* – яратылганмы.

[4] *Бил хәсән* – күркәм холыклы.

Кульязманың күпчелек битләрен шәкертләр белән миссионерларның мөгамәләсе тәшкил итә (135–159 б.). Белгәнебезчә, XIX гасыр азагы, XX гасыр башы Россия территориясендә яшәүче халыклар өчен икътисади, сәяси, мәдәни һәм дини тормыштагы төрле үзгәрешләр белән характерлана: авыллар саны кими, фабрика, заводлар төзелә. Шул ук вакытта рус православ диненең миссионерлык эшчәнлеге тагын киңрәк таралыш ала, Себердән алып Урта Идел буена кадәрге территориядә урнашкан авылларда төрле миссионерлык мәктәпләре ачыла, христан динендә булмаган халыкларны дингә чакыру, өндәү эше янә бер көч ала.

Шушы миссионерлык темасын ачыклауга юнәлтелгән берничә хикәя бу кульязмада да урын ала. Беренче бүлекчә итеп «1903 нче сәнәдә 26 нче гыйнварда Уральский областендагы миссионер поп илән бер шәкертнең мөгамәләсе»н әйтеп үтәргә кирәк. Мәктәпнең эшчәнлеген күрергә дип килгән шәкерт төрле сораулар илә миссионер поп һәм шул мәктәптә укытучы бер казак белән ике диндә булган уртак һәм капма-каршы мәсьләләрне ачыклауга юнәлтелгән мөгамәлә алып баралар. Сүз барышында шәкерт үзен «Оренбург Каргалысында белем алдым» дип таныштырып үтә, шулай ук казак һәм нугай телләрен белүе турында да әйтә. Шәкертнең: *«Русча укыйтын шәкерд юлдасымыз бар иде, сезнең школа ачкан хәбәреңез ишедеб суны сорасаин диб килдем, сездең монда содержание казнаданмы, янә ногай шәкерд аламы?»*, дигән соравына, миссионер болай дип җавап бирә: *«Безнең монда содержание казнадан. Шәкердне казакдан алабыз, әмма ике фәкыйрь булса, ногайдан да аламыз»*. Мәктәптә русча язу-уку, хисап, счет дәресләре укытылуы турында да да әйтеп үтә. Шулай ук миссионер Коръәннең Саблуков ясаган тәрҗемәсе[1] белән таныш икәнен әйтә, миссионерлыкның төп мәгънәсен ачыклый, христиан күзлегеннән Адәм белән Хәва, Гайсә вә Мәрьям кыйссаларын кыскача сөйләп үтә.

---

[1] Саблуков Гордий Семенович (1804–1880) – православ рухание гаиләсендә туган, Духовный академия профессоры. Саблуков тәрҗемәсе, аңа кадәр эшләнгәннәренә караганда, Коръәннең төп гарәп текстына һәм мәгънәсенә иң якыны булган. Китап 1878 елда басылып чыккан.

1905–1909 елларда Касыйм каласыннанң миссионер җәмгыяте рәисе Василий Даронкин тарафыннан берничә ачык мәктүб брошюра формасында бастырып чыгарыла. Шуларның берсенә «Касыйм мөселман татарларыны христиан диненә дәгъва кылыб язмыш ачык мәктүб»енә кулъязма авторы җавап язарга керешә (140–153 б.). Доронкин үзенең мәктүбендә ялган дин тикшерүдән курка, дип әйтеп үтә. Бу сүзләргә дәлил итеп (янәсе Ислам дине хак дин түгел икәнен исбат итүче аятьләр итеп), Коръәндәге 2 сүрә, 103 аять, 3 сүрә 95–100, 114 аятьләрне китерә. Шул мәктүбләргә җавап итеп кулъязма авторы аятьләрне дөрес аңларга, Коръәннең төп нөсхәсен укырга, гарәп телен үзләштерергә өнди, 16 «Нәхл» сүрәсенең 125 аятен китерә:

ادْعُ إِلَىٰ سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ ۖ وَجَادِلْهُمْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ ۚ إِنَّ رَبَّكَ هُوَ
أَعْلَمُ بِمَنْ ضَلَّ عَنْ سَبِيلِهِ ۖ وَهُوَ أَعْلَمُ بِالْمُهْتَدِينَ

(Ий Мухәммәд г-м һәм аның өммәте! Раббыңның юлы булган Ислам диненә кешеләрне чакыр вә чакырыгыз Коръән дәлилләре белән, дәхи тәэсирле яхшы вәгазьләр белән, дәхи кешеләргә хаклыкны төшендерү өчен, алар белән тартыш вә көрәш иң күркәм юл белән! Әлбәттә, синең Раббың Аның юлыннан адашкан кешеләрне белә, һәм Ул Коръән юлында булган хак мөэминнәрне дә белә)[1]. Икенче бер дәлил итеп Гәнкәбут, Бакара сурәләреннән аятьләр китерә, Ислам диненең хак дин икәнен исбатлый.

Шулай ук «Коддус исемле мөслимнең Сергий исемле нәсрани миссионер илән мөгамәләсе» (164–177 б.), «Христиан миссонерларына дин буенча җаваб» (178–191 б.) дигән бүлекләре тарих ягыннан аеруча игътибарга лаек.

Кулъязманың алдагы битләрендә тагын бер кызыклы мәгълүмат бар: «Московские ведомости» газетасының 1906 елгы 100–101 саннарында басылган мөселманнар хакында «Руссиядә ят халыклар мәсьәләсе» (154–159 б.) мәкаләсенең тәрҗемәсе. Бу мәкаләдә мөселманнарга каршы хөкүмәтнең нинди фикердә

[1] Ногмани тәфсире.

торуы һәм шул фикерне ни тарафча йөртергә тиешлеге турында языла.

Яңа бер бүлек итеп кульязмада Нәҗмеддин Әбу Хафс ән-Насафий әл-Хәнәфинең[1] «Мәҗмугаль ‘акаи ән-Насафийә» исемле әсәренең[2] тәрҗемәсе бирелә (130–163 б.). Күпчелек атаклы дин галимнәре бу китап белән таныш булалар һәм аңа шәрехләр язалар. Мәсәлән, киң таралган шәрехләрнең берсен атаклы фәлсәфәче Са‘дуддин Мәс‘уд ибне Гомәр әт-Тәфтазаний[3] яза. Әсәренең азагында болай дип тәмамлый: «*Чынлыкта, «әл-‘Акаид» җыентыгы безнең динебезнең нигезе булган күп сорауларга җавапны үз эченә ала. Автор бу эшендә иң төгәл һәм әйбәт формада дин өйрәнүнең нигезен күрсәтә»*[4].

Соңгы битләрендә риваятьләр (197–198 б.), нәсыйхәт гомумия (199–202 б.), әхлак темасына караган әсәрләрнең тәрҗемәләре (203–206, 220–226 б.), «Мөгаллимләр өчен нәсыйхәт гомумия» (212–216 б.), салаватлар (227–235 б.) китерелә.

Эчтәлеге ягыннан бай өченче бер мәҗмуга «Китабе фикъһе Кейдани», «Хикаяте Габдулла мубарак», салаватлар, мөнәҗәтләр (42–46 б.), пәйгамбәрләр кыйссасын үз эченә алган. Палеографик үзенчәлекләре буенча, якынча 1830 елларда язылган. Кәтибе – Таҗеддин ибне мулла Талиб, атаклы дамулла Мөхәммәд Сәиджагфар әс-Саратави (Сартави) мәдрәсәсендә белем алучы шәкерт булса кирәк.

---

[1] Нәҗмеддин Әбү Хафс ән-Насафи әл-Хәнәфи (тулы исеме – Гомәр ибне Мөхәммәд ибне Әхмәд ибне Исмәгыйль ибне Мөхәммәд ибне Гали ибне Локман, 1067 (кайбер чыганакларга караганда – 1069) – 1142) – ислам дине белгече, хәнәфи мәзхәбе буенча хокук белгече. Гакаид, фикһ, тәфсир, хәдисләр, тарих, гарәп теле буенча йөзләгән китаплар авторы.

[2] «Мәҗмугал гакаид ән-Насафийә» – ислам динен өйрәнү нигезләрен кыскача аңлату.

[3] Са‘дуддин Мәс‘уд ибне Гомәр әт-Тәфтазаний (1322–1390) – гарәп-мөселман фәлсәфәчесе. Аның мантыйк, юриспруденция, шигърият, сарыф, математика, риторика һәм Коръән экзегетикасы буенча әсәрләре популяр уку-укыту әсбабы булып тора.

[4] Акыда ан-Насафий. https://obislame.info/verouchenie/akyda-an-nasafij.html. 22.05.2019

Бу кулъязмаларны Ногайбәкова Әнисә Кыям кызы ничә еллар дәвамында кадерләп саклап килгән. Ул аларны Мирасханәгә тапшырды.

Әнисә ханым тапшырган материаллар арасында атаклы суфи язучысы Сөләйман Бакырганиның «Хикәяте Хәким ата» кулъязмасының булуы куандырды. Татар халкы аның әсәрләрен укып тәрбияләнгән милләтләрнең берсе. Әдәбиятыбыз тарихын аннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. «Ул үз чорында ук дан һәм шөһрәт казанып, шул дәверләрдән үк буын-буын әдип һәм шагыйрьләрнең формалашуында да зур роль уйнаган, шигърияте тәэсирендә тарихи буыннарны үстергән шәхес. Бәлки шуңа да аның тормышы борынгыдан татар укучысын кызыксындырып килгән, моның сәбәбе аның легендар дини-диндар, мистик шәхес, әүлия дәрәҗәсенә ирешкән суфи шагыйрь булуыннан дип уйлыйм», – дип яза үзенең бер мәкаләсендә Ф. Яхин[1]. Бу әсәр күпчелек буын татарлар өчен өстәл китабы булып, халык арасында кулъязма хәлендә күчерелеп һәм укылып йөргән. Басма варианты исә Казанда 1846 елда 23 бит күләмендә «Хикәяте Хәким ата» исеме белән дөнья күрә. Әсәрдә Сөләйман Бакырганиның тормыш юлы тасвирлана, дини риваятьләр китерелә, әкияти эчтәлектәге гаҗәеп хәлләр сурәтләнә. Ульяновск өлкәсендә табылган нөсхәгә килгәндә, әлегә кәтибе ачыкланмады. 58 сәхифәдән гыйбарәт. Татар телендә, гарәп графикасында, 21×17 см.

Экспедиция барышында икенче бер мөһим, татарлар арасында киң кулланылган дини эчтәлекле, шигъри формалы «Мөхәммәдия» әсәренең кулъязмасына да тап булдык. Әсәрнең авторы – төрек шагыйре Мөхәммәт Чәләби. Китапны ул 1449 елда язып тәмамлый һәм XVI гасырда әлеге әсәр Кырымда, ә XVII гасырда безнең төбәкләрдә тарала башлый һәм тиз арада татар рухи тормышының аерылгысыз өлешенә әйләнә. Г. Ибраһимов аңа югары бәя биреп: «Бездә, һәм шигырь, һәм җыр, һәм

[1] *Яхин Ф.* Г. Тукайның рухи остазларыннан булган Сөләйман Бакыргани һәм аның иҗади мирасы. http://gabdullatukay.ru/tukay-science/scientists/yahin-ferit-g-tukajnyn-ruhi-ostazlarynnan-bulgan-solejman-bakyrgani-hem-anyn-ijadi-mirasy/ 22.05.2019

музыка уларак, гасырлар буенча җан азыгы булды»[1], – дип әйтә. «Мөхәммәдия» китабы татарлар арасында киң таралган өчен, әлбәттә, язучыларның әсәрләренә дә кермичә калмый. Без аны Г. Кандалый, Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Кәрими әсәрләрендә очратабыз[2]. Кулъязманы Чардаклы районының Абдулла авылында яшәүче Насыйрова Гөлбаһрам Галимҗан кызы (1937 елда туган) Мирасханәгә тапшырды. Текст тулы түгел, ахыргы битендә кәтиб исеме Гатаулла Хәмидулла ән-Назари дип күрсәтелгән. Татар телендә, гарәп графикасында язылган, 217 биттән гыйбарәт. Палеографик анализлар нигезендә әсәрне 1832–1840 елларда язылган дип исәпләргә була.

Авылда үзлегеннән тарих белән кызыксынып, китаплар җыеп, нәсел-нәсәбәсен өйрәнүчеләр дә бар. Шундыйлардан берсе – Хәкимов Шамил Әхәт улы. Бүгенге көндә аның шәхси архивында дистәләгән, төрле тематикага караган кулъязма һәм басма китаплар саклана.

Басма китапларга Чардаклы районында урнашкан Иске Үрәнбаш авылы да бай булды. Камалов Рафикъ Гомәр улы (1944 елда туган) Мирасханәгә тапшырган китаплар арасында: Мәхмүд ибне Убайдулла ибне Мәхмүднең «Мөхтасәр әл-Викая» («Викаятур ривая фи мәсаилиль Хидоя» китабының кыскартылган варианты); 1853 елда Рәхимҗан Сәгыйть улы типографиясендә басылып чыккан Коръән Шәриф (359 биттән гыйбарәт); Коръән тәфсире (гарәп телендә, басылган елы билгесез); «Мишкат аль-анвар фи латаиф аль-ахбар» китабының фрагменты; 1916 елда басылып чыккан кесә календаре (үз эченә «Олуг Руссия падишаһларының сарае», «Гыйльме һәйәт вә һава», «Руссиядә гәвам мәгарифе», «Беренче тыйбби вә тиз ярдәм», «Кечкенә өй аптекасы» турында кызыклы материаллар тупланган.

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 5. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 353–354.

[2] *Мөхәммәтов Илдар.* Габдулла Тукай иҗатында Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабы. http://gabdullatukay.ru/tukay-science/scientists/mohemmetov-ildar-kdu-aspiranty-gabdulla-tukaj-ijatynda-mohemmed-chelebinen-mohemmediya-kitaby/. 22.05.2019 г.

Николаевка районы, Әхмәтле авылында яшәүче Айбулатова Мәгърифә Билял кызы Мирасханәгә 3 кулъязма дәфтәрен тапшырды.

Табылган кулъязма материаллар арасында мөнәҗәтләр, ырымнар, бәет һәм дини эчтәлекле шигырьләр күп урын алган. Мәсәлән, хатын-кыз язмышына багышланган, гыйбрәтле «Көчләп бирелгән Газизә бәете». Эчтәлегенә килгәндә, 1912 елда «Ч» шәһәрендә бер татар гаиләсендә булган хәлләр турында сүз бара. Укымышлы, матур, яхшы күңелле Газизәнең язмышы тасвирлана. Бәет халык арасында киң таралган мәкальләр белән баетылган. Әсәрдә хатын-кызның ир-атлар белән тигез хокуклы булуына басым ясала.

Бәеттә «язмыштан – узмыш юк», «тормышны үзебезчә хәл итеп булмый» кебек гыйбарәләр дә урын алган:

Яман тәкъдир сәбәб булса бәндәләрнең башына,
Кайгы-хәсрәт кушыладыр эчәр суына-ашына.

Икенче бер юлда:

Яман тәкъдир язса каза һич сәбәбтән китмидер.
Бәндә каршы торса да, чара файда итмидер.
Бәхетсезгә вакытсыз эш килә дә бәйләнә,
Бәндә мескен гаҗиз калыб, башы, күзе әйләнә.

Бәет азагында кулъязма дәфтәр хуҗасы тарафыннан шул ук темага караган тагын бер мөнәҗәттән өзек өстәп куела. Кәтиб балаларның сайлаган юлларына киртә куймаска, сүзләренә колак салырга өнди. Байлыкка кызыгып, ялгыш хата эшләмәскә, булган малына карап, кеше турында фикер йөртмәскә өйрәтә:

Алтынга буясаң да, карга шөнкәр булмас ул,
Канатларын киссәң дә, шөнкәр карга булмас ул.

Дини эчтәлектәге мөнәҗәтләрдән «Касыйдаи Мәүлед әннәби», «Ишан бабалардан калган догалар», «Кадер кичәсе шигыре», Татарстан һәм Ульяновск җирлегендә таралыш алган Мәүлед кыйссасы һ.б. бар. Халыкта бүгене көнгә кадәр сакланып, алар әле дә төрле мәҗлесләрдә көйләп укылалар. Мәүлед кыйссасыннан өзек:

Ярадылмыш бу бөтенләй буш иде,
Бер Ходайдан башка бер ни юк иде.
Һәм бар итде элек әүвәл нурын ул,
Һәм барлыгның зурысы булды Рәсүл,
Ошбу нурдан җир йөзенең барлыгы,
Ошбу нурдан күк йөзенең хаклыгы.
Булмаса ул булмас иде бернидә,
Һәм яратмас иде төтен җирендә.
Яратылды аның өчен һәммәсен,
Аның өчен бар итде бәндәсен,
Хак яратды хәзрәти Адәмне әүвәл.
Балкыды һәм маңгаенда якты нуры.
Ялтырады маңгаенда якты нуры.

Ата-бабаларыбыз үзләреннән соң нәсыйхәт итеп калдырган мирасны кадерләп саклап киләчәк буыннарга җиткерүне үзебезгә бурыч итеп куярга тиеш.

* * *

Ульяновск өлкәсенә оештырылган комплекслы экспедиция барышында археографик материаллар арасында табылган кайбер мөнәҗәт һәм бәетләрне гарәп графикасыннан күчереп тәкъдим итәбез.

**«Көчләп бирелгән Газизә» бәете**

«Ч» исемле бер шәһәр бар, Кама юлы сулында,
Бик зур гына пристань бар, пароходлар юлында.
Гөрли көймә, шаулый сулар язгы ямьле көнендә,
Су өсләре чуб-чуар ут була тагын төнләрдә.
Пароходлар сызгырганда су буйларын гөрләтә,
Моның тавышы моңлыларның йөрәкләрен дөрләтә.
Шундый матур пристаньның шәһәрендә күб байлар.
Шул шәһәрдә үк өч-дүрт урам күбе мөселман-байлар.
Гариф дигән кечкенә карт игенчеләр маклеры.
Үз сүзле, ак сакаллы Мәрфуга карчык ире,
Бу Мәрфуга карчык үзе яхшы кеше, холкы киң.
Гомер иткән сабыр итеб, шул маклерга булыб тиң.

Бу маклерның балалары – ике кыз, бер ир бала.
Ир баласы байга салыб малын ала да сала.
Олы кызы үзе теләб иргә барган Сәлимә,
Сөйкемле дә, мактаулы да икенчесе – Газизә.
Газизәнең гыйльме яхшы, үзе күркәм, гаебсез.
Бер вакытда чыгармаган авызындан гайбәт сүз.
Сабый чакда уйнаб йөргән үзе шәһәр буенда
Иргә барыб хатын булу һич булмаган уенда.
Шулай үсеб буйга җиткән, бер кайгы да күрмичә,
Алдагы эшне һичкем белми күз алдына килмичә.
Яман тәкъдир сәбәб булса бәндәләрнең башына,
Кайгы-хәсрәт кушыладыр эчәр суына-ашына.
Мең тугыз йөз ун ике ел көз көнне ди булганда,
Салкын җилле, томанлы көн, буйлы яңгыр койганда.
Юллар пычрак булу белән шәһәргә иген килмәгәч,
Маклерга ризык булмый, хезмәт булмагач.
Газизәнең атасын да фәкыйрьлек бик чорнаган,
Гомеренә маклер булган, малга туеб тормаган.
Ризык кайдан табыйм икән диеб торган чагында,
Шакир дигән бер бай кайткан торыб Себер ягында.
Иртыш буе Павлодарда кәсеб итеб мал җыйган,
Кыз табмаган ул яклардан, өйләнә алмый алчыкган.
Алҗуының сәбәбе шул – әллә ямьсез яраткан,
Озын яңак, курнос борын, күзен янга караткан.
Тагын әле эстәве бар – эчүе дә, тартуы,
Мондан бер кыз алырга диб булган икән кайтуы.
Симбирия байларында алалмаган кыз сораб.
Ахырындан «Ч»га кайткан табмаганга абдыраб,
«Ч»га кайтыб, зур байлардан сораб кыз алалмаган.
Ямьсезлеген күреб, байлар кызын утка салмаган,
Гаҗизләнгәч табалмыйча, риза булган фәкыйрьгә,
Кызы матур булса, алыб, Сибириягә кайтырга.
Шул арада яучы адәм маклер кызын мактаган.
Сандугачның ябалагын алар өчен саклаган.
Сүз салгачтан маклер әввәл ямьсез диб тартынган.

Ахырындан риза булган фәкыйрьлеге сартындан.
Биш йөз сумлаб акча алыб гаризасын табшырган,
Риза түгел кызын биреб, гакылындан шаштырган.
Сине бирдем Шакирга диб, маклер кызга сөйләгән,
Кыз ишеткәч атасындан, Хактан үлем теләгән.
Атасы әйтә Газизәгә: Шакир байның малы күб,
Сибириядә магазины бар диләр һәм бай диләр,
Күб байларның кызлары андый байга бармыйлар.
Гомергә ана куенында ятыб калмый кыз бала.
Никах вәгъдәсе ирешкәч, кыз баланы кем дә ала.
Әткәм кем алса да алсын, бирмәсәнә аюга,
Гомерем үтәр кан яше түгеб, башым төшкәч кайгыга.
Шулай сөйләб, Газизәнең йокы төшми күзенә.
Кем дә елар, хараб булдым диб әйткән сүзенә.
Бу Шакирны узса-барса күрә икән Газизә,
Күргән чакта калтыраныб ошата икән аюга.
Дус кызларга әйткән, Ходай үзе сакласын,
Шакир төсле ир булгыйнча, әҗәл гүргә кабласын.
Кызы риза булмаганны күреб елый анасы,
Дога кылыб үгетли дә, кабул итми баласы.
Анасы әйтә Газизәгә: «Тот атаңның сүзене,
Шәһәр халкы арасында кызартма инде йөзене».
Газизә әйтә: «Үгетләмә, яхшы түгел эшегез,
Малга алданыб хур итәсез, булдым дошман кешегез.
Мине болай сатмыйча да бу вакытка җитдеңез,
Исәбләмичә башымны бүген әрәм итдеңез».
Анасы әйтә Газизәгә: «Атаң холкын беләсең,
Туктатырсың, әйтә алмыйм, үз сүзледер, күрәсең».
Газизәнең карышуы Шакирның үзен күргәнгә,
Ямьсез булыб эчеб йөреб, урамларда йөргәнгә.
Шакирның да ямьсезлеген күзе күреб коты очкан,
Шул сәбәбле, көн-төн елаб, үлем тели бер очтан.
Сөйләб елаб торган чакда зур апасы Сәлимә,
Кич кунарга чакырадыр безгә әйдә диб Газизә.
Алыб баргач үгетлидер, риза бул ди, сеңлесен.

Газизә әйтә: «Үгетләмә, ул аю бит, белмисең!»
Төн булгачтан апасында талыб киткән йокыга,
Сискәнгәләб тиз уянды, чыдый алмый куркуга.
Апасы әйтә: «Нәрсә булды, тиз уяндың, сискәнеб?»
Кара эт күрдем, дигән, килә өстемә ...
Тешләдеме ул кара эт, диб сорады Сәлимә,
Тешләмәде, тешләвен дә, курктым дир Газизә.
Газизә әйтә: «Ул карт этне мин юрадым Шакирга,
Ходай нинди яман тәкъдир язгандыр мин фәкыйрьгә».
Моны ишеткәч апасы да, бик кайгырыб утырган.
Бәхетсез син, туганым, диб күзенә яшь тутырган.
Апасы әйтә: «Туганкаем, эткәй башың ашады,
Барыбызга да кайгырырга зур хәсрәт ясады».
Газизә әйтә: «Туганым, Шакир ямьсез, сөйкемсез,
Андан ары Сибир йире тору өчен күңелсез.
Анда качкын, карак, залим – барсы да җыелган.
Анда бик аз яхшы кеше, бар да илдән куылган.
Туганкаем, гозерем шул – үгетләче этине,
Бай Шакирга бирәм диеб, утка салмасын мине».
Күб сүздән соң Газизәне зур апасы китергән
Мәрфуга әби елаб мескен намазлыкта утырган.
Бир кызыма бәхет диеб бер Аллаһдан сорыйдыр,
Кайтдыңмы бәбкәм диеб, күрү белән елыйдыр.
Газизә әйтә анасына: «Кайтартсана, әнкәем!»
Анасы әйтә: «Атаң каршы, тыңлата алмыйм, бәбкәем».
Тыңлат әнкәй үкенерсез, яхшы булмаз ахыры,
Мин дөньяда яшәмәмен, сез булырсыз ил хуры.
Шулай дигәч, Сәлимә әйтә: «Әти кайларда йөри?
Әллә юкса туй итәм диеб йөриме ул карт бүре?
Картаеб да кеше акылы керми инде анарга,
Алма кебек кыз баласын йөри инде ашарга.
Әнкәй әйтә чыгыб китде, туй кирәген аларга.
Йөри инде котырыныб, кызын утка саларга.
Шулай сөйләб бетерүгә, маклер тотыб бер тукын
Кайтыб керә сөйләнгәләб, тиз ясарбыз диб туен.

Эшчеләргә салыб куйган туй кирәге барсыны,
Моны күргәч, Газизәнең артды йөзенең сарысы.
Нәрсәләргә күз дә салмый- үзенә сөйләнә.
Үтерсәләр дә бармыйм дигәнне ишетеб,
Маклер әйтә: «Балакай, сиңа әйтәм, тыңласана сүземне,
Шәһәр халкы арасында кызартма инде йөземне!»
Шул вакытда Сәлимә әйтә: «Әти, юкны сөйләнмә,
Биш йөз сумга кыз сатам диб, зинһар юкка киңәнмә».
Әткәсе әйтә Сәлимәгә: «Син бу эшкә кушылма,
Әгәр бу эшкә кушыласың булса, минем сүздән тыш булма».
Әткәйгә иңәләләр улы-кызы бирмә диб.
Ул аларга җаваб куя этләр кебек эрмә диб.
Елаб-елаб әйтсәләр дә җиңәлмиләр атасын.
Бер көн үкенерсез, диләр, малга алданыб сатасың.
Шулай дими ни дисеннәр, куркалар бу сүзендән,
Я ул, я мин дигәнне ишетеб, Газизәнең үзендән.
Яман тәкъдир язса каза һич сәбәбтән китмидер.
Бәндә каршы торса да, чара файда итмидер.
Бәхетсезгә вакытсыз эш киләдер дә бәйләнә.
Бәндә мескен гаҗиз калыб башы, күзе әйләнә.
Маклер карт да вәгъдә куйган туйны тиз кылырга,
Егерменче сентябрьдә кызга никах булырга.
Кичке сәгать уникедә кияү килергә диләр.
Кайгысызлар кайгылының бер дә хәлен белмиләр.
Газизәнең ул вакытда күзләрендән яшь килгән,
Үтерәләчәк кеше кебек сүз табмый хәле беткән.
Җан кыючы җәллад кебек[1] бер нәрсә белми.
Сүз кушканга җавабы юк катыб калган, селкенми,
Маклер карт да йөгереб йөри, туй итәргә тырыша.
Кызның агасы Ибраһим карт атасын орыша:
«Кызың асылда риза түгел, көчләб җылатыб бирмә», –
дигәч, карт да ачуланыб малаена әйтә: «Син өрмә!»
Шул арада Шакирның да кардәшләре җыелды.

[1] *Җәллад кебек* – баш кисүче, палач кебек.

Боларны күргәч, Газизә җансыз калган тик булды.
Мулланы да китерделәр никах мәҗлесен итергә,
Газизәдә һич ният юк Шакирны ир итергә.
Анасы әйтә Газизәгә: «Балакаем, риза бул!
Телә Аллаһдан мәхәббәт, бир, Ходай, диб изге юл!
Безне оятка калдырма, инде риза булам дисәнә».
Газизәдә яхшы сүз юк никадәрле дисә дә.
Әнкәем, үгетеңне колагыма алмыймын,
Бар сүзем шул үлсәм дә ул Шакирга бармыймын!
Шулай көчләб, ризалыксыз, яман тәкъдирләр белән,
Мулла никах укыб куйды ялган шаһидлар белән.
Безнең татар гадәте шул – кыз бармыймын дисә дә,
Ярый була ялган шаһит кыз риза түгел дисә дә.
Күрмәгәнгә елатыб та, каргаб, көчләб бирәләр,
Гомере буена җафаланыб торганны да күрәләр.
Газизә дә һич беркемне күрмәенчә гомер иткән,
Аю кебек Шакирны күргәч, аның гакылы киткән.
Нишләсен соң тәкъдирләр дә яран язган булгачтан.
Шакирга анасы үгет бирә кызга никах булгачтан:
«Инде өйләндең, хатыныңны анда кеше күрмәсен,
Аю алманы ашаган, диеб күргән адәм көлмәсен».
Ни әйтсә дә исереб, эчеб, күзе тынган, тыңламый,
Эченә ярыб салса да, бер сүзен дә аңламый.
Төнге сәгать уникегә йиткән чакда өйләрдә
Утлар сүнгән, дөм караңгы төшеб калган айларда.
Бер кечкенә өйдә ут бар, ул да кияү бүлмәсе,
Шул бүлмәдә елаб тора Газизәнең җиңгәсе.
Бераздан соң кияү, кияү килә дигән өн килә,
Газизә әйтә хараб булдым, шул акайган җен килә.
Кияү килгәч, бераздан соң җиңгәләре таралды,
Газизәнең теле дә юк, өне юк катыб калды.
Мондан соңгы хәлләрдә дә хәбәр булмаган,
Күб кич бергә торсалар да, балга чебен кунмаган.
Без кайчакта ятмый дигән сүз сөйләнә телләрдә,
Газизә пычак тоткан, диб сөйләнәләр илләрдә.

Кияү мондан бик хурланыб чыкган ашыгыб, китәм диб,
Анда барыб үз эшемне теләгәнчә итәм диб.
Сентябрь егерме бишендә хәзерләнә китергә,
Алыб китеб барган чакда эшен үзенчә итергә,
Коменский канпайтанның «Фияр» дигән пароход,
Китер өчен хәзерләнә төрле якта ход ала.
Моны ишетеб Газизәнең бергә үскән кызлары,
Озатырга килгән бар да яшькә тулыб күзләре.
Җиңгәләре, күршеләре, бар да озата килгәннәр,
Юл буенча күб җыелган, ишеткәннәр, белгәннәр.
Газизә дә бәхилләшә сезне инде күрмәм диб,
үз-үзенә уйлаб куя мин дөньяда йөрмәм диб.
Әнкәй бәгърем, бәхил булчы, сине тагын күрмәмен,
Актык күрүем диб белегез, дөньяда озак йөрмәмен.
Сеңлесенең бу сүзләрен ишеткәчтән Сәлимә:
«Зинһар инде сабыр ит, ди, туганым Газизә».
Кичке сәгать җиделәрдә Газизәнең анасы,
Озатырга бергә төште Ибраһим агасы.
Шакирның да туганнары бар да озата елаб,
Газизә дә башын салган, сүз әйтәлми кан елаб,
Мисле җанлы җеназа тик булыб бара бичара,
Биш йөз сумга сатылгачтан, кайгырса да ни чара.
Дөньяга адәм тумасын, туса бәхетсез булмасын,
Шундый юнсез атаң булыб, шәфкатьсезлек кылмасын.
Газизәне озатырга шәфкатьсез карт бармаган.
Көчләб кызын сатса да, ул бәхиллеген алмаган.
Озатырга баручылар конторына керделәр,
Һәрбересе елаб-сыктаб бәхилләшеб йөрделәр,
Газизәдә тын-тавышы юк, күзләренә яшь тулган.
Кайгы белән калган бәгыре каткан – таш булган.
Газизәнең уй-фикере йилкенә дә ашкына,
Кешегә генә белдерми, югалырга ашкына.
Бераздан соң пароход та тавыш бирә башлады.
Актык тавыш биргәндән соң, каршы аркан ташлады.
Пароход та кузгалырга ары-бире селкенә.

Газизәнең йөрәге дә чыгам диеб йилкенә.
Коменский кузгалгачтан бар да яулык селкиләр.
Пассажирлар Шакирны да нинди аю бу, диләр.
Бер-берсенә сөйләшәләр бу нинди кызны алган диб,
Бичара кызның эченә мәңгелек ут салган диб.
Кичке сәгать җиде булгач, пароход та кузгалды,
Газизәнең аналары басыб елашыб калды.
Газизә дә каютындан чыгыб менде балконга,
Арлы-бирле караб йөри озатучы халыкга.
Каласың, ди, туган илем, күренмәскә мәңгегә,
Бу суларда җансыз булам, калыр тән генәм.
Газизә шундый сүзләр сөйли көймә байтак юл алды,
Озатырга төшүчеләр бар да күздән югалды.
Газизә кыз төн буена түкде күзендән яшен.
Күссенә дә уйлаб ала югалтырга үз башын.
Төн үтде, иртә көн булды, сәгать алтыга сукды.
Тышка чыгам диб сөйләнеб, Газизә каютадан чыкды.
Газизәдә җан чыгарга тәмам вакыт ирешкән,
Каютындан чыгу белән, сикереб суга төшкән.
Сикереб суга төшкәнен шунда бер хатын күргән.
Төшү белән пароходның куляса астына кергән.
Пароходта шау-шу кубкан, бар да халык йөридер,
Шакир чыкган Газизәне гүгрәгәләб эзлидер.
Капитанга хәбәр булгач, пароходны туктаткан,
Пароход тиз туктаса да, ул су төбенә баткан.
Сарапулдан түбәнрәк Беляевкага якын
Газизәнең җансыз тәнен батырган суга дулкын.
Капитанга хәбәр булган табшырдым диеб сезләргә,
Шул йирдәге урятникка Газизәне эзләргә.
Шакир белән анасы да шунда төшеб калдылар,
Маклер картка кыз үлде диб,тиз үк хәбәр салдылар.
«Ч» шәһәренә телеграмдан тиз үк хәбәр җәелде,
Газизәнең якынлары үлгәндәй булыб калды.
Ишеткәчтән маклер карт да чыгыб китде өендән,
Кая барыр урын табмый, кызын көчләб бирүендән.

Шакирның да кардәшләре сөйләгәнләр төрлесен:
хурлыкындан суга төшкән, булмаган диеб тугры кыз.
Чумучылар Газизәне судан эзләб алдылар,
Башы ватык, тәне кара, күреб хайран калдылар.
Сәбәбе шул, төшү белән, кулясага юлыкган,
Башына да, тәненә дә төрле җиренә сукган.
Тапычкасы суга акган, шәле дә юк башында,
Энҗеләгән калфагы бары төшми калган башында.
Газизәне судан алгач, доктор караб кыз дигән,
Шакирга да, анасына гүргә куегыз дигән.
Тәфтиштән соң Газизәне юыб гүргә куйганнар,
Менә гыйбрәт: көчләб бирү нинди була, туганнар.
Утка салынды, судан алынды.

Тәмам би-л-хәер вәс-сәлам.

Бу язуны мин язмадым язды каләм,
Бу язуны укучыга бездән сәлам.

*Яңа Малыклы районы Әбрәй авылы,*
*Галимов Йосыф Габдулла улы*
*тапшырган кулъязма дәфтәрдән алынды*

Әгүзү билләһи минәшшәйтани рраҗим.
Бисмилләһи ррахмани ррахим.
Хәмед илә[1] башладым дуслар мирасы,
Гыйззәт әйләсен[2] колга Ходасы.
Бар иде бер камил халык арасында,
Гомер серде Зимничай каръясендә.
Ходаның дустыдыр ул шәйех камил.
Фәнадән кичде ул туксан яшендә,
Төн-көнен кичерде хак эшендә.
Зөлкәгда аеның дүрте иде,
Чәһаршәмбе көнне раузага керде.

[1] *Хәмед илә* – мактау белән.
[2] *Гыйззәт әйләсен* – кабул итсен, якын итсен.

Шәфәгать укыб итәиб сәналәр,
Дәресләр укытыб җитмеш сәнәләр,
Килеб анда Ходай зикерен укырлар,
Аңар килмәс насыйбы юк сукырлар.
Анардан булды күб кәрамәт,
Ходаем кальбемезне кыл сәламәт.
Нәбинең варис китде яранлар,
Нә кылыйк бәрадәрләр яранлар.
Мөбәрәк шәйехебез мөршид камиль
Аның мөриде җәмиг галәмгә шамиль.
Догасындин аерма, Рабби, Рабби,
Аллаһым, мәгъфирәт кыл[1] хатабызны,
Салма гыйшкка барчабызны,
Мәдәте падишаһлар падишаһы,
Безне гыйшкындан аерма, Иляһи.
Мөбәрәк көндә кичде фәнадин,
Аның тик камил ир тумас анадан
Аерма камил остадым үзендин,
Сират кичкәндә бир һидаят.

**Мөнәҗәт**

Үлемнең илчесе бер көн
Газаб белән килер булгай,
Өзелер бәндәнең гомере,
Газиз җаның алыр булгай.
Газиз җаның алыр аңла, угыл-кызың калыр ташга,
Аяк баскан җирең һәр адым
Каты рәнҗеб, хата кылгай.
Юлым ерак, азыгым аз,
Раббым, хәлем ничек булгай?
Мөхәммәд хөрмәте өчен
Бу тамчысын җитәр булгай.
Бетүләр очыб киткәндә,
Күндер, Раббым, уң кулыма.

[1] *Мәгъфирәт кыл* – ярлыка, кичер.

Шунда каты курку булгай.
Кайдин алыб кайда бирдең,
Барчасындин сөаль булгай
Кулыңдин үзгә эш кылмас,
Күзеңдин яшь акай булгай.
Бу мәннең күңеле кайгыдан
Ташыб торганга еглайдыр,
Кулымдин һич бер эш кылмас,
Бу ни хәл, күңелем еглайдыр.
Ак чәчләрем шелтә кыладыр,
Ни җаваб бирерсең дия,
Кыямәт шул чәчләрем
Шаһид булганын белмәдем.

Бөтен әгъзаларым булса шаһид,
Ходай хозурында нишләр бу гариб?
Аяк сөйләр кай җирләрдә йөргәнен,
Кайда барыб ничек гомер сөргәнен.
Кулың сөйләр нинди эшләр тотканын,
Ходайдин куркыб калтырар бу җаның.
Бөтен әгъзаларым булсалар шаһид
Ходай хозурында нишләр бу гариб?
Бәхилләшерләр синең ике күзең,
Ул заманда Ходаем бирсен түзем.
Бәхилләшерләр ике аягың синең,
Җан алырга Газраил дустың килер.
Үлем ачысына дуслар юк дару,
Бигрәк авыр караңгы гүрдә калу.
Үлем хастасына, дуслар, ятарбыз,
Газраилне күргәч без ни әйтербез?
Килдем диер синең җаныңны алмакка,
Вәгъдә юктыр бер сәгатькә калмакка.
Явызларның җанларын алыр каты,
җәһәннәмдер анарга тамуг уты.
Яшем чыкмый, йөрәгем катсындин.
Бигрәк куркам үлемнең ачысындин,

Үлемнең ачысы бигрәк ачыдыр.
Кабер эчендә төрле газаб бардыр.
Кабер эчендә төрле газаб бар,
Юктыр анарга керергә дидар.
Тәмугда янар, мәңгесен үлмәс,
Сыгынамын сиңа, рәхим кыл миңа,
Сахар тырганга рәхмәтең ява,
Яусын рәхмәтең, китсен михнәтең,
Ходаем салсын кыямәт дәртен,
Рәхмәтең, Илаһым, безләргә тамсын.
Ходаем юлында йөрәгем янсын,
Яшьләрем аксын кыямәт өчен,
Аллаһ юлында бетсен бар көчем!

Үлем!
Әй, үлем, тукта миңа,
Ачма инде син кочак,
Күбме соң тордым беләмен,
Әлдә бит гомерем озак.
Бик теләмим бит үлемне,
Мин чибәр тормыш телим,
Һәммәсен бер кат таныйм да,
Соңгыдан үлсәм үлим.

**Мөнәҗәт**

*(«Йә, Рәсүл Мөхәммәд, булдың галәмгә рәхмәт!»)*

Йә, Рәсүл Мөхәммәд, булдың галәмгә рәхмәт!
Дөньяда чикдең зәхмәт, өммәт өчен Мөхәммәд.
Аллаһым бу галәмне Синең өчен яратды
Әүвәлдин ахыргача Синең өчен таратды.
Әүвәлге пәйгамбәрләр һәммәсе белде Сине!
Һәммәсе сөйде Сине! Өммәт булдылар Сиңа.
Син нәбиләр тәмамы, Син барының имамы.
Һәркем Сине мәдәхли[1], өммәт булдылар Сиңа!

[1] *Мәдәхли* – олуглый.

Коръән иңдерде Сиңа, юлны белдерде Сиңа,
Шәригатьне күрсәтде, йә, Рәсүле Мөхәммәд!
Сиңа булды дин Ислам, китабың булды Коръән,
Бөтен галәмгә солтан, йә, Рәсүле Мөхәммәд!
Сине Әмин диделәр, сине калим диделәр.
Сине күркәм яхшы диб, бөтен галәм сөйделәр.
Ата-анаң вафаты Сине ятим калдырды.
Сине Аллаһ үстерде өммәт өчен Мөхәммәд.
Сине Аллаһ чакырды Газраил җан алмакка.
Сиңа мөмкин түгел диб, бармаенча калмакка.
Сиңа якын дусларың Әбү Бәкер, Гомәрдер,
Дәхи Госман, Галидер, һәммәсе дә вәлидер.

**Мөнәҗәт**

*(«Нигә моңача йокладың?»)*

Бездин сәлам дусларга, таләб юлын куймасын,
Сәгадәтне теләсәң, һәркем гафил булмасын.
Уяныб Аллаһ дигел, дәрт белән аһ-ваһ дигел,
Хәсрәт белән ваһ дигел, нигә моңача йокларсың?
Гафләтдән күземне ач, рәхмәтеңне миңа сач,
Рәхмәтеңә мин мохтаҗ, нигә моңача йокларсың?
Гафләтдә син ятмагыл, нәҗастә батмагыл,
Хак коллыгын уймагыл, нигә моңача йокларсың?
Төне-көне син тырыш, нәфесең белән сугыш,
Милләт өчен син тырыш, нигә моңача йокларсың?

*Николаевка районы Чирекле авылы,*
*Ногайбәкова Әнисә Кыям кызы (1959 елда туган)*
*тапшырган кульъязма дәфтәрдән алынды*

**Моңлы бәет**

Иляһым бирдең хәсрәт,
Безгә түгел, Пәйгамбәргә,
Хәбәр итмәк кирәк инде
Безнең кебек бәндәләргә.

Фираклыкдин безнең хәлләр,
Бәгеремдә кара канлар,
Күзләрдә ачы яшьләр,
Бир, Иләһи, сабырлыкны
Зәгыйфь кылың фирак булган
Барысындин ул алырылган.
Уң кулыма нәмамны бир, Һуаллаһ,
Хисабымны җиңел кылгыл, Һуаллаһ,
Хайрәтләргә сөргән чакта
Расулаллаһ шәфәгатен кылсын Һуаллаһ.
Ун мең еллык сыйрат күберен Һуаллаһ,
Аны кичмәк ни мөшкилдер Һуаллаһ.
Кылдың нечкә кылычдин үткен Һуаллаһ.

**Мөнәҗәт**

*(«Хозер пәйгамбәр хилкага керде*[1]*»)*

Хозер пәйгамбәр хилкага керде,
Бонлар кемләр диб Ходадин сорады,
Фәрештә диде бонлар мөридләр,
Рәсүл Аллаһга бонлар өммәтләр,
Фәрештә бирде аңа җавабын.
Өзелеб йөрде халыкка сәвабын.
Хозер пәйгамбәр хилка төзгүче,
Яхшы иманны күреб белгүче,
Хозер пәйгамбәр хилкага керде,
Аллаһның боерыгы берлән йөрде.
Хозер пәйгамбәр күңел сандыгы,
Күркәм холугы, Аллаһның дусты,
Таулар, ташларда, йөрер суларда,
Яхшыларга ул юлгыр юлларда,
Юлгыр юлларда алышыр кулларда,
Күбрәк эшләнер изге кулларга.
Карарга кирәк ул баскан эзгә,

[1] *Хилкага керде* – түгәрәк, утырган кешеләр түгәрәге.

Ул баскан эзгә үсәр үләннәр,
Галим булырлар аны күргәнләр.
Ул баскан эзгә рәхмәт явадыр,
Ул узыб киткәч, нуры каладыр мөбәрәгемнеке.

**Сәваблы тәмле мөнәҗәт**

Бисмилләһи рахмани ррахим.
Аллаһ, Аллаһ без әйтик ошбу мәйданның эчендә,
Бер Ходаем мал мәхәббәт мәдех әйтергә[1] һәркемгә.
Аллаһ, Аллаһ без әйтик утырыб дустлар мәйданларда,
Хәзрәт Кәгъбәм кыл шәфәгать мәхшәр көнендә мизанда.
Сәхәр вакытындагы кошлар, алар күңелләрне хушлар,
Хәзрәт Кәгъбәмне яд итик[2], мәйданларда утырыб дустлар,
Тибрәнәдер тау вә ташлар һәм агачдагы яфраклар
Аһ, дустларым, алар яна хәзрәт Кәгъбәмнең гыйшкында.
Ул Исламның былбыллары куныб сайрар гөлләрендә.
Хәзрәт Кәгъбәм аермагыл безне мәхшәр көнләрендә.
Хәзрәт Кәгъбә, генәм дидем, йөрәккенәм улыб бара,
Кылма Кәгъбәм, йөзебезне мәхшәр көнләрендә кара.
Тарикның былбыллары куныб сайрар мәйданларда.
Гыйшык утына янганлар – хәзрәт берлән бергә китәр.
Хәзрәт Кәгъбәм шәфкать кылса, җәннәт бакчаларын гизәр.
Ул җәннәтнең хур ияләре су сибәләр гөлләренә,
Хәзрәт Кәгъбәм, кыл шәфәгать, без Гасый мәсикенләреңә,
Хәзрәт әйтер: «Балаларым бездән калгандыр бу урын,
Чын ихласдин янганларга Ходам салыр үзе нурын».
Аллаһ әйтеб утырганларга, хәзрәтне телгә алганлар,
Хәзрәт Кәгъбәмне күргәнләр, ни бәхетле җанлар алар.
Җаныбызны һәм биргәндә, Газраиль дустым килгәндә,
Хәзрәт Кәгъбәм дәрманым син, янымда бул җан биргәндә,
Хәзрәт Кәгъбәмнең юлында, җанларыбыз булсын корбан.
Хәзрәт Кәгъбәбез мөһрибан шәфкать кылыр ул безләргә.

[1] *Мәдех әйтергә* – мактарга, яхшылыгын сөйләргә.
[2] *Яд итик* – искә алыйк.

Хәзрәт Кәгъбәмнең юлында, яныб-көеб без улыйк.
Чын хакыйкать дуслар илә, Хәзрәт Кәгъбәм ни сөйлим.
Гүрмәдин баш күтәргәндә, хайран булыб утырганда,
Хәзрәт Кәгъбәм кыл шәфәгать, мәхшәр көнендә мизанда,
Аһ, дусларым, уйганыйк, хәзрәткә без барыйк.
Хәзрәт Кәгъбәмнең юлы хак, чын күңлебезгә алыйк.
Гүремдә ялгыз калганда, сорау сөалем алганда,
Хәзрәт кыл Кәгъбәм шәфәгать, мәхшәр көнендә мизанда,
Илаһым фазыл кәрам берлән, ярлыкар ул колларны,
Аһ, дустларым, онытмыйк, Хәзрәт Кәгъбәмнең юлларын.

**Мөнәҗәт**

*(Рабигыләүвәлдә дөньяга килде...)*

Рабигыләүвәлдә дөньяга килде,
Пәйгамбәр буласын Әминә белде.
Бераздан күб җатлар килде,
Әминә аларның серләрен белде.
Шул заман баланы кулына алды,
Пәйгамбәр нурына хәйранга калды,
Шул заман үзе нур эчендә калды.
Мөбарәк нурлары муенын җылгады,
Әминә баланы караб туймады.
Йөзенә нур-нур баткан иде.
Нурга күмелеб бала яткан иде.
Хәлимә баланы кулына алды.
Пәйгамбәр нурына хәйранга калды.
Әминә аңлады, китә инде баласы,
Аерылыб баласын караб каласын.
Хәлимә китәдер баланы алыб,
Еглама, Әминә, син, – Хәлимә диде.
Баланы хәзер алыб күр, – диде,
Китә балам диб кайгыга калды.
Инде китәсең, балам, кулымдин.
Караб калыйм киткән юлыңдан,
Балам, кулымдан нигә китәсең,
Бик ерак илләргә барыб җитәрсең.

Балам китәдер инде мин ни диим.
Исәнлек хәбәрен кайдан кетәрем,
Хәлимә баланы кулына алды
бер арык дәвәнең илтеб өстенә салды.
Үзе дә Хәлимә дәвәгә менде.
Бу арык дәвәне Әминә күрде,
Ничек җитәрсең Таиф иленә, – диде.
Дәвәгез бик арык күренә диде.
Мәдәт бирүче[1] бер Аллаһ, диде.
Әминә баласын озата бара.
Күзендин туктамый яше ага.
Шәһәрне үткәчдән аерылыб кала,
Әминә баладин бик еракга кала.
Хәлимә кулын бирмәин калам инде.
Ялгызым буш өйгә мин барам инде.
Аллаһның хәбибе синең өстеңдә,
Ак болыт күләгә баш өстендә.
Күреб Хәлимә хәйран калды,
Тиз генә баланы кулына алды.
Ак болыт икесенә күләгә булды.
Хәлимәнең күзенә яше тулды.
Шул заман бер тавышы килде:
Курыкмагыл, Хәлимә, еглама, – диде.
Һич курку килмәс кальбең диде.
Хәлимә күрде караб алгарак,
Кәрванлар барадыр алдарак.
Хәлимә бу эшкә бик гаҗәб итде.
Шул вакыт Хәлимә кәрванын күрде.
Дәвәсе бик йөгрәк тиз килеб җидде.
Кәрванлар шул җирдә ялга туктады,
Хатынлар бу эшкә гаҗәбкә калды.
Хәлимә дәвәсе шул җиргә җүкде,
Сөт кабын китереб дәвәсен сауды,
Хатынлар бу эшкә гаҗәбкә калды.

[1] *Мәдәт бирүче* – ярдәм бирүче.

Синдә бу кемнең дәвәсе диделәр.
Үз дәвәм бу, – диде, – Таиф илендән.
Кәрванлар бәчасы туйды сөтдән,
Тагын саудылар, каблары тулды.
Ач иде кәрванлар – барчасы туйды.
Хәлимә баланы кулына алды,
Пәйгамбәр нурына хәйранга калды.
Кәрван барчасы дәвәгә менде.
Хәлимә кил диде, дәвәсе килде.
Меңгезде баланы дәвәсе эстенә.
Ак болыт күләгә башы өстендә.
Баралар хатынлар дәвәнең алдыдан.
Диделәр сөйләгел бу эшнең асылын,
Мин белмимен, диде, бу эшнең асылын.
Сорамадым нәселендән бу ятим баланы.
Бу ятим балага мин булдым ана.
Хәлимә дәвәсе бик куәтле бара,
Кәрванлар һаман бик ерак кала.
Караб күрделәр һаман ак болыт.
Шул көнен Хәлимә Таифкә җитде.
Килүбен өена дәвәдан төшде.
Шәтүбән дәвәдән өенә керде.
Хәлимә шат булганын ире дә күрде,
Фәкыйрь иделәр бу көнгә кадәр.
Аллаһның рәхмәте бонларга килде,
Хисабсыз байлыгына дәлилләб бирде.
Тәмам кылам ошбу каләмем.
Аллаһның дустына сәлам булса.
Хата булса урмагыз йөзгә,
Хатасыз бәндә юк, һич Хакдин үзгә.
Тәмам.

*Николаевка районы Әхмәтле авылы,*
*Айбулатова Мәгърифә Билял кызы*
*тапшырган кулъязма дәфтәрдән алынды*

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КӨНБАТЫШ ДИАЛЕКТЫНЫҢ УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНДӘГЕ СӨЙЛӘШЛӘРЕ ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Миңнира Булатова*

Татар теленең көнбатыш (мишәр) диалекты вәкилләренең язма тарихта билгеле булган иң борынгы яшәгән җире булып Цна һәм Мокша елгалары бассейннары санала. XVI–XIX гасырларда Рус дәүләте тарафыннан аларны бу бассейн территориясеннән башта көнчыгышка, аннан соң көньяк һәм көньяк-көнчыгыш юнәлешләрендә күчереп утырту барган. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, аларны күчерә башлау Рус дәүләтенең чикләрен күрше күчмә халыкларның һөҗүменнән саклау өчен, хөкүмәт тарафыннан ныгытмалы саклану сызыклары, яңа крепостьләр төзү белән бәйле. Шул вакытларда ук (XVI гасыр), мишәр сөйләшләре инде ике типка – ч-лаштыручыларга һәм ц-лаштыручыларга аерылган булган. Соңга таба төрле тарихи сәбәпләр аркасында, бер-берсенә якын торган яңа сөйләшләр барлыкка килә. Алар фәндә кабул ителгән территориаль-лингвистик билгеләр нигезендә бүленеп чыгалар. Ульяновск өлкәсе территориясендә татар теле көнбатыш диалектының хвалын, карсун, мәләкәс сөйләшләре таралган. Бу сөйләшләр, XX гасырның икенче яртысыннан башлап, татар тел белгечләре-диалектологлары Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Г.К. Якупова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова, З.Р. Садыйкова һәм Т.Х. Хәйретдиновалар тарафыннан махсус диалектологик экспедицияләр уздырылып өйрәнелә. Ульяновск төбәге татарларының тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-

гадәтләре, этнографиясе, аларга хас сөйләш-тел үзенчәлекләре галимнәрнең бихисап фәнни, фәнни-популяр мәкалә һәм китапларында чагылыш таба. Мәсәлән, алар татар диалектологиясенең җитди казанышларын тәшкил иткән «Урта Идел һәм Урал төбәге татар халык сөйләшләре атласы» (1989), «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләре» (ике китапта, 2008), тулыландырылган һәм эшкәртелгән «Татар халык сөйләшләре атласы» (2015), шулай ук «Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре» (Рамазанова Д.Б., 2011), «Татар-мишәр рухи мирасы: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор» (Баязитова Ф.С., 2003) кебек хезмәтләрдә дә урын алган.

## I. ХВАЛЫН СӨЙЛӘШЕ

2017 елның җәендә Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районының Атлаш, Мосеевка (Муса), Иске Мостяк, Яңа Мостяк, Урта Терешка, Кирюшкино, Иске Зеленай, Вязовый Гай, Яңа Зимичә, Иске Яндука, Иске Кулаткы исемле татар авылларына Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан уздырылган экспедиция милләттәшләребезнең гореф-гадәтләрен, көндәлек һәм мәдәни тормышларын яктырткан материаллар тел үзенчәлекләре җәһәтеннән фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирде.

Иске Кулаткы районының татар авылларында көнбатыш диалектның хвалын сөйләше таралган. Шулай ук бу сөйләш Ульяновск өлкәсенең Николаевка, Павловка районнары халкына да хас. Иске Кулаткы районында 1990 елда Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдиновалар да экспедициядә булалар.

Хвалын сөйләше 1961, 1963 елларда Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан махсус өйрәнелгән. Бу галимә турында тулырак әйтеп узарга кирәк. Чөнки ул шушы җирлектә – Ульяновск өлкәсендә – туып үскән күренекле шәхес.

Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова 1925 елның 25 августында Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы Мосеевка (Муса) авылында туа. Ленинград дәүләт университетында югары белем ала, 1948–1952 елларда аспирантурада укый. 1952 елда «Особенности

касимовского говора татарского языка» дигән темага кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый. 1952–1986 елларда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында хезмәт куя. Фәнни тикшеренү эше белән шөгыльләнә, тел белеменең төрле өлкәләренә караган күпсанлы фәнни китаплар, монографияләр, мәкаләләр яза. Л.Т. Мәхмүтова – барыннан да элек диалектолог. Ул тел белеме бүлегенә җитәкчелек иткән вакытта татар диалектологиясе аерым мөстәкыйль тармак буларак формалашып җитешә, яңадан-яңа үрләр яулый. Татарлар яшәгән барлык төбәкләргә диярлек диалектологик экспедицияләр оештыра. Аның күпчелек хезмәтләре татар теленең көнбатыш диалекты сөйләшләрен өйрәнүгә багышланган. Мәсәлән, аның «Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарского языка)» дигән монографиясендә көнбатыш диалекты бар тулылыгында тикшерелә.

Иске Кулаткы районындагы милләттәшләребез безне татарларга хас кунакчыллык, итәгатьлелек күрсәтеп, якты чырай белән каршы алдылар. Алар «күңел җимешләрен», «тел җәүһәрләрен», ягъни әби-бабалары тапшырып калдырган йолалар, гореф-гадәтләр турында безгә сөйләделәр. Сәфәребезне нәтиҗәле итүдә хуҗалык җитәкчеләренең, мәктәп һәм мәдәният хезмәткәрләренең ярдәме зур булды. Санап узган авылларда олысының да, «оланының» да, кечесенең дә халкыбыз традицияләрен ихтирам итеп саклап, үстереп гомер кичерүен күрдек.

Иске Кулаткы районы татарларыннан мәгълүмат алган вакытта җирле сөйләшкә хас үзенчәлекләр ачылды. Алга таба көнбатыш диалектына караган хвалын сөйләшенең тел үзенчәлекләрен һәм халык традицияләрен чагылдырган материалларга – сөйләм үрнәкләренә тукталырбыз.

### Фонетик үзенчәлекләр

**Сузыклар.** [*а*] сузыгы хвалын сөйләшендә, татар теленең башка мишәр сөйләшләреннән аермалы буларак, арткырак позициядә ясала һәм җиңелчә иренләшкән [*а*$^{о}$] булып әйтелә.

[*ә*] авазы, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек, алгырак позициядә ясала.

[*у*], [*ү*] сузыклары хвалын сөйләшендә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек, алгырак сузыклар итеп, нечкәртебрәк әйтелә.

Сузык авазлар өлкәсендәге фонетик үзенчәлекләр, нигездә, аваз тәңгәллекләренә карый.

[*ы*]~[*а*], [*э(е)*]~[*ә*] бер төркем сүзләрдә очрый: *мәктеп* – әд. мәктәп, *йаңы* – йаңа (яңа), *кагыз* – кәгазь, *сыранча* – саранча, *сымаwыр* – самовар һ.б.;

[*э(е)*]~[*и*]. Хвалын сөйләшендә татар әдәби телендәге [*и*] сузыгы урынына [*э(е)*] куллану актив. Бу тәңгәллек бигрәк тә мишәр сөйләшләрендә әдәби телдәге [*җ*] авазы урынына әйтелгән [*й*] авазыннан соң күзәтелә: *йер* – әд. җир, *йебәрү* – җибәрү, *йемерелү* – җимерелү, *йеб* – җеп, *йезнә* – җизни, *йемеш* – җимеш, *йеңгә* – җиңги, *йеде* / *йиде* – җиде һ.б. Әдәби тел тәэсирендә хвалын сөйләшендә бу сүзләрнең *җ* варианты да кулланыла: *җир, җиң, җил, җиңел, җиде* һ.б.

[*и*]~[*ә*] тәңгәллеге түбәндәге сүзләрдә очрый: *сике* – әд. сәке, *кечерик* – кечерәк. Ләкин: *пәке, чәчәк, сәнәк.* Киресенчә, түбәндәге сүзләрдә [*ә*]~[*и*]: *зәрәт* – зират, *кәмү* – кимү, *шәкәр* – шикәр, *пәсук* – песок, *мәләш* – миләш, *кәмә* – кимә < көймә, *әпәй* – ипи, ләкин: *кирәк, бик.*

Әдәби телдәге [*у*], [*ү*] сузыкларына [*о*], [*ө*] тәңгәл килү бер төркем сүзләрдә очрый: *шолай* – әд. шулай, *орлау* – урлау, *олым* – улым, *осак* – усак; *көп* – әд. күп, *көʏл* – күл, *өлән* – үлән, *бөлеп* – бүлеп, *көпер – күпер, төгөл/тегел* – түгел, *көңөл* – күңел, *чөпрәк/чепрәк* – чүпрәк; киресенчә, [*у*]~[*о*], [*ү*]~[*ө*]: *үч* – әд. өч, *куйаш* – кояш, *үмә* – өмә, *йүгән* – йөгән; *бутка* – ботка, *гумер* – гомер; [*ы*]~[*у*]: *йыва* – йуwа, *сывык* – суык, *ывыз* – угыз, *шындый* – шундый.

А ң к а у г а р м о н и я с е. Алгы һәм арткы рәт сузыклары тәңгәллегенең хвалын сөйләшендә түбәндәге очраклары күзәтелә.

Аерым сүзләрдә арткы рәт сузыклары әдәби телдәге алгы рәт сузыкларына тәңгәл килә: *чыган* – әд. чегән, *йанаша* – йәнәшә (янәшә), *хайыр* – хәйер (хәер), *йорырга* – йөрергә, *хал'* – хәл, *мачы* – мәче, *корка* – күркә, *кочок* – көчек, *хабар* – хәбәр, *сура* – *сүрә, ар'ан* – әйрән, *ат'/әт'* – әйт һ.б.

Киресенчә, әдәби телдәге арткы рәт сузыклары урынына сөйләштә алгы рәт сузыклары кулланыла: *чәйкәде* – әд. чайкады, *йөн* – йон, *кечерткән/кечеркән* – кычыткан, *чебелдек* – чыбылдык, *бәлчек* – балчык һ.б.

[*о*], [*ө*] авазларының әйтелеше хвалын сөйләшендә әдәби телнең орфоэпик нормалары белән туры килә һәм икенче иҗекләрдә дә әйтелә: *соло, тормош, борно;* өлешчә ***о>ы,*** ягъни иренсезләштерү очраклары да бар: *сылы, бырны, дыва* – дога, *тырмыш, кебе, сет* һ.б. Киресенчә, кайбер сүзләрдә [*о*] авазы [*ы*] сузыгын алмаштырып килергә мөмкин: *ошану* – әд. ышану, *койар* – кыйар.

А в а з ө с т ә л ү. [*и*]*: чәкчәки* – әд. чәкчәк; [*ә*]*: кәләшә* – кәләш, *пәрәмәчә* – пәрәмәч; [*ы*]*: макы* – мәк, *ывак* – вак.

А в а з т ө ш ү. [*ә*]*: тәрәз* – әд. тәрәзә, *кыргыр – кырыгар*; [*о*]: *карабдай* – карабодай; [*у*]: *марта* – умарта (корты), [*а*]: *чабатлар* – чабаталар, *алашлар* – алашалар (атлар); [*е*]: *килнем* – килeнем, [*ы*]: *катны* – хатыны.

**Дифтонглар.** Дифтонглар белән бәйле үзенчәлекләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк.

[*р*], [*н*], [*л*], [*д*], [*т*], [*ч*], [*с*] тартык авазлары алдыннан килгән ***-ай*** дифтонгы монофтонглаша, [*й*] тартыгының төшеп калуы аннан соң килгән әлеге тартыкларның палатальләшүенә китерә: *бар'ам* – әд. бәйрәм, *ар'ан* – әйрән, *кас'ы* – кайсы, *кан'амау* – кайнамау, *сал'а* – сайла, *кач'ан* – кайчан, *кан'ата* – кайната, *ад'а* – әйдә һ.б.

Әдәби телдәге ***-өй*** дифтонгы хвалын сөйләшендә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, монофтонглаша. Мисаллар: *ү* – әд. өй, *үләнү* – өйләнү, *сүлә* – сөйлә, *кү* – көй, *түмә* – төймә, *үдә* – өйдә, *өрәнү* – өйрәнү һ.б.

Ике сузык арасында ***-үw/-еw/-өw ~ -өй:*** *үwәбез* – өйәбез (өябез), *сүwенче / сеwенче* – сөйөнеч (сөенеч), *сүwәк / сөwәк* – сөйәк (сөяк), *күwә/кәwә* – көйә (көя), *сүwәл / сөwәл* – сөйәл (сөял) һ.б.

Аерым сүзләрдә иҗек ахырындагы ***-ый*** дифтонгына сөйләштә ***-ий*** дифтонгы тәңгәл килә: *абзий/әзий* – абзый, *җийнау* – җыйнау, *кийнау* – кыйнау, *бармийм* – бармыйм.

**Тартык авазлар** системасында, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек, хвалын сөйләшендә дә әдәби телдән аермалы

үзенчәлекләр бар. Тартык авазларның составы һәм аларга характеристика, нигездә, теге яки бу сузык авазның барлыгы, юклыгы һәм аваз тәңгәллекләренә карый. Тартык авазлар хвалын сөйләшендә, әдәби телдәге шундый ук тартыклар белән чагыштырганда, артикуляцион яктан алгырак позициядә ясала. Бу бигрәк тә тел арты тартыкларын әйтүдә күзәтелә.

Тартык авазлар хвалын сөйләшендә, әдәби телдәге кебек үк, калын һәм нечкә вариантта әйтеләләр. Аларның кулланылышы сузык авазның калын яки нечкә булуы белән бәйле. Сөйләштә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек, тел арты [*к*], [*г*], [*х*], [*ң*] авазларын әйтү хас: *кар, карга.*

Хвалын сөйләшенә ***й***-ләштерү характерлы. Тел уртасы [*й*] тартыгы татар теленең үз сүзләрендә һәм гарәп-фарсы алынмаларында сүз башында күзәтелә: *йел* – әд. җил, *йәйәү* – җәйәү (җәяү), *йома* – җомга. Шуның белән бергә сөйләштә өрелмәле [*җ*] авазы да кулланыла.

[*җ*] авазы татар теленең үз сүзләрендә сүз башында очрый: *җиде, җир, җиң, җәйәү, җәймә, җемелди* һ.б.

Шулай ук гарәп-фарсы алынмаларында сүз башында, сүз уртасында куллану очраклары бар: *җавап, җәбер, җәмийәт* (җәмгыять), *энҗе* һ.б. Ләкин: *дөнйа, марйа* – марҗа.

[*ч*] авазы хвалын сөйләшендә, татар әдәби телендәге кебек, өрелмәле аваз булып әйтелә: *чалма, чир, чүмеч, чүлмәк.*

Тел очы [*д*], [*т*], [*ж*], [*ш*], [*з*], [*с*], [*р*], [*л*], [*н*], [*ч*] авазлары, алардан соң килгән ***-ай***/***-әй*** дифтонгларындагы [*й*] авазы төшү нәтиҗәсендә палатальләшәләр һәм нечкә [*д'*], [*т'*], [*ж'*], [*ш'*], [*з'*], [*с'*], [*р'*], [*л'*], [*н'*], [*ч'*] булып әйтеләләр. Мисаллар: *кан'а* – әд. каенана, *кат'а* – кайта, *ат'а* – әйтә, *кас'ы* – кайсы, *кач'ан* – кайчан, *кан'ар* – кайнар.

[*л*] авазы төшеп калган берничә сүздә, [*т*] тартыгы палаталь [*т'*] булып әйтелә: *йугат'ма* – әд. йугалтма (югалтма), *йугат'ырма* – йугалттырма, шулай ук: *йыгыт'ма* – йыгылтма (екма).

Ирен тартыклары. [*б*]~[*п*]: сөйләштә *шурба* (шулпа) сүзендә борынгы төрки [*б*] авазы сакланган: *йебәк* < *йепәк* < *йефәк* (ефәк). [*п*]~[*б*]: *пот* – әд. бот, *потак* – ботак.

[*п*]~[*ф*]. Традицион мишәр сөйләшләрендә, шул исәптән хвалын сөйләшендә дә, түбәндәге сүзләрдә этимологик [*п*] саклана: *йапрак* – әд. яфрак, *керпек* – керфек, *тупрак* – туфрак. Алынмаларда [*п*]~[*ф*]*: сәдәп* – сәдәф, *пытыр* – фытыр, *ышкап* – шкаф, *Сапийа* / *Сафийа* һ.б. Тик: *файда, Нәфисә.*

[*м*]~[*б*] сөйләштә берничә сүздә генә күзәтелә: *малан* – әд. балан, *мөрө* – бөре, *мәке*– бәке. Ләкин: *белән, корбан* һ.б.;

Тел очы тартыклары. [*з*]~[*җ*]: *кәзә* – кәҗә; [*д*]~[*т*]: *дустыган* – тустыган; [*н*]~[*д*]: *алны – алды, алнына – алдына.* Ике сузык уртасында *лд~лт***:** *ачкылдым-чөчкелдем* – ачкылтым-төчкелтем; [*л*]~[*р*]: *арлак* – арырак, *бирләк* – бирерәк, *зурлак* – зуррак; [*с*]~[*ч*]: *кирпес* – кирпеч, *ачкыс* – ачкыч, *бачкыс* – баскыч. Киресенчә, [*ч*]~[*с*]: *бачкыс* – баскыч, *кырмычка* – кырмыска; [*ч*]~[*т*]: *чөчө* – төчө (төче), *чике* – тике (тикле), *чөчкелт* – төчкелт.

Яңгырау тартыклар алдыннан [*ш*]*,* [*ч*] авазлары яңгыраулаша: *бижйәш* – биш йәш (яшь), *эжйук* – эш йук, *сугыжйыллары* – сугыш йыллары (еллары), *ажйаулык*– ашйаулык (ашъяулык), *пижҗбашты* – пич башы, *пижҗйагарга* – мич йагарга (ягарга).

[*н*]~[*ң*] (иялек килеше кушымчасы -ның/-нең һәм фигыль кушымчаларында): *Радищевода анын праздникы көнен үткәрәләр. Бернәрсәгә дә бакмасын. Мәләшне йаратмыйсынмы? Нәстәви догасын укыйсын.*

Гарәп-фарсы алынмаларындагы тирән тел арты [*ғ*] авазы төшә: *сәат* – әд. сәгать, *айыт* – гайыт (гает), *үмер* – гомер, *йома* – җомга.

[*г*]~[*к*] ике сузык арасында күзәтелә: *чигерткә* – әд. чикерткә, *сигезән ике* – сиксән ике, *йага* – йака (яка), *чогыр* – чокыр.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр. [*т*]~[*к*]: *читлавык* – чикләвек; [*к*]~[*т*]: *keләү* – теләү, *keләнче* – теләнеп йөрүче, *keләнү*; [*к*]~[*х*]: *катарлы* – хәтәр, *катны* – хатыны; [*ң*]~[*г*]: *үңгәрү* – үзгәрү, [*х*]~[*к*]: *вахыт* – вакыт; [*т*]~[*с*]: *төтәсен* – сүтәсең, *согына* – тыгына; [*т*]~[*ч*]: *тишенү* – чишенү, [*в*]~[*б*]: *вәке* – бәке, [*т*]~[*д*]: *тага* – дага.

Аваз өстәлү. [*т*]: *йаз башты* – яз башы, *пижҗбашты* – мич башы; [*р*] *кечеркән* – кычыткан; [*д*]*: кузгалдак* – кузгалак; [*й*]: *бйер* – бер.

Аваз төшү. [*т*]*: кечеркән* – әд. кычыткан; [*к*]: *арбуз* – карбыз; [*й*]*: эләк* – йеләк (җиләк)*, асый идек* – йасый идек; [*н*]*: камбай* – комбайн.

Метатеза күренеше: *элке* – әд. элек, *эстәкер* – эскәтер (скатерть), *азбар* – абзар, *үрмәкчә* – үрмәкүч, *кабак* – капка.

### Грамматик үзенчәлекләр

Хвалын сөйләше әдәби телдән, нигездә, аерылмый, шулай да түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин.

**Исемнәр.** Бу сөйләшкә дә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек, ялгызлык исемнәрне кыскартып сөйләү хас. Алар икенче, хәтта беренче иҗеккә кадәр кыскартылалар, аннан соң еш кына ***-кай*/*-кәй, -ук*/*-үк*** кушымчалары ялгана: *Мәргү* – Мәргубә, *Хайрук абзий* – Хайрулла абзый, *Хал'кәй бабай* – Халиулла бабай, *Бәдр'ук* – Бәдриҗамал һ.б.

Хвалын сөйләшендә изафәнең I һәм II төрләре параллель кулланыла: *эт эләк* / *эт эләге* – бүре җиләге, *тәрәзә төп* / *тәрәзә төбө.*

**Сыйфатлар** хвалын сөйләшендә, нигездә, әдәби телдәгечә. Тик чагыштыру дәрәҗәсен белдерә торган ***-рак*/*-рәк*** кушымчасы нигезе ***р*** га беткән сыйфатларга, рәвешләргә ялганганда, кушымчадагы ***р*** авазы ***л*** белән тәңгәлләшүен генә билгеләп үтәргә кирәк: *зурлак* – әд. зуррак, *бирләк* – бирерәк, *арлак* – арырак.

Әйтеп узарга кирәк: Иске Кулаткы районы халкы телендә «*әйбәт*» сыйфаты әйтелми, «*яхшы*» вариантын гына кулланалар.

**Саннар.** Аларның төркемнәре, грамматик категорияләре әдәби телдән аерылмый. Шуның белән бергә, төп сан урынына җыю саны формасын куллану очраклары бар: *Илләү* (әд. илле) *идек, илле бер олан идек кечкенә урамда. Болар сигезәү* (сигез) *икән. Күбәү анда: тугызаумы* (тугызмы, тугызлапмы), *унберәүме* (унмы).

Шулай ук, бу күренеш *күп* рәвеш сүз төркеменә дә хас – *күбәү*/*көбәү*: *Бик көбәү* (күп) *иделәр.*

**Алмашлыклар. Күрсәтү алмашлыкларындагы аермалыклар:** *бу, ул, шол, ана, үнә, вана, вәнә.* Мисаллар: *Үнә* (әнә) *ул, Кулатка йулын менеп киткәндә. Айакка вата* (менә) *чабата. Вата йәшибез. Вәнә* (әнә) *йакшы гына йегеткә бар да кит, ди.*

*Нәрсә* сорау алмашлыгы белән беррәттән *нәстә* алмашлыгы да кулланыла: *Нәстә* (нәрсә) *эләктерден кулыңа? Укый-йаза бел-ми бернәстәдәме?*

**Рәвешләр** өлкәсендә түбәндәге үзенчәлекләр күзәтелә.

Әдәби телдәге *көн буе, төн буе, кыш буе* тибындагы рәвешләр урынына хвалын сөйләшендә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек, *көнсәтә, көн ката, кыш ката* формаларын куллану актив: *Йаз башы ташуларны көн ката бага идек. Көнсәтә урамдалар балалар.*

Рәвешнең ***-лый/-лий*** формасы сөйләштә, башка мишәр сөйләшләре белән чагыштырганда, актив түгел. *Акчалый түләмиләр. Кышлый, йазлый* формалары да сирәк.

Бәйлек сүз төркеменә дә *-лый/-лий* формасының кушылуы күзәтелә: *Ул шул таулар ашалый* (аша) *шул кругтарак байларны талый булган.*

***-лата/-ләтә:*** *Чөчөләтә пешердем. Беленне пич каршында пешерәсен, чөчөләтә була инде, ачылата булса, дражжи саласын.*

*Тапкыр, мәртәбә* сүзләре белән беррәттән *тынап* (раз) сүзе кулланыла: *Кортыга икешәр тынап* (ике тапкыр) *дару сибәләр. Кырда кененә ике тынапмы* (ике мәртәбә) *ашаталар. Шулар инде өчәр тынап* (өч тапкыр) *бийергә алалар тра-л'а-л'ай уйын-җырына. Татар теле ике тынап* (ике мәртәбә) *атнасына, и бер әдәбийәт.*

Лексик рәвешләр: *жар* – эссе, *зәрәдән* – иртән, *төнәген* – кичә, *элке* – элек, *берсәк* – бераздан, *берчи* – гел, *йантыгы* – ягы, кырые, *әкерт кенә* – әкрен генә.

**Фигыльләр.** Фигыль формалары хвалын сөйләшендә, нигездә, әдәби телдәгечә. Кайбер үзенчәлекләрне күрсәтеп китәргә мөмкин.

1 нче һәм 2 нче зат нәтиҗәле үткән заман, әдәби форма белән беррәттән *(укыганмын),* диалекталь формада да кулланыла: *Мин барыпмын, без барыпбыз* (барганмын, барганбыз). *Син барыпсын* (баргансың). *Мин үги әнидә үсепмен* (үскәнмен).

Күптән үткән заманны, әдәби ***-ган/-гән иде*** формасы белән беррәттән, ***-ды/-де + иде*** аналитик тезмәсе ярдәмендә дә белдерү очраклары теркәлгән: *бардым иде* – барган идем, *бардын иде* – барган идең, *барды иде* – барган иде, *бармады иде (ыйы)* – бармаган иде һ.б.

Сөйләштә дәвамлы үткән заманның көнбатыш (мишәр) диалекты сөйләшләренә хас ***-а/-ә + булган*** төзелмәсе дә күзәтелә: *Аларга продукталар китерә булганнар* (китерә торган булганнар). *Чыгып багып йөри булганнар* (йөри торган булганнар). *Кас'ы-кас'ы авылда гына барып китерә булганнар сөннәтче бабайларны. Хвалынга бара булганнар. Җәймә пешерә булганнар элке.*

Теләк фигыль. Башка мишәр сөйләшләреннән аермалы буларак, хвалын сөйләшендә ***-гы/-ге + иде*** формасы сирәк очрый: *баргы иде* – барасы иде.

Теләк, ният ***-гы + кели*** конструкциясе белән белдерелә: *баргы келим* – барасым килә, *баргысы кели* – барасы килә. Мәсәлән: *Ашаткым да кели кергән кешене. Ашамас иден, ашык кели.*

Шарт фигыль сөйләштә, нигездә, татар әдәби телендәге кебек, ***-са/-сә*** кушымчалары ярдәмендә ясала: *Әгәр дә инде без, качкан кешеләр, тегенең мәрәсенә барып тук-тук тукысак, котылабыз. Укыса, белә ул.*

Фигыль дәрәҗәсе. Кабатлаулы эш яки хәл хвалын сөйләшендә ***-гала/-гәлә/-гакла/-гәклә*** формалары белән белдерелә: *баргакла* – баргала, *килгәклә* – килгәлә. *Мәчеткә йөргәкләдем* (йөргәләдем) *намаз укырга.*

Инфинитив сөйләштә, татар әдәби телендәгечә, ***-ырга/-ергә*** кушымчалары ярдәмендә ясала: *Коро йылгага җийәү барырга кирәк. Өстәлне кагызга себерергә йарамый – тавыш куба.*

Хәл фигыльнең сөйләштә, әдәби телдәге формалары белән беррәттән, ***-ганчык/-гәнчек, -гачтан/-гәчтән, -гачтын/-гәчтен, -гычтан/-гечтән*** кушымчалары да кулланыла: *алганчык, алганчак* һ.б. Мәсәлән: *Хал'ләнә башлагачтан бәбәй майы җийа идек. Киндерашны ывып ашадык, җиткәчтән.*

***-ып/-еп*** формалы хәл фигыльнең юклыгы ***-мыйча/-мича (мичә), -мыйынча/-мийенчә*** кушымчалары белән дә ясала: *укымыйынча, сүләмийенчә* һ.б. Мисаллар: *Бер касталанмыйынча йәшәп үлде. Йул буйы сүләшмичә бардык, ди.*

Фигыль яки фигыль + *түгел* тезмәсе урынына *юк* модаль сүзен куллану: *Бик тиз аңгарам* (аңлыйм), *но урысча сүләргә йук* (сөйли белмим). *Аны йәшерегә йук* (йәшермим). *Исторblock сүләп*

*тә бетерергә йук* (бетерерлек түгел), *йөрәк майым. Эштән бер көн дә калырга йук* (калырга йарамый). *Атергә хал' йук* (сөйләп бетерерлек түгел). *Урыслар ат'а икән: «Поптан башка күмергә йук* (күммәскә)*». Кабактан* (капкадан) *чыгарга йук* (чыгарлык та түгел), *теннә орлыйлар иде ди, әнәй әтә .*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре.** Кайбер ***бәйлекләр*** сөйләшнең үзенчәлеген тәшкил итәләр. Мәсәлән, *тике/тәке* – кадәр, *чике* – тикле (кадәр): *Шуның чике* (тикле) *сөйәкләр чыккан иде казыгач. Караңгыга тәке жарда эшләдем. Вата пайыт астына тәке* (кадәр) *су килә иде.*

Хвалын сөйләшендә *әмән* сүзе теркәгеч (гүя, әйтерсең лә) һәм охшату-чагыштыру бәйлеге (шикелле, кебек, бугай) буларак актив кулланыла: *Кара болыт зыйанлы – нәрсәдер әмән* (кебек) *була инде. Безнең аwыл йегетләре әмән төшкән мачылар* (сыман) (такмактан). *Әмән бер кызайыбыз бер тынап җийа, икенче кызайыбыз икенчесенә җийа. Кәнәфинен артлы, йантыкларын тешерәләр әмән* (әйтерсең лә) *мудалап инде. Анда минеке булмый әмән әтийек. Әмән кийәүгә чыгасың, кан'а кулыга эләгәсең бит инде.*

Сорау кисәкчәсе *-мы/-ме* хвалын сөйләшендә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек, логик басым төшкән теләсә нинди җөмлә кисәгенә ялганып килә: *Марат, әнийең аларны озакмы тотты вата? Мәчеткәме барырга дисез?* (Мәчеткә барырга дисезме?). *Анда китергәннәр утызнымы муллаларны?* (Анда утыз мулла китергәннәрме?).

### Лексик үзенчәлекләр

Хвалын сөйләшенең төп лексик составы, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Диалекталь лексиканың шактый зур өлеше көнбатыш (мишәр) диалектының башка сөйләшләре белән уртак. Сөйләш өчен характерлы диалекталь лексиканың кайбер тематик төркемнәрен күрсәтеп үтик.

Туганлык һ.б. терминнар: *анай* – әд. әни, *атай* – әти, *кан'а* – каенана, *кан'/ кан'ата* – каената, *әбкай* – дәү әни, *брат* – абый, ир кардәш, *тәтә* – апа, *әбзәй* – абый, *апалы-братлы* – абыйлы-энеле*, җиңкойым* – җиңги, *кызай* – дус кыз, *олан* – бала, *әшнә* – дус, *нәчәл* – рус. начальник, *кәбәм* – эндәшү сүзе.

Йола, гореф-гадәтләр белән бәйле сүзләр: *руза вакыты* – рамазан вакыты*, йаңгыр боткасы, йаңгыр теләге* – озак яңгыр яумый торса, өй саен йөреп йомырка, ярма һ.б. җыеп, су буенда ботка пешерү һәм соңыннан су сибешү йоласы; *бәбәй майы* – балага исем кушу мәҗлесе, *бирнә* – каенана, каенатага бирелә торган әйберләр, киленнән бүләк, *безелек* – язын, кар киткәч, җир ачылгач та беренче уйыннар.

Кеше һәм аның эш-хәрәкәте белән бәйле сүзләр: *калын* – әд. симез, таза, *йадау* – ябык, *маскарчы* – мәзәкчән, шаяртырга яратучан, *койты* – начар, *челги* – сөял, *бәбәк* – күз, *үзгәчә* – башкача; *тыну* – хәл җыю, *багарга* – карарга, *йәшү* – чакыру, *тетеп бетерү* – юкка чыгару, җимерү, *басу* – казу (*бакчалар баса иде*), *туу* – тудыру *(Анайым сигезне туган* (тудырган). *Дүрт бала тудым* (тудырдым))*, кырку* – кисү, *йүләү* – тегү, (бит) *себерү* – (битне) сөртү, *көлкеш* – уен-көлке, *фотога сугу* – фотога төшерү, *жарлану* – эсселәнү, *мәктәпкә тийәрбез* – мәктәпкә кагылырбыз, кереп чыгарбыз, *орлык чийертү* – көнбагыш чиертү, *йылышу* – күчә төшү һ.б.

Каралты-кура, хуҗалык эшләре һ.б. белән бәйле лексика: *ике йаташлы* – ике катлы, *ызба* – өй, *йорт* – двор (*йорт бездә двор (ихата) мәгънәсендә, каралты-куралар бар да керә*), *азбар* – сарай, *пижай/пижбай* – мич башы, *пайыт башы* – сарай башы, *пайтасты* – сарай, лапас асты; *аран*– җылы мал абзары, *клад* – кибән, *лабак* – (< лабагрейка) – урып-җыю машинасы, *пул'* – мунча ләүкәсе, *кәнәфи/түр* – тактадан гына эшләнелгән диван, *тубал* – тал чыбыкларыннан үрелгән түгәрәк, тирән кәрзин, *чичел/чичин* – тал чыбыгыннан үрелгән әрҗә, чана, *пуланча* – утынлык, *саласка* – кечкенә чана, *зат* – әйбер, *йеслек/йөзлек* – сөлге, *палаwник* – аш чүмече, *шава* – киң таба, *кучарка* – кисәү агачы, *дустыган* – чүмеч, *пристин'а* – рус. простыня, *код'ала* – тараксыз каба, *чебелдек* – кроватка әйләндереп куелган кашага, *кашма* – сарык йоныннан басылган киез (рус. кошма, войлок), *йастык* – мендәр, *куфай* – фуфайка, *запун* – альяпкыч, *кәпәч* – кәләпүш, *чылдыр* – чулпы, *тәпеш* – тапочки, *пайпак* – куй йоныннан бәйләнгән следочек, тапочки кебек, *варига* – бияләй һ.б.

Аш-су исемнәре: *әпәй* – ипи, *катлама* – урама, *мөшкә/эремчек* – эремчек, *җәймеш* – йука, *таба катламасы* – табикмәк, *кыйыкча* – кош теле, *кытырмач* – сохарый, *күмәч/таба күмәч* – вак кабартмалар, *питырас* – ачы камырдан пешерелгән вак-вак түгәрәк ипиләр, *пәже* – киндер, *пәрәмәчә* – ит пәрәмәче, *чигелдәк* – бавырсак, *сыван аш* – кысыр аш; *салма/эләкшә* – токмач, *сеңәл* – сыек, *шурба* – шулпа, *кагыт* – как, *урнаш* – яңгыр боткасы, *шама / чәй шамасы* – чәй чүбе, *чумара* – чумар һ.б.

Үсемлек атамалары һәм хайваннар дөньясы белән бәйле сүзләр: *чамбыр* – чабыр үләне (рус. чабрец), *ыргазы(й)мбай* – умырзая, *кырмалау* – тигәнәк, *кучан* – әрекмән, *кузгалдак* – кузгалак, *мачы күрик* – песи тарысы, *пангы* – гөмбә, *айбагар* – көнбагыш, *әби белән бабай* – тузганак, *казгылдич* – кәҗә сакалы, *көчөк үләне* – эт җиләге, *кара әләк* – кара җиләк, *эт әләк* – бүре җиләге, *урман әләге* – җир җиләге, *мәтрушка* – мәтрүшкә, *кыркабаш* – шалфей, *үгез күз* – гөлҗимеш, *мошкы* – мүк, *американский алабута* – зур, киң яфраклы алабута, *чәйер* – каен тузы, *күкчәчәк* – арыш чәчәге (рус. василек), *малан* – балан, *мәләш* – миләш, *изүмләк* – изюм, *капыста* – кәбестә, *картук/карту* – бәрәңге, *каwын* – кабак, *пымадур* – помидор, *сыйырчык ашы* һ.б.; *әлчи* – куйның ашык сөяге, *алаша* – ат, *кочок* – эт, *мачы* – мәче, *кукы* – кәккүк, *кучат* – әтәч, *куй* – сарык, *кучкар* – сарык тәкәсе, *әлчә* – куйның гузнасы, *кыр'ка* – күркә һ.б.

Табигать күренешләре, рельеф һ.б. белән бәйле сүзләр: *кизләү* – күл, *йаз башы* – яз, *йаз* – җәй, *зәрәдән* – иртән, *йантыгы* – ягы, кырые, *төнәген* – кичә.

## ЭКСПЕДИЦИЯ ВАКЫТЫНДА ХВАЛЫН СӨЙЛӘШЕ ВӘКИЛЛӘРЕННӘН ЯЗЫП АЛЫНГАН, ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ЧАГЫЛДЫРГАН МАТЕРИАЛЛАР (СӨЙЛӘҮ ҮРНӘКЛӘРЕ)

### Җир-су

**Иске Мостяк кизләүләре.** Аwылда кизләүләр (*күлләр*) күп. Тал кизләwе бар. Таллыктан чыккан ул, су буйыннан. Йугары оч-

тан Дәwи кизләве. Дәwи исемле кеше булган. Үзе кизләү казыган и шуннан киткән. Бөгөн дә аның суын эчеп торабыз. Бик көчле су ул. Ганкәй кизләве. Ганкәй бабайныкы. Борчак кизләwе – кушаматлары инде, аларның артларында кизләү агып тора. Җапка кизләwе. Ярулла инде. Куд(р)акай кизләwе. Койолар бик күп иде. Вуйын койосы бар. Бассейн йасаганнар борон бабайлар и көᵞл дип киткән. Көᵞлләр инде Сары күл генә. Җире торфанлы булган. Шуңа сары. Үпкәм күле бар. Wата ике авыл уртасында. Анда барырга йарамый. Бөгөн дә баталар анда.

**Урманнар**. Зиминчә урманы. Кретуй урманы. Крутой булган ул. Казантау – анда байлар торганнар. Алтыннар күп тапканар аннан. Бийек тавыбыз. Креп (*крепостнойлар*) булган Казантау артында. Аwылдан чыгып, шул анда утырган булганнар. Крепост' кебек үзләренә йасаганнар. Подземный урыннары булган. Граница булган инде. (Бу авыллар граница буларак утыртылган, саклау өчен). Казанга охшаган ул. Чокур. Байлар анда тормаганнар. Войынный кебекләр торган. Муракай дигән кеше. Ул Ул'йановсктан чыккан. Ул шул таулар ашалый (*аша*) шул кругтарак талаган булган байларны и йарлыларга бирә булган. Бу кругны кул астында тыткан.

*Сөйләүче: Ганиев Марат Исхак улы (1936),*
*Ганиева Мөнирә Якуп кызы (1937).*
*Иске Кулаткы районы Иске Мостяк авылы*

**Коры йылга.** Рәхмәтле урын инде. Анда китергәннәр утызнымы муллаларны, байларнымы китереп атканнар. Бер кабергә көмгәннәр. Бу башта шул үлеләр. Шул йылганың теге башында бик зур йахшы кизләү чыгып тора. Ул кырда инде ул кизләү. Шунда бетен соравыбызга барабыз. Хайыр итәбез. Нәзер әтәбез. Барып шунда соралабыз. Кочокка йорырга бик файдалы. Әтәсен шул затым булса, или әйбереңне йугатсаң, кочокка (*этка*) хайыр. Тапкач ук, бирергә кирәк. Коро йылгага инде җийәү барырга кирәк.

*Сөйләүче: Хөснетдинова Тәнзилә Солтан кызы (1931).*
*Иске Кулаткы районы Атлаш авылы*

## Тормыш-көнкүреш турында

**Атлаш авылы.** Армийәгә киткәндә миңа 17 йәш иде. Кат'кач кийәүгә чыктым. Бер йыл барып укыдым Камышлыда. Педагогический институттны бетердем бер йыл. Кат'тым үгә әт'ик. Урысча йахшы гына белмим. Мин служит' иткәндә дә мине беләләр – мин татарка – бик тиз аңгарам (*аңлыйм*), но урысча сүләргә йук (*сөйли белмим*). Куйы как үрәндем. Как раз вайна башланганда мине алдылар кырдан. Чыккан иде уборкага. Советта кеше йук. Берсе дә йебәрми баласын әрмийәгә. Имеш ирләр арасына йебәрмиләр. Миңа воли неволи советта: «Бар служи и все!». Мин киттем. Аwыллардан җийылды кызлар. Көүп булды. Классташларым үлеп бетте. Шул тике (*тикле*) кырылдылар. Үч (*өч*) йыл йөредем. Ач, жар. Старый Руста, Великий Луки (Ленинград тирәсе). Аннан актык путта инде.

*Сөйләүче: Маннапова Гәүһәр Исән кызы (1924).*
*Иске Кулаткы районы Атлаш авылы*

**Урта Терешка.** Шушы аwылда туган (*туганмын*), шунда үскән (*үстем*). Вата йуклык иде мин туган йылны. Самый калхуз кергән йыллар иде, беләсен. Җиде класс укыдым. Элке латинча да беләм. Дүрт ай укып калдым мин беренчегә кереп. Аннан суң урыс хәрефе чыкты. 46 нчы йылны укып бетердем дә. Миңа бетен налогны китереп куйдылар. 16 йәшемннән работник йасадылар мине. Биш йаз плугар эшләдем тырактырда. Кызларны куйдылар плугарга. Безнең тиңнәрне малайларны армийага алдылар. Кызлар биш йаз (*җәй*) эшләдек дизел'дә плугар.

Караңгыга тәке жарда эшләдем. Атларны бераз тындыралар (*хәл җыйдыралар*) иде. Печән чабарга кырга йөри идек. Анда аш пешерәләр, ашаталар иде. Көненә ике тынапмы (*тапкыр*) инде. Бөлеп-бөлеп ашны зур нидә. Руз'бас (ул печән шундый, үзеннән үсә – арыш, бодай үсә, төрле өлән үсә) чабарга кушалар иде. Бездә су буйында элке бакчалар иде. Пымадур үстерә, йөз чиләк су ташырга должен син. Барасың эшкә, обедка тике йөз чиләк су инештән алып куйарга кирәк шул пымадурларга. 5–6 кеше бакчага эшкә йөри иде. Эшләгәннәргә кийарлар итәләр иде. Кийар бирәләр иде йарты киламы, бер киламы. Кийар белән шул әпәйне

ашый идек. Истурийа сүләп бетерегә йук (*бетерерлек түгел*), йөрәк майым. Шундый хал'ләр.

*Сөйләүче: Бикбаева Гөлҗиһан Имат кызы (1930).*
*Иске Кулаткы районы Урта Терешка авылы*

Биги бабай килгән булган. Көпернең теге йагында. Бында инде Мансур бабай килеп утырган. Мансыравыл диләр инде. Турысын гына әт'кәндә алар белән кан'амаган инде. Йазгы көнне (*җәйен*) китә идек икедә эшкә. Фермага. Аннан йарый әниеңнең ашы әзер. Йатып тынасын (*хәл җыясың*), 11 дә тагын китә идең. Аннан кичен кат'асың уникедә дә, йә туры клупка әл дә.

Һәрбер симйага чөгендер бүлеп бирә иделәр. Шуны мантыклыйсын, җийасын. Айбагар (*көнбагыш*) мантыйкларга да йөредек. Кукуруз мантыйкладык элгәрегерәк.

Пичләр. Калай, эчендә кирпеч. Калай эченә тутыралар. Курып йасый. Аннан пичне шуның эченә сала. Теге пичебез 49 йыллык. Электән шулай эшләнгән. Калайны шундыйга буйыйбыз. Элек карага иде. Кара пичләр йасыйлар иде. Хәзер ал'уминовый төс. Галанка (голланд миче).

Кәнәфи (*тактадан гына торган диван*) бар иде. Түр дип әт'ә иделәр бездә. Артлы, йантыкларын төшерәләр әмән (*әйтерсең лә*) мудалап инде. Артында да алында да такта иде.

Дүрт мәчетне беләм. Төптә бер. Әле аның урынына йаңаны куйдылар. Вата монда бар иде. Манарасын кисеп тешерделәр дә игеннәр салдылар. Әл дә берсе шкул булып эшләде. Аwылның очондарак. Берсенен урынысын (*урынын*) гына беләм. Хәзер йаңы ике мәчет бар.

*Сөйләүче: Байбикова Рәсимә Абдулкадыйр кызы (1947).*
*Иске Кулаткы районы Урта Терешка авылы*

**Яңа Зимичә авылы.** Шушы аwылда үстем. Йарлы семйасыннан. Җидәү үстек. Әтиләрем булганнар алты бырат.

Бер кеше килеп утыргачтын да бу Зиминчә булыр дигән. «Зим эчәр» сүзеннән. Зимне булыр – туклыклы булыр. Зиминчә шуннан калган. Урыс аwылы иске Зиминчә дә бар каадыр. Анда урысłармы йәшәгән – белмим. Аwыл зур иде,балам. Ат'ергә хал' йук. Ызбаларыбыз көᵞп йабылды. Ике-бер (*бер-ике*) кешегенә торалар.

11 гә чике дә укыдылар. Ике йаташлы (*ике катлы*) шкулыбыз, но йабылды. Кулаткага, районыбызга, укытып йөретәләр. Монда дөртка хатле гына. Безнен аwылыбызда иң баштан ук җиде мәчет, җиде мәхәлла булган.

*Сөйләүче: Забирова Разия Усман кызы (1941).*
*Иске Кулаткы районы Яңа Зимичә авылы*

**Кирюшкино авылы легендасы: «Пуп белән бергә күмәргә».** Кирилл бабай килеп утырган. Бездән биш километр Адушино аwылыннан. Урыс шунда урнашкан, урыслар җийылыр дийеп. Безнен халык урнашкан су буйына. Шуннан калган. Элгәре шулай булган. Урыслар өстә, татарларга ирек йук. Күмәргә булса, пуп белән бергә күмергә. Татарлар кызык йасаганнар. Безнең бабайлар wакытында була бу хал'. Джийылалар инде. Урыслар әтә икән: «Поптан башка күмергә йук». Безнең үз йеребез. Татарлар күп булса да, поп белән генә күмергә. Попны китерә дә үзенчә эшли инде. Үлене җигачтын, попны китергәннәр дә бәреп төшергәннәр дә күмгәннәр бергә. Тереләй. Әле килгән дә: «Поп кайа?». «Сез әттегез бергә күмергә. Без попа не хоронит'. Күмдек», – дигәннәр болар. Попы белән күмгәннәр дә куйганнар. Митяй каберлекләре, диләр. Анары поплар килми башлаганнар. Бездә шундый кызыклы хал' булган.

*Сөйләүче: Хабушева Гөлҗиһан Абдулла кызы (1943).*
*Иске Кулаткы районы Кирюшкино авылы*

**Бай кызы турында легенда**. Бай йәшәгән. Анын бер генә кызы, алты малайы булган. Йахшы арбага утыртып урамда әләндерәләр. Матур йегет булган. Бай кызы белән йегет сүләшәләр инде. Читән аша гына сүләшү булган элке. Бай күреп калган: кыз бу йагында, йегет икенче йакта читәннең. Бай кызына ни әт'мәгән, узган да киткән. Әләнгән дә булачак кийәүне (йегетне) чыбык белән бик каты кинаган. Бу йегеткә бик обидны булган. Бу бабай үзе сүләгән. Бу кыз белән араны өзмәгән. Кыз белән озак сүләштереп торган. Үзенә иләштергән (*ияләндергән*), качып чыгарга ризалаштырган. Качып чыгулар булган элке. Кызга ат'кән: «Бүген килеп алам», дийеп.

Бер бик йәмсез генә йегет тә булган аwылда. Ул йарлы да, йәмсез дә. Кемгә дә үләнә алмый ул, шундый булган. Барган да ул йегеткә: «Брат, үләнәсенме?». «Миңа кем килсен», – дигән тегесе. «Шуның кызын аласынмы?». «Кит, ул миңа килмәс, мин аннан куркам», – дигән. «Аласынмы?».»Ну йарый, алам». Аның алашасы (*аты*) булган. Килгәннәр теге кызны алырга. Тәрәзә төбенә теге бара да икән. Чыга да арбага-чанага утыртып, томалап алып китә бай кызын. Иткәннәр (*илткәннәр*) дә теге йәмсез йегеткә биргәннәр. Кыз йаратмый аны, төннә бармый да анарга. Бу бай кызы, шундый пачутлы кеше. Әтинен сеңлесе булган аларның бер киленнәре. Ул килгән. Аны җибәргәннәр җиңгасын хал' белергә. Бабай ат'кән: «Бернәрсәгә дә бакмасын». «Алай болай булса, үзе теләмәсә, алам». И бу ат'кән: «Үзем теләп килдем», – дигән. Аннан соң әни әйтә: кибеп, корып койылып үлде кыз, ди. Йаныпкүйеп торган инде. Шундый хал'ләр булган элке.

Кабактан (*капкадан*) чыгарга йук иде, ди, әнәй ат'ә. Кабактан чыксаң, кабак баганасы төннә орлыйлар (*урлыйлар*). Тәртибе шул булган.

*Сөйләүче: Кысаева Нурия (1942),*
*Иске Кулаткы районы Кирюшкино авылы*

## Туй йоласы

Без качып чыктык. Әтиләр белмиләр. Муның белә инде этисеэнисе, үләнәчәген. Кызныкы белми, этиләре белмәде. Туй җиде көн барган.

Ничә пар ул'ыйлар. Например, биш пар. Теге йантыгында (әд. *ягында*) биш көн, теге йантыгында биш көн. Һәр көн туй. Иң беренче йегет йантыгында йөреп бетерәләр. Аннан теге йантыгында. Ничә пар уный – шуның кадәр. Кыз йагыннан биш пар, малай йагыннан биш пар. Кемнең хал'е ничек. Бишәрдән дә кәм түгел.

Урамга конфетлар сибәләр иде. Болай вата кода-кодагыйлар бирнәләр бирешәләр, материал күлмәклек. Авыл буйлап йырлап йөриләр. Туйга барасын. Атларны бизи идек: шәлләр, тәртәләргә шарф, йеслек (*сөлге*) дугага.

*Сөйләүче: Ганиева Мөнирә Якуп кызы (1937).*
*Иске Кулаткы районы Иске Мостяк авылы*

Туйлар ике көн, өч көн бара иде. Ул вакытта ник'ах укыталар да, кичтән алып көн ката (*көн буе*), көн озында йөри. Икенче көнне дә сийлананалар: эчәләр, ашийлар. Анда шулай ике кенне. Подаркалар сабыннар салалар иде. Кодачалар йөрү бар иде. Үдән (*өйдән*) үгә. Ул бүләкләрне кызнын әнисе әзерли. Йурган, йастыклар белән. Коргычлар кирәк бетен ызбаларга, тәрдәләргә. Кроват'не кийендерергә кирәк инде. Простын', покрываллар. Кызны бирәләр шуның белән. Аны сондыкка (*сандыкка*) салып биргәннәр. Аның эчендә кыз киемнәре. Ә бирнә – ул ата-анага, кан'ага (*каенанага*), кан'га (*каенатага*) бирәләр. Кемнәре бар – шуларга. Шул бирнә була. Кан'ага күлмәкне бирергә кирәк йахшысын. Шәл. Айакка калушлар. Килендәшләренә таварлар, тастымалмы. Ул бирнә санала.

Йәш вакытта уйын өсләре була иде. Тауда. Хөзбән тавы. Йаз башында анда төрле уйыннар була иде. Бер-ике сүләштек тә алып кат'ты. Салма белән каршы алды әнисе. Аннан инде мулла бабайны чакыралар ник'ахка. Кызны килештерергә кирәк. Әтиәнисеннән ризалык алырга кирәк. Әти башта риза булмады.

*Сөйләүчеләр: Хабушева Гөлҗиһан Абдулла кызы (1943),*
*Бикмәтова Айсылу Хөсәен кызы(1946).*
*Иске Кулаткы районы Кирюшкино авылы*

**Урлау.** Бабай мин орлап алып кат'ты. Киченге йакта. Пугай таwы бар иде. Алаша белән. Барып әттеләр әтигә. Кызыгыз бездә. Шундый адәт (*гадәт*) иде. Орлап алучылар булган. Шулай үмер иткәннәр.

**Әбиләр туйы**. Минем әнийем китерә бер унны-унбишне монда ни. Каршы алалар. Бийеп, йырлап йә саласка (*чана*) белән баралар. Утырталар анда кемнедер, кызык йасап. Үдә ике йакның кодачасы. Утыралар, ашыйлар, бииләр кунаклар. Икенче кенне кыз үенә бара йегет үеннән тагын бер унбиш әби. Беренче кенне йазылышалар да йәшләр туйы була. Икенче кенне парлылар туйы була. Үченче кенне кызның үендә була туй. Парлылар туйында туганнар кызның йантыгыннан (*ягыннан*) ун пармы, сигез пармы. Үченче кенне кыз үендә була. Йегерме берне китергән кыз йантыгы (*21 кеше китергән кыз ягыннан*) кодача, кодагый.

Бер гармунчыбыз масхарчарак (*мәзәк итеп, шаяртып*): Ай-хай кодагый, тавык басып үтерден, Алладан да ойалмадын. Йегерме бер кодача китерден дип йырлаган, көп (*күп*) кодача китергәнгә. Төрттереп эткән инде.

**Бирнә.** Тчаршаулык унбер метр зур гына. Аны килгәчтән (*килгәч*) караwатка тчаршау йулисен (*тегәсең*). Таwар, эскәтер, клейунка, йурган йастык – шундый нәстәләр. Аны зур гына пристин'ага чорнап китерә иделәр. Сондык та бар. Анда синең йөслегең, эскәтерең.

*Сөйләүче: Забирова Разия Усман кызы (1941).*
*Иске Кулаткы районы Яңа Зимичә авылы*

**Алма коймак**. Николайский район, Тат Сайманнан булыпмын. Монда кийәүгә чыктым. Тат Сайманда йәшләр туйлар була иде. Алма коймак – ул йәшләр кушыла. Зур туй була, кызыл туй була. Аннан инде йәшләр туйы иде. Шунда инде без оланчакта (*балачакта*) частушкалар, 1973 йылларда кыз балалар йырлап йөриләр иде. Зурлардан без дә өрәнеп калдык. Алма коймак әтелә иде ул. Монда алай төгел. Кийәүгә чыккач, кан'ам дә шундый шутник, частушкаларны кара-каршы әт'еп, халыкны кач'ан ис китерә иде. Кан'алар турында такмаклар:

Кан'анамны-анайымны түрдә генә тытармын.
Алай-болай сүләнсә, ике кабып бер йытармын.

Кан'ама-анайыма газит укытыр идем,
Кечеркәннәр арасына итеп утыртыр идем.

*Сөйләүче: Хөснетдинова Камилә Гөмәр кызы (1957).*
*Иске Кулаткы районы Атлаш авылы*

## Йола, бәйрәмнәр

**Кәрә.** 23–25 декабр'дән тотоналар кәрәне. Кәрәләр бар. Хәзер инде балалар гына йөри. Элек барыбыз да. Иремнен дусты гармун белән йөри. Керәбез кемдә ут бар. Кызык кийенә идек. Терлечәли кийенәсен дә инде. Капрон калготкины кийәсен дә, корыммы төртәсен. Кызылын да сөртәсен. Борынгыдан килгән

кәрәләр. Безнең йакта бетмәде ул. Кәрәләр керә, йырлыйлар. «... сондыгында конфетың бар. Миңа бир», дип йырлап чыга. Чегелдәк (*бавырсак*) кебек нәрсә пешереп куйабыз. Йукамы. Аннары: «Әби, сау бул, Яңы йыл бәхет китерсен! Озон үмерле бул!», дип әтеп чыгалар. Кәрәләр булып олылар чыкты безнең дәвердә. Дайаркадан килеп, таң аткынчы тен йөри идек шулай.

*Сөйләүчеләр: Фәрит Хәлил улы (1959)*
*һәм Нажҗия Җиһанша кызы (1959) Абдуллиннар,*
*Хәерова Суфия Ибраһим кызы (1954).*
*Иске Кулаткы районы Яңа Мостяк авылы*

**Раштуа көнендә.** Чигелдәк, кызыл йомырка Раштуа көнне пешерәләр. Камырны вата шулай ывак-вак кисәбез и май эчендә пешерәсең. Аны Йаңы йыл алдыннан Раштуа була, шул кеннәрне йериләр, кийенешеп. И шуларга бирсән, терлегең күп була, диләр. Аннан суң кызыл йомырка кенне бирсән дә, пасха кенне. үеңдә шуны пешереп бирәсен, пешереп куйасын.

Айак сыныйбыз – буйыйбыз йомыркаларны, кызыл йомырка кенне кем керә синең үеңә, начар кеше керсә, терлегең кат'мый, чебешләрең булмый, чыкмый; йахшы кеше керсә, барысы да йахшы бара.

*Сөйләүче: Юсупова Сания Исмәгыйль кызы (1953).*
*Иске Кулаткы районы Вязовый Гай авылы*

**Кызыл йомырка** йәштән үк бар иде. Суган кабыгына кызарталар иде. Аны ашамасаң, борча баса, диләр иде. Аны җийалар иде. Бәхетле буласың. Аны оланнарга (*балаларга*) бүләләр кен дә берсенә, икенчесенә. Әтиләргә, әниләргә барына да бүләләр. Кемгә йомырка күбрәк сала инде – ул бәхетле була имеш. Кемнең айагы җиңел аны сыныйлар иде. Әле дә. Сынамыш кенне. Тәмле-тәмле ризыклар. Беренче кеше кем керә инде, айагы җиңел булырмы, йукмы инде. Иногда кемдер белгәнеңне кертәсең. Или хозайка үзе чыгып керә. Йат кешенең айагы ниндидер булыр. Апрел'дә.

**Сабан туй** була иде. Алашлар (*атлар*) белән түәлеп семйа-семйа, без арба артына асылып бара идек, оланнар. Сабантуй урман йанында бик көчле була иде.

**Башкич уздыру.** Сыйыр бозаулый икән, башкич уздыралар, мәүлет уздыралар. Аwыз ачтыралар иде.

*Сөйләүче: Бикбаева Илһамия Хөсәен кызы (1938).*
*Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылы*

**Бәби майы, акыйка корбаны**. Коран уку була, дыва укыйлар. Бәбәй майы булса, бәбәйгә акыйка корбаны чалдыралар. Малайга икене акикә корбаны суйырга, ә кызга берне. Анда куй суйалар. Карту (*бәрәңге*), ит белән салма ботка. Дыва кылалар да. Чәй эстәленә майны беренче куйалар.

Бал да була – баланың теле татлы булсын, йомшак булсын. Шуңа күрә бәбәй майына дигәч, обизател'но майны куйалар. Сорыйбыз онытсалар. Кайа майыгыз дийеп. Йарты метрлык, бер метрлык таwар китерәләр иде бәбәйгә.

Балага күз тисә, өшкергәннәр әбиләр. Күмер салганнар, су салганнар. Өчне эстәлнең уголын шулай себергәннәр. Кем дә чәй эчеп китсә инде, чашканы чәйкәгәннәр. Ишек бауларын себергәннәр. Баланын битләрен, эченә, кулларын йывып чыгарып бәргәннәр. Күз тигәне беткән. Башларына сәдәфтән йасап куйганнар. Кызыл әйбер. Кызылга иң беренче күзең төшә.

*Сөйләүче: Тимушева Роза Хабир кызы (1932),*
*Абдушева Зәйтүнә Әделша кызы (1955).*
*Иске Кулаткы районы Иске Кулаткы поселогы*

**Келәү пешерү.** Йаңгыр йаумаса келәү пешерә идек. Төшеп йылга буйларына. Шунда Алладан сорап, укып йөри иделәр. Җийилабыз картлар, йәшләр. Аннан инде берсәк (*бераз*) ашыйбыз, берсәк су сибешә идек. Кийәүгә чыккачтын (*чыккач*), келәү пешерә идек йылга буйларына барып. Оланнарны җийыштырып (*җийып*). Келәү дип пешереп, анын дуwаларын (*догаларын*) укып, йырлап.

*Йаңгыр йау, йау, алла бир амин, алла бир амин,*
*Бир Алла, бир Алла.*
*Биргәнеңне кир* (кире) *алма, кир алма.*
*Йаңгыр йау, йау, йау, иләктән, чиләктән.*
*Пәрәмәчә коймактан, коймактан.*

Шоларны әт'еп-әт'еп йырлап йөри идек без оланчакта. Шуннан инде оланнарны шулай өйрәттек су буйына итеп. Берсәк әл дә исемдә калган кас'ы-кас'ы.

*Сөйләүче: Аббасова Саидә Шакир кызы (1928).*
*Иске Кулаткы районы Атлаш авылы*

**Су (ташу) багу** булган. Йаз башында. Көпергә $^{д}$җийыла идек. Йазгы ташу инде. Көчле су килә кырлардан. Бозлар урыныннан кузгала каандыр. Агып китә. Шуны багып торабыз. Кичен.Саллар агызалар иде. Саламнарны кабызып. Зур-зур бозлар кузгалды дийәләр иделәр. Шунын өстенә салам бәрә идек тә, аны кабызалар да, шул су буйлап китә. Йана бара. Зәләмәләребезне (*иске әйберне*) йолкып-йолкып бәрәбез. Мамыгын алабыз да бәрәбез. Шәл чәчәкләре бәрә идек. Имеш аwыруларын агып китә шул сулар белән. Исерек төшеп йывына да иде.

*Сөйләүчеләр: Хабушева Гөлҗиһан Абдулла кызы (1943),*
*Бикмәтова Айсылу Хөсәен кызы(1946).*
*Иске Кулаткы районы Кирюшкино авылы*

**Көймә йебәрү**. Уйын өсте. Йәшләр дә, балалар да чыга иде. Кимә йебәрү боз киткәндә. Салам вата кабызып йебәрә идек. Боз wатылып, шунын өстенә салам йандыралар. Шул кимә йебәрү була.

*Сөйләүчеләр: Салюкова Әлфия Ибраһим кызы (1927).*
*Хамзин Рафаэль Җиһанша улы (1966).*
*Иске Кулаткы районы Муса (Мосеевка) авылы*

**Безелек** – йаз башын (*язын*) кар киткәч, бозлар ташу вакытында, җир ачылгач та беренче уйыннар ул. Ул элгәредән килгән. Егет кызлар бер-берсен чакырышалар иде. Көрәшү була иде. Без оланнар кен ката (*көн буе*) багып тора идек. Ай йактысы була иде. Утрау кебек җирләр иде. Анда чәчелми дә. Малайлар учак йагып карту көмеп ашап-эчәләр иде. Боз киткәндә эстендә йакмыйлар. Боз киткәндә оланнарны саклыйлар иде. Картлар кызлар теләк тели иде. Алар суга бәрәләр иде чоргап. Акканын бага – каа да терәлмәсен. Без йәшләр көймәләр йасап бәрә (*җибәрә*) идек. Кимә вата кагыздан йасый идек, шуны йебәрә

идек. Йазулар йебәреп, ырым кебек. Кас'ының саулыгы йук – саулык сорый.

*Сөйләүче: Бикбаева Илһамия Хөсәен кызы (1938).*
*Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылы*

**Йорт анасы.** Үзгә (*башка*) йортка күчкәндә күчерәләр. Саласкага (*кечкенә чанага*) куйдык йастык, ди. «Йорт анасы, ад'а безнен белән, үзгә үгә күчәбез», – дип. Ап-аwыр саласка тартып бардык, йул буйы сүләшмичә бардык, ди. Ни дә әт'мәскә кирәк. Икенчеләр сүли: «Җийәү апардык. Җилкәләребезгә асылды. Ару тиргә төштек», – ди.

Ыwызга (*угыз*) чакырдык к'анамны. Ыwыз пешерәләр, сийыр бозаулагач, дыва кылдыралар. «Әнкай, син үзең уйаттын, мин сийыр бозаулый» дип ди. «Ничек уйатыйм? Сыйырың бозаулаганны белмәдем дә», ди. «Тәрәзә шакыдың да әт'тен. Сыйырың бозаулый, тор» дип, ди. «Сәат (*сәгать*) үчтә». «Үчтә синең араннарыңны багып йерим мени?!» – дип ачуланды к'анам. Ул йорт анасы икән. Йорт анасы безнең алашаныкын өᵞрә иде, кәбәм. Икесен бергә йалгый да вата. Йаратса – өᵞрә.

Тынычлык булмаса, ват әт'әләр: йорт анасына азык куй. Йорт анасына вата күмәч пешереп куйасын. Аны аран (*сарай*) башына куйасың иң өскә. Кош тимәсен, мачы тимәсен. Камырлар басасын җиде штук. Тыссыз, түгәрәкләп җидене йасыйсын. Иләкнең киресеннән ынны илисен. Майга гына басырга аны. Пичкә духовкага тыгып аласын. Пешкән кебек әмән. Бик каты пешми, тыгып кына аласын. Менгереп куйасын: «Мәгез, ашагыз, сезгә аш китердем», дип әт'әсез. Нәәстәви дывасын укыйсын. Йә бусага тебенә куйасын. Веник куйды, веник өстенә кагыз куйды да, шунда күмәчне йасыйлар да куйып чыгалар. Агачка кыстырып куасын. Ашый.

Ү (*өй*) салганда дыва куйып калдырганнар. Һәр матчага кыстырдылар айател көрсине. Шайтан-җен кермәсен дийеп. Акча тегел. Айател көрсине генә йабыштыралар иде. Йаңы ызбага күчкәндә иң беренче мачыны кундыралар. Аннан соң укыйсын әррахман сурасын. Йорт анасы үзе күчә ул синең белән.

*Сөйләүчеләр: Абитова Нурҗиһан Хәлил кызы (1946),*
*Забирова Разия Усман кызы (1941).*
*Иске Кулаткы районы Яңа Зимичә авылы*

Йорт ийәсен күченгәндә оланнарны утырттык та, кашма (*сарык йоныннан киез, палас кебек*) бар, юрганмы инде шунда, тәпешләреңне кийеп, оланнарны утыртып алып киләләр инде. Йаңы йортка. Утырган булса йорт ийәсе, алаша тирли, тартып килеп. Чакырмыйлар. Ул үзеннән үзе китә булган (*китә торган булган*). Йорт анасына мөрйә кругына күмәчләр куйалар иде. Тызсыз. Вата (*әнә*) путалакка куйабыз. Ызба башына менергә. Тезеп куйасын да. Алар ашыйлар.

Бер сыр' (*сыер*) сатып алдык, йорт ийәсе йаратмый ул сыр'ны. Зәрәдән торабыз. Ару иде, тир эчендә иде сыр'ыбыз. Ул сырыбызны колхозга сдават' иттек. Кешене дә йартатмый ул әл дә, койты (*начар*) кеше булса. Өшкерәләр иде әбиләр, бәхилләтәләр иде. Мич башына куйалар иде ашарга.

*Сөйләүчеләр: Бикбаева Илһамия Хөсәен кызы (1938).*
*Иске Кулаткы район, Иске Зеленай авылы*

## Кич утыру, вечер, уеннар

**Тәре йарыш** – кара-каршы бииләр. Монда йегет, монда кыз. Бу йакта да шолай. Берсе берсен алыша да инде. Аннан китереп нитәләр. Шул тәре йарыш, диләр.

**Орчык** – алар инде өчәрләп. Өч пар. Алар татар күенә (*көенә*). Бу пар бусы белән әләнә. Тагын бергәләп, аннан кызлар инде. Әләнеп-әләнеп йөргәнгә орчык дип атала. Йегетләр әләнә (*әйләнә*) дә үзенең пары белән бер кругта. Аннан тагы кызлар басып тора, йегетләр әләнә икенче кыз белән. Өенчесе. Аннан кызлар уртага баса. Үзенең пары белән беренче әләнә. Аннан хәрберсе белән әләнеп тешә.

**Алтыдан** – бер-ике йегет, дүрт кыз кара-каршы бииләр. Аннан үзләренен парлары белән, аннан тагын быйакта былар белән. Үᵊч пар була, алты кеше инде. Алтыдан була инде. Алты типтерү дип әтәләр иде. Тоже такмак әтәләр, гармунчы, бийеw күләренә дә.

*Сөйләүчеләр: Хөснетдинова Камилә Гомәр кызы (1957).*
*Иске Кулаткы районы Атлаш авылы*

Иң оланчакта (*балачакта*) ун'ий идек: ашыктан, гөрләштән, шакшакыйдан, такта басыштан.

**Ашыктан.** Биш ашык була, булмаса биш таш ала идек. Аны вата шулай куйа идек тә, сикертә идек тә, берсен кулыбызга тота идек. Икәү кара-каршы утырасың да, кас'ың йахшы уздыра, шул йахшы буласың инде. Читкә китсә, үзгә (*башка*) кеше ун'ий иде.

**Такта басыштан** ун'адык, качып-качып. Кл'уктан ун'ий идек. Сикерә идек. Мунчала дилбегәсе куйып. Мунчала кәркешешә идек. Сикереп йөри идек.

**Кл'ук** уйыны. Вата шундый түгәрәк ни куйалар. Бер каравылчы була. Без инде калкалар белән монда бер бишәү. Әле бәрәсең дә шул кл'укка, тийерсә (*тидерсә*) – тиз генә чабышып, тегесе тиз генә алып китсә, шул караулчы, монда китереп куйса, мин караулга калам. Күчә. Вата мәрә (*мера*) сыза идек.

**Мәчтән** ун'ый идек. Ике йакка – бер йакка пастухлар, бер йакка мәрәли мәчләре. Икенче йакта мәчне каршы ала торганнар.

Аннан ары киттек инде берсәк (*бераз*) зурайып. Киттек ышкулга (*мәктәпкә*). Шкулда туже ***трай л'а л'а*** уйный идек. Трай л'а л'а – круг басабыз да. Кара каршы бер круг нитә, пар-пар инде. Шулай әләнә идек. Аннан инде китте клупка. ***Алтыдан*** баса идек. Мин танцыга гел эләкмәдем. Вичер ун'ый идек, анда йырлап-йырлап. Бер башта зурлар, икенче башта оланнар иде. Ачу килсә, терле частушкалар әтеп, кимнәп (*хурлап*) йырлый идек, мактап төгел. Кас'ын мактап та йырлый идек.

**Гөрләштән** уйыны – әле бер бишәү җийыласың. Берсе бер урынга каплана да, без качабыз. Качып бетәбез дә, аннан суң эзләргә тытына каплаган кеше. Без бишәү терлебез терле төшкә. Теге эзләп йери. Әгәр дә инде йантыктан, без инде качкан кешеләр, тегенең мәрәсенә барып тук-тук тукысак, котылабыз. Хет унау ун'а анда.

**Шакшаки** уйыны. Дүрт уголга баса идек ызбаларга. Дүрт уголга дөᵞрт кеше. Тегеләргә икесенә вата бу уголдан бу уголга күчеп йөрергә кирәк. Шакшакый әткән кеше монын уголына керәлсә, бусы посок кала. Килә дә шакшакый, вон тудый. «Вон тудый» дигәчтән, болар икәү алышыналар. Әгәр шакшакыйның моны тойып урынын алса, бу баскан кеше шакшакый була.

**Такта басыш**. Әле шундый такта. Монда кавын бүән куйабыз да, тактаны вата куйалар. Кавын пуйан. Тактаның бер башында ун чыбык була. Әле йарый анда бер пастух була инде. Караулчы. Монда инде бер биш-алтау. Күзен каплый да каравылчы, бу хутта без качабыз. Теге эзли-эзли. Бу эзләгәндә икенче кеше килә. Тактаны баса да ычыра чыбыкларны. Әле килеп пастух җийа-җийа тагын. Тагын шулай куйа. Тагын китә эзләргә. Качкан кешеләр чыкмий бул'ше. Эзли-эзли. Басалар да тагы такта ыча китә чыбыклар.

*Сөйләүче: Хөснетдинова Тәнзилә Солтан кызы (1931).*
*Иске Кулаткы районы Атлаш авылы*

**Кич утыру. Кусок ыштан.** Элгәре кич утыру. Кас'ы бәли, кас'ы чигә. Шунда йырлый. Йегетләре керә йаннарына. Кусок ыштан ун'ый иделәр. Бер кеше бегелә. Аның аркасына кулларын тезәләр. Кемнең кулы өстә. Рәсимәнеке. Анда минеке булмый әмән этийек. Белмәдең дийеп аркасына тагын сугалар. Аннан белсә инде, шул кеше йата иде өстәлгә, аны калдыралар иде. Кич утырганда картыраклар пешерә иде, ә йәшләр чигә иде. Кем запун чигә, кем йаулык вышиват' итә тамбу белән. Хозайка үдә инде. Бер үгә җийылалар. Ул үзе ашата иде дә.

*Сөйләүче: Байбикова Рәсимә Абдулкадыйр кызы (1947).*
*Иске Кулаткы районы Урта Терешка авылы*

**Вичердә** кызлар да малайлар да. Хозаин кертсә, керә. Хозаин үдә карап утыра. Да. Вичер булмаса, кич утыру гына булса, чигү чиккәннәр. Вичер булса, кругтан ун'ый идек.

**Тәре кисәбез** уйыны. Алты кеше өчәр-өчәр кара-каршы бии идек тә, аннан под ручка әләнә идек. Өч малай, өч кыз.

**Кул сугыштан**. – Шуны йаратасыңмы дип суга идек. Йук йаратмыйм. Тагын суга. Куллар кызаргынча суга иделәр.

**Угол алыштан**. –Ләйләй-падиша, иди туды, кадича этә идек. Теге барып баса. Икенчесе моның урынысын ала, теге кала уртада. Тагын ***йөзек салыштан, чиртадан, машыктан.***

**Дурачтан.** Йаз башын (*язын*) бер атнага урамга чыга идек. Ачыла иде тау башы. Анда ун'ый идек дурачтан. Баса идек икәүикәү дә, ике йакка чабып китә. Чапка иткән кеше тытырга тийеш.

Йүгерәбез, өчәү киләбез. Кас'ыбыз әле дурач, белмидер, синмедер, бумыдыр. Әтә «Сания дурач». Дерес әт'сә, Сания була, дөрес әт'мәсә инде, үзгәсе. Әткән кеше киредән дурач була.

**Чижек уйыны**. Йасый идек вата шулай ике сызык. Ике метрмы булсын арасы. Палка белән чижик йасий идек. Икенчесе аның ызын була. Ул чижикны бәрәсен. Зур палка белән. Башына суга. Чижик очып китә дә кемнең каршына барып төшә. Сызыкнын бу йантыгына (*ягына*) төшсә, дерес була. Тимәсә үзгәсе (*башкасы*) баса.

**Кич утырганда** кем чикте, кем челтәр бәләде. Кем насук алып бара иде, балам. Күбрәк челтәр бәләргә өрәндек, чигү чигәгә. Элгәре йастык тышлар, пристин'алар, йөслекләр чигә идек.

**Сал йебәрә** иделәр. Салам йагып шул хуттан. Ташулар элгәре йахшы ага иде. Ташулар багарага чыга идек. Шунда әбиләр әтә иде: «Нәстә дә булса зәләмәңне этеп бәр суга. Йаулык-ниме алып бар. Битеңне себер (*сөрт*) дә суга бәр. Аwыруымны алып кит», әткәннәр агым суга. Шундый ырымнар бар иде.

*Сөйләүче: Забирова Разия Усман кызы (1941).*
*Иске Кулаткы районы Яңа Зимичә авылы*

## II. КАРСУН СӨЙЛӘШЕ

Бер атнадан фәнни сәфәребезне Карсун районында дәвам иттердек. Ульяновск өлкәсенең Карсун районы Нугай (Нагаево), Сакускай (Уразовка), Гуринка (Татарские Горенки), Аксу (Голышевка) авылларында таралган татарларны көнбатыш (мишәр) диалектының карсун сөйләше вәкилләре дип саныйбыз.

Әйтеп үтик, беренче тапкыр карсун сөйләше 1969 елда диалектолог Д.Б.Рамазанова тарафыннан өйрәнелә. Галимә Ульяновск өлкәсе Инза һәм Кочкур районнарында экспедициядә була, андагы татар авыллары сөйләшен карсун сөйләше дип билгели. Элек алар Корсунь (Карсун) өязенә караган булганнар, сөйләш исеме дә шуннан алына.

2017 елда Карсун районының әйтеп узылган авылларыннан җыелган материалларыбызга фонетик, грамматик һәм лексик яктан тикшерү уздырылды. Түбәндә кыскача анализ һәм халыкның

рухи-матди мәдәниятен яктырткан сөйләү үрнәкләре тәкъдим ителә.

### Фонетик үзенчәлекләр

**Сузык авазлар**. Татар теленең көнбатыш (мишәр) диалектына хас үзенчәлекләр – [*а*] авазының ачык, иренләшмәгән варианты, [ә] һәм [*у*] авазларының югарырак күтәрелешле һәм алгырак позициядә ясалышлы булулары — карсун сөйләшендә дә күзәтелә.

Сузыкларга кагылган башка үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә, төрле позицион күренешләргә кайтып кала.

[*ы*]~[*а*]: *йаңы* – йаңа (яңа), [э *(е)*]~[*ә*]: *тенне* – төннә (төнлә), *киткенчәк* – киткәнче; [*ә*]~[*и*]: *әпәй* – ипи, *мәләш* – миләш; [*и*]~[*ә*]: *пилмин* – пилмән; [*и*]~[*ы*]: *ачл'ик* – ачлык, [*э(е)*]~[*ү*]**:** *кеңел* – күңел, *беген* – бүген; [*о*]~[*у*]: *орлау* – урлау, *корка* – күркә*;* [*ө*]~[*ү*]***:*** *көмәч* – күмәч, *төбә* – түбә, *көп* – күп; [*ы*]~[*у*]: *йыwаш* – йуwаш (юаш); *шындый* – шундый, *Сыры* – Сура (елга ис.) һ.б.

Сөйләшкә системалы рәвештә иренсезләшү хас: *келке* – әд. көлке, *сет* – сөт, *тырды* – торды, *кылак* – колак; *керәш* – көрәш, *тешә* – төшә һ.б.

Арткы рәт авазларына алгы рәт сузыклары тәңгәл килү, һәм киресенчә: *кечеркән* – әд. кычыткан, *бәлчек* – балчык, *йогора* – йөгерә, *чиган* – чегән *чиклаwык – чикләвек, фәйда* – файда һ.б.

Дифтонглар, ***-өй*** дифтонгы, нигездә, монофтонглаша: *ү* – әд. өй, *сүләтә* – сөйләтә, *үгә* – өйгә һ.б.

Сузыклар алдында ***-үw*/*-еw*/*-ев~өй:*** *теwә*/*тевә* – төйә (төя), *үwеп*/*эвеп* – өйеп (өеп), *кеwе*/*кеве* – *көйе*(көе), ***ө~өй:*** *өрәнү* – өйрәнү.

Тел очы [*л*], [*н*], [*р*], [*д*], [*т*], [*с*], [*ч*] тартыклары алдындагы ***-ай*/*-әй, -ой, -уй*** дифтонглары монофтонглаша, ә күрсәтелгән тартыклар нечкә вариантта әйтелә: *кат'а* – кайта, *кан'ар* – кайнар, *кан'ана* – кайнана (каенана), *кас'ы* – кайсы, *ат'а* – әйтә, *кач'ы* – кайчы (*с*, *ч* тартыклары йомшармаска да мөмкин).

Алгы рәт сузыкларыннан торган сүзләрдәге ***-әй*** дифтонгында ***й*** төшә: *бәли* – әд. бәйли, *әлнә* – әйләнә, *бәрәм* – бәйрәм.

Сүз азагындагы ***-ый*** дифтонгына [*ы*], [*и*] монофтонглары яисә [*ы*й], [*и*й] дифтонгоидлары тәңгәл килә: *тугий*/*туги* – тукый, *тарый, барми*/*бармий* – бармый, *тарий*/*тар'и* – тарый һ.б.

**Тартык авазлар.** [*п*]~[*ф*] *тәңгәллеге*: *калпак* – әд. калфак, *тупрак* – туфрак, [*н*]~[*ң*]: 2 нче зат хикәя фигыль һәм иялек килеш кушымчаларында күзәтелә: *аласын* – аласың, *барырсын* – барырсың, *синең/синен* – синең; сирәк [*с*]~[*ч*]: *берсәк* – берчәк (бераз), *пис* – мич, *насар* – начар, [*х*]~[*к*]: *әхийәт* – әкият, *хардашлар* – кардәшләр, *бд~пт: ибдәшләр* – иптәшләр, [*й*]~[*җ*]: *йәйәү* – җәяү һ.б.

Кайбер сүзләрдә ике сузык уртасындагы [*к*] авазы яңгыраулаша: *тугу* – туку, *тыгырык* – тыкрык, *чугыну* – чукыну, *йага* – йака (яка) һ.б.

Фарингаль [*һ*] авазы әйтелми: *адәт* – әд. гадәт, *айыплама* – гаепләмә һ.б.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр. [*н*]~[*д*]: *алны* – әд. алды, *алында* – алда, *алынгы* – алдагы; [*н*]~[*м*]: *агын* – агым; [*м*]~[*н*]: *үләм* – үлән; [*н*]~[*л*]: *шартнатып* – шартлатып; [*г*]~[*н*]: *чыргый* – чырный; [*т*]~[*к*]: *утлау* – уклау; [*к*]~[*т*]: *йикмеш* – җитмеш, *кели* – тели; [*к*]~[*г*]: *кәрәбә* – гәрәбә; [*г*]~[*к*]: *газыдык* – казыдык; [*й*]~[*к*]: *сондый* – сандык һ.б.

Аваз төшү: *сак* – әд. усак, *саклык* – усаклык һ.б.

Аваз өстәлү. Сүз башында сузыклар алдында [*й*] өстәлә: *йәрләү* – әд. эрләү, *йындыр* – ындыр; [*д*]: *кузгалдак* – кузгалак; *ди* фигыленә *р* өстәлү: *барырсын дир* (ди).

Сирәк кенә мондый үзенчәлекләр күзәтелә. [*ч*] авазы мишәр диалектындагыча кушык аваз, тик аның әйтелешендәге шартлау элементы шактый көчсез, язуда аны [*ᵗч*] рәвешле күрсәтеп була: *бакᵗча* – бакча, *ᵗчигелдәк* – чигелдәк – әд. төш; *кеᵗче* – кече һ.б.

[*ч*] авазының яңгырау пары [*җ*] авазы да (сөйләштә ул шактый еш кулланыла) берникадәр шартлау элементы белән әйтелә: *ᵈҗебәк* – әд. йефәк (ефәк), *ᵈҗийа* – жыйа (җыя), *ᵈҗирлый*, *ᵍҗибәреп* һ.б.

Палаталь [*л'*], [*р'*], [*н'*], [*д'*] тартык авазларын куллану очраклары бар: *пыр'-пыр'* – пырылдап йөргән кеше кушаматы, *ачл'ик* – ачлык, *запун'не* – запонны (алъяпкычны), *Л'окман, Мобар'ак, ахыр'е* – ахыры һ.б.

Сүз азагындагы [*ч*], [*ш*], [*с*] авазлары сузыкларга, янгырау һәм [*й*] тартыкларына башланган сүзләр алдында яңгыраулаша:

*пиҗ йага* – әд. мич яга, *биҗ йылдан* – биш елдан, *эҗ йез* – өч йөз, *эҗ-дүрт* – өч-дүрт, *эҗ бала* – өч бала, *унбиж йәш* – унбиш яшь һ.б.

## Морфологик үзенчәлекләр

Карсун сөйләшендә дә 3 нче зат берлек сандагы *хикәя фигыльләргә* һәм шулай ук хәбәр функциясендәге башка сүзләргә, мишәр диалектындагы кебек үк, ***-дыр/-дер*** кушымчасы ялганып килә: *Ул йер бик зур буладыр* (була). *Уллары каладыр* (кала).

Әдәби *ди, дип әйтте, дип әйтер* карсун сөйләшендә ***дир/дийер*** рәвешендә: *Ул йукка йыламаган икән дир. Хәят апаның сондыгында бар дийер.*

Нәтиҗәле үткән заман әдәби *-ган/-гән* һәм диалекталь *-ып/-еп* кушымчалары белән ясала: *Урамга чыккан булыпбыз* (булганбыз). *Нәнәй* (әни) *мәмәй дип әтә, мәмәй дийепмен. Мин йаз башын* (язын), *Соры* (Сура елгасы) *киткән чакта туыпмын* (туганмын).

*-а/-ә, -ый/-и + булган* (әд. *-а/-ә* торган булган): *Йер йеләгеп киптерә булганнар* (киптерә торган булганнар). *Кырда уйный булганнар* (уйный торган булганнар).

Теләк фигыльләр *-ыйым/-ийем* (берлектә), *-ыйык/-ийек* (күплектә) кушымчалары белән ясала: *Ашыйык* (ашыйк), *эчийек* (эчик), *уйнап көлик. Ад'агыз, дуслар, керийек* (керик). *Бер-беребезне какмыйык* (какмыйк), *бер беребезне каккан чакта бер-беребезне йаклыйык* (яклыйк).

Эчке теләк, барлык мишәр сөйләшләрендәгечә, ***-кы/-ке + кел-*** (әд. *-асы/-әсе, -ыйсы/-исе + кил-)* төзелмәсе белән белдерелә: *Йокы кели* (йоклыйсы килә) – *иртән торырга кирәк. Минем үземнең өрәнге келәде (өйрәнәсем килде) итек басарга. Минем һич киткем келәми* (китәсем килмәде) *аwылдан.*

Хәл фигыльләр. *-гач/-гәч* кушымчасы карсун сөйләшендә ***-гачтан/-гәчтән*** формасында кулланыла: *Бу тауда тракторлар белән җир эшкәртү wакытлары җиткәчтән* (җиткәч), *тауның итәген сукалагачтан* (сукалагач) *соң, кеше сүwәкләре чыга. Су туңгачтан* (туңгач), *печәнне йылга аша ташыйлар.*

Әдәби телдәге *-ганчы*/*-гәнче* кушымчасы сөйләштә ***-гынчык***/***-генчек, -гинча***/***-гинчә, -гынчак***/***-генчәк*** вариантларында күзәтелә: *Ипине армийәдән кайткынчык* (кайтканчы) *саклап тотасын.Кичне, койаш иңгенчә* (иңгәнче) *инде, кычкыралар иде, керегез үгә дип.*

Бәйлек. Көнбатыш (мишәр) диалектына хас *сынны* (шикелле, кебек) бәйлеге кулланыла: *Бу азыкны колак сынны* (кош теле шикелле) *камырдан йасыйлар бит. Тактада йата идек, әлеге сынны* (кебек) *койкалар йук.*

## Лексик үзенчәлекләр

Рухи мәдәният, йолалар: *фатийә* – никах; *бирнә бирешкән* – бүләк биреп, кызны килешү; *күрендек* – кызны сорарга баручының (каенананың) кызга бүләге; *кан'ишка төшү* – егет йортына килү, килен булып төшү; *йахшы сүз алып китү* – кызның егеткә кияүгә чыгарга ризалыгын алу; *тигәнә* – киленнең булачак каената-каенана һәм аларның балаларына әзерләгән бүләге; *бирнә* – туйда кыз тарафыннан кияүнең әти-әнисенә һәм барлык туганнарына бирелә торган бүләге; *үз әйберләре* – кызның сандыкка тутырып китергән үзенә кирәк-ярак әйберләре; *урнаш* – кичен яңа йортны котларга килү, бүләк бирү, күңел ачу; *гучнич* – күчтәнәч һ.б.

Туганлык атамалары: *ат* – исем; *әтекай* /*атакай* – әти; *нәнәй* – әни; *бабакай* – дәү әти; *әникай*/*әбекай* /*карт нәнәй* – дәү әни; *кийәү белән бикәч* – туйда кияү белән кыз (килен) һ.б.

Кешене һәм аларның эш-гамәлләрен тасвирлый торган сүзләр: *усал* – начар; *йадау* – ябык; *карсак* – тәбәнәк; *калын* – юан; *йәмне* – матур; *пыдаука* – зур башлы кеше; *консыз* – ямьсез, *күрекле* – матур, аерылып тора; *саккурасы* (усак + курасы (агачы) – озын буйлы кеше; *кулсыллы* – оста куллы; *олаклау* – әзерләү, бүлү, *күәтләнеп йөрү* – бизәнеп-ясанып, матурланып йөрү һ.б.

Хуҗалык итү, йорт-җир һ.б.: *ызба* – йорт; *прагал* – переулок (тыкрык); *азбар* – 1) ишегалды, 2) хуҗалык санын әйткәндә кулланыла; *лаука* – кибет; *усад'* – бәрәңге бакчасы, *кабердә(а)к* – зират; *кәнәпи* – такта диван; *бит себергече* – сөлге; *тәрәз күзе* – тәрәзә пыяласы; *путалак* – түшәм; *саласка*/*сан'е* – чана; *чирәп* –

балчыктан ясалган киң авызлы чүлмәк; *ката* – җилпуч; *палёндык/ аш кашыгы* – аш чүмече (рус. половник); *пур'ап* – кар базы; *клад* – кибән; *рагужа* – юкәдән тукылган тукыма һәм капчык һ.б.

А ш - с у а т а м а л а р ы: *нәзек колак/май колагы/туздырма* – кош теле; *чигелдәк* – бавырсак; *пирук* – пирожки; *кылак/каты кылак* – көлчә (лепешка); *питрац* – төче камырдан пешерелгән вак күмәч; *карабит* – эченә киндераш салынган таба күмәче, *катлама* – рус. рулет; *кыңгыр* – бөккән (пирожки хоть с чем); *борма*.

К и е м - с а л ы м: *запун* – алъяпкыч; *йүләү* – тегү; *кәркеш* – чабата киндерәсе; *тастымал/санфитка* – кулъяулык; *сапук* – киез итек; *сырга* – алка; *басма* – йаулык; бит себергеч – сөлге; *куфайка* – фуфайка, *сыйау* – чабата ясау таягы һ.б.

Ү с е м л е к а т а м а л а р ы: *айбагар* – көнбагыш, *абдырай /абдрахман йапрагы* – әрекмән; *сак* – усак, *паңгы* – гөмбә, *айу камыры//шипулник* – гөлҗимеш, *картуф* – бәрәңге, *казайак* – йонлы бәрәңге (бутень клубненосный), *кан'үлән* – сары мәтрүшкә, *су гөле* – кына гөле һ.б.

ЭКСПЕДИЦИЯ ВАКЫТЫНДА КАРСУН СӨЙЛӘШЕ
ВӘКИЛЛӘРЕННӘН ЯЗЫП АЛЫНГАН, ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕН
ЧАГЫЛДЫРГАН МАТЕРИАЛЛАР
(СӨЙЛӘҮ ҮРНӘКЛӘРЕ)

## Авыллар тарихыннан

**Сакускай**. А*w*ыл турында бар ике версийә. Бер версийәсе: булган кеше основател «Сакол» исемле. Бу чынбарлыкка туры килми.

Икенчесе. Монда кач'ан аwыл тепләнгән, монда булган саклык. Бездә сак – ул усак. Бик калын урман булган усаклык. Кач'ан Уразовкага әләнгән – аны белмийем. Тирә-йак татар аwыллары безне һаман Сакускай диләр. Уразовка – уразадан инде.

Якуб исемле бай йорты саклана. Труд'ага. Ул йер бик зур буладыр (*була*). 1910 йылны революцийәгә тике (*тикле*) үлә. Уллары каладыр. Революция wакытында туздыралар. Йортларыннан куып чыгаралар. Анын килненен калпагы (*калфагы*) әл дә саклана музейда.

Бу мәчет салынган иске йанган мәчет урнына. 1884 нче йылны. Шул кенән бу мәчет бер кенгә дә йабылмаган. Манара да киселмәде. Анда 60 йылдан артык имам булып Сабир$^{д}$жан хәзрәт бабай тыра. 90 йәшендә үлде. Шунда тике шул бабай саклап килде. Анан калган бабайлар. Шулай иттереп мәчет бер дә йабылмады.

Авыл тузып (*бетеп*) бара. Йәшләр дә картлар да калмады. 1979 йылда монда мен дә илле кеше иде. Хәзер өч йезгә йакын кеше. Кеше әз. Хезмәт йук, эж (*эш*) йук. Бетенесе бетте. Барысы да тузды (*бетте, таралды*).

*Сөйләүче: Диаров Сагид Таһир улы (1951).*
*Карсун районы Сакускай (Уразовка) авылы*

**Ногай (Нугай иле) авылы.** Әти-әни дә Нугай илендә туганнар, үскәннәр. Кала тау. Анда элгәре, атакай (*әти*) шулай сүли иде, Нугай бабай килеп утырган. Биредә бетеннәй су булган денйада. Нугай бабай килгән дә, шул тау башына утырган. Шуннан Нугай иле булып калган. Атакайга бабакай (*дәү әти*) сүләгән.

Ак кизләү – ул урман буйында. Бизәмшә кизләwе бар. Кабриклар (*зират*) турысында ул. Чәчүк пасаткасы – ул инде, сугыштан кат'кач, утырткан пасатка. Без әл дә кечкенә ыланнар идек. Пасатканы кисеп алганнар инде. Ул наратлык иде. Таҗиков Сафиулла утырткан аны. Тагын Кайман пасаткасы бар иде. Кайман кушыматы (*кушаматы*). Аты (*исеме*) Атаулла иде.

Авылда бер мәчет. Элгәреге булган эч (*өч*) мәчет. Сталин заманында мәчетне каушаттылар. Мәчетне каушатканын мин дә беләмен. Аны wаттылар. Теш кебек кенә беләмен. Без йылаштык. Минем түтәм – боларның әбкалары (*дәү әнисе*) – нәнәсенен (*әнисенең*) анасы – абыстай Шакирә дийә идек. Безнең ыланчак. Абыстай күрә дә кочаклап алып китә киселгән манара башын. Аны $^{д}$җийыштырып куйа, йылий-йылий да. Үзендә саклап тыта, ызба (*өй*) башында. Хәзер аны клупка китерде. Музейга. Коран'нарны йергә күмгәннәр. Мәчетнекен. Кылуп йанында.

*Сөйләүче: Вәлиуллова Таибә Кашап кызы (1942).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

**Уразовка (Сакускай) авылы**. Аwылның урыннары. Теге очта алан дигән аwыл. Монда бар Калатау дигән урын. Аннан бирерәк Мар' дигән тау. Бу йакта Мерәй таwы. Калатау дигән йердә хан торган. Хан кызлары йери торган баскыс (*баскыч*) бар иде. Аргырак урман йагында траншей йасалган булган. Хан алан дигән йергә җиткәчтән (*җиткәч*), тәүәсе (*дөясе*) хасталана да үлә. Тәүәсендәге йекне бушатып калдыра ул. Көмеп калдыра. Ул тештән предреволюционный вакытларда урман эченнән бер бабай бакыр акчалар таwып китерә. Аннан соң урман эшләгәндә күп кешеләр дә бу акчаларны таwып китерә. Берсе дә сакланмаган.

Монда мар′ бар. Мәрә халкы. Токымнары бар. Кушаматлары мәрәнекеләр, мари халкы була. Бу тауда тракторлар белән [д]җир эшкәртү wакытлары җиткәчтән соң, тауның итәген сукалагачтан соң, кеше севәкләре чыга. Каберлекләр булган була. Аннан табалар [т]чынайак кусогы, китайски ироглофлы. Натуральный йаңгал. Севәкләр эреләр була, курупный кешеләр булалардыр.

Исмаил бабай бар иде. Алар сүлиләр иде: болгарны туздыргачтын (*туздыргач*), су йулы буйлап килеп, Сыры (*Сура*) буенча килеп, бетенесе качкын халыклар белән булган. 1200 йылларда тирәсе күчкәннәр монда Сакускай, Аксу, Нугай иле (ногайлар килгән) авыллары. Мерәй тавында су буйында йортларны сала тытыналар. Иске кабриклар өсте монда. Унике тамырга тике белә иде бабай.

*Сөйләүче: Диаров Сагид Таһир улы (1951).*
*Карсун районы Сакускай (Уразовка) авылы*

## Тормыш-көнкүреш турында

**Рагужа.** Без тугый (*тукый*) идек. Мунчала кичтән үк. Шкулга тике тырып тугый идек. Рагужа – ул мунчаладан эшләнгән мешук. Җәй башын атакай-нәнәйләр (*әти-әниләр*) китәләр урман'га. Майның актыгында, июн' башында. Берәр ай урман кыралар. Салдыралар кабыгын. Ул йүкәне кизләүгә батыралар, аны груз белән бастыралар. Аннары соң кез [д]җитә. Август – сентәбрдә этиләр,

кемнең абыйсы китәләр. Шуны киптереп китерәләр. Лишнийын сдават′ итәләр иде хөкүмәткә. Калганын үдә тугырга калдыралар. Тугыйсын да заготовител'ләргә сатасын. Шунын белән кен күрә идек. Аның күленәләре бар. Станогы бар. Элгәре бик каты тугыйлар иде. Рагужага урый булганнар кашыкларнымы. Ул тукыма типа нержавейка, бозылмий беркач'ан да.

**Урнашы.** Йаңы ызба куйсалар, урнашы дийәләр иде. Йаңы ызбага вичерга кызлар, йегетләр килә. Гармун белән килсә, бетен вичер кыза.

Кезне **казлар өсте**. Кичне инде хазийка йәшә (*чакыра*) кызларны. Йакын туганнары куна да шунда. Иртән иртүк торасын да, чалалар инде каз-үрдәкләрне, казларны йуасын, йолкасын, арчыйсын. Ун'ыйсын да тагын эшеңә тотынасын. Әтү икенче кенне $^{д}$җибәрмиләр вичерларга. Казлар күп иде. Кен дә йәшәләр иде.

*Шамсетдинова Шәмсә Хасиян кызы (1944).*
*Карсун районы Сакускай (Уразовка) авылы*

**Чирукка бүлү**. Терлек суйганда кемне йәшәсен (*эндәшәсең, чакырасың*), шул килә. Чирукка бөлү (*бүлү*). Весларга куйасың: кемгә уналты кило, кемгә унбиш кило – бөләләр. Бер тайда җийыштырабыз 14 кеше. Бетенесенә тигез бөлепбез. И сатып алалар. Элгәре дә әле дә шулай.

*Сөйләүче: Әбелхаерова Гөлфия Мөстәким кызы (1975).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

Чирук. Сугым. Ат суйгач. Йакыныңны йәшәсен Чалучы кирәк. Хазер итне бө$^{ү}$ләләр чирук. Атнын дөрт элешен. Дөрт элешне тагын дөрткә бө$^{ү}$ләсен. Шул әт'елә чирук. Например, айагын дөрткә бө$^{ү}$лә. Шул айакта 4 чирук. Бер атта чыга уналты чирук. Шуны эләшләр. Кем ала – сатып ала. Кышына суйа. Киченә җийылып утыру йук.

*Сөйләүче: Шәмсетдинова Шәмсә Хасиян кызы (1944).*
*Карсун районы Уразовка (Сакускай) авылы*

**Сура елгасы**. Мәңге дайарка (*доярка булып*) эшләдем. Моннан берничә километр Стрел'никова дигән татар аwылында

тудым. Мында кат'тым. Йәрәшелдем. 62 нче йылны бала тудым (*тудырдым*). Биш балам булды. А*w*ыл бетеп бара. Кем дә тормий. Мәчет бар. Төптә. Элкедән үк бар иде.

Куйлар кырктык. Казлар йылкырга йәшә булганар. Шунда йырлаганар. Нәнәйдән качып, орланып бара идем. Апаларның йырлаганын карарга. Әле бакчага чыккан сайын үз төшемә (*үз алдыма*) йырлыймын.

Мин йаз башын, Соры (*Сура елгасы*) киткән чакта туыпмын (*туганмын*). 23 марта соры китте дийер, нәнәй (*әни*) сине туды (*тудырды*) дийер. Без йогырыпбыз (*йөгергәнбез*) бозлар багырга. Соры – ул Сура каандыр килә. Элке заманда параходлар йөри иде. Элке бездә паром иде. Лодкаларда йери идек. Соры буйинча. Кызлар белән Сырыйның теге йагында шоморт, күк эләк, кайын эләге, җир эләге, чиклавык, мәләш, балан, паңгы җийа идек. Шында йырладык:

Дуслар – алма, дуслар – хөрмә,
Дуслар – кура йеләге.
Ачыйык, эчийек уйнап көлийек,
Бетмәс дөнйа кирәге.

Тырмышымны усал (*начар)* дип әт'ер халем йук (*әйтмәс идем*).

*Сөйләүче: Абдрахманова Нәзирә Исмаил кызы (1940).*
*Карсун районы Гуринка авылы*

**Армиягә озату**. Элке салдатка озатканда вичыр җийасың – йырлыйлар бииләр. Иртән озатасын. Ынга кулларын бастыралар иде. Аннан әпәйне авызына каптырасын. Арты белән чыгаралар. Ынны килеш урамга чыга. Әпәйне кибәргә куйалар. Аны ул кат'кынчы саклап тотасын. Сондыкка салганнар йә киштәгә куйганнар. Кат'кач шул әпәйне каптыралар.

*Сөйләүче: Хабибуллова Сания Кәрим кызы (1935).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

Иртәне салдат киткәндә тирә-күршеләре, туганнары – бар да [д]җийылалар. Алашага (*атка*), озон арбага утырта салдатны. Гармонист ун'ий. Болар зур йулга хатле озата булганнар (*озата торган булганнар*), районга вайынкаматка сдават' итә булганнар.

Карсунга тике барасың. Йегетка санфитка (*кульяулык*) биргәннәр. Бездә чигә булганнар.

*Сөйләүчеләр: Мушаряпова Нажҗия Шәйдулла кызы (1961),*
*Сафиуллова Хәят Садыйк кызы (1939).*
*Карсун районы Сакускай (Уразовка) авылы*

### Уен, вечер, урнаш

**Уеннар.** Оланчак (*балачакта*) ***чиж*** уйнадык. Клетка сыза идек. Чижга палка белән сугып. Аннан ***кл'уктан*** уйнадык. ***Йезелеш*** уйный идек, оланнар белән. Тытынасын бер берен белән и җибәреләсен дә йогырасын. Кем сине тыта, ул матур була. Шахтер йырын этә идек:

Шахтер йегет шахталарда
Йота күмер тузанын.
Сигсан сажын йер астында
Сизми гүмере узганын.

**Урнаш җийу.** Буй кызлар булганда кич утыру да казлар өстенә йери идек. Урнашларга. Кем йаңы ызба куйа, шуларга кичне җийалар. Шул урнаш әт′елә инде. Бүләкләр итәсең ызбаны кортлап (*котлап*). Анда йегетләр, кызлар төн ката (*төн буе*) йырлап-бийеп үткәрә идек у кенне.

*Сөйләүче: Вәлиуллова Таибә Кашап кызы(1942).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

**Елга буенда (келәү йыштыру, сабантуй).** Йаз башын кызлар йыйылыша булганнар. Кар эргәч ун'арга. Кач'ан йаңгыр йаумый, келәү йыштыралар иде. Чиләкләр белән бер-берeсен ызак йаумый торганда су белән кыйындыралар иде. Әбиләр пешерәләр иде су буйында (Евлейка йылгасында) безгә эләкчә (*токмач*), бутка. Аннан суң киченме или иртәгенме йаңгыр йава иде. А*w*ылыбызда сабантуй да йыл сайын йылга буйында уза. Анда урныбыз йахшы – тау, йылга. Бийыл су буйына тешергә йаңгыр йава, тирәч.

*Сөйләүче: Әбелхаерова Гөлфия Мөстәким кызы (1975).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

**Йөзелеш.** Тау башында йезелеш ун'ий идек. Йаз башында (*язын*), йер кипкәчтән. Ике кеше вата шулай басып тора и алында (*алда*) бер кеше. Күп кеше икешәр кеше баса бер рәттән. Артан бер кеше йезеләләр дә йогыралар. Йезеләләр дә үзгә (*башка*) белән кушылалар. Как йегете белән айырылып бергә китә инде – йөзелә. Йегет кеше йугырта кемедер, йараткан кызы артынан йогора. Теге тыттырмаска тырыша. Тытса, аннан алынга тытына. Шулай итеп пар'-пар'.

*Сөйләүче: Мусаллямова Фаиля Искәндәр кызы (1933).*
*Карсун районы Гуринка авылы*

## Кием-салым

Әл дә мин белгәндә калфак кигәннәр иде. Минем нәнәйгә (*әнигә*) кан'асы биргән булган. Кулсыллы (*оста куллы*) булганнар, үзләре чигә булганнар. Минем әбкам – әтийемнең әнисе – шул эшләр белән эшли булган. Аwылларга да чигә булган. Элгәреге себергечләр (*сөлгеләр*) булган. Минем туйларга алып бетерделәр кручоклы себергечләр, чигә булганнар барын да. Кө$^{Y}$лмәкләр абыркалар (*оборка*). Музейга биреп бетердек. Хәйәт апаның сондыгында бар дийер, ул кө$^{Y}$лмәк йакшы иде әл дә. Кан'амның кө$^{Y}$лмәге. Күрсәгез: йәшел өстендә йапрак-йапрак, алды сагылмалыкка.

Кунакларга йерегәндә камзуллар кийәләр иде. Элгәре камзуллар киңәйеп тыра, йәмне (*матур*) иде. Куфайка, туннар кидек. Тужурка кийә идек. Ул кыскак (*кыска*) кына шулай. Айакка чабата, чепрәкләр чылгый идек. Нәнәй (*әни*) тегеннән-моннан чепрәкләр җийыштырып, моннан гына ыштаннар тегә иде.

Йаңа йылларга атакай йаңы чабата тугый иде. Кинәнә идек. Куй булганда, наскилар, чулкалар. Өрәндек инде – элгәре йыннарны арчый идек кырмалауларда. Бәләк белән чапап-чапап тигез генә куйа идек тә, нәнәй йерли (*эрли*) иде.

*Сөйләүче: Вәлиуллова Таибә Кашап кызы (1942).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

Бетен үмерем күлмәкләр тектем халыкка. Йонны йәрләргә (*эрләргә*) өрәндем. Бәләдем бетенесен оланнарыма. Наскилар,

челтәрләр бәли идек. Эскәтерләр бәлибез. Бит себергечләргә, салфиткага чәчәк чигеп. Кийәү кешегә бирә идек. Кан'ишка төшкәндә (*ир йортына килен булып төшү*), бит себергечләрне атка да бәли идек. Кийәү белән бикәч (*егет белән кыз*) утыра. Алынга (*алга, алдына*) кучер утыра.

*Сөйләүче: Мусаллямова Фаиля Искәндәр кызы (1933).*
*Карсун районы Гуринка авылы*

Киндераш чәчтек. Тирмәнгә бара идек. Тарттырырга. Киндераштан нәнәйләр йерлиләр, кагалар иде. Минем ат'кай сапужник иде. Дратуа (рус. *дратва – калын җеп*) йасыйлар иде. Кө$^{ү}$ннән тегәләр иде. Бездә кужзавуд бар иде. Киндердән йеп йасый идек. Йерли идек. Нәнәй аны эшләде көп. Утынны саласка (*чана*) белән дә алаша белән дә ташыдык. $^{т}$Чабата тиз туза иде. Йомыркага бер бабайдан сатып ала идек, кичкә туза иде. Ә бер бабайныкы бер атнага җитә иде. Кышын да чабата иде. Кәркешләр чорныйсын. Тактадан йасилар шакмак. Хет баскач ө$^{ү}$тми су. Аны да кийеп бактым, сеңелләрем кимәде.

$^{т}$Чәчкә чулпы такканнар. Ниндидер акчалар иде. Кан'амныкы бар иде каадыр. Без лента үрепбез, икедән йебәрә идек. Бай кеше колакка сырга ала, тага иде. Йарлы багып кына тора.

Чепрәк $^{д}$җыйучы барын да сата иде: былаука (*булавка*), энә. Сатып ала идек. Йамарга да йук. Шпулка (*җеп*) да ала идек. Сүwәк (*сөйәк*) җыйдылар.

*Сөйләүче: Калифуллова Таифә Хәсән кызы (1937).*
*Карсун районы Сакускай (Уразовка) авылы*

## Туйлар

Орлаганнар. Минем үз кызымны орладылар. Мине сорап алдылар. Килде кан'ем (*каенатам*), кан'ам (*каенанам*). Сорадылар. Элгәреге акчага, 600 сумга, мәхер сүләделәр. Минем атакайым сүләде: 300ен сразу бирделәр, 300ен фатийада (*никахта*) бирделәр.

Фатыйа (*никах*) бер кен, туй эч кен. Беренчесендә ник'ах була. Икенчесендә сий (*сый*) была: кыз йебендә (*ягында*), аннан йегет үендә сий була. Икенче көнне кыз йерында кызлар ник'ах

булгачтан, кийәүне алып китәләр кире. Братлар, җизнәләр китерә йегетне. Китергәч сий была аракылар белән. Эченче кенне йегет үенә киләләр. Сий-гармуннар, бийүләр.

Кыз белән йегет атларга утырып йазылышырга бара. Йаз (*җәй*) булса – тырантаста, кыж булса – чаналарда. Оланнарга элгәре копик акча, конфит сибәләр иде.

**Күрендек.** Күрендек – киленгә сорарга бара кан'а кеше, шунда күренә кан'а, күрә килнен, бүләк бирә үзенә. Минем нәнәйгә кан'асы биргән булган күрендеккә калфак.

**Күремне.** Күремнегә кийәүне китерәләр күренергә. Кулйаулыклар чигә идек үз кулыбыз белән. Килүчеләргә бө^үләкләр бирәләр, йаулыклармы анда. Малайларына себергечләр бирәләр, кызларга йаулыклар, запуннар бирә идек, косин'калар. Нәнәйләр олаклап (*олылап әзерләп, бүлеп*) куйалар иде ничә белән килә кийәү. Шуларга бүләкләрне олаклыйлар иде. Кан'га, кан'ага, семйаларга бүләкләрне бирәләр иде. Бирнә инде.

**Тигәнә йыштыру**. Кан'ага ти(е)гәнә йыштыралар иде. Тигәнә – намазлык, сөлгеләр куйалар, эстәкерләр (*эскәтерләр*). Кан'га, кан'ага кө^үлмәк, ыштан, намазлык. Тегәнә кан'ага (*каенанага*) гына и симйадагы кешеләренә. Тегәнәгә, например, сигез кеше сем'йада, сигезесенә дә күлмәкләр. Кан'ага ыштан да кө^үлмәк, йаулык. Кан'га кө^үлмәк кенә куйыла. Минем ^өүч кенә иде, кан'сеңлем дә кан'игачым. Аларга да бирәбез.

**Бирнә бирү.** Бирнә ул айырым, эләшәсен бирнәне бетенесенә дә. Бирнәгә катыннарга йаулыклар, ирләргә себергеч (*сөлге*). Бирнәне дә ник'ахта бирәләр. Ә сондык белән үз әйберләреңне алып барасын, ул бирнә дип аталмый.

**Кан'ишка килү.** Кан'ишка (*ир йорты*) төшкәндә сондык белән килә идек. Анда үзеңә әйберләрең: чашка, комган, кашыклар, кийемнәр. Нәнәйләр үендә нәрсәләр кийәсен, шуларны сондый түәп алып киләсен.

*Энә генәм, җеп кенәм*
*Калды сондык төбендә.*
*Рәхәт кенә тыныч кынам*
*Калды анам йебендә.*

Кан'ишка киләсең, ка'нә сиңа ухыватыңны (*чуен кыстыргыч*) бирә. Кан'ишка килгәч, мунчаны йактым. Әти-әни мунчага, дийепмен. Мунчадан чыккачтан, кан'ам миңа ухыватны бирде.

*Кан'иш йорты – кабыктык,*
*Кабык булса да тамыктык.*
*Анай йорты саламдыр,*
*Саламдыр да сарайдыр.*

*Сөйләүче: Вәлиуллова Таибә Кашап кызы (1942).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

**Бирнә бирешкән.** Йегетнең этисеме килә сорап. Шуңа бирә күлмәкме, бит себергечеме инде. Баш кодалыйга, сораучыга. Шуны, бирнә биргәчтән, сүләнгән сүз ышанычлы инде. Бирнә бирешкән, дир бездә ат'әләр.

**Кайнишкә төшү.** Никах укыткачтын, ат [д]җигеп кан'ишка (*егет йортына*) тешерәләр. Йома кенне ник'ах. Икенче кенне йегет йагына баралар. Йегермешәр йортмы ир йагын йериләр. Кунак итеп. Таң аткынчы йериләр. Һәрберсендә аш. Икенче кенне кыз йагына китәләр.

Ник'ахтан сың иртән кийәү белән бикәч мунчада йывыналар. Киленнен йакын туганнары, кызлар мунча йагалар. Кийәүгә йәш килен тутырып җибәргән, шуны өләшкәндер балаларга. Чиклавык, чигелдәк, конфит йакшыларны. Ул киленнеке этелә. Ә кийәү үзенә китерә инде.

*Сөйләүче: Шәмсетдинова Шәмсә Хасиян кызы (1944).*
*Карсун районы Сакускай (Уразовка) авылы*

**Йахшы сүз алып китү.** Туйлар йахшы уза. Йегетләрнең атакай-нәнәйләре киләләр сорарга. Риза булсалар, кызны бирсәләр, алар шунда йахшы сүз алып китәләр, диләр. Бер нәрсә булса бирәләр: йаулык йә бит себергеч. Бу йакшы сүз алып китү була. Аннан ник'ах.

**Бүләк бирү, бирнә өләшү**. Элке сөлге дә шәл. Йәмне (*матур*) шәлләр, узорлы, лаукадан (*кибеттән*). Бай кеше күлмәклек бирә. Кан'асына, кан'га биргән. Бүләк дийелә что син риза. Ник'ах

укыганда те йактан да бы йактан да ᵈҗийылалар. Зур эстәл. Мулла йәшәләр ник'ах укырга. Шунда йегет йагына бирнә эләшәләр: селге, анын эстенә йон шәл.

*Сөйләүче: Кафиятуллова Мәстүрә Ибраһим кызы (1939).*
*Карсун районы Аксу (Голышевка) авылы*

**Казык санау.** Никахка тике кыз үенә баралар казык санарга. Казык – исерек мәҗлесе. Аракы куйалар ирләргә. Кода-кодагыйлар күрешүе була инде. Йакын туганнары белән бара кыз үенә. Шунда сүләшәләр: туй ничек була, кач'ан ник'ах укырга.

**Билге бирү**. Беренче көнне кан'е белән кан'ага билге бирәләр. Йахшы шәл бирәләр. Күрешү-сүләшү була инде. Билге биргәндә аракы эчмиләр. Йахшы эстәл була. Туйга кадәр ул. Шунда сүләшәләр кач'ан туй була. Билге биргәннән суң никах була. Мулла йәшәләр ник'ахта. Кыз йаныннан да ир йагыннан да ᵈҗийылалар. Шунда бирнәне эләшеп чыга.

*Сөйләүче: Кафиятуллова Мәстүрә Ибраһим кызы (1939).*
*Карсун районы Аксу (Голышевка) авылы*

## Ырым-шырым

**Балам-багалмам...** Күз тигәндә өстәл ᵗчитләрен йывалар. Күмер, тыз кашык, пычак, аларга су койасың, чыга торган төшеннән. Кирсенчә кийаш иңгән йактан йуарга кирәк. Шул суны ылан авызына эчерәсең. Ишек бауларын, сапларын, тәрәзәнең пыйаласын себерәсең (*сөртәсең*). Бусагаларны. Кешенең көᵞзе төшкәндер тәрәзәгә ыланга. Бусаганы себерә иде дә шуны дә эчереп. Бетә иде. Ул суны артка бәрәсең баш ашаңа. Үз күзең үзеңә тисен дип әтеп. Тышка бәрәсең. Арткы йакка. Кибла йагына тегел.

Койаш иңгән wакытта ыланны йыклатырга йарамый. Йыкласа да әни уйата иде. Бишектә бит инде. Әтә иде: шайтаннарның туй wакытлары, зарар килер. Үдән чыкмый идек койаш иңгәндә, ахшам wакытында. Без урамга чыкканда элгәре кичне, икендек wакыт, койаш иңгенче инде кычкыралар иде: керегез. Ырышалар (*орышалар*). Керә идек урамнан. Әл дә йырлый да идек:

*Ай да калка башлады,*
*Ад'агыз, дуслар, керийек,*
*Йокы кели башлады.*

Йуклык иде. Кадерле заманалар иде.

*Сөйләүче: Вәлиуллова Таибә Кашап кызы (1942).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

**Йорт анасы.** Минем карт нәнәйгә дә сүләде. Алар йаналар. Карт нәнәй тышка чыга. Кабак турысында бер нәстә чыккан. Баскан дийер. «Нәстә булды үзеңә, ник йылыйсың?», дийер. Әтәм, ди, йорт анасы бу. Йылый бу. Икенче кенне йандык, ди. Ул йукка йыламаган икән, дийер.

*Сөйләүче: Вәлиуллова Таибә Кашап кызы (1942).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

Теннә эч кен ызбада кемдер йери-йери. «Дамаwайыңны керт-тенме?» – дийер. Һәрбер уголдан күмер алгыч белән йыштырып йереп, «ад'а минем белән!» – дийергә иске ызбадан. Идән уртасына куй да күмер алгычны, бар бу ызбага, дир. И все. Шуннан соң бетте, дир. Мине йәшмәделәр дип әтеп тойдырып йереде үзен.

*Сөйләүче: Әбелхаерова Гөлфия Мөстәким кызы (1975).*
*Карсун районы Нугай иле авылы*

Ботка пешерәмен бер чүлмәккә. Тызсыз пешерәмен. Лаукадан (*кибеттән*) ал да, йаңы булсын чүлмәгең. Иске булмасын. Ботка куй. Йанына тызын куй. Мәтәм: «Куйамын үзеңә ботканы, тыз-сыз ашама. Терлегемә дә тимә, үземә дә тимә». Йереп тырамын и сүләнеп тырамын. Багана башына куйабыз. Азбарга. Сийырга да тийә. Сийыр тиргә төшә. Алашаның кайсысын (*кайсын*) йарата, кайсысын – йук.

*Сөйләүчеләр: Фәисканова Таһира Садыйк кызы (1945),*
*Халилюллова Мәсрурә Әдгам кызы (1942).*
*Карсун районы Аксу (Голышевка) авылы*

# III. МӘЛӘКӘС СӨЙЛӘШЕ

2017 елда Ульяновск өлкәсенә уздырылган фәнни экспедициябезнең дәвамы – өйрәнелгән районнарыбызның өченчесе – Мәләкәс районы. Мәләкәс районы татарлары Атнагыл (Аллагулово), Мөси (Моисеевка), Филип (Филипповка), Мукшы Күле (Мордово Озеро), Парау (Боровка) авылларында бердәм яшиләр. Тел үзенчәлекләре ягыннан бу як сөйләме мәләкәс сөйләше дип атала.

1963 елда Г.К. Якупова җитәкчелегендә диалектологик экспедиция оештырылып, мәләкәс сөйләшенең тел үзенчәлекләре өйрәнелә, 1975 елларда З.Р. Садыйкова тарафыннан да сөйләшкә материал туплана.

Сөйләш Ульяновск һәм Самара өлкәләренең төньяк районнарында да таралган. Бу территориягә татарларның (темников мишәрләренең токымнары) күпләп күчеп утырулары XVII гасыр урталарында Сембер һәм Самара ныгытылган хәрби линияләрен төзү эше белән бәйләнгән. Хөкүмәтнең колонияләштерүеннән тыш, бирегә татарлар ирекле күчү юлы белән дә килеп утырганнар. Легендаларга караганда, бу җирләргә күчеп килүләр XVIII гасырда да дәвам иткән. Хәзерге Карсун районы регионыннан килүчеләр дә булган.

### Фонетик үзенчәлекләр

Мәләкәс сөйләше фонетик үзенчәлекләре ягыннан татар теле мишәр диалектының башка сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә. Шуның белән бергә, сөйләшне билгели торган аерымлыклар да бар. Алар, башлыча, кайбер авазларның әйтелешендә, аваз тәңгәллекләрендә һ.б. да чагыла.

**Сузыклар.** Сөйләштәге сузык авазлар, бигрәк тә [*а*], [*ә*], [*у*] авазлары, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, алгырак позициядә ясалалар.

[*а*] сузыгы – иренсезләшкән, арткы рәт авазы: *йар, карт, баралар.*

[*о*], [*ө*] ирен сузыклары, иренсезләшеп, [*ы*], [*е*] булып әйтеләләр: *пышый* – әд. поши, *ыста* – оста, *кендез* – көндез, *бетенесе* – бөтенесе, *кен* – көн, *кез* – көз, *телке* – төлке, *йери* – йөри. Башка

мишәр сөйләшләрендәге кебек, бер төркем сүзләрдә [*о*] авазы үзе дә әйтелә: *осак* – әд. усак, *орлау* – урлау, *корчак* – курчак һ.б.

Сузыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә, төрле фонетик күренешләргә кайтып кала.

Сузыклар тәңгәллеге. [*ы*]~[*а*], [*э(е)*]~[*ә*] күренешенең кушымчаларда чагылышы: а) хәл фигыль формаларында: *баргынчы(к)/баргынча(к)* – барганчы, *килгенче(к)/килгенчә(к)* – килгәнче; ә) *-ар/-әр* кушымчалы фигыль формаларында: *табыр* – табар, *келер* – көләр, *белер* – бөләр, *сатырга* – сатарга, *кабырга* – кабарга, *йөзергә* – йөзәргә, *үсергә* – үсәргә.

[*ә*]~[*и*]. Бер төркем сүзләрдә сүзнең беренче иҗегендә әдәби телдәге тар [*и*] сузыгына киң [*ә*] сузыгы тәңгәлләшә: *әпәй* – ипи, *мәләш* – миләш, *кәбән* – кибән, *кәштә* – киштә, *кәм* – ким, *нәк?* – нигә?, *кәртә* – киртә. Икенче иҗектә: *әнәй* – әни, *әтәй* – әти.

[*и*]~[*ә*] берничә сүздә күзәтелә: *әзерик* – диал. *әзрәк* – азрак, *фирештә* – фәрештә, *тирәзә/тирәз/тәрәз* – тәрәзә, *типич* – тәпәч, *мыни* – *менә*, *кифен* – кәфен.

[*о*], [*ы*]~[*у*]: *монча/мынча* – мунча, *орлау/ырлау* – урлау, *осак/ысак* – усак, *корчак* – курчак, *олым* – улым, *Абдылла* – Габдулла, *шолай* – шулай.

[*у*], [*ү*]~[*о*], [*ө*]: *бутка* – ботка, *куңгыз* – коңгыз, *куңгырт* – коңгырт, *суң* – соң, соңыннан, *чугу* – чоку, *улагу* – олагу, *уйат* – оят, *үмә* – өмә, *үнәр* – һөнәр, *үмер/гумер* – гомер, *йүткерә* – йөткерә, *хурмәт* – хөрмәт.

[*ө*] / [*е*] ~ [*ү*]: *көп/көҮп* – күп, *көпертмәле/көҮпертмәле* – күпертмәле, *төгел/тегел* – түгел, *кеңел* – күңел, *бөген/беген* – бүген.

Әдәби телдә алгы рәт сузыклары белән әйтелә торган бер төркем сүзләр сөйләштә арткы рәт сузыклары белән әйтеләләр: *(тәрәзә) топ* – (тәрәзә) төбе, *лаука* – ләүкә, *капыста* – кәбестә, *кукук* – күке, *шопша* – шөпшә, *мый* – ми, *йогорык* – йөгерек, *корка* – күркә, *чаука* – чәүкә, *йанаша* – йәнәшә (янәшә).

Әдәби телдә арткы рәт сузыклары белән әйтелә торган бер төркем сүзләр сөйләштә алгы рәт сузыклары белән әйтеләләр: *әбзәй* – абзый, *чәйкәргә* – чайкарга, *хазер* – хәзер, *мендый* – мондый, *чәндер* – чандыр, *йен* – йон, *бәлчек* – балчык, *кечеркән* – кычыткан.

Сузыклар төшү. Сүз башында сонор авазлар алдыннан килгән [*о*], [*у*], [*и*], [*ө*], [*э(е)*] сузыклары төшә: *мурта* – умарта, *йалу* – ойалу (оялу), *йәрләү* – ийәрләү (иярләү), *ләктерү* – элəктерү, *йәрү* – ийәрү (ияpү), *йәңке* – өйәңке (өяңке), *зату* – озату.

Кайбер күп иҗекле сүзләрдә уртадагы яки ахырдагы сузык төшә: *иләшү* – ийәләшү (ияләшү), *йүш* – йүwеш (юеш), *куш* – куwыш (куыш), *тәрәзә/тирәз* – тәрәзә, *кый* – койы (кое).

Ике сүз арасында килгән беренче сузык төшә: *кыраш* – коры аш (итсез аш), *балитәк* – балаитәк, *урамдук* – урамда ук, *шундук* – шунда ук.

Сузыклар өстәлү. [*ы*], [*э(е)*] авазлары өстәлә: *ылаука* – ләүкә, *эшешенгән* – шешенгән, *ыстанса* – станция, *ыриза* – риза.

**Дифтонглар.** Мәләкәс сөйләшендә, татар теленең башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, дифтонглар монофтонглаша.

***-өй*** дифтонгы, монофтонглашып, [*ү*] гә күчә: *сүләшү* – әд. сөйләшү, *ү* – өй, *кү* – көй, *түмә* – төймә, *үлә (намазы)* – өйлә (намазы).

***-өй*** дифтонгы монофтонглашканда, күтәрелешләре төрле булган сузыклар арасында ирен-ирен [*w*] тартыгы барлыкка килә: *үwә* – өйә (өя), *түwәбез* – төйибез, *сүwәк* – сөйәк (сөяк), *сүwәл* – сөйәл (сөял), *күwә* – көйә (көя), *күwәнтә* – көйәнтә (көянтә).

***-өй, -әй, -уй, -ый*** дифтонглары монофтонглаша. Бу очракта ике сузык арасындагы тартыклар палатальләшә: *кат'а* – әд. кайта, *бар'ам* – бәйрәм, *ад'а* – әйдә, *кар'ак* – кайрак, *кас'ы* – кайсы, *бәләү* – бәйләү, *ар'ан* – әйрән, *бун'* – муйын (муен), *ун'ий* – уйный, *кун'* – куйын (куен), *әләнү* – әйләнү, *әтә* – әйтә.

-***ой, -ый*** дифтонглары ***-ий*** дифтонгына күчә: *киймак* – әд. коймак, *кийаш* – койаш (кояш), *кийар* – кыйар (кыяр), *сийыр* – сыйыр (сыер), *укий* – укый, *кини* – кыйный.

**Тартыклар.** Башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, [*к*], [*г*], [*ң*], [*х*] авазлары сөйләштә тел арты тартыклары булып әйтеләләр: *карга* – карга, *кабак* – капка, *кагыз* – кәгазь, *хазер* – хәзер.

Әдәби телдәге өрелмәле [*ч*] авазы сөйләштә кушык аваз [*тч*] булып әйтелә: *тчишмәлек* – чишмәлек, *тчыбык* – чыбык, *тчаука* – чәүкә, *петчән* – печән һ.б.

Шулай ук [*ц*] варианты да очрый (Атнагыл авылына хас): *эц* – эч, *пәрәмәц* – пәрәмәч, *цәй* – чәй, *килгәнце* – килгәнче, *сөннәтце* – сөннәтче, *мәцет* – мәчет, *цегендер* – чөгендер, *тугац* – тугач.

Сүз башында әдәби [*җ*] авазына [*дҗ*] кушык авазы тәңгәл килә: *дҗиләк* – җиләк, *дҗиде* – җиде, *дҗиңел* – җиңел, *дҗийу* – җыю, *дҗәй* – җәй; сүз уртасында *з~җ: мердзә/мерзә* – мөрҗә (морҗа), *пәзи* – пәҗи, *кәзә* – кәҗә, *пәрәнзә – пәрәнҗә.*

Тартыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр авазлар тәңгәлләшүенә һәм төрле комбинатор үзгәрешләргә кайтып кала.

[*б*]~[*w*]. Билгеле бер төркем сүзләрдә ике сузык арасында килгән әдәби [*w*] авазына сөйләштә [*б*] тартыгы туры килә: *чыбар* – чуwар (чуар), *чыбан* – чуwан (чуан), *йыбату* – йуwату (юату), *чыбалу* – чуwалу.

[*м*]~[*н*] берничә сүздә күзәтелә: *үләм* – әд. үлән, *җилем* – җилен, *патмус* – поднос, *чырмау* – чорнау.

[*п*]~[*ф*] билгеле төркем сүзләрдә һәм кеше исемнәрендә күзәтелә: *тупрак* – әд. туфрак, *калпак* – калфак, *керпек* – керфек, *Пакизә* – Фахыйзә, *Сапый* – Сафый.

[*н*]~[*ң*] хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыльләрдә, күрсәтү алмашлыкларында күзәтелә: *алырсын* – әд. алырсың, *барасын* – барасың, *киләсен* – киләсең, *күрерсен* – күрерсең, *анарга* – аңарга, *монарга* – моңа.

[*д*]~[*т*]: *дустыган* – диал. *тустыган* – аш чүмече, *күwәндә* – көйәнтә (көянтә), *ибдәш* – иптәш, *абдырау* – аптырау, *төшдем* – төштем.

[*й*]~[*җ*]. Сөйләшкә сүз башында, нигездә, *й*-ләштерү хас: *йеде* – әд. җиде, *йыйу* – җыю, *йемерек* – җимерек, *йер* – җир, *йеп* – җеп, *йыр* – җыр.

[*г*]~[*к*]. Бер төркем сүзләрдә ике сузык арасында яки сүз башында саңгырау [*к*] авазы яңгыраулаша: *чигеркә* – чикерткә, *тугу* – туку, *йага* – йака (яка), *чугынган* – чукынган, *чыгыр* – чокыр, *сигезән/сигсән* – сиксән, *тугызан/туксан* – туксан һ.б.

[*к*]~[*г*]. Яңгырау [*г*] авазының саңгыраулашуы *сикез* (сигез), *тукыз* (тугыз), *кебе* (гөбе) сүзләрендә күзәтелә.

[*к*]~[*х*]. Бер төркем татар сүзләрендә һәм кайбер алынмаларда да әдәби телдәге [*х*] авазына сөйләштә [*к*] авазы тәңгәл килә:

*касталану* – хасталану – авыру, *катын* – хатын, *йакшы* – йахшы (яхшы), *маскар* – мәсхәрә.

[*х*]~[*к*] берничә сүздә билгеле: *әрехман – әрекмән, wакыт/wахыт* – вакыт, *кадәр/хадәр* – кадәр, *духтыр* – доктор, *хойма – койма.*

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр. [*б*]~[*ф*]: *йебәк* – йефәк (ефәк); [*w*]~[*б*]: *wәке* – бәке, *йаwып* – йабып, [*к*]~[*т*]: *келәү – теләү;* [*к*]~[*ф*]: *куфайка* – фуфайка, [*й*]~[*д*]: *йәшу* – дәшү; [*с*]~[*з*]: *кистек* – кийез итек (киез итек); [*н*]~[*д*]: *алын* – алды, *ишег алны* – ишегалды, *алын-артлы* – алды-артлы; [*г*]~[*у*]: *агдарырга* – аударырга.

Ассимиляция (авазлар охшашлануы). Кайбер сүзләрдә тел очы [*н*] тартыгы үзеннән соң килгән ирен-ирен [*б*] авазына охшашлана: *умбиш* – унбиш, *умбер* – унбер, *гомбагар* – көнбагыш.

[*л*] авазы үзеннән соң килгән [*г*] авазына өлешчә охшашлана: *йаңгыз* – йалгыз (ялгыз), *йаңгал* – йалган (ялган), *йаңлыш*//*йаңгылыш* – йалгыш (ялгыш), *аңгару* – аңлау, соңгару – соңлау.

Сүз ахырындагы [*ч*], [*ш*] тартыклары, тел уртасы [*й*] һәм яңгырау тартыклар алдында килгәндә яңгыраулашалар: *бижй ез* – биш йөз, *пиж башты* – мич башы, *тажарасы* – таш арасы, *алтмыж дҗиде* – алтмыш җиде.

Тартыклар төшү. ***лт*** тезмәсендәге [*л*] төшә: *йугату* – әд. йугалту (югалту), *итү* – илтү, *кузгату* – кузгалту; *эшләргә* сүзендә ***л*** төшүе дә очрый – *эшәргә*.

Гарәп алынмаларында тирән тел арты [*ғ*] авазы төшә: *аза* – әгъза, *айып* – гайеп (гаеп), *сәәт/сәат* – сәгать*, Абдулла* – Габдулла, *Мәрифә* – Мәгърифә, *Нәймә* – Нәгыймә, *йыма* – җомга; [*т*]: *кечеркән / кычыркан* – кычыткан, *чигеркә* – чикерткә, *тапату* – таптату; [*ш*]*: алма-тилмә* – алмаш-тилмәш; [*р*]*: пичәткә/пичәрткә* – пирчәткә; [*н*]*: сыңыдан* – соңыннан, *анан* – аннан, *чәчә бармак* – чәнчә бармак; *белә* – белән.

Традицион сөйләшкә хас булмаган, гарәп-фарсы алынмалары аша кергән [*h*] авазы төшә: *әр* – әд. һәр, *ич* – һич, *әммәсе* – һәммәсе, *шәәр* – шәһәр, *Майнур* – Маһинур, *Шийап* – Шиһап, *Фәймә* – Фәһимә.

Иҗек төшү очраклары: *кистек* – кийез (киез) итек; *ишкән* – ишеткән.

Тартыклар өстәлү. [*т*]: *пиҗ башты* – мич башы; [*й*]: *йезу* – өзү.

Метатеза: *азбар* – абзар, *бачкыз* – баскыч, *бүрке* – бүрек, *элке* – элек, *күреш* – күрше, *әчәт* – этәч, *каулау* – куwалау (куалау), *бырны* – борын, *җымак* – оҗмах, *кымрыска* – кырмыска.

## Морфологик үзенчәлекләр

**Алмашлыклар.** Зат алмашлыкларын куллану буенча сөйләштә үзенчәлекләр күзәтелми.

Күрсәтү алмашлыклары. Әдәби телдәге (*менә, әнә, бу, ул, шул, теге*) күрсәтү алмашлыклары белән беррәттән, сөйләштә *мени, мына, мыни, ана* һәм тартым кушымчалы *бусы, улсы, шулсы* алмашлыклары актив кулланыла. Мәсәлән: *Мени* (менә) *мондый ризыклар бар бездә.*

Карсун һәм хвалын сөйләшенә хас булган *вата, ватә, ванә, ване* (< рус.) вариантлары мәләкәс сөйләшенең без йөргән авылларында күзәтелмәде.

*Шул* күрсәтү алмашлыгыннан ясалган *шолай, шылай, шондый, шындый, шонарга, шынарга* сүзләре сөйләштә актив кулланыла.

Сорау алмашлыклары. Әдәби телдәге нәрсә, ничек сорау алмашлыклары урынына *нәстә* (сирәк *нәмәстә*) алмашлыгы йөри: *Кем нәстә* (нәрсә) *сүли алган. Нәстә халләр?* – Хәлләр ничек?

**Рәвешләр.** Лексик рәвешләрне куллану буенча сөйләш, нигездә, әдәби телгә якын тора. Диалекталь характердагы лексик рәвешләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: *шап-шактый* – әйбәт итеп, *берцәк*/*берцик* – бераз, *буйлата* – тоташтан, *гелән* – һаман, *әзерик* – азрак, *тептә* – бөтенләй, *тенә* – кичә, *тым ак* – чем ак, *үңгә*/*үзгә* – башка, *беткел* – бөтенесе, *насила* – көч-хәл белән, *алын-артлы* – алды-артлы; *жар* – эссе, *карчак* – түбән, *күбәү* – күп, *хутлы* – җайлы, җайга, уңайлы, нык. Мисаллар: *Алын-артлы* (алды-артлы) *укыганнар бабайлар корәнне. Берцик* (бераз) *монда баргац тагы куак. Тенә* (кичә) *таwыгым йугалган иде, телке алгандыр дидем.*

***-ча(к)/-ца(к)*** кушымчалары белән рәвешләр ясалу хас: *Аңгынца* (аңарчы) *ылан туды. Аңынча* (аңарчы) *авылда бернәстә йук иде*. *Аңгырчак* (аңарчы, аңа кадәр үк) *чыктын.*

**Фигыльләр.** Сөйләштә хәзерге заман хикәя фигыльнең 1 нче зат берлек саны кыска *(барам, киләм)* һәм тулы *(барамын, киләмен)* вариантларда кулланыла: *Шәкәр кабып йебәрсәм, туксынам. Эшлимен, бернигә дә мохтанмыймын. Куй итен бик йаратып бетермимен.*

2 нче зат берлек санда хәбәрлек кушымчасының борынгырак ***-сын/-сен*** варианты сакланган: *Чече камырдан тәмне генә майда камырында йасыйсын* (ясыйсың). *Плита өстендә кабартма пешерәсен* (пешерәсең).

Хәзерге заман хикәя фигыльнең 3 нче зат берлек саны, әдәби телдән аермалы буларак, еш кына ***-дыр/-дер*** хәбәрлек кушымчасы ялганып та ясала: *Аннан киләдер* (килә) *кодалар. Кагытны элек Рушан әбийең йасыйдыр иде* (ясый иде).

Билгеле киләчәк заман *(-ачак/-әчәк)* сөйләш өчен характерлы түгел. Бу форма сирәк кенә *йук* һәм *төгәл* сүзләре белән кулланыла: *Анда барып, ызак тырачагым йук* (озак тормаячакмын).

Теләк фигыль. Эчке теләк (-асы кил-) сөйләштә ***-гы/-ге, -кы/-ке + кел-*** конструкциясе белән белдерелә: *Жар* (эссе), *урамга чыккым келәми* (чыгасым килми).

Максатны, теләкне белдерү өчен ***-ма/-мә*** формасы һәм ***кели*** (< тели) ярдәмче фигыле белән ясалган конструкция кулланыла *(барма кели, килмә кели): Кийәүгә алма кели* (алырга тели). *Бәрәмгә барма келибез* (барырга телибез).

***-ырга кели*** *формасы сирәк кулланыла: Йаңгыр йаwырга кели* (тели) *ахырсы.*

Инфинитивның мәләкәс сөйләшенә ***-ырга/-ергә*** формасы хас: *Хатын-кыз зирәткә керегә йарамый. Кезен укырга барабыз. Колхозда черек бәрәңге җийырга бара идек.*

Исем фигыльнең сөйләштә ***-у/-ү*** кушымчалы формасыннан (*Хазер урманга йерү йук*) тыш ***-ыш/-еш*** формасы да кулланыла: *Анда ачуланыш* (ачулану) *йук. Ничә пар белән, саwымнар белән килеш* (килү) *бит инде. Кечкенә оланнар уйнаш* (уйнау) *иде урамда.*

***-гач*/*-гәч, -кач*/*-кәч*** һәм ***-гачтан*/*-гәчтән*** кушымчалы хәл фигыльләр актив кулланылышта: *Кат'кач ук сийыр алдык. Казларны күл буйына бара идек чәйкәргә йолккачтан* (йолыккач).

***-ганчы*/*-гәнче*** кушымчалы хәл фигыльнең сөйләштә ***-гынчы*/*-генче, -гынча(к)*/*-генчә(к)*** кушымчалы вариантлары да еш кулланыла: *Үзебез йасый идек чабатаны, кешегә баргынчы* (барганчы).

**Синтаксис.** Сөйләшкә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, инверсия күренеше, ягъни җөмлә кисәкләренең үзара бәйләнеш тәртибе ирекле булу хас: *Элке шулай иде йаңы ызбага күчкәч* – Элек, яңа өйгә күчкәч, шулай иде. *Бийегәннәр болар йырлап-йырлап* – Болар җырлап-җырлап биегәннәр. *Берцик* (бераз) *кына кушабыз тыз анарга* – Аңа бераз гына тоз кушабыз. *Кичен тагын йыйылалар кодалар* – Кичен кодалар тагын җыелалар.

### Лексик үзенчәлекләр

Туганлык-кардәшлекне белдерә торган сүзләр: *әнәй*/*анай*/*анакай* – әни, *әтәй*/*атай*/*атакай* – әти, *әбий*/*әбкәй*/*зур әнәй* – әби, әнисенең яки әтисенең әнисе, *бабай*/*бабакай* – бабай, әнисенең яки әтисенең әтисе, *абыстай*/*апа*/*тутай* – бертуган апа, *әзи*/*әбзәй*/*әзәй* – бертуган абый, *дәдәй* – әнисенең яки әтисенең абыйсы, *бырат* – ир туганы, *ылан* – бала, *нук*/*нука* – онык, *тудыкай* – туганнан туган, *җиңгәчи* – абыйсының хатыны.

Кешенең тән төзелешен, сыйфатларын, халәтен белдерә торган сүзләр: *йәйәк* – яңак, *чәндер* – арык, ябык, *аухат* – куәт, *акыш-мәкыш* – аңгы-миңге, *йерәкләну* – ачулану, ярсу, *күпшенү* – күбенү, *урегү* – сагыну, тансыклау, *каста* – авыру, *киңәнү* – шатлану, *тыну* – тынычлану, хәл җыю, *дарылу* – омтылу, талпыну, *чибак* – озын буйлы кеше, *тузу* – ашыгу, (битне) *себерү* – сөртү , *йүләү* – тегү, *бәрү* – сибү, *йөрәкләнү* – курку.

Ашсу: *кәлҗемә* – сумса, *чигелдәк* – бавырсак, *шәкәр пукыле* – шикәр шакмагы, *баwырсак* – чәкчәк, *чумара* – чумар (клёцки), *питырач* – сөткә һәм күкәйгә генә басылган төче камырдан чынаяк зурлыгында әвәләп майлы табада пешерелгән кабартма, *эләкшә* – өйдә ясалган токмач, *кагыт* – как, *саwым* – туйга алып барыла торган күчтәнәч.

Хуҗалык, тормыш-көнкүреш белән бәйле диалекталь сүзләр: *чит/нүwеш* – почмак, *ызба* – өй, йорт, *ишег алды* – өйалды, *йырт* – ишегалды, *пайыт* (< рус. поветь) *асты* – лапас, *кабак* – капка, *нәүрәп* (< рус. погреб) – кар базы, *тымбыр/гылдыр* – диал. *болдыр* – өй алды баскычы, *лаука* – кибет, *дустыган* – су чүмече, *чиличке* (< рус. саночки) – кечкенә чана, *эленге* – тәрәзә пәрдәсе, *цәпе* – чүпрәк, тукыма, *матига* – күмгеч, *чашкы асты* – чынаяк тәлинкәсе һ.б.

Кием-салым: *тәлпәк/тәбәтәй/түбәтәй* – түбәтәй, *бүрке* – бүрек, *кистек* – киез итек, *зыбын* – чикмән, *чолка* – киҗе-мамык оек, *ыркача* (<рус. рукавица) – зур күн бияләй, *түмә* – муенса, *тастар* – кунаклар алдына сала торган озын тастымал, *капут* – күлмәк итәге бөрештереп куелган, *алынйапма/алйапма* – алъяпкыч, *сөлге* – бит сөртергә, *тастымал* – кул сөртергә, *колак алка* – алка, *кушма* – сарык йонынннан зур палас, җәймә һ.б.;

Хайваннар һәм үсемлекләр: *алаша/ат* – ат, *тай* – колын, *куй* – сарык, *мачы*/мычы – песи, *кычык* – эт, *былан сыйыры* – болан, *пышый/луч* – поши, *дәwә* – дөя, *мурта* – умарта, *әчәт/кучат* – әтәч, *крыйса* – күсе; *айбагар* – көнбагыш, *айу камыры* – гөлҗимеш, *киндераш* – киндер орлыгы, *кечеркән* – кычыткан, *элән* – җитен, *таракан чиклаwыгы* – кедр, эрбет чикләвеге, *туйыралык* – куаклык, *рахман* – әрекмән һ.б.

Табигать күренеше, көн атамалары: *кизләү/тчишмә* – чишмә, *уй* – чокыр, *йырынды* – ерганак, *кигәwен йәшене* – аҗаган, *йага* – чит, чит җир (чужая сторона); *баш кен* – дүшәмбе, *буш кен* – сишәмбе, *чәршәмбе көн*, *атна кич* – пәнҗешәмбе, *җөма көн* – җомга, *атнарас* – шимбә, *базар кен* – якшәмбе һ.б.

## ЭКСПЕДИЦИЯ ВАКЫТЫНДА МӘЛӘКӘС СӨЙЛӘШЕ ВӘКИЛЛӘРЕННӘН ЯЗЫП АЛЫНГАН, ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ЧАГЫЛДЫРГАН МАТЕРИАЛЛАР (СӨЙЛӘҮ ҮРНӘКЛӘРЕ)

**Мөси авылы**. Муса исемле кеше килеп утырган аwылга иң беренче. Монда урман гына булган бит инде. Биж йез (*биш йөз*) йыллыгын уздырдык аwылның.

Йаз башында (*язын*), су аккан wаккытта, йазгы ташу wакытында очта чыга идек, йегетләр кызлар белән. Йар буйлап халык була иде. Зиләйлүкне джырладык, әләнә (*әйләнә*) идек. «Су агыш» ун'ий идек. Икешәр кеше тотынып чыга барасың. Джиңелерәк, безне аwылда тчишмәлекләр, буаны бусалар, күлебезгә су джийыла. Шолай.

*Сөйләүче: Галиуллова Нажия Ярулла кызы (1940).*
*Мәләкәс районы Мөси (Моисеевка) авылы*

**Филипповка.** Иң башта чуwашлар гына торганнар. Аннары татарлар килгәннәр. Самый кечлеләре калган. Бер урамда чуwашлар тора. 25 процент чуwаш, 75 проценты татар монда. Мәктәптә урысча укибыз. 11 класс. Татар теле и чуаш теле факул'татив итеп укытыла. Мәдрәсәдә дин укырга өрәтәләр балаларга. Үлә намазык (*өйлә намазы*) укыйлар да үнгә (*өйгә*) китәләр. Мәчет картлары үләгә җийылалар.

*Сөйләүче: Гиниятуллина Дания Гыйльметдин кызы (1937).*
*Мәләкәс районы Филип авылы*

Тегендә Шыбыр күле, Әwрәл күле. Месигә, Месидән Чермешәнгә барып төшә. Мансур йылгасы бар. Госфунт кыры. Кыруклы кыры – ул бик зур кыр булган. Байныкы бер. Шуннан калган ул. Саланча чуашлар йагында. Аwылда татарлар и чуашлар йәши. Көпернең бу йагыннан китә татар, теге йагында чуашлар. Хәзер буталды инде. Бу аwылга баш Филип чуашы килеп утырган. Чуашлар калган теге йакта. Татарларны куганнар, кибла йагы, диләр. Аларны чиркәүләре бар иде. Ул чиркәүдән клуб йасадылар. Мәчетләребез элгәредән. Өᵞч мәчет булган.

*Алаутдинов Зыяфутдин Зыятдин улы (1935),*
*Мәләкәс районы Филип авылы*

**Атнагыл.** Мәцетебезгә 26 йыл. Атнагылда дөᵞрт мәцет иде. Иң оцта бар иде. Кара мәцетне клуп йасаттырдылар. Касын ышкулга алдылар. Шулай итеп мени (*менә*) бу мәцет кенә калган иде. Бу мәцет искерде дә бетеп торды. Аның урнына мени йаңа мәцет салдылар. Азат хатында сигезән сигезенце йылларда кил-

де дәресләр, унике килде. Һәрберсен йазып өрәнә бардым. Арәп (*гарәп*) йазуын.

*Сөйләүче: Гайнуллина Гилҗиһан Идиятулла кызы (1938). Мәләкәс районы Атнагыл авылы*

**Тормыш юлы...** Китапларны алып калды, мәцетләргә таратырбыз дийеп. Китаплар көᵞп. Бу аwылда тудым. Үстем. Бер каа да китмәдем. Сеңелем тумыйца калган иде әтәй сугышка киткәнде. Ул 42 нце йылны апрелдә туды. Әтәй сугыштан кат'алмады. Әнәй белә генә үстек. Эшәргә (*эшләргә*) туры килде. Сикез йәштән үк. Бозаулар карадым фермада. Йегерме йеде йыл пучтал'он булып эшәдем. Стажларым көᵞп булды. Биж бала иде. Цегендер дә утый идек элгәре. Мендый җиләкләр йыйып кайтырга да элгерә идек.

Урманга озатканнар иде. Урманнан кат'а идек тә. Туры клупка. Аннан туры урманга. Дойаркаларны урманга ызатканнар бит фирмага. Фирмеда тегел идек әле, актыккы йылларда гына фирмада булдык. Без биж йыл буйы Чирмешән буйында салашта кунып тора идек. Агачтан йасалган, куаклар белән каплангган. Чирмешән Мәләкәстән агып килә. Шунда сәбакайлар (авыл исеменнән) да бар иде. Йырак тегел. Сәбакай татар аwылы. Анда бара идек. Алар безгә. Күп такмак әтә идек. Рамайны, Сарманны йырлый идек.

*Сөйләүче: Гайнуллина Гилҗиһан Идиятулла кызы (1938). Мәләкәс районы Атнагыл авылы*

**Бизәнгечләр, киемнәр.** Элгәрегеләр акча кебек тәңкәләр такканнар чәчләренә. Әнәйләрнең әнәйләре шулай такканнар алар. Колакка колак алка, мун'га түмә, кулга беләзек такканнар.

Көᵞлмәкнең итәкләре – капут. Өстә, йубкага да йасыйлар. Йубка киңрәк прәшкә, мени берештереп куйасын. Ул капут була.

Сарык йоныннан шәл бәләүчеләр шәл дә бәлиләр иде. Сарык йоныннан кистек (*киез итек*). Бәләкәйенә кистек калушы, диләр. Зур булса, кистек дисен. Кулга пичәркә. Куфайкы кигәннәр.

Кайыннын кайырысын кайыралар. Аны су буйына тешерәләр. Анда мунчалага әләнә. Аны судан алалар да мунчаласын алалар.

Чабата йасыйлар. Йеп белән эләктерә. Төшмәстән (*төшмәскә, төшмәс өчен*).

*Сөйләүче: Гиниятуллина Дания Гелметдин кызы (1937).*
*Мәләкәс районы Мөси (Моисеевка) авылы*

Цитекләре әнәйләрнең бар иде. Ак кө$^{Y}$пертмәле шәлләр дә. Зур кызлар булгац инде, әнәй биреп йөри иде аларны. Кө$^{Y}$пертмәле шәл дибез – ул йефәкнеке. Цыганнар (*чегәннәр*) кө$^{Y}$пме сорадылар моны күргәц.

*Сөйләүче: Гайнуллина Гилҗиһан Идиятулла кызы (1938).*
*Мәләкәс районы Атнагыл авылы*

Киндер сукканнар, эрләгәннәр. Аны йомшартканнар да, каба төптә арчып, йон белән эрләгәннәр. Киндерашны ашыйлар иде. Кыздырганнар да. Бүсер сыны йасап ашаталар иде. От грыжи.

Сарык йонынннан кушма да йасаганнар. Йонны тетәләр дә җәйәләр, су белән кистек йасаган кебек әләндерәләр. Ул үзе йабыша. Аны идәнгә җәйәләр. Әле мәйет тереп йерибез. Шундыйга безнең кушмабыз бар. Ул мәчеттә тора.

*Сөйләүче: Нуруллова Рушания Сафиулла кызы (1934),*
*Хайретдинова Роза Шайхетдин кызы (1942).*
*Мәләкәс районы Филип авылы*

**Балага исем кушканда.** Хет мулла бабаймы, укыганнар бар иде. 11 кешегә бүленеп бирелгән. Алын-артлы (*аллы-артлы*) укыйлар. Корәнне 11 бабай укий иде. Йәшә (< *дәшә – чакыра*) идең дә аларны. Элгәре бабайлар бар иде. Бар да искечә укилар иде. Укыганнарга садака бирәләр иде.

Бала баш очына коран китабы куйганнар. Чәпедән (*чүпрәк*) йүләгәннәр (*текәннәр*). Ул олан баш очында тора. Кайбер бала пәрәнзә (*пәрәнҗә*) белән туа. Күлмәктән туган, диләр. Тугац кына аны ацып алалар. Йуалар, киптерәләр. Саклап торорга кирәк. Бетенесен үдә үзем таптым. Кендек әби килгәнце үзем таба идем. Пәрәнзә белән туган бәхетле бала була, үмерле (*гомерле*) бала була.

**Сөннәтче бабай**. Мокшы Күленеке Гезәйер бабай килә иде, сөннәтце бабай. Оланнарны (*балаларны*) тытып тора идек. Дубовый прошок сибә иде. Сары прошок.

**Мәет юуу**. 45 йәшләремнән башкарып йерим, йуам. Әле аwылныкын гына тегел, күрше аwылларга да башкарып йерим. Кәфенен дә кисәм. Йәштән өрәнгән идем. Мәйетнеке дуwаларын белергә кирәк. Хатын-кыз эцкә, зирәткә, керегә йарамый.

**Су хуҗалары**. Йаңгыр булмаган йылда апа Ленинградтан килгән иде. Бик хутлы жар иде. Куак төбенә цыгып укыгыз әт'-тем. Шул куак йанында әбиләр укыды.

Йаңгыр булмаган йылларда йаңгыр теләге дийеп кизләү янына барып укилар иде. Шунан соң кат'ып йетәлмиләр иде – йаңгыр йаwа иде. Бучкаларга су тутырып, үләргә (*өйләргә*) кереп су да сибешкәннәр.

*Сөйләүче: Гайнуллина Гилҗиһан Идиятулла кызы (1938).*
*Мәләкәс районы Атнагыл авылы*

**Ризыклар.** «Чумара». Менә шулай нәзек кенә җәйәсең. Аннары кискәләсен. Катыктан чумара эшлисен. Кемнең катыгы бар – катыклый. Ашыңа катык саласын.

«Кабартма». Без элгәре үләм (*үлән*) ашап үстек. Какы, кузгалдак, мачы бырчагы, әрехманның кепчәсен ашадык. Туңган бәрәңгене әтмим дә инде. Аны киле белән шолай түwәбез. Киленең эче куш (*куыш*). И кабартма йасыйсын. Элгәре плита бар иде, пич иде. Шонда плита өстендә кабартма пешерәсен.

Өстенә йагып теге пәрәпәч тә пешердек. Өстенә йагасын. Йә бәрәңге йагасың. Йә тары буткасын сыйыграк йасап. Итле пәрәпәч тегел бу. Кабартма да дийә идек аны. Кимак, йука, кош теле, пирук һ.б. дә пешерәбез.

«Әпәй». Киндераш туже әпәй салып. Аны тирмәннән. Кул тирмәне бар иде. Аның белән тарттырасын да кап-кара әпәй була. Киндер заводы бар иде. Материаллар чыгаралар. Шунда ташыдык. Киндернең үзеннән тегел, аның үләменнән, сабыннан.

«Чигелдәк». Раштуада чигелдәк (*бавырсак*) пешерәләр. Әле дә бар ул. Ул чигелдәкне үзебез дә кабабыз. Терлекләргә кысыр

калмасын дип, сыйырга бозау кирәк, сарыкларга бәрәннәргә кирәк. Сыйырга берне генә, сарыкка икене каптыралар, ике бәрән бәрәннәсен дип. Аларны әле дә эшлибез. Элгәредән калган. Әнәйләр сүли иде. Тирес туннар кийеп әләндереп йериләр раштуада. Кылындыртып.

*Сөйләүче: Гиниятуллина Дания Гыйльметдин кызы (1937). Мәләкәс районы Мөси (Моисеевка) авылы*

«Кәлҗемә». Элгәре атны суйалар иде. Тайлар. Сугым ите. Үгезме, танамы шу(л)арны суйабыз. Эцәкләреннән кәлҗемә дибез. Баwырын мысаруфка аша цыгарып үwәләр, тәмне була. Суганын, кишерен жарит' итәләр дә. Баwыр үзе коймак кебек кенә пешә. Катлау-катлау кишере белән суганны куйасың да сөртә барасын. Бу хутка кисеп-кисеп. Чече камырдан тәмне генә майда камырында йасыйсын. Бәрәңге белә масаруфка аша цыгарган эцәкне. Пешерәсен дә пирожки шикелле. Бездә ул кәлҗемә атала.

«Саwымнар» йасый идек. Туйга алып барасың каз, пирук, кош теле, чакчак. Мыни шундыйлар. Ул саwым атала. Аны туйга алып барганнар. Йегет йагы үзенә. Йегет йагы бал алып килә. Ә кыз йагы чакчак пешереп барабыз. Без дә кош теле дибез. Баwырсак. Майда пешерәләр пиражки, йезем куйабыз эстенә.

*Гайнуллина Гилҗиһан Идиятулла кызы (1938). Мәләкәс районы Атнагыл авылы*

Пешерәбез: чумара, бәлеш, пәрәмәч, пируг, мантый. Йуканы әнәйләр пешерә иде. Әле кош теле пешерәбез. Бездә дә чәкчәк дибез. Баwырсагы зуррак, чәкчәге кечкенә. Кагытны (*как*) элек Рушан әбийең йасыйдыр (*йасый*) иде.

*Сөйләүче: Алаутдинова Наиля Вәлиулла кызы (1938). Мәләкәс районы Филип авылы*

**Уйыннар, йолалар.** «Чижу». Без бит мишәр – каты сүлибез. Хазер сүлим: качыш, туп бәрү ун'ий идек. Малайлар чижуны ун'ий иде. Сүwәк (*сөяк*) табалар иде дә палка куйалар иде. Аны сугып агдарыга (*аударырга*).

«Түгәрәк» уйный идек. Утырта идек барсын да. Аларны башларына сугып йери идек. Кем круг әләнеп килеп дҗитә, шул оланга. Кем эләкми – шул көтүтче кала иде. Аwыл эчендә уный идек.

«Кызлар дҗыйуы». Үләрдә кызлар дҗыйа идек. Кертмибез йегетләрне. Тәрәзәдән кыш көне булса, аны өреп-өреп безне карыйлар. Йырлый идек. Ашарга пешерми идек. Болай гына.

«Казлар үмәсе». Казлар үмәсендә (*өмәсе*) йолка идек. Китчен килә иде кызлар йанына. Ашыйлар шунда. Хозаин пешерә иде. Казлар йолккан төштә куна идек. Казларны күл буйына бара идек. Чәйкәргә йолккачтан (*йолыккач*). Куйан күленә.

«Черек бәрәнге, башак, киндераш, айбагар җыйыш». Элгәре колхозда черек бәрәңге җийырга бара идек. Кечкенә чакта. Кырга баргач, дҗырлый идек әле:

*Әнәй, мине сагынсагыз,*
*Тәрәзәдән карагыз.*
*Колхуз бәрәңге бакчасында*
*Азап чигә балабыз, дийеп.*

Айакка кийәргә йук. Куллар өши. Шулай йырлап-йырлап. Башак җийарга бара идек. Анда кәлтәләр була. Киндерашның орлыгын түwә идек. Киле беләң. Айбагарны (*көнбагыш*) да киле белән түwә идек. Тирмән тарттыра идек. Кул тирмәне бар иде, кинилар. Ын кебек була инде. Элгәре түwәләр дә тегендә йырлап йебәрәләр.

«Йаңгыр келәүе» йасыйлар. Кырда трактористларга столовой бар шунда пешерәләр. Ашаталар. Утырып укыйсың. Мулла азан әтә. Су сибәләр шлаңгыдан.

«Ызбага күчкәндә йасин укыту». Әтәйләр-әнәйләр белән теге урамда тора идек. Давай ызбага йасин укытырга кирәк, диде. Дҗиде бабай кирәк укырга үгә. Санап йердем. Йәшеп (*чакырып*) чыктым аларны. Дҗиде бабай йасин укыйлар парәләп. Элке шулай иде, йаңа ызбага күчкәчтән.

*Сөйләүчеләр: Алаутдинов Зыяфутдин Зиятдин улы (1935),*
*Алаутдинова Наиля Вәлиулла кызы (1938),*
*Насирова Мөслимә Гафиулла кызы (1949).*
*Мәләкәс районы Филип авылы*

«Шырпы салу». Мени утырасың да барын да рәттән. Берсе чыга да ул шырпы салып йөри. Кем шырпы сала, ул тиз генә чыга да тагы тытына салырга да и анан суң әләнә, әләнеп ун'ый.

«Су агыш». Мени ике кеше кул күтәреп басалар. Бер кеше алында менеп басып тора. Чыга да мени мондагы кешегә тотына. Тагы теге алындагы кеше ала да тагы чыга да монда баса. Су агыш была бу.

«Кызлар дҗыйуы». Уйыннары элгәре ызбада уйный идек. Аннары соң гына клупка йөри башладык. Кызлар дҗыйуы дип әтә идек. Малайлар килә. Алар туже унийлар. Ашау йук. Кем кемне йарата, үгә кат'ырга тузган чакта (*өйгә кайтырга ашыкканда*), сине йараткан кеше килә йаныңа. Үгә кат'абыз.

«Су теләге». Йаңгыр йаумаганда су теләге йасилар. Анда кырга чыгалар да, пешерәләр. Барсын да ашаталар. Дҗыйыла халык. Шунда эстеңә су да сибәләр. Анда ачуланыш йук. Плов, аш та пешерәләр. Базны казилар иде дә и казаннар куйалар. Кырдук шунда. Үләрдә пешермиләр.

*Сөйләүче: Гиниятуллина Дания Гыйльметдин кызы (1937).*
*Мәләкәс районы Мөси (Моисеевка) авылы*

«Каз үмәсе» бар. Йөз баш каз. Әбиләрне цәй эцерә инде. Казны сразы гына пискә (*мичкә*) тыга иде дә беренцесен арцып, калганын инде йуып бетергәц, тапый да һәрберенә эләшә. Каптит' итәләр иде. Баwырын-нийен барын да эләшә иде. Әле куна калалар иде. Әбиләр. Әбиләрне йыш йәшә идем шолай. Мушовкадан, Мокшы Күленнән киләләр иде. Әхирәтләрне йәшә идек. Әхирәт кошуы иде. Алар әнәй үлгәц тә килеп йеределәр.

*Сөйләүче: Гайнуллина Гилҗиһан Идиятулла кызы (1938).*
*Мәләкәс районы Атнагыл авылы*

**Туйлар.** Мин мени каршы ызбада (*өйдә*) гына тора идем. Үзем ризалаштым. Аның белән әзрик (*әзрәк*) кенә йердем. Мулла чакырдык актыктан. Әтәй сугышта үлеп калган, бер әнәй генә. Үзебез алтау, күбәү (*күп*). Туй ике көн бара. Беренче көндә, безнең бит элгәре бишәр йорт алалар иде. Туганнарына. Качан

ул йортларга кереп бетәбез. Ә иртә белән, сәәт унга, төп йортка, кийәүгә чыгучы кешенеке атала кыз йорты – йегетнең үенә китәм. Бусагага килен басып тегел, атлап керегә тийеш. Ишек тобенә куфайка куйалар. Урамдук керәсез бит. Куфайка өстенә акчалар бәрәләр (*сибәләр*). Сыныйлар анда. Бу аны басып кереп, айак астыннан аны алырмы, алмасмы килен. Алмаса, йахшы санамыйлар. Килен йахшы булмый, диләр. Алырга кирәк аны. Мендәргә дә бастырганнар. Бал, май чыгаралар шундук, йегеткә дә киленгә дә каптыралар.

*Сөйләүче: Гиниятуллина Дания Гыйлметдин кызы (1937).*
*Мәләкәс районы Мөси (Моисеевка) авылы*

Барып кызны килешәләр. Баш кода килүче була инде. Аннан кыз йагын йәшәләр үзләренә кунакка. Анда туй йагын сүлиләр иде. Ничә пар белән, саwымнар белән килеш (*килү*) бит инде. Йегет йагы кыз йагына китерә бал. Саwымга. Кыз йагы чәкчәк, шул бәлеш инде. Икенче атнаны йегеттә. Йәш килен токмачы була. Саwымнар алып баралар. Үрдәкме, казмы. Йәш килен токмачы кийәү йагында. Кыз анда булгач. Җиде йорт алып китә. Сүләшәләр ничә пар белән. Үдә уздырырга. Бирнә бирәләр кода-кодагыйга. Күлмәклек.

Элке орласалар да торганнар. Тора-бара йарата. «Ир йаратмаса – туза (*тузына*), кыз-хатын йаратмаса – түзә (*чыдый*)».

*Сөйләүчеләр: Хәйретдинова Роза Шәйхетдин кызы (1942),*
*Нуртдинова Гөлләр Хәтимулла кызы,*
*Нуруллова Сәрия Җәмил кызы.*
*Мәләкәс районы Филип авылы*

Йөрмәле мәтәм, атаң-анаң да белмидер минем арттан йергәнеңне. Сыйыр саwып беткәц, цыгып барам кат′ырга дийеп. Монда йахшы тегел, сүләшик әле, ди. Аның аты булган. Бер йегетне алып килгән. Алучыга баручы дип әт′кән иден, алырга килдем, диде дә утыртты да китте атына шолай итеп.

Беренце атнаның җома кенне тотыналар иде: беренце йазылышасын, төшкә генә ник′ах укырга бабаң килә. Аннан соң

картлар килә, аннан киләдер (*килә*) кодалар. Картлар икенце кенне шул кодалар дибез бит инде. Картларны йәшәсең. Кода килгән һәрберсе йәшә. Берсенә атна сайын, берсенә атна сайын йәшә. Унике кода иде. Аннан соң тотона йәшләр.

*Сөйләүче: Гайнуллина Гөлҗиһан Идиятулла кызы (1938). Мәләкәс районы Атнагыл авылы*

Йомгаклап шуны әйтер идек, сөйләм үрнәкләрендә күренгәнчә, Ульяновск өлкәсе татарлары әби-бабалары тапшырып калдырган, милләтебезгә хас йолаларны, гореф-гадәтләрне ихтирам итеп, туган телләрендә аралашып гомер кичерәләр. Алга таба да гаять әһәмиятле һәм матур яңгырашлы татар телебез сакланып калсын иде.

Гомумән, татар әдәби теленең үсешендә көнбатыш (мишәр) диалекты мөһим урын алып тора. Әдәби тел үзенең фонетик һәм лексик төзелеше белән урта диалектка якын торса, аның морфологик төзелеше күбрәк мишәр диалектына нигезләнә.

Көнбатыш диалектның башка сөйләшләрендәге кебек, хвалын, карсун, мәләкәс сөйләшләрендә дә сүз төркемнәре һәм аларның төп грамматик категорияләре, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Үзенчәлекле саналган морфологик билгеләрнең күпчелеге теге яки бу морфологик категориянең яки күренешнең төрле фонетик вариантлары булудан гыйбарәт. Биредәге сөйләшләрнең үзенчәлекле билгеләре күбрәк фигыльләр өлкәсендә күзәтелә.

Татар теленең көнбатыш сөйләшләре лексик һәм фонетик яктан бер-берсеннән бик аз аерыла. Әдәби телдә очрамаган, сөйләшләрнең спецификасын тәшкил итә торган сүзләр шактый гына булса да, көнбатыш диалектының төп лексик составын татар әдәби теле белән уртак сүзләр тәшкил итә. Фонетик һәм грамматик үзенчәлекләрендә дә шундый ук күренеш саклана.

# КАРСУН СӨЙЛӘШЕ ТУРЫНДА КАЙБЕР КҮЗӘТҮЛӘР

*Дария Рамазанова*

1969 елда Ульяновск өлкәсенең Карсун тирәсендәрәк урнашкан авылларында булырга туры килде. Аларның сөйләш үзенчәлекләрен өйрәнү белән беррәттән, магнитофон тасмасына күпсанлы җырлар, легендалар, бәетләр язып алынды. Без булган Инза районының Тат. Гуринка, Драка, Нугай иле, Шлемасст авыллары революциягә кадәр Корсунь өязенә караган булган. Мордва республикасының Дубенки районындагы – Ламай, Кочкур районының – Татар Ымызы, Пенза өлкәсенә караган Лупино районының Шыкша авыллары да шушы төбәктә урнашканнар. Көчле дәрт, шашып сөюне чагылдырган, нечкә хисләр бөркелеп торган җырлар безнең күңелгә бигрәк тә тирән уелып керде. Ул җырларда халыкның көчле рухы, бай хисләр дөньясы тоемлана. Авыз иҗаты әсәрләрендә чын халык тормышы чагылуына торган саен ныграк инана барасың.

Мишәрнең рухи халәте гасырлар буе чарланып килгән. Аларның ерак бабалары – куманнар тормыш-көнкүреш үсеше ягыннан шактый күренекле халык булган. Алар Европа илләре белән сәүдә иткәннәр. Аралашырга җайлырак булсын өчен, аларның телен чагылдырган тәрҗемә сүзлек тә төзелгән булган. Бөтен тел белеме дөньясында танылган бу мәшһүр сүзлек 1303 елда басылган һәм «Кодекс Куманикус» (Codex Cumanicus) дип аталган.

Соңрак мишәрләрнең тормыш-көнкүреше Рус дәүләте тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Алар русларның көньяк күршеләре булып торганнар, тора-бара бу дәүләтнең көньяк чикләрен даладан килүче баскыннардан саклау хезмәтенә керешкәннәр. Тарихта билгеле булганча, Рус дәүләтенең көньягында чик саклау өчен күтәртелгән сыртлар ясалган, алар агачлар белән ныгытылган. Сыртның тышкы ягында канаулар казыганнар. Билгеле ераклыкта ныгытмалар төзелгән. Менә шушы чик саклау сызыкларында, башка халыклар белән беррәттән, мишәрләр дә хезмәт иткән. Шулай итеп, дошман яуларының, баскынчыклар һөҗүменең иң каты көчен мишәрләргә беренчеләрдән булып татырга туры килгән.

Рус дәүләтенең чикләре көньякка һәм көньяк-көнчыгышка таба киңәя бара, яңа ныгытмалар, чик сызыклары төзелә, аларга мишәрләр һәм башка халыклар күчерелә тора. 1571 елга хәтле үк Рус дәүләтенең көньяк чигендә Ряжск Шацк – Темников – Алатыр линиясе булуы мәгълүм. Бу ныгытылган шәһәрчекләр Мокша һәм Цна елгалары бассейннарында урнашкан. Көнбатыш диалекты турында зур һәм җитди хезмәт язып чыккан телче галимә Л.Т. Мәхмүтова бу бассейннарны мишәрләрнең борынгы төп яшәү урыннары булган, дип күрсәтә. 1635–1646 елларда Алатырка – Белгород – Воронеж – Тамбов ныгытылган сызыгы төзелә. Аларга Шацк һәм Темников мишәрләре күчереп утыртыла.

1648–1654 елларда тагын да көньяккарак «Тамбов – Мокшанск – Саранск– Корсунь – Симбирск» сызыгы барлыкка килә. Корсунь (халык телендә: Карсун) төркеме авылларының килеп чыгуы да шушы вакыйгалар белән бәйле, ягъни бу авыллар XVII гасырда ук барлыкка килгәннәр, аларга Темников, Алатыр, Кадом тирәләрендәге йомышлы татарлар күчереп утыртылган. Чама белән шул еллардан алып яшәп килә Карсун тирәсендәге татар авыллары. Сөйләүләренә караганда, Карсун тирәләрендә тагын Әстерхан, Кырым якларыннан килгән төркиләр катнашкан. Казан татарлары, Карсун сөйләше өчен характерлы күренешләрнең килеп чыгышы шуның белән дә бәйле булырга мөмкин (*җ*-ләштерү, *ч*-ләштерү, *итәслек* – житәрлек;

җырларда Агыйделнең актив кулланылуы һ.б.). Карсун төркеме авылларының сөйләм телендә урта диалектка хас үзенчәлекләр, кайбер башка күренешләр дә табылу әлеге авыллар тарихында хәзергә ачылып бетмәгән сәхифәләр дә булу турында сөйли.

Менә шундый аяныч та, хәвефле дә, һәлакәтле дә булган тарихи вакыйгаларда чарланып ныгыган мишәр туганнарның рухы. Ирекле яшәргә теләгән көннәре дә күп булган аларның. Мәсәлән, Шар′ук качкын турындагы җырның киң таралуы шул турыда сөйли.

Карсун сөйләше Ульян өлкәсенең ерак почмагында урнашкан, мәсәлән, мәләкәс, хвалын сөйләшләреннән аерылып тора, шуңа күрә биредә сөйләшнең үзенчәлекләр системасын мөмкин кадәр тулырак бирергә теләдек. Л.Т. Мәхмүтова сөйләшне мөстәкыйль сөйләш булып җитмәгән, дип саный. Ул вакытта сөйләш әле өйрәнелмәгән булган. Бу юллар авторы Д.Б. Рамазанова махсус экспедиция оештырып өйрәнгәннән соң, әлеге төбәк сөйләшенең шактый чуар икәнлеге ачыкланды. Чуарлык исә бу төркемнең читтәрәк урнашуы, башка этник элементлар да катнашу белән бәйләнгән. Тел үзенчәлекләренә игътибар итик.

**Фонетик үзенчәлекләр.** Көнбатыш диалекттагы сузык авазлар үзенчәлекләре – *а* авазының ачык, иренләшмәгән варианты, *ә* һәм *у* авазларының югарырак күтәрелешле һәм алгырак позициядә ясалышлы булулары – карсун сөйләшенә дә хас.

Сузыкларга кагылган башка үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә, төрле позицион күренешләргә кайтып кала.

э (е)~ә: *ускенчә* – үскәнчә, *килгенчәк* – килгәнче; ы~а: *кагыз* – кәгазь, *йаңы* – йаңа (яңа), *Сыры* – Сура (елга ис.) һ. б.; э (е)~и: *энеч* – инеч, *деңгез/меңгез* – диңгез.

ә~и: *шәкәр* – шикәр, *кәм* – ким, *кәмеде* – кимеде, *чәгәрту* – чиктерү; бер төркем рус алынмаларында: *сәстра* – сестра, *пәнүк* – пенок, *пәсүк* – песок, *пеләчә* – плечо, *пеләмәннек* – племянник; и~ә: *әзрик* – әзрәк.

и~ы: *йасмик* – йасмык, *ахыр'и* – ахрысы, э (е)~ү: *тегел* – түгел, *у~о* (рус алынмаларында): *кину* – кино, *килу* – кило, *митру* – метро; о~у: *пох* – пух, *корка* – күркә, *койу* – кую; *ө~ү:*

*төбә* – түбә, *көп* – күп; ү~ө: *бүгә* – бөгә; ы~у: *йыwача* – йуwача (юача – камыр ашы); *шылай* – шулай, *ыл* – ул һ.б.

-ыб~-уw: *чыбалту* – чуwалту (чуалту), *чыбан* – чуwан (чуан).

-ыw~-уw: *сыwык* – суwык (суык), *йыwарга* – йуwарга (юарга), *хуwатлы/хыwатлы/хыватлы* – куәтле һ.б.

-ев/-еw~үw: *йевеш/йеwеш* – йүwеш (юеш), *тевен/теwен* – түwен, төйен (төен), *кевәндә/кеwәндә* – күwгәнтә (көянтә) һ.б.

и~ү: *күзләү* < *кизләү* – чишмә, *күсәү* – кисәү; у~и: *сибагач* < диал. *субагач* – чабагач.

Иренсезләшү: *сет* – сөт, *керәш* – көрәш, *бегә* – бөгә, *келке* – көлке һ.б.

Алгы рәт сузык белән булган фигыльләрдән соң килгән *алу* ярдәмче фигыле нечкә вариантта әйтелә: *керәлми* – керә алмый, *йерийәлмимен* – йөри алмыйм, *бирәлмәгәннәре* – бирә алмаганнары һ.б.

С у з ы к л а р   г а р м о н и я с е бозылу очраклары күзәтелә: *атәләр* – әйтәләр, *дәру* – дару, *адәм* – әдәм һ. б.

Арткы рәт авазларына алгы рәт сузыклары тәңгәл килү: *Мәйсәрә* – Маһисара, *әләсә* – алайса, *бәлчек* – балчык һ. б.

Киресенчә, алгы рәт сузыкларына арткы рәт сузыклары тәңгәл килү: *шиша* – шешә, *эстэна/ыст'ана* – стена, *Мачтура* – Мәчтүрә, *корка* – күркә, *мый – ми* һ.б.

А в а з л а р   т ө ш ү, у: *сак* – усак, *марта* – умарта; *ы-е: кырк* – кырык, *ирк* – ирек, *бүрк* – бүрек һ. б.; *ә: тәрәз* – тәрәзә.

А в а з   ө с т ә л ү, е: *йеретә* – йөртә, *эшешенә* – шешенә.

Дифтонглар, *-өй* дифтонгы, нигездә, монофтонглаша: *сүминчә* – сөймичә, *үлә вакыт* – өйлә вакыты, *үләндерү* – өйләндерү һ. б.

Сузыклар алдында -үw-еw/-ев~өй: *эwә/эвә* – өйә (өя), *кевәндә/кеwәндә* – көйәнтә (көянтә). ө~өй: *өрәнү* – өйрәнү.

*-ай/-әй* дифтонгының сүз азагында тараю очраклары теркәлгән: *малый* – малай, *шылый* – шулай.

Тел очы *л, н, р, д, т, с, ч* тартыклары алдындагы *-ай/-әй, -ой, -уй* дифтонглары монофтонглаша, ә күрсәтелгән тартыклар нечкә вариантта әйтелә: *бат'ал* – байтал, *кан'ар* – кайнар, *ат куригы* – ат койрыгы, *ат'а*– әйтә; *кас'ы* – кайсы, *качы* – кайчы (с, *ч* тартыклары йомшармаска да мөмкин).

Алгы рәт сузыкларыннан торган сүзләрдәге *-әй* дифтонгында *й* төшә: *әләсә* – алайса, *бәләгән* – бәйләгән, *әтми* – әйтми, *әрән* – әйрән.

Сүз азагындагы *-ый* дифтонгына *ы, и* монофтонглары яисә *ы*$^{й}$*, и*$^{й}$ дифтонгоидлары тәңгәл килә: *тугий/туги*– тукый, *тары*$^{й}$*, тарий/тар'и* – тарый, *Бары* – Барый һ. б.

Т а р т ы к  а в а з л а р әйтелешендә түбәндәге үзенчәлекләр бар.

*ч* авазы көнбатыш диалекттагыча кушык аваз, тик аның әйтелешендәге шартлау элементы шактый көчсез, язуда аны $^{т}$*ч* рәвешле күрсәтеп була: $^{т}$*чә*$^{т}$*чле* – чәчле, *ага*$^{т}$*ч* – агач, *э*$^{т}$*ч* – эч һ. б.

*ч* авазының яңгырау пары *җ* авазы да берникадәр шартлау элементы белән әйтелә: $^{д}$*җымакен* – җомга, $^{д}$*җиткәннәр,* $^{д}$*җизнәсе,* $^{д}$*җитәслек* – җитәрлек һ.б.

*к, г, х,* авазлары, көнбатыш диалекттагы кебек үк, тел арты авазлары итеп әйтеләләр: *кагау* – тилгән, *кыйы* – кое, *кайгы, хал* – хъәл' (хәл) һ. б. ш.

Палаталь *л', р', н , д'* тартык авазларын куллану очраклары бар: *ачл'ик* – ачлык, *н'ур* – нур, *ад'аша* – адаша, *Мобар'ак, Ахс'ан, йар'ен* – йарын (ярын) һ. б.

Калган үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә, төрле комбинатор үзгәрешләргә кайтып кала.

Ирен-ирен *б* авазына *м* тәңгәл килә: *мере* – бөре, *ман* – белән.

*в~w* шактый актив: *кеwе/кеве*– көйе (көе), *түләwен/түләвен* – түләвен, *аwыл/авыл* – авыл һ.б.

бд~пт: *ибдәш* – иптәш, *абдырау* – аптырау; б~п: *Зәйнәб* – Зәйнәп. д~т: *ачкылдым* – ачкылтым, *дыны беткән* – тыны беткән, *эрәде йук* – рәте юк, *арышның пыды* – арышның поты һ. б.

п~ф: *керпек* – керфек, *йапрак* – йафрак (яфрак), *йебәк* – йефәк (ефәк), *кәләмпер* – канәфер, *пирма* – ферма, *шипер* – шифер. Шулай ук *ф* авазы үзе дә сөйләштә шактый еш күзәтелә.

н~ң: 2 нче зат хикәя фигыль һәм иялек килеш кушымчаларында күзәтелә: *аласын* – аласың, *карарсын* – карарсың, *күрәсен* – күрәсең, *синең/синен* – синең, *аның/анын* – аның, *кешенен* – кешенең һ.б.

ч~с (рус алынмаларында): *чимйә* – семья, *читса* – ситсы, *чилнек* – сенник, *чилезин* – селезень, *wылач* – власть; шулай ук: *чәчәк*– сәнәк.

с~ч очраклары төрле сүзләрдә һәм төрле позициядә булырга мөмкин: *баргастан* – баргачтан (баргач), *эс* – өч, *избер* < *исбер* – һичбер, *асты*– ачты, *тез капкасы* – тез капкачы һ. б.

Рус алынмаларында ч~ц: *балнича* – больница, *лиснича* – лестница, *кулча* – кольцо, *купич* – купец, *кырилча* – крыльцо, *гуринча* – горница, *чиркау* – церковь, *макрича* – мокрица һ. б.

Ике сузык уртасындагы *з* авазына өрелмәле *җ* тәңгәл килү очраклары бар: *Аҗиҗә* – Газизә, *Аҗук* – Газизә, *магаҗин* – магазин, *ружа* – руза (ураза), *риҗинка* – резинка, *иҗгелек* – изгелек һ. б.

ң~л *(г* авазы алдында): *йаңгылыш/йаңгыш* – ялгыш, *йаңгыз* – ялгыз.

Бер төркем сүзләрдә ике сузык уртасындагы *к* авазы яңгыраулаша: *тугу* – туку, *тыгырык* – тыкрык, *күгерт* – күкерт, *чугыну* – чукыну, *йага* – йака (яка) һ. б.

Бу күренеш ике сүз арасында да күзәтелә: *бу гыз* – бу кыз, *җитэслег әле* – җитәрлек әле һ. б.

Шул ук вакытта: *сикез/сигез* – сигез, *тукыз/тугыз* – тугыз.

х~к: *хуwатлы/хыwатле* – куәтле, *әхийәт* – әкият, *дихтар* – гектар, *тырахтыр* – трактор, *хардашлар* – кардәшләр һ. б.

Фарингаль *h* авазы әйтелми: *әрбер* – һәрбер, *әркем* – һәркем, *гон'а* – гөнаһ, *әммәсе* – һәммәсе һ. б.

Сүз уртасында *h* авазына *г* туры килергә мөмкин: *Зеерә/Зегрә* – Зөһрә.

Төрле күтәрелешле сузыклар арасында й~һ: *Мәйсәрә* – Маһисара, *зийен/зийн* – зиһен, *Җийанша* – Җиһанша һ. б.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр. w~б: *wәке* – бәке; н~м: *агын* – агым; н~д: *алны* – алды; ч-ж: *күк чәйәсе* – күк җәясе (салават күпере), *ченаза* – женаза; **з-д:** *изән*– идән; р~й: *әрбер/әйбир/әрбир* – әйбер; н~л: *шауный* – шаулый; с~р: *йитәслек* – җитәрлек; г~й: *чигәли* – чийәләй (чиялэй); мд~мн: *шәмдек* – шәмнек – шәмдәл; д~г: *дихтар* – гектар; г~н: *чыргый* – чырный; к~т: *йикмеш* – җитмеш; к~г: *кәрәбә* – гәрәбә.

А в а з   т ө ш ү. Тамырлары *р* авазына беткән фигыльләргә *-ыр/-ер* кушымчалары ялганганда, кушымчадагы *р* төшә: *барыга* – барырга, *кересез* – керерсез, *барысыз* – барырсыз һ. б.

Ике сузык арасындагы *г* авазы редукцияләнә һәм төшә: *ышамаан* – ошамаган, *сәәт* – сәгать һ. б.

Икеләтелгән тартыклар кыскара: *мынан* – моннан, *китмәсен* – китмәссең һ. б.

Гарәп-фарсы алынмаларында сүз башындагы *г* авазы төшә: *Айша* – Гайшә, *Аҗиҗәкәй* – Газизәкәй, *умер* – гомер, *айып* – гаеп һ. б.

Тел очы тартыклары алдындагы сонорлар төшә: *күсәтеп* – күрсәтеп, *муча* – мунча, *йугату* – йугалту (югалту), *аткыры* < арткыры – аркылы, *мысы* – монысы, *чәчү* – чәнчү һ. б.

Кайбер сүзләрдә сүз башындагы *й* төшә: *эләк* – йеләк – җиләк, *ирәпеч* – йирәнеч – җирәнгеч һ. б.

А в а з   ө с т ә л ү. Сүз башында сузыклар алдында *й* өстәлә: *йөзә* – өзә, *йындыр* – ындыр; *ң: калаңкул* – колокол; *ди* фигыленә *р* өстәлү: *дышман буласың дир* (ди).

*Сигезән* (сиксән), *тугызан* (туксан) сүзләрендә этимологик нигез саклана.

Сүз азагындагы *ч, ш, с* авазлары сузыкларга, янгырау һәм *й* тартыкларына башланган сүзләр алдында яңгыраулаша: *биҗ йыл* – биш ел, *эҗ йез* – өч йөз, *эҗ бала* – өч бала, *чырыж йук* – чырыш йук – чыршы юк, *избер* < *исбер* – һичбер һ. б.

М е т а т е з а : *кымрыска* – кырмыска, *элке* – элек, *урны* – урын, *ирне* – ирен, *эстәкер* – скатерть, *былгахтир* – бухгалтер, *чырыш* – чыршы, *азбар* – абзар һ. б.

**Морфологик үзенчәлекләр.** ***Исемнәр.*** Иркәләү-кечерәйтү кушымчалары, мишәр диалектындагы кебек үк, рәт гармониясенә буйсынмаска мөмкин: *әбкай* – әбекәй. *Нәнәкасы* (әбкәсе) чәй эчерә.

Кеше исемнәре кыскарып, *-ый/-ий, -ук/-үк, -ч/-ш* кушымчалары алырга мөмкин: *Кәлүк бабай* – Хәлиулла бабай, *Мерәй* – Миркасыйм, *Кал'мәй* – Кәлимулла, *Ибен ук* – Ибнеәмин, *Рамка* – Рамазан, *И мал'* – Гималетдин, *Исмук* – Исмәгыйль, *Ибрүк* – Ибрай, *Хал'ук* – Хәлил, *Дил'ок* – Диләфрүз һ.б.

Бер төркем сүзләргә икеләтелгән тартым кушымчасы ялгана: *катнысы* – хатыны, *кирәгесе йук* – кирәге юк. *Чыкканысы* (чыкканы) *үлә дә бетә бәпкәләрнең. Кийәү чигелдәге* (чәкчәге) *була вагысы* (вагы). *Сет бар иде дә, чәйгә алган идем эстесен* (өстен).

Абстракт нисбәтлекне белдерә торган *-ныке*/*-неке* кушымчасы, әдәби телдән аермалы буларак, ачыклаулы мөнәсәбәт оештыра, һәм ул ялганган сүзләр, инверсияләнеп, хәбәр түгел, аергыч булып килә. Мәсәлән: *Апаның йәш килнесе бар, аныкы* (аның) *телен аңгарырга йук* (аңлап булмый). Бу күренеш алмашлыкларда да күзәтелә: *Гырижам бар минеке, аwыр эштән. Ике матка* (матча) *иде минеке, сынды.*

Мондый сүзләргә, нократ, пермь сөйләшләрендәге кебек, өстәмә тартым кушымчасы ялгану очраклары да теркәлгән: *Агачныкысы* (агачныкы – агачтан) *була убыты, түндәге* (тәгәрмәч турында сүз бара).

1 нче һәм 2 нче зат берлек саны төшем килешендә угыз тибындагы кушымчалар белән дә исемнәр ясалырга мөмкин: *Энәме* (энәмне) *кыстырдыңмы анда? Чу инде сүземе бетерийем* (сүземне бетерим). *Мин үз туйымы,* (туемны) *сүләрмен. Апаңы* (апаңны) *кайа йаткырийык?*

***Алмашлыклар.*** Аларның составы, төркемнәре, кулланылышлары әдәби телдәгечә. Сөйләштә кайбер аерымлыклар да күзәтелә.

Зат алмашлыкларын ың составы, төрләнеше әдәби телдәгечә: *Син кенәге кеннеме эзли йерисен, ул үтте вет инде. Безне теп болгарлар диләр.*

Күрсәтү алмашлыклары: бу, теге, шул/шал, менә, ваты/хата/вата/ ватаккынак/ватаккынасы – менә, она/ана/энә – энә, wана– энә, вуни, вунигынак/вуникынак – энә, шылай/шулай, шындый/шундый; бусы/мысы – монысы һ. б.

Мәсәлән: *Бездә вата рагужы тугилар вет, кас'ы кайа китте. Wата кылуптан түбәнерәк кенә тыралар. Бусы wата* (менә) *минем сеңелем. Вата, без тыра тырган урындайы үләре. Она* (энә) *минем сеңелемнеке кызы. Сез байлар вуни, күтәреп тә булмий. Ватаккынак качт'ум аныкы. Берсе ватак* (менә) *шунда тыра. Вуни чалуда йериләр. Ул куйлар бакты, бу заффирмы иде.*

Икеләтә тартым кушымчасы ялгану очраклары күзәтелә: *Кайсысы?* – Кайсы? *Берсе тыра Саратуда* (шәһәр исеме), *вата кайсысы. Пинсәне эстәгәч үлеп тә китәләр касысы.*

Күрсәтү алмашлыкларының урын-ара килешләре карсун сөйләшендә дә *-нарга/-нәргә, -нардан/-нәрдән, -нарда/-нәрдә* кушымчалары белән ясалалар: *Кирпеч көп китте тегенәргә* (тегеңә). *Анардан зурлагы эшкә керде. Мин шынарга кийәүгә киттем.*

Тартым кушымчасы ялганганда, ул, бу алмашлыклары үзгәрешсез кала: *Улсының* (анысының) *малайы учител. Бусы* (монысы) *дайарка тырды йиде йыл, бәрде* (ташлады) *ватаккынасы. Улсы йегерә (*йөгереп) *йери эшләп. Чусынкы, улы була тана калуш белән кийә тырган.*

С о р а у  а л м а ш л ы к л а р ы: *нәрсә/нәстә/ни/нийәстә* – нәрсә, *кайа* – кая, касы/кайсы, *нәгә/ник* – ник, нигә, ничек. Мисаллар: *Нәстә* (нәрсә) *безне сүләтә йериләр. Нәгә әтмисең? Бу нийәстә* (нәрсә), *ник сың җеп белә чырнаган диләр. Вуни* (әнә) *мин ничек сүлимен.*

Б и л г е л ә ү  а л м а ш л ы к л а р ы: *әрбер* – һәрбер, *әркем* – һәркем, *әр* – һәр, *кай/кайсы* – кайсы. Мәсәлән: *Кай йылны бик була эләк.*

Б и л г е с е з л е к  а л м а ш л ы к л а р ы: *нәрсәдер, никтер, каадыр* – каядыр һ.б. Мәсәлән: *Нәнәй нәрсәгәдер йебәрде кеше үтенә. Атаwыны* (курпы) *никтер йаратмый аны терлек. Әле утарга да йуг инде, нәстәдер сибәләр дә, быдайдан бийекләрне кырыта.*

Ю к л ы к  а л м а ш л ы к л а р ы: *берни, ичкем* – һичкем, *бер кайа да*/кайа да; *кем дә* – беркем дә, *избер* – һичбер, *ничек тә* – берничек тә һ. б. Мисаллар: *Малайы берни дә әтмидер. Пеләмәннек ыра ыстансада, бүтән кемем дә йук. Мин кайа* (беркая) *да барганым шук. Йәш килнесенең сүләwен аңгарырга ничек тә йук.*

***Саннар.*** Аларның төркемнәре, грамматик категорияләре әдәби телдән аерылмый. Шуның белән бергә, төп сан урынына җыю саны формасын куллану очраклары бар: *Без сигезәү* (сигез) *үстек, эәҗ бырат, дүрт сеңел, хазер кем дә йук.*

Биредә күп сүзенең дә сан төркемчәләренә хас кушымчалар алуын күрсәтеп үтәргә кирәк: *Безнең бит балалар күбәүләр иде,*

*берсе генә йантыгыбызда хазер. Күбәр измим дә инде, чимйә әз булу белән, әпәй катып китә. Элке вет картуф күбәр чәчә идек.*

***Сыйфат.*** *р* авазына беткән сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе *-рак/-рәк* (әд.), *-лак/-ләк* кушымчалары белән ясала: *Нәнәй, ыланшакны (бала-чаганы) җийыштырып, үзе китте урырга, зурлагыбызны (зуррагыбызны) үдә калдырды. Безнекеләр сукырыраг иде атай да, нәнәй дә. Тырмыш аwырлак (авыррак) аларның. Зурлагы (зуррагы) Тала, кечкенәрәге Ал'ка инеше (елга исемнәре).*

Кайбер очракларда икеләтелгән кушымча ялганырга мөмкин: *Бүтән аwылларда зурлагырак су бар.*

***Рәвешләр.*** Карсун сөйләшендә үзенчәлекле диалекталь рәвешләр табыла: *берсәк* – бераз, берникадәр, *тенәге кенне* – кичә, *кучасы белән* – төркеме белән, *әwәлдә* – элек һ. б.

*-ры/-ре* кушымчасына тәмамланган рәвешләрнең чагыштыру дәрәҗәсе *-лак/-ләк* кушымчасы ярдәмендә ясала: *Wата кылуптан түбәнерәк кенә, балничадан арлак* (арырак) *тыралар. Эчкәрләк* (эчкәрерәк) *ут. Табаннан йугарлак* (югарырак) *тубык вет. Паҗийын* (басасын) *алалар элгәрләк* (элгәрерәк, алданрак), *аны умакка* (киндер көлтәсе чүмәләсе) *куйалар. Килче бирләк* (бирерәк).

Шулай ук: Иртәрләк (иртәрәк) чыгарганнар. Тау артынарлак баргачтан кушак суwы чыга.

*-лата/-ләтә* кушымчасының актив кулланылуы игътибарны җәлеп итә: *Зурн'алата да бирәләр, акчалата да түлиләр. Әле wата сетләтә ташлыйбыз, элке үзем атлый идем. Таба күмәч, чечеләтә пешергән бу, ачылатасы да була.*

Ел фасылларын һәм тәүлек вакытларын белдерә торган сүзләрдән вакыт рәвешләре ясалу, нигездә, әдәби телдәгечә: *Шул чике йогора йери, тене буйы йазыб утыра. Ник тенне* (төнлә) *йерисен? Кичне* (кичен) *кетү кергәндә генә кат'абыз. Кийәү булачак кичне* (кичен) *керә. Кене буйы эшлибез. Кичен* (килеп) *йиттек, иртәсен киттек сабан туйга. Кенезен* (көнозын*) айаг эстән эшлисен инде. Урманда йазын әләк була, кайын әләк. Кем тен ката* (төн буена) *ут калдыра.*

Шул ук вакытта мишәр диалектына хас вакыт рәвешләре дә актив кулланыла: *Бийыл кыш ката* (кыш буе) *урманда. Җәй катага калмыймысыз? Йаз ката* (яз буе) *йери дә суйалар кезне* (көзен). *Кен сәтә* (буе) *эшләдек.*

***Фигыльләр.*** Затланышлы фигыль формалары. Хикәя фигыль. Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең 1 нче зат берлек сан формасы тулы һәм кыска вариантларда кулланыла: *Утны күтәрәмен дә, ник пузда* (соң) *киләсен?*

1 нче зат хәзерге заман хикәя фигыль *-ийым/-ийем (-ыйм/-им)* кушымчасы белән дә белдерелергә мөмкин: *Май ашийымсын?* – Май ашыйсыңмы? *Укийым* (укыйм) *дисә укырга бара. Ни сүлийем, чүп тә белмийем бит.*

3 нче зат берлек сандагы хикәя фигыльләргә һәм шулай ук хәбәр функциясендәге башка сүзләргә *-дыр/-дер* кушымчасы ялганып килә: *Теге җибәреп килгәндә генә кал'усасы чыгадыр да йыгыладыр* (чыга, егыла).

Нәтиҗәле үткән заман әдәби *-ган/-гән* һәм диалекталь *-ып/-еп* кушымчалары белән ясала: *Мужыт әнисен күргәнсездер. Без ун бала булыпбыз* (булганбыз), *әнинеке. Мин унтугызда булыпмын* (булганмын) *инде ул чагында. Анан соң без игез тыwыпбыз* (туганбыз). *Ачыплар* (ачканнар) *тәрәзәне ике йакка. Картайыпсын* (картайгансың) *икән, көптән күрешмәдек.*

Дәвамлы үткән заманның карсун сөйләшендә түбәндәге формалары теркәлгән.

*-а тырган иде: Үзе мунча йарата тырган иде бик.*

*-адыр иде: Сетне сезеп куйадыр идек базга.*

*-а иде* иң актив кулланыла торган форма: *Элке йериләр иде сырарга кызны. Калым диләр иде, акча бирә идек, бәбеч* (читек), *йахшы пал'та да бирәләр иде, бирелмәгәннәре бер күлмәк белә дә калайде.*

*-а/-ә, -ый/-и + булган* (әд. -а/-ә торган булган): *Алар мунчада йыклый булганнар* (йоклый торган булганнар). *Тастар булган, сарыйлар иде, ваты шылай чыргала булганнар* (чорнала торган булганнар).

Тамырлары *-р* га беткән фигыльләрдән ясалган 1нче һәм 2 нче зат киләчәк заман формалары тулы һәм кыска вариантларда килә: *Үзем барымын* (барырмын) *йаныгызга. Хазер кайа барысыз*

(барырсыз). *Алып бирем* (бирермен) *үзегезгә. Мин куй суйдырым* (суйдырырмын) *үзләреннән. Ату йадарсыз* (ябыгырсыз) *да Казанга кире кайтып йитәлмәссез.*

Карсун сөйләшендә 1 нче зат берлек санның юклыгы да тулы һәм кыска формаларда кулланыла: *Кагызын тапмамын, үзегезгә күрсәтер идем. Бармам инде әлдә, дир.*

Теләк фигыльләр *-ыйым/-ийем* (берлектә), *-ыйык/-ийек* (күплектә) кушымчалары белән ясала: *Күрсәтийем* (күрсәтим) *үзеңә күрәннәр, кереп баккайдең.*

Эчке теләк, барлык мишәр сөйләшләрендәгечә, *-кы/-ке + кел-* (әд. *-асы/-әсе, -ыйсы/-исе + кил-)* төзелмәсе белән белдерелә: *Баккысы келәми* – Карыйсы килми. *Алмагачын да асрак кели* (асрыйсы килә). *Сезнең чәйме эчкегез кели, ашакларымы кели* (эчәсегез киләме, ашыйсыгыз киләме)?

Теләк мәгънәсе инфинитив + *кели* конструкциясе белән дә белдерелә: *Берсе Мәскәүдән килергә кели быйыл. Әле кайчан келисез инде китәргә.*

Киңәшле теләк *-гай + иде* + зат кушымчалары төзелмәсе белән белдерелә: *Син сыраб алгайдең, дир – Сиңа сорап алырга иде, ди. Берәр сүз ат'а башласа, ырламагайдең, дир* (урламаска идең, ди). *Чәшкәләрегезгә пәсүк салгайдең, улсыгыз эри тырыр иде. Сал пәсүк, салгай идең* (салырга иде). *Бире утыргай дең* (утырырга иде). *Мине эшемә җибәргайдың, анарга алаша биргайдың* (җибәрергә идең, бирергә идең). *Карттан сырашкайдегез сез* (сорашырга булган сезгә).

Боерык фигыль карсун сөйләшендә, нигездә, әдәби телдәгечә.

Бары тик нәзакәтле кушуны, йомшак кына боеруны белдерү өчен, боерык фигыльгә *-чы/-че* кисәкчәсе ялгануын билгеләп үтәргә кирәк: *Wыт суга килгәч сырачы* (сора әле). *Карачы, кетүwен сергәнме?* – Көтүен куды микән, карасаң икән. *Менче бирләк* – Бирегәрәк менсәң икән.

Тамырлары *к* авазына тәмамланган боерык фигыльләргә 2 нче зат күплектә *-кыз/-кез* кушымчалары ялгана: *Чыккыз* (чыгыгыз), *кулларыгызны йыwыгыз wана. Баккыз, баккыз, күк җәйәсе күтәрелгән* – Карагыз, карагыз, салават күпере чыккан.

Фигыль дәрәҗәләре *-акла/-әклә* (тамыр сузык авазга тәмамланса) һәм *-гала/-гәлә, -гакла/-гәклә/-акла/-әклә* (тамыр азагында тартык аваз булса) кушымчалары белән ясала: *Вич кискәләп бетерделәр. Тугыклибыз* (тукыштырабыз) *берсәк, әле йазны тугыганыбыз йук. Ары-бире укыклый* (бераз укыштыра) *белгәннәрен. Картофны качан инде йаргалап пешерәбез. Йарый, йерекләгез* (йөрештерегез) *әле.*

Шулай ук -ыштыр/-ештер формасы да күзәтелә: Берсе үдәген караштырып тыра.

*-ынкыра/-енкерә* кушымчалы форма эш яки процессның тиешеннән кимрәк башкарылуын белдерә: *Аwынкырагач* (янтайгач, ава төшкәч) *пажар булырга мемкин икән.* Билгеле булганча, бу форма Урал төбәге сөйләшләрендә актив.

Юнәлешләр. Бер юнәлеш урынына икенче юнәлеш формасы кулланылу очраклары күзәтелә: *Әле вет жарлар килә, сетләр ачыша* (ачый) *иткенчек.*

Карсун сөйләшендә дә, мишәр диалектына хас булганча, йөкләтү юнәлешендә *-гыз/-гез* кушымчасы киңрәк кулланыла: *Эшкә кергезәләр* (кертәләр). *Күргәз* (күрсәт). *Үзенең мулла малайы икәнен белгезмичә* (белдермичә) *рафак бетерде. Артны* (чәчкапны) *башка кигезәләр* (кидертәләр) *иде дә артка бәлиләр. Атын гына белгезәбез* (белдерәбез) *анарга.*

Затланышсыз фигыль формалары. Инфинитив. Әдәби телдәге һәм мишәр диалектындагы кебек үк, карсун сөйләшендә дә ул *-ырга/-ергә* кушымчасы белән ясала: *Мыны эзләгәннәр ат куригына бәләргә* (бәйләргә). *Безгә вет йырак йерергә. Айбагар майы кылак* (кош теле) *пешерегә дә йакшы.*

*-мак/-мәк* формасы да сорау алмашлыгы һәм *кирәк* модаль сүзе белән берлектә инфинитив функциясендә кулланыла: *Пазур бит, нишләмәк кирәк?!*

*Бу форманың исемләшү очраклары бар:* Тырмышта да шылай, ашамагы-эчмәге кирәк.

Исем фигыль, әдәби телдәге кебек үк, *-у/-ү* кушымчасы белән ясала: *Сездә ничек, терлек тыту бармы? Унбиж йыл йугалуwына. Тагын килү булса, безгә килегез.*

Сирәк кенә *-ыш/-еш* формасы да күзәтелә: *Авторларын белеш* (белү) *кирәк вит.*

*-мыш/-меш: Укымыш* (уку) *кешене матурайтадыр. Тумышың Казаннанмы? Картаймышлы калгач йабыгырак* (ярлырак) *тырасын.*

Сыйфат фигыльләр. Сөйләштә *-ыр/-ер/-ар/-әр, -учы/-уче, -а/-ә* тырган кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыль формалары кулланыла: *Үзе шундый шадра, багар йире йук. Сине бер сүмәгәнең ырлар, нишләр халең бар? Бызауны кайа да бәләр йер йук. Әле вет элкеге шикелле картоф ашаучы кеше дә йук. Гуртка бара тырган афтабус килде.*

Әдәби телдәге *-арлык/-әрлек* кушымчасы карсун сөйләшендә *-аслык/-әслек* вариантында әйтелә: *Сатаслык* (сатарлык) *та әзерлиләр халык, куй* (сарык) *күп. Сет бар әзерәк пешерәслек* (пешерерлек). *Бараслыгыбыз йук хазер, картайдык. Мәзудәнең зийне җитәслег әле.*

Хәл фигыльләр. Хәрәкәтне белдерә торган фигыльләрне ачыклап килгәндә, әдәби телдәге *-ып* формасы урынына *-а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләр кулланыла: *Бу гыз сулармы бага йери* – Бу кыз сулар карап йөриме? *Санап куйа барыга кирәк. Абдрый* (аптырап) *калдык, белмәгәнне ничег атәсең? Җиңгәчи сули* (сөйләп) *килә.*

*-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльләрнең юклыгы *-мийнча/-минчә* кушымчалары белән ясала: *Эшләргә йәшәләр дә, бармийнча* (бармыйча) *йарамый. Санатурийаны карамийнча* (күрмичә) *китмәгез инде. Аның апасы, сүминчә* (сөймичә, яратмыйча) *генә барды, кийәүгә. Чимйәле кеше сийр тытмийнча* (тотмыйча) *да хале йук. Мин ашаминча* (ашамыйча) *да тук.*

*-гач/-гәч* кушымчасы карсун сөйләшендә *-гачтан/-гәчтән,* сирәк кенә *-гастан/-гәстән* вариантларында кулланыла: *Мәтәм, бәхетле дә булырсыз, атанадан ризалык алып киткәчтән* (киткәч). *Мунча куйабыз каткачтан* (кайткач): *Йырагырак китмәгез, урманга баргаст ан* (баргач).

Әдәби телдәге *-ганчы/-гәнче* кушымчасы сөйләштә *-гынчык/-генчек, -гинча/-гинчә, -гынчак/-генчәк* вариантларында күзәтелә:

*Үзләренә у салгинча миндә тырдылар. Тырыгыз без дә генә әләкләр пешкинчә* (пешкәнче). *Бәрәнгеләр җыйгынчак (җыйганчы) тыра. Апам асырый мине үскенчә* (үскәнче). *Тен буйы, таң аткинча* (атканчы) *туги идек.*

***Ярдәмлек сүз төркемнәре. Бәйлекләр.*** Сөйләштә әдәби телгә хас бәйлекләрнең барысы да табыла, тик аларның кайберләрендә төрле фонетик үзгәрешләр күзәтелә: *белән/ман* – белән, *чике/чик* – чаклы, *хадәр* – кадәр, *тике* – тикле, *шикелле, кебек, сыман, тесле* – төсле, *хатлек* – хәтле.

Мисаллар: *Шул чике* (чаклы, кадәр) *бәйәгә утнын сатыб аласын. Кылупка чик* (кадәр) *җиткәннәр. Тынычлы булмаса йез түбән килсен ул, кирәгесе шул хадәр* (кадәр) генә. *Унысы да земән тикеләр* (тикле), *йыклилар дир. Аның вет энә кебек нәрсәләре була чәнечә торган. Шының тике йасыйлар йуwачаны* (бәлешне). *Сезнең кебек йәшләр авылда тырмый бит. Утызар вузга тике наwуз тугә идем. Кымыг ат'кәннәр узенә, кумык сыманрак кеше ул. Балан ачы, мәләш тесле. Шул ызбалар әлегә хатлекләр* (хәтле) *тырды.*

Мишәр диалектына хас *сынны* – шикелле, *ашалый* – аша, *бите* – кыры, яны, өсте кебек бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр дә кулланыла: *Синен сынны кызлар күп биредә* – Синең шикелле (ягъни вуз бетереп эшкә килгән) кызлар биредә күп. *Улсы йегерә йери урман битендә* (кырында) *шылай. Туң май сертәргә йарамый камыр битенә* (өстенә), *ката.*

Карсун сөйләшендә, мишәр диалектындагы кебек үк, әмән теркәгече актив кулланыла: *Миңа вет әмән* (әйтерсең лә) *самаwарың кан'и, кылакларым шауный. Иул кыры, әмән* (әйтерсең) *йаумаган да. Безнең тел китапларга бакканда әмән* (гүя) *йат кебек.*

Карсун сөйләшендә *чай* модаль сүзе кулланыла. Ул ике мәгънә төсмерен белдерә: а) фараз итү, гоман итү: *Керик, чай сүләшергә килгәнсез* (чагышт.: мәләкәс сөйләшендә *чәй* – шулай ук), ә) шулай да, бит: *Үз тиңебез чай алар.*

**Синтаксик үзенчәлекләр.** Ияртүчесе фигыль булган сүзтезмәләрдә бер төркем фигыльләр, әдәби тел белән чагыштырганда, башка килешне башкаралар: *Әле җиде* (балам), *җидесенә*

(җидесеннән) *дә туймыймын. Үзеңнән зур кешеләрне* (кешеләргә) *путчин ат ителегез, тыңнагыз сез аларны, дир. Ырышам үзләренә* (үзләрен)*, нәгә әйткәннәр. Айагычтан* (аяк өсте) *тырырга йаратмый улсы. Ыланнарга* (оланнарны) *да ырышам.*

Билгесез (төшем) килештәге сүзнең инверсияләнгән аергычы төшем килеше кушымчасы ала: *Барып бызауны + чер, пичтән су сал йылыны* (җылы су сал).

Исем хәбәрләр зат кушымчалары ала: *Сез сың тырмышталармы* (тормыштамы)? *Казанның үзендәсез* (үзендә) *икән сез.*

*Кирәк* модаль сүзе, әдәби телдән аермалы буларак, фигыль кебек төрләнә: *Бусы кирәгер* (кирәк булыр), *бусы кирәкмәс* (кирәк булмас) *дип куркып тырдым. Выни кыружкаларыгыз, сет кирәксә* (кирәк булса) *салырга.*

Сорау җөмләләр интонация белән генә дә оешырга мөмкин: *Таптыгыз магажинны?* – Кибетне таптыгызмы?

*Әллә* сүзе һәм интонация белән: *Элә шәкәрсез эчәсең?* – Әллә шикәрсез эчәсеңме?

Сорау кисәкчәсе җөмләнең логик басым төшкән теләсә кайсы кисәгенә ялгана: *Мәйсәрәме йырлаган?* – Майсәрә җырлаганмы? *Әллә чәйме эчергең келәми?* – Әллә чәй эчерәсең килмиме?

2 нче зат хикәя фигыльләрдә сорау кисәкчәсе зат кушымчасыннан алда килә: *Зәйнәб, эчәмесен* (эчәсеңме) *тагы? Бул'шы сызламамысын, сызламамысын* (сызламассыңмы), *ышкимын да ышкимын айакны.*

Карсун сөйләшендә дә аналитик төзелешле кушма җөмләләр еш күзәтелә: *Ван кайа тилевизир куйган бит, шул эвнең теге йагында. Минем малайым шул, кайсы фырунтта үлде.*

**Лексик үзенчәлекләр**. Карсун сөйләшенең диалекталь лексикасы, нигездә, мишәр диалектындагыча, берникадәр үзенчәлекләр дә табыла. Кайбер тематик төркемнәрдән мисаллар китерәбез.

Туганлык атамалары һәм кешене тасвирлый торган сүзләр: *каwын-ыру* – кардәш-ыру, *тудыкай* – якын хатын-кыз туган, *нәнәй* – әни, *аг абыстай* – әнисенен апасы, *йәш бабакай* – эти яки әнисенең абыйсы; *карсак* – тәбәнәк, *тирес/тирес-тирмән* – кире, кире беткән, *йаурын* – иңбаш,

калак сөяге, *бума кастасы* – үзчир, эпилепсия, *тиле-тәлпәк* – тиле-миле һ. б.

Хуҗалык итү, йорт-җир һ. б.: *латасты* – лапас, *уйма* – идән асты, шунда төшә торган тишек, *жуwылгы* – юан, озын чыбык, *урдык* – сәке, *чилнек* – арба, чана һ.б. тора торган каралты, *субагач* – чабагач, *шырма* – пәрдә, чаршау, *кура* – киртә, *кү́чмә* – басма һ. б.

Аш-су атамалары: *кылак* – кош теле, *катлама* – торпыча (тар юка камырны урап, майда пешерелә), *асл'ан май* – акмай, *эшти* – шулпа (*Сылының эштийе нәүле була), кан'ар* – пешерелгән ризык *(Кан'ар ашйымсыз, кан'ар пешерийемме?), кызган каймак* – мичтә кайнаткан сөтнең өсте, *кыраш* – камырдан гына пешерелгән камыр ашлары, *йымшак* – ак икмәк һ. б.

Кием-салым: *үз халат* – халат, *абурка* – бала итәк, *запун* – алъяпкыч, *җүләү* – тегү, *балдак* – куныч, *бәбеч* – читек, *бәбеч-калуша* – читек-кәвеш, *кылакбау/кәркеш* – чабата киндерәсе, *хасита* – хәситә, *йапма* – изү капламасы, *кунчек* – изү төбе, изүнең аскы башы, *арт/арт тәңкә* – чәчкап, *сапук/ыйык* – киез итек, *зәмәт* – такта койма, *кукиш калфак* – кечкенә калфак, *әмерхан башмак* – күн ботинка һ.б.

Терек һәм терек булмаган табигать. Рельеф, табигать күренешләре һ.б.: *чалу/ылук* – болын, *йаңгыр басу* – яңгыр яву, *күк дугасы/күк чәйәсе тыру* – салават күпере чыгу, *чиклаwык йәшене/кыры йәшен* – аҗаган һ. б.

Үсемлек атамалары: *сак* – усак, *паңгы* – гөмбә, *нәүле паңгы* – лайлалы гөмбә, *айу камыры* / *шипулник* – гөлҗимеш, *тәт'әй* – ашый торган үләннәрнең берсе, *гачнич* – кыргый пастернак, *атаwы* – курпы, *картуф* – бәрәңге һ.б.

Хайван атамалары: *кучат* – этәч, *кыргайак* – үрмәкүч (*Вуни баг әле кыргайак, шында пәнәwез сузган ул), пивет* – бытбылдык, *чага* – бәрән, куй – сарык, *кочок* – эт, *чилезин* – ата үрдәк, *чәчкеч* – ук (бал кортының) һ.б.

Рухи мәдәният, йолалар: *кийәү чигелдәге* – вак төш, вак чәкчәк, *кул сугу* – кызны килешү, *май ашы* – бәби туе, *буш кен* – сишәмбе, *арчи* – кызны егет йортына озата баручы туганна-

ры (*Бер-ике атнадан килеб алалар кызны, арчилар белән), сүкәү* – имләү, *кабаг эстенә чыгу/кабакка чыгу* – капка төбенә чыгу, *варган* – гармонь һ.б.

**Сөйләү үрнәкләре**

...асыл гына иттереп артымнан йери / казлар эстенә барабыз йакшы гына // вичуркаларга барабыз // эх унибыз да инде / җегетләр карап тыралар / сыкланышып тыралар үзебезгә // биг инде севә мине җегет // алынган инде / салдат // китәргә вет анарга кезне кирәк // йереде инде артымнан/ бик җегетләр киткәнен кетеп тыралар // эй дийер җегетләр дийер/ бу кызны дир хат йазыштыг / алмагыз дир / йанында дир тырдым дир атасы килеб алды фанар белә дийер // йок / җегетләр әтәләр / бакмибыз / син йаңгал / алдаш сүлисең / сүләмә алай / диләр // бу хатны йандырыгыз / кирәкми бу хат / йурап сүли // ату дийер алырлар диб этеп дийер сүләдем дийер миңа әтә // алырлар әтәм / дийр / алырлар мыны мин килгәнчә салдаттан // йук дийер мин ызак тырмам салдатта / сине килгәч алырмын дийер // ул тугыз ай гына тырды // кез җитте // барам алаша белә суга кезне / шулай кырпак кына кар йауган / мине орларга чыгалар // орларга чыккачтан / харындаш күзләү буйында тыра иде // бучка белән суны тутырамын / артка чананың басамын да китәмен // алашам курка да сал аштан / китте дә // җегетем калды акайып / алалмады мине // всурауна этәдер орлармын мин мыны // кеңелдә барыга бар инде / белгезмимен эс'сырны // ну нишләргә? // тытынды сыратырга // бер дә сыратты // ике дә сыратты // эх нәнәй бирмәде // нәнәй бирмәгәчтән ырларга чыга // аның хардәшләре тегендә байлариде / алашаны җигәләр // мин суга барамын / мин белмим ырлаганны // судан киләмен / азбар (ишегалды) үтә киләмен // җегет сукмакта / сукмак тар // нишләргә // бер ирне кычкырамын / тиз чык / дидем / Галийәк дәдә / тиз чык / ана. йулда бер җегет тыра // хазер / дийер бер җиңен кийә / берсен йук // йыгыра мин сиңа бирмәм / дийр // йарый / киж булды / тәрәзәгә килде җегет кич // йук димен / бармыйын / димен / чыкмагайдең ырларга // кичне тагы икенче кенне сыраргa җибәрә / нишләргә? // учурауна ырлыймын дийер / или

үзгә ырлар үзеңне / йукка йугаласың / миңа кил дийер // ну йарый / барымын димен / җибәр баш кыда // башкыданы җибәрде // килде башкыда // йәрәшелдем // туйны йазга калдыралар // кышны йәрәшелдем // кул сугарга (килешергә) җийындылар кул сукканда фатийаны (никахны) укытканнар // кийәүгә вит кирәг инде йакшы күлмәкләр кигезергә // машина белән тегеб элгертәләр живы гына киҗеле ыштаннар // ычкырлар шуның бул'ыгы иде / чылкалар да / бар да киләмен бирегә инде йаз башы (яз көне) // кан'ишемнең кибәне зур иде / сугарга йәшәләр үмәгә үземне инде // йәш киленне кергезәләр // керәмен // бик йакшы субагач китердем // запун кырдым / арт тактым / киттем сугарга // уртага керәмен дә йакшы гына келтәләрне урталый йезәмен // кан'ым этәдер / киленнән уңдык дийер // матур килен алдык дийр // анарга сетле бытка айырым куйик дийер сийларбыз үзен // шулай үмер иттек // бала кан'ам биләде үзе мин килгәч әл дә // унбиж йыл тырдык кан'иштә / быларны мин барын да бактым // аннан чыктык айырылып // бирнәне бирдек бик йакшы // йакшы эстәкер / йакшы тугыган эстәкер бирдек сары белән / чәчәкле эстәкер // йакшы шәлләр куйдым күлмәкләр куйдым / битсебергечләр (сөлгеләр) / ыштан / балайак басмалары ике кайынсеңелем килде сый эндәргә / ал арга күлмәк / берсенә йабына тырган шәл салдым // бирнәне мин кү$^{о}$п бирдем // унике үгә керделәр сый // кан'ым этә / киленне суга җибәрегез / артыннан багып калийым // элке вет кан'най катчалар ийе вет / капланып та йери идек / күренмибез дә // мин инде суга киттем кийенеп / айагымда бәбеч-калуша / суга киттем // килен матур / артыннан багып калдык / йакшы килен / этә // шулай без умер иттек йакшы гына // бер сүгәнгә генә бардым / шуның беле үмер иттем / шуның белән мин үләмен дә инде // бетте //

*Сөйләүче: Шибанова Зөләйха.*
*Инза районы Шлемасс авылы.*
*1969 елда язып алынды*

**Туйлар, туйлар** ... Кызны йәрәшәләр. Башкыда бара. Барадыр да башкыда. Эһе, ад'а, ад'а, утыр, утыр. Утырырга вит ди, башкыда аңгарта инде. Бетә (янәсе, рус. будто) кыз сорарга килгән инде. Утыр, ату матлик тешәр башыңа, идән уртасында тырма, түргә

утыр ди (хуҗа, кызның ата-анасы). Утырта. Мин бэк зур йымыш ман килдем үзегезгә вит ди. Безнең шандый Исмайыл атлымы, ниме малайыбыз бар, шал анда йинде Зегрәгезнеме, Фатимагызнымы бергә кушыйг үзләрен. Шыннан сың тегеләр әтә, белмибез, әлдә йәш пака, быйыл бирмибез, йәреңгә биребез ди. Йуг инде, алар ди ахыры бер-берсенә йараганнар, ди, дабай ике йәшне бергә кушыйг инде. Ну ни хал', әтийе килер ди, әтийенә, абыйларына, апаларына аңгартырбыз, иртә мән килерсез ди, и (башкода) чыгып китә. Ул кенне булмый эш. Аннан икенче кен тагы килә. Самуарлары куйган, әзерләгән инде. Анда йөз суммы, ике йөз суммы мәһере булыр инде. Акчалата ул мәһер. Аны бетенесен түләми инде, күпме, азмысын гына бирә. Шуннан сың сүзне бетәрәләр. Ашый эчә дә и баш кыданың кулына тыттыралар инде сүз алышынмасын эчен әле бер пылатинса, йөзлек, и бер баж йаулыгы, басма и йаулык бырын себерә тырган. Тастымал да әтәләр. Бырынгылар әтәләр ийе йаулык, насаwый пылатуг этәләр быйыл (хәзер). Шылай итеп кул сугалар да киттеләр. Wут дискыт та иртәгә без киләбез сезгә инде зур тевен белән акча салырга. Икенче кенендә инде баралар зур тевеннәр белән. Тевеннәрендә була ике ышлай фурма питырас, ишле-кушлы булсын, и эстәкернең дүрт угылына иллешәр тийен акча бәлиләр кемешләрне. Кызга йакшы йын күлмәкме әле, йебәк күлмәкме куйалар шал тевенгә, баш кыданыкына куйалар. И кан'ананыкына да шылай куйалар. Кан'ана бәли инде дүрт угылга дүрт акча, куйа инде анда йын күлмәкме, йебәк күлмәкме куйа, шанда куйа инде шалысын (шәлен), аннан сың куйа шанда йакшы чылкасын да, рубашкасын да куйа йебәкне. И шылайтеп тевеннәрне бик йакшы гына тевәләр (төйниләр) дә китәләр чыгып. Ике тевен белән баралар. Кардәшләр дә тевен мән бара. Падарка ман баралар. Алар да шылай күлмәкләр ыштапел, утыралар ашарга-[э]чәргә кыз әвендә и шанда укыйлар. Анда катнаша кыз әвендә никахка әнийе малайның, әтийе бара, и башкыда бара ирле катын. Шанда инде тагы кардәшләре. Мулла укый. Пичкә терәлмәгез, ди мулла [ә]тә. Никах укыганда пичкә терәлергә кушмый кешегә, ышты анарга тимәсен синең пеләчәләрең. Шылай бездә зывидино. И шанда ни барыгыз ман ди мулла [ә]тә алладан

сырагыз. Ии ни бар йәш килен дә шанда үзенә инде бәхет, эризык сырый, анда кем булган кешеләр дә тели. Ишекне кыручукка [ә] ләләр и җибәрмиләр кемне дә. Кыз тыра инде бетә wын кырган ширма, ышыкта тыра. Хыт икенч[е] үдә тыра [ә]тийем вот арт ызбада. Малайн[ы] утырталар эскәмийәгә. Мулла әтә, мин әтермен шылай син разый булып алдыңмы, эч ыраз. Тег[е] әтәдер, малай тырадыр да күкрәгенә кулын куйадыр да, алдым. Аннан кызның әтийен тыргызалар, дискыт та кызыңны разый булып бирдеңме. Аннан сың инде дийа (дога) кылалар да анна сың култыктыралар (култыклаштыралар). Сыңыннан ашарга-[э]чәргә тытыналар. Шанда сахырник ман чыгаралар шәкәр, шал шәкәр эстенә куйалар шал акчаны, мәһерне, анда инде күпме бар. Ан[ы] инде әтийе ала, әтийе булмаса ыстарший агасы, абийы ала шал акчаны. Чыгарга вакыт җитәдер дә шаннан сың китерәләр инде ват ничә тевен, ун кешеме утырган, җегерме кешеме утырган, тевеннәр мән килгәннәр. И шаларга каршы былар да бирә шал бирнәне, китереп куйалар, бересенә бер катын китереп куйа, кызныкы кардәше. Икенчесенә икенчесе китереп куйа. Эченчесенә эченчесе. И шаларны чапкай итеп (кул чабып), шал фурмага түбәләренә күтәрәләр, эрәхмәт алла саулык бирсен инд[е] анда безнең киленгә, бергә үмер итсеннәр, и шалайтып алла бәрәкәт итәләр дә. И шаннан сың култыктыралар да ашаб эчеп чыгалар и кәнфит сибәләр инде кабаг эскә, акча сибәләр. Кызның түбәсенә кайнанасы ман башкыданын катны эрис (дөге) сибәләр, ышты дискыт та бай булсын үмерендә инде, йакшы азык ман гына тырсын. Кемеш акча түбәсенә кыйалар. Аннан сың чыгып бииләр тышта гармунга каршы и аннан чыгып китәләр шалай гармушкалар ман. Туйда [а]ннан тужы шулай. Канфит китерәләр тевендә туйда. Шал канфитны выргыталар. Нарут җийылган туй багарга. Шандыгылар канфитны сибәләр дә ыланнар джийа. Акча сибәләр, көмеш акча җиргә. Ан[ы] инде баш кыда сибә, кайнана сибә. И шанда бииләр.

Туй булды, ни бар барча кардәшләре кызн[ы] алырга киләләр гармун белән. Йырлаша киләләр, йыр, күй. Кыз инде йылый чыга капланып. Пухуwуй шәлен йабынган. Аның айаг астына куйалар бер адийал. Адийал эстенә инде шанда бастыралар кызны вәдәккә

(арба) утыртканда. Вәдәккә күтәреп абыйы менгезеп куйа, малай ман икесен. Вәдәкнең эстен йабалар кызыл киҗеле чаршау белән, шандый белән вата. И галакуллар, гармушкалар. Алашалары, эч алаша бер тырантаста. Мыннан ишектән чыкканда йырлыйлар.

Ишектән керер үзе,
Ин [э]лек сайлам бирер үзе.
Ни алем җегет үзе ди,
Бал, шәкәрдин татлы сүзе.

Уг аттым уйга (чокыр)деште,
Ул уйдин кышлар ысты.
Ул кышлар мыңны кышлар ди,
Шул туташка ди йулдашлар.

Тешергәндә тагы кызның астына адийал җәйәләр, адийал эстенә тешерәләр. Күтәреп абыйы кергезә үзен. Йывача белән бал кабызалар малай ман кызга. Йывача май эчендә пешергән шандый телемнәр, ысдубныйлар. Эчәр тапкыр, элке малайга эс тапкыр, аннан кызга эс тапкыр кабызалар. Бал ман инде, ышты йакшы, тату гына булсын үмерләре, йакшы, тәмне генә үтсен. Кабыза инде бер анда кыз, малайның бер ратнуй сеңелесе кабыза. Икенче кенне инде кызлар бара, кызның нәрсәләрен итәләр, әвендәге. Анда йөзлеге, пуристынасы, урны җире, иастыкларын... адийал итәләр, кав'орлар итәләр инде икенче кенне и шаны ман малайның эмтен инде кииендерәләр кызлар. Йырлап кийендерәләр.

Килделәр кыдачалар ди,
Пешердек йыwачалар.
Ашагыз да, эчегез дә,
Кадерле кыдачалар.

Ни бийектер табыгыз,
Каршы йаwа карыгыз.
Килә кыдачаларыгыз,
Каршы чыгыб алыгыз.

Сезнең дә [а]лтын алмагыз,
Безнең дә [а]лтын алмабыз.
Безнең алтын алмабызны
Хур итәргә алмагыз.

Сезнең дә [а]лтын алмагыз,
Безнең дә [а]лтын алмабыз.
Сезнең алтын алмагызны
Хур итәргә алмыйбыз.

Кан'ише эwенә нәрсәләрен китергәс, йакшы гына шал ызбаны кийендерә. И шанда тагы кызлар сыйлананалар, бииләр, йырлыйлар, йыр, кеw була. Эченче көнендә паклун (кыз белән кияүнең туйдан соң беренче тапкыр кыз ягына кунакка барулары) була. Паклунга әнийесе эwенә кыз бара, теwен белән. Эҗ-дүрт үгә паклунга керәләр, әнийенә пирут, аннан сың кардәшенә пирут, ир кардәшенә, кыз кардәшенә пирут (рус.вперед, башта) керәләр. Бер эч үгә керәләр.

*Сөйләүче һәм җырлаучы: Ахмерова Мәрьям.*
*Мордва Республикасының Кочкур районы*
*Татар Ымызы авылы. 1969 елгы экспедициядә язып алынды*

### *Кыз йылату йыры:*

Ишектән кердем атладым,
Атлас кына җәйдем түреңә;
Атлас чәчәгемне җийа, җийа
Кунак кына булдым эти-әни эвеңәй.
Әй таң кучат, таң кучат,
Таңнан гына бырын
Тудыкайлар тырыр тчак.

*Сөйләүче һәм җырлаучы: Кадриева Зөбәйдә.*
*Пенза өлкәсенең Лунино районы Шыкша (рус. Синорова) авылы.*
*1969 елгы экспедициядә язып алынды*

### *Бәетләр, җырлар*

Шау-шу итеп ни шауныйдыр
Агидел буйының әй камышы,
Артым йугалгынчы ди ишетеләй
Гөлстан хайләлейем дауышы.
Булмагыз җегейетләр былай хур,
Качкынның михнәте бигерәк зур.

Ай-һай бунимдагы сәйәтемнен
Йалтырыйдыр анын кемешей,
Мәскәү генйаралыгын суйып чыккан
Әл дә дей кинжалымда йебеше.
Их дусларым, безгә ди мал кайда,
Башлары исәне булса шул файда.

*Ульяновск өлкәсенең Карсун районы*
*Тат. Гуринка авылы*

Шәрукнын башында кримка бүрк
Алмагачка кунганый кыш кебек.
Йөрегән дә йулым, туган илем
Йыкым арасындайан күргән төш кебек.
Шау-шу итепе ниләр таушый
Агидел буйынын эх камышы,
Чакырым йарымнаны ишетелә
Гөлестан халәлемнең тавышы.

*Мордовиянең Дубенки районы*
*Ламат авылы*

Халык күңелендә намуслы яшәргә омтылыш, гаделлекне яклау һәрвакыт өстенлек алып килә. «Абделмән купич (купец) җыры» шуның бер үрнәге дисәң дә ялгыш булмас. Ялган акча ясап баеган сәүдәгәрне халыкның яратып җиткермәвен, аңа мыскыл катыш көлемсерәп каравын тоелып тора ул җырларда:

Итегемнен тебе таш җәйсә дә
Сутлар йөри-йөри дә саз булдый.
Алты пот тартадыр кәгазь акчам,
Башымны йоларга ла аз булды.
Абделмән купичның абзары (*ишек алды*),
Абзары гына тулы казларый
Каладин калага елый йөри
Абделмән купичның кызларый.
Абделмән купичның ырашивайларый
Аның филюгылары сарукай.
Купич арасында купич идең
Бер купич та талмый парука.

Абделмән купичның атлары
Тау битендә кылганнар кимерә,
Әле генә матур Абделмәнкәй купич
Астыруктан бычып ла тилмерә (....).

Абделмән купис турындагы бәетләр Себер якларына да барып чыккан.

Карсун төбәгендә дә халыкларга авыр тормыш көнкүреш итәргә туры килгән. Мәсәлән, качкыннар турындагы җырларга игътибар иттек. Патша хезмәтеннән качып, качкын хәлендә яшәргә мәҗбүр булган Шарук турында бер төркем ырлар язып алынды.

Шар'укнын башында каракул бүрк,
Алмагачка кунган кыш кебек.
Туган гына йыртым, йергән йулым
Йыкым арасында күргән теш кебек.
Булмагыз, йегетләр, былай хур
Качкынның михнәте бигерәк зур.
Миннән генә калган чалгы белән
Чапчы, әти кәбәм, башыйымны,
Йезләрең саргаер, рәхат күрмәс,
Сагынырсын Шар'ук улыңны.
Булмагыз йегетләр былай хур,
Качкынның михнәте бигрәк зур.

*Мордовиянең Дубенки районы*
*Ламат авылы*

Качкынныкта йөрү бик авыр булса да, халык күңелендә горурлану, Шар'укны ярату сизелеп тора:

Шар'укның башындай кримка бүрек
Алмагачкай кунганый кыш кебек.
Ыламат (Ламат авылы) илендә йерүләрен
Йыкым арасыдай деш кебек.

Халыкның күңелендә бу эшкә гаепле кешеләр дә әйтелә:

Сызырам курпысы (корпусы) таш кына
Җавышка йорамый баш кынам.

Тормыш-көнкүреш вакыйгаларын чагылдыра торган халык иҗаты әсәрләре арасында бәетләр шактый зур урын алып тора. Безнең тарафтан «Мөршидә», «Чалган кыз» һ.б. бәетләр язып алынды.

Карсун якларындагы халык авыз иҗатында түбәндәге бер әһәмиятле фактны күрсәтеп үтәргә кирәк. Билгеле булганча, татар җырларында Агыйделне кушып җырлана. Карсун якларында исә Агыйделне кушып җырлау аеруча актив булу белән күзгә ташлана. Белгәнебезчә, хәзер Агыйдел дигән елга атамасы Башкортостанда һәм Татарстанда таралган.

Тамбов, Пенза якларында сирәк очрый, анда да тарихи җырларда һәм халык җырларында очрый. «Идел» дигән сүз борынгы телебездә гомумән «елга» мәгънәсендә йөргән. Бик борынгы кешеләрнең яшәү урыннарын, нигездә, елга буйларында табыла. Иделләр кешенең тормыш-көнкүреш өчен, көн итү өчен бик әһәмиятле чыганак булган. Аны яратып «Ак Идел» дип йөрткәннәр. Тора-бара Башкортстанда «ак» сүзе билгеле бер елгага карата берегеп киткән, ә башка төбәкләрдә «Агыйдел» формасы аеруча җырларда гына сакланып калган. Карсун якларындагы татар авылларында Агыйдел сүзен без бик күп яздык, ул аеруча халык җырларында.

**Агыйдел**

Йырактан ук ялтырап күренә
Агыйдел йарының ак ташы,
Ниләр генә күреп, ниләр кичкән
Ир-йегеткәй белән ат башы.
Агыйдел буенай барсамчы,
Йар агалый йатып калсамчы.
Сүмәгән ярларга баш бәләмәй
Йалгыч йомарланып йатысамчый.
Агыйделкәй дашыкач без нишләрбез
Алуткага утырып кичәрбез.
Болай да севешеп айырылгастан
Ахирәткәй барыгыч нишләрбез.
Агыйдел буеның йары да крута
Йарыладыр кыйаж жарына

Бик матур булсаң дай байагырсың
Тарый алмагач сөйгән йарыңа.
Агыйделкайлаардан чыккан чакта
Атым тайлады да кубызгай.
Деште дә генә күңелем, деште лә күзем
Сада үскәвән бу матур буй кызгай.

**Агыйдел**

Дештем Агиделгә кер йыуарга
Йыуарга да теген йыларгай.
Йыладым, йыладым, белә алмадым
Йезеп сәүгән йарым син кайда.
Ылы йулкайларда барган чакта
Йылтыраб ук тыра җиз йызак.
Алучы кешегә берне тегел,
Кетеп тыручыга бик ызак.
Базарларга барсам алыр идем
Агидел буйының арбузын.
Күрсәм җаникайны сүләр идем
Ычырата алмимын йаңгызын.

*Җырлыйлар: Мустакимова Әминә (1901),*
*Оркыйа (1911) Шибановалар.*
*Инза районы Шлемасс авылы.*
*1969 елгы экспедициядә язып алынды*

Безнең материаллар да мишәр җырларына төзек рифма, матур яңгырашлы көй хас икәнен күрсәттеләр. Җыр текстларында күңелгә ятышлы образлы сүзтезмәләр, мәгънәле чагыштырулар тулып ята: *кыңгыр салган ак калфак, кәйләм (каләм) каш, нечкә бил, камыш буй, син сандугач – мин карлугач, энҗе-мәрҗән, бал шәкәрдин татлы сүзе, алтын алмам, йөрәк парәм* һәм башка мишәр җырларының югары һәм бай поэтикасын күрсәтеп торалар. Шушы ук чаралар, гомумән, халкыбызның бөтен авыз иҗатында да, казан татарларында да киң таралганлыгын аерым ассызыклап үтәргә кирәк.

Җыеп әйткәндә, карсун сөйләше авыллары халкы теле үзенчәлекле, җыеп алынган материал бик бай.

# УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНДӘ ҮСКӘН ТЕЛ ГАЛИМНӘРЕ – ЯКТАШЛАРЫБЫЗ

*Флера Баязитова*

## Туган тел һәм Латыйф Җәләйнең олы мирасы

Татар теле белеменә зур өлеш керткән өлкән буын галимнәр Җ. Вәлиди, Х. Бәдигый, Г. Сәгъди, М. Корбангалиев, Г. Алпаров, Г. Шәрәф, Г. Ибраһимов, Ш. Рамазанов, В. Хангилдин, Р. Газизов һ.б. арасында профессор Латыйф ага Җәләй эшчәнлеге үзенә бер аерым урын алып тора.

Латыйф ага Җәләй 1894 елның 17 ноябрендә хәзерге Ульяновск өлкәсенең Майна районы Иске Кызыл Су (Тат. Урайкино) авылында туа. Олы фән юлына аяк басканчы, Л. Җәләй катлаулы тормыш юлы үтә. Аңа тормышның ачысы-төчесен бик иртә татырга туры килә. Кышларын ул мәхәллә мәктәбендә укый. Аны тәмамлаганнан соң, 1906 елда Мәләкәс мәдрәсәсенә укырга керә, ләкин, әтисе вафат булу сәбәпле, 13 яшеннән Мәләкәс шәһәрендә сезонлы эшче-йөкче булып эшли башлый. Бик авыр шартларда яшәвенә дә карамастан, Латыйф ага, үзенең чиксез тырышлыгы аркасында, заманына күрә ярыйсы гына төпле белем ала. Мәдрәсәне уңышлы тәмамлаганнан соң, 1911 елда ул Самара губернасы Иске Җүрәй авылына мөгаллим-укытучы булып китә.

Дөнья күрү теләге белән, 1914 елның башында ул Урта Азиягә юл тота. Ташкентта җәен җиләк-җимеш бакчаларында кара эшче, ә кышын пешекче булып эшли. 1915–1917 елларда солдат хезмәтендә була, империалистик сугышта катнаша, Беренче

бөтендөнья сугышына җибәрелә. 1917 елның ахырларында Латыйф ага фронттан туган якларына кайта, яңадан укытучылык эшенә керешә, төрле авылларда беренче баскыч мәктәпләрендә укыта һәм үзенең белемен күтәрү өстендә бик тырышып эшли. 1921 елны, алдынгы укытучы сыйфатында, Латыйф ага Җәләйне Самара шәһәренә күчерәләр. Анда ул 1932 елга кадәр төрле мәктәпләрдә, педагогия техникумында татар теле укытучысы, балалар йорты мөдире, мәктәпләр инспекторы булып эшли. Шул елларда ук уку-укытуның аерым мәсьәләләре буенча китаплар бастыра, фәнни күзәтүләр алып бара, беренче баскыч мәктәпләр өчен кулланмалар төзи.

1932 елда Латыйф Җәләй Самара педагогия институты каршындагы аспирантурага укырга керә, 1933 елны Казан педагогия институтына күчеп, аспирантурада укуын дәвам иттерә һәм 1935 елда аны тәмамлап чыгып, шул ук институтның татар теле һәм әдәбияты кафедрасында укытучы булып эшли башлый. Шушы елларда булачак галимнең тел тарихы, диалектларны өйрәнү белән кызыксынуы тагын да көчәя. Казан педагогия институтының татар теле кафедрасында башланып киткән укытучылык эшчәнлеге шушы юнәлештәге фәнни-тикшеренү эшләре белән үрелеп бара. Бу эшне ул Казан дәүләт университетының тел кафедрасына күчкәч тә (1944 ел) дәвам иттерә, тел тарихы, грамматика һәм диалектология курсларын төзеп, шулар буенча студентларга лекцияләр укый.

1939 елда Л. Җәләй, укытучылык эшен дәвам иттергән хәлдә, Татарстан Мәгариф Халык комиссариаты карамагындагы Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтында (хәзерге Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) эшли башлый, 1956 елдан 1962 елга кадәр тел бүлеге мөдире вазифасын да башкара. Бу елларда аның фәнни-иҗади эшчәнлеге тагын да активлаша.

Галимнең фәнни эшчәнлеге гаять күп тармаклы. 30–50 нче елларда вакытлы матбугат («Мәгариф», «Совет мәктәбе», «Совет әдәбияты» журналлары, «Кызыл таң», «Кызыл Татарстан», «Социалистик Татарстан», «Совет Татарстаны» газеталары һ.б.)

битләрендә һәм төрле җыентыкларда Латыйф Җәләйнең татар тел белеме һәм әдәбиятының актуаль мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре, рецензияләре, укытучыларның сорауларына җаваплары бер-бер артлы басылып торалар. Шулар белән танышып чыгу гына да аның киң колачлы, эрудицияле, өлгер каләмле фән эшлеклесе булуын тулы күзалларга мөмкинлек бирә.

Татар әдәбиятын яхшы белү, аның үткәне һәм хәзергесе белән нык кызыксыну яшь белгечне әдәби тәнкыйть дөньясына алып керә. 30–40 нчы елларда ул шушы өлкәдә җитди эшчәнлек күрсәтә. Татар әдәбиятын үстерүдә, яшь язучыларны тәрбияләүдә кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша, әдәбиятка яңа аяк баскан яшь каләмнәрнең беренче адымнарын ныклап күзәтеп бара, алар иҗатының тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнү буенча да бүген дә актуальлеген югалтмаган җитди тикшеренүләре дә бар. К. Насыйри, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Ш. Камал, Г. Бәшир, С. Хәким, К. Нәҗми, Ә. Еники, М. Әмир, А. Расих һәм башка кайбер татар язучыларының иҗатларына карата язылган мәкаләләре шундыйлардан. Ул язган 60 тан артык мәкалә-рецензияләр, әдәбият белеме таләпләре югарылыгында булып, көн кадагына сугып баралар. Шуның өстенә галим башлангыч мәктәп укытучылары өчен диктантлар җыентыгы, урта мәктәпнең VIII сыйныфлары өчен татар әдәбияты буенча дәреслек, әдәбияттан дәреслек-хрестоматияләр, укытучылар өчен төрле методик кулланмалар, программалар төзи.

Танылган башкорт теле белгече, профессор Җ.Г. Киекбаев бик дөрес билгеләвенчә, «Л. Җәләйнең башка татар телчеләреннән аермасы шунда, ул татар тел гыйлеменә юнәлеш керткән зур галим: нәкъ менә ул татар телен тарихи, чагыштырмалы планда өйрәнүгә нигез салучы».

Чыннан да, Латыйф Җәләй татар тел белеменең чирәм җир хәлендә булган ике зур катламын (тел тарихын һәм диалектологияне) күтәреп фән киңлегенә чыгара. Аның тел тарихына багышланган беренче хезмәте «Татар теле тарихының кайбер мәсьәләләре» дип атала. Анда, нигездә, тарихи грамматика проблемалары яктыртыла. Автор бу хезмәтен 1942 елда М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү университетында кандидатлык

диссертациясе итеп яклый һәм, татар теле белеме буенча беренчеләрдән булып, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек була.

«Татар теленең фонетикасы буенча материаллар» (1954) дигән тикшеренүендә Л. Җәләй телебезнең фонетик системасындагы төп үзгәрешләрне күзәтеп чыга. Татар әдәби теленең нормалашу процессын өйрәнү, аның әйтелеш нормаларын эшкәртү һәм конкрет системага салу кебек гаять катлаулы, актуаль проблеманы хәл итүдә дә Латыйф ага Җәләй актив катнаша. «Татар теленең орфоэпик нигезләре» (1953) дигән китабы нәкъ шул мәсьәләгә багышланган.

Галимнең тел тарихына бәйләнешле соңгы һәм иң зур хезмәте «Татар теленең тарихи морфологиясе буенча очерклар» дип исемләнә. Ул хезмәтнең кульязмасы, басмага әзерләнгән хәлендә, Институт архивында саклана иде. Ниһаять, 2000 елда, Институтның тырышлыгы белән, бу хезмәт дөнья күрде (китапның редакторы – филология фәннәре кандидаты Ф.С. Фасеев).

Тарихи грамматика белән беррәттән, Латыйф Җәләй татар диалектларын өйрәнү буенча да күп һәм зур эшләр башкара. Мәгълүм булганча, татар диалектлары инде күптән, Октябрь инкыйлабына кадәр үк тикшерелә башлаган. Татар диалектологиясе белән теге яки һу дәрәҗәдә В.В. Радлов, А.Г. Бессонов, Н.Ф. Катанов, С.Е. Малов һәм башка галимнәр шөгыльләнәләр. Ләкин әле татар диалектологиясе системалы тикшерелгән аерым фән югарылыгына күтәрелә алмый.

Октябрь инкыйлабыннан соң татар диалектологиясе белән күренекле тел галиме Җ. Вәлиди кызыксына һәм бу өлкәдә шактый эш башкара. Эстафета Җ. Вәлиди кулыннан Латыйф Җәләйгә күчә һәм шуннан соң татар диалектлары эзлекле рәвештә бөтен киңлеге һәм тирәнлеге белән өйрәнелә башлый.

Латыйф Җәләй диалекталь фактлар өстендә эшләү, халыкның җанлы сөйләү телендәге үзенчәлекләрне җыю, аларны төркемләү бик җитди фәнни эш итеп каралырга тиеш, дигән фикерне алга сөрә. «Халык телендәге диалекталь фактлар тиешенчә өйрәнелмәгәнлектән, әдәби телнең үзенә яраклы материаллары тар-

кау яталар, хәлбуки, халыкның җанлы телен өйрәнү һәм андагы байлыкны туплау шушы телнең фәнни эшләнешен тиешле югарылыкка күтәрергә ярдәм итә. Шулай булгач, гомумән культура фронтында эшләүче кешеләр халкыбызның җанлы телен өйрәнүгә әһәмият бирергә тиешләр», – дип яза Л. Җәләй «Татар диалектологиясе» (Казан, 1947, 127 б.) китабында.

Турыдан-туры Латыйф Җәләй катнашлыгында һәм җитәкчелегендә татарлар яшәгән Идел буе һәм Урал төбәкләренә җирле сөйләшләрне тикшерү-өйрәнү өчен күпсанлы экспедицияләр оештырыла. Ул татар теле сөйләшләрен өйрәнүдә диалектология фәнендә сыналган анкета методын да куллана һәм, Татарстан төбәкләренә татар теле әдәбияты укытучыларына анкеталар таратып, алар аша кыйммәтле материаллар туплый, диалектологик экспедицияләрдә яшь тикшеренүчеләрне, студентларны «Диалектологик сораулыклар» белән тәэмин итә, алар белән бергә үзе дә бик күп төбәкләрдә, авылларда була. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1947 елда галимнең «Татар диалектологиясе» дигән монографиясе басылып чыга. Галим бу хезмәтендә татар диалектларының өйрәнелү тарихын, аларның классификациясен бирә һәм диалектларның төп үзенчәлекләрен ача.

Болардан тыш, Латыйф Җәләй катнашлыгында өч кисәктән торган «Диалектологик сүзлек» (1948, 1953, 1958) бастырып чыгарыла. Бу сүзлекләрдә экспедицияләр вакытында тупланган лексик материаллар урын ала.

Татар диалектларын практик өйрәнү Латыйф Җәләйгә татар диалектологиясендә хәзер дә капиталь хезмәт саналган монография язарга мөмкинлек бирә. Татар теленең урта диалекты турында монография дип аталган бу хезмәтне Латыйф ага докторлык диссертациясе итеп яклый һәм филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә ала.

1956 елда «Татар теле белеме алдындагы бурычлар» исемле мәкаләсендә Латыйф Җәләй татар теленең диалектологик атласын, тулы диалектологик сүзлек һәм татар теленең аңлатмалы сүзлекләрен, татар теле белеме буенча тулы библиография төзүнең кирәклеген, бу проблемаларның көн тәртибенә басканлыкларын

күрсәтеп чыга. Әйтергә кирәк, Латыйф Җәләй инициативасы белән башланган бу зур эшләр күп еллар тел секторының һәм диалектология группасының җитәкчесе булган Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова, Латыйф аганың яраткан шәкерте булган Нәҗия Борһанова, Гасимә Якупова, инде аларның да шәкертләре булган бер төркем диалектологлар: Зидә Садыйкова, Леонид Арсланов, Фәрит Йосыпов, Дөрия Рамазанова, Тәнзилә Хәйретдинова, Флера Баязитова һ.б. тарафыннан уңышлы дәвам иттерелә.

Бүгенге көндә «Татар теленең диалектологик сүзлеге»нең беренче (1969) һәм икенче (1993) китаплары басылып чыкты, төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып, «Урта Идел һәм Урал төбәге татар халык сөйләшләре атласы» эшләнеп бетеп дөнья күрде, аерым сөйләшләргә, этнографик төркемнәргә багышланган дистәдән артык китаплар, фәнни монографияләр дөнья күрде, диалекталь лексиканың аерым тематик төркемнәре җентекләп өйрәнелә һәм бу өлкәдә дә монографияләр чыгып тора. Латыйф ага хыялланган «Татар теленең өч томлык аңлатмалы сүзлеге», «Татар теле белеменең тулы библиографиясе» дә нәшер ителде.

Тел тарихы һәм диалектология – үзара бик тыгыз бәйләнештә тора торган фәннәр. Латыйф Җәләй тикшеренүләрендә тел белеменең бу ике өлкәсе һәрвакыт игътибар үзәгендә тотыла, берберсе белән тыгыз элемтәдә карала. Шуның өчен Латыйф аганың рухы бүгенге көндә диалектологларның эшләгән эшләренә һәм уңышларына сөенеп, хәер-фатиха биреп торадыр кебек һәм без, хәзерге буын диалектологлары, үзебезне, гәрчә турыдан-туры аның лекцияләрен тыңлап, үзен күрү бәхетенә ирешмәгән булсак та, Латыйф Җәләйнең шәкертләре дип саныйбыз, тел белеменең шундый кызыклы, игелекле тармагында эшләвебез белән горурланабыз да.

Латыйф Җәләй фәнни кадрлар хәзерләү юнәлешендә дә зур эшчәнлек күрсәтә. Аның фәнни җитәкчелегендә аспирантура үтеп, диссертация яклаган ике дистәгә якын галим – фән докторлары һәм кандидатлары бүгенге көндә дә уңышлы эшләп киләләр.

Педагог буларак, Латыйф ага Җәләйнең үзенә генә хас бик үзенчәлекле уңай сыйфатын шәкертләре әле дә хәтерлиләр: ул

студентларны сәгатьләр буе авызына каратып тыңлата белгән, аның лекцияләре исә һәрвакыт галимнең үз күзәтүләренә, фәнни тикшеренүләренә нигезләнгән, фактик материалларга бай була торган булган.

Ул үзенең хезмәттәшләре, аралашкан кешеләренә карата киң күңелле, эчкерсез киңәшче, кешеләргә игътибарлы, ярдәмчел, туры сүзле галим булган, гыйльми тәҗрибәсе белән чын күңелдән уртаклаша белгән.

Олы галимебез, күренекле җәмәгать эшлеклесе Латыйф ага Җәләй 1966 елның 1 августында вафат була.

Тууына 110 ел тулу уңае белән республикабызның киң җәмәгатьчелеге, тюркология дөньясында танылган, татар теле белемендә аеруча күренекле урын тоткан галим һәм педагог, филология фәннәре докторы, профессор Латыйф Җәләйне тирән ихтирам белән искә алалар.

«Шәһри Казан» газетасының 1994 ел 15 октябрь санында Латыйф ага Җәләйнең шәкерте профессор Гомәр ага Саттаров «„Туган тел",– дип, җан атып» дигән мәкаләсен язып чыккан иде. Бу мәкалә Латыйф Җәләйнең эшчәнлегенә, аны искә алуга багышланган һәм автор үзенең җылы истәлекләре белән дә уртаклашкан. Латыйф ага яшәгән Маяковский урамының исемен Латыйф Җәләй исеме белән алмаштыру турында тәкъдим дә керткән иде. Безнеңчә, бу бик урынлы һәм зарур. Шәһәребезнең хакимият башлыклары һәм киң җәмәгатьчелек бу тәкъдимне хупларлар һәм тормышка ашырырлар дип ышанып калабыз.

### Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова

Ләйлә Мәхмүтова 1925 елның 25 августында Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы Муса (Мосеевка) авылында туган. Аның әти-әниләре аң-белемгә омтылышлы, мәгърифәтле кешеләр булган. Әтисе Мәхмүтов Таһир Хәбибулла улы 1888 елгы, ул Г. Тукайның якын дусты, 1909 елда Саратов губернасы татарларыннан беренчеләрдән булып, Казанда Татарская учительская школаны (КТУШ) тәмамлап, рус-татар мәктәбе укытучысы исемен алган. Таһир ага укучыларда үз гореф-гадәтләребезгә, татар

халкына мәхәббәт, аңа хезмәт итү рухы тәрбияли. Шуңа күрә аның кызы да туган телебезне өйрәнү, халкыбызга хезмәт итүне максат итеп куя, үзенең тормышын шуңа багышлый.

Ләйлә Мәхмүтова 1945–1950 елларда Ленинград (хәзерге Петербург) университетының Шәрык факультетында югары белем алган. Ул биредә шәрык фәннәренең зур галимнәре Н.К. Дмитриев, А.Н. Кононов, В.М. Жирмунский һ.б. аралашкан, аларның хезмәтләрен өйрәнгән. Гарәп-фарсы телләрен өйрәнү буенча И.Ю. Крачковскийның, А.Ю Якубовскийның лекцияләрен тыңлаган. Шул университетта аспирантурада укыганнан соң, 1952 елда вакытыннан алда «Особенности касимовского говора татарского языка» дигән темага кандидатлык диссертациясен уңышлы яклаган. Ул Рязань өлкәсенең касыйм сөйләше таралган авылларны йөреп, искиткеч бай материал туплый, ул сөйләшнең татар теленең урта диалектына караганлыгын дәлилли.

Туган бишегенә, үз халкына хезмәт итү хыяллары белән тәрбияләнеп үскән кеше буларак, ул үзен фәнгә багышлый, бөтен гомерен Татарстан һәм Казан белән бәйли.

1952 елдан алып 1986 елга чаклы, лаеклы ялга киткәнче, хәзерге Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында хезмәт итә. Башта кече фәнни, 1959 елдан өлкән фәнни хезмәткәр, 1961–1986 елларда тел бүлеге мөдире вазифаларын башкара.

Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова үз заманының һәм бүгенге көн таләпләренә җавап бирердәй итеп фәнни-тикшеренү эшен оештыра алган кеше. Институтның төп бүлекләренең берсе булган, озак еллар ул җитәкләгән тел белеме бүлеге татар телен өйрәнүне югары дәрәҗәдә башкара. Талантлы галимә, таләпчән җитәкче, үз сүзендә тора белә торган искиткеч намуслы кешенең кул астында сәләтле тел белгечләре туплана һәм нәтиҗәле иҗат итә. Бик күп яшь галимнәр үстерә ул. Аның укучылары инде барысы да фән кандидатлары, фән докторлары, күпсанлы китап авторлары булдылар.

Бу елларда диалектология, лексикография һәм башка тармаклар зур үсеш ала. Галимәнең үз фәнни эшчәнлеге дә киң кырлы,

ул тел белеменең төрле өлкәләренә караган күпсанлы фәнни китаплар, монографияләр, мәкаләләр авторы. Дүрт томлык (1955–1959), бер томлык «Тусча-татарча сүзлек»ләрне (1969; 1971; 1984; 1985; 1991), «Татар теленең фразеологик сүзлеге»н (1957; 1959) төзүдә катнаша. Өч томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1977–1981) редакторларының, Мәскәүнең «Фән» нәшриятында басылган «Хәзерге татар әдәби теле» (1969, 1971) ике томлыгы авторларының берсе һ.б.

Ләкин Л. Мәхмүтова – барыннан да элек диактолог һәм татар диалектологиясе эшен оештыручы галимә. Аның катнашлыгында татар халык сөйләшләрен өйрәнү эше планлы төс ала. Ул тел белеме бүлегенә җитәкчелек иткән вакытта татар диалектологиясе аерым мөстәкыйль тармак буларак формалашып җитешә, яңадан-яңа үрләр яулый. Татарлар яшәгән барлык төбәкләргә диярлек диалектолик экспедицияләр оештырыла. Аның җиде-сигез кешедән торган диалектологлар төркеме Татарстанда гына түгел, аннан читтәге, ерактагы төбәкләрдә: Пенза, Ульяновск, Саратов, Мордовия, Чувашия, Оренбург, Самара, Киров, Удмуртия, Башкортстан һ.б. яшәүче татарларның җирле сөйләшләрен өйрәнә. Шулай итеп, төрки халыкларның телләрен, мәдәниятләрен өйрәнүче республикалар арасында беренчеләрдән булып татар теленең диалектологик атласын, ягъни тел үзенчәлекләренең карталарын төзү өчен материллар туплый. Ул җитәкчелек иткән чорда капиталь фәнни хезмәтләр әзерләнә һәм дөнья күрә, аңлатмалы һәм тәрҗемә сүзлекләр, атлас һәм диалектологик сүзлекләр, күпсанлы фәнни монографияләр басылып чыга. Шул ук чорда Мәскәү һәм башка шәһәрләрдә якланган күп кенә диссертацияләр дә, тел бүлеге аша үтеп, лаеклы бәя алалар.

Бик озын юллар узып, күп авылларга барып җитеп халыктан тупланган материаллар белән татар теленең диалектлар системасы ныклы фәнни нигездә билгеләнә, яңа сөйләшләр ачыклана, аларның таралыш чикләре, формалашу үзенчәлекләре ассызыклана. Л. Мәхмүтова татар диалектологиясенең теоретик нигезләрен ныгытуга зур өлеш кертә: диалектлар һәм сөйләшләрне төркемләү принципларын, аларны тикшерү һәм өйрәнү методларын, диалек-

таль материални аңлату һәм нәтиҗәләр чыгару юлларын билгеләү һ.б.мәсьәләләр аның хезмәтләрендә чагылыш таба. Ул Латыйф ага Җәләй башлаган эшне бөтен җегәрлеге белән дәвам иттерә.

Аның күпчелек мәкаләләре мишәр диалекты сөйләшләрен өйрәнүгә багышланган. Татарстан, Башкортстан, Мордовия республикалары, Рязань Ульяновск, Пенза, Саратов өлкәләре һ. б. төбәкләрдә таралган мишәр сөйләшләренең тел байлыгы тикшерелгән. Мәскәүнең «Фән» нәшриятында 1978 елда басылган «Опыт исследования тюркских диалектов» дигән монографиясендә мишәр диалекты бар тулылыгы белән тикшерелгән.

Диалекталь материални кардәш һәм кардәш булмаган телләр, борынгы һәм иске татар язма истәлекләре белән чагыштырып өйрәнү, уртак җирлектә формалашкан төрле телләрнең үзара йогынтысын тикшерү кебек мәсьәләләр дә аның игътибарыннан читтә калмый.

Татар теленең борынгы язма истәлеге «Codex Cumanicus» (1303 елга караган хезмәт) әсәре белән җирле сөйләшләрне чагыштырып язган зур күләмле мәкаләсе татар теле тарихы өчен зур әһәмияткә ия бай чыганак булып тора.

Л. Мәхмүтова бик күп авылларда булып, халыктан язып алынган диалекталь лексиканы, тел байлыгын сүзлекләргә теркәп калдыру эшенә дә зур игътибар итә. Ул – «Диалектологик сүзлек»нең өченче чыгарылышын (1958), «Татар теленең диалектологик сүзлеге»н (1969) төзүче авторларның берсе.

Галимәнең татар диалектларын лингвистик география методы белән, татар халкы яшәгән барлык төбәкләргә барып туплау һәм тикшерүне җайга салу өчен тырышлыгы искиткеч, бәяләп бетергесез. Ул – татар теленең диалектологик атласын төзү принципларын эшләүче, төрки телләрнең диалектологик атласын төзүдә Идел-Урал зонасы җитәкчесе, Европа лингвистик атласына татар теле материалларын туплау эше өчен җаваплы җитәкче, бу атласны төзү буенча СССР ФА комиссиясе әгъзасы. Аның катнашлыгында һәм авторлыгында, төрки телләр арасында беренчеләрдән булып, «Урта Идел һәм Урал алды татар халык сөйләшләренең атласы» төзелә.

Ләйлә Мәхмүтова татар диалектологиясе буенча даими чыгып килгән дистәдән артык фәнни җыентыкларның төзүчесе һәм редакторы, күп кенә монографияләрнең фәнни редакторы булды. Ул татар далектологиясендә зур фидакярлек белән эшли торган күп галимнәрне әзерләгән. Аның эшен яшьләр дә дәвам иттерәләр.

Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтованы туган авылы Муса (Мосеевка) кешеләре хөрмәтләп искә алалар. Шул авылда туып үскән, Ләйлә апаның чордашы Нурҗиһан Әхмәтша кызы Арсланова «Муса авылы (Мосеевка) тарихы» дигән бик күп мәгълүматлар тупланган китап чыгарган (2012 ел). Бу китапта ул Ләйлә Мәхмүтова турында бик җылы итеп, фән кешесенә зур хөрмәт белән, олылап язган: «Якташыбыз, Муса (Мосеевка) авылы кызы Ләйлә Мәхмүтова, җәмәгать эшчәнлегендә дә шулай ук таләпчән, гаҗәеп кешелекле, югары әхлак үрнәге булган. 77 яшендә, 2002 елның 20 февралендә, танылган тюрколог, татар теле белеменә зур өлеш керткән олы остаз, хөрмәтле галимә, авылдашыбыз Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова якты дөнья белән хушлашкан. Аны Казан шәһәреннән үзенең дуслары, коллегалары Муса авылы зиратына китереп җирләделәр. Бүген аның каберенә мәктәп укучылары хезмәт күрсәтә, чәчәкләр утырта, җыештыра»[1].

---

[1] *Арсланова Н.* Муса авылы (Мосеевка) тарихы. Саратов: Новый ветер; Старая Кулатка: МЦБ, 2012. Б. 152.

# УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНДӘ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

***(Этнолингвистик аспект)***

*Флера Баязитова*

**Аш-сулар**

**Эшти (аш) пешерү**

– Капыста тури, картубын тури, кишер, суган сала.

Ләкшә (токмач) дә кисеп сала кас′ы кеше. Вәт сиңа эшти!

Кечеткән эштийе, картуп эштийе, кузгалдак эштийе. Катык катып ашилар.

**Борчак белән салма**

– Салма йаси идек ачы камырдан, борчаклы салма. Катык ой-ота идек тә салманы катык катып аши идек. Ите йук дип абдырап тормый идек. Шулай ашап таза булганбыз.

**Килен салмасы**

– Мин йәш килен. Кан′н′ам әтә:

«Кызым, салма йәйеп кунакларга ашатырга». Мин әйтәм: «Аш күп бит». «Йук, салма кирәк».

Ну мин йәймәне йәйдем дә йомшады йәймә. «Сыразы кис» диләр. Йарай, кисәм. Күп кенә он сиптем дә кистем дә. Мине багып торалар икән. «Менә, башы кисте», – диләр (башы эшләде дигән сүз инде). Кан′н′ам керде дә, шулпага салды да, салма өлгерде дә.

**Сызык белән салма**

– Салма пешкәч аз гына итеп сызык салып йибәрәләр иде. Майны эреткәч сызыгы кала бит. Сызык белән мәҗлес үткәрәләр иде.

**Чөгендер белән каwыннан (кабактан) курага киптерү**

– Курага киптерә идек. Wак кына итеп турилар чөгендерне, каwынны (кабакны). Шыны таба белән пичтә киптерәләр. Выт сиңа курага! Шының белән чәй эчә идек. Шуңа таза булганбыз.

**Ачы кимак, чөчөләмә кимак**

– Сөткә атлый да чөчөләмә кимак пешерә, теверле булырга тийеш тегел.

Ачы кимак колмак белән ачыткан, табада майда пешергән.

**Алабута күмәче**

– Кышкыга әллә ничә мишук алабута әзерләп куйа идек, алабута күмәче пешерә идек. Менә келәнче кергән ишектән, әби алып бирде пичтән соңгы алабута күмәчен

Алабута җыры да бар:

Алабута хат йибәргән,
Тиздән өлгерәм дигән.
Йегетләр белән кызларны
Ачка үтермәм дигән.

Алабута хат йибәргән,
Тиздән өлгерәм дигән.
Йөзәр гырам итеп кенә
Видымыс төзим дигән.

Алабута онын да йөзәр чырам гына биргәннәр.

**Чумара, умач**

– Чумара да, умач та булды. Чумара пешерәләр иде камыр басып.

Шаwада гына уwып сала умачны. Катык катып ашилар.

**Әпәй салу**

– Әпәйне үзебез сала идек пичкә. Квашн'а төбендә ачыткы камыр калдыралар. Ачыткы йасый идек колмактан. Әпәйләрне колмак белән ачытып сала идек. Колмак ачыткысы белән салган әпәйне, ул искерми иде. Аз гына анис та сала идек. Пич төбенә салалар иде әпәйне. Пич төбен пумала белән себертә кан'н'ам. Мин әле йәш идем. Бер күмере дә, көле дә калмасын, әпәй төбе чичта булсын. Элеке алтышар зур-зур әпәйләр сала идек пичкә. Аwыл әпәйе бик тәмле була иде.

Элеке агач балайак (кисмәк) белән квашн'а куйа иделәр. Ә хәзер бит кәчтерүл, зур кәчтерүлләр.

«Бер кунак йәшү бер йыл өмерне кыскарта», – дип әтә иде нәнәй (әни).

**Белен**

– Беленгә бер чашкы бүрттергән тары салабыз. Тары пешмәсен дә, бик чи дә булмасын.

**«Күршебез кимак, пәрәмәчә ашаган»**

– Менә күрше чыккан, утыра кабак эстә(капка төбендә). Әтәләр:

«Синең мыйыклар бик майлы, ахыры кимак, пәрәмәчә ашадың?»

«Да, ди, без шылай кимак, пәрәмәчә ашибыз».

Әле оныгы чыккан да:

«Бабакай, бабакай, мыйыгыңны майлый торган майыңны мачы ашады», – дигән.

Әле тотонганнар көләргә.

## Бәбәй майы

**Бәбәй майы** – бала туу хөрмәтенә уздырыла торга мәҗлес.

– Бәбәй майы җыйалар бәбәйгә. Чәй янына бал белән май куйалар, пәрәмәчә, пирмин, чәкчәки, кикча пешерәләр.

Олан туwа, бәбәй майына җыйа идек күршеләрне, туганнарны. Котлап бүләкләр салабыз, тевеннәр илтәбез, адийалмы, күлмәкме.

Әй, чирәп-чирәп (чүлмәк-чүлмәк) буткалар китерәләр иде. Элек шылай йәмле итеп чирәпләр йаси иделәр. Бәбәй майына ничә кеше килә, барысы да бутка китерә чирәп белән. Нинди бутка? Нинди булса да, карабдай, йә солы, йә тү (тары), йә арпа буткасы. Сары майны күз йасап салган. Аны чыгаралар, әтәләр: «Выт, бу мыныкы, выт бу мыныкы».

Ул бутканы нишләткәннәр? Үзләре ашаганнар, оланшакларны утыртып ашатканнар. Ул чакта оланшаклар күп була иде, хәзерге шикелле тегел.

*Карсун районы Нугай иле авылы*

### Бәбәй мунчасы

Бәбәй майы көнне бәбәй мунчасы да йагалар. Карт кодагилар, йәш кодагилар, кан'н'а да йывыналар.

Бәбәйне мунчада йыва иде әби, минек (< рус. веник) белән бәбәйнең аркасын сыпыра, әтә:

Олыны күрсәң – бабай әт,
Уртачыны күрсәң – агай әт,
Йәшне күрсәң – акырма,
Картны күрсәң – бакырма,
Бахетле бул,
Матур булып үс.

*Карсун районы Нугай иле авылы*

### Киленнәр олыларны камаган (олылаган)

– Киленнәр сүләшмәгән кан'ата белән. Әле менә эспичка (шырпы) эзли икән кан'ата, тапмый икән. Килен йардәмгә килгән, эспичканы тапкан да шалтыраткан, кан'ата ишеткән, рахмәт эткән.

Кан'ата әткән: «Балам, минем насугым (оекбашым), варигам (бияләем) йугалса, ничек әтерсең, алар бит шалтырамый, – дигән.– Балам, сүләш, түлке әдәпле бул», – дигән.

Менә шулай камаганнар (олылаганнар) олыларны, кан' (кайната) белән кан'н'аны (кайнананы).

*Иске Кулаткы районы Яңа Зимичә авылы*

### Кийәү кунакка барган

– Бер кийәүдән сораганнар: «Кан'ата-кан'анага барасызмы?»

«Барабыз, һәр бар'ам сайын барабыз», – дигән кийәү.

Ул икән йылга ике генә бар'ам: корбан бар'амы, руз'а бар'амы.

*Барыш районы Калда авылы*

### Каз үмәсе

**Каз үмәсе (***хвл.* каз өмәсе).

– Каз-үрдәкләрне йолкорга кызлар чакыралар. Йегетләр дә керә ак кушаклар (билбаулар) белән билдән. Йәшел, кызыл белән чиккән шарфлар белән.

Кайа үмә – йегетләр шунда. Йегетләр гармун ун'ап утыралар, ә кызлар үрдәк-казларны йолокалар. Йолкоп беткәч, суга китәләр йыварга.

Кызлар бик севенәдер үмәгә. Чакырмасаң – үпкәләш була: «Нигә мине калдырдың?»

«Салам тапа да кызларны салма ашарга чакыр», – дигәннәр. Тик үмә булсын, чакырмый калдырмасын.

Каз үмәсенә болай гына йибәрми:

«Килеп, ти, сәнка (< рус. санка) белән алырсыз».

Үмә беткәч тагы сәнка белән китерә:

«Менә, тәтәй, кызны китердем», – ди.

## Казлар эсте

**Казлар эсте** *(мәл.* көзге каз өмәсе вакытлары).

– Казлар эстенә кызлар йийалар иде. Ул бер зур бар'ам.

Элеке йолкалар, табын ашы, чәй әзерлиләр. Казларны кевәндәгә тагып кизләүгә китәләр кызлар тезелеп. Калудага салып йывалар иде казларны.

Казларны гузлар кагып чоланга эләләр, тозлаган казларны пүгрәпкә төшерәләр иде.

Казлар эстендә иртән үк тотыналар эшләргә. Казның каwырсынын сыйыралар. Бер казны аса (пешерә) каз йолкучыларга.

## Казлар эсте урнашы

**Казлар эсте урнашы** (*мәл.* каз өмәсе көне алдыннан кызлар җыелу, күңел ачу).

– Кичтән казлар эсте урнашы була иде, ул инде вичыр, утыру була иде. Казлар эсте урнашында йырлыйлар, бийиләр, бутилкә әләндерәләр. Йегетләрне дә кертә идек. Кемгә нинди йыр, бийиләр, такмак әтәләр иде.

Казлар эсте урнашында бер йегет минем белән танышырга келәде, йырлады:

Җәйен кисәм җиңсез күлмәк,
Кер куна беләгемә.
Тамыр җәйгән гөлләр кебек
Китмисең йөрәгемнән.

Мин дә атвит бирдем:

Алдыр алйапкычларың,
Гөлдер алйапкычларың.
Йук дисәң дә бардыр әле
Күңел йываткычларың.

## Корка сыйыру

**Корка сыйыру** (*мәл.* күркә йолку).

– Коркалар күп асырыйбыз иде. Йырлап-йырлап корка сыйыралар, вичыр ун'илар кызлар. Йегетләр дә керә иде, кенелле, куча-куча йөриләр. Посудаларымы, идәнеме җуwып китәләр.

## Кәрәләр көне

**Кәрәләр көне** (Раштуа көннәрендә төрлечә киенеп, яки киемнең тискәре ягын әйләндереп киеп, өйдән-өйгә кереп теләкләр әйтеп йөрү).

– Кәрәләр көне – 25 декабрь, хәзерге 7 январь.

– Кәрәләр алар кыш көне, йаңа йыл көннәрендә йөриләр. Тирес туннар кийеп (ягъни тунның тискәре ягын әйләндереп киеп), тайаклар тотып, гармушка белән йөриләр. Кабакларны (капкаларны) ачып керәләр дә бийиләр. Битлек кигәннәр, сакал такканнар. Танып та булмады кас'ын.

– Кас'ы гармун ун'и, кас'ы мандалин. Кәрәләрне көтеп алабыз. Балалар йөри хазер. Балаларга күчтәнәч әзерләп куйабыз.

Кәрә-кәрә дидегез,
Кәрә керми дидегез.
Кәрәләр килеп кергәчтен
Чемел-чемел көлдегез.

## Кәрә йөрүчеләр

– Кәрәләр керәләр иде йаңа йылда кабакларны шакып. Туннарны тирес туннар, әйләндереп кигән туннар, бүрекләрен әйләндереп кийәләр, шайтан булып йөриләр. Тайак тотып бийиләр. Танытмастан битенә корымнар сөртә.

– Оланнар чыга иделәр кәрә йөрергә. Кәрә йөрүчеләргә чигелдәкләр бирә идек. Малай-шалайлар йөриләр иде шалай. Алар этә иделәр:

Рахмәт үзегезгә,
Алла саулыккызны бирсен,
Хайwаннарыгыз күп булсын,
Кошларыгыз күп булсын.

### Чигелдәк пешерү

**Чигелдәк –** вак бавырсаклар.

– Кәрә көннәрендә чигелдәк пешерәләр әрбер өйдә. Чигелдәк пешермәсәң күңелдә шом кала.

Элгәре йуклык wакытлар. Пич каршында чигелдәкләр пешерәләр камыр басып.

«Бу чигелдәкләргә тимәгез, кичен кәрәләр керсә, аларга бирергә».

Әби этә ди шылай. Ә без, оланнар, ашак келибез, берне булса да алырга. Әби пешергән, өйеп куйган.

Кәрәләр керә иделәр, бийи, йырлый иделәр. Чигелдәкне бирәләр кәрәләргә, мишукларына салалар.

Кәрәләр этә иделәр:

Куйларыгыз, чагаларыгыз күп булсын,
Куйларыгыз көтүдән килсен,
Чагалы куйларыгыз көтү белән булсын,
Куйларыгыз куча булсын.

### Чигелдәкне терлекләргә каптыра

– Чигелдәкне сирга да, куйларга да каптыра. Кош-кортларга да бирәләр.

Чигелдәкне терлекләргә су, он белән басып басып, озынча итеп кисәләр.

Терлекләргә каптырырга дигән чигелдәкне сөткә басарга йарамый, исе килә, ашамыйлар. Суга гына пешергән чигелдәк була.

### Кәрә киче күпере-женне

– Кәрә киче күпере бар иде. Иске Зилунай белән йаңа Зилунай арасында. Ике аwылы тоташтырып тора торган күпер.

«Ул күпердән чыкмагыз, кәрә киче күпере ул җенне, кешене адаштыра», – дигәннәр. Ул күпердән чыкмый, әйләнеп чыга булганнар.

«Упкыллыкка илтә Кәрә киче күпере, адаштыра ул күпер», – дип әтә торган булганнар.

*Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылы*

## Келәү

**Келәү** (яңгыр теләү йолалары).

– Су буйларында келәү була иде. Бу безнең Новая Зимница аwылында шулай. Су буйларында келәү була иде.

Таганнар корып казан асалар. Кем йомырка, кем картук китерә, кем сөтен. Чумара салалар, эшти пешерәләр. Куча олан аwылда. Кашыгын тоткан, саwытын тоткан, утыралар.

Килә алмаган кешеләргә илтеп бирәләр, үзебез илтәбез.

Кизләү йанында су сибештек, шыл ашаган саwытлар белән сибешә идек.

*Иске Кулаткы районы Яңа Зимичә авылы*

## Ульян өлкәсе авылларында язып алынган борынгы җырлар

Бу җырлар диалектологлар Л.Т. Мәхмүтова, Д. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова, Ф.С. Баязитова тарафыннан төрле елларда экспедицияләрдә язып алынган («Материалы по татарской диалектологии», Казань, 1962, 1974, 1978, 1983, 1989, 1990).

### *Агидел буйы*

Агиделкай дашыкач без нишләрбез,
Алуткагу[1] утырып китчәрбез.
Былай да сеwешеп айырылгас'т'ан,
Ахирәткәй баргатч нишләрбез.
Бәләсәм йаwлык килешәдер кашыма,
Йәрәшминчә җиттеләр башымай.

[1] *Алуткагу* (< рус. лодка + афф. -га) – көймәгә.

Агидел буйының йары да кырута[1]
Йарыладыр кыйаж жарына.[2]
Бик матур булсаң да байагырсың,[3]
Тарыйалмагач[4] сәwгәне йаренай

Агидел буйының йары кырута,
Тайанып менәргә талы йук.
Үләнмәгән йегет ни бахетсез:
Йанында йөртергә йары йук.

Барсаң базарларга ал кушагни,[5]
Биг ызыны булмаса да, киң булсын.
Сүсәң дә йар'л'арны сү шундыйын
Бик матур булмаса да, тиң булсын.

Барсам базарларга алыр идем
Агидел буйыныкы арбузын.
Күрсәм җаникайный сүләр идем
Ычыраталмимын йаңгызын.

Агиделкайлардин чыккан чакта
Атым тайлады да кубызгаwай.[6]
Дәште дә генә кеңелем, дәште лә күзем
Сада үскәwән бу матур буй кызгай.

### *Кузырлы чана*

Кузырлы гна чанай, эй кузырлы чанам,
тәртәләре кызыл да тубылгы.
теннәр уртасында уйанамын, җаныйым, кемгә
кемгә сал'ийым йылы ла кун'ымный.

---

[1] *Кырута* (< рус. крутой) – тәке.
[2] *Жарына* (< рус. жара) – эссе.
[3] *Байагырсың* – боегырсың.
[4] *Тарыйалмагач* – туры килмәгәч, тиешмәгәч.
[5] *Кушак* – билбау.
[6] *Кубыз* – улак.

Кузырлы гна чанай, әй күн йапма, җаныйым,
йергән йулларыңны дай ынытмай.
Мин дә ынытсам, син ынытма, җаныйым,
миннән йәш кеңелеңне сыwытма.

*Оркыя һәм Исхак Шибановлар.*
*Инза районы Шлемасс авылы. Экспедиция, 1969 ел*

### *Әтеки*

Чыршыдан чыра йардыгыз,
Йакты йанмасын дидегез.
Ай, белдегез дә күрдегез,
Йаны тынмасын дидегез.

Кабакны кердем, борылдым
Кунача күрдем, севендем.
Ата-ана кулыннан сыйрылдым
Йат култыгына сыйындым.

Җиң генәм тулы җиңийем
Кайсы йагына сибийем.
Эч кенәм тулы хасерәт
Кайсы тудыкайыма сүлийем.

Ай-хай башымда тастарым
Ике очонда да бер салу.
Кигач кына кашлар, тудыкалар
Икебездә дә бер йазу.

Ак ситча минем запуным
Корсам мәҗлестә килешә.
Йан йулдаш кынам димидер,
Җәйгән урынны йил ишә.

Утырдым кайын төбенә
Кайын эләге пешкәнчә.
Мин анакайны көтәмен
Кийаш урынына төшкәнчә.

Ай-хай, башыңда бүрк кырпуың
Җым итәдер лә, атакай.
Көңөлгенәңнең катылыгы
Чын икән лә атакай.

*Хаҗи Зәйнәп әби, 82 яшь.*
*Иске Кулаткы. 1947 ел*

### Ульян өлкәсендә элек Саратов губернасы Хвалын өязенә караган Иске Кулаткы районында

«Әтәки» – кыз урнысын чыгарганда җырлана торган җырлар.

Энә генәм, йеп кенәм
Калды сондок төбендә.
Ун'аганым көлгәнем
Калды энийем түрендә.

Бизәрле сондокка басып
Бирәнерсең йиңгакай.
Усал кан'селең киткәч,
Кинәнерсең йиңгакай.

Миннән калган йәшел сондок
Ачмагыз да бакмагы.
Миннән калды сеңелкайым
Какмагыз да сукмагыз.

Кыштыр-кыштыр катламаны
Ашисынмы, кодагый.
Бер кызыңны алып киткәч,
Йыларсынмы, кодагый.

*Павловка районы Муратовка авылы. 1960 ел*

### *Әтеки*

Кабактыйн[1] бийек карлар йауган
Эремәс дийеп белдегез.
Аз тордом, күп күрдем, тудыкайлар.
Ахр'ы китмәс дидегез.

*Яхина Халифә.*
*Иске Кулаткы районы. 1961 ел*

Әткай йортонда[2] кибәннәр генә,
Түбәсен бийек салганнар гына.
Бу дөнйасында ыр'ахат' йәшидер
Белеп сәүгәнен алганнар гына.

Унөч йәшендә сабый кийәвем,
Кочакласам да, йылый башлыйдыр.
Сабый кийәүне «аша» дисәм дә,
Ашлар йыйсам да, ашата алмыйм.

Әтекайның түрендә утырыр урным бер такта,
Уйнаганым-йырлаганым калды борлоп бер йакта.

Чебелдеккайым чоп-чобар,
Чебеннәр кунса, кем кывар.
Кыз балагызны алып киткәчтин,
Әнекайым кан-йәшләр йылар.

---

[1] *Кабактыйн* – капкадан.
[2] *Йортонда* – ишек алдында.

Әтекайамның капкасы ачык,
Нигә капкасын йапмадың гына.
Әтекай, сиңа бик зур пинәм[1] бар:
Сабыйдан башка кийәү тапмадың.

Әт'кай, садыңда пешкән алмалар,
Кызылларын ук алып салыгыз.
Әтекай, сиңа үтенечем шул,
Моноң йаныңдин алып салыгыз.

Ак күлмәгемне, әнкай, тектерден
Йәмле йәйләрдә кийәргә генә.
Әнекай, бәне асраб үстердең,
Матур йегеткә севәргә генә.

*Зурагаева Хөббениса, 70 яшь.*
*Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылы. 1961 ел*

Ике абыстай бер туганым
Алдыгыз сез малымны.
Узган-барган, йөргән чакта
Кереб белегез хал'ымны.

Әнкәй, кәбам, бир бәхиллек
Имездең ак сөтеңне.
Әнкай, кәбам, кил каршыма
Үбийем уң битеңне.

Ишектән кердем генә
Карадым түргә генә.
Кил, әтекай, д'ыва кыл,
Мин китәм үмергә генә.

*Кузахметова Зөләйха, 77 яшь.*
*Павловка районы Шомалак авылы. 1961 ел*

### *Балдыкай*

Ах, барина-барина, балдыкай,
Бакма кеше йарына, балдыкай.
Кеше йар'ы йар' булмас, балдыкай,
Үз йар'гынаң йар' булыр, балдыкай.

[1] *Пинәм* – үпкәм, кинәм.

Барма такта йанына,
Такта төшәр (башыңа), балдыкай,
Алма, йегет, бай кызын,
Бурыч өwәр башыңа, балдыкай.

Ал, егет, йарлы кызын, балдыкай,
Нужа чигәр йанында, балдыкай.

Алма, йегет, бай кызын,
Бай кызы йор'оннан[1], балдыкай,
Ике күзе эренне, балдыкай,

Ал, йегет, йарлы кызын,
Йарлы кызы йарка[2], балдыкай,
Ике күзе чарка[3], балдыкай.

* * *

Бара идек йул белән, балдыкай,
Очорады бер кунача[4], балдыкай,
Куначада, әй, кодача, балдыкай,
Пешерәдер йывача, балдыкай.

Тыкыр-тыкыр бийергә, балдыкай,
Идәнеңнең уйы[5] бар, балдыкай,
Чыгарыгыз йәш киленне, балдыкай,
Ничә каре[6] буйы бар, балдыкай.

Йегет начар бийесә болай җырлыйлар:

Басма идән тактасына, балдыкай,
Сындыры(р)сың тактасын, балдыкай,
Ник сең[7] болай бийалмыйсың, балдыкай,
Әмән[8] бозау йуртасын, балдыкай.

---

[1] *Йор'оннан* – йефектән, ефәк киемнән.
[2] *Йарка* [< рус. ярка] – «сәламәт, хәрәкәтчән, тере» мәгънәсендә.
[3] *Чарка* [< рус. чарка] – «зур чәркә» кебек мәгънәсендә.
[4] *Кунача* – куну урыны.
[5] *Уй* – казылган җир, уйым, тигезсез урын.
[6] *Каре* – борынгы озынлык үлчәү берәмлеге (терсәктән бармак очларына кадәр булган озынлык).
[7] *Сең* – соң.
[8] *Әмән* – кебек, шикелле, сыман.

Ай, арыштир-арыштыр, балдыкай,
Арыш башы камыштыр. балдыкай,
Бии белмәгән кийәүне, балдыкай,
(Йәш) бозауга алыштыр, балдыкай.

*Яхина Халифа, 60 яшь.*
*Иске Кулаткы районы Мостәк авылы*

### *Сахипҗамал*

Йегетнең өстендә ыштүф камзул,
Буй-буй төшкән аның буйавы.
Төнләр уртасында утырып,
Шул буладыр кызның уйавы.
Мәрхупҗамал, сау бул,
Сахипҗамал, озата бар.
Ак та гурынчаны[1] ни күркәйтә[2],
Матур буйкызларның[3] сөлгесе
Торчы, абызым[4], үзәлең[5] килгән дип,
Уйатадыр кечерәк сеңлесе.

Кызарып та койаш калыккан чакта
Шәүләләре суга ызбага.
Бу нә генә, гаҗәп, бу нә хикмәт,
Ир балага йакын була кыз бала.

Бийек дау башында салкын чишмә,
Агып төшә алпутның садына.
Уңлы да гына суңлы кашым тарта,
Ахры сүгән йар гынам сагына.

*Кулаткы районы Мостяк авылы*

---

[1] *Гурынча* [< рус. горница] – ак өй, алгы өй.
[2] *Күркәйтә* – күркәмли, күркәм итә.
[3] *Буйкыз* – буй(га) җиткән кыз.
[4] *Абызым* – апасына иркәләп, олылап әйтү сүзе.
[5] *Үзәлең* – сөйгәнең, гүзәлең.

## *Сугыш бәете*

Су өсләрендә су фылутлары
Мисли һавада кар болытлары.
Су буйларында балалы үрдәк,
Искә дөшә дә өзелә үзәк.

Йакшы атларны тупка җигәләр,
Гирманчыларны тиздән җиңәләр.
Без ашаганда атлар кешниләр,
Ашарга сырап, шинил тешлиләр.

Гирманга каршы сугыш ачтылар
Мона гирманнар җәйәү качтылар.
Гирман аскәре дауга менгәннәр,
Хайләләп анлар фыла элгәннәр.

Тау-таш йатадыр, солдат үлесе,
Җаны да чыкмаган була күбесе.
Атабыз мылтык, базлардыйн чыгып,
Гирманлар килә, «Ура» кычкырып.

*Иске Кулаткы районы Мостяк авылы*

## *Туй йырлары*

Урамыгыз-турыгыз,
Бигрәк йәмле туйыгыз.
Шушы туйларыгыз кебек
Үтсен үмер буйыгыз.

Сандугачлар ойалады
Ойалары пыйала.
Шушы сандугачлар кебек
Шад йәшәгез дөн'йада.

Абау алла, күс тигән,
Күс тимәгән, ис тигән.
Эрәхмәт булсын кодагига
Матур буйкыз[1] үстергән.

Әнкәй, сиңа бүләгем,
Биш митырдан күлмәгем
Асырадың да үстердең,
Эр'ахт'ымны күрмәдең.

Калфузларның атлары
Боллоннарда көстөнгән[2].
Үкенмим, балам, үкенмим,
Матур йегет үстергән.

Кодагиның кабагын[3], ди
Төрле сырга сырлагыз[4].
Кодагиның көңлен күреп,
Бер-ике йыр йырлагыз.

---

[1] *Буйкыз* – буйга җиткән кыз.
[2] *Көстөнгән* – пошкырган.
[3] *Кабак* – капка.
[4] *Сырга сырлагыз* – буяуга буягыз.

Өстегезгә килешәдер
Киемнең күгелчеме.
Синең кебек булса булыр,
Сахраның күгерчене.

Кодаларның атлары
Болонда печән аший.
Бирнәләрен йаратмилар,
Кодаги башын каший.

Аклы ситча күлмәгемне
Тектерден, әнекайым.
Матур йегеткә бүләккә
Үстерден, әнекайым.

Тауга турат[1] туктаган,
Эшлийәсе чуклаган.
Сәүгәнемнең хат'ры' калган –
Йат куйнында йоклаган.

Каршыбызда алмагачка
Сандугач кундырмадык.
Кундырсак та, биздермәдек,
Дошманга сиздермәдек.

Ай икегез-икегез,
Икегезнең битегез.
Икегез дә пар килгәннәр
Ыр'ахат' үмер итегез.

Әткай-әнкай димиләр,
Хат'ыр'ы калыр димиләр.
Әллә кемнәргә димниләр,
Сәүгәнем бар – белмиләр.

Йаңгыр микән, кар микән?
Йаумаган йир бар микән?
Сәүгән йарына бирмиләр,
Әллә дөн'йа тар миән?

*Зурагаева Хөббениса, 70 яшь.*
*Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылы. 1961 ел*

– Килешергә баралар алдан. Атасы белән әңкәсе бара кийәүнең. Килешәләр инде мона, сүләшәләр инде. Балны кыз җортона китерәләр кодалар туйга җегет җагыннан. Биш кила бал инде, чәйен дә салалар, майын да салалар ийе элгәре. Хәзер ничектер инде. Анары паштитлар салып киләләр инде. Ирләрне җийалар инде саwымга. Аннары сың катыннар җийалар. Туйга киләләр дә кодалар саwым алып киләләр. Кыз җагы кунаклар җийып куйган була. Саwымда мыни каз алып киләләр, аннары паштит алып киләләр зурын гына. Барсына да шулай кисәк-кисәк кисәкләп бүләләр инде аны. Күчтәнәч апкиләләр, (бүләк) саwымга килгән кунаклар. Күлмәклек тә алып киләләр. Кайсы акча да алып килә инде.

*Аюпова Яхъя. Цильна районы*
*Елхово-Озерное авылы. 1981 ел*

[1] *Турат* – туры ат.

Бөгөн туй. Иртә тороп эләкшә[1] була, бездә генә икән эләкшә. Ваты Фатиманың килне йыррактан килде. Кодагый әтә, бездә эләкшә йук. Бөгөн туй, иртә тороп баралар ызба кийендерегә кызның туганнары. Бар да тевеннәр белән. Анда инде йегетнең туганнары җийыла. Алар инде үне кийендерәләр. Урнарты[2] вата, кавир, пылуш[3] ала ол'онны[4]. Артызбага коргоч, әбигә сөлге тага. Мунча йөслекләре айырым. Үзенең урнысын кийендерә дә анан кан'ананыкын кийендерә.

Өшәнчекләр – кыз әйберләре ул. Җийа бир дә җийа бир. Бирнә бирәбез, әби белән бабаларына куш күлмәк[5]. Малый да шылай бирә, кыз да шылай.

Кызны бирәләр дә аймы тора, ике аймы тора йарашкач, кийәүләр йөри. Кас'ы йөкле булган. Йегетнең шапкасына[6] да никах укыткannар. Кыз күргәнме, йукмы инде, аны сорап тормыйлар. Кыз белән йегет кушыла. Чөче су[7] йасыйлар да кыз белән йегеттән уртлаталар[8].

«Килен йакшы булсын, тату торсоннар».

Кыз төшә. Мин тун йәйәмен. Икесе шында баса да бал суwы[9] каптырамын. Ике көмеш тәңкә айак астына:

«Йалтырап шылай торсыннар».

Килен бусага бирә, бусага керә[10]. Йөслекме[11], яулыкмы сала. Кан'анага бусага салып керә. Чебелдек була.

---

[1] *Эләкшә* – токмач; мәҗлес тә шулай атала.

[2] *Урнарты* – йокы урыны артына стенага эленгән келәм.

[3] *Пылуш* – плюш.

[4] *Ол'онны* – < рус. олень, ягъни болан сурәте ясалган келәм.

[5] *Куш күлмәк* – парлы, ике күлмәк.

[6] *Шапка* < рус. шапка – бүрек.

[7] *Чөче су* – баллы су.

[8] *Уртлата* – авыз иттерә, каптыра.

[9] *Бал суwы* – баллы су; килен төшергәндә эчертә.

[10] *Бусага салу* – килен төшкәндә, бусагадан кергәндә бирелә торган бүләк.

[11] *Йөслек* – сөлге.

Иртә тороп мужикның тәтәсеме, сеңнесеме мунча йага. Суга чыгаралар киленне. Чулка[1] куйа.

Сондокны ачкан wакытта кем сондок ача, шынарга йаулык.

Ат әттерәләр[2]. Кем алма апай, сеwәр апай, кечерәк апа, бер генә апа. Йә күркле абзый, алма абзый, шәкерт абзый.

Кан'ата белән сүләмиләр вет. Килен аши иде чыланда. Алары йук закун булган.

*Салекаева Магира.*
*Николаевка районы Татар Сайманы авылы. 1989 ел*

## УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНДӘ ӨЙРӘНЕЛГӘН АВЫЛЛАР, СӨЙЛӘП МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР

### Яңа Малыклы районы

**Урта Исәнтимер:** Нургалиева Гаян, Билалова Хәлимә, Ибәтова Кәшифә, Шәкүрова Зәкия, Сафина Минниса, Шәфигуллина Фатыйма, Галиева Халидә, Хисаметдинова Бибизиннәт, Вәлиахмәтова Халисә, Эмирова Зәйтүнә, Сөнгатуллина Сара, Кулахметова Зөләйха, Шәкүров Мирзаҗан, Билалова Затия, Билалова Закирә, Миннафина Разия.

### Барыш районы

**Калда:** Батраева Һаҗәр, Батраев Равил, Ибрагимова Әйшүк, Чагаева Бибинур, Чагаев Хасан, Казакова Бибинур, Хабиева Камар, Казакова Ханифә, Камаева Хава, Чагаева Фәтихә, Чагаев Якуб, Чагаев Ибраһим, Таиров Абдылхак, Ахмеров Хәсән.

### Иске Кулаткы районы

**Иске Мостяк:** Магдиева Хадичә, Хабидуллина Сара, Юсупова Фаилә, Алтынбаева Фаизә, Нурмәтова Гөлҗамал, Невлиятуллина Бибинур (1929), Невлиятуллин Әбдерәким Сулейманович (1928), Шафеева (Невлиятуллина) Нурия (63 яшьтә);

**Атлаш:** Давыдов Расим, Курмакаева Рәсимә, Хасанова Фәүзия (82 яшь);

[1] *Чулка* – оек.

[2] *Ат әттерә* – килен кеше кийәүнең туганнарына йагымлы сүзләр белән эндәшергә тиеш булган.

**Муса (Мосеевка):** Арсланова Нурҗиһан (90 яшь); Азизова Тәүхидә (1928), Ахтямова Руфия (1964), Салюкова Әлфия Ибрагимовна (1927), Салюкова Гөлсем Зәкәрия кызы (1958), Салюков Кәрим (1952);

**Яңа Мостяк:** Хаева Суфия Ибраһим кызы (1954), Аксянова Саимә Абдулхаков кызы (1951), Ризванова Халидә (1956), Абдуллина Нажия Җиһанша кызы (1959);

**Урта Терешка:** Давыдова Фәһимә (60 яшь), Бикбаева Флера (50 яшь), Байгузина Фатиха Туктар кызы (1929), Хамзина Акилә Сафа кызы (84 яшь), Хаерова Әлфия Мөнир кызы (1975);

**Кирюшка:** Нарбикова Мәрьям Ризван кызы (1935), Кушаева Нурия (1943), Нарбиков Зөфәр (1943), Алеева Фатиха (56 яшь), Рафикова Хашия Зарифулла кызы (60 яшь);

**Иске Зеленай:** Мустафина Роза Ильяс кызы (1946), Мустакаева Рокия Батыр кызы (1954), Ахмерова Равиля Каюм кызы (1942), Бикбаева Факия Федор кызы (1957), Узбекова Фирюза Садык кызы (1946), Бикбаева Фәридә Рәшит кызы (1957), Умярова Фәридә (1947), Смирнова Рякибә Али кызы (1951), Абайдуллина Мәвлегөл Султан кызы (1952), Бикбаева Сәкинә Якуб кызы (1950), Бикбаева Тәнзилә Лерон кызы (1961), Бикбаева Илһамия Хөсәен кызы (1938);

**Вязгай (Вязовый Гай):** Мустафина Фәүзия (76 яшь), Муракаева Сания Каюмовна, Тимербулатова Рукия Фатих кызы (1940), Мустафина Румия, Муракаева Сәкинә, Шабанова Суфия, Ахмедова Сания Сабир кызы (87 яшь), Юсупова Сания Исмаил кызы (64 яшь), Амирова Рушания Саид кызы (71 яшь);

**Яңа Зимичә:** Тугушева Зәйнәп Абдулла кызы (83 яшь), Насыйрова Әминә (1924), Забирова Румия Гафиятовна (67 яшь), Забирова Разия Ус₽ ман кызы (1941);

**Иске Яндука:** Мингалишева Нәфисә Зәгидулла кызы (65 яшь), Рафикова Рәшидә Абдул кызы (1939), Байгулова Разия, Салихова Румия (1939 елгы), Тимербулатова Нурия (1956), Таһирова Фәһимә Билал кызы (1939), Мингалишева Руфия (54 яшь), Нугаев Расим Каюм улы (1940), Аюпов Туктар Батырхан улы (1950);

**Иске Кулаткы:** Абдюшева Зәйтүнә (1955), Тимушева Руза (1932).

## Карсун районы

**Нугай иле:** Абдуллина Рауза Якуп кызы (76 яшь), Юсупова Рәйсә (54 яшь), Мухаметжанова Нәкыя (82 яшь), Адилхаева Сания (1936);

**Сакускай (Уразовка):** Диарова Мәгъфурә (65 яшь), Диаров Саид (65 яшь), Муратова Хәят Ситдик кызы, Хәйретдинова Халимә Хасан кызы (1934), Аликберова Алсу (1953), Чусмакаева Камилә (1933);

**Гуринка (Тат. Горенка):** Сагитова Фәйрүзә (67 яшь), Касимова Нәкыя (81 яшь), Алеева Рәшидә (87 яшь), Исмаилова Кадерия (79 яшь), Низаметдинова Рәйсә (70 яшь), Кантимирова Нәкыя (79 яшь);

**Аксу (Тат. Голышевка):** Шакурова Рәйсә (1941), Әдгамова Мәсрурә (75 яшь), Кафиятуллина Мәстүрә (1939), Вахитова Кәүсәр Хасан кызы (61 яшь), Кафиятуллова Миннура (90 яшь), Мурашина Хадича Сафик кызы (89 яшь), Зиннурова Факия (50 яшь).

## Мәләкәс районы

**Атнагыл:** Галәутдинова Вагиза (Фаизә) (1942), Хәбибрахманова Тәнзилә (1939), Хәбибрахманов Рафик, Вәлләхмәтова Майбәдәр (1921);

**Мөси (Моисеевка):** Галиуллова Нәҗия Ярулла кызы (1940), Ахметзянова Кәүсәрия Исхак кызы (1943), Мирзаҗанова Сания Насибулла кызы (1940), Кафиятуллина Бибизә Бәхтегәрәй кызы (1952), Туфиятуллова Рауза (1938), Гиниятуллина Дания (1938), Валиуллова Сария;

**Филип (Филипповка):** Нитфулова Рауза Фәсхетдин кызы (71 яшь), Нитфулов Ринат, Кафиятуллова Руфия (70 яшь);

**Мукшы Күле:** Җәббәрова Сәмәрия (1940), Гайнетдинова Назимә (1957), Гайнетдинова Руфия (50 яшь), Гатауллова Закирә (1935), Шәрипова Гөлҗиһан (1932);

**Парау:** Ибатуллина Зәйтүнә Сафиулла кызы (101 яшь).

# АТАМАЛАРДА САКЛАНГАН ТАРИХ

*Фәридә Таһирова*

Тел тирән диңгез кебек бертуктаусыз хәрәкәттә, үзгәрештә ул. Бер яктан, ул яңа сүзләр, чит тел берәмлекләре белән тулыланып, баеп тора. Икенче яктан, кулланылыш өчен төгәлсез, уңайсыз булганнарын чыгарып ташлый тора. Әдәби телне чын мәгънәсендә бертуктаусыз баетып торган иң мөһим чыганак исә – телнең сөйләш һәм диалектлары. Аларны тикшерү тел белеменең иң җитди бурычларыннан берсе. Ульяновск өлкәсендә яшәгән татарларның теле дә – этрафлы лингвистик тикшеренү өчен бик биремле объект. Бу хезмәтебездә безне кызыксындырган өлкә – диалектның сүз байлыгы. Диалектның үсемлекләр, хайваннар, эш кораллары һ.б.ларның атамалары, көнкүреш лексикасы, аерым тармакларга караган терминологиясе шактый әйбәт өйрәнелгәнгә күрә, аларга тукталмыйча, сүз байлыгының тарихи вакыйгалар, аерым шәхесләр һ.б.лар белән бәйле, культур кодлар саклаган өлешен, ягъни иң экспрессив, иң җанлы, сөйләшүчегә иң якын өлешен анализлауны максат итеп куйдык.

Хәзерге Ульяновск өлкәсендә яшәгән татарлар дигәндә, беренче чиратта, татар теленең көнбатыш диалектында сөйләшүчеләр күздә тотылганга күрә, мишәрләр турында сүз алып бару дөрес дип саныйбыз. Мишәрләрнең барлыкка килүе, бу төбәккә җирләшү тарихы, теле һ.б. мәсьәләләр галимнәрне күптәннән кызыксындырганга күрә, бу турыда тарихчылар, этнографлар, әдәби тел һәм диалект белгечләре, төбәкне өйрәнүчеләр (алар арасында

татар гына түгел, рус һәм чит ил тикшерүчеләре дә бар) һ.б.лар тарафыннан күпсанлы хезмәтләр язылган. Аларның барысын да санап чыгу мөмкин түгел, кайберләрен генә атап үтү дә җитәдер[1].

Тел үзенчәлекләрен тикшерүдә якташыбыз Л.Т. Мәхмүтованың[2] хезмәтләре аеруча мөһим урын тота. Р.Г. Мөхәммәдованың[3] хезмәтләре дә бу төбәктә яшәгән татар халкын этнографик яктан өйрәнүдә шундый ук әһәмияткә ия. Күтәрелгән темалар, бирелгән материалның тирәнлеге, хезмәтнең әһәмияте, проблемага якын килү, фикер һәм карашлар ягыннан да нык аерылалар. Шуңа карамастан, ул хезмәтләрдән чыгып, бу төбәктә яшәүче татарларның тарихы, көнкүреше, теле һәм культурасы турында гомуми фикер формалаштырырга мөмкин.

Ульяновск өлкәсендә яшәүче татарларның тарихына килгәндә, бу якка алар башка төбәкләрдән, башлыча хәзерге Түбән Новго-

---

[1] *Малов Е.А.* Сведения о мишарях. Казань: Тип. импер. унив. 1885. 79 с.; *Магницкий В.К.* Несколько данных о мишарях и селениях их в Казанской и Симбирской губерниях. Казань: Тип. Импер. ун-та,1896; *Ахмаров Г.* О языке и народности мишарей // Известия Общества археологии, истории и этнографии (ИОАИЭ). 1903. Т. XIX. Вып. 2. С. 91–160.; *Малов С.Е.* Из поездки к мишарям (О наречии мишарей Чистопольского уезда). Казань: Тип. Импер. ун-та, 1904.; *Ахмаров Г.* Тептяри и их происхождение // ИОАИЭ. 1908. Т. XXIII. Вып. 5. С. 340–364.; *Биктимеров Ә.* Мишәр яки мишчәрләр // Шура. 1908. №14. Б. 436–438; *Бәшири З.* Мишәрләр // Шура. 1910. № 1. Б. 5–6; № 3. Б. 74–77; № 4. Б. 106–108; № 6. Б. 173–175; № 7. Б. 202–206; *Арсланов Л.Ш.* Татарские говоры правобережных районов Татарской и Чувашской АССР: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1966.; *Закиев М.З.* Об этнониме «мишар» и происхождение мишарей // Советская тюркология. 1978. № 3. С. 42–49; *Гарипова Ф.Г.* О гидрониме мишә, этнотопонимах мишәр и мажар // Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1990. С. 131.; *Орлов А.М.* Мещера, мещеряки, мишаре. Казань: Татар. кн. изд-во, 1992.; *Закиев М.З.* Татары: проблемы истории и языка. Сборник статей по проблемам лингвоэтноистории, возрождения и развития татарской нации). Казань: ИЯЛИ АНТ, 1995. 464 с.; *Исхаков Д.М.* Этническое развитие Волго-Уральских татар в XV – начале XX вв.: дис. в виде науч. докл.… д-ра ист. наук. М., 2000. 111 с. һ.б.

[2] *Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов: Мишарский диалект татарского языка. М.: Наука, 1978. 272 с. һ.б.

[3] *Мухамедова Р.Г.* Татары-мишари. Историко-этнографическое исследование. М.: Наука, 1972. 292 с. һ.б.

род, Рязань өлкәләре, Чуваш һәм Мордва Республикалары территорияләренә караган авыллардан күчеп килгән дигән мәгълүмат бар. Бу күчеш төрле төбәкләрдән, төрле чорларда һәм төрле сәбәпләр аркасында барган. Әлеге территорияләр Мәскәү дәүләте составына кертелгәннән соңгы чорларда күчүләрнең бер төрлесе чик буе киртәләре (засечные линии) торгызу белән бәйле. Ләкин ирекле рәвештә күчү дә, дәүләт тарафыннан бирелгән җирләргә килеп урнашу да, христианлаштырудан качып килү дә була. Мәсәлән, XVIII йөз башында татарларга Терешка елгасы буенда утарлар бирелә.

Бу турыда кайбер риваятьләр дә сакланган. Мәсәлән, заманында шуларның берсе Хәмит Ярми тарафыннан язып алынган. Риваятьтә Сембер губернасының Чокалы авылыннан чыккан Нөркә исемле кешенең егерме биш ел гаскәрдә хезмәт итүе, сугышларда батырлыклар күрсәтүе, шуның өчен патшадан махсус грамота алуы, Терешка елгасы буена килеп урнашуы, шул рәвешле, Иске Зеленай авылына нигез салыну турында сөйләнә (ФФ, колл. 76, п. 1, сак. бер. 10).

Татарларның мишәрләр дип аталган этник төркеме Идел-Урал регионының шактый киң территориясендә таралып яши. Хәзерге вакытта Ульяновск өлкәсендә дә, башка төбәкләрдә яшәгән татарлар да, үзләренә карата үзатама, этноним буларак ***мишәр*** сүзен кулланмый. Киресенчә, бик күптәннән ***татар*** сүзе кулланыла, һәм моны тел фактлары да, галимнәрнең фикере дә раслый. Мәсәлән, көнбатыш диалектында ***татар*** сүзенең мәгънәләре урта диалекттагы белән чагыштырганда күпкә артык; *бер татар да юк, барысы да урыс* (сүз «милләт» мәгънәсендә кулланылган); *карт татар выт син, акыл керегә вакыт!* (ир кеше); *елама, син вет татар тике инде!* (егет); *татарың качан китә?* (хатын ире). Мисаллар мишәрләрнең үзләрен татар буларак идентификацияләүләрен ачык күрсәтә. Мишәр сүзе исә хәзерге вакытта бары тик татар теленең көнбатыш диалектында сөйләшүчене белдерә һәм күбрәк галимнәр тарафыннан кулланыла.

Халык хәтерендә аның килеп чыгышына, ул катнашкан тарихи вакыйгаларга, элек яшәгән җирләренә һ.б.ларга караган

шактый күп мәгълүмат саклана. Күпчелек очракта әлеге мәгълүмат хәзерге информантларның үзләренә дә аңлашылмый торган сүзләрдән, риваятькә әверелгән фактлардан, яңгырашы үзгәргән исемнәрдән һ.б. гыйбарәт. Әлеге аерым фактларны бергә җыеп, төрле яктан – тарих, этнография, тел һ.б. ягыннан якын килеп, чагыштырып, махсус тикшеренү нәтиҗәсендә генә тулы бер картина итеп күзаллау мөмкин.

Бу төбәктә яшәүче татарларның элек яшәгән җирләреннән күчеп утыру процессын тарихи документларда күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, түбәндәге чыганакта безнең төбәккә кагылган кызыклы тарихи фактлар теркәлгән[1] (к. рәс. 1–2).

Хәзерге Ульяновск өлкәсенә караган җирләр төрле вакытта төрле административ берәмлекләргә караганга, татарларның рәсми статусы, салымнар түләү, җир бүлү, рус гаскәрендә хезмәт итү кебек мөһим факторларның үзгәреп торуы аркасында, бу төбәккә бәйле тарихи документлар да Идел буеның, гомумән Россиянең Казан, Саратов, Самара, Хвалынск, Пенза, Уральск һ.б. күп кенә шәһәрләренең архивларында саклана. Аларны өйрәнү тарихи гына түгел, башка бик күп фәнни тикшеренүләр өчен дә мөһим чыганак булып тора.

Төрле территорияләргә таралып яшәсәләр дә, мишәрләр төрле уртаклыкларын һәм үзара бәйләнешләрен саклыйлар. Тарихи документлардан соң мондый уртак үзенчәлекләрне чагылдырган иң мөһим чыганак булып тел, беренче чиратта аның лексик катламы тора. Бер яктан, төрле сөйләшләрдәге сүз байлыгының шактый зур өлеше алар өчен уртак. Гадәттә бу гадәти тормыш-көнкүреш лексикасына карый. Икенче яктан, һәр сөйләшнең үзенә генә хас сүз катламы була, ул – халыкның тарихи һәм культур кодларын саклаган өлеше. Моңа беренче чиратта ялгызлык исемнәр (авыллар, елга-күлләр, урман-таулар исемнәре, исем-фамилияләр, кушаматлар һ.б.) керә. Аларны тикшерүнең мөһимлеге турында галимнәрнең карашы бердәй. Мәсәлән, А.В. Суперанская болай

[1] Библиографическое описание. Саратовская ученая архивная комиссия. Труды Саратовской ученой архивной комиссии; под ред. С.С. Краснодубровского. Т. 3. Вып. 2 (1). Саратов, 1909.

| Названія населенныхъ мѣстъ. | До или послѣ переписи 1725 г. | Владѣльцы или составъ населенія. | Откуда пришло населеніе. |
|---|---|---|---|
| 46) Д. Сулейманово (Верхній Мастякъ), 66 д. м. п. | Послѣ. | Служилые татары. | Перешли изъ Симбирскаго у. (д. Мастякъ). |
| 47) Д. Кулатка, 174 д. м. п. | До | Служилые татары. | Указаній нѣтъ. |
| 48) Д. Средн. Кулатка, 28 д. м. п | Послѣ. | Служилые татары. | |
| 49) Д. Нижн. Кулатка, 25 д. м. п. | Послѣ. | Служилые татары. | |
| 50) Д. Ендовка, 102 д. м. п. | Послѣ. | Служилые татары. | Перешли изъ д. Старый Чуканъ (Симбирскаго у.), д. Картиковской, д. Зимницы, д. Ст. Тимошкина. |
| 51) Д. Новая Терешка, 118 д. м. п. | До | Служилые татары | Указаній нѣтъ. |
| 52) Д. Средн. Терешка, 72 д. м. п. | До | Служилые татары. | |
| 53) Д. Ендовка (Давыдовка), 34 д. м. п. | Послѣ. | Служилые татары. | Перешли изъ д. Средней Терешки. |
| 54) Верхняя Терешка, 249 д. м. п. | Послѣ. | Служилые татары. | Указаній нѣтъ. |
| 55) Д. Еделево, 391 д. м. п. | До | Служ. мордва, новокрещен. 230, некрещ. 160. | |
| 56) Зеленовка (Михайловка), 54 д. м. п. | Послѣ. | Служилые татары. | Перешли изъ дд. (Симб. у.): Мастяка, Лебежайки, Ст. Терешки, Стар. Чукала, Нижне-Чекурской. |

1 нче рәсем. Саратов губернасы Хвалын өязендә халык санын алу нәтиҗәләре теркәлгән ведомость

| Названія населенныхъ мѣстъ. | До или послѣ переписи 1725 г. | Владѣльцы или составъ населенія. | Откуда пришло населеніе. |
|---|---|---|---|
| 33) Д. Бѣлая Гора, 28 д. м. п. | Послѣ. | Служил. чуваши. | |
| 34) Д. Старый Атлашъ, 345 д. м. п. | До | Служил. татары. | Свѣдѣній нѣтъ. |
| 35) Д. Мосеена (Нов. Атлашъ), 13 д. м. п. | До | Служил. татары. | |
| 36) Д. Атлашъ, 21 д. м. п. | Послѣ. | Служил. татары. | Перешли изъ дд. Стараго Атлаша, д. Шатыршакъ, Нов. Тукшумъ, Ст. Какерли. |
| 37) Д. Зимницы, 100 д. м. п. | До | Служил. татары. | Свѣдѣній нѣтъ. |
| 38) Д. Ислаева (Нов. Зимницы), 63 д. м. п. | До | Служил. татары. | |
| 39) Д. Невѣркино, 138 д. м. п. | До | Служил. чуваши. | |
| 40) Д. Лебежайка (Вязоный Гай), 64 д. м. п. | До | Служил. татары. | |
| 41) Д. Елань-Кадада, 102 д. м. п. | До | Служил. чуваши. | |
| 42) Усть-Карноваръ (Елань-Кадада), 38 д. м. п. | Послѣ. | Служил. татары. | Перешли изъ Алаторскаго, Касимовскаго и Темниковскаго уу. |
| 43) Д. Евлейка, 137 д. м. п. | До | Служил. татары. | Указаній нѣтъ. |
| 44) Д. Мастякъ, 156 д. м. п. | До | Служилые татары. | |
| 45) Д. Средн. Мастякъ, 123 д. м. п. | До | Служилые татары. | |

2 нче рәсем. Саратов губернасы Хвалын өязендә халык санын алу нәтиҗәләре теркәлгән ведомость

ди: «Имена собственные – самая восприимчивая часть языка, они реагируют на все исторические и культурные события быстрее, чем любой другой его элемент»[1]. Ялгызлык исемнәрнең зур бер өлеше чынлап та турыдан-туры тарихи урыннарга, тарихи вакыйгаларга бәйле рәвештә барлыкка килгән. Мәсәлән, Карсун районы Нугай иле авылы янындагы бер тау ***Калатау*** дип йөртелә. Микротопоним әлеге тау башында борынгы кирмән булган дигән риваять белән бәйле. Риваятьнең нигезе бар дип уйлыйбыз, бу тирәдә узган чик буе киртәләре сызыгындагы ныгытмаларның берсе тагын да борынгырак чорга караган булырга мөмкин. Икенчесе дөреслеклеккә якынрак кебек. Борынгы шәһәрләр урнашкан тауларны ***Калатау*** дип атау очраклы түгел. Мәсәлән, Татарстанның Балык Бистәсе районындагы ***Калатауның –*** болгар чорына караган Чаллы шәһәре, ә Чистай районындагы ***Калатауның*** Җүкәтау шәһәре урнашкан җир булуы мәгълүм. Мондый риваять Иске Кулаткы районы Иске Мостяк авылы янындагы ***Казантау*** турында да яшәп килә. Аның артында елга буенда крепость торган, җир асты юллары да ясалган булган, хәрбиләр каравыл хезмәте тотканнар дип сөйлиләр (Иске Мостяк авылы; информант Ганиев Марат Исхак улы, 1936). ***Мәрәй тавы*** (Карсун районы, Уразовка авылы) атамасы да тарихи булырга тиеш. ***Мәрәй*** сүзенең беренчел мәгънәсе «уктан ату өчен мишень; ярыш төре буларак уктан ату үзе» икәнен истә тотсак, бу тауның хәрби тарих белән бәйле булуын фаразлау мөмкин. Бу фараз тарихчыларның фикеренә дә каршы килми. Тарихчы Ф. Хуҗин: «Ульян һәм Самара өлкәләрендә болгар истәлекләре күп һәм ел саен яңалары табыла тора», – дип раслый[2].

Билгеле булганча, күчеп килгән халык озак вакытлар дәвамында үзенең туган җиреннән алып килгән атамаларын саклый. Моны хәзерге топонимия мәгълүматлары да дәлилли. Мәсәлән, ***курмиш***/***курмыйш*** сүзе хәзерге вакытка кадәр актив кулланышта

---

[1] *Суперанская А.В.* Общая теория имени собственного. М.: Изд-во ЛКИ, 2007. С. 40–41.

[2] *Хуҗин Ф.* Болгар иле һәм аның шәһәрләре: ачышлар, табышлар, фаразлар. Казан: РИЦ «Школа», 2005. Б. 215.

йөри, семантик үзгәреш кичереп, «авылның бер очы, бер микрорайоны, бер мәхәлләсе», шулай ук «бер хуҗалык» мәгънәсен белдерә. Билгеле булганча, заманында Түбән Новгород губернасында Курмыш шәһәре һәм өязе булган. Иваново, Рязань, Түбән Новгород өлкәләрендә хәзерге вакытта да ***Курмыш*** атамасын йөрткән дистәләгән авыл бар. Бу ике лексик берәмлек арасында турыдан-туры бәйлелек булуы ачык аңлашыла.

Кайбер авылларда микротопоним буларак ***Узин*** сүзе кулланыла. Иске Зеленай һәм Зимичәдә (Иске Кулаткы районы) ул авылның бер очын, бер микрорайонын белдерә. Беренче карашка ул әдәби телдәге ***үзән*** сүзенә кайтып калырга тиеш булса да, мишәр диалектында әлеге сүз кулланылмаганга күрә, аның урынына башка берәмлекләр йөри (***елга, яр*** һ.б.). Көньяктарак аккан (Саратов өлкәсе, Казакъстан) ***Узень*** елгасы белән бәйле булу ихтималы да бар, әмма ул яктан күчеп утыру бу чорларга карамый. Безнеңчә, бу микротопоним Пенза һәм Саратов өлкәләрендә аккан ***Уза*** елгасы (Сура кушылдыгы) белән турыдан-туры бәйле. Пенза өлкәсенең Шемышейка районында хәзерге вакытта да XVII гасырда нигез салынган ***Усть-Уза*** исемле зур татар авылы бар. Саратов өлкәсенең Петровск районындагы Яңа Усть-Уза авылы булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Ничек кенә булмасын, бу – аерым очрак, шушы төбәктә куллану үзенчәлеге булып тора, чөнки башка фикерләр булуга карамастан (борынгы русча ***узменъ*** «тар урын, тар ермак, су» сүзеннән (И.И. Срезневский)), ахыр чиктә ***Уза, Узин***/***Узень*** сүзләре, әлбәттә, барыбер ***үзән*** сүзенә кайтып кала.

Хәзерге ***Яндука*** авылы (Иске Кулаткы районы) атамасы да шул рәвешле күчеп килгән булуы мөмкин. Элек бу атама архивларда русча ***Ендовка*** рәвешендә теркәлгән. Ул Түбән Новгород өлкәсендәге ***Ендовище*** атамасы белән аваздаш булып, аларны бары тик ***-ище*** «зур», ***-ка*** «кечкенә» мәгънәсен белдергән кушымчалар гына аера, ягъни зур авылдан чыгучылар кечерәк авылга нигез салган булуы мөмкин.

Кайбер кушаматларның нигезендә шулай ук тарихи мотив ята. Мәсәлән, ***Шалман*** (Иске Кулаткы районы Иске Яндука авылы) кушаматы ***лашман*** сүзеннән килеп чыккан. Бүгенге көндә куша-

матны йөртүче юк, бу нәсел XX гасыр урталарында юкка чыккан яки бу кушамат белән тәңгәлләштерелми. Әмма әлеге нәсел кешеләренең гадәттән тыш эре гәүдәле, көчле булуы турында халык арасында бүген дә сөйләнә. ***Лашман*** сүзе үзе дә бу сөйләштә «артык зур, эре» мәгънәсендә кулланыла. Билгеле булганча, Пётр I нең указы белән диңгез флоты өчен кораблар төзелә башлый һәм крестьяннарны урман кисү эшенә лашманлыкка алу башлана. ***Лашман*** (немецча ***Laschmann***, ***Laschen*** – кисү, чабу, юну һәм ***Mann*** – кеше). Урта Идел буенда бу коточкыч авыр хезмәткә алынганнарның күпчелеген татарлар тәшкил итә. Бу вакыйга күп кенә татар атамаларында бүгенге көнгә кадәр саклана (Татарстан Республикасының Чирмешән районындагы Лашман авылы, Рязань өлкәсендәге Лашман авылы һ.б.). атлаш.ру сайтындагы тарихи материаллар да хәзерге Иске Кулаткы районы халкының лашманчылыкта катнашуын раслый. Мәсәлән, анда бу хезмәттә күпме кеше катнашу турында мәгълүмат теркәлгән. Сайтны оештыручы физика-математика фәннәре кандидаты Рөстәм Самерханов, гомумән, төбәкне өйрәнү буенча тынгысыз эш алып бара. Мәләкәс районы лашманчылары тарихы турында Мәсгут Гайнетдинов хезмәтендә шактый җентекле язылган[1]. Ул да шулай ук архив материлларына таянып эш итә. Мәсәлән, татар авылларында яшәүчеләрнең лашманлыктан удел крестьяннары төркеменә күчерелүе турында Сенатның



**Опись дѣлъ, принадлежавшихъ архиву уѣзднаго казначейства въ г. Петровска.**

Отъ 2 января 1783 г. № 30... „Казанская адмиралтейская контора требовала, чтобы состоящимъ въ здѣшнемъ намѣстничествѣ служилымъ татарамъ, бывшимъ изъ нихъ въ осени 781 и зимѣ 782 г. въ работѣ при заготовности и вывозкѣ карабельныхъ и прочихъ лѣсовъ, по силѣ указа 21 іюня 1774 г., учинить при платежѣ ими адмиралтейскаго сбора зачетъ, полагая конному по 16 к., а пѣшему по 10 к. въ день да за переходъ и переѣздъ изъ домовъ до пристаней и обратно въ дома пѣшимъ по 3 к., а коннымъ по 6 к. въ день же и сколько онаго зачета и коликому числу душъ въ точности зачесть надлежитъ (контора) приложила реестръ"...

Изъ реестра видно. что въ работахъ участвовало изъ 97 селеній Петровскаго, Кузнецкаго и Хвалынскаго уѣздовъ всего 9690 душъ. коимъ зачтено 7082 р. 30 к. Самое большое число татаръ высылалось на работы изъ слѣдующихъ селеній: Усть-Уза 634, Мостякъ 193, Моисеевка 195, Ст. Атлашъ 396. Кулатка 191, Верхняя Терешка 274, Ср. Терешка 174, Зимнина 210, Могилы 334, Каменный Бродъ 161, Вершаутъ 240, Суляево 306, Бикбулатъ 152. Канадеи 272, Вѣгеево 152. Верхняя Елюзань 395, Средняя Елюзань 631. Нижняя Елюзань 318, Индерка 467, Пендѣлка 308, Труево 181.

3 нче рәсем. Аерым авыллардан лашманлыкка алу турында

[1] *Гайнетдин М.В.* Мәңге тоныкланмас көзгебез. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 348 б.

1837 елгы 22 март указы китерелә (күчермә Сембер архивында саклана):

Ставрополь өязе Филип волостеннан:
Югары Исәнтимер –206 җан;
Урта Исәнтимер – 142 җан;
Яңа Исәнтимер – 200 җан;
Мулиев Враг – 159 җан;
Моисеев (Масәй) – 297 җан;
Үрәнбаш (Мукшы Күле) – 289 җан;
Сабакаева (Әврәле) –152 җан;
Аллагулова (Грязнуха тож) – 275 җан;
Измайлово (Тёплый Стан тож) – 502 җан;
Сабакеева (Сосновый Враг тож) – 89 җан;
Кубан озеро – 34 җан;
Выселок (Сускан) – 501 җан;
Лабитово – 263 җан;
Абдреево – 247 җан;
Новое Урайкино (Кызылсу) – 86 җан;
Филипповка – 353 җан;
Елховый куст – 272 җан.
Уразгилде волостеннан:
Татарский Калмаюр – 14 җан;
Чувашский Калмаюр – 67 җан;
Старый Урянбаш – 157 җан;
Новый Урянбаш – 77 җан;
Айтугановская Енгалиевой – 364 җан;
Ертуганово (Кандалка тож) – 437 җан;
Асаново – 147 җан;
Ставрополь өязеннән барысы –5357 җан.

Пётр I заманыннан башлап Урта Идел буенда яшәгән татарлар регуляр рус гаскәрендә хезмәт итә башлыйлар. Гадәттә хезмәт срогы 25 ел тәшкил итә. Кырым татарлары яки Башкортстан һәм Оренбург губернасы татарлары (мишәрләре һәм типтәрләре) кебек аерым милли берләшмәләрдә хезмәт итү мөмкинлеге булмый, башлыча руслар һәм башка халыклар белән

бергә теләсә кайсы полкта, теләсә кайсы төбәктә хезмәт итәләр. ***Солдат*** кушаматы (Иске Кулаткы районы Иске Яндука авылы) тарихның әлеге сәхифәсе белән бәйле. Ул 25 ел хезмәт иткән кешегә кушылган булган. Хәзерге вакытта аны йөртүче юк, соңгысы ***Солдат Гафуры*** була. Нәселнең башка кушамат белән дәвам итүе дә мөмкин.

***Вуен (воин) коесы*** (Иске Кулаткы районы Иске Мостяк авылы; информант Ганиев Марат Исхак улы, 1936) микротопонимының нигезендә дә шул ук тарихи мотив ятуы ихтимал.

Тарихчыларның мәгълүматларына караганда, Сембер халкы 1812 елгы Ватан сугышында, татарча итеп әйтсәк, Рус-француз сугышында актив катнаша. Билгеле булганча, сугыш башлануга Россиядә өч хәрби округ, шул исәптән Идел буе округы булдырыла. Регуляр гаскәр белән беррәттән, Сембердә ополчение җыю бара, нәтиҗәдә өч җәяүле, бер атлы полк төзелә. Алар составында әлбәттә, татарлар да була. Соңрак, ополчение полкларына Идел һәм Җаек буенда урнашкан иррегуляр Мишәр, Типтәр полклары да кертелә. Бу ополчение Глогау, Замостье, Дрезден, Магдебург һәм Гамбург кебек шәһәрләр өчен барган сугышларда катнаша. 2 нче Типтәр һәм 2 нче Мишәр полкларының Парижга барып җитүе билгеле. Бу полкларның сугышчылары «1814 елның 19 мартында Парижны алган өчен» һәм башка билгеләр белән бүләкләнә. 1812 елгы Ватан сугышында катнашучыларның барысы да «1812–1814 еллар сугышы истәлегенә» дигән көмеш медаль белән бүләкләнә.

Бу тарихи вакыйга лексикада шулай ук чагылмый калмый. Мәсәлән, ***Пальчин*** кушаматы (Иске Кулаткы районы Иске Яндука авылы) ***апалчин – ополченец*** сүзеннән килеп чыккан. Бу турыда ***Пальчин*** кушаматын йөртүче Тимербулатов Шаһимәрдән абый 1970 елларда үзе сөйли торган булган. Бабаларының берсе әлеге ополчениедә катнашканга күрә, аңа шул кушамат бирелә. Бүгенге көндә дә бу нәсел кешеләре әлеге кушаматны йөртә.

Беренче бөтендөнья сугышында, төрле мәгълүматларга караганда, бер миллионнан артык татар солдаты катнаша. XX йөз башында Идел-Урал регионында татарларның саны 3,5 миллион

кешедән чак кына артык булуын истә тотсак, моның бик зур күрсәткеч икәне аңлашыла. Алар арасында, әлбәттә, безнең якташларыбыз да күп була. Бу турыда шулай ук тарихи документларга нигезләнеп фикер йөртә алабыз. Мәсәлән, Россия дәүләт китапханәсендә сакланган түбәндәге документта күп кенә якташларыбызның исем-фамилияләре теркәлгән[1] (к. рәс. 4–5).

Бу төр документларда милләттәшләребезнең кайда һәм ничек сугышуы, батырлык күрсәтү, яралану, һәлак булу очраклары

| № п/п | Фамилия | Имя, Отчество | Губерния, Уезд, Волость, Нас.пункт | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Тагиров | Абдул Ахат | Туркестанское ген.-губ., Ферганская обл., мч. Коканда | ↓ |
| 2 | Тагиров | Али Тагирович | Саратовская губ., Хвалынский у. | ↑ |
| | | Воинское звание: | Рядовой | |
| | | Вероисповедание: | Мусульманское | |
| | | Семейное положение: | Женат | |
| | | Событие: | Ранен | |
| | | Дата события: | 11 ноя.1914 | |
| | | Источник: | «Именной список №1002 убитым, раненым и без вести пропавшим солдатам.», стр.16025 | |
| 3 | Тагиров | Ахмат Галий | Уфимская губ., Бирский у., Илишевская | ↓ |
| 4 | Тагиров | Ахмет | Казанская губ., Царёвококшайский у. | ↓ |
| 5 | Тагиров | Валеулла | Уфимская губ., Уфимский у., Булекей- Кудейская | ↓ |
| 6 | Тагиров | Галим | Уфимская губ., Уфимский у., Караякуповская, д. Расбагат. | ↓ |
| 7 | Тагиров | Галям | Уфимская губ., Уфимский у. | ↓ |
| 8 | Тагиров | Гантрафик | Пермская губ., Осинский у., Бардымской | ↓ |
| 9 | Тагиров | Заир | Пермская губ., Шадринский у., Беломорской | ↓ |
| 10 | Тагиров | Зикур | Уфимская губ., Бирский у., Старо-Балтачевская | ↓ |
| 11 | Тагиров | Ибатул Хамет. | Уфимская губ., Стерлитамакский у. | ↓ |
| 12 | Тагиров | Ибрагим Изатул. | Симбирская губ., Сенгилейский у., Старо-Тимошкинская вол. | ↓ |
| 13 | Тагиров | Карим | Уфимская губ., Уфимский у., Карит-Куковской | ↓ |
| 14 | Тагиров | Ликлихитдин | Пермская губ., Шадринский у., Тече-Башкирской | ↓ |
| 15 | Тагиров | Миссшхидтит. | Пермская губ., Шадринский у., Башкиротеченской в. | ↓ |
| 16 | Тагиров | Мухтур | Уфимская губ., Белебеевский у., Якимковская | ↓ |

4 нче рәсем. Беренче бөтендөнья сугышында катнашучы татарлар турында мәгълүмат

[1] Именной список убитым, раненым и без вести пропавшим нижним чинам [Текст]. – П.: Военная тип. имп. Екатерины Великой, 1914 – 1920.

| № п/п | Фамилия | Имя, Отчество | Губерния, Уезд, Волость, Нас.пункт | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Хабибулин | Ахмет Хайретдинович | Симбирская губ., Буинский у., Ново-Какерлинская, и село | ↓ |
| 2 | Хабибулин | Халиулла | Симбирская губ., Курмышский у., Чембелеевская вол. | ↓ |
| 3 | Хабибулин | Хасян | Симбирская губ., Курмышский у., Чембелеевская вол., с.Рыбницы | ↓ |
| 4 | Хабибулин | Якуб Хабибулович | Симбирская губ., Карсунский у., Сосновская вол., Урозов. | ↑ |

| | |
|---|---|
| Воинское звание: | Ефрейтор |
| Вероисповедание: | Мусульманское |
| Семейное положение: | Холост |
| Событие: | Ранен |
| Дата события: | 27 августа 1914 г. |
| Источник: | «Именной список №269 убитым, раненым и без вести пропавшим нижним чинам.», стр.4226 |

5 нче рәсем. Беренче бөтендөнья сугышында катнашучы татарлар турында мәгълүмат

теркәлә. Татарларның күпчелеге сугышта «түбән чинда», ягъни гади солдат булып катнаша. Әмма түбәндәге документтан күренгәнчә, рус гаскәренең сайланма полкларыннан саналган һәм императорларның шәхси гвардиясе дәрәҗәсендә булган Лейбгренадер полкында хезмәт итүчеләр дә булган (к. рәс. 6).

Халыкның тарихында, мәдәниятендә булган мөһим үзенчәлекләр һичшиксез лексикада чагыла. Һәм мондый үзенчәлекләрне аеруча киң чагылдырган лексик катлам булып топонимнар, микротопонимнар, кыскартылма исем-фамилияләр, кушаматлар һ.б.лар тора. Югарыда китерелгән мисаллар кебек турыдан-туры аерым тарихи вакыйга, чор, күренеш белән бәйле булмасалар да, бу төр сүзләр төбәк, авыл, аерым нәсел тарихын чагылдырганга күрә, алар ахыр чиктә барыбер тулаем халык тарихын саклый торган әһәмиятле элементлар булып торалар.

Топонимнарның, шул исәптән микротопонимнарның, ясалышы нигезендә яткан мотивлар гаять күптөрле. Микротопонимнар арасында кеше исеме белән атау беренче урында тора. Шундыйларга түбәндәге атамалар карый: ***Сафа тавы, Чәкәй тавы*** (кыскартылма, исем яки кушамат; Иске Кулаткы районы Муса авылы; Кузахметова Маһидә Алиҗан кызы, 1938); ***Дәви кизләве*** (кыскартылма, Дәви (Дәүләтша?) исемле кеше казыган булган); ***Ганкәй кизләве*** (кыскартылма, Гани....?); ***Җарка кизләве*** (кыскартылма, Җарулла исеменнән; Иске Кулаткы районы Иске Мостяк авылы; информант Ганиев Марат Исхак улы, 1936); ***Атаулла кизләве,***

| № п/п | Фамилия | Имя, Отчество | Губерния, Уезд, Волость, Нас.пункт | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Антобаев | Макудис Иванович | Саратовская губ., Хвалынский у., Старо-Кулаткинская | ↑ |
| | | Воинское звание: | Ефрейтор | |
| | | Вероисповедание: | Православное | |
| | | Семейное положение: | Женат | |
| | | Событие: | Ранен | |
| | | Дата события: | 9 мар.1915 | |
| | | Источник: | «Именной список №1332 убитым, раненым и без вести пропавшим солдатам.», стр.21312 | |
| 2 | Бектемиров | Сулейман | Саратовская губ., Хвалынский у., Старо-Кулаткинская в. и с. | ↑ |
| | | Воинское звание: | Лейб-гренадёр | |
| | | Вероисповедание: | Мусульманское | |
| | | Семейное положение: | Женат | |
| | | Событие: | Ранен | |
| | | Дата события: | 18 дек.1914 | |
| | | Источник: | «Именной список №356 убитым, раненым и без вести пропавшим нижним чинам.», стр.5690 | |
| 3 | Белялов | Хусаин | Саратовская губ., Хвалынский у., Старо-Кулаткинская в. и с. | ↓ |
| 4 | Бикбаев | Мукдин | Саратовская губ., Хвалынский у., Старо-Кулаткинская | ↑ |
| | | Воинское звание: | Рядовой | |
| | | Вероисповедание: | Мусульманское | |
| | | Семейное положение: | Холост | |
| | | Событие: | Пропал без вести | |
| | | Дата события: | 7 дек.1914 | |
| | | Источник: | «Именной список №227 убитым, раненым и без вести пропавшим нижним чинам.», стр.3632 | |
| 5 | Газваров | Юнус | Саратовская губ., Хвалынский у., Старо-Кулаткинская | ↑ |
| | | Воинское звание: | Рядовой | |
| | | Вероисповедание: | Мусульманское | |
| | | Семейное положение: | Холост | |

6 нчы рәсем. Беренче бөтендөнья сугышында катнашучы татарлар турында мәгълүмат

***Сәнҗук маңгае*** (Иске Кулаткы районы Урта Терешка авылы; Закирова Зәкия Мәин кызы, 1938); ***Исән елгасы*** (Иске Кулаткы районы Атлаш авылы; Маннапова (Хәмзина) Җәүһәр Исән кызы, 1924; Бөек Ватан сугышы ветераны); ***Михайля елгасы*** (анда Михаил исемле кеше тегермән тоткан); ***Яков угылы*** (бакчалар, урыс утары булган диләр; Иске Кулаткы районы Вязовый Гай авылы, информант Деникаев Рушан Ибраһим улы, 1947).

Урын белән бәйле исемләндерелгән атамалар: ***Тал кизләве*** (таллыкта булганга күрә), ***Күл юлы урманы*** (урман эчендә борын заманда ясалма буа яки бассейн булган; Иске Кулаткы районы, Иске Мостяк авылы); ***Мулла кизләве*** (мулла өе турысында; Иске Кулаткы районы Урта Терешка авылы).

Иң мөһим үзенчәлектән чыгып аталганнар: ***Сары күл*** (торфлы җирдә урнашкан, шуңа күрә суы сары), ***Упкын күле*** (батып үлү очраклары еш булганга күрә; Иске Кулаткы районы, Иске Мостяк авылы); ***Нимес тирмәне*** (Павловка районында Тазбалык елгасындагы тегермәнне немец кешесе төзеткән булган); ***Айгыр елгасы*** (бу урында кыргый атлар булган дигән риваять бар); ***Кәҗәкүл*** (якын-тирәсендә кыр кәҗәләре булган; Иске Кулаткы районы Вязовый Гай авылы); ***Күркле тау*** (яз башында ыргаземба́й чәчәге (пион тонколистный, «Россиянең Кызыл китабы»на теркәлгән) аткач, бик матур манзара барлыкка килә; Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылы).

Үзенчәлекле лексик берәмлекләр булган кушаматларга килгәндә, хәзерге кушаматлар яңгырашы, килеп чыгышы, кушылу мотивлары ягыннан күптөрле. Алар турында телче Н.В. Подольская болай дип яза: «Прозвище – дополнительное имя, данное человеку окружающими людьми в соответствии с его характерной чертой, а также профессией, сопутствующим его жизни обстоятельством или по какой-либо аналогии»[1].

Исем кушудан аермалы буларак, кушамат бирүнең мотивы нигезендә кешенең шәхес буларак характер үзенчәлекләре яки аерым индивидның физик сыйфатлары ята. Ягъни кешегә берәр уңай сыйфатны белдергән исем кушып, аның шундый булуын өмет итсәләр, кушаматны кешенең чынлыкта нинди булуын күреп, шуңа нигезләнеп тагалар. Кушаматта, шул рәвешле, башкаларның бу кешегә мөнәсәбәте чагыла. Гадәттә кушаматлар кеше гомеренең төрле чорында кушыла һәм аны белүчеләр даирәсе артык киң булмый. Соңгы чорларда кушаматлар корпусының бик тиз үзгәрүчән булуы, тиз алмашынуы, нәсел кушаматларына караганда индивидуаль, ягъни аерым шәхескә тагылганнарының ешрак кулланылуы күзәтелә.

Кушаматлар арасында иң борынгылары, мөгаен, хайван атамалары булгандыр. Бу кушаматларны борынгы тотемистик

---

[1] *Подольская Н.В.* Словарь русской ономастической терминологии / отв. ред. А.В. Суперанская. Изд. 2-е, перераб. и доп. М.: Наука, 1988. 192 с.

ышанулар белән бәйләп карау бик кызыклы булыр иде, әмма хәзерге вакытта моны нигезле, дәлилле итеп исбатлау мөмкин түгел. Кушамат буларак зоонимнар куллану күпчелек очракта гади охшатуга гына кайтып калмыйча, метафорик күчерү юлы белән кешенең (яки гаиләнең, ыруның) сөйләү, йөреш, кыланыш һ.б. сыйфатларына, берәр конкрет вакыйгага ишарәли. ***Бозау*** (әнисенең улын ияртеп йөрү гадәтенә төрттерү); ***Бүре*** (усал кешеләргә тагыла); ***Титиләр*** (гаилә ишле булуга ишарә); ***Кучатлар*** (җор телле, уен-көлкегә, төрлечә кыланып күрсәтергә осталар); ***Корка*** (кыяфәте һәм холкы белән ата күркә кебек гайрәтле); ***Әрлән*** (кара һәм кечкенәләр, үзләре күбәү); ***Черки*** (һәр эшкә җиңел керешүче, җиңел холыклылар); ***Кукук*** (ир башы белән башка авылдан хатыны авылына күчеп килгән) һ.б.

***Куян, Кәҗә, Аю, Бүре, Төлке, Үрдәк, Чебен, Кучат, Кырка*** / ***Корка*** кебек кушаматларны һәр авылда диярлек очратырга мөмкин, әмма төрле торак пунктта аларның мотивлары бер үк төрле булмый. Югарыда әйтелгәнчә, кушаматларның кулланылышы, таралу ареалы тар була, шуңа күрә, бер авылда, районда яшәгән кушаматның кемгә, кайчан, ни өчен кушылуы башка райондагы кешеләргә мәгълүм булмый. Аларның авылында яки районында шул ук кушаматны башка сәбәп белән тагарга мөмкиннәр. Мәсәлән, ***Кыргызлар*** кушаматы бер районда тышкы кыяфәткә бәйле рәвештә бирелгән булса, башка районда аерым вакыйга белән бәйле килеп чыга: бер кызны туганнары казакъларга (ул вакытта кыргызлар дип йөртелә) саталар.

Холык үзенчәлекләрен, гадәтләрен чагылдырган кушаматлар: ***Мокай*** (астыртын), ***Шыр-шыр*** (сөйләмчәк), ***Топтыгин*** (йөремсәк), ***Пашча*** (патша сүзеннән – ереләнүчән, масаючан); ***Кайгысыз*** (үзләре байлар, башка кешене уйламыйлар) һ.б.

Үзенчәлекле, еш әйтелә торган сүздән, сөйләшү үзенчәлеген чагылдырган кушаматлар: ***Чурай*** («чирут» (чират) сүзеннән), ***Культура*** («культурный булсын» сүзеннән); ***Пример*** («например» сүзеннән).

Кушамат кушу мотивлары арасында иң гадие һәм еш очраганы кыяфәт үзенчәлегедер мөгаен: ***Ызыннар*** (озын буйлылар),

***Пайпан*** (таза, симез кеше), ***Полсапог*** (кыска буйлы), ***Аю*** (бик таза, эре, йөрәкле).

Кушамат буларак этнонимнар бирү еш кына шул ук тышкы охшашлык мотивына нигезләнгән: ***Чиганнар*** (чегәннәр кебек каралар). Ләкин бу һәрвакытта да шулай дигән сүз түгел. Башка мотивка таянып бирелгәннәр дә бар: ***Мадяр*** (Венгриядә сугышта булган). Алда китерелгән ***Кыргызлар*** кушаматы да шундыйлардан.

Тарихи шәхесләр, киң танылган, популяр кешеләр исеме белән атауның нигезендә төрле вакытта төрле мотив ятарга мөмкин. Күпчелек очракта төп мотив булып, әлбәттә, тышкы охшашлык тора: ***Хрущёв, Гитлер, Корчагин, Косыгин, Романов, Чемберлен*** (фронтта бер күзен югалткан) һ.б.

Биографиясендәге яки авыл тормышындагы берәр мәгълүм фактка нигезләнеп кушылганнар: ***Гимня*** («гимназист» сүзеннән, заманында бабаларының берсе гимназиядә укыган?), ***Сипарат*** (авылда беренче сипарат алучы) һ.б.

Кеше исеме яки фамилиясе кыскарып, үзгәреп барлыкка килгән кушаматлар шулай ук күп: ***Фәскай, Можҗа, Гани*** һ.б.

Кушылу мотивы билгеле булмаган, сакланмаган, онытылган кушаматлар: ***Люки, Куряй, Чашын, Нәтәк, Патай, Пыка, Катый, Черкен, Фря*** һ.б.

Әлбәттә, югарыда анализланган берәмлекләр исемлегенә тагын бихисап мисаллар өстәргә мөмкин булыр иде. Гомумән, күрүебезчә, халык телендә аның тарихына, культурасына, этнографиясенә, көнкүрешенә караган бай мәгълүмат саклана. Элеге байлыкны саклау, онытылып юкка чыкмас борын, аны тиешенчә, төрле яклап бәяләү өчен, даими һәм систематик рәвештә тикшереп тору мөһим. Ульяновск өлкәсендә үткәрелгән комплекслы экспедиция вакытында безнең тарафтан алып барылган эзләнүләр нәкъ әлеге бурычны күздә тотып башкарылды, чөнки диалект материаллары теләсә нинди лингвистик – этимологик, терминологик, лингвокультур һ.б. – тикшеренүләрнең нигезендә ята.

## Язып алынган әсәрләр

### Мөнәҗәтләр

1

Әгузе билләһи минәшшәйтан
ирраҗим
Бисмиллаһи иррахмән иррахим.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Мөнәввәр әйлә кальбымны
Иман белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Мөнәввәр әйлә кальбымны
Ислам белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Мөнәввәр әйлә кальбымны
Коръән белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Мотый әйлә кальбымны
Гыйбадәткә сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Саф әйләгел кальбымны
Гөнаһлардан сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Шайтан ширендин саклагыл
Фәзлең белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Җан бирмәкне асан әйлә
Фәзлең белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Каберемне руман әйлә
Фәзлең белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Рәхмәт фәрештәсен җибәр
Каберемә сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Сөалемне асан әйлә
Җавабымда сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Уңымдин биргел нәмамны
Кыяму́ттә сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Изге гамәлемне авыр кылгыл
Мизанымда сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Рәсүлулла шәфигатен
Насып әйлә сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Сират күперен җиңел күчер
Фәзлең белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Тамугыңны харам әйлә
Фәзлең белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Җәннәтеңне насыйп әйлә

Фәзлең белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Дидареңне насыйп әйлә
Фәзлең белән сөбхан Алла.
Бисмиллаһи Тәгаль Алла,
Әррахмән әррахим Алла,
Догаларым кабул әйлә
Мырадым бир сөбхан Алла.
Амин.

2.

Бисмиллаһи иррахмән иррахим.
Бу дөньяда кунак булдым,
Белер-белмәс гамәл кылдым,
Ходаем, үзең кабул кыл.
Рәхим кылгыл Иләһием.
Ерак кылма күңелемне,
Якын тоткыл үлememне,
Сәхәрләрдә зикер белән
Сафландыр күңелемне.
Зикер кылып сафлансын,
Иблис мәалавын җәфалансын,
Бер Ходаем иман нурын
Безнең калепләргә салсын.
Алла дисәң, калебың үлмәс,
Иманыңның нуры сүнмәс,
Кабереңдә азап күрмәс
Укыек Аллаһ, Аллаһ дәю.
Йөримен дөньядан туймый,
Башымны сәждәгә куймый,
Азыгымны әзерләми,
Ярый хур булмасам анда.
Бер үлмәк бар, терелмәк бар,
Гамәлләрне сорамак бар,
Ләхетем тар, чыгар җир юк,
Монда рәхмәт нәзарың сал.
Раббым, утыңда яндырма,
Мәңге тамугта калдырма,
Рәхмәтеңнән син аерма,
Укыйк Аллаһ, Аллаһ дәю.
Ху йыгачы сачак аткан,
Ботагына без дә куныйк,
Яумел мәхшәр мәйданында,
Дусларым, бергә булыйк.
Рәсүлулла пыраклары
Җәүһәр-якут тояклары,
Изгелекләр кылыйк, дуслар,
Без – бу дөнья кунаклары.
Рәсүлулла – үзең җәүһәр,
Баскан эзләрең менәвәр,
Фидядыр юлыңа җаным.
Йөзе рушанлыгы бетмәс,
Мәдех итсәм сүзе бетмәс,
Күзләремдин яшьләрем бетмәс,
Аллаһ, Аллаһ әйтеп дәю.
Амин.

3.

Бисмилләһи иррахмән иррахим.

1. Аллаһтан рәхмәт явар шул җаннарга,
   Сәхәр торып таң намазы кылганнарга,
   Дәм ганимәт бер сулышны байлык санап,
   Алла исемен зикер итик мәйданнарда.
2. Сәхәрләрдә кылган дога булыр мәгъбуль,
   Изге җаннар таат белән булыр мәшгуль,

Булыйм дисәң рәсүлгә өммәт, Аллага кол,
Алла исемен зикер итик мәйданнарда.
3. И, бер адәм, дөнья куйма михнәт чигеп,
Рәсулулла димәдеме, дөнья җефет,
Акыл ирсәң бу сүз барчабызга үгет,
Алла исемен зикер итик мәйданнарда.
4. Бу дөньяны күпме кусаң, булмый җитеп,
Рәсулулла диде дөнья куганны эт,
Булыйм дисәң әгәр инсан, булмыйча эт,
Алла исемен зикер итик мәйданнарда.
5. Аллаһ яден әйтү кирәк һәр заманда,
Кичә-көндез, өйдә вә яки япанда,
Кайда әйтсәң, сәйяр фәрештәләр анда,
Алла исемен зикер итик мәйданнарда.
6. Дөнья өчен файдалыдыр хаерлы мал,
Ахирәткә файдалыдыр изге гамәл,
Тотмас борын якабыздан килеп әҗәл,
Алла исемен зикер итик мәйданнарда.
7. ----------------------------------------------
Бу аятьне аңнаган кол мәхфумни
Бушка үткәрмәс язын-кышын, көнен-төнен,
Алла исемен зикер итик мәйданнарда.
8. Ни ганимәт дөнья ахирәт мондый колга
Бар үмерен фидя кылган изге юлга.
-------------------------------------------
-------------------------------------------
9. Алланың сөяр дусты рәсулулла,
Остазымыз мөршид Камил Хәбибулла,
Мөридләрен дәват кылган ошбу юлга,
Алла исемен зикер ит, диеп мәйданнарда.
10. Карамагыз сүнгән йөрәк наданнарга,
Минем кебек ашап яткан хайваннарга,
60 сәнә үмеремне җилгә үткәрдем.
Алла яден әйтәлмәдем мәйданнарда.
11. Бу мөнәҗәт ядкарь булсын агайларга,
Мөрид, мохлис булган әби-бабайларга,
Үлде диеп, зинһар, дуслар, онытмагыз,
Без фәкыйрьне яд итегез мәйданнарда.
Амин.

### *1951 елның 14 январенда Андижан шәһәрендә утта янып үлгән Нурҗиһан бәете*

1. Янган хабәреңне ишеткәчтән,
Яшь урынына, балам, кан түгәм.
Ахтык язган хатыңны кулыма алып,
Бер карыйм да, балам, биш үбәм.
2. Күз алдымнан китми яшь вакытың,
Күкрәгемдә үскән чакларың,
Әнкәем, бу көн мин сау, диеп
Фронтлардан язган хатларың.
3. Ирләр кебек кулыңа мылтык алып,
Дошманнарга уклар атканың;
Дошманнарны җиңеп, тар-мар итеп,
Фронтлардан исән кайтканың.
4. Әле күз алдыма китерәмен
Халык килеп сине бакканын,
Идән уртасында синең зифа буең
Кара күмер кебек ятканын.
5. Күз алдымда тора җан юлдашың
Сине кочагына алганы,
Тиз ярдәмче машинасы белән
Илтеп больницага салганы.
6. Тәмам күзем белән күреп торам
Әзраил җаныңны алганын.
Уйлыймын да җанымнан җөдә булам
Ике балаң ятим калганын.
7. Бүген икенче хат абыең яза
Анда ни вакыйга булганын;
Көн күрмәгән кечек балаң белән
Икеңне бер ләхеткә куйганын.
8. Җеназа намазын укыганда
Бихисап халыкның булганын.
Һәркайсы бәндәнең синең өчен
Күзләренә кан-яшь тулганын.
9. Хыялмыдыр әллә төшме күрәм,
Җаның җәннәтләргә очканын,
Бу нинди изге җан килде диеп,
Хурлар каршы килеп кочканын.

10. Һич онытмам синең бу яшеңне
Исән булса минем тәндә җан.
Күз нурымны утта һәлак иттең,
Һай шәфкатьсез шәһәр Андиҗан.
11. Итмәдеңме фикер кем карар дип,
Ятим калгач ике яшь ылан.
Хәзер белдем сине инде, шәһәр,
Синдә юк һич шәфкать, миһербан.
12. Барча дәрья – кара, җирләр – кәгазь,
Булса иде урманнар каләм,
Бу бәет һич язып бетмәс иде,
Шунда бәет тәмам, вәссәлләм.
13. Күзем каны белән бәет язам,
Җан кардәшең, абыең Абдылла,
Шәһитлек әҗерен бирсен сиңа
Яраткан Ходаем бер Алла.
14. Туган идең Баку шәһәрендә,
Вафат булган җирең Андиҗан.
Хабарыңны ишеткәч кан-яшь түгә,
Янып үлгән дигәч Нурҗиһан.
Тәмам.

*Фазылова Хәдичә Усман кызы (1954).*
*Иске Кулаткы районы Зимичә авылы*

Сип-сип тарысын,
Сүгәнеңә барысың.
Сүгәнеңә баралмасаң,
Үкенечкә калырсың.

*Мәзитова Халидә Зиннәтулла кызы (1953).*
*Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылы*

1. Агиделне буйлама.
Үзең ничек, мин дә шылай,
Ялыныр дип уйлама.

2. Идән астым бозлавык,
Егылып үлде бер тавык.
Миңа каршы ер ерладың –
Телеңә чыксын сызлавык.

*Әхмәтова Рәсимә Закир кызы (1942).*
*Иске Кулаткы районы Урта Терешка авылы*

1. Агиделне киң диләр,
Аны диңгез димиләр,
Сөйгәнең кала димиләр,
Сөймәгәнгә димлиләр.
2. Мәрҗәннәрем, мәрҗәннәрем,
Мәрҗәннәрем су буйлый,
Күңелләрем сезне уйлый,
Күзләрем карап туймый.
3. Кулымдагы йөзөгөмнөң
Исемнәре Хәттәбир,
Сөясеңме, сөймисеңме –
Дөрөсөн генә әт тә бир.
4. Пуховый шәл шәлмени.
Мин уртага чыккач кына
Бер ерыгыз жәлмени.
5. Билемдәге риминым
Үземнең риминым төгөл.
Бар иде сине сөюче,
Хәзер илләрдә төгөл.
6. Лимун сары, лимун сары,
Иң сарысын ал миңа.
Ят ярларга күзең салма,
Салсаң күзең сал миңа.
7. Сачым озон, җиргә тигән,
Тарагым юк тараргә,
Таулар биек, баскычлар юк,
Сагынганда карарга.
8. Траляля матур уен.
Матур икән сөйгән ярың,
Әрәм үсмәгән буең.

*Закирова Зәкия Мәин кызы (1938).*
*Иске Кулаткы районы Урта Терешка авылы*

### Ырымнар, ышанулар

Ызбада мәчтән (туп) унярга ярамый, кош-корт утырмас, чебеш чыкмас.

Бусагага басма – бәхытең булмас.

Җәяккә таянсаң, сагыш килә.

Аягыңны селкеп утырма – шайтан тирбәтәсең.

Ызбада сызгырма, шайтан җыясың.

Ыланга күз тисә, өстәлнең өч угылын кулыңны суга манып себерәсең, аннан өч күмер саласың, чыңылдаса күз тигән була. Шул су белән маңгаен сыдырасың, корсагыннан сыдырасың. Аннан ул суны бусаганың ишек ябыла торган урынына бәрәсең. «Каян килдең, шонда кит» диеп бәрәсең дә, ылан басыла, еламый.

Күз тимәсен диеп маңгаена кором сөртә, шапкасына төмә кадыйлар. Башта кешенең күзе шонарга төшә икән.

Ыланнар бер-берсенә якын булсын өчен, бер-берсенең киемен кигезәләр, әнисенә якын булсын диеп, әнисенең чабуына чырныйлар.

Иген өлгөргәндә, катыннарны кырга чыгара булганнар, әни сүли иде. Катыннарның күлмәкләре озон була, катын итәге тисә,

иген биек булып үсә ди. Утарга чыгара булганнар, хатын-кыз выт, итәге тисен диеп.

1. Карамалның чабатасын
Киеп чыктым күршегә,
Үгә эләнеп катькинча
Төбе төштө берчигә.

2. Алюмин чуеннары.
Бу вечерда сүгәнем юк –
Првалис уеннары.

3. Әнә килә автамабил,
Тиягәннәр коярлар.
Боронорно бик күтәрмә,
Чиләк элеп куярлар.

4. Кар бит ак бит, кар бит ак бит,
Карны ашамыйлар бит.
Яр бит җан бит, яр бит җан бит,
Ярны ташламыйлар бит.

5. Ярымны бүләк итәм,
Ләкин үзем армиядән
Катючыларны көтәм.

*Кушаева Нурия Рәхимҗан кызы (1942).*
*Иске Кулаткы районы Киръявыл авылы*

1. Егетләр дисәң егетләр,
Авызлары салынган,
Әле савитский влась,
Кем аларга ялынган.
2. Риминнары бушаган
Буйга карсак, бозау корсак,
Шимпанзега ошаган.
3. Милициямени ул,
Сине сөя, мине сөя.
Белеп сөямени ул.

*Бикбаева Илһамия Хөсәен кызы (1938).*
*Иске Кулаткы районы Иске Зелёнай авылы*

Мунча кергәннән соң чыгып киткәндә, башка керүче булмаганда, аны ябып әйтелә торган сүзләр:

Бисмилләһ иррахман иррахим.
Пары да күп, сывы да күп,
Мулла белән мулла катны,
Азанчы белән азанчы катны евыныгыз.

*Давудова Равилә Кяшаф кызы (1965).*
*Яжа Малыклы районы Зирекле Куак авылы*

**Сүз уйнату**

Мөси ач
Филип ялангач,
Мукшы Күленә кермичә кач,
Атнагылга киләсен дә майлы бутка пәч.

*Гыйззәтуллин Рәис Равил улы (1958).*
*Мәләкәс районы Атнагыл авылы*

ИНФОРМАНТЛАР

**Иске Кулаткы районы**

**Иске Атлаш авылы:**

Курмакаева Расимә

Курмакаева Разыя Мостафа кызы (1942)

Маннапова (Хамзина) Җәүһәр Исән кызы (1924), Бөек Ватан сугышы ветераны

Аббясова Сәйдә Шакир кызы (1928)

Мәзитова Халидә Зиннәтулла кызы (1953)

Хөснетдинова Камилә Үмәр кызы (1957), Ульяновск өлкәсе Николаевка районы Татар Сайманы авылында туган

Хөснетдинова Тәнзилә Солтан кызы (1931)

**Муса авылы:**

Салюкова Әлфия Ибраһим кызы (1927)

Кузахметова Маһидә Алиҗан кызы (1938)

**Иске Мостяк авылы:**

Ганиев Марат Исхак улы (1936)

Ганиева Мөнирә Якуб кызы (1937)

**Яңа Мостяк авылы:**

Абдуллина Назия Җиһанша кызы (1959)

Батыршина Марифәт Азам кызы (1936)

Назирова Суфия Минибай кызы (1927)

**Урта Терешка авылы:**
Шәрипова Мәрьям Фассай кызы (1950)
Әхмәтова Расимә Закир кызы (1942)
Рафикова Зәкия Мәен кызы (1938)
**Киръявыл авылы:**
Кушаева Нурия Рәхимҗан кызы (1942)
Нарбиков Зөфәр Зөлкарнәй улы (1937), Алма-Ата шәһәрендә туган
**Иске Зелёнай авылы:**
Бикбаева Илһамия Хөсәен кызы (1938)
Рафикова (Давудова) Равиля Кәшаф кызы (1965), Зирекле авылында туган
Бикбаева Раидә Муса кызы (1941), Мәскәүдә туган
**Вязовый Гай авылы:**
Измайлова Әсма Билал кызы (1926)
Деникаев Рушан Ибраһим улы (1947)
Деникаева Мәүлүдә Зәкәрья кызы (1951)
Юсупова Сания Исмәгыйль кызы (1953)
Бәширова Халидә Яхъя кызы (1961)
**Яңа Зимичә авылы:**
Фазылова Хәдичә Усман кызы (1954)
Бахтиярова Рауза Ибраһим кызы (1938)
Хайруллина Фаиля Ибрагим кызы (1938)
**Иске Яндука авылы:**
Нугаев Расим Каюм улы (1940)
Таһирова Фәһимә Билал кызы (1940)

### Карсун районы

**Нугай иле авылы:**
Биткузин Шәүкәт Кәрим улы (1942)
Миннибаева Кадия Абдулкадир кызы (1947)
Юсупова Гөлнара Камиль кызы (1970)
Хәкимов Әхтәм Хәйдәрҗан улы (1961)
Баймурзина Мәүлидә Мәрдәм кызы (1971)
Камалетдинов Әнвәр Хәйдәр улы (1971)
Баймурзин Али
**Сакускай (Уразовка) авылы:**
Мөшәрәпова Надия Шәйдулла кызы (1961)
Алтынбаева Рокыя Исмаил кызы (1946)
Абдрахманова Хадия Фәйзрахман кызы
**Гуринка (Тат. Горенки) авылы:**
Мөсәлләмова Фаилә Искәндәр кызы (1933)
Абдрахманова Нәзирә Исмаил кызы (1941), Стрельниковода туган

**Аксу авылы:**
Шакурова Рәисә Исмаил кызы (1941)
Шакурова Мөнирә Җиһанша кызы 1950)
Бахитова Рәисә Минхәйдәр кызы (1957)
Муратшина Кадичә Сафа кызы (1929)
Хафиятуллова Мәстүрә Ибраһим кызы (1939)
Халимуллова Мәсрүрә Әдигам кызы (1942)

**Мәләкәс районы**

**Атнагыл (Аллагулово) авылы**
Сулейманова Алсу Азат кызы (1978)
Гыйззәтуллин Рәис Равил улы (1958)
Галеева Мария Шаһит кызы (1948)
Вәлиәхмәтова Миннирумия Кәрим кызы (1938)
**Мөси авылы:**
Хөснуллов Борһан Хәсәнҗан улы (1939)
**Филип (Филипповка) авылы:**
Замалетдинова Румия Шәймәрдән кызы (1940)
Замалетдинов Рифгать Ибраһим улы (1937)
**Мукшы Күле (Мордово Озеро) авылы:**
Сингатуллов Нәфигулла Нәбиулла улы (1939)

# УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫ
## (Халык иҗаты үрнәкләре)

*Ильмир Ямалтдинов*

Сембер-Ульяновск төбәгендә яшәүче халкыбызның фольклоры, авыз иҗаты белән кызыксыну ике йөз елдан артык элек башлана, дип әйтсәк һич тә ялгыш булмас.

Россия Фәннәр академиясе ачылганнан соң (1725), аның эшчәнлегенең аерылгысыз бер юнәлеше буларак, күпмилләтле илдә яшәүче халыкларның тарихын, этнографиясен өйрәнү максатыннан экспедияләр оештырыла. XIX гасырның беренче яртысында Казан университеты галимнәренең хезмәтләрендә дә татар халкының тарихына, рухи мирасына һәм фольклорына караган кыр тикшеренүләре нәтиҗәләре яисә башка чыганаклардан алынган материаллар бар[1]. Аннан соң да Ульяновск җирлегендә яшәүче милләттәшләребезнең халык иҗатын өйрәнү эше татар галимнәре һәм әдипләре тарафыннан дәвам иттерелә.

XX гасырның урталарыннан Ульяновск татарларының сөйләшләрен өйрәнү өчен, телче-диалектологлар әлеге төбәккә берничә тапкыр (1956, 1960–1966, 1969, 1975, 1982, 1983 һ. б.

[1] *Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора / И.И. Ямалтдинов. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 35–36.

елларда) экспедициягә чыга[1]. Галимнәр Латыйф Җәләй, Ләйлә Мәхмүтова, Нажия Борһанова, Гасимә Якупова, Зидә Садыйкова, Дөрия Рамазанова, Флера Баязитова һәм башкалар, тел материалы буларак, халык иҗаты үрнәкләрен дә туплыйлар.

Ульяновск төбәгенең татарлар яшәгән районнарына Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан иң беренче фольклор экспедициясе 1964 елның июнь аенда танылган фольклорчы галим, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми җитәкчелегендә оештырыла. Экспедиция эшендә җиде фольклорчы катнаша. Алар ике төркемгә бүленеп эшлиләр. Беренче төркем галимнәре Х. Ярми (җитәкче), Х. Гатина, А. Йосыпов Иске Кулаткы районы Иске Кулаткы, Иске Зеленай, Усть-Кулаткы, Иске Мостяк, Иске Атлаш һәм Николаевка районының Татар Сайманы авылларын өйрәнәләр. Икенче төркем галимнәре И. Надиров (җитәкче), Т. Галиуллин, Ф. Урманчеев, С. Исәнбаев Карсун районының Тат. Горенки (Гуринка), Тат. Голышевка (Аксу), Нагаево (Нугай), Чардаклы районының Абдулла, Иске Майна районының Тат. Урайкино (Кызыл Су) һәм Чынлы районының Елховое Озеро (Кәшә) авылларында тикшеренүләр уздыралар. Барлыгы 5 районның 12 татар авылында булалар.

Институтның 1965 елгы фольклор экспедициясе июнь аенда Хәмит Ярми җитәкчелегендә Уляновск һәм Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәләренә оештырыла. Институт архивында Яңа Малыклы районы Урта Исәнтимер, Иске Төгәлбуга авылларында И. Надиров (төркем җитәкчесе), Ф. Урманчеев һәм Х. Мәхмүтов тарафыннан язып алынган халык иҗаты үрнәкләре һәм авыл тарихларына караган материаллар саклана[2].

Шулай итеп, 1964 – 1965 елларда Институт хезмәткәрләре әкиятләр, бәетләр, лирик һәм кыска җырлар, табышмаклар, халык

---

[1] Атлас татарских народных говоров / отв. ред.: Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хайрутдинова. Изд. 2-е, доп. и перераб. Казань: ИЯЛИ, 2015. С. 20–26; Материалы по татарской диалектологии. 1978. Вып. IV. С. 111.

[2] Татарстан фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 77 колл, 2 п., сакл. бер. 31–33; 35–39; 42, 43, 46.

уеннары, мәкаль кебек халык иҗаты жанрларына, балалар фольклорына караган һ.б. фән өчен бик кыйммәтле халык иҗаты материалларын бөртекләп җыеп алып кайталар. Алар институтның архивында саклана[1]. Әлеге материалларның бер өлеше Институт әзерләгән унике томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасында (1976–1988) һәм соңрак нәшер ителгән әлеге җыелманың «Балалар фольклоры» китабында (1993) басылган яисә җыентыкларның искәрмәләрендә вариант буларак күрсәтелгән.

Шулай ук Мирасханәдә институтның фәнни хезмәткәрләре тарафыннан СССРның төрле шәһәрләрендәге музейлардан, архивлардан, китапханәләрдән һәм экспедицияләр барышында тупланган материаллар саклана[2]. Алар арасында Ульяновск өлкәсенең татар авылларыннан язып алынган халык иҗаты үрнәкләре дә бар. Фондка беренче саклау берәмлеге 1960 елның июль аенда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы фәнни архивы аша кабул ителгән[3]. Шулай итеп, әлеге коллекциядә саклана торган материаллар вакыт ягыннан алданрак та язып алынган булырга мөмкин. Ульяновск төбәгендә аерым шәхесләр һәм Казан дәүләт университеты студентлары тарафыннан язып алынган аерым халык иҗаты әсәрләре 1960 ел белән теркәлгән. Алга таба да Казан дәүләт университеты студентлары төрле елларда Ульяновск төбәгендә фольклор экспедицияләрендә катнаша.

Ульяновск өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең рухи мәдәниятен, шул исәптән фольклорын җыю, өйрәнү һәм халыкныкын яңадан халыкка кайтару өлкәсендә филология фәннәре кандидаты Резеда Камил кызы Садыйкова җитди эш алып бара. 1993–2010 елларда Р.К. Садыйкова җитәкчелегендә Ульяновск дәүләт педагогия университетының милли төркемнәре студентлары өлкәнең татар авылларында фольклор практикалары үтә, халык иҗаты үрнәкләре җыя һәм нәтиҗәдә фольклор фонды туплана.

---

[1] Татарстан фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 76–77 колл.

[2] Шунда ук. 69 колл.

[3] *Әхмәтҗанов М.И.* Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече. Казан, 2005. Б. 77.

Әлеге фондта саклanган фольклор үрнәкләренең бер өлеше Р. Садыйкова тарафыннан әзерләнгән хезмәтләрдә дөнья күрә[1]. «Халкыбыз җәүһәрләре» китабында Сембер-Ульяновск төбәге татарларының рухи мирасы өйрәнелә, барлана. Хезмәтнең шактый зур өлешен бәетләр, мөнәҗәтләр, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, җырлар, мәзәкләр, әкиятләр, риваятьләр кебек халык авыз иҗаты жанрларына, татар мифологиясе, им-томнар, ырымнар, халык уеннары, йола һәм балалар фольклорына караган үрнәкләр алып тора. Китапның искәрмәләр һәм чыганаклар өлешендә әсәрләрнең паспорты бирелә. «Таулы-чишмәле Кулаткы ягы» китабының нигезен Иске Кулаткы районының татар авылларыннан җыелган фольклор материаллары тәшкил итә. Анда урын алган үрнәкләрнең паспорты әсәрләрдән соң бирелеп барыла һәм алар шулай ук тулы.

Ульяновск өлкәсе Николаевка районы Татар Сайманы авылы мәктәбе китапханәсендә шактый тулы паспортлаштырылган 100 дән артык берәмлек фольклор үрнәкләре саклана. Аларны 2005 елда авыл халкыннан, Ульяновск дәүләт педагогия университетында укыганда, Татар Сайманы авылында туган Ульбекова Эльза Шамил кызы язып алган.

Һәм, ниһаять, 2017–2018 елларда, биш дистә елдан артык вакыт узганнан соң, әлеге төбәккә берничә өлкәгә кагылышлы тикшеренүләрне максат итеп куйган Институтның комплекслы фәнни экспедициясе оештырылды.

Ульяновск өлкәсенең татарлар яши торган барлыгы 7 районның 40 тан артык авылында ***(Иске Кулаткы районының** Иске Атлаш, Муса (Мосеевка), Иске Мостяк, Яңа Мостяк, Урта Терешка, Яңа Терешка, Киръявыл (Кирюшкино), Иске Зеленай, Вязовый Гай, Зимичә, Иске Кулаткы, Иске Яндука,* **Карсун районының** *Нугай иле (Нагаево), Сакускай (Уразовка), Гуринка (Татарские Горенки), Аксу (Татарская Голышевка),* ***Мәләкәс районының** Атнагыл (Аллагулово), Мукшы Күле (Мордово Озеро), Мөси (Моисеевка), Филип (Филипповка), Парау (Боровка),* ***Павловка районының** Йәүли*

[1] *Садыйкова Р.К.* Халкыбыз җәүһәрләре. Ульяновск: «Корпорация технологий продвижения» нәшр., 2011. 192 б.; Таулы-чишмәле Кулаткы ягы. Ульяновск: Өлкә типографиясе «Печатный двор», 2018. 200 б.

*(Евлейка), Муратовка, Шомалак (Татарский Шмалак),* ***Николаевка районының*** *Татар Сайманы, Әхмәтле, Зур Чирекле,* ***Чардаклы районының*** *Чардаклы, Үрән (Енганаево), Абдулла, Әсән, Татар Колмаеры, Кызылсу (Уразгильдино), Папау (Поповка), Иске Үрәнбаш, Малаевка (Кечкенә Үрәнбаш, Яңа Үрәнбаш),* ***Яңа Малыклы районының*** *Иске Исәнтимер, Урта Исәнтимер, Өчкаен (Әмир, Баткак, Гимран поселоклары), Әбдери, Лабит, Зирекле Куак (Елховый Куст), Иске Төгәлбуга авылларында)* булып, шәхсән минем тарафтан 1000 берәмлеккә якын халык авыз иҗаты үрнәкләре һәм татар халкының традицион мәдәниятенә караган материаллар язып алып кайтылды.

Ульяновск өлкәсендә яшәүче татарлар арасында, сан ягыннан караганда, аеруча киң таралган авыз иҗаты жанрларыннан җырларны һәм мөнәҗәтләрне аерып чыгарырга була. Беренчесенә килгәндә, берничә йөз **җыр** язып алынды. Аларның күбесе кыска җырлар һәм такмаклар. Мәсәлән, Николаевка районы Әхмәтле авылында Сәйфуллова Сания Мостафа кызы (1935), Татар Сайманы авылында Саюкова Наилә Төхвәт кызы (1952) һ.б., Зур Черекли авылында Аюпов Мидхәт Идрис улы (1956) безгә махсус берничә дистә халык җыры җырлап күрсәтте. Аларның әйтүенә караганда, андый җырлар бик күп.

Павловка районы Йәүли авылында Назырова Разия Ризван кызының (1942 елгы) кыз чактан ук язган җыр дәфтәреннән 140 тан артык җыр күчереп алынды, шуларның 50 дән артыгы – кыска җырлар, калганнары – лирик озын һәм автор җырлары. Шулай ук халыклашкан һәм берничә рус җыры да бар. Уннан артык җыр көе белән язып алынды.

Чардаклы районы Абдулла авылында Насыйрова Раушания Рамил кызының (1970) җыр дәфтәреннән 50 дән артык автор һәм 50 халык җыры язып алынды.

Яңа Малыклы районы Урта Исәнтимер авылында Шәкүрова Рәисә Ислам кызы (1964) Галиев Якуб Мирзяҗан улының (1935 – 2014) дәфтәреннән 52 кыска җыр язып алган булган, аларның күчермәләре алынды. Шәкүрова Рәисә биргән мәгълумат буенча, Галиев Якуб абыйның 1980 елның 17 октябреннән яза

башлаган «Җырлар язам истәлек өчен» җырлар җыелмасы 5 дәфтәрдән (12 – 18 битле) тора һәм Сабирова Миңниса Сөләйман кызында (1937) саклана. Кызганыч ки, без аны очрата алмадык (өйдә булмады).

Ульяновск өлкәсендә «Көймә» җырын һәрбер авылда очратырга була. Әлеге уен-бию җыры берничә вариантта язып алынды[1].

Ульяновск төбәге татарларында озын көйләр дә саклана. «Олы юлның тузаны», «Рәйхан», «Сарман буйларында» һ.б. җырларны һәр авылда диярлек яратып башкаралар.

Автор җырларын да бу төбәк халкы бик яратып җырлый. Алар арасында халыклашкан җырлар да бар. Иске Кулаткы районы Яңа Мостяк авылында Аксянова Саимә Абдулхак кызы (1951) һәм Абдуллин Фәрит Хәлил улыннан (1959) авылдашлары Ришат Кузахметов көе, Хаҗәр Хәсәнова сүзләренә «Мостягым» һәм Бөек җиңүгә багышланган, ел саен Җиңү бәйрәмендә яратып башкарыла торган «Мәңгелек дан» җырлары язып алынды. Шулай ук Абдуллин Фәрит Хәлил улыннан (1959) «Мостягым» җырының икенче вариантын (авторлары билгесез) теркәдек.

Кызганыч ки, тарихи җырлар очрамады. Институтның 1964 елгы фольклор экспедициясе вакытында Карсун районы Гуринка авылында Рәйхана Гыйззәтуллинадан (1899) Т. Галиуллин тарафыннан Казан ханлыгы чорына караган «Тоткын Сөембикә җыруы», Николаевка районы Татар Сайманы авылында Исхак Ульбаевтан (1903) – Х. Ярми, Васфи Бикмаевадан (1909) Х. Гатина тарафыннан, Карсун районы Гуринка авылында Хәсән Шәриповтан (1906) – Т. Галиуллин, Кәрим Якуповтан (1903) – И. Надиров, Әхмәт Хәйретдиновтан (1900) Ф. Урманчеев тарафыннан качкыннар, тоткыннар турындагы «Шәрүк беглый», Иске Кулаткы авылында Кашаф Юсуповтан (1893) Х. Ярми тарафыннан «Лачын Хәсән», Карсун районы Гуринка

[1] Николаевка районы Татар Сайманы авылында Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952), Әхмәтле авылында Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935), Мустеева Розалия Кәбир кызыннан (1957), Зур Черекли авылында Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951), Сөләйманова Хәлимә Сабит кызыннан (1950) язып алынды.

авылында Хәсән Шәриповтан (1906) Т. Галиуллин тарафыннан «Аким качкын», Карсун районы Гуринка авылында Әбүбәкер Хәйретдиновтан (1900) – Ф. Урманчеев, Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылында Фатиха Ибраһимовадан (1901) Х. Гатина тарафыннан «Әбделмән купис», Карсун районы Гуринка авылында Хәлил Каюмовтан (1905) И. Надиров тарафыннан патша армиясе, рекрутлар турындагы «Наемщик», Карсун районы Аксу авылында Җамал Халиковтан (1916) Ф. Урманчеев тарафыннан «Шәмсекамәр – батыр кыз» тарихи җырлары язып алынган. «Татар халык иҗаты»ның «Тарихи һәм лирик җырлар» китабында «Лачын Хәсән», «Аким качкын», «Наемщик»[1] җырларының текстлары басылган, «Тоткын Сөембикә җыруы», «Шәрүк беглый», «Әбделмән купис» (Икенче вариант), «Шәмсекамәр – батыр кыз» тарихи җырлары томның искәрмәләр һәм чыганаклар өлешендә вариант буларак күрсәтелгән[2]. Ләкин Ульяновск өлкәсендә язып алынган «Шәмсекамәр – батыр кыз» тарихи җыры текстында басылган текстта булмаган түбәндәге строфа бар:

Шәмсекамәр, беләзегең
Кай җирләрдә коелган?
Шәмсекамәрнең уң бите
Ядрә белән уелган.

Ульяновск өлкәсе татарларында аеруча киң таралган халык иҗаты жанрларының икенчесенә килгәндә, **мөнәҗәтләр**не һәрбер авылда очратырга була. Аллаһы Тәгаләгә, Пәйгамбәрләргә, Ислам диненә, Коръәнгә мәдхияләр, шигъри нәсыйхәтләр, бәйрәм, аерым алганда мәҗлес мөнәҗәтләре киң таралган. Бу аңлашыла да, чөнки Ульяновск өлкәсе татарларында дин көчле.

Ульяновск өлкәсендә мөнәҗәтләрне мәҗлестә, Коръән укыганнан соң, чәй янына әйтү гадәте бар. Мәсәлән, Николаевка районы Зур Черекли авылында Рамазанова Хәлимә Адельша

[1] Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче И.Н. Надиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 57–59, 76.

[2] Шунда ук. Б. 380, 382–383, 390, 395.

кызы (1951): «Мөнәҗәт белән мәҗлес тулы була, мөнәҗәтсез мәҗлеснең күрке дә юк», – дип саный.

Николаевка районы Татар Сайманы авылы халкы мәҗлесләрдә, мәҗлес мөнәҗәтләреннән соң, кыска җырларны башкара. Мәҗлес ахырында абыстай татарча теләк тели, дога кыла, аннан соң мәҗлес мөнәҗәте белән рәхмәт әйтә башлап, мөнәҗәт көенә кыска җыр җырлыйлар[1]:

Өегезгә керү белән
Карадым көзгегезгә,
Ашыгызга сывыгызга
Рәхмәт хөрмәтегезгә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нурәхмәт.
Ашыгыз тәмле, йөзегез ямьле
Хөрмәтегезгә рәхмәт.

Кайдан килдегез сез безгә
Батмаенча диңгезгә,
Сез кадерле кунак безгә
Ни хөрмәт итик сезгә...

Иязләр, җеннәр турындагы **мифологик сөйләкләр, хикәятләр һәм әкиятләр** халык арасында борынгыдан сөйләнеп килгән, халык аларга ышанган, буыннан-буынга тапшырган. Бигрәк тә, татар халкында киң таралганнары – атның ялын үрә торган абзар иясе, төрле кыяфәткә (песи, эт, бабай, матур кыз һ.б.) керә ала торган, яисә бала елаган тавышка ияртеп адаштыручы җен-пәри-шайтан-мәлгунь, атны тугарып, дугасын (сбруен) кире якка җиккән очракта гына котылып була торган адаштыручы җенле урыннар, яратмаганга күрә күзенә күренүче яисә табак-савыт шалтыратучы, яисә сыер бозаулаганда тәрәзә шакып уятучы өй иясе (йорт

[1] Николаевка районы Татар Сайманы авылында Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952), Шафеева Сафия Хәмит казыннан (1948), Юнушева Тәнзилә Якуп кызыннан (1949), Саюкова Накия Яхия кызыннан (1956), Долгова Фатыма Исмаил кызыннан (1948), Айзадуллова Тянзиля Ярулла кызыннан (1946) язып алынды.

анасы), адашкан кешегә юл күрсәтүче Хозыр-Ильяс, чәчен тарап утыручы су анасыннан башлап, Ульяновск төбәгендә генә була торган, аерым алганда, Йәүли авылыннан урманга барганда юлына очрасаң яисә Кучатка башында адаштыручы җен юлы[1], Муратовка авылында җен кагылмасын өчен «Аятел-көрси»не укый-укый сәгать барышына каршы мич тирәләрен акбур яисә күмер белән сызып чыгу һәм җене киткәнче баланың биленә «ат коеры бәйләү»[2], Шомалак авылында кып-кызыл төлке сыйфатына кереп, озынаеп барып, кеше яшәмәгән яисә ару тормаган йортка төшүче аздякы һәм теләсә нинди йозакны ача алу, теләсә кайда үтеп керү – теләсә нәрсәгә сәләтле булу өчен чикләвек чәчәге алып кайтып килгән ике егетне адаштырып, чәчәкләрен алып, мичкә тыгып куйган шайтан[3], Татар Сайманы авылында кеше яшәмәгән йортка койрыгын болгап төшеп югалучы аздякы[4], Әхмәтле авылында биргән садакаңны ишек алдыңа калдырып китүче яисә үлгән баласы белән басып торган хатынны алмыйча киткән машина йөртүчене кире җибәрүче бабай – Хозыр-Ильяс[5], Зур Чирекле авылы тирәсендә пычрак урынга ут кебек килеп төшеп, ялангач хатын сыйфатына әйләнгән аздякы һәм сакта торган солдатка сугыш вакытында үлгән хатыны булып күренүче мәлгуньшайтан[6], Зур Черекли авылында туй үткәрергә җыенганда өйгә хәмер кертмәскә кушучы актан киенгән, сакаллы, зур гына буйлы Хозыр-Ильяс һәм мунчада кеше булмаганда чабынучы йорт

---

[1] Павловка районы Йәүли авылында Назыйрова Разия Ризван кызыннан (1942) язып алынды.

[2] Павловка районы Муратовка авылында Ибраһимова Рәисә Хәбибулла кызыннан (1938) язып алынды.

[3] Павловка районы Шомалак авылында Бикбаев Якуб Хәсән улыннан (1933) язып алынды.

[4] Николаевка районы Татар Сайманы авылында Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952), Долгова Фатыйма Исмаил кызыннан (1948) язып алынды.

[5] Николаевка районы Әхмәтле авылында Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935), Мустеева Розалия Кәбир кызыннан (1957) язып алынды.

[6] Николаевка районы Зур Черекли авылында Сөләйманова Нажия Моталлиб кызыннан (1955) язып алынды.

ата-аналары[1], яисә яраткан кешесенең чәчен үрүче яисә төсен яратмаган сыерны сырты белән улакка (колодага) салучы йорт анасы[2], Зур Чирекле авылыннан ерак түгел Заляк дигән урында адаштыручы шайтан[3], Үрән авылында чабынырга менгән әбинең себеркесен тартып алып, мунчадан куып чыгарган яисә бер бабайны сүзсез генә мунчадан алып чыгып, коенырга төшергән, яисә мунчада бер баланы алыштырган җеннәр, яисә су газилары, су хуҗалары, су – кое тоту, яисә себеркегә атланып йорт хуҗасын күчерү[4], Иске Үрәнбаш авылында бер хатынга кайтып йөрүче үлгән ире булып ияләшкән җен[5], Иске Исәнтимер авылында межага ятмаска, торырга кушып, шакылдатып уятучы[6], яисә межадан узып барганда, бер бабайдан нәрсә чәчкәнен кызыксынып, ул бабай бодай урынына әрем дип алдап җавап кайтаруына дога кылып китеп, соңыннан догасы кабул булган Хозыр галәйһиссәлам һәм зираттан Чирыш бабай булып кайтып йөреп, морҗадан чыгып китүче Камка түтигә ияләшкән җен[7], Чаука бабай каберендәге куыштан чыгып йөрмәсен өчен, барып, тишегенә имән чөй кагып кайткан Әлхәрәй бабай[8], адәмгә охшаган, кап-кара киемнән ир-ат кыяфәтендә булган, «Аятел-көрси»нең ахырын укымауны сораган җен һәм Аллаһы

---

[1] Николаевка районы Зур Черекли авылында Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951) язып алынды.

[2] Николаевка районы Зур Черекли авылында Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951), Сулейманова Хәлимә Сабит кызыннан (1950), Сулейманова Нажия Мөталлиб кызыннан (1955) язып алынды.

[3] Николаевка районы Зур Черекли авылында Аюпов Мидхат Идрис улыннан (1956) язып алынды.

[4] Чардаклы районы Енганаево (Үрән) авылында Яруллова Рауза Бари кызыннан (1949) язып алынды.

[5] Чардаклы районы Иске Үрәнбаш авылында Мөбәракшина Саҗидә Харис кызыннан (1951) язып алынды.

[6] Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында Сәфәргалиева Сәрия Сөнгатулла кызыннан (1941) язып алынды.

[7] Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында Самаркина Миңнесания Шакир кызыннан (1936) язып алынды.

[8] Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында Якупова Мәрьям Ибраһим кызыннан (1936) язып алынды.

Тәгаләгә адәмнәрне аздырам дип әйтүче, соңыннан Мәлгунь исеме бирелгән Иблис[1], Иске Төгәлбугада кәҗә Мингали бабайның карчыгына ияләшкән җен һәм Халида апаның баласын алмаштырган мәлгунь[2], ызан (межа, грань) буйлап килеп, башына кигән һәм имеп яткан балага гына сәлам бирәм диюче Хозыр галәйһиссәлам һәм асылыну нәрсә була икән ул дигән ирнең муенына чыбыркысын бәйләп сүрәүче мәлгүн-шайтаннар, һәм мич пумаласын иңбашына куеп, дога укый-укый йорт иясен күчерү,[3] мич өстендә аш пешерә торган казанның тирәсенә акча тезеп чыгып, догасын укып, өй хуҗасын озату[4], Бибисара әбине тарантас белән мунчага алып барган мәлгуньнәр[5], тиреслектән елан булып күтәрелеп, озын койрыклы кызыл ут булып барып, ярга төшүче аздякы[6] турындагы мифологик сөйләкләр, хикәятләр һәм әкиятләр бар.

1977 елда Яңа Малыклы районы Өчкаен авылында Вәлиева Мәхмүҗамалдан (1884) Казан дәүләт университеты студентлары Д. Салихова һәм Р. Мингалина язып алган «Йорт иясен ничек алдаганнар» мифологик хикәяте тексты унике томлык «Татар халык иҗаты»ның «Риваятьләр һәм легендалар» китабында басылган[7].

**Тарихи һәм топонимик риваятьләр** дә язып алынды. Авыл тарихларына (Муратовка, Ундра, Карсунда торучы Языков кем булган? Сайман, Чирекле, Акъяр, Кузнецкий, Кызылсу, Папау,

---

[1] Яңа Малыклы районы Зирекле Куак авылында Яббарова Рәйсә Нурулла кызыннан (1918) язып алынды.

[2] Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында Әюпова Зәйнәп Миңгали кызыннан (1935) язып алынды.

[3] Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында Гәйнетдинова Миңзадә Шакир кызыннан (1936) язып алынды.

[4] Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында Гобәйдуллина Исламия Нурулла кызы (1947) язып алынды.

[5] Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында Әюпова Зәйнәп Миңгали кызыннан (1935) язып алынды.

[6] Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылында Әхмәтҗанова Рәисә Шәкүр кызыннан (1947) язып алынды.

[7] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 266–267.

Малаевка, Иске Үрәнбаш, Исәнтимер, Атлаш һ.б.) бәйлеләре – шул авылларда яшәүче милләттәшләребезнең үзләренең тарихларына битараф булмаганлыкларының ачык мисалы.

Татар халкында «Әүлия зираты» исемендә булган яисә «изге урын» белән бәйле риваятьләр киң таралган. Алар Ульяновск өлкәсе татарларында да бар. Мәсәлән, «Коры елга» риваяте Иске Кулаткы, Павловка районнары төбәгендә еш очрый. Риваятьләр буенча, анда егерме алты яисә утыз мулла атып үтерелгән, Аллаһы Тәгалә әмере белән, су аларның каберләрен юмыйча, агымын үзгәртә. Ул урын изгеләштерелгән: барып дога кылалар, теләкләре үтәлсен өчен һәм үтәлгәч, садакалар куялар.

1956 елда Уляновск өлкәсе Чардаклы районы Абдулла авылында Заһретдинов Габдрахманнан (69 яшь) Г. Якупова язып алган Абдулла авылы тарихы 1978 елда Татар диалектологиясе буенча материаллар, 1987 елда унике томлык «Татар халык иҗаты»ның «Риваятьләр һәм легендалар» китабында басыла[1].

Институтның 1964 елгы экспедициясендә Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылында Абайдуллин Тимербулаттан Зеленай авылы тарихын – Х. Ярми, 1965 елны Яңа Малыклы районы Урта Исәнтимер авылында Усманов Таиптан Исәнтимер авылы тарихын Ф. Урманчеев язып ала. Алар унике томлык «Татар халык иҗаты»ның «Риваятьләр һәм легендалар» китабында басыла[2], Яңа Малыклы районы Урта Исәнтимер авылында Әхмәтов Минсафадан язып алынганы томның искәрмәләр өлешендә вариант буларак күрсәтелә һәм тексты бирелә[3].

Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы Кызылсу авылында Мөхәммәдова Рокыядан (65 яшь) «Киез итектән зарар юк», Таҗетдинов Гыйләҗетдиннән (85 яшь) «Чикләвек бәһасе», «Ишан рухына багышлап» татар мәгърифәтчеләре турындагы риваятьләр һәм «Ибраһим бабай җиләге» легендасы Х. Та-

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 198–199.

[2] Шунда ук. Б. 199.

[3] Шунда ук. Б. 341.

җүков тарафыннан язып алына һәм 1964 елда «Казан утлары» журналының сигезенче санында, соңрак «Риваятьләр һәм легендалар» китабында басыла.

Казан дәүләт университеты студенты Р. Мингалина Ульяновск өлкәсе Чардаклы районы Абдулла авылында Хәмидуллин Габделхактан (79 яшь) Болгар чорына караган «Изге кушкаен», Казан ханлыгы чорына караган «Казан шәһәренең исеме ничек килеп чыккан» «Иван Грозный ничек Казанга сугыш ачкан» тарихи, татар мәгърифәтчеләре турында «Габделҗаббар ишан», көнкүреш «Бөдрә тал», «Әллүки», «Сакмар көе» риваятләрен язып алган. Унике томлык «Татар халык иҗаты»ның «Риваятьләр һәм легендалар» китабында «Туйбикә казаны»[1] («Казан шәһәренең исеме ничек килеп чыккан»), «Иван Грозный ничек Казанга сугыш ачкан»[2], «Габделҗаббар ишан»[3], «Бөдрә тал», «Әллүки», «Сакмар көе»[4] риваятьләре басылган, «Айдархан һәм сәхабәләр» риваятенең варианты буларак «Изге кушкаен» риваяте күрсәтелә[5].

Ульяновск төбәгендә нигездә барлык татар халкы өчен хас **уеннарның** тасвирламасы сакланган. «Түгәрәк»[6] уеннан башлап, «Лапта», «Ак кирәк, күк кирәк» белән беррәттән, аулак өйләрдә, кичке уеннарда[7] традицион уйналып килгән «Йөзек салыш», «Йолдыз санашлар» да бар. Кышын кич утыруларда, яз башында кич табигатькә чыгуларда, соңрак мәдәният йортларында «Агыш», «Толкай», «Траляй», «Көлтә җыю», «Алтылы», «Елан», «Тәре кисү» («Кристовой»), «Күпер»[8] һ.б. уеннар булган, ә балалар тарафыннан «Дәңгездән» («Деңгелди», «Класс», «Мак», «Чик»), «Унике таяк»[9], «Күлек», «Гузна» «Ашык», «Чижык»,

[1] Шунда ук. Б. 43 – 44.
[2] Шунда ук. Б. 59.
[3] Шунда ук. Б. 104.
[4] Шунда ук. Б. 223.
[5] Шунда ук. Б. 296,
[6] Ульяновск өлкәсе татарлары «Круг» дип сөйли.
[7] Ульяновск өлкәсендә татарлар аулак өйне вечер дип сөйли.
[8] Ульяновск өлкәсе татарлары «Мус»тан дип атый.
[9] Ульяновск өлкәсе татарлары «Унике палкадан» дип атый.

«Шаркати», «Түндәк алыш», «Аю базы», «Буяу сатыш» уеннары аеруча яратып башкарылганнар.

**Әкиятләргә** килгәндә, Ульяновск өлкәсе Чардаклы районы Үрән авылында өй яндырып күмер сатучы (ахыры һәм исеме билгесез) һәм үзенең хәйләсенә алданган карак турында күләме ягыннан зур булмаган «Ышану» әкияте язып алынды[1].

Павловка районы Муратовка авылында Әбүбәкерова Венера Рәшит кызының (1965) бабасы Ханбиков Зиннәтулла Әмин улына (1923), аның әкиятләренә карата тирән, җылы хисләр саклана. Бабасының әкият сөйләгәннәрен түбәндәгечә искә ала:

«Ул бабам минеке 1923 елгы иде. Ханбиков Зиннәтулла Әмин улы. Авылда гомер буе тимерче булып эшләгән, таза булган.

Ул килә иде, эштән кайтканда һәрвакыт менә сиңа куянчик китерде, дип, күчтәнәч китерә иде. Ул күчтәнәчне куянчик чыгарган, куянчик биргән дия иде.

Кичен әкият сүләгәндә әтә:

– Нәрсә турында сөйләргә?

– Аю турында. Заказ бирә идек.

И шул бесконечный аю турында әкият, без йоклап киткәнче. Үзенең өй алдында җыя иде. Ул күп белә иде.»

Кызганыч ки, аның хәтерендә бабасының бер әкияте дә, әкият сөйләү традициясе дә сакланмаган.

Институтның 1964, 1965 еллардагы фольклор экспедицияләре вакытында Николаевка районы Татар Сайманы авылында И. Ульбаевтан – Х. Гатина, Яңа Малыклы районы Исәнтимер авылында Х. Иблямовтан Ф. Урманчеев язып алган әкиятләр «Татар халык иҗаты»ның әкият китапларында «Хезмәтче», «Хәйләкәр мылтыкчы», «Ут гармуны» әкиятләренең варианты буларак күрсәтелә[2].

---

[1] Чардаклы районы Үрән авылында Яруллова Рауза Бари кызыннан (1949) һәм Хәмзина Разыя Бари кызыннан (1952) язып алынды.

[2] Татар халык иҗаты. Тылсымлы әкиятләр. Икенче китап / Томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б 431, 433; Татар халык иҗаты. Көнкүреш әкиятләр. Өченче китап / томны төзүче искәрмәләр әзерләүче Л.Ш. Җамалетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Б. 339.

Ульяновск өлкәсе Мәләкәс районы Парау авылында Фатих Вафиннан Н. Булатов язып алган «Тегүче кыз», Яңа Малыклы районы Баткаклы авылында Ибраһим Вафиннан Ә. Синегулов язып алган «Бай һәм крестьян», Иске Кулаткы районы Вязовый Гай авылыннан 1952 елда Исхак Ишмөхәммәтов язып җибәргән «Бай – акчага, ярлы – хәйләгә» әкиятләре «Кулсыз кыз», «Мужик белән алпавыт», «Мулла белән мәзин» әкиятләренең варианты буларак күрсәтелә[1]. Әлеге әкиятләр институт архивында 1960 ел белән теркәлеп, 69 коллекциядә саклана.

2005 елда Ульяновск өлкәсе Татар Сайманы авылында Ульбекова Равия Мөдәрис кызыннан (1933) Ульяновск дәүләт педагогия университеты студенты Э. Ульбекова «Биш фынт», «Кара сыер», «Тартма», «Яшь килен», «Үги ана», «Алтын шаруклар», «Хуҗа» әкиятләрен язып алган. 2018 елда «Хуҗа» әкиятенең варианты Павловка районы Муратовка авылында Ибраһимова Рәисә Хәбибулла кызыннан (1938) язып алынды. Кунакка башта хәерче булып килгән бабайның Хозыр-Ильяс булуы ачыклана. Без әлеге әкиятнең текстын алга таба ияләр, җеннәр турындагы мифологик сөйләкләр, хикәятләр һәм әкиятләр өлешендә урнаштырдык.

Сирәк булса да **бәетләр** дә очрады. Татар халкында киң таралган «Сак-сок»[2] бәетләре, «Мөршидә бәете»[3] һәм «Суга баткан Гайшә»[4] бәете язып алынды. Николаевка районы Әхмәтле

---

[1] Татар халык иҗаты. Көнкүреш әкиятләр. Өченче китап / томны төзүче искәрмәләр әзерләүче Л.Ш. Җамалетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Б. Б. 322, 332–333, 335.

[2] Мәләкәс районы Атнагыл авылында Фәисханова Сания Солтангәрәй кызыннан (1938), Николаевка районы Зур Чирекле авылында Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951), Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында Самаркина Миңнесания Шакир кызыннан (1936), Галиева Гөлзифа Миңсафа кызыннан (1932), Якупова Мәрьям Ибраһим кызыннан (1936), Сәфәргалиева Сәрия Сөнгатулла кызыннан (1941) язып алынды.

[3] Николаевка районы Әхмәтле авылында Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935) язып алынды.

[4] Карсун районы Аксу авылында Фәисханова Таһирә Садыйк кызыннан (1945), Николаевка районы Әхмәтле авылында Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935) язып алынды.

авылында Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935) язып алынган «Сафиулла бәете», Карсун районы Нугай иле авылында Хәйретдинова Мария Каюм кызыннан (1959) язып алынган «Гүзәлия бәете», «Илдар бәете» бу төбәктә бәет чыгару традициясенең дәвам итүен күрсәтә.

Балалар фольклорының «Багу поэзиясе» әсәрләреннән берничә бишек җыры, әйтеш, юаткыч, мавыктыргыч, сөйләм такмагы, шулай ук «Күңел ачу» һәм «Уен фольклоры» үрнәкләре язып алынды.

Ульяновск өлкәсендә традицион рәвештә «Йокла, балам, йом күзең», «Әлли бәлли бәү итә» һәм «Аллаһу-Аллаһу» бишек җырлары киң таралган. Аларның берничә вариантын теркәдек.

Табышмаклар һәм паремияләр үрнәкләре дә өлкән буын вәкилләренең күңелендә генә саклана. Хәзерге вакытта дастаннар очрамаса да «Йосыф вә Зөләйха» әсәренең эчтәлеге Карсун районы Гуринка (Татарские Горенки) авылында Касыймова Нәкыя Якуп кызыннан (1936), Мәләкәс районы Атнагыл авылында Фәисханова Сания Солтангәрәй кызыннан (1938) язып алынды.

Йола фольклорына килгәндә, йолалар, гореф-гадәтләр турындагы мәгълүматларны җырлары, уеннары, махсус әйтелә торган сүзләре белән бер күренеш буларак язып алырга тырыштык. Мәҗүсилек һәм борынгы чорлардан калган сүз үрнәкләре, ырымнар, келәүләр, имләүләр, йолалар язып алынды.

Ульяновск өлкәсенең Павловка, Николаевка, Чардаклы, Яңа Малыклы, Иске Кулаткы районнарының татар авылларында гомер итүче милләттәшләребездән язып алынган, халкыбызның буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп килгән кайбер фольклор үрнәкләрен (язылып алыну тәртибендә тематик бүлекчәләргә урнаштырып) тәкъдим итәбез.

## МИФОЛОГИК СӨЙЛӘКЛӘР, ХИКӘЯТЛӘР ҺӘМ ӘКИЯТЛӘР (ияләр, женнәр турында)

### Җен юлына очрасаң адашасың

Урманга барганда вата шулай инде оланнар адашкалап йөргәннәр. Юлына очрасаң – адяшасың, шул җен юлына очрасаң адашып алып китә үзеңне. Ул юлны бик озак эзләрә кирәк аны, кайтып булмый. Кай вакыттан соң каадыр барып син чыгасың, ә үз юлыңа килеп булмый.

Безнең тау башындук, мында, адяштыра. Тау башы, вата Кучаса, Кучатка башы. Артыбыздук вата, бездән соң тагы бер урам – кырау урамы әтелә, бу инде безнең мәчет урамы санала. Кучатка башы – тау башы дигән сүз инде. Нишләп ул кучатка – төрле якка юллар киткән, шуннан кучатка башы булган ул. Кочерга юл.

### Йорт анасы

Ул һәрбер йортта бар. Йортны парядыкта тоткан йорт анасы. Тәртипле йортта йорт анасы була. Эчкән йортта йорт анасы юк. Күзеңә күренми ул. Может ишегеңне дә ачып керергә дә, тиха гына әләнеп чыгып та китәргә. Ул шундый, ә үзеңнең күзеңә күренми.

* * *

Хозур Ильяс бик укымышлы кеше.
Хозур Ильяс юлдаш булсын, дип
Әгүзе билләһи … рахим
Өч догамны укыйм

Йә, Раббым, шул догалар хакы-хөрмәтендә, йә Рабби, Ходаем, шул балаларымның юлларын хәерле кыл, җиңел кыл, уңышлы кыл, бәла-казалардан имин кыл, кайгы-хәсрәтләрдән, авырулардан имин кыл, йә Рабби, яхшы юлдашларга гына юлыккыз, йә Рабби, Ходаем, яманнардан ерак кыл үзегезне, и, Бер Ходаем, саулык-сәламәтлек белән җитеп, саулык-сәламәтлектә яшәргә дә насыйп итсен үзегезгә. Амин.

Ул инде укыганнарның янында шәүләсе йөри дип әтәләр инде. Намаз укысаң, хәтем укысаң.

*Павловка районы Евлейка (Йәүли) авылында*
*Назырова Разия Ризван кызыннан (1942) язып алынды*

Мин үзем мынчадан чыкканда ук утырам утыргычка да, йорт аналарына дога кылам, укыйм. Покойлана алар. Күңелем белән сизәм. Әле бит күзгә күренми, нитми инде, нәстә. Шул йортка бәрәкат сала дигән сүз ул.

*Павловка районы Евлейка (Йәүли) авылында*
*Шабакаева Рауза Мәхмүт кызыннан (1939) язып алынды*

## Йорт аналары

Яңы өйгә кешеләр үзләре күченә. Аннан соң ат йегеп, тозсыз ипи пешереп баралар, чакыралар. Шул арбаны еле ат китерә дия иделәр, утырышып киләләр. Авыр килә, ди. Кайвакытта ат күбекләнеп килә, ди. Үзләре күченеп килгәч, алар да (өй иясе) килә булган шулай. Йорт аналары.

Аны китерәләр дә, матлича дияләр иде, мында сарайга матличага шул ипине куялар. Иртә торалар – ул ипи юк. Ка китә ул, күрәсең, алалар. Шунарга абзар иясе дә дияләр бездә. Шул самый йорт анасы диябез инде шунарга. Атларны, сыерны шунда ялап, тигезләп куялар. Курюкларын үрәләр сыерныкын да.

## Җеннәр

Җеннәр бар. Алар йөриләр. Алар төрле сыйфатка кереп киләләр. Эт сыйфатына да кереп киләләр, хайван сыйфатына да. Кеше кыяфетендә дә була.

* * *

Алар ике: Хозур галәйәссәләм, Ильяс галәйәссәләм. Алар фирештәләр. Алар тере, син кая барсаң – синең яныңда. Юлга чыккач этәләр: Хозур галәйәссәләм юлдашың булсын диеп, сиңа ярдәмче булсын диеп.

## Хозур Ильяс

Бер кеше мәҗлес җыйган. Бу хәерче сыйфатына әләнеп килә боларга, кунакка диеп, хәер сорап килгән. Монда кешеләр йыйылган булган. Хәер сорагач, бабайга әйтәләр:

– Мешать итеп йөремә монда. Бар кит юлыңа.

Бабай озак та үтми киемнәрен алыштырып килә. Киемнәрен алыштырып килә, бай шикелле. Моны, бабайны күтәреп алалар да,

кил утыр мәҗлескә, утырталар. Өстәлнең уртасынук, чиста киемнән. Әле утырталар да, ашарга утыргач, теге еңен озайта төшә дә:

– Ашагыз, ашагыз, ашагыз, аша.

Еңен озайта төшәдер дә, тагы кабат:

– Аша, аша, бу синең хөрмәтеңә, аша.

Хәерче сыйфатында танымадылар аны. Ә киемнәрен алыштырып килде дә, еңен салган да тарелкага, аша дип әйтә, ди, бу синең хөрмәтеңә. Бу Хозур Ильяс булган.

Шулай сүлиләр.

* * *

Хозур Ильяс әле әйтеп куя шунда: балаң бәхетсез булыр, әли үзең бәхетсез булырсың, дип әйтеп сала, ди. Әли киресенчә бәхетле булырсың, балаң бәхетле булыр.

Аның баш бармагында сүәге юк, ди, сүәксез. Качан кул алышалар бит. Кул-кул биргән вакытта кешеләр шуның өчен шул бармакны тоталар. Любой кеше белән кул алышканда, менә бу бармаклар тотылган булсын. Сөяксез булса ул пустой кеше түгел.

Кеше адаша бит юлыннан барган вакытта. Шул юлда килеп булыша үзенә, юлын күрсәтә. Багасың вот янында килә, сүләшә, әйләнеп багасың – бер кая да юк. Юкка чыга.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Ибраһимова Рәисә Хәбибулла кызыннан (1938)*
*язып алынды*

Баланы урынына яткырган вакытта Аятел-көрсине укып яткырырга кирәк. Өйдә җен булгач, мич тирәсен сөртәләр, сыдырып чыгалар анда хыть акбур белән, хыть кумер белән. Үзең укыйсың аятел-көрсине, үзең – сызасың. Аны кояш барышы бит былай кояштан бу ягына (сәгать барышына каршы. – *И.Я.*) сызасың.

Ат курюгы бәйлиләр биленә. Җене киткәнче йөрергә тиеш.

Дүрт почмакка ата иделәр сәгать уникедә, әгәр шундый шайтаннар булса. Шылай сүли иделәр.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Ибраһимова Рәисә Хәбибулла кызыннан (1938)*
*язып алынды*

Пензенский область якын монда. Анда бер елга бар, кизләү, вот шунда адаштыра булган халыкны. Шул Кизләү елгасында. Тугай елгасы дип әтәләр иде. Шундый урыны булган.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Ханбеков Нариман Валиулла улыннан (1934) язып алынды*

Олан кебек елый. Ә кеше бара – дальше китә ул тавыш. Тагы бара – тагын китә дальше. Ул шулай адаштыра булганнар шайтаннар.

Хозур Ильяс ярдәм иткән, булышкан адәмнәргә.

Шайтаннар адяштырырга теләгәннәр.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Сейфуллин Сабирҗан Шакир улыннан (1939) язып алынды*

Йорт аналары бар дияләр. Һәр өйдә бар, һәр йортта бар, үдә бар.

Дыва (дога. – *И.Я.*) кылалар йорт аналарыбызга, йорт аталарыбызга дыва кылалар мәҗлесләрдә.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Сейфуллина Разия Измаил кызыннан (1941) язып алынды*

## Аздякы

Җен дигән нәрсә хәзер дә бар. Мин үзем дә күрдем.

Кырдан ике мужик киләбез. Мешоклар куйган сыртыбызга. Бер иллешәр кила булгандыр. Ерак түгел чыкты бер йорттан төлке. Кып-кызыл.

Тауны артыбыз белән мендек, курктык. Төлке очмый. Ул озаеп бара. Төлке сыйфатында. Беркем дә тормаган йортка төште. Мин аны сүләдем. Әттеләр бабайлар:

– Ул, ди, аздякы.

Ул ару тормаганнан.

## Шайтан

Яңгыз барганда юлда шайтан бар, юлны адаштыра. Алашаны кертә юлга. Сиңа монда барырга, ул монда алып китә. Бервакыт барасың да юлда барганда син етәргә тиеш, син етмәдең, барасың

да барасың каадыр и круг әләнәсең адашып. Аннан тойсаң – төшеп атны тугарасың да дуганы әләндереп җигәсең, укыйсың. Да, әтәләрие шулай. Мин әләндердем бервакыт.

Миңа эти-әни әтә иде – укы. «Колхуалла»ны укый идем, «Әбҗәт»не.

## Йорт анасы

Сөйлиләр. Ул бар иде. Азбарыңа кара алаша барса – син караны гына тот. Аңа кызыл килсә, иртәсен чыксаң, ул хайван тир эчендә була, аны йорт анасы төнне ашарга бирми – марить итә. Ул бар йорт анасы.

Яраткан алашаның ялын үрә иде. Әйтерсең, яхшы кызның чәчен тараган. Ә ул үрә. Алар бар иде.

## Хозур Ильяс

Хозур аләйәссәлам яз башы, апрель аенда, камчысын суга, кар эри, елыта инде. Картлар шулай сөйли иде. Хозур Ильяс шул числода камчысын суккач, ел удачно була.

Юлда, өеңә килеп сораса, аңа обязательно бирергә.

* * *

Бер кыз, ди, азган. Су бирмәгән. Әле бабай бара, китә авылдан чыгып, авылдан чыкканда яткан, телен салган.

Бага бу кыз:

Эх, раббым Алла, бу хайван су эчмәгән бит. Бага, коеда чылбыры бар, чиләге юк. Әле ботинкасын үзенекен чыгара, бәли дә коега ебәрә, суны чыгара да икенче ботинкасын сала да эчерә. Эчерә, кучук эчә. Аннан кучук аның күзенә бага да рәхмәт әткән кебек әтә.

Бу кыз китте. Аерылды, бара. Бер вакыт Аллаһы Тәгаләнең әмере белән тавыш килә:

– Аллаһы Тәгалә синең ни бар гөнаһыңны бәхилләде. Син хәзерге вакытта гөнаһсыз кеше.

* * *

Кешене утыртырга куша иделәр. Юлда барасың бит инде.

Анда да әйтәләр Хозур Ильяс йөрегән. Син анарга яхшы итәсеңме? Нитмисеңме?

## Су анасы

Егет кеше урамнан катя. Эче поша, чыга, вота мос (мост. – *И.Я.*), яхшы су иде клуб артында. Килә дә суга багып тора: таш өстенә чыгып утырган бер кыз, чәчләрен тарап тора. Су анасы, дип әтә иделәр шуны. Аны инде бу бер көн баккан, ике көн баккан. Кит каян килсен монда су анасы. Ә бу сызгыра да, яхшы сызгыра, теге суга чумып китә. Аны шул берничә күргәннәр. Аны әтәләр сызгырырга ярамый. Аны сызгырып кугач, ул зарар бирә. Аны халык күрсә дә әтми, сүләми иделәр андыйларны.

Күп андый мәкальләр.

## Чикләвек чәчәге

Ике яхшы моселманча укыган егетләр булалар. Чикләвык чәчәк аткач, болар бара, чикләвык чәчәген ала и берсе – авызга каба, берсе – шул төшен яра да пәке белән чәчәген куйа да кулы белән тота. И килгәндә боларны шайтан адаштыра да иртән уяналар болар мунча пичендә. Пичкә тыккан үзләрен. Ул алардан алган аны шайтан. Авызларыннан да алган. Әгәр дә алмаса, алар кая любой төшкә барсын, любой төштә замокны ача булган, любой төшкә керә, любой нәрсәне ала. Алар саклый алмаганнар чикләвык чәчәген алгач.

Чиклавыкның чәчәген бар өзеп ал, авызыңа кап та китер. Чиклавык чәчәген ала да авызына каба да и китерә. Каа салып китерәләсең? Ә берсе ярган шул төшне, шунда кыстырган чәчәкне и ту шайтан алган үзләреннән.

Чиклавыкның чәчәгенә тияргә ярамый, ул сихырлы.

Ул чиклавык чәчәген алгач кешеләр любой нәрсәгә способный булалар. Шуны сөйли иделәр. Булган безнең авыл кешеләре, барганнар икәү. Үмәр белән Шакир бабай. Ну саклый алмаганнар. Кулындагы киселгән урыны калган, алганнар тегеләр аны, алган шайтан.

Аларга по пути дыва укырга кирәк. Аның девасын белергә кирәк. Девасын белгәч, шайтан киләлми синең янына. Ничә сәгатьтә ала алмаса – ул синдә кала.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Бикбаев Якуб Хәсән улыннан (1933) язып алынды*

Мин үскәндә бер әби бар иде. Зыян күрсә, ничектер аз гына йомырканы тишә, чәч бөртеге, тырнак, аяктан тырнак, кулдан ала. Ходайдан сорап: авыруы китсен диеп, ул итеп ташларга тиеш. Янында кеше барса, сүләнмичә барырга, сүләнмичә кайтырга тиешләр алар. Шул йортка керергә һәм бикләргә – чыкмаска таң атканчы, кояш чыкканчы. Анда атын, юлын әтә. Аның авыруына шифа бир, ди. Аны итеп бәрә торган булганнар алаша белән, алаша да тарта алмый – шайтан утыра, кое-как бара. Төрлечә, кеше үзе генә дә бара.

* * *

Йорт аналарын күчерәбез диеп, әпәйне аергандай кисәләр. Баламны үзгә йортка чыгарам, әпәйне уртага кисәбез дә, яртысы – сиңа, яртысы – миңа. Шуннан әтәләр – кискән әпәй ябышмый. Аерым торырга тиешләр алар. Тырышсыннар үзләренә үзләре.

Төнне мунчага яңгыз барма, җиннәр, төнне йөремә – шайтаннар. Төнне евынырга бармагыз – су анасы әтәләр иде.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Долгова Фатыма Исмаил кызыннан (1948) язып алынды*

Авылның елгалырак урынында яшьләр була, и анда тормый торган йортлар и багалар, нидер төшә, төшә, күрәләр и югала. Болар тиз генә ул урыннан китәләр. Ул җен төшә була. Аздякы – җен. Курюклый, курюгын нитеп төшә. Элек әтә торганнар иде: җыештырыгыз, аздякы төшәр йортыңа.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952),*
*Долгова Фатыма Исмаил кызыннан (1948) язып алынды*

* * *

Йорт анасы бар диләр һәрбер йортта. Бездә бер әби бар. Чыгып китсә өеннән йорт аналарына, йорт аталарына арчып-арчып канфитлар куям, ди. Тәрәз төбенәме, шулай куям, ди. Йорт аналары, йорт аталары ашагыз мин килгәнче, дип. Калдыра, аш-су калдыра. Яраткан йортында шул кешеләрне ярата, шул йортны ярата, зыян килми ул йортка. Вот дева кылганда әйтәбез: Йорт анакайлары, йорт атакайлары сезгә дә саулык-сәламәтлек бирсен. Шул йортта хуҗа булып яшәргә насыйп итсен.

* * *

Әгәр син садака бирәсең икән, Хозур Ильяс ул җыймый, калдырып китә, ди. Вот бирәсең садаканы, багасың – ул ишек алдында куеп калдырган. Вот шул була диләр Хозур Ильяс.

### Хозур Ильяс

Бер шофер бара. Камаз. Бер хатын баскан, кулына олан тоткан. Оланы икән үле. Бу шофер инде туктаткысы келәмәгән. Алмаган ул аны. Аннан бу җиткән – бер бабай. Ул бабайга туктаткан. Бабай әйткән:

– Нек алмадың хатынны? Юлда хатын баскан, тора.

– Туктатмадым инде, дигән.

– Аның выт кулында үлгән олан, син алмадың. Әле бар, ал.

Аннан килә, бу бабай юк, югальган. Ул Хозур Ильяс.

*Николаевка районы Әхмәтле авылында*
*Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935),*
*Мустеева Розалия Кәбир кызыннан (1957) язып алынды*

### Аздякы

Әтием сүли иде. Яшь вакытта әтием хаста булган. Әле эшкә баралар. Эшләдек тә мин, ди, салашта (шалаш. – *И.Я.*) калдым, ди. Эшчеләр киттеләр каадыр 12 чакрым абидка, ашарга. Мин, ди, шында калдым, ди, кырда, ди, ятарга, ди. Бервакыт баксам, ди, шундый ут кебек килеп төште, ди. Ул теге помойлыкларда булган. Шул ут кебек килеп төште, ди. Шуны күрдем дә, ди, ут кебек төште, ди. 12 чакрым киткән кешеләремнән алдан чабышып җиттем, ди. Әле, ди, барсалар, ди. Син нек монда килдең? Шултике үземә куркыныч булды, ди. Ват аздякы шул, төшә ул помойларга. Күрәсең, ул булган. Әтием әтә иде, үзем күрдем. Ут кебек килеп төште, ди, и хатын сифатына әләнде, ди. Ялангач хатын сифатында. Мин шуны, ди, күрдем дә, ди, киткән рабочидан – халыктан алда чабышып җиттем, ди.

* * *

Әле сугыш вакытында минем әтиемнең хатыны үлә 1943 елда, кала авылда 5 баласы.

Әле, ди, урманда барам, ди, автоматым белән сакта торам, ди. Әле, ди, шул, ди, хатыным булып килде, ди, и мин тотындым атарга, ди. Анарга хатыны булып төшкән шул – мәлгүндер инде, шайтан инде була, күрәсең.

* * *

Абзиларым эләккә баргач, урман эләге җыеп килгәндә адяштык, ди. Бер каан чыгалмыйбыз урманнан, ди. Шундый бер ап-ак бабай килде, ди. Таягы кулында, ди. Чыгарды да, ди, и юк та булды, ди. Адашкан җирдән чыгарды, ди. Хозур Ильяс адяшканны юлга чыгара, ди.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Сулейманова Наҗия Мөталлиб кызыннан (1955) язып алынды*

Минем әтиемә Хозур Ильяс чыккан. Пензенский областян алаша китерә идем, ди, ат китерә идем ди. Ат өстенә атланган, ди, төн уртасы, ди. Берни күренми, караңгы, ди. Кыр-урман эче, ди. Юлыма адяштым, ди. Алашам, ди, вис тиргә батты, ди. Каа барырга белми, ди. Бер кругта әләнә, әләнә алашам, ди. Куркуга калдым, ди, урман эче, караңгы, ди. Әле багам, ди, бер ап-актан озын гына таяк тоткан ак киемнән киенгән, ди, бер бабай бара, ди, тиха гына, ди. Әле әтәм, ди, бу кемдер бара, моның артыннан мин тиха гына барыйм әле, ди, барам, ди, артыннан тиха гына аның артыннан, ди, әле, ди, юлга чыктым, ди, юлга чыктым да, ди, и шул кешем юк булды, ди. Ул Хозур Ильяс адашкан төштән мине чыгарды, ди.

* * *

Мин кече улымны үләндерергә җыена идем. Шулай диванга яткан, көндез иде. Йоклыйммыдыр, йокламыйммыдыр идем. Үзем дә белмим. Әле каршыма килеп бер бабай басты. Актан киенгән, сакаллы, зур гына буйлы, әле килде дә, балам, ди, син, ди, туй уйнарсың, ди, эвеңә (өеңә. – *И.Я.*), ди, аракы-хәмер кертмә, ди. Әле мин куркынып сискәнеп киттем кеше дә юк, ни дә юк.

Әле инде оланнарым җыелдылар, сүләделәр туйга китәргә. Мин әйтәм Хозур Ильяс килде каршыма, ул мәтәм этте: эвеңә аракы кертмә. Ярый, әни, диләр. Әлхәмдүлилләһи шөкер, эвемә аракы кергән юк.

* * *

Йорт анасы бар. Ул яраткан кешесенә генә чыга. Әниемә йорт анасы чыккан. Чыктым, ди, сыер савырга, ди. Терлеккә аш сала торган урында, шунда, ди, ап-ак яткан, ди.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951) язып алынды*

Әле минем абзием авылдан киткәч, нинди генә авылларда тормаган инде. Актык урынында торганда: тордым да, ди, чыктым йортыма и, Раббым, этәм, ди, минем йорт анасы бар микән, юк микән этәм, ди. Әтәләр йорт аналары бар, диеп. Әле, ди, чыксам, ди, шылайга сүләнеп торам, ди, ап-ак кына, киенгән, ди, узды китте, ди, йортымнан, ди. Ул йорт анасы булып чыкты, ди. Ә, этәм, ди, бар икән, үземнән калмый икән йорт анам.

* * *

Яңа өйгә чыкканда: аерылып үдән киткәндә, алаша белән баралар, чтобы йорт анасы алашага утырып барсын. Аның дывасы бар укырга. Йорт аналарына «Табаряк» укыйсың. Пешкән ит янына тоз куясың, әпәйне эскәтергә чорныйсың да и кертеп куясың өстәлгә – яңа чыккан үнекенә (өйнекенә. – *И.Я.*). Шунда инде «Табаряк» укыйсың. Йорт анакайлар риза булып, шатланып, үзем белән килгән булыгыз, бергә торырга тыныч кына, тынычлыкта яшәргә насип ит эвебездә.

* * *

Йорт анасы яраткан кешенең чәчен үрә булган. Вот әниемнекен чәчен үргән. Аны берничек тә сүтәлмисең. Вот ничек үрәбез шулай үрә булган. Аны кисеп кенә ала булганнар. Атларныкын да үрә булган, да.

* * *

Йорт аналары бар. Яратмаган әле сыерларын – салалар калодага. Чыгасың – сиерың каладога сырты белән яткан, тирләгән, пешкән.

Күршенең өченче елны бозавы бар иде. Чыгам, ди, иртән – ничек керә торгандыр, ди, керергә дә юк, шул колодага яткан, ди,

бозавы. Йорт анасы яткызган була. Яратмаганга шулай эшли. Кайсы кара төс бармый, кайсына кызыл, чобар.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951),*
*Сулейманова Хәлимә Сабит кызыннан (1950),*
*Сулейманова Нажҗия Мөталлиб кызыннан (1955) язып алынды*

Минем туганымның малае безгә мунчага йөри иде. Мин кыз вакытта әл дә. Әле мунчадан чыккан да, әбисенә керде, әтием минекенә:

– Әделша, Әделша абзи, ди. Мунчага бармадымы, ди. Мәтәбез, юк. Анардан да сорый. Бармадым, ди. Кемдер, ди, ишекне ачып, ди, әмән керде, ди.

– Кем дә бармады.

– Керде дә, ди, мунчага, ди, чабынырга тотынды, ди. Мин чыктым, ди. Мунчага керде дә, ди, чабынырга тотынды, ди.

Без чыга идек, последний керә идек әбием белән мунчага, әбием әтә иде:

– Йорт party аналары, йорт аталары, мунча сезгә калды, рәхәтләнеп евыныгыз. Әле дә мин әтәмен. Бисмилля итеп ишекне ябамын да:

– Йорт атакайларыбыз, йорт анакайларыбыз, чабыныгыз, мунча сезгә.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951) язып алынды*

### Залякта шайтан адаштыра

Бездә әнә линия уза. Теге ягында Заляк – полянка бар. Шул Залякта кешеләрне адяштыра. Бу юл белән китәсең – син барып төшәсең Кормәилгә. Үзең дә тоймыйсың ничек барганыңны, адяштыра сине, син аны белмисең, барып адяшып төшәсең син. Автобуска бара идек моннан. Заляк аша барырга. Хәзер җитәм остановкага диеп, син барып чыгасың Кормаевкага, моннан 3 км. Шайтан адяштыра кешене Залякта. Барып төшәсең зур поляна, линияне күчәсең, анда посадка, теге ягында поляна – Заляк әйтелә. Еләк тә анда була. Шуның уртасыннан юл бара. Өч юл анда. Берсе шулай асфальтка җиткән, узган теге якка, анда тора

мордвиннар. Шунда барып чыккан. Ничектер күчкән, асфальтны тоймаган. Шайтан алдый: кулыңны аягыңны бәли.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Аюпов Мидхат Идрис улыннан (1956) язып алынды*

Элгәре бит җеннәр халык белән бергә йөрилер иде.

Минем әтинең әнисен куып төшергәннәр, әбине. Элек бит су буенда иде мунчалар. Су юк иде бит элекке колонкаларда. Инештә менә монда артта су буенда мунча иде. Кара мунча, идәне бит инде йердә, йер өстендә кечкенә генә керосин ние. Кара мунча төтен чыгып элеккеге заманда. Яккач 3–4 семья керә инде, күп кеше, сулары да әз. Минем әтинең әнисе мунчага киткән. Кич булган. Бу әби менгән пулга (полга) чабынырга бу икән чабына, үзе генә барган. Әниләр баргалагынчы. Минем әни – килен. Әниләр барып ала торган булганнар элеккеге заманда кайняларны.

Башта винигын алганнар кулыннан. Бу ни галәмәт хәл, кулыннан төшеп китте дип уйлаган әби. Арткарак киткән дә, әкрен генә килгәннәр дә:

– Төш, – дип мыны шудырып төшергәннәр, әбине этәргәннәр. Сүләмәгәннәр дә. Этәрә баралар, ди, этәрә баралар, ди. Этәрә-төртә, әби шуыша бара пулдан. Әби инде әйберләрен кочаклаган да, чыккан ишек алдына. Әниләр барганнар, керми, ди. Килен, кермим, мине куып төшерделәр, дип этә, ди, анда, винигымны алдылар. Дөрес, винигын да алганнар, виникны куйганнар идәнгә, ди. Утыргыч кебек ясаганнар үзләренә, шунда куйганнар. Ә виник пулда булган. Алганнар кулыннан тартып. Инде уйлаганнар әниләр кулыннан төшкәндер дип. Ул төшмәгән, алганнар, утыргычка куйганнар шулай виникны әкрен генә. Әле әби чыккач даңгырдаттырып табакны бәргәннәр, юына торганны, суын түккәннәр әбинең вот бит нәрсә.

* * *

Мунчаларда булды ул хәл. Бер бабай үзе генә керә торган булган. Ул бабайны мунчадан алып чыкканнар кичке якка. Теге якта, кая минем братларым тора торган каршы якта, анда су буенда мунчалар. Ул бабайны әкрен генә алып чыкканнар, кемнәр икәнен

бабай белмәгән. Җәй көнне алып чыкканнар, сүзсез генә. Бабай чыккан хәзер, коенырга төшергәннәр. Чумыралар да алалар икән дә, чумыралар да алалар бабайны. Ул бабайның малае төшә артыннан. Ә бабай суда була әле. Сүгенәлми дә икән бабай, укий да алмый икән. Телдән калган. Әле кайткан ул бабайны өшкерттеләр: җиде «Ясин» чыгарттылар. Шуннан соң гына бабай телгә килә.

Элекке күп иде җен. Хәзер үзебез янга килмиләр, куркалар.

* * *

Җен алыштыру да булган. Мына әби сүләде безгә, аны кемнеке ничек хәзер оныттым. Бер баланы алганнар, и бүтәнне биргәннәр. Хәзер бит инде алып кайтканнар. Ул бала бит елый да елый икән. Бабайны алып килгәннәр өшкертергә. Бабай әйткән:

– Бу бала сезнеке түгел, дигән. Өшкергәнне алмый, ди. Өшкерәлми ул бабай. Аңнатканнар инде мунчада шулай дип.

Бабай:

– Итеп куегыз пулга. (Авылда булган хәл, мунчада.) Итеп куйганнар. Үз оланнарын китергәннәр. Үз оланнарын алып кайттылар, аннан соң җеннәр үзенекен алып киткәннәр, ә аны китергәннәр. Кая тотканнар, ничек тотканнар, белмим. Ул баланы алып кайтканнар, олан камыр кебек булган, җиде «Ясин» чыгартканнар. Ул үскән. Исемнәрен дә әби сүли иде. Бала вакытта сүләнгәннәр иде. Онытылган.

## Кое тоту

Ябылган коелар узып китәсең дә, изгеләр, кое газизлары, су газизлары – аларга да укыйсың. Кое тоткан, ди. Кое газизлары, су газизлары – һәрбер нәрсәнең хуҗасы бар аның. Мена алар кемнәндер өмет итәләр. Мена төшкә керә бит ул. Йә аягыңа бәләнә, йә кулыңа бәләнә. Шул газизлар бәләнәләр, өмет итәләр. Авырта. Йә раббым, дип миңа эшкәрт инде, Раббым, илаһи, дип догаларны укыйсың, ни белгән догаларыңны. Әниемнең әнисенең капка төбендә кое булган, элеккеге заманда. Мин әбиләргә йөри идем кунарга. 15–16 яшемдә булганмындыр инде. И минем аягыма чыкты сөялләр. Алар башта әз генә чыкты, аннан әрнергә тотынды, аннан күбәйделәр. Йә, Раббым, мәйтәм ник кенә соң бу

хәтле әрни минем бармагым. Бармакка менде берсенә-берсе инде. И мин төш күрәм: как-будто бу әбинең капка төбендә, мин аны белми идем элекке, шул кое, ул йер, капка төбендә (бит) җир инде мына шул кое сап-сары, үтә тонган бәке кебек и үтә күренә ул. Шуннан түгәрәк кенә бер зур гына бака чыкты да минем аягыма ябышты, и кечкенә бакалар чыкты, тагын ябыштылар аягыма. Мин аны иртән тордым да әбиемә сүләдем. Әби этте: Кызым, ди, бәбкәм, минем капка төбендә кое, кое токкан сине, ди. Әби миңа догалар укыды. И шул догаларны укыганнан соң өшкерде дә, минем ул сүәлләр төне белән коелдылар.

Йә, Раббым, диде. Минем оныгымнан, Раузадан өмет итүче су, кое газизлары, диде. Өмет иткән булсагыз, диде, риза булыгыз. Сезгә Рауза исеменнән, оныгым исеменнән шушы «Ясин» сүрәләремне укыймын, диде. Өмет итсәгез, җибәрегез, диде. И укырга тотынды. «Әлхәм» сүрәсен укый, «Әлиф-ләм», «Аятелкөрси», «Фәләк», «Нәс». Йа, раббым, Илаһи шушы оныгымнан, Раузадан өмет итүче кое газизлары, су газизлары, изгеләр, кемнәр генә өмет итә торгандыр, токкан булсагыз ебәрегез, риза булыгыз, аның исеменнән шушы «Ясин» сүрәләрен укыдым. Илаһи, үзең кабуллардан кылсаң иде. Раббым, үзеңнең ризалыгың өчен укыдым, илаһи амин. «Раббәнә», Аллаһу әкбар.

Коелды, бетте, әрнемәде, чыкмады.

Су тота инештә. Шул ук догаларны укыйсың. Су газизлары да бар. Коеныкы аерым. Ябылган коелар бар. Ә су – инеш бит инде ага, елга ага.

Изгеләр бар тагы. Изге адәмнәр. Алар да мени укыган, ниткән вакытта өмет итәләр инде. Укыйсың инде багышлаганда. Су, кое газизлары, изгеләр. Ясин укыганчы әтәбез инде.

Хайваннар хуҗасы, тимерләр хуҗасы, ут хуҗалары. Зәңки бабай – хайваннар хуҗасы инде. Калганнарның исемнәрен белмим.

* * *

Йорт хуҗасы бит инде ул мени син бүтән йортка күчәсең икән аны үзең белән бергә алып китергә тиеш. Метлага атланасың да, әдә, миннән калма өй хуҗасы, минем белән бергә күчәбез, – дип,

укый-укый алып барасың. Метлага йорттан атланасың. Яңы йортка барып җиткәнче метла белән барасың. Күчә ул синең белән, калмый, хуҗа алып бара аны. Барасың бүтән йортка. Ул как-будто ишекне ачып чыга. Ишек үзе ачыла, кемдер йөри. Ул өй хуҗасы. Бүтән йортка барасың үзенең килгәнлеген белгертә. Шыкылдап йөри башлый, каядыр барып бәрелә. Килдеңме, яхшы, минем белән бергә иялән бу безнең йорт була, дип укыйсың инде үзең белгәннәрне. Хуҗа яратамы – өй хуҗасы ярата.

* * *

Хайваннар хуҗасы ул аерым. Мына инде кай вакытта ялларын үрә бит инде. Әйтәләр инде ул ошатмый. Аларга да укырга кирәк. Зыян итә башлыйлар алар.

*Чардаклы районы Енганаево (Үрән) авылында*
*Яруллова Рауза Бари кызыннан (1949) язып алынды*

Озын табагачка атланды да:

– Әдә, бу йортка син зыян итмә. Син хуҗа буласың дип сүләнә-сүләнә алып керә. Будка (ботка. – *И.Я.*) пешереп куя – утырып аша, дип йорт иясенә.

* * *

Тауны менгән вакытта, ди. (Ул шуфер иде.) Йөгереп менде дә кабинкага басты, ди, ап-ак киемнән киенгән кеше, ди. Кабинкага кермәде, ди. Менгәчтән төшеп калды, ди. Кайтып куркып сүләгән иде шуны. Моннан 8 км. Вата күрше авылга. Менгән дә машина белән. Тигезлектә төшеп калды ди. Хозур Ильяс юлдашың булсын дип әтәләр бит.

* * *

Кемдер барган мунчага кояш иңгәч. Юынганда үзен ботарлап ләүкә астына керткән булган җен.

*Чардаклы районы Абдулла авылында*
*Насыйрова Раушания Рамил кызыннан (1970)*
*язып алынды*

Әбиләр сүзе: Аждаһа төшә диләр иде элекке. Мунча көлләренә.

* * *

Адаштыра җен. Атның адымын әкренәйтә. Ат сизә, куркына дияләр иде.

* * *

Атның ялы үрелгән дияләр иде. Җигәргә чыгалар, атның ялы үрелгән.

*Чардаклы районы Татар Колмаеры авылында*
*Шәрәфетдинова Фатыйма Камалетдин кызыннан (1936)*
*язып алынды*

Ашыйсызмы, эчәсезме – савытыгызны калдырмагыз, ул сезнең савытыгыздан аши җен. Сез аны чайкап куегыз.

* * *

Ул иләшсә ирең булып кайта, ди. Бер хатын этә икән:

– Минем ирем үлмәде.

– Ничек үлмәде? Ничә ел инде, ничә ай инде ирең үлгәнгә? дигәннәр.

Ул:

– Минем ирем кайтып йөри, үлмәде.

– Ничек?

– Юк. Мин көн дә ирем белән ашап-эчәм, мин аңарга ашарга худлыйм, ул аши, бергә йоклыйбыз, дип этә ди.

– Ай, Алла, ничек йоклыйсың синең ирең үлгәнгә инде күпме?

– Юк. Кайтып йөри. Без аның белән сөйләшәбез, телевизор карыйбыз, ашап-эчәбез бергә йоклыйбыз, дип этә, ди.

– Туктале, син карале, ашаганда син өстәл астына игьтибар итәсеңме? дигәннәр.

– Юк. Өстәл астына ул хатын игьтибар итсә өстәл астында мена озын койрык икән. Аны куркытырга кирәк дигәннәр. Мена өйнең читенә атырга ди. Дүрт читкә дә (почмакка. – *И.Я.*). Мена шуннан соң ул хатын тынычка калган.

*Чардаклы районы Иске Үрәнбаш авылында*
*Мөбәракшина Саҗидә Харис кызыннан (1951) язып алынды*

### Хозур галәйәссәлам

Безнең әтиләрнең элекке җирләре булган. Хәзер бардык, ди, каршы Рәвизәләр белән. Алар үзләренең брат белә, ди. Мин үземә брат белә, ди. Киттек җирләрне карарга, ди. Алар үзләренә бер шалаш ясап ятты, ди. Мин үземә бер шалаш ясап яттым, ди. Йокымсырап китеп барам, ди. Шыкы-шыкы берсе шыкылдата, ди. Нәсә бар инде, дип әтәм, ди. Башым күтәрдем дә, ди, бернәрсә юк, яттым, ди. Әз генә ятып тордым да, ди, тагын шыкылдата, ди. Әкертен генә кесәдән шырпыны алдым да, ди, кабызып карадым, ди. Кечкенә генә ап-ак сакаллы карт каршымда басып тора, ди. Хозур галәйәссәлам. Иртә белә торгач карадым, ди. Карасам межаның нәкъ уртасына ятылган икән, ди. Хозур галәйәссәлам булган, торырга кушкан, межага ятмаска.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Сәфәргалиева Сәрия Сөнгатулла кызыннан (1941)*
*язып алынды*

Әни сүли иде. Бабай чәчкәндә, кызау белән чәчкәндә, Хозур галәйәссәлам межадан уза, ди:

– Алла куат бирсен, бабай, нәрсә чәчәсең?

– Әрем, улым, – дигән.

– Илаhи амин, әрем булсын, дигән. Бабай барган. Бабайның атасыдыр инде ул. Барса әрем, ди, кызым, ди. Хозур галәйәссәлам дога кылып киткән. Ялт иттереп теге бодай юк. Бодай чәчкән булган. Әрем үскән.

Хәзер генә ул каргыган каргышларыбыз, теләгән теләкләребез ахирәткә калыр, ди. Элекке көне белән була торган булган. Көнесәгате белән төшкән теләк тә, каргыш та. Менә әхирәткә кала хәзер.

* * *

Менә синең җирең, минем җирем. Уртага бүлер өчен межа – Хозур галәйәссәлам юлы.

* * *

Безнең бер апаның ире үлде. Хәзер уйлап ятам, ди. Кайтса кертер ием әле. Балаларның этисе бит ул. Кумас ием, нитмәс ием,

бергә торыреык. Хәзер шытыр иткәнгә, ди, борылып карадым, ди. Карасам тәрәзәгә кайтып баскан, ди. Шуннан борылып яттым да:

– Тьфу-тьфу, мәлгүн, җен алдап йөри икән.

* * *

Камка түтинең дә кайтып йөри диләр. Чирыш бабайны исәпләгән-исәпләгән ул. Карты зираттан кайтып йөри торган булган. Мөрҗәдән чыгып китә торган булган, ди. Алар бик матур әйбәт торганнар, ди.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Самаркина Миңнесания Шакир кызыннан (1936)*
*язып алынды*

Минем кайнанам бик укымышлы кеше иде. Хәзер Чаука Гөлсем апалар белән янаша торабыз. Чаука Зәйнәп апа үлде. Бик кинәт кенә, иркә генә тора иде, тормышлары да яхшы гына иде. Безнең күршедә генә Гөлсем апа тора, аның сеңлесе. Бервакытны бу кергән. Кайнанама әйтә менә шундый хәл, ди. Гөлсем апа әйтә: Пич башына менеп утырдым. Менеп утырсам, ди, бервакыт калитка ябылган кебек булды, ди, шылт иткән кебек булды, ди. Башымны былай иттереп пич башыннан карадым да, ди. Ак күлмәк кигән апа кереп китте, ди, Зәйнәп апаны. Үенә керә имеш. Мин тәрәзәдән апаны күреп калдым. Ак күлмәк кигән апа үтеп китте, ди. Кайнанам әйтте инде моны диде укырга кирәк. Әле ул минем төшемә дә кереп йөдәтә диде. Менә шундый хәлләр булган.

Чаука бабаңның үзе турында да сөйләгәннәр иде. Чаука бабаң үлгәчтән имештер, ди, аның каберлеге ишелгән. Кемдер барган анда. Укыргамы. Куыш калган. Ул вакытта хатын-кыз бармый иде. Хәзер теләсә кем кереп йөри. Аннары әйткәннәр. Әлхәрәй бабаң барып тишегенә имән чөй кагып каткан икән. Чыгып йөрмәсен өчен.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Якупова Мәрьям Ибраһим кызыннан (1936)*
*язып алынды*

Юлда йөрүчеләргә юл күрсәтүче, диләр иде безгә. Адашсаң кырдан Хозур Ильяс кычкыр, ул сиңа юл күрсәтер дияләр иде.

* * *

Җеннәр бар, җеннең Иблисе бар. Аллаһы Тәгалә белән сүләшкәннәр бит Иблис:

– Адәмнәрне мин供 аздырам, дигән җен.

– Ничек аздырасың, аздыралмыйсың.

– Минем юлдан чыгармыйм. Ул минем юлымда булыр, дигән. Теле белән булмаса канына кереп адаштырам.

– И, мәлгүн, дигән Аллаһы Тәгалә. Элек Иблис булган. Мәлгүн исем биргән Аллаһы Тәгалә.

* * *

Җен кергән дә:

– Син, ди, укыйсың, ди, Аятел-Көрсинең ахырын укыма, ди.

– Ник? минәйтәм. Анда өч кенә сүз, ничек калдырасың.

– Аны укысаң безгә авыр, ди. Без дөнья күрәлмибез, ди.

– Үә лә яһидиһү һевзеһүмә. Үә һүә галиул газыйм, – дидем дә, юк булды шуннан. Безгә авыр була ахырын укысаң, ди. Адәмгә охшаган, кап-кара киемнән баскан ир-ат. Татарча сүләшә. Үзем белә сүләшеп торды бит әле.

Гыйлеме дә бар, укилар, ди, алар.

*Яңа Малыклы районы Зирекле Куак авылында*
*Яббарова Рәйсә Нурулла кызыннан (1918) язып алынды*

Зәйнәп апа, Хатимулла абзи хатыны:

– Хатимулла көн дә кайтя, дип әтә торган булган ул. Кызы барие Зәмзәмия исемле. Ире үлгәч килгән инде. Ире булып килеп йөргән. Өенә килеп йөргән җен. Читләренә (почмакларына. – *И.Я.*) атканнар, куркытканнар имеш тә. Барыбер Ташкентка киткәннәр качып дип сүлиләр ие.

*Яңа Малыклы районы Зирекле Куак авылында*
*Яббарова Рәйсә Нурулла кызыннан (1918) язып алынды*

## Җен алыштырган

Мин чыктым тормышка. Кайням бар. Күрше Халида апа сыерлар арканнарга киткән, аккурат абит вакытта, кыл абит вакытта. Сәгать 1 тулгач, 15 минут узгач укыйбыз намазны. Кыл абит

вакытында намаз укырга ярамый. Бу абит вакытындада китә сыер арканнарга. Трактрный бригад янына. Монда кайтса бишектәге яшь бала уже үзенеке тегел, алмаштырган.

Егырып керде, кайням Халиса исемне, барыбыз да үдә:

– Халиса апаа, Минҗианым әллә нишләгән.

Әни егырып керде, кайняна-әни. Ислак абыең да бар. Ирем дә бар. Без инде аннан соң гына кердек. Керсәк, дөрес олан камыр кебек, олан моныкы тегел, камыр кебек, ярар. Әни аны, кайнямәни алды да бусагага ыргытты, мени ишек төбенә. Анда ыргытты да, әзрәк шулайрак төшерде инде ул.

– Ват, бәдбәхет, каан килдең, шунда кит, ват бәдбәхет, каан килдең шунда кит. Бусына без кереп эләктек.

Име-томы шул булсын,
Име-томы шул булсын,
Каан килдең шунда кит,
Каан килдең шунда кит
Име-томы шул булсын,
Каан килдең шунда кит –

оланны алып шулай итә. (Кайням-әни бик гыйлем иде. Үз әнием дә бик гыйлем иде). Оланны ала да яңадан бусагага ыргыта. Әле бит яхшы ук төшерә оланны. Еласа еласын, еламагае. Ала өч мәртәбә шулай төшерә. Ала-сала як-якка. Җен алмаштырган диделәр.

Җен алыштырмасын өчен, үзең чыгып киткәндә, баланың баш очында китап, иске китап тора. Аннарысың чыгып киткәндә, баланың өстенә шулай аркылы йә пычак, йә качы куеп калдыралар иде. Бу бит инде Халида исемне апа оланга бернәрсә куймый, кайтса – оланны пәри алмаштырып куйган. Җенне без мәлгнүн диябез, җен димибез. Аны мәлгүн алыштыргание. Первай үзе өшкерде әни. Аннары бабайларны яшеп, бабайлардан азан әйтеп шушы бала барыбер игә килде.

**Кәҗә Мингали бабайга җен иярләшкән**

Җен иялдәшә. Ары башта кәзә Мингали бабаңның карчыгына иялдәшкән ие. Мин ул әбиеңне бик яхшы белмим. Бабаем кайтып йөри диеп сүли торган булган әниләргә. Әниләр барып-барып

аны өшкерәләр иде. Анда әбиләр җинау барып укилар иде көндә. Угылга (почмакка. – *И.Я.*) мылтык белә аттырганнар.

**Хәербәнәт булыпияләшкән җен**

Тимертауга барганда безнең янга бер яшь кенә хатын утырды. Бер кызым Тимертауда минем. Хәзер моның үз әнисе үлә дә, әтисе яңгыз гына кала, әтисенә без инде пәри иләшә дибез – җен иләшә шушы бабайга. Бу байның карчыгы үлә, карчыгы үлгәч, бу бабайга җен иләшә. Шушы катын сүләп барды шундый яхшы иттереп. Хәзер төнен-көнен шушы бабай уйлана да уйлана, әби юк. Аннан әби булып мәлгүн килеп йөри монарга – җен. Җен килеп йөри. Хәзер, ди, әтиебез, ди:

– Әлхәмделилләһи шөкер, Хәербәнәтем килде дип әтә, ди.

Җен иләшкән. Минем әнием, ди, шушы бабай янына барып йөри иде, ди. Хәер бабай янына барып йөри дә, бабай янына барып утырган саен:

– Бабай, нәстә хәлең? Менә мин синең хәлең белергә барам бит.

– Әлхәмделилләһи шөкер. (Карчыгының исемен сүли ди.) Бергә, менә кайта-китә дип әтә ди. Ул мәлгүн мөрҗәдән килеп керә икән, мөрҗәдән кире чыгып китә икән. Һәркөнне ничек элекке бабай әби торган – гамале кылып торганнар алар, шул мәлгүн белән җен иләшкән анарга. Бабай көнен буена капка төбендә көтеп утыра икән. Аннары кичен керә. Мәлгүн мөрҗәдән төшә ут булып, ут булып чыгып китә икән койрыкларын да күрсәтеп. Бабай анысын да сүли. Шулай итеп, бабай үзләренең ничек гамәл кылганнарын да – барын да сүли. Килеп йөрүче мәлгүн үз катыны булып килеп йөри икән бабайга. Бабай бит һәркөнне саргая бара, саргая бара икән. Ызнай, үзенең карчыгы кайтты диеп, күршеләргә дә сүли бара. Үзенең элеккеге карчыгын янына килеп йөрүче әбиңә дә сүли. Әбиең монардан шикләнә башлый. Моның бит инде хәлен белергә керәләр.

– Ай, Алла, бу хәл болай ярамый, монарда ни бар икән, шиек бар икән дия. Әби белән ничек гүмерләнгән шулай гүмерләнгән байтак бабаң. Шушы бабай саргайды, саргайды, саргайды, ди, саргаеп кипте, ди. Монда үзенең эшен эшләп китә: кирәген әбиең белә сүләшәләр, чәй эчәләрме, кире мөрҗәдән менеп китә икән,

койрыкланып, анысына хәтле сүли үзе. Мына шул җен иләшү мына шушы. Саргаеп, кибеп үлде шушы бабай, ди.

*Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында*
*Әюпова Зәйнәп Миңгали кызыннан (1935)*
*язып алынды*

**Хөзүр галәйәссәлам**

Кайнәм-кайнатам бурлакка эшкә чыгып киткәннәр. Өчәү алар. Урак вакыты, ди. Кайня-кайната да була анда. Бурлакка чыгып китәләр. Хәзер бурлакка чыгып китәләр дә, ызан буйлап, ике җир арасын ызан дияләр, яшел кием киенгән (казаки атала ул) таяк таянган, ди, бер бабай килеп туктый болар янына. Әниләр көлтә бәлиләр, кайнатам атлар белән чаптыралар лабагрейка белә, өч ат белә. Хәзер без, ди, олан имезеп утырабыз, ди. Әнинең ул оланы үлгән. Сәлам бирде, ди. Сәлам бирде дә, ди. Бөтенебезнең башында ялангач, ди, минем оланымның, ди, башында оек балтырыннан бәләгән тәбәтәй – ул вакытта юк бит инде, бәләгән дә куйган. Бу балага сәлам бирәм, сезгә сәлам бирмим дип әтте, ди. Шулай итеп, сорашып китә: парауларны сорашкан. Кайната парауларны сүләп биргән, барын да әтеп бирелмәгән алай да.

Өченче кеше сүгенеп кирәкмәгән нәстә сүләгән. Шуңа:

– Менә нәстә чәчтең – шуны урырсың, дигән. Шуның шулай булды, ди, иген үсмәде, кипте, ди. Бу Хозур булган, Хөзүр галәйәссәлам.

Ике җир арасыннан – ызаннан, межа дисәң дә ярый, грань дисәң дә ярый. Ятырга ярамаган – зәхмәт бәргән. Барын да сорашты, ди, Парауларны да сорашты, ди. Шулай итеп, бу бабай сорашкан, сорашкан барын да. Киеме дә, читекләре дә ямь-яшел, таягы да. Үзе сәлам биреп килгән. Сәламне сезгә бирмим дигән.

* * *

Аннары соң берсе тегендәрәк атын туктаткан, болар монда карап тора икән. Теге:

– Асылыну нәстә була икән? – диеп әтә икән.

Тоткан да моның муенына чыбыркысын бәләгән дә, чыбыркысы белән сабан янына сүриләр, ди. Ай, Аллам, моннан карап

торабыз, ди, кайням сүли. Нәстә эшли бу, нәстә эшли бу. Чыбыркысыннан сүрәп баралар, ди, асарга. Ай, Алла, барып җиттек, ди:

– Нишләдең?

Менә шулай, шулай эткән ием, нәсә була икән әтеп шуны сыныйм әле дип тотына да, муенына чыбыркысын бәләп сүриләр, ди, мәлгүн, шайтаннар. Бер төштә чыгырлык юк, ди, шушы мужикны сүриләр, ди. Мин тырышам, дип әтә, ди, китмәскә. Әле мәлгүн сүри. Уйнарга кушмый шул.

* * *

Йорт иясе, өй иясе бар. Без бит әпәй салганда пич төбенә сала идек тә, пумала белән, коры пич төбенә, калайлар белән түгел, коры пич төбенә әпәй салыш иде. Шул әпәй пумаласын куеп үзеңнең йорт ияңне:

– Әйдә, киттек, дип ияртеп барасың, алып китәсең. Пич пумаласын иң башына куеп. Кайнам бар иде. Үзенең белгәнен укып, иман укып:

– Әйдә, киттек, киттек үзебезгә.

Шулай укый-укый бара:

– Яңы йортка киттек, әйдә.

Өч мәртәбә әләнә.

Например, без башка авылдан күченеп киләбез. Оланнарны утыртып киләбез, ат тарталмый, ат киләлми, ул икән үзеңнең йорт ияң. Салават әтеп, үзеңнең йорт ияңне апкилергә икән ул.

*Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында*
*Гайнетдинова Миңзадә Шакир кызыннан (1936)*
*язып алынды*

### Өй хуҗасын озату

Өй хуҗасы булган. Минем абыем мулла, мәчеттә хезмәт итте. Сөйли: Өй хуҗасын озатмасаң ул бөтен кешегә мишайт итеп ята икән. Аны елына бер мәртәбә, казан, мына шундый аш пешерә торган түгәрәк казан тирәли акчаларны тезеп, әйләндереп чыгалар, укып дога. Аның аерым догасы бар. Аш пешерә торган, элеккеге пичләргә зур казан куя идек. Токмач, бәрәңге пешерә торган казаннар. Теләкләр уздырып, акчалар тезеп өй хуҗасына

багышлыйбыз. Өй хуҗасы иту йокларга да бирми, яшәргә дә бирми, бәхет тә бирми. Пичкә куясың казанны, аш саласың, бутка пешерәсең. Буш торган чагында кешегә белгертмичә генә көмеш сары акчаларны тезеп елына бер мәртәбә, шуны дога укып әйләндерәсең. Пешергән чакта да, аның тирә ягында шыгыр урыннарына тезеп, түгәрәкләп, ул акчага тотынмыйсың син, елына бер мәртәбә, әйләндереп чыгып үзенең догасын укып, өй хуҗасына багышлыйсың. Һәрбер өйдә өй хуҗасы бар. Без хәзер газда пешерәбез. Ул казан куя торган котел тора. Буш торса да. Минем абыем мулла иде. Абый:

– Син аны озат, ди.

Мин аны озаттым. Хәзер миңа ул кагылмый. Озатмасаң елныңелына синең өстә тора, йә бер сырхау китерә, йә бер бәхетсезлек китерә. Әгәр дә ки искә алмасаң. Шул өй хуҗасына догалар укып, күчерәсең, кит миннән диясең, авырлык килсә. Вак акчалар тезәсең. Садакага бирәсең. Аның догалары бар. Китапта аерым дога белән.

*Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында*
*Гобәйдуллина Исламия Нурулла кызы (1947)*
*язып алынды*

Безнең үз әнием мунчада бер әйберне дә калдыртмады. Эчә торган суларыгыз беркайчан ачык калмасын. Беркайчан ризыкның өстенә япмыйча, әгүз итеп япмыйча, калдырырга ярамый. Шайтаннар тия.

* * *

Кайнямның апасына төннең берендә киләләр дә:

– Әби, (Бибисара әбиеңне) әби, берәү бәбәйләргә кели.

Без аңарга дәү апа дия идек.

– Әби, сине алырга килдек.

Дәү апа сизә, кем икәнен, яхшы хәл тегелне сизә.

– Хәзер, хәзер.

Тора, яхшы иттереп киенә, үзенчә укып чыга. Чыкса тырантас белә көтеп торалар мыны.

– Әби, берәү бәбәйли алмый, сине алырга килдек, диеп алып китәләр өчәү. Тырантас белә алып керәләр мунчага дәү апаны.

Ат буклары куйганар түен-түен. Дөрес, бери бәйбәйли алмый, ди, ләүкәдә ята, ди. Әбиең бәбәйләтә. Мәлгүн бит, шайтан.

Чиләк була шунда, мунчада. Ул чиләкләрне, дәү апа этә иде, кемнекендер алып киткәннәр мунчага, олан коендырырга, мәлгүннар. Хәзер әбиеңә күчтәнәчләр түенниләр. Ул күчтәнәчләрне әби ачып карама, дияләр. Анда күчтәнәчләрне тутырганнар: ат бугы. Дәү апа belә, карамый. Кайткач үзенчә укып, «Салават» әйтеп караса: ат быгы. Ничек итеп тутырып куйганнар. Шушындый хәлдә дә курыкмыйча дәү апа бара. Аннары китереп куялар ат белә аны. Суларын да кире китереп куялар. (Без шул суны эчәбез – оланнар коендырган суны. Шушы олан коендырган суны минем йорттан алып китте, пример, хәзер туган баланы коендырган. Шушы суны китереп куйган. Без бит аны белмибез. Мына шуны бит без эчәбез, белмәгәч. Бер ише бит адәм затыннан булыр, ди, ул мәлгүннең. «Аятелкүрси»не ешрак укыгыз.) Хәзер китерә әбиеңне, китерәләр дә, әбиең куркса да куркмаска тырыша. Тырантас белә алып китәләр, укып барган, укып кайткан. Кайткач та төн ката йокламадым, укыдым дия иде. (Төннең берендә мунчага алып китсеннәр әле сине.)

*Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында*
*Әюпова Зәйнәп Миңгали кызыннан (1935) язып алынды*

Ул бик бәхетле кешегә генә. Йә бәхетлегә, йә бәхетсезгә. Шул йорт анасын күрсә. Әлимә апай белән без эшләдек. Бер 3 ел гына үлгәненә. Кайсы үдә күргәнем белмим. Монда үз евендәме, туган әвендәмедер күргән. Ул әтә: «Киенгән шулай, – ди, – әби кебек. И шулай утырган, – ди. – Ачтым ишекне, ди, – терлек, куйлармы булган анда, нидер. Шуны ачтым, –ди, – ул утырган шулай. Бетте дә, – ди. Әби кебек киенгән. Ваты ничек әбиләр киенәләр бит. Запоннар белә. Бу да шул. Запон – фартук кебек инде. Билдән генә. Минем кебек ап-актан киенгән. Фартугы бар».

* * *

Вата мин кай көнне генә төшемдә күрдем. Шулай ак кигән бер ир кеше. Үземнең күзем йомган. Ну йокламыйм. Нәсәдер ул

миңа әтте, мин анарга әттем. Исемдә юк. Күземне ачтым – югалды. Шул булды микән йорт анасы.

*Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылында*
*Байбикова Халида Хайбулла кызыннан (1936) язып алынды.*

Наилә апай сүли иде: « Мин күрдем, ди. Әле, ди, бер кемнедер күмәләр и шул артыннан, ди, бер бабай, ди. Винек тотып селкеп бара. Шул винекнең яфраклары алтын кебек, ди. Үле артыннан бара. Винек ялтырый. Мужик фурмасында ди, моннан үлене илтәләр, ә ул барган артыннан».

**Аздякы**

Олан тоткан, чыктым. Магазин ниенә тике бардым. Аннан соң магазиннан киләм. Төшем түгел бу, көндез, олан тоткан киләм. И багана төбенә җиттем. Сәгатен только бакмадым. Әле навозлардан Камил әбзәйләрнең навозларыннан, күршебезнең навозыннан күтәрелде змийа. Кызыл ут бара, кызыл ут и курюгы озын и ярга төште. Олан ничә яшендә булган икән. Бер 2,5 яшь булган. Аннан соң мин кердем дә, канятама әтәм:

– Әти, эти, мин аздякы күрдем.

– Яхшылыкка булсын дип әйт, – ди. Шул. Болай куркмадым.

* * *

Иске үдән яңа үгә арба җигә булганнар. Озын арба җигә булганнар. Шуның белән аны күчерә булганнар, йоласы булган. Алаша җигәләр, зур арба, озын арба җигә булганнар. Шул йорт анасын соранып, утыртып. Яңы үгә күчерә булганнар. Күчкәнен беләләр шул күмәчләрне куеп. Җиткәч күмәчләрне азбарларга куялар. Икенче көнне торалар. Юк булса, югалган булса значит ашаган ул, анда. Күчкән дигән сүз.

* * *

Бездә вата теге елны бер ызба янды. Жарлар иде, мин әз генә форточканы ачам, шулай йоклый идек. Вата шулай тыңнап торам, җил тегел, елый кемдер эме. Мин аларны очраттым, алар Кулаткыга күчтеләр. Мин алардан сорыйм:

– Сезнең йорт анагыз бармы иде.

Ул әтә:

– Бар иде.

Мәтәм:

– Елап тора, нишләтәсез аны, күчерегез. И ишекләре капкалары вата ябылып тора. Әллә йөри инде ул.

*Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылында*
*Әхмәтҗанова Рәисә Шикур кызыннан (1947) язып алынды*

## Ышанулар, ырымнар, йолалар, гореф-гадәтләр

### Келәү

Яңгыр яумаса сорыйбыз инде Ходайдан. Тау битләренә чыгып, инешләргә төшә идек тә, сорый идек Ходайдан:

Яңгыр яу-яу-яу
Иләктән, чиләктән
Пәрәмәчә-коймактан.
Бир Алла, бир Алла
Биргәнеңне кире алма.

*Павловка районы Йәүли (Евлейка) авылында*
*Кәримова Ильмира Равил кызыннан (1966) язып алынды*

Арыштан, бодайдан
Без сорыйбыз Ходайдан
Бир Алла, бир Алла,
Биргәнеңне кире алма.
Картафларга төп бир,
Игеннәргә баш бир
Бир Алла, бир Алла,
Биргәнеңне кире алма, кире алма.

*Павловка районы Йәүли (Евлейка) авылында*
*Шабакаева Рауза Мәхмүт кызыннан (1939) язып алынды*

Яңгыр яумаса, ярмалар җыябыз, җәймәләр җәябез үзебез, катыклы салмалар пешерәбез. Башта укырга кирәк. Бабайлар укый. Инеш буйларында, кая безгә шифасы тия торган төшләр бар. Бабайлар булмаса, әбиләр башлый иде, намаз белән башлана иде. Аннан инде балаларны тау битләренә илтеп, зур казаннарда аш

пешерә иделәр. Салмасын пешерәбез, буткасын да пешерәләр, йә картуф изәбез инде. Шулай итеп, балалар, кечкенә балалар келәүне кычкыралар:

Яңгыр яу-яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә-коймактан,
Арыштан бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма, кире алма

Яңгыр яу, яу, яу
Арышларга баш бир,
Бодайларга баш бир,
Картыфларга төп бир,
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма, кире алма, –

диеп әтә идек.

Бакчаларда алмагач,
Бакчалардан ни файда
Алма биреп тормагач,
Яңгыр явып тормагач.
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма, кире алма.

Ашаталар, аннары коенышалар. Шының тәкле савытлар итә идек шында инде ярты половник салалар: шында картошкамы, боткамы. Ит-фәләннәр юк иде элекке. Йомырка сытып. Йомыркалар җыя идек, авыл буеннан. Кем нәсә бирә.

Әле дә теләк итәбез. Ике ел элек каршы якка, анда безнең полевой стан, анда аш пешерәләр. Шында менеп әбиләр-бабайлар инде, шында карт-корылар, шында кем менәлгәннәр – барысы да җыелды. Әттек, әттек, әттек. Оланнар инде бөтен көчләренә ерлап сорыйлар инде. Әле үгә килеп җитәлмәдек, чиләк читәннән яңгыр койды.

Атлашта да корбан чалганнар. Безгә сибәләр иде. Кулаткыда корбан чалганнар шулай. Корбанны чалалар вата яңгыр сорарга. Корбанны чалалар, укып чалалар. Әле генә корбан, элекке

юк иде. Корбан ашын зур казаннарда асалар, анда инде хәзрәткә дә бирәләр инде, мулла әбигә дә, барсына да бераз-бераз өлеш итәләр. Калганнарын весь пешерәләр бала-чагаларга, картларга. Әле бала-чагалар бик күп йөремәй дә инде. Картларны ашаталар инде. Корбанга каси төше колагы да кисмәгән булсын, тәкә булмасын, теше терлек (девочка) кирәк. Куйлар чалалар бездә.

* * *

Тау башына менеп кызыл йомырка да тәгәрәтәбез. Урыста Пасхасы бездә кызыл йомырка. Әниләр пешерә иде, красивый ясый иде. Без бара идек тау битенә, шыннан каты ата идек, тау битеннән инешкә тике каты төшә, сытылып бетә. Аны утырып ашый идек, югатырга ярамый.

*Павловка районы Йәүли (Евлейка) авылында*
*Шабакаева Рауза Мәхмүт кызыннан (1939),*
*Назырова Разия Ризван кызыннан (1942),*
*Кәримова Ильмира Равил кызыннан (1966) язып алынды*

Балаларның да сөрткәннәр күмерләр салып, җиде күмер салып суга, өстәл угылларына. Әгәр инде олан елый, чыдый алмый олан, еласа инде өшкерергә кирәк аны тиз генә. Тиз генә ишек бауларын, чыга торган ишекнекен, өстәл угылларын – дүрт угылны өшкереп-өшкереп юып су белән. Баланың бит-башын юып вись аяк очларына тәкле өшкереп оланны яткырырга кирәк. Олан тынычлана. Ул дөрес. Аның догасы, сүзләре бар:

Күздән килгән – күзгә кит.
Илдән килгән – илгә кит.
Судан килгән – суга кит.
Җилдән килгән – җилгә кит.
Кеше күзеннән килсәң – кеше күзеңә кит.
Яман кешеләрдән, яман күзләрдән
килсәң – яман кешенең үзенә кит.
Яман кешеләрдән,
Яман көчләрдән,
Яман күзләрдән,

Яман куллардан,
Яман сүзләрдән,
Үзең сакла, Раббым!

*Павловка районы Йәүли (Евлейка) авылында*
*Шабакаева Рауза Мәхмүт кызыннан (1939),*
*Назырова Разия Ризван кызыннан (1942) язып алынды*

Әбиебез безнеке карт иде, үрәтә иде, елый булса олан, күз тисә: 3 ягын йу да и бусага төбен сыдырып бәр. Шылай куша иделәр. Чын да олан туктый иде. Еламый иде. Бишекнең 4 түгел – 3 угылын гына евып нитәсең, бер угылы кала иде. Девалыклар (догалыклар. – *И.Я.*) куялар. Яздырып куясың мулла бабайдан, аласың, ул баш өстендә тора һәрвакыт.

Оланны йоклатырга кушмыйлар икенде укыгач. Ахшам белән икенде арасында. Анда инде китап сүзләре белән. Ярамый, мужет зарар тияргә, шайтан ниеннән дә шылай.

**Яңгыр яумаса**

Бездә адәт (гадәт. – *И.Я.*) – озак яумаса корбан чалалар. Барабыз урманга, урман читенә, анда чалып пешерәләр, анда халык, хатын-кыз да, ирләр дә. Намаз укып, Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сорап. Бер булмаса – икенчесе чала. Ике мәчет. Йә беренче мәчет, йә икенче мәчет.

Балалар тиха гына утырып торалар. Аннан соң салма ашыйлар. Аннан:

Яңгыр яу, яу, яу,
Иләктән, чиләктән
Пәрәмәчә-коймактан
Бир Алла, бир Алла,
Биргәнеңне кире алма, кире алма.
Бар ятимнәр, бар сабыйлар
Аларны ачка калдырма.

Коена идек бер-беребез белән. Сулар бәрешә идек, анда кизләү иде, безнең вакытта. Әле бик алай ук оланнар яшьләр йөрергә бакмый картлар.

* * *

Күршедә недавны гына биш яшенә етте, йөриәлми, сүлиәлми, и чыгарып шылай көтү килгәндә бәлиләр әмәндә и кыршау кисәләр. Нәстә уки булганнардыр.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Абубикярова Фәния Мирзаҗан кызыннан (1943) язып алынды*

**Келәү**

Кыр кәләве үткәрә идек. Келәү дия иделәр. Шунда бабайлар килеп анда кырда укыйлар, әбиләр йыйылып укыйлар. Корбан чала иделәр. (Качан калхуздан бирәләр сарык. Шул сарыкны чала иделәр.) Аш пешерә иделәр. Ашлар пешереп шында йыйылып бала-чага ашый иде, укыганнан соң.

Алар су юынып йөриләр коеданмы таба, бумаданмы таба, кая су бар, шыны өсләренә сибәләр.

Кырда укыган вакытта сорыйлар:

Яңгыр яу, яу, яу,
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан, –

дия идек.

**Күз тисә**

Балага күз тисә – ишектән өчәр мәртәбә тоткычларын евып, аннан соң касяклярын евып, тәрәз пыялаларын евып шуны балага кечкенә бармак белән манчып-манчып авызына тамызалар. Чәнти бармак белән. Аннан соң битен евалар баланыкын шул су белән.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Ибраһимова Рәисә Хәбибулла кызыннан (1938) язып алынды*

**Яңгыр теләге**

Яңгыр сорый идек. Әбиләр-бабайлар йыйыштыралар чирәмгә оланнарны. Анда аш пешерәбез, яңгыр сорыйбыз:

Яңгыр яу, яу, яу,
Иләктән, чиләктән,
Арыштан, бодайдан,
Пәрәмәчә-коймактан
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма, кире алма.
Бар ятимнәр, бар сабыйлар
Аларны ач калдырма.

Олан ваты елый, бик елый башлый, аны өшкертәләр. Бабайларга йөретәләр шундыйларны. Әбиләр бар инде өшкерә торган.

Бишек бавларын ева идек. Бишек угылларын, өстәл угылларын. Дүртесен дә. Ишек тоткачларын, аннан чыгарып бәрәләр инде кояш баегангача. Мине әбием бераз шулай өйрәткән.

Каян килдең шунда кит, – дип шул суны бәрәләр инде.

Йә йелдән килсәң – йелгә кит.

Җирдән килсәң – җиргә кит.

Күктән килсәң – күккә кит – шылай әйтә иделәр әбиләр.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Сейфуллина Разия Измаил кызыннан (1941) язып алынды*

Бусагага ярамый утырырга, бусага аша бер-береңә акча, кием зат бирергә ярамый. Гөнаһ ахрысы. Бусаганы күчеп бир яисә үгә кереп бир. Тәрәз аша бирмә. Кул китәмедер инде. Йорт себерергә ярамый кояш баегач, чүпне чыгарырга ярамый. Шулай колакка салынып кала картлардан. Эшеңне бетер кояш иңгәнче. Акча бурычка бирмә – кояш иңгәч. Бирәсең, син бәр идәнгә, ул алсын. Кеше килә, кризис, ничек бирмисең? Өстәлгә ярамый утырырга, тәртипле генә өстәл янына.

## Зәм-зәм суы алу

Шабан аеның уртасы була – унбише. Кизләү бар бездә, очта. Уникедән соң барып шуннан су алабыз. Төнне, 12 дән соң. Анда төшә укыганнар. Мулла бабай төшә. Азан этә элгәре. Азан эткәннән соң инде халык шунда кайсы чиләк белән, кайсы машинада, кемнеке бар, кайсы атта төшеп зәм-зәм сывы алалар. Шул су инде бик зур фәйдәле. Мунча да евыналар күп алган кешеләр. Укыганнар намазга тота.

**Баланың тышавын кисү**

Тышавын кисәләр йөри алмаганнарныкын.

Мунчала бәлиләр ике аягына. Элгәре выта шуннан көтү киләиде. Сыер көтүе. Аның артыннан инде куйлар менә иде.

Моннан куйлар менә башлагач, оланны ебәрәсең, бу яктан теге якка олан бaралмый, йөри алмый. И вот куйлар төшкәч, качы белән аяк бәләгәнне кисәләр иде. Чыннан да йөреп китә. Йоласы булган ахыры.

– Оланың йөри алмый, кистер көтү төшкәндә, обязательно кистер, – бездән дә картлар шулай әтәләр.

Ишетеп калганнарыбыз бар. Әбиләр шулай эшли иде.

* * *

Килен төшкәч, егет белән кыз мунчага кергәч, алар калдыра виник астына акча, табак астына акча куя. Мунча ягучыга. Мунчасын яккан, уздырган, идәннәрен юган ялт итеп, винигын парлаган. И болар инде евынып чыга егет белән кыз да инде. Бу инде көтеп тора. Ә шунда кайсы да булса: күрше малаемы, үдәге малаемы кереп сыптыра. Кызык.

* * *

Көтү чыгарганда азан әтәләр. Халык төшерә көтүчеләргә төрлесен: төрле аш-су. Кайсы пирог, кайсы бәлеш, кайсы йомырка – кемнең күңелендә нәстә бар – көтүчегә. Бер өч-дүрт көн шулай төшерәләр. Кочыгы янында булса, кочыгына бирәләр. Аляавылларда көтүче юк. Элгәре 3 сум да 5 сум, 10 сум иде. Әле 2 нче ел үзбәкистанныкы көтү көтә. Сигез йөз сыер башы. Быел әттеләр меңне сораган диеп. Мең сум аена бир – ул көтү көтә.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Насыйрова Нәзифә Әхәт кызыннан (1946) язып алынды*

**Бала юындыру**

Оныкамны яткырдым һәйбәт, ап-ак иске өстенә яткырдым да шунда тотындым ерларга:

Анаңны – ана диеп бел.

Атаңны – ата диеп бел, – чабалар әл дә. Венигың кулыңда, һәйбәт сабынныйсың.

Апаны – апа диеп бел.
Абзины – абзиең диеп бел.
Әтиең кискән утын төгел.
Әниең яккан мунча төгел.
Әниләргә – әни әт.
Әтиләргә – әти әт.
Әбкаңны күргәч акырма.
Бабаңны күргәч бакырма.
Абзиларга – абзи әт.
Апаларга – апа әт.

Шулай тәүфиклы гына бала булып үс! Баламның баласы, йөрәгемнең парәсе!

* * *

Олан выт елый-елый. Шул гына килеп китте, ди. Олан тотынды еларга, ди. Даваегыз, давай. Ала иде һәйбәт кайнаган суны. Чокырга бармагын мана да, ишек тоткычларын, бишек бауларын, оланның авызын, бит-башын сыдырып ала. Каан килдең – шунда кит, диеп кояш баеган төшкә бәрәләр иде шул суны. Шул олан йомшара иде. И йокыга китә иде.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Сейфуллина Разия Измаил кызыннан (1941) язып алынды*

Әни-әти Коръәнне башка куеп чыгардылар үдән, армияга киткәндә. Артың белән чиктык ишектән, әпәй каптырдылар, калганын каядыр тыгып куйдылар. Сау-сәламәт барып служить итәргә, сау-сәламәт кире кайтырга, дип.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Бикбаев Якуб Хәсән улыннан (1933) язып алынды*

## Раштуа

Безнең электән ук калган шундый традиция, әби-бабайларыбыздан, бабаларыбызның бабайларыннан инде.

Чана менгерә булганнар, ат чанасы. Таба булганнар бер хозяинны, чана белән инде, баралар, ул кешенең ишекләрен ябалар, чтоб ул чыкмсын хозяин, тотмасын, кумасын. Алар шул чананы орлап алалар, авыл буенда йөретәләр-йөретәләр һәм менгерәләр

аны крышага һәм куялар крышага клубныкына. Төннә, уникедән соң. Җиденче гыйнвардан сигезенә. Безнең ряженыйлар чыгалар. Яшьләр чыга, кем нинди костюм таба һәм киенә. Без аны Раштва дибез. Менгерәләр, иртә беләнме анда, бер ике көннәнме ул чананы төшереп алып китәләр.

Киенгәннәр (ряженыйлар) йөриләр, крышада йөриләр алар. Ул зур чана, аны бит әле менгерергә кирәк. Алар маскалар кияләр, чтоб битне күрмәсен, хозяин танымасын кем ул эшне эшләгән. Анда йөзгә якын кеше катнаша. В основном хатыннар юк, ирләр. Әгәр дә мужик булып киенеп чыкса гына. Алар безне дә клубта ябып куялар. Без чыкмасын, күрмәсен өчен. Без эштә. Аларга ул комаучау итми, чөнки бу – традиция.

Үдән үгә дә йөриләр. Алар әллә нишлиләр. Әгәр дә аларның юлына эләктең, кыш бит инде, алар карга да бутап алалар үзеңне. Бакмыйлар: баламы, бала түгелме. Нәкъ бу көнне. Иенче көнне аларга әйтсәң, алар как будто ничего этого не было. Ул безнең сакланып калган традиция.

Гадать итәләр, вальник ыргыталар кияүдә булмаган кызлар.

Балдак юк бездә, тик кәгазь яндыралар инде. Нинди фигура чыга – синең ирең шундый эштә эшләр.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Сәйфуллина Гөлнара Шамил кызыннан (1986) язып алынды*

Олан егылса:

Әф-төф күберәк
Моңардан да бигерәк
Иске сука тәртәсе
Чуаш хатын чәркәсе
Тьфу-тьфу-тьфу…

**Күз тиюдән**

«Фатыйха» сүрәсе укыла башта.

100 мең атлы бер хан,
1000 атлы ясин сан,
Күңелең төште бир дарман

Синнән теләмим ярдәм.
Йа рахмани, йә рәхими,
Ай катя, көн катя,
Син дә кайт.
Урының түгел – урнашма,
Җиреңтүгел – җирләнмә,
Илдән килдең – илгә кит,
Җилдән килдең – җилгә кит.
Имең-томың шул булсын
Тагын-тагын иңкетмә
Йа рахман, йа рахман,
Әлхәмделилләһи раббил галәмин.

Күздән бу.

* * *

Кургашин. Аны эретәләр. Матка төбендә, идән уртасында бала тора. Өстән коялар эрегән кургашинны шул суга – нинди форманы ала – шунардан курккан була. Койганда әтәләр:

– Ни коям?

– Куркыт коям.

И чыга – чебешме, кемме чыга. 3 тапкыр эшләргә кирәк. Аның шифасы бар. Аннан аны буена (муенына – И.Я.) еп белә тагалар, йөрми торган бала булса ястык астына куялар. Бераз саклана, аннан ташлана.

* * *

Көтү килә, баланы чыгаралар ике аягыннан бәләп и тышавын кисәләр дип әтәләр. Ул епне кисәләр и йөреп китә, җиңелрәк йөреп китә.

Бисмилла, «Әлхәм» укыйм да, сау гына йөре, бәла-каза күрмә, исән-сау үс дип дога кылам, кисәм.

* * *

Ишек бауларын, өстәлләрне, бусагаларны барысын да вич су белән йыштырасың да маңгаена, авызына, күзенә, битенә, корсагына, кендекләрен уңга-суңга әйләндерәсең. Бусага аша ыргытасың. Ул үдән чыгып китсен.

Оланны йывындыра да шул су белән, өч юл чатына бәрәләр.

* * *

Авылыбызда бар иде бер бик яхшы бабай. Доктор Айболит дип әйтә иделәр. Балалар лечить итә иде, экземадан да. Врачлар лечить итмәгәнне итә ие. Кара дегет, күмер белән укий да име-томы шул була иде. Ульяновскидан врачлар нелечимый балаларны Сайманга ебәрә иделәр. Пычак белән дә чирталый. Акча алмый иде бабай.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952)*
*язып алынды*

**«Зәм-зәм» суы**

Безнең авылда Бәраат кичәсендә мөселманнар җыелабыз. Безнең чишмәләребез бар. Авылыбызда 4–5 чишмә. Шунда халык төшә төнне 12 сәгатьтән соң. Хәзрәтләребез дә төшә, намазлар укибыз. Бу үзебезнең авылыбызга тынычлык, бәракәт сорап. Шул вакытта җыелышып барыбыз да әйтәбез «Зәм-зәм»ебезне:

1)Даһи зәм-зәм бер кое,
Күмелмәс аның сыву
Җәннәттән килгән юлы,
Эчтек әлхәмдулилла.

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр
Лә иләһе иллә Аллаһы.
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр
Вәлилләһил хәмде.

2) Алдым комган кулыма,
Киттем Аллаһ юлына.
Коранемнең яктылыгы
Караңгы каберема.

Аллаһу әкбәр,Аллаһу әкбәр
Лә иләһе иллә Аллаһы.
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр
Вәлилләһил хәмде.

3) Бардым Мәккә шәһренә,
Анда кундым бер кичә.
Бер кичәсе мең кичә,
Эчтек әлхәмдулилла.

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр
Лә иләһе иллә Аллаһы.
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр
Вәлилләһил хәмде.

4) Алдым таяк кулыма,
Киттем Алла юлына.
Аллаһ безгә юл бирсен,
Калебларга нур итсен.

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр
Лә иләһе иллә Аллаһы.
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр
Вәлилләһил хәмде.

5) Зәмзәмнәргә барырбыз,
Барып суын эчәрбез
Аллаһ Тәгалә насыйп итсен,
Сиратын да кичәрбез.

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр
Лә иләһе иллә Аллаһы.
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр
Вәлилләһил хәмде.

Зәм-зәм сувы алабыз. Шул вакытта барыбыз да бик дус булабыз. Сәдакалар бирешәбез. Алганда әйтәбез эчәбез дип, кайтканда ерлыйбыз эчтек дип. Без Зәм-зәмгә үдән чыгабыз җыелышып. Әби-бабайдан килгән инде ул. Мәңгедән мәңге.

Мунчаларыбызны ягып, тәһарәтләнеп, чиста саф күңелләребез белән, авылыбыз белән яшебез-картыбыз тау башына менәбез. Читтәге балаларыбыз да килә. Сихәтле су алабыз. Авыруларга шифа бирә. Шул су бер ел тора, бернәрсә дә булмый: яшәрми дә, күгәрми дә, бернинди ис тә чыкмый, ничек алдык шулай тора.

Авыргач та эчәбез. Балалар хәлсезләнсә, хаста кешегә дә эчерәбез. Үлем ястыгына яткан кешенең дә авызына салабыз шул зәм-зәм суны, терелеп китә.

Шунда сорыйбыз Ходай Тәаләдән үзебезгә саулык, балаларыбызга.

Кайтабыз да, йортыбызга чыгып, йорт аналары, йорт бакалары – барысына да дога кылабыз. Йорт аналары, йорт бакалары, йорт еланнары – барысына да тынычлык.

Шул су белән чәй куеп эчәбез.

* * *

Йә, Раббым, үзеңнең барлыгыңны – берлегеңне өмет итеп бөгенгесе көнне шушы йортларда мәҗлесләр уздрылды. Алла Тәгаләнең ризалыгы өчен булсын. Шушы йортларда йорт анакай, йорт атакай, йорт пәриләре, йорт еланнары, йорт бакалары барчасы да риза булып киткән булсыннар. Шушы укуларыбыз аларның барчасына җитсен, йа Раббым, диеп дога кылабыз без.

### Таң суы

Тан сывы. Ул бездә бар. Шифа китерә. Без аны берәмләп кенә эшлибез, җинаулашып түгел, кемгә кирәк. Иртә торасың, тан сывын аласың, коедан шул суга укып өшкерәсең. Шифалу су үзеңә. Балаларны эчертәсең. Саулык сорыйсың. Ниятләп аласың.

### Бәбәй мунчасы

Шушы сүзләрне әтеп баланы мунчада чабалар:

Әниең яккан мунча тегел,
Әтиең китергән винек тегел,
Тәгәри йөз, каталы йөз.
Зурларга әби әт, картларга бабай әт,
Олыларны – олы диеп бел,
Кечеләрне – кече диеп бел,
Әниеңне – әни диеп бел,
Әтиеңне – әти диеп бел,
Әбиеңне – әби диеп бел,
У-лю-лю-лю-лю-лю.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952),*
*Шафеева Сафия Хәмит казыннан (1948),*
*Юнушева Тәнзилә Якуп кызыннан (1949),*
*Саюкова Накия Яхия кызыннан (1956),*
*Долгова Фатыма Исмаил кызыннан (1948)*
*язып алынды*

* * *

Безнең авылны әтәләр нәзерле диеп. Безнең авылда һәр елны корбан чалалар. Кайчандыр алар әткән булганнар яңгыр сорап, һәр ел корбан чалырбыз диеп бәла казадан да. Авыл нәзерне үтәп бара. Һәр ел сарык, сарык булмаса, тавык чалабыз. Бар иде колхозлар. Колхоз элекке бирә иде тана. Ул уже тиешле кебек иде, кагыйдәгә кергән иде. Халыктан җыелса сарыклар да алалар иде. Һәр ел шул сазда, чишмә янында корбан уздыра иделәр, җәен, июнь айларында.

Яңгыр сорап та, уңышлык, дөньяларга тынычлык. Яшь түктермәсен, кан түктәрмәсен, бәла-каза килмәсен, – дип картлардан калган йолабыз.

Без, балалар, төшә идек кашыкларыбыз белән:

Яңгыр яу, яу, яу,
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә-комактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Елгаларың тулы су булсын!
Игеннәрең мул булсын!
Терлеккә ашарга иген булсын!
Безгә ашарга сөт булсын!

Кашыкны кагып сорыйбыз. Бабайлар, әбиләр укый-сорый, ә балалар шушы сүзләрне әйтә, такмакларны. Аннан су коеныша идек, ашаганнан соң. Су коенып йөри идек. Бучкаларда, кайда сулар бар. Кем уза – шуңарга сибәбез: машинага да, кешегә дә. Гореф-гадәтләребез бара картлардан калган, белгән кадәр.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952),*
*Долгова Фатыма Исмаил кызыннан (1948)*
*язып алынды*

## Яшь килен мунчасы

«Яшь килен мунчасы» бездә. Яшьләр кала үзләре генә. Өч көн үзләре генә куналар. Иртән килеп кайнанасы мунчаны яга или каен сеңлесе мунчаны яга, кайнана булмаса. Мунчаны уздыра. Аннан яшь кияү белән килен иң беренче керәләр мунчага. Алар мунчадан чыккач, өстәл белән каршы алалар үдә. Аннан туганнары килә, күршеләре керә тәбрикләргә. «Яшь килен»мунчасын якканга бүләк бирәләр. Яшь килен калдыра йөслек (сөлге. – *И.Я.*), күлмәклек.

Сорап алганда күбесе кышын үләнә инде. Алар 15 пар алаша җигеп, колокол тагалар атка, урам әләнәләр.

* * *

Яңгыр яумаса – корбан суялар. Безнең авылыбыз, сугышып алынган кебек, корбан белән алынган. Сугышып алганнар җирне. Сугышып алганга күрә, һәр ел алар әйткәннәр корбан чалырбыз дип. Чәчү бетә дә корбан чалалар. Вот әле сабантуй чыгардылар. Хәзер дә корбан суялар. Йөриләр авылдан, кем күпме бирә. Анарга терлек алалар. Корбан елгасы бар безнеке. Һәр ел шунда корбан чалалар. Весь кем тели, шул барып ашасын. Су сибешәләр.

Безнең авылда урамнан да җыялар оланнар:

Яңгыр яу, яу, яу,
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә-коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, яңгырыңны!
Бир, Алла, яңгырыңны!
Бир, Алла, яңгырыңны!
Корбан ашы чыгарыгыз!

И, чыгарып өләшәсең кемнеке ние бар. Тоз, йомырка булсын.

Көтә сине агалар,
Сорый сине бабалар,
Сине күргәч шатланышып
Йөгереште балалар.
Яу, яу, яңгыр яу,
Йөгереште балалар.

Бакчадагы алмагач
Корый яңгыр яумагач,
Бакчалардан ни файда бар
Алма пешеп тормагач?
Яу, яу, яңгыр яу,
Алма пешеп тормагач.

Алтын тамчы, көмеш тамчы
Син Алладан көтәбез,
Син булмагач ачлык, диеп,
Илебездән китәбез.

Элек шулай җырлыйлар иде.

Мин үзем үле өстенә йөрим. Анда мөнәҗәтләр, бәетләр әтә идек:

Ятырбыз бер көн туфрак астына,
Гурда куярлар безнең баш очына
Әҗәлең җитәр, тәннәрең бетәр,
Ясин укырга вакытлар җитәр.
Укый алмамын, бетәр сулышым,
Булмас артымнан дева кылучым.

**Күз тиюдән**

Су ала, бишек бауларын юа, битен юа. Әмән битләрен юалар. Ишекне ачалар да, ишекнең артына салалар, ишек тупсасы аша бәрәләр инде:

Ай кайта, көн кайта, син дә кайт.
Ай кайта, көн кайта, син дә кайт.
Каан килдең шунда кит.
Ш-ш-ш (өрә. – *И.Я.*)

Я суга өшкереп бирәсең.

«Әлхәм», «Кылху», «Фәләк», «Нәс» – әле чыкты.

«Зәм-зәм» суына «Ясин» укып өшкерәм.

**Куркык кою**

Куркык коя дип әйтәләр, мин үзем белмим. Бер хатын бар монда, куркык коя. Матка астына утыртты да оланны, әнисе итәгенә. Ала су табакка, салкын су. Кургашин кирәк. Ул кургашинны кашыкка сала, йылыта аны, йылыта да шул салкын суга салып ебәрә. Ул салкын су эчендә ни күренә, нинди шәүлә төшкән. Ат шәүләсе булса – алашадан курккан, кеше шәүләсе булса – кеше күзеннән.

**Бала йөри алмаса**

Йөри алмаган балаларга бәйләгәннәр аякны, көтү килгән вакытта көтү алдына чыгарганнар. Юкәне беләсеңме? Шуның белә бәйлиләр аякны, тышаулыйлар и көтү килгәндә шуны тишәләр, кисәләр.

### Кәзә кирелчәге

Кирәлчәк булса, бусагага оланны куя, тотып тора, теге яктан бу якка күтәреп алалар. Кәзәне кечерәкне алалар, күбрәге кәзә тәкәсен.

Кирелчәк ул ыһхһ итсә, кирелтә – кәзә кебек ыңгыраша.

Ул йокларга бирми, кирелтә. Бусагага яткызалар оланны. Бер якта ире бер якта хатыны:

Ай кайта, көн кайта, син дә кайт.

Каан килдең шунда кит, – дип кәзәне бирә. Өч тапкыр әйләндерәләр дә баланы алалар.

*Николаевка районы Әхмәтле авылында*
*Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935) язып алынды*

### «Кочук йоны»

**«Кочук йоны»** балада дип әйтәләр, аркасында. Мунчага ягалар, анда онны суга язалар, белен ясыйлар, камырны ясыйлар. Мунчага парын сала, баланы яткыза итәгенә, марля йәйә аннан соң шул катыкны сылый өстенә, марляны яба. Парын сала да и бинек белән, каен бинеге белән:

Ай катя, көн катя, син дә кайт.
Ай катя, көн катя, син дә кайт.
Ай катя, көн катя, син дә кайт, –

дип чаба-чаба да, ул марляны кайтырып ала, кап-кара йон була анда, ул аны чәнчә.

### Раштуада

Яшь вакытта без уйнап йөри идек. Раштва булсын. Агачлар тетә идек, бусын тетә идек, «шык-шык»лар куя идек, без малайларча киенеп малайлар белән бергә чыгабыз, шык-шык куябыз да хозяйка чыга:

– Әй, хулиганнар, тагы безне сез юри итәсез.

Чананы да куйдык, утыннарны да теттек, бүрәнәләрне дә теттек.

Раштва каршына кабактан чыгалар да и бәрәләр итекне. Кая таба борыны – шул якка кияүгә чыгам, или шул яктан үләнәм.

Куй тоткач ядаурак булса – ядау киявең булыр, тазарак булса – киявең тазарак булыр, йоннырак булса – бай булыр.

*Николаевка районы Әхмәтле авылында*
*Мустеева Розалия Кәбир кызыннан (1957) язып алынды*

**Яңгыр сорау**

Яңгыр яумаса балалар белән, әбиләр белән чыгабыз урамга, урам буенча яңгыр сорап йөрибез. Аннан җыелып бергәләп пешерәбез. Өченче көн күршебез куй чалып бирде, без аны пешердек. Бабайлар үзләре чыгалар корбанга. Анда да эшмәкәрләр бирә. Алалар тана, и чалалар аны кырда и кырда пешерәләр. Вис авыл халкы анда җыела, утырып бабайлар дыва (дога) кылалар.

Үләдән соң чыгалар бабайлар кырга и анда сорыйлар яңгыр. Бабайлар намаз укый.

Балалар ерлап йөрибез инде, сорыйбыз инде:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә-коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, яңгырың!
Бир, Алла, яңгырың!

Бакчаларда алмагач
Корый яңгыр яумагач,
Бакчалардан ни файда
Алма пешеп тормагач.
Яңгыр явып тормагач.
Бир, Алла, яңгырың!
Бир, Алла, яңгырың!

Аннан җыеп йөргән продуктыдан пешерәбез аш, су сибешәбез.

* * *

Яшьләр танышалар. Аннан ебәрәләр баш кода. Сүләшәләр. Сүз бетерәләр. Сүз бетергәндә бүләкләр бирешәләр. Егет кеше китерә зур бүләкләр. Моннан инде эскәтер, йөслек бирәләр. Егет акча бирә. Алышынмасын диеп. Аннан сүлиләр инде качан никах булырга. Хәзер инде бездә күбесе никахта гына. Кичке туйлар булмый, аракы туйлары, хәмер туйлары булмый. Шунда инде яшьләр дә була, картлар җыелалар. Никях зурлап үтә. Кафеда үткәрәләр әле. 300 дән 400 хәтле кеше җыела никяхка. Яшьләр барып язылып киләләр, кызлар-егетләр шунда. Әбиләр-бабайлар да утыра, яшьләр дә утыралар бергә.

* * *

Бар иде мунча. Иртә иртүк, яшьләр йоклаганчы күршеме, кардәшеме мунча яга. Аннан яшьләрне мунчага ебәрәләр. Шунда инде кияү комган астына акча куеп калдыра. Да, бездә шулай иде.

* * *

Сыйлыйлар: эләкчә, бутка, тавык боты.

Кияүне беренче тапкыр тавык пешереп көтәләр. Основной пилмән, пәрәмәчә – кияү пәрәмәчәсе.

Яшь киленнәрне китерәләр иде никяхтан соң кияү эвенә. Китерәләр алашалар белән. Анда ястыклар куйган, артта яшь киленнең сондыгы.

Кыш булса кияүнең өс киемен урлыйлар иде – йолаталар – түләтәләр акча.

* * *

Бал дигәне бар иде. Бал ашаталар. Анда инде яшь кызлар гына. Кияү егет никяхта бал бирә кызга, чәй куялар, шәкәр куялар. Кызлар чәй эчә. Кияү егетнең кызларны сыйлау йоласы. Савытлар белән бал чыгаралар иде.

Егетләрне кичке туйга чакыралар. Җырлар җырлыйлар:

Сезнең алмагачыгыз,
Безнең сандугачыбыз,
Сезнең алмагачыгызга
Кунды сандугачыбыз.

* * *

Син дә булдың кодагый
Мин дә булдым кодагый,
Кодагыйлар арасында
Андый эшләр булгалый.

Балага күз тисә өстәлнең читләреннән, ишек читләреннән чайкиляр да шуның белән баланы юындыра булганнар и тышка чыгарып бәрә булганнар.

* * *

Мин кечерәк вакытта ничәдер айлык булганмын. Әнием сүли иде. Гел елак син, дип әнием әтә иде, күздән калдың син, ди.

Күршедә мунчага керткән, аларның балалары булмаган. Ул апа мине севеп-севеп юындырган. Әле әнием әтә китереп бишеккә ятгыздым, ди, үлдең, ди, дышать та итмисең ди, мамык кебек булдың, ди. Шунда выт Хәлимәнең карт әбисе дә мунчада булган. Әнием әтә бу күрше хатыны евындыра сине, ди, шул әби, ди, мине чеметеп алды, ди. Әтә, ди, күзектердең балаңны, үтердең балаңны. Әни, ди, китереп яткыздым, ди, син, ди, үлдең, ди. Чаба-чаба бардым, ди, шул күрше хатынга әтәм, ди, баламны күзектердең. Алла, ди, чабуымны хәзер яхшы күлмәк кигән, ди, күлмәгенең чабуын кисеп бирде, ди.

Борынгы йоллар бу.

* * *

Су алганнар, авызын чайкый шуның белән, битләрне юдыра. Ишек сабын, өстәлнең дүрт угылын евып, шул суны чайкаттырасең, аннары чыгарып бәрәсең.

Җирдән килсәң – җиргә кит,
Судан килсәң – суга кит,
Аллаһу, Аллаһу…

* * *

**Мунчада чабу**

Әбиең яккан мунча түгел,
Әтиең кискән утын түгел,
Давай веник, давай таз,
Париться будем сейчас.
Чаж-чож, чаж-чож.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951) язып алынды*

Атаң кискән утын түгел,
Анаң яккан мунча түгел,
Каталый үс, тәгәри үс
Чабам сине елама.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Сулейманова Нажҗия Мөталлиб кызыннан (1955) язып алынды*

## Кыршаулык кисү

Көтү килгәндә кыршаулыгын кисә булганнар. Кич белән көтү килгәндә, баланы чыгаралар и еп белән аягын бәлиләр, и көтү килгәндә качы белән кисәләр. Икенче көнне китә тәпи-тәпи, китмәсә 3 тапкыр итәләр, бала йөремәсә.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951) язып алынды*

Икылдаган балага чыпчык бумасы диләр. Тазга куялар иде. Таз астына җим салалар, чыпчык тоталар, шуны инде бугазлыйлар шул баланың исемен әтеп, инде чыпчык бумасын нитәбез дип, чыпчыкны чалалар.

* * *

Ныжывы дип әтәләр. Ул бала кочак җыелган, аякларын ебәрми. Әле яккан пич инде була, пич инде вис бетә. Әпәй сала торган такталар була. Шул күрәккә утыртасың да баланы тыгабыз:

– Ныжы кывасың. Кемнең ниен кыласың?

– Үмәрнең ныжысын кывамын.

Шулай өч тапкыр тыгып аласың.

## «Тәкә кирелчәге»

Гел кирелә, ашый да кирелә, йоклаганда да кирелә. Ул тәкә кирелчәге дип әтәләр. Аны инде чын кәзә тәкәсе китерәсең и шыны баланы тотасың да бала аша шул тәкәне сикертәсең. Әле инде тәкәләр юк – пуховый шәл белән итәләр.

Баланы тупсага саласың. Икәү утырасың. Өч тапкыр чыгарырга. Исемен әтәсең – кемнең кирелчәген кирелтәсең.

Берсе бер яктан әтеп:

– Миләүшәнең тәкә кирелчәген кирелтәм, бирә.

Икенчесе ала да шуны ук әйтеп кире бирә. Шул йоланы үткәргәч бала кирелми.

Әтәсең шулай да:

– Ай кайтя, көн кайта, син дә кайт.

Йа Рабби, шул оланның кирелчәге бетсен.

## Куркык коюю

Куркык коялар. Ват әле матка ниләре юк. Матка (матча) кемнеке бар – матка турысына баланы утыртасың. Кургашинны аласың. Кургашинны (олово) эретәсең. Савыт тотасың, башта иләк тотасың, аның өстенә табак тотасың и шуны китереп саласың. Бере кычкыра:

– Кемнең куркыгын коясың?

– Шул баланың куркыгын коям.

Аннан чыгарып аны аласың. Анда инде куркыкның рәсем чыга. Аны уң кулың белән тотасың да суң якка бәрәсең – ташлыйсың (ул кул башы аша. – *И.Я.*). Кешедән куркса – кеше, эттән куркса – эт рәсеме чыга.

## Баланың авызына ак төшсә

Әле инде ак төшкәч, шундый әбиләребез бар, мин аны эшли белмим, мәченең күрюгын евасың, тере мәченекен, и аны катыкка тыгасың, и шуны авызына баланыкына сөртәсең әйләндереп. Хет кайсы якка әйләндер. Бернинди дару бетерми, шул бетерә. Анда мәче нинди дә ярый. Анда аның дывасы бар, укилар әбиләр и этәсең кемнеке төшкән шул акны ала көне белән.

## Кочук йоны

Кочук йоны чыга баланың аркасына. Спакойный түгел, йоклый алмый, гел движениеда и багасың, анда кара-кара йоннар чыккан. Аны инде кулларың белән ржаной мукадан ясыйсың камыр. Марле йәйәсең баланың аркасына и куясың моны да и шуның белән чабасың. Шул камырга – тестыга ябышып чыга. Шуларны бегенге көнгә әле дә эшлибез.

## Раштвада

Коелар ясаганнар, буралар спичкалардан. Кызлар инде кем инде шунда коедан су ала шул кияүгә чыга инде.

Бура ясый спичкадан. Аны баш астына куя, ул тетелмәскә куя инде. Шуннан кем коедан су ала – төшендә күрсә инде, шунарга бара.

Йөзек куя булганнар. Йөзекне бeләп куйа да инде. Бер йөзекне еп белән төшерә.

Бураны шулай бурыйсың, шунда еп белән шулай куясың. Еп бәләнгән була, асылынып тора йөзек. Шул йөзекне коедан кем күтәрә төшеңдә и шуңа кияүгә чыгасың. Раштва вакытында эшләнә, элгәре эшлиләр инде, гадать итә идек, әле юк инде.

Чыгып элгәре куйлар тота булганнар. Әмән кызлар чыга да, җыелышабыз да караңгыда, күренмәсен, и чыгып кочаклый идек: яшь куймы очрый, кара куймы? Картмы? Яшь куй – яшь егеткә чыгасың, карт куй – карт егеткә. Блондинмы, брюнетмы.

Капка аша калушлар бәрә идек. Калушлар кайа карый, шул якка кияүгә чыгасың.

Тәрәзә шакып йөри идек, кандала ашый. Кандала, кандала, – тәрәзәгә чиертеп.

Спичка белән еп куя идек. Забурга бәйлисең епне и тартасың. Тәрәзәгә суга: шык-шык. Крыльцога чыга иделәр:

– Хәзер ашатам мин сине, кандала.

**Кызыл йомырка көнне**

Шунда ваты кое бар безнең урамда. Шунда бик зур тал үсә иде. Карт тал иде. Шул талга кызыл йомырка көнне вис – тазлар, кәзәләр, туалитларга хәтле китереп куялар иде шунда. Бер карт учителебыз бар иде. Аларның кәзәсе бар иде. Шул кәзәне дә китереп бәләгәннәр шунда. Аның туалитын да китереп куйганнар шул тал төбенә. Егетләр – яшьләр. Уен. Кызыл йомырка кичәсендә абизательно сак бул. Әле инде алар юк. Безнең үскән вакытта егетләр шундый иде. Әле инде бармыйлар. Без үзебез дә, кызлар да, йөри идек. Аннан гур белән язып куясың – кемнеке бу. Селсавит каршында тага иделәр. На обший показ куялар иде. Чыга идек багарга. Мунчалардан кемнеке бельелары кала, оят бит инде, икенче вакытта калдырмыйсың. Мунчадан вич җыештырып ала идек, берни калдырмый идек, исемнәрен язалар. Әле инде юк. Бер 10 еллар ул эш бетте.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951),*
*Сулейманова Нажия Мөталлиб кызыннан (1955) язып алынды*

Уеннар уйни идек вечерларда. Казлар йолка идек. Без борынгы ниләр әл дә. Әле бит алар югальде.

Көймә килә түгәрәк,
Әллә ниләр сөйләр идем,
Сез янымда күбәләк.
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Эзе юк.
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Сөйләшергә генә генә
Үзе юк.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Сулейманова Асия Ризван кызыннан (1954),*
*Рахманкулова Рәшидә Ирфан кызыннан (1955)*
*язып алынды*

Яңгыр яумаса укыйбыз догалар, сорыйбыз, корбан чалалар электән.

Балалар белән йөрибез:
Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә-коймактан
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, яңгырын!
Бир, Алла, яңгырын!
Арышларның башлары
Ач булмасын, тук булсын!
Сыерларның сөтләре
Әз булмасын, күп булсын, күп булсын!
Бакчаларда алмагач,
Агачлардан ни файда,
Алма биреп тормагач.

## Тәкә кирелчәге

Бала кәҗә кебек тавыш чыгарса – тәкелдәсә, ике кеше аны кәҗәнең астыннан чыгара.

Берсе:

– Нәрсәнең кирелчәген чыгарасың?

Икенчесе:

– Тәкә кирелчәге чыгарам.

Өч тапкыр әйтәсең.

Аннан тагы икенче, өченче көнне. Өч көн эшлисең.

* * *

Аннан олан йөри алмаса озак, әмән көтү килгәндә чыгарсың көтүгә дә, тышаулыйсың оланны. Кисәсең дә аннан йөрергә китә. Әле дә эшлибез.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Сулейманова Асия Ризван кызыннан (1954),*
*Рахманкулова Рәшидә Ирфан кызыннан (1955) язып алынды*

## Аякны тотып алса

Аякны тотып ала. Сүрәләр укыйлар: «Кылху», «Фәләк», «Әлиф-ләм», «Нәс»). Аннан:

– Шул баладан өмет иткән булсаң – риза бул, ебәр. Бөтен өмет итмә диеп дога кыласың.

## Күз тиюдән

Укыйсың шул ук догаларны, аннан өшкерәсең бу бәндәне:

– Кемнең күзе төшкән үзенеке үзенә, үз күзе – үзенә, ди.

## Мәстүрә әби кулы

Минем аякны сылаучы әби – аның кулы шифалы булган. Хәзер менә бу апаның кулы шундый менә. Хәзер авыртса, кирәк булса без ул әбинең исемен атап, минем кулым түгел, минем күзем түгел, мени Мәстүрә әбинең кулы булсын, шифалы булсын, диеп әтеп дога кылырга кирәк. Шулай эшлибез без. Предкыларныкын кайтарабыз. Безнең әтинең әбисе ул суга өшкергән.

## Күзеккәннән шикләнсәң

Утыралар, ди, мәҗлестә, и мин, например, карап утырам:

– Их, матур да бу.

Ул кеше шикләнә. Аның чашкасыннан или тарелкасыннан алып әйберен чәйкәп бер йотырга кирәк, ди. Әби шулай сүләй иде. Күзеккәннән шикләнсәң.

* * *

Үлек булса, урам буенча этеп йөриләрие. Җәназага барыгыз, – дип кычкырып йөри идек, утырып атка:

– Үле бар, җеназага барыгыз.

* * *

Авыз ачканда:

– Ахшам. Азан эттеләр, – дип кычкырып кайта идек мәчеттән.

* * *

Яңа чебиләрне аласың да ночнушка эченнән төшерәсең аска табан. Чебиләр үсәләр. Үлмәсеннәр дип шушылай төшерәсең 12 безнең чыкты 12 сен дә төшердем. Үзе төшә ул. Күкрәктән салып җибәрәсең дә.

*Чардаклы районы Үрән (Енганаево) авылында*
*Хамзина Разыя Бари кызыннан (1952) язып алынды*

Өшкергәндә төрлечә әйтәләр:

Каян килдең – шунда кит, – дип әйтәләр.

Карадан булса – карадан, актан булса – актан китсен, – дип тә Зәңгәрдән булса – зәңгәрдән шулай әтәләр.

Кемнең күзе төшкән – үзенеке үзенә кайтсын.

**Таң суы**

Чәршәмбе көнне таң суы алалар. Шул таң суы белән «Әлхәм», «Кылхуалла»ларны укып, тәрәзәләрне себерәләрие, ишек бауларын чәйкиләр күз тигәннән, оланга күз тисә. Аннан шул догаларны укып инде: үзеңнеке үзеңә кайтсын диеп, шул сүзләрне әйтеп, өшкерәсең инде, юындырасың битен, өстенә сибәсең. Чыгарып түгәргә ярамый аны таң суын, чистарагын эчәсең. Күп эшләмисең аны.

* * *

Минем әби үземнең этиемнең әбисе мени монда артта өч мунча иде рядом, өч хуҗаныкы. Әбиләрнеке иде, тагын бу таш ызбадагы күршенеке иде и мени бу чыршы куагындагы. Өч мунча иде су буенда. Елга бар, Үрән елгасы. Мени моннан бакча артыннан

ага. Бу шул елга буендук торабыз, артыбыздан ук ага. Переулок аша гына. Ындырдан күренеп тора. Ак изба анда зур. Безнең бакчабыз артында елга.

Мунча кертәбез оланнарны алып кайткач:

Таштай, пичтәй таза бул,
Балдай, майдай татлы бул, шылай диеп.
Әти-әни диеп бел,
Олыларга мәрхәмәтле бул,
Тәүфикълы бул, хәерле гомерле.

**Тимрәү имләү**

Аны сызалар. Аны кульча (кульча – тимер кольцо) белән сызалар или күмер. Кыз хатынга – пятница, ирләргә – среда. Пятница, суббота, восресенье – өч көн рәттән сызарга кирәк. Йөртәсең тимрәү кругында. Имнәү атала ул.

Әм-әм, әмрәмүн,
Тәм-тәм, тәмрәмен,
Ай китә – төн китә,
Тимрәү булса син дә кит, – бу тимрәү имнәүе була.

**Арпа чыкса**

Янмаган шырпы башын юешләтәсең дә, шул арпаных өстенә сөртәсең.

*Чардаклы районы Абдулла авылында*
*Миннирахимова Гөлнара Иршат кызыннан (1972) язып алынды*

**Куркылык коюю**

Куркылык коялар кургашиннан. Ике кеше кирәк анда. Таба белән су тотып тора баш өстендә. Берсе тотып тора. Кургашинны яндыра барасың чыра белән, ул шул суга тама. Анда инде төшә нәрсәдән куркканы. Кеше башымы, хайванмы, машинамы. Карыйсың да, су эченнән аласың, марляга бәйлисең дә муниня тага идек и кая кала шунда кала, курку чыга.

*Чардаклы районы Абдулла авылында*
*Насыйрова Раушания Рамил кызыннан (1970) язып алынды*

Солдатка озатканда әпәй тешләтә идек. Солдаттан кайткынча йыйып куя идек югарыга. Солдатны чыгарганда, алы белән

ызбага каратып, арты белән цыгарып үдән үк, кабактан, аннан утырып китәләр. Урам әләнәләр иде элек. Безнекеләр әләнеп тормады, элеккеләр әләнәләр иде.

* * *

Сез кайтканда яхшылар өсте сул якта кала. Элекке яхшы халыкны шунда күмгәннәр. Шында бараларие яңгыр яумаса әбиләр. Шында яңгыр сорарга. Аш пешерәләр иде. Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сорыйлар иде әбиләр. Ә кайтканда инде, анда кергәндә, чувашлар безгә циләк-циләк су – салкын су коеп ебәрәләр ие. Кайтып еткәнсә яңгыр ява иде аннан.

Яңгыр яу, яңгыр яу
Иләкләп тә циләкләп, – дияләр иде.

*Чардаклы районы Татар Колмаеры авылында*
*Кутбеева Суфия Нурмөхәммәт кызыннан (1942)*
*язып алынды*

Яңгыр яумаса, яңгыр теләге уздыралар иде. Кизләү дигән бар иде Кызылсуда (туган авылы. – *И.Я.*). Аны бик уздыралар иде элекке. Чистарталар. Анда аш пешерәләр, сарык суялар иде. Халык җыела иде. Ү саен кереп су сибеп чыгыш иде. Халык урам буйлап су сибешеп йөри иде. Хәзер изгеләр өстенә барып итәләр, сарык суялар.

Яңгыр яу, яу, яу,
Арыштан, бодайдан, арпадан
Без телибез Ходайдан
Алла, бир, Алла, бир.

*Чардаклы районы Татар Колмаеры авылында*
*Шәрәфетдинова Фатыйма Камалетдин кызыннан (1936)*
*язып алынды*

Әлгәре, оланнар, күз тигәч, елы су аласың чүмеч белән. Шул елы суга кулыңны тыгып-тыгып бөтен тәрәзәләреңне себереп аласың, ишек тоткычларын себереп аласың. Аннары шул су белән вич баланы сөртеп чыгасың. Аннары үзен нәрсә белгәннәрне шул суга укып өшкерәсең да:

Ай катя, көн кайтя
Күзеккән булсаң син дә кайт, –

дип ишекнең петлясына саласың ул суларны. Шуның белән баланың бетә иде.

*Чардаклы районы Уразгильдино (Кызылсу)авылында*
*Хабибуллова Нәкыя Исмәгыйль кызыннан (1952) язып алынды*

**Яңгыр теләве**

Аны халык белән колхоз бергә эшлиләр ие. Колхоз продуктылар алып барып, сарык суялар, картларны яшәләр. Корбан уздыралар. Картлар намаз укыйлар, өстәл коралар. Бутка пешерәләр иде, чебеш боткасы. Кизләүдән суны алалар иде дә яшьләрне коендыралар иде бер чиләк су белән:

Яңгыр яу, яу, яу,
Иләкләп тә чиләкләп,
Аю килә калтырап,
Кояш чыга ялтырап.

Безгә ул бәйрәм кебек иде.

Яңгыр теләп уздырмыйча бездә яңгыр яумый, һәр елны.

*Чардаклы районы Кызылсу (Уразгильдино) авылында*
*Хәсәнова Гөлсинә Гомәр кызыннан (1963) язып алынды*

Күзгә арпа чыкса:

Ай кайтя, төн кайтя
Арпа булса син дә кайт.
(3 мәртәбә әтергә кирәк)

Аннан шул әйберне против часовой стрелки (9, 8, 7 … 1) әйтәбез.

Алай да бетмәсә, бозлатасың да карны, кочыткы сидегенә тидереп, арпага тидерергә кушалар.

*Чардаклы районы Кызылсу (Уразгильдино) авылында*
*Хөснетдинова Гөлҗиһан Ситдыйк кызыннан (1940),*
*Хәсәнова Гөлсинә Гомәр кызыннан (1963) язып алынды*

Яңгыр яумаса яхшылар өстенә барып корбан чалыш. Кызылсудан, Үрәннән кайда татар авыллары бар – җыелышып киләләр. Укилар. Кечкенә чагымда барган идем әбигә ияреп. Анда Сотельный дигән авыл бар иде. Хәзер юк. Анда һәрберсенең турысында кое. Обязательно кайтканда безнең өскә сулар сосып куялар. Салкын су бәрәләр иде. Качсаң да куып тотып бәрәләр. Алладан сорыйлар.

## Кырык төен

Әбием бәйли иде 40 төен. 40 төен бәлим. Ак епне алам. Укыйм. 40 төен бәләдем. Бер атнада 3 кат бәләдем. Өзелде дә төште. Иртән тордым бабамның сүәле юк. 40 төенне укый-укый бәлим. «Әлхәм», «Кылһуалла» укыйм. Укыганда әбинең әткәннәре колагымда тора. Башта 1, 3, 5, 7, 9, 9, 7, 5, 3, 1 шулай 3 мәртәбә тирес-торыс саный иде. Мына нәстә ул анысы мин белмим. Шуны эшләдем. Иртән тордык, бабаем төшкән, ди.

## Куркылык кою

Әби куркылык коя иде. Чыра яндырып, эретеп суга тамыза иде. Ул кешене шул нәрсәдән курккан дип укып өшкерә иде. Әби Калмаюрдан үзе. Әбинең туганнары бар да укыган. Хәзер әбинең кеме дә калмады. Әби әлвидалар укый иде.

*Чардаклы районы Папау (Поповка) авылында*
*Гиматдинова Фәния Шакир кызыннан (1932) язып алынды*

## Шилык

Шилык дия идек. Яңгыр теләү дип әтми идек. Әбиләр инешкә ат башы салалар иде. Аерым, хутлаган, киптергән ат башы бар иде кемдәдер. Шуны укып салалар иде. Мына шуны салгачтан яңгыр була дияләр иде. Аннан аны, вакыты җиткәч, барып алалар иде әбиләр. Агып китми, аны бәләп куялар.

Урам буенча пожарный бар иде. Анда бит пожарный машина юк. Куйган бочка ике яктан качать итә торган ике якка шлангасын сузган и шул шлангыдан су ага иде. Урамда очраган бер кешегә аттырталар. Абыйлар аны эшли де. Без:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләкләп тә чиләкләп, – дия идек.
Аннан сызгырып ебәрәбез.

Яңгыр яумагач, әбиләр менәләр ие иске зиярәткә. Алар җыелып, әниләр, картлар, карчыклар баралар иде. Яшьләр машина белән ташийлар. Укып кайталар иде иске зиярәткә. Укыгачтын ява иде яңгыр.

## Тимрәү сызу

Тимрәү сызабыз дия иде. Очлы гына ясаган агач. Агач белән сыза шулай (Вертикаль сызык, аның өстенә горизонталь сы-

зык һәм аның өстенә диагональ сызык сыза – *И.Я.*) тимерәүнең өстенә.

* * *

Тәпи йөреми торса, элек-электән сарык көтүе кайткан вакытта сарык көтүе юлына утырта торган булганнар.

* * *

Теле ачылмый торса, Кызлар тавына алып баралар.

*Чардаклы районы Иске Үрәнбаш авылында*
*Мөбәракшина Саҗидә Харис кызыннан (1951) язып алынды*

Имнәгәннәр кузеңә арпа чыкса. Сул күзгә арпа чыкса, уң кулның атсыз бармагына тиз өзелә торган җеп (шадра сөлгеләр бар бит) тиз туза торган җеп бәйләгәннәр.

Каян килдең шунда кит, – дип җепне бәйлиләр ие дә, бетә ие.

Ә хәзер балан белән имниләр яхшы иттереп. Нинди дога беләсең, дога укып.

Балан белән тимрәү булса имниләр. Коры тимрәү булса – күмер дә мени казанны уа торган мунчала белән имлиләр ие.

* * *

– Сарияга ни булган? (күзгә төртә)
– Арпа булган.
– Нәстә имнисең?
– Арпа имним.
(Күзгә төртә барасың, кулына да ярый).
Име-томы шул булсын
Тьфу, тьфу, – дип.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Самаркина Миңнесания Шакир кызыннан (1936),*
*Галиева Гөлзифа Миңсафа кызыннан (1932),*
*Якупова Мәръям Ибраһим кызыннан (1936),*
*Сәфәргалиева Сәрия Сөнгатулла кызыннан (1941)*
*язып алынды*

## Куркулыкны ничек койганнар?

Куркулыкны беләсеңме ничек койганнар? Моны бик беләм. Менә баласы куркып уяна йокыдан. Алганнар кәсәгә су и кашыкка

кургашин. Шуны кашык белән утка куеп эреткәннәр. И әлеге суга шуны тамызганнар. Укый, укый тамызганнар. Анда имештер хайван рәсемеме имеш, кешеме. Аннары шушы сүрәткә караганнар да:

– Ә бу кәҗәдән курккан икән, бу эттән курккан икән, дигәннәр дә догасы белән укыганнар баланың өстенә.

**Төне-көне күчсә**

Аннары бала көндез йоклый, төннә йокламый. Төне-көне күчте дигәннәр. Хәзер инде нишләргә дигәннәр? Балалы йорттан йә әбисе, йә әнисе күрше хатынына кичкырын кояш иңгәндә садака кертә. Ишекне ача, керә, садаканы куя, дога да кылдырып тормый, әйтми дә, кергән идем дә, чыккан идем дә дими. Алар беләләр, кемдер садака керткән – шулай булган икән дип: – Көне төнгә авышсын,– диеп. Именны аны кояш иңгәндә керткән.

* * *

Таң суы алу да булган.

Бала күзеккәч әйткәннәр анарга таң суы алырга. Кояш чыкканда, кояш чыгыр-чыкмаста барган ул чиләк белән. Эндәшмичә барган, эндәшмичә, кеше очраса да эндәшмәгән. Кайткан да шул суны елытып баласын коендырган.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Якупова Мәръям Ибраһим кызыннан (1936) язып алынды*

**Патша бәйрәме**

Бездә ул көнне кешегә керергә ярамый. Патша бәйрәме дип атала. Алай да йомыркаларны пешерәләр инде кеше яңлыш керсә, ул кешегә шушы пешергән йомырканы бүләк итеп чыгаралар. Начар аяклы кеше керсә, сиңа начарлык булса әтәләр ие: менә, шушы гына кергән иде Патша бәйрәм көнне, дип. Керергә бик тырышмыйлар халык берсенә-берсе ул көнне. Ел буена начар хәлләр булса, кергән кешегә ябалар.

*Яңа Малыклы районы Урта Исәнтимер авылында*
*Шакуров Гакыйл Хәсән улы (1961) язып алынды*

* * *

Тәрәз пыяласын, ишек тоткаларын себергәннәр. Беренче балам тугач күзеккән иде. Тормыш иптәшемнең әбисенең күзе бик

каты иде. Хөршидә әбинең. Ул килгән иде, карады. Анарга бер дә кайнанам күрсәтми иде баланы. Ул китте дә төн ката елады. Күз ниләренә зәп-зәңгәр полосалар чыкты. Ник елый? Ник елый?

– Әллә әбиең килдеме, – ди кайнанам миңа.

– Да, – минәйтәм.

– Карадымы оланны?

– Карады, – минәйтәм, сүде димен.

– И, Аллам, күзеккән генә инде, ди.

Китте ирем, әбиеңнең чабуын ертып кайтты күлмәгемнән. Аны алды да, шырпы белән яндырды да шул төтенне баланың борнына бисмилләһи рахмани рахим, дип нәсәдер этеп, бер өч мәртәбә төтенен кертте борнына и шуның белән бала туктады да тетелеп йоклап китте. Мына бу күзегүдер инде. И шул полоса – зәңгәр полоса бетте.

* * *

Елый олан, эче, бернәрсәсе дә юк. Хәзер врач грыжасы бардыр, ди. Артта Сабира апа. Шунда бардым җәй көне. Сабира апа яткырды оланын тишендереп мына шулай сыдырды. Сыдырды да грыжасы бар, ди, эчендә, ди, шуның өчен елый, ди. Хәзер алды да, мәрхүм, мени шындый агачтан ясалган аяк формасы. Шул агачны тотты да. Белмим нәстә укыгандыр. Искечә үки иде. Мени шулай йөретте, йөретте корсагыннан. Бала елавыннан да туктады. Ибетте дә. Шул грыжа булмады больше. Укып нәсәдер эшләде елами торган бала булды. Агач фурмасы иде. Ул торамы юкмы хәзер андый әйберләр.

*Яңа Малыклы районы Зирекле Куак авылында*
*Рахматуллова Нурия Борһан кызыннан (1960) язып алынды*

Арпа чыкса имниләр иде. «Әлхәм», «Кылхуалла» белән укыйлар. Безнең әти-әни арпаны имниләр иде ясин укый иде дә:

Име-томы шул булсын,
Кайтсын-бетсен,
Тьфу, тьфу,
Име-томы шул булсын.

(Уңга, сулга төкерә, күзенә төкерә).

* * *

Әм-әм әмрәү.
Тим-тим тимрәү, –

Тимрәүне дә шылай сызалар ие. Кайчан пычак үткәрә торган кайрак белә, аның белә дә булмаса үзеннең савыт юа торган ләке мунчала, хәзер бит мынчала тегел. Элеке бит агачтан ясалган мунчала.

Име-томы шул булсын,
Кайтсын-бетсен,
Каян килдең шунда кит,
Тьфу, тьфу,
Име-томы шул булсын,
Каян килдең шунда кит,
Тьфу, тьфу,
Име-томы шул булсын, –

дип кайрак белә имниләр иде. Казан мунчаласы дия идек. Беренче им ул иң шифалысы. Име-томы шул булсын, кайтсын-бетсен – берсен алып ыргыта. Тагы күмер, күмер белән:

– Нәстә булган?

– Тимрәү булган.

– Име-томы шул булсын.

Күмерне ышкый да:

Кайтсын-бетсен
Каан килгән шунда кит.

Мунчаланы әле кайчакта, юеш тимрәү булса – юешләтә, юешләтә дә:

– Име-томы шул булсын, ват бәдбәхет, юеш чүпрәккә этерәм, үзеңне каты гына этерәм, каты гына бетерәм (бөтерә). Каты гына бетерә өч мәртәбә, як-якка, юеш тимрәү дә була бит ул. Чи тимрәү дә була. Шуның өчен чие үзенә, юеше үзенә. Чиенең кирәкмәгән нәстә агып тора ул, тимрәүнең, анысы да бар. Ә юеше – юешләнеп кенә тора. Казан чүпрәге белә, казан мунчаласы дия идек, шуның белән итә идек тимрәүне. (Казан мунчаласы – юкә мунчала).

**Бәби мунчасы**

Иң беренче әби мунчага алып керә иде, туу белә мунчага алып керә. Аны әзрәк юган атлы була да. И инде аны кага-суга:

– И, и, улым (кызым), име-томы шул булсын, әти-әниеңне зурла. Әби-бабайларыңны зурла, име-томы шул булсын. (Ул хәзер балага мунчала. Хәзер туган балага виник җиле җибәрә.) Зур әниеңне – зурла, намазын җәй, кашыгын китер, урынын җәй – хәзер туган балага. (Себерке белән имни шулай.)

– Әтиеңә – әти диң,

Әниеңә – әни диң,

Кайнатага – кайната – барысын тезә, әле кайнасын беләме, кайнатасын беләме. (Шулай такмаклый.) Үзе үсә – үзе зур булыр. Әтисен дә зурлар, әнисен дә зурлар, кайнасын да зурлар. Кайнатасын да зурлар. Урынын җәяр, намазлыгын җәяр.

Шулай тыкы-тыкы-тыкылдыйлар иде.

– Зур үс, бәхетле бул иманны бул, динне бул, әти-әниеңә булыш, әби-бабаңа булыш, әби-бабаң белә бергә намаз укы. Мына элеккедән шушыларны әниләр тыкы-тыкы тыкылдый иде инде.

*Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында*
*Әюпова Зәйнәп Миңгали кызыннан (1935) язып алынды*

## Куркулык коюю

Куркулык коюю да бар. Кургашин белә дә, чәер белән дә. Кара чәер дип атала инде ул (смола). Аны савытка салып эретәсең. Баланы утыртасың. Баланың башыны пәрәнҗә кебек әйбер ябындрасың. Баланы тоттырып утыртасың. Бишегеннән алып кулга, урындыкка утыртасың. Үзең укыган дога белән тирә ягыннан йөреп шушына куркулык коясың. Име-томы шул булсын. Җилдән-җилгә китсен. Әҗер саваплары булсын диеп, үзеңнең белгән догаларың белән. Чытыр, чытыр килгән чакта сүрәтләр чыга. Аны аласың суыннан җыеп. Ялт иттереп ул бер комочкага иteлә. И бети ясап муенына тага идек баланың. Өзелеп төшкәнче йөри.

Баланың көне-төне буталса, төннә йокламый иде бала, көндез йоклый иде. Шунарга ак җеп белә кара җеп куеп бетерә идем мин. Төннә йокламый. Шар хәтле күзләре ачык, ә синең йокың кели, ул га-га-га сөләшеп ята. Шпонка ебен укып, укып 33 мәртәбә чорныйсың ялт иттереп (Беләк аркылы, озын иттереп). Түеннисең и төннә йокламаса кара җепне бәләп куясың. Бишек башына, укып. Ә көндез йокласа, ак җепне бәли идек. Көн белән төнне бутый бала.

* * *

Бородавкалардан ләүкәдән ләм алып (кеше юынгач пычрагы кала) шушы урыннарга сөртергә кушалар ие. Медицина булмаган. Халык үзен үзе.

* * *

40 төен бәли идек. Үзең белгән доганы укыйсың, 40 төен бәләп. Мондый обычный еп. Нинди еп була. Граньга илтеп күмәләр ие. Төннә итәргә кирәк. Артыңа карама. Төннең берендә ул. 12 ме анда берме. Сәгать 1 дә бит инде мәлгүн 12 дә дия иде әниләр.

Төннә мунчага бармагыз. Җен авыштыра дияләр ие. Мунчада шаукым бар. Мәлгүн.

* * *

Көпә-көндез дә мунчада егылырга ярамый. Берәү миңа званить итә. Шундый, шундый хәл, ди. Мин куркам, ди. Бернәрсә эшли алмыйм ди. Вич пастельдән торалмыйм, ди. Мин әтәм, нәстә булды синең белән. Мына, ди, китәр алдыннан егырып барып тәһарәт алыйм дип әткән идем, мунчада егылдым, ди. Ничек егылдың сың мин әтәм. Башың кайсы якка егылды синең димен. Аягым китте ди, кыйбла ягына таба, башым бусагага таба аудым. Мин әтәм значит шаукым инде. Без бит остабикә белән мулла внучкасы булып үстек. Бала-чактан ишеткәнем буенча әби мыни имләп тора.

– Мин сиңа укып, мин чыкмыйча син телефоннан чыкма.

– Яра, ди, үзе елый, куйды бу телефонны хәзер.

Мин 2 рәкагать намаз укыдым Ходай Тәгалә ризалыгы өчен. Төнге 12 нче ярты. Минем бер матур мачым бар иде, иптәшкә. Ул минем арттан бер дә калмый. Хәзер укыдым мин, мунчага барып егылган төшеннән себеркене алдым. Ходай Тәгаләгә тапшырып киттем перекрестокка, төннә бит, төнге 12 дә. Барам, барам, кыш көнне бит бу, кар да юк, шулай эз белә барабыз, минем арттан мачы бара бер дә калмый. Шушылай иттереп бардым. Шушы себеркене укыганнарымны кабат итеп кайттым ыргытып перекрестокка. Иренмичә әкертен генә кайтып барам. Төнге сәгать 1 тулды, 2 нче китте. Хәзер звонить итәргә куркам. Бу кеше бит авыр хәлдә, торалмый. Вич изрәдем дә киттем. Әзрәк тордым сулыш алып та звонить итеп карыйм. Ай Аллам, ди. Нәсә булды минем

белә, ди. Кул юган кебек исәннәндем. Элеккеге гореф-гадәтләргә бүген дә ышанып яшәргә кирәк.

* * *

Мына җиде кат япсаң да тәрәзә төбендәге әйберне ашарга ярамый. Беркайчан тәрәз төбенә куймагыз ризык әйберен. Юына торган әйберләрне дә үзең белә йөртергә кирәк.

*Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында*
*Гобәйдуллина Исламия Нурулла кызы (1947) язып алынды*

**Теләккә чыгу**

Теләккә чыга идек. Савытлар белә катык, кем бәрәңге, кем он итә. И анда чумара пешереп ашый идек. Кычкыра идек:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә-коймактан, коймактан.
Алла бир, амин.
Алла бир, амин.
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма, кире алма.
Арыштан, бодайдан
Без сорыйбыз Ходайдан, Ходайдан.

Тагын икенче кат шуларны әтә идек.

Качан зәрәтләргә чыга идек.

Без инеш буена чыгабыз, утырышабыз, быелны чыктык. Теләккә чыгабыз.

Безнең бер арендатарыбыз бар иде. Ул куй суя иде.

Без кечерәк чакта савытлап картуф, он, катык итә идек. Келәү дә әтәбез, теләк тә. Су сибешәбез. Кырга чыгып 2 рәкәгать намазын укыйбыз и теләк телибез инде. Кичкә яңгыр ява. Кырда да сибешәбез, авылга килеп тә сибешәбез. Кайсыберсе ачулана.

Казаннар бар. Ике зур казан пешерәбез.

*Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылында*
*Әхмәтҗанова Рәисә Шикур кызыннан (1947) язып алынды*

Теләккә бара идек. Яңгыр сорый идек. Прадуктылар алып барабыз. Касы картуф алып бара, касы он алып бара, касы ит алып

бара, йомырка, катык. Төрлесен алып баралар. Аш пешерәләр. Аннан инде оланнар су сибеп йөриләр иде, ашагач. Бөтен кешегә су сибеп йөриләр.

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә коймактан, коймактан.
Яңгыр яу, яу, яу
Арыштан, бодайдан.
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, бир, Алла.
Яңгыр яу, яу, яу
(Биргәнеңне кире алма).
Бакчаларда алмагач
Корый яңгыр булмагач.
Бир, Алла, бир, Алла,
Яңгыр яу, яу, яу.

Ява иде яңгыр апакаем.

* * *

Озак торды өебез. Килгәчтән күмәчләр пешердем дә, яхшы чыга, тозсыз күмәч (пешерә) анарга. Алтынымыдыр пешердем. И аны пает башына, баганалар башына, сарайда тезеп чыктым. Алтыны диделәр дә – алтыны куйдым ясап. Укып куйдым «Әлхәм»не, «Кылһу»-ны, «Аятелкөрси»не укыдым. Йорт анасы, азык куям үзегезгә вата.

Йорт анасына куялар азык. Йорт анасы, йорт атасы ашагыз, диеп.

*Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылында*
*Байбикова Халида Хайбулла кызыннан (1936) язып алынды*

## Риваятьләр-легендалар, авыл тарихлары, сөйләкләр

Бу авыл элекке вакытта, картлар сүләве буенча инде, элеккеге вакытта Петр I вакытында ниндидер заслуга ясаган бер салдат – татарныкы. Ул инде анарга йер биргән. Элекке бирә булганнар йер. Ул бу йерләрне биргән. Таляувыл, Мыратывка – алар бер булган Алявыл белән рядым авыл. Аларны бер иттереп шул салдат инде килгәч, аның ике баласы була – ике малай. Мурат и тагын ничектер, мин инде белмимен. Алар аерылалар ике брат та. Берсе

бере китә Мыратывкага и авылга ат бирәләр Мурат булуына күрә Муратовка диеп. Без шылай ишетеп инде. Башта сәвитта булган Алявыл белән бергә, рядым, моннан каадыр бер уникеме унбишме километр. Анда зур авыл. Татар авылы. Хәзер ул Пензенский областька керә. Ике мәчет иде авылда. Савитлар вакытында ул мәчетләрне икесен дә теттеләр. Берсе таки тора әле дә. Анда инде яптырганнар, коммунислар бирмәгәннәр укырга. Мында вата мәчет ясадылар, уздыгыз мәчет, безнеке ул, яңы мәчет инде. Аның урынысында иске мәчет былган, аны клуб ясадылар. Ул клуб иде, төптә склад, лаука иде, аннан вата инде кире алдылар картлар, мәчет булды.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Абубикярова Фәния Мирзаҗан кызыннан (1943) язып алынды*

Әүлия зираты. Анда бер бабай күмелгән. Ул бабайны инде, урманнар булган анда, шул урман эчендә бу бабайның, ди, акчасы бар диеп үтерәләр, азгыннармы инде. Бер сум акчасы булган, ди. Шунда күмгәннәр, ди. Көтүче булган дип әйтәләр.

* * *

Ике брат килгәннәр бу якка каандыр. Берсе Морат, берсе Шом бабай булган. Берсе – Шом бабае утыра бире, Морат бабай – Муратывка ваты. Монда Шомалак – Шом бабай килгән.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Сейфуллин Сабирҗан Шакир улыннан (1939) язып алынды*

## Коры елга

Без йәйәү киттек, 30 км Атлаш. Кулаткинский район. Апам инде, Алия апам анда чыкты. Кунакка барабыз. Атлашка еткәндә анда бер 1 км шул төштә әни узалмый, аннан укый да инде, и китә. Әле авылга бардык. И әни сорый анда соң нәстә булган? Аннан сүлиләр: анда аталар 26 кешене, шул Коры елгада. И аннан Алланың әмере белән ул төштән су акмый, үңге төштән китә, вот шул. И юмый үзләрен.

Родник анда чыгып тора. Тал, и су чыгып, агып тора. Шунда атканнар, үтергәннәр. Коры елга әтәләр анда. Хәер куялар анда. Тимердән ясалган решеткалар, сетка, утыргычлар бар хәзер.

## Әүлия зәрәте

Аляавыл юлында бар безнеке урман, Мәхмүт урманы, вот шул Мәхмүт урманында зәрәт. Минем хатын белән Саббиха йөриләр эләккә (җиләккә. – *И.Я.*) и анда бакчалары тетелгән аларныкы, ну анда урман эчендә. Бакча барып куйдым. Анда ну үлгән кемдер, ташлар гына куйганнар. Ташка язылмаган. Ике зәрәт анда. Ташлар. Бу якта, и бу якта. Шуны мин барып ухаживать иткәлим. Ну үлгән кемдер. Кайсы әтә туңып үлгән, кышын килгән дә шунда. Авыл очындагысы – көтүче. Ә бу эчтә, урманда, беркем белми. Вот анда әвлия зәрәте әтәләр анарга. Әниләр барып уки, шундый бик кирәккәч. Төнне барып укыйлар. Айның 15 кичәләрендә. Укыганнарга Алла Тәгалә бирә, ди.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Сейфуллин Наим Закир улыннан (1949) язып алынды*

## Ун Ындыр

Монысы бабайлар сүләгәнчә: 1552 елны Иван Грозный Ульяннан Татарияга бара. Хәзерге вакытта анда Ундра дигән авыл бар. Иван Грозный керә шул авылга. Ундра. Ул авыл булган – Ун Ындыр – ун бай булган анда. Су яхшы, аларның су тирмәннәре булган и ындырлары. Ындырда көлтә өйгән, суккан, рабочий эшләгән. Аларның үзенең столовые, пекарня булган. Бик зур авыл, татар авылы. Мәчетләре булган – бер мәчет диеп кенә ишеттем мин аны. Иван Грозный бага: авыл яхшы, татарлар. Приказ биреп катржникларны чакырта, китертә. Әле саламны ташыйлар бер ындырдан. И весь яндыра, катржникларга әтә:

– Выбирайте дүртәр хатын үзегезгә и киткән.

Әле болар күтәрелә Тюменьга таба, направление булган.

Бабайлар әтә иделәр Төмәннән килгән егетләр. Дүртесе дә татар. Берсе киткән Шомалакка. Берсе киткән Мордовылга, аннары ул авыл мукшыга әләнгән. И монда Шом бабай калган инде. Подваллар ясыйлар үзләренә, торырга. Урман булган бу төш. Болар үләнәләр, семья. Берсен ебәрәләр кире Тюменьга, аннан монда тагын килә халык. Алар куркканнар чукындырудан. Алар визде сибелгәннәр.

Муратывкага Аля авыл племянниклары киткәннәр. Муратывкага Аля авылдан килгәннәр. Йәүли яшерәк бездән. Алар Тюмень

татарлары даже Николаевский район Черкли авылы. Алар да Тюменьнан килгәннәр – Сайманнан күчкәннәр.

* * *

Авылның исеме Шомалак киткән. Кайсы елны икәнен бер кеше белми. Әтә иделәр бабайлар: безнең территория кергән Саратывский губерняга. Саратывская губерня, Хвалынский уезд, Безобразкий волость, деревня Шомалак. Нидән Шомалак булган? Мәчет ясагач селога күчкән инде. 1528 елнымы мәчет куйганнар. И шуннан киткән село булып инде. Бездән башлана өч су. Бездә су башы. Суга сокланып утырганнар монда борынгы бабайлар. Шомалак постоянно әпәй ашап торды. Йер бар ие, чәчтеләр, эшләделәр. Халык трудовой иде.

**Языков кем булган?**

Карсунда торучы Языков кем булган? Сарманнан – Татариядан баеган татар килә. Килгән ул Карсун территориясенә. Бер бай кеше 600 гектар җирен сата. Ул ала, акчаны биргән дә, теге Мәскәүгә киткән. Әле яз баш чәчәргә чыгарга монарга җирне бирмиләр. Без бирәбез җирне христианга гына, моселманга юк. И ул русский вераны алган. Татар булган Языков.

**Шәеп кизләве**

Яхшы чишмәләр кырда бар иде. Шәеп кизләве әйтә идек. Борын, атлар белән эшләгәндә, су агып тора иде. Әле аны ил басты бер 10 ел, бетте. 2–3 төштә андый бассейннар, родниклар бар иде. Шәеп бабай булган, шуңа Шәеп кизләве.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Бикбаев Якуб Хәсән улыннан (1933) язып алынды*

Авылда зур пожар булган, күп хуҗалыклар янган. Савиттагы архивлар да янган. Бетүләр булган, шул бетүләр кемнең өендә булган, утка каршы, шул өйләрне калдырып, ут сикереп икенче йортка киткән. Алар укымышлы булганнар.

Аятелкөрсине 318 тапкыр язсаң, аны картлар сүләгәне бар, яшел төскә чорнап крыша башына, ызба башына куйсаң ул уттан саклар, дип әтәләр.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952) язып алынды*

## Сайман

Сайман – тирән булмаган кечкенә елга дигәнне аңлата. Авылның тарихы 400 еллардан артыграк. Безнеке авыл 7 км озынлыгы. Килеп бер партия урнашканнар бирегәрәк, үзгә кавем – кабилә килгәч, алар тегендәрәк барып төзелә башлый. Ул әтелә бездә яңавыл. Ул вакытта булган ераграк, ә хәзер инде алар бергә кушылган. Ә кайсылары әйтә нигез салучы булган Сөләйман – Сайман киткән. Шундый юллар да бар:

Безнең авыл бик зур авыл –
Җиде ярым чакырым.

7 мәчет булган. Хәзерге клуб – ул элеккеге мәчет.

1969 елны мин эшкә кердем савитка. 3300 кеше иде авылда, 700–800 якын өйләр. Терлек күп иде. Авыл буенда өч көтү 500–600 гына сыер иде, сарыкныкы аерым иде. Укучылар 1000 нән артык, 2–3 сменада укыган вакытлар бар иде. 1973 елны 1300 укучы иде Сайман авылында.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Долгова Фатыма Исмаил кызыннан (1948) язып алынды*

## Чирекле

Әби-бабайлардан без ишетеп калганыбыз. Безне сүлиләрие Тюмень ягыннан килгән. Җиде семья. Вот шул килеп урнашкан булганнар безнекеләр Резлей төбенә – первый авыл Чирекле шунда булган. Анда рус авылы әл дә бар. Аннан тора бара безнең бабайлар килеп табалар бик матур гына чирәм өстенә су агып тора булган. Әтинең сүзе. И алар күченәләр бирегә. Монда бик зур урман булган. Кешеләр йөри алмаган, куе урман булган. Тимер юлның теге ягы наратлык, бу ягы каенник булган. Куаклыкка күрә черки күп булган, шуннан Чирекле калган.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Сулейманов Хөсәен Юныс улыннан (1951) язып алынды*

## Казнатау

Казнатау бар, ул зур тау. Пугачев узып баргандамыдыр, бер сүләгән иделәр, шунда үзенең алтыннарынмы күмгән булган. Шуннан киткән «Казна». Узган ул безнең йерләрдән.

* * *

Бездән белогвардейцы тоже узганнар. Тимер юлдан. Вис авыл халкы, әтием сүли иде, качканнар, анда безнеке елга Резлей. Шул елгага качканнар. Атып узганнар белогвардейцылар шунда вись халык 3 көнме, 1 атнамы торганнар шул елгада. Авылга атып үткәннәр поездан.

* * *

Елга анда, суы бик су тегел, Акъяр дип әтәләр. Шул Акъяр ягында безнекеләр вот әмән авыл халкы беренче урнашкан, теге ягында Резлей булган. Резлей халкы. Шул елгадан үтә булган аларның начар сулары, терлек сулары. Шуннан инде безнең әби-бабайлар килгәннәр бу якка. Монда инеш булган. Монда куаклык булган, урман булган. Монда бик күп черкиләр булган. Әтиләребез сүли иде шулай, да.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951) язып алынды*

## Кузнецкий

Екатерина II да узган. Пенза өлкәсендә Кузнецк шәһәре бар, шунда аның арбасының калисосы емерелә. Шунда үзенекеннән яхшы ясап бирәләр калисосын и ул кузнецы – Кузнецкий кушып киткән. Ул г. Нарышкин булган. Безнең авыл Кузнецкий районы – Пензага караган. Монда килгәннәр унике гаилә. Алар ак бүрәнәдән өйләр салганнар. Акъяр тавы тирәсендә Резлейка елгасы буенда. Резлей һәм Никулино авыллары арасында.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Сулейманов Хөсәен Юныс улыннан (1951),*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951) язып алынды*

## Кызылсу авылы

Кызылсу авылы иске авылдан. Старая Майна районы Кызылсу дигән авылда пожар була. Шуннан өч брат күчеп килгәннәр монда. 1908 елда килеп төпләнгәннәр.

*Чардаклы районы Кызылсу (Уразгильдино) авылында*
*Шафигуллина Дания Шаһиҗан кызыннан (1948) язып алынды*

Исәнтимер авылы хәзер юк. 1978 елда бетә. Кызылсуга күчеп бетәләр, кем Чардаклыга, кем Поповка кача. Алар тау башында иделәр, үчкоз артында.

*Чардаклы районы Кызылсу (Уразгильдино) авылында*
*Хәсәнова Гөлсинә Гомәр кызыннан (1963) язып алынды*

**Папау авылы**

Бер километрмы бар – поп торган. Шуның өчен Попов кушканнар. Бу безнең Ези бабайның сугышып алган йере. 25 ел сугышкан Ези бабай. Рәсеме бар клуб каршында. Ези ул Езиатулла булган. Ул служить иткән. Екатерина әткән:

– Сиңа нәрсә бирим? – дигән.

– Миңа бернәрсә кирәкми, йер бир, –дигән.

– Ә нишлисең ул йер белән?

– Мин халыкны урнаштырыр идем.

– Ничек син кеше табырсың? – дигән.

Безнең бабайларны берәмләп йыйган авыллардан. Минем әтинең игезәкләр табып килгән Чатказдан, әти сүли иде. Чатказ ул Татарияда кададыр шунда. Чатказдан әтинең бабалары. Без алты кеше җыелган. Бабам йыйып йөрегән. Аның кочыклары булган. Ул кочыкларны ияртеп йөргән. Бер авылга барган да, кочыкларыңны бирсәң, кеше табып бирәбез дигәннәр. Ул кочыкка алыштырган кешене. Алабай дип кушканнар безнең нәселгә. Безнең Ези бабай – әнинеке. Әти ягы – Балтачай нәселе. Әтинең әтисе Мәхмүд бабай. Шушы Ези бабай 6 кеше алып килгән. Монда авылга урнашканнар. Бу бабаң урнашкан. Безнең монда бик матур су иде, буйдан-буйга авылны чыкканчы, ул бик каты матур су булган. Кыш чыккач, ул су баскан урнашкан бабаңнарны. Аннан алар күчкәннәр мондарак.

*Чардаклы районы Папау (Поповка) авылында*
*Гиматдинов Назыйм Сәгыйрь улыннан (1932) язып алынды*

**Малаевка. Иске Үрәнбаш**

Малаевка авылы. Шундыйрак кеше булган. Ул шуның исеме белән аталган. Безгә (Иске Үрәнбашка) алар Иске авыл әтәләр. Малаевка элек татар авылы иде. Хәзер бар да бар. Ул яңы

төзелгән, шуңа күрә анарга Яңа авыл (Малаевкага) әйтәләр. Аны йөретәбез Яңы Үрәнбаш диеп.

Иске Үрәнбаш элек була теге якта, юл бар. Иске зиярәтебез дә бар. Анда күмелгән кешеләребез дә бар. Анда төзелгән булганнар. Бик юл өсте булган ул якта. Аларны караклар бик бимазалаганнар. Орлаганнар, яндырганнар, кинаганнар. Аннан соң мондарак күчкәннәр. Ничәнче елны әтәлмим. Минем абыйлар, апалар – 30 нчы елгы бер олы апам. Ул да бу күчкән авылда туган 30 нчы елны. Анда иске урында бернәрсә юк. Авылны чыгасың да ерак анда бер күпер бар. Дмитровград юлы. Ә ул элеккеге Кандал юллары, Старый Майна юллары булган. Хәзер анда юл яхшы – асфальт. Элекке инде Абдулловаларга аннан атлар белән Кызылсуларга, Питровски рус авыллары анда инде атлар белән бара торган булганнар. Ул урынга куаклар утырткannar. Идрис куагы диләр. Идрис исемне абый, авыл күчкәчтән, тамга ясаган. Зиярәт калгачтан, янгарак чыгып, Идрис куаклары. Зиярәткә тамга ясап утырткан булган ул куакларны. Моннан бер 3 км бар.

Төпсез тоба, анда бармагыз дияләр иде. Үрән елгасында Идрис куаклары тирәсендә. Якты күл, Күкерт сазы, Сыер куагы, Бүре куагы – печән чаба торган урыннар.

*Чардаклы районы Иске Үрәнбаш авылында*
*Мөбәракшина Саҗидә Харис кызыннан (1951) язып алынды*

Малаевка. Кечкенә Үрәнбаш. Иске Үрәнбаш.

Безнең бабалар служивые булганнар. 1665 елны Саранск төбеннән примерно 100 семья китергәннәр Чардаклыга.

Северный сугышы тотына, Петр I тотына. Аларны вата безнең авылларга тараталар. 100 ызба кала – өй. Анда китерәләр пленныйларны. 100 семьяны бүләләр. Бер өлеше Папау, бер өлеше Үрәнбаш, бер өлеше Үрән, бер өлеше Кызылсу, Иске и бер өлеше Иртуган. Үрән белән Кызылсуга күбрәк киткән халык – бер 25 семья.

1790 елларны перепись була. Анда инде Иске авыл күчкән була. Күпердән монда күчә. Ник күчә? Бу юл Сибирский тракт дип аталган. Сибирьгә обозлар ебәрәләр. Авыл халкына аларны обслуживать итәргә авыр. Крестьян мәңге ярлы бит: 1000 ел. Урманда бандитлар, разбойниклар була, талау. Разрешение бирәләр

күчәргә. Монда күл янына күчә. Шул күчкән вакытта 3 брат була. Әле өйләнгән була, берсе өйләнмәгән була. Күчеп монда утыралар. Монда күл була, елга янында. И шуннан китә безнең авыл. Безнең авыл 1845 елгы примерно. Аңа хәтле Иске авыл хуторы дип саналган. Иң беренче татар авылы булган, аннары китереп утырткannar урыс янынук.

Безнең авылның исеме Кечкенә Үрәнбаш, теге яртысы Малаевка. Хәзер бөтен төшкә Малаевка язалар. Халык Яңа авыл дип йөртә. Ә теге (Иске Үрәнбаш. – *И.Я.*) Иске авыл дип атала. Халык исемендә.

Минем бабай Сәйфетдин (1882), аның әтисе Туймәт, Туймәтнең әтисе Туйгалде, Туйгалденең әтисе Туктар.

*Чардаклы районы Малаевка (Кечкенә Үрәнбаш, Яңа Үрәнбаш) авылында Туйметов Марат Шәмсетдин улыннан (1952) язып алынды*

**Исәнтимер**

Риваятьләр буенча безнең авылыбызның килеп чыгышы шушылай булган. Безнең Чирмешән буена килгән 3 кеше. Берсе татар, берсе мукшы, берсе чуаш. Алар бергә балык тотканнар дус кына. Аннан соң татарның балтасы Чирмешәнгә төшеп киткән. Ул бик каты кайгырган.Чирмешәннән чумып-чумып эзләгән. Ниһаять балтасын тапкач, бик шатланып әйтеп куйган:

– И, исән бул тимерем, – дип. Шушыннан инде безнең авылның исеме килеп чыккан – Исәнтимер. Исеме шушыннан килеп чыккан дип сүлиләр.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында Закирова Зария Гыйззатулла кызыннан (1956) язып алынды*

**Уеннар, аулак өйләр**

Аулагыйлар безнеңчә, авылча әйткәндә инде, вечерлар. Яшьләр вечерга җыела иде – кемнең зуррак өе инде. Яшь кызларымы, яшь егетләреме – барысы. Көн дә бер үдә шундый җыелыш була иде. Ерлыйлар, бииләр, уйныйлар. Ул вакытта, без бала чакта, ут та юк иде. Лампалар да юк иде. Чыралар белән шылай угылларга тыгып чыралар белән генә шылай. Әниләребез-әбиләребез заманында шылай иде. Әле бер егетебез бар иде, алар инде үзләренә

групповой вечер уйнадылар, бер-берселәре белән очрашкыйлары кели яшьләр, беләсең, клублар юк иде ул вакытта. Клуб булса да артта иде. Яшьләр – кызлар анда йөрергә курка инде. Шында инде авызларына кабып керосин кабып китереп көн буе ташыйлар иде, безнең эвебез зур иде бик.

Безнең үзебезнеке тегел инде, дәдемнең: яз башы инде уйныйлар иде яшьләр шулай бераз-бераз җир ачылса инде.

**«Толкай»**дан уйныйлар инде. Шулай кызлар-егетләр баса, араларыннан инде егет кеше теләгәнен алып артка баса. Берсе парсыз. Аннан чыгып китәләр дә әләнеп киләләр. Әле кем инде парын тапмый аны или ерлаталар, или нәсә сүләтәләр шунда. Шында кушалар, ну әле җир ачылып бетмәгән – биергә.

*Павловка районы Йәүли (Евлейка) авылында*
*Шабакаева Рауза Мәхмүт кызыннан (1939) язып алынды*

Уеннар уйный идек. «Круг»тан уйный идек. «Траляй»дан уйный идек. «Алтылы» дип әйтелә торган, пар-парлылар. «Мус»тан (мост) уйный идек. Егетләр белән кызлар. «Күпер» дигәне.

Агыйделнең буеннан
Әйдәгез, дуслар, уйныек
«Траляй» дигән уеннан –

шылай әтәләр и икешәр-икешәр әйләнәләр. Уен, шундый бию.

*Павловка районы Йәүли (Евлейка) авылында*
*Назырова Разия Ризван кызыннан (1942) язып алынды*

Кызлар белән уйныйсың төрле уен шунда. «Ишелү» уйныйсың. Аннан йә давай дүртәү чыгабыз, йырлап-йырлап, биеп «Тәре кисәбез». Общий кучага йыйылып «Круг»– ерлап-ерлап итә идек. Круг эченә алып-алып бии иделәр.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Абубикярова Фәния Мирзаҗан кызыннан (1943)*
*язып алынды*

Вечерлар була иде ул вакытларда. Шул вечерларда уйнап йөри идек яшьләр. Дүрт почмакка басып та уйный идек. Шул «Кристовой» дия иделәр.

Чыга идек малайлар белән шында «Круговой» дип уйный идек, гөрләп күз бәйләп уйный идек.

**«Дәңгездән»** уйный идек. Дәңгездән («Классики». – *И.Я.*) – 6 шакмак. Аны уртага бүлә, аны болай-болай кискәли. Беренчесенә бәрәсең, анда төшсә әләнеп чыгасың. Аннан соң киләсең дә тагын икенчесенә бәрәсең. Бер аяк белә сикер-сикерә әләнәсең. Болай сикереп чыгасың да, урап килгәч, тагын аласың да, бәрәсең. Бер аякта басып торган килеш. Өченчесенә бәргәндә эләкмәсә – икенче кешегә бирәсең.

**«Круговой»**дан уйный идек. Берсе уртага кала, икесе ике башта тора.

Бу яктагысы ыргыта, уртадагыга тидерергә тиеш. Теге кача. Әгәр эләкмәсә бу уртадагынарга, икенче якта торганы ала. Ул тырыша монарга эләктерергә. Тиз-тиз генә бәрәләр. Кем эләктерә инде аннан ул каладыр уртага.

**«Унике палкадан»**. Аны, палкаларны, вата 12 штук йыйабыз, куябыз аркылы агач и мында палка. Аннан шул палка өстенә 12 палканы куябыз. Ул палкалар аркылыга тора, килеп бу төштә басасың да ул сибелеп китә. Сибелеп китәләр дә, аннан соң аны йыйыштырганчы мондагы кешеләр кача. Йыйыштырып бетереп китә эзләргә боларны. Әгәр дә килеп өлгермәсә, качкан кешенең берсе килеп баса да, тагын теге йыйыштыра, тагын качалар. Эзләгән кеше качкан кешене табып, үзе басып өлгерсә, табылган кеше палкаларны йыйыштыра. Калганнар кача. Йыйыштырып бетереп китә эзләргә.

**«Гузна»**дан уный идек. Аны тоже китереп утыртасың. Малайлар бәреп ега, тиз гнә алып китереп куеп өлгерәсең, ул синең урыныңа кала.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Ибраһимова Рәисә Хәбибулла кызыннан (1938) язып алынды*

**«Күлек»** әйтә идек. Утырта идек тә, палка белә бәрә идек. Биеклеге 15 см. Мәрә, мәрә белән, палка белән.

«**Чижык»** әтә идек. Палканың бер башы бу баштан юынган, икенче башын – бу яктан. Төрле якларында саннар язылган. Палка белән сугасың, оча, күпмәгә анда унгамы төшә, бишкәме төшә.

Аннан соң»Пан»нан уйный идек, «Гузна»дан. Терлекнең гузналары була бит, система, аякларында. Шунардан уйный идек.

«Ат карак»тан уйный идек.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Ханбеков Нариман Вәлиулла улыннан (1934) язып алынды*

**«Шаркати»**дан уйный идек. Баз казый иделәр. И басасың өчәү-дүртәү, купме анда и базга төшермәскә шарны. Бер генә баз. Малайлар дүрт–биш–алты. Палкалар белән торасың инде. Базга чтобы төшмәсен.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Сейфуллин Сабирҗан Шакир улыннан (1939) язып алынды*

Вечерлар була иде клубта, таныша идек. «Круг» уйныйбыз, «Траля-ляй». Яз башы сулар ага башлагач зур елга бар. Шунда йыйыла идек тә анда уйный идек чирәмдә.

«Сарман»ны да ерлый иделәр, «Галиябану»ны да ерлый иделәр. Бар артисткаларыбыз иде, укытучыларыбыз ерлый иде. Клубта була иде вечер, концертлар.

Бормалы су буйларында
Үскән зифа буйларым, –

дип ерлыйлар, яисә:

Сандугачлар у садта
Китмәсләр без кусак та,
Йә бәхетле, йә бәхетсез
Булырбыз кушылсак та.

*Павловка районы Шомалак авылында*
*Сейфуллина Разия Измаил кызыннан (1941) язып алынды*

**«Елан» уены**

Елан дигән уеннан,
Утырып тору ярамый
Торыгыз урыныгыздан.

Анда биш кеше. Уртада малай, ике читтә икешәр кыз. Малайны әләнеп йөрисең и йөзелмисең (өзелмисең). Елан кебек килеп чыга. Өзелмәскә кирәк.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952) язып алынды*

«Орчык»тан уйный идек. Уртага басалар. Орчыкка баскан биш кеше. Орчыктан әйләнәләр. Кемне тели шуны ала.

**«Карту ярыш».** Вот икәү басабыз. Монда каршы. Аннан болар каршы. Башта без әләнәбез, аннан алар әләнә. Бу бер малай, бер кыз әләнә идек.

**«Мак»**тан («Классики» – *И.Я.*) уйный идек. Сикереп мак тибәбез. Сыза идек тә дүртле була иде, бишле була иде. Бер якта – 5, бер якта – 5. Әнә шул өстәл киңлеге ярасың да, менә шулайга бүләсең. Вот шундый уен иде.Чүлмәк төбеме, крем савытымы – тупрак төйисең дә шунарга, ебәрәсең.Төшәлмәсә, чыгып китсә – үзгә кеше ала.

**«Мәч»**тән уйный идек, сикертеп мәчне. Сыер йонынннан да ясый торганнар ие, сикерми торганны.

*Николаевка районы Әхмәтле авылында*
*Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935),*
*Мустеева Розалия Кәбир кызыннан (1957) язып алынды*

Уеннар уйный идек:

Менә сиңа уң кулым
Менә сиңа сул кулым,
Менә сиңа ун кул, сул кул
Менә сиңа буш кулым.

Алышынасың да тагын китәсең биеп.
«Дүртәү» уйнау бар иде.
«Агыш» – ике кеше тотына менә шулай. Бииләр, ерлыйлар.

**«Деңгелди»**

Менә шулай квадратлар сызасың алты штука. Өчне болай, өчне шулай. Вот берәм-берәм сикертеп уйный идек. Ташны бер аяк белән этеп (күчереп). Таш – вазелин савытын туфрак белән тутырасың. Беренче шакмакка ыргытасың да шуны. Бер аягың күтәреп тора, бер аягың белән сикерәсең, шул ук вакытта тибәсең. Әгәр сызыкка эләксә все калдың. Икенче кеше чыга. Җиңер өчен вис әләнеп чыгарга кирәк, алты куплетын да. И тагы икенче класска күчәсең, өченче … алты классны бетерәсең шулай.

**«Ашык»**

Ашыкларны тезәсең шулай. Ашыклар – сөякләр. Тезеп куя инде. Бер-ике метр. Чөкисең диләр өстән. Бер ашык зурысы була. Крупный рогатый скотныкы була – үгезнеке. Монда сарыкныкы, но анарга груз куя идек. Или груз или зурны куя идек. Тидерергә кирәк, алар ничә ава. Аннан ашыкларың «сага»мы, «туй»мы, «әлче»ме синең ашыгың нинди фурмы күрсәтә – шул фурмадагы ашыкларны син аласың. Әгәр анда шундый фурма күрсәтмәсә – кире тезеп куясың. Шул бәрә торган «сага» диеп атала.

**«Клюк»**

Утыртып куясың. Үзең палкы аласың, ебәрәсең дә тия инде ул. Берне генә утыртып куясың. Ике метр ераклыктан бәрәсең, бәрә торган палканың озынлыгы бер 60 сантиметр якынча. Басып тора торган клюкныкы бер 10–15 сантиметр. Түгәрәк була ул.

* * *

Волейбол уйный идек, футбол. Туп бар иде.
«Лапта» уйный идек.
Малайлар – кызлар бергә уйный идек.
Качыш та уйнадык.

**Ак кирәк, күк кирәк**

– Ак кирәк, күк кирәк
Исемең матур кем кирәк?
– Ильмир кирәк!
Ул чыга. Аннан тагын тотыналар.
– Миңа Мансур кирәк.
Мансур чыга.
– Нинди җәза бирәбез. Йә ерлаталар, йә кусатса кычкырта.

*Чардаклы районы Үрән (Енганаево) авылында*
*Хәмзина Разыя Бари кызыннан (1952) язып алынды*

«Клюк» уйный идек.

Шакмак сызып **«Дәңгелди»** – сикереп-сикереп шул клеткалардан уйный идек. Кем сызыкка баса – бетә инде ул. Үзгә кеше тотына иде.

«Түндәк алыш», «Буяу сатыш» уйный идек. Тезелеп утыра идек тә түндәк. Түндәк сайлыйбыз, кайсы түндәк. Аны сайлыйсың, аның урынына утырасың, торып китәсең.

**«Аю базы»** уйный идек, казый идек җирдән түгәрәкләр, аннан мәч тәгәрәтәсең бит инде. Сыер йонын алып, мәч ясый идек. Шуны тәгәрәтәбез. Кертергә кирәк базга. Кемнең базына төшә. Кул белә тәгәрәтәсең. Базлар казып куябыз шылай янәшә-янәшә, берничә баз. Бу яктан ебәрәсең, кем базына төшә.

*Чардаклы районы Татар Колмаеры авылында*
*Шәрәфетдинова Фатыйма Камалетдин*
*кызыннан (1936) язып алынды*

**«Әйләнеш»**

Алтау чыга. Менә шулай икәүләп уртада, ә дүрт кеше ян яклап баса. Әйләнәсең. Иптәшең китә теге якка, син моны аласың (Сул кул белән башка кешене култыклап ала). Ул сул кул белән теге якны ала. Мының белән әйләнәбез дә, тагы килеп каршы иптәшем белән (уң кул белән алып әйләнә), уртадагылар уң кул белән. Башкалар сул кул белән култыклашып уйныйлар.

**«Агыш»**

Бик күп кеше кулларын өскә күтәреп баса. Ә астан икәүләп һәрберсе үзенең парын алып – «агып» чыга:

Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Сүзе генә килә генә,
Сөйләшергә генә, генә
Үзе юк.

Капкадан чыккан кебек парлашып чыга. 10 пар. 10 пар да капка кебек торалар. Берсе алда басып тора. Ул ике кеше басканның сыңарын ала да, кереп китә. Артка баса, калган иптәш башканы ала.

**«Чик»**

Кыз вакытта «Чик» уйныйбызмы дия идек.

Алты куплет сызабыз. Өстә ярты түгәрәк. Шуны чик дия идек. Вакса савылары бар. Карасы бушый да. Бер аяк белән генә

этәреп. Икенче аякны төшерергә тегел, кайсысынадыр җиткәчтән төшерергә. Шакмак буйлап зур түгәрәккә кертергә. Сызыкка эләксә – бетте – югала, иенчесе чыга. Бәрәсең дә, берне әләнеп чыгасың, түгәрәккә китерәсең. Аннан икенчесенә бәрәсең, тагын әләнеп чыгасың. Өченчесенә бәрәсең. Өченчесенә бәргәндә йә эләгә, йә юк – тәгәрәп китә. Анда уже эшләгәнең югала. Шулай 4 нчесе, 5 нчесе, 6 сы йөреп чыксаң җиңүче буласың.

## «Лапта»

«Лапта» диябез. Анда 2 группага бүленәбез. 6 кеше буламы, 5 кешеме. Бер подавальщик. Мәчне берсе палка белән сыптырырга тиеш. Күтәртеп ебәрәсең дә шул вакытта берне сыптыра. Ул китә инде әллә кая очып. Китәсең куалап. Ул мәчне алып килгәнче син барып кайтырга тырышасың, өлгерергә кирәк. Әгәр өлгермәсәң бетте, көтүче буласың. Бишең дә. Чабалмадың, син генә чабалмадың дип.

*Чардаклы районы Иске Үрәнбаш авылында*
*Мөбәракшина Саҗидә Харис кызыннан (1951) язып алынды*

## «Класс»

Класс сигез була. Аның бер ягында думы (домы. – *И.Я.*) була. Сызыкка тидермәскә. Аны яз башында сыза идек. Пыяла кисәге ыргытасың. Бер аякта гына сикерергә. Тегене бәреп чыгаралмасаң янасың. Янгач икенче кеше уйни башлый. Бөтенләй сикереп чыксаң – бер өй ясыйсың. Теге кешегә осложняется. Хәзер син сигезен дә сыңар аякта сикереп чыктың да, ди, берсен өй ясадың. Хәзер теге кеше болай бара да анда керми, керергә тегел. Бер шакмакны еще да сикереп чыгарга тиеш. Шушы шакмакка тидермичә, шушы шакмакка тигерергә тиеш. Класс уены, авырая бара. Теге кеше өйне ясый бара, тигеҙәргә бүлеп куерга да мөмкин. Ул акыл белән уйнала.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Самаркина Миңнесания Шакир кызыннан (1936),*
*Галиева Гөлзифа Миңсафа кызыннан (1932) язып алынды*

## Бәетләр

### *Мөршидә бәете*

Әнкәем мине бигрәк яратты,
Орышмады бер сүз әйтмәде,
Ул явыз хатын кара йөрәкле
Усал эшкә ирен өйрәтте.

Диде, син ирем, сине яратам,
Бу кызыңнан тормыш калмады,
Приюткамы бир, сугамы агыз,
Кая булса да үтер аны.

Мөршидә кызым, әйдә йөрергә,
Үлгән әниең кабер өсләрен
Чәчәк белән бизәп кайтырбыз.

Шул сүзне әйткәч, киттем кинәнеп,
Дидем, әткәй, әйдә барыек,
Үлгән әнием кабер өсләрен,
Чәчәк белән бизәп кайтыек.

Мөршидә кызым, килче каршыма,
Ахыры рәнҗерсеңме син миңа,
Мин сине суям, булма дөньяда
Әниең белән яшә кабердә.

Әтием кулында ялтырый пычак,
Җыйган чәчәкләрем бер кочак.
Суйсаң да, әтием, рәнҗемим сиңа,
Ятим калдым, бәхетем булмагач.

Явыз әтием, буйнымны кискәч,
Тиздән чыкмый минем җаннарым.
Кызын чалганны әнием белмәде,
Каберенә агадыр каннары.

### *Сафиулла бәете*

Азбарда сыерым җиккәнче
Юлдашларым көтеп тора,
Мине юлда калдырырга
Алар икән хәйлә кора.

Самигулла дүрт яшендә
Атага туймыйча калды,
Олы Кузнецкий юлында
Газраил җанын алды.
(Туңып үлә. – *С.С.*)

Азбарда сыерым җиккәнче
Сөәп куйдым синәгемне –
Сөягемне тотар дип.
Миннән калган нәрсәләрне
Балаларым, сез киярсез,
Олы Кузнецкий юлында
Әтием үлде диярсез.

### ***Гайшә бәете***
*(өзек)*

Гайшә апа батты, диеп,
Балалар да чабыша.
Гайшә мескен агып килә,
Саламнарга ябыша.

Кибетнең тәрәзәсеннән
Егет моны күзләгән,
Күреп калсам да риза, дип
Чумып-чумып эзләгән.
Моны биргәннәр үзгә, бу суга сикереп төшкән.

*Николаевка районы Әхмәтле авылында*
*Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935) язып алынды*

### ***Сак-Сок бәете***

Кибла яныннан җилләр исәдер,
Безнең ризыкны әңкәй кисәдер.

Самавар куйды, чәйләр эчерде,
Эчеп бетергәч, каргап очырды.

Газиз әңкәем, бер сүз әйтәем,
Бәхиллек бирсәң, өйгә кайтамын.

Төшкәндер безгә әңкәй каргышы,
Үзебез туганчы тәкъдир язмышы.

Яңгыр явадыр, әңкәй, башыма,
Елап килдек без әңкәй каршына.

Бардым урманга, бастым баланга,
Балам кычкыра кара урманда.
Әңкәй елама, үзең каргагач.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951) язып алынды*

### *Сак-Сок*

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен ишетәсе.

Мәдрәсәдә пыяла ишек,
Сак белән Сокның тавышын ишет.

Чыктык басуга, урак урырга,
Ходай язгандыр шулай булырга.

Өй түбәсендә сайрый карлыгач,
Әңкәй, елама, үзең каргагач.

Гамач күлмәгем бер дә кимәдем
Очып киткәндә, сау бул димәдем

Әңкәй каргагач, ералды канат,
Очып киткәндә, калдылар карап.

Бездән васият ата-анага –
Үлың-кызыңны юкка каргама.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Самаркина Миңнесания Шакир кызыннан (1936),*
*Галиева Гөлзифа Миңсафа кызыннан (1932),*
*Якупова Мәрьям Ибраһим кызыннан (1936),*
*Сәфәргалиева Сәрия Сөнгатулла кызыннан (1941)*
*язып алынды*

### Мөнәҗәтләр

Раббым Алла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Атаң-анаң риза булса.

Раббым Алла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Тоткан рузяларың булса.

Раббым Алла, диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Чалган корбаннарың булса.

Раббым Алла, диде Муса
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Тирә күршең риза булса.

Раббым Алла, диде Муса
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Кыз кардәшең риза булса.
Әби-бабабыздан калган бу.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952),*
*Шафеева Сафия Хәмит казыннан (1948),*
*Юнушева Тәнзилә Якуп кызыннан (1949),*
*Саюкова Накия Яхия кызыннан (1956),*
*Долгова Фатыма Исмаил кызыннан (1948) язып алынды*

### Мәрхаба

Рәҗәп, Шабан ае узгач,
Килде маһи Рамазан.
Рәсүлулла хөрмәтенә,
Килде шәһри Рамазан.
Мәрхәба, йә мәрхәба
Йә шәһри Рамазан, йә шәһри нур,
Лә иләһе иллә Аллаһы,
Лә иләһе иллә Аллаһ.

Маһи шәриф кергәчтин
Җиргә күккә нур сачар,

Рузә тоткан бәндәләргә
Җәннәт ишеген ачар.
Мәрхәба, йә мәрхәба,
Йә шәһри Рамазан, йә шәһри нур,
Лә иләһе иллә Аллаһы,
Лә иләһе иллә Аллаһ.

Рузә тоткан бәндәләргә
Маһы шәриф иңдерде,
Рузә тоткан бәндәләргә
Рәхмәт аен белдерде.
Мәрхәба, йә мәрхәба,
Йә шәһри Рамазан, йә шәһри нур,
Лә иләһе иллә Аллаһы,
Лә иләһе иллә Аллаһ.

Рузә тоткан бәндәләргә
Фирештәләр шатланыр,
Рузә тоткан бәндәләрне
Хур кызлары каршы алыр.
Лә иләһе иллә Аллаһы,
Лә иләһе иллә Аллаһ.

Маһы шәриф хөрмәтенә
Йөрәкләре пакь булыр
Мәрхәба, йә мәрхәба,
Йә шәһри Рамазан, йә шәһри нур
Лә иләһе иллә Аллаһы,
Лә иләһе иллә Аллаһ.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Ибраһимова Рәисә Хәбибулла кызыннан (1938) язып алынды*

**Рамазан ае мөнәҗәте**

Рәҗәп Шабан ае үткәч,
Килә маһи Рамазан.
Рәсулулла хөрмәтенә
Инде маһи Рамазан.

Рәсүлулла хөрмәтенә
Маһи шәриф иңдерде,
Рузя тоткан колларына
Рәхмәтени белдерде.

Маһи шәриф ае иңгәч,
Җиргә, күккә нур сачар,
Руза тоткан колларына
Җәннәт ишеген ачар.
Сәхәр торган бәндәләр
Алар өлеш алырлар,
Маһи шәриф ае берлә
Хак каршына барырлар.
Сәхәр торган мөэминнәргә
Фәрештәләр шатланыр,
Рузя тоткан бәндәләрне
Хур кызлары каршы алыр.
Маһи шәриф рузясы
Гонаһларны күндерер,
Ул мөбәрак хурмәтенә
Тәмуг утын сүндерер.
Руза тоткан бәндәләрнең
Күңелләре шат булыр,
Ул мөбәрак хурмәтенә
Гөнаһлардан пакь булыр.

* * *

Мәҗлестән соң әйтелә торган мөнәҗәт:

**Мәҗлес мөнәҗәте**

Мәҗлесләр күркәм булсын,
Гумерегез озын булсын.
Әҗәлгә хак биреп форсат,
Тиз булмасын вафатыгыз.
Мәләикле рафик улсын,
Рәсулулла шәфиәт кылсын,
Савап һәм әҗерләр белән
Гамәл дәфтәрегез тулсын.
Утырабыз хәзер бергә
Рәхим кылсын Ходай безгә,
Хавзе кәүсәр шәрабыннан
Эчсә идек бергә-бергә.
Җыелыштык бүген бергә,
Рәхим кылсын Ходаем безгә,
Мәкшәр мәйданына каршы
Барса идек бергә-бергә.
Без һәм килдек сезнең үгә,
Рәхим кылсын Ходаем сезгә,
Дога агачи төбендә
Булса идек бергә-бергә.
Укыек Коръән, әйтиек Салават
Рәзүлебезнең үзенә,
Киамәт көне булганда,
Карарбыз аның йөзенә.
Укыек Коръән, әйтик тәһлил
Фатыйма апайга багышлап,
Киамәт көне булганда
Ул торыр безне сагышлап.
Рәсулуллаһ намаз укый,
Башындадыр аның тажы,
Өммәти, өммәти, – диеп
Күзендин агадыр яши.
Рәсулулла шуны әйтте
Сөекле сүзем Фатыймага,
Мөэминнәргә шәфигатче
Булырбыз мизян янында.
Рәсулулла пыраклары,
Алтыннандыр тояклары,
Ихлас белән әмәл кылыйк,
Без – бу дөнья кунаклары.
Рәсулуллаһ рузасында
Хаҗилар, изгеләр эзе,
Рәсулулла киямәт көн
Каршы алыр үзебезне.

Уза үмеребез зарланып
Фани дөньяга алданып,
Сорыйм җәннәт, сорыйм дидар
Иляһыем сиңа ялварып.
Иляһыем сиңа ялварам,
Сорыйм синнән дүрт нәрсәне –
Бере иман, бере дидар,
Бере җәннәт, бере дәүләт.
Иляһыем сорый сәндән,
Гафу кылгыл гөняһымны,
Ахырдан да нәсип әйлә
Шәфиәтле иманымны.
Иляһыем сорый сәндән,
Җиңел кыйлгыл хисябымны,
Киәмәт көне булганда
Уңдан биргел китябымны.
Сират күпере төбендә
Фатыйма апа түгә күз яшь,
Өммәти, өммәти, – диеп
Рәсуллаһ күтәрми яшь.
Укыек Аятел көрсине,
Хывзыһыма дигән сүзне
Рәсулулла киямәт көн
Хывзыдан сугарыр безне.
Амәлем булмасын рия,
Сүзләрем булмасын көфер,
Мөхәммәд өммәте кылдың
Әлхәмдулиллаһи шөкер.
Иляһыем сорыйм сәндән
Кабул кыйлгыл хаҗәтемне,
Дөньялыкта мин тарлыкта
Насип әйлә җәннәтеңне.
Кеше халән кеше белмәс,
Янар бәгерем уты сүнмәс,
Мәгәрһәмдән кеше үлмәс,
Ирешмәсә әҗәлләре.
Рәсулуллаһ шулай дигән,
Сылават әйтегез дигән,
Сылават әйтмәгәннәргә
Шәфиатымны кылмам дигән.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Сулейманова Наҗия Мөталлиб кызыннан (1955)*
*язып алынды*

**Мөхәмммәд хөрмәтенә**

Калебларга иман тулды
Мөхәммәд хурмәтенә,
Калебларга иман тулды
Мөхәммәд хурмәтенә,
Калебларга иман тулды
Мөхәммәд хурмәтенә,
Әгәр Адәм атабыз,
Соңрак Һава анабыз,
Зиннәтләнде дөньябыз
Мөхәмммәд хурмәтенә.
Зиннәтләнде дөньябыз
Мөхәммәд хурмәтенә.
Юсефне алдадылар,
Бер коега озаттылар.
Юлчылар чыгардылар
Мөхәмммәд хурмәтенә.
Юлчылар чыгардылар
Мөхәмммәд хурмәтенә.
Рәхим син, Аллаһы син,
Коткар җәһәннәмеңнән.

Җәннәтеңне нәсип ит
Мөхәммәд хурмәтенә.
Җәннәтеңне нәсип ит
Мөхәммәд хурмәтенә.

**Майдан түгәрәк булсын**

Мәйдан түгәрәк булсын,
Җаннар күбәләк булсын,
Шул мәйданның уртасында
Рәсүлуллабыз булсын.
Рәсүлуллаһ дыва кылсын,
Догасы кабул булсын.
Мәйдан түгәрәк булсын,
Җаннар күбәләк булсын,
Шул мәйданның уртасында
Хадича анабыз булсын.
Хадича ана дога кылсын,
Догасы кабул булсын.
Мәйдан түгәрәк булсын,
Җаннар күбәләк булсын,
Шул мәйданның уртасында
Айша анабыз булсын,
Айша ана дога кылсын,
Догасы кабул булсын.
Мәйдан түгәрәк булсын,
Җаннар күбәләк булсын,
Шул мәйданның уртасында
Фатыйма анабыз булсын.
Фатыйма ана дога кылсын,
Догасы кабул булсын.
Мәйдан түгәрәк булсын,
Җаннар күбәләк булсын,
Шул мәйданның уртасында
Хаҗәр анабыз булсын.
Хаҗәр ана дога кылсын,
Догасы кабул булсын.
Мәйдан түгәрәк булсын,
Җаннар күбәләк булсын,
Шул мәйданның уртасында
Әминә анабыз булсын.
Әминә ана дога кылсын,
Догасы кабул булсын.
Мәйдан түгәрәк булсын,
Җаннар күбәләк булсын,
Шул мәйданның уртасында
Халимә анабыз булсын.
Халимә ана дога кылсын,
Догасы кабул булсын.
Без сораган догалар –
Барчасы кабул булсын,
Без сораган догалар –
Барчасы кабул булсын.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Мавлютова Сафия Рякыйб кызыннан (1955),*
*Нугайбекова Әнисә Киям кызыннан (1959),*
*Субханкулова Хәдичә Әбубәкер кызыннан (1953),*
*Салькина Рауза Яхъя кызыннан (1953),*
*Гаффарова Мәгъдәүзә Биктимир кызыннан (1942),*
*Ягудина Фәридә Усман кызыннан (1951) язып алынды*

**Җырлар**

Уфаларга мин бармадым,
Дусларым гына барды.
Дусларымның сау бул дигән
Сүзләре генә калды.

Ах, Розечкам-галубычкам,
Мин ташламыйм гомергә
Син дә минем кебек булсаң
Теләмим суынырга.

Син дә кара каш идең,
Мин дә кара каш идем,
Син ятларга карамасаң,
Мин дә карамас идем.

Казанда да мин булдым
Мәскәүдә ике-өч кундым
Сафар айларында тудым
Шуннан бәхетсез булдым

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Ханбеков Нариман Вәлиулла улыннан (1934) язып алынды*

Урман, урман, урман буйлары,
Урманыңда сайрый кошлары.
Сәйләм сезгә, сәйләм,
Тормышыгыз ямьле булсын,
Уңышыгыз күкрәп булсын,
Сәйләм сезгә, сәйләм.

Урман, урман,урман буйлары,
Урманыңнан чыга юллары.
Сәйләм сезгә, сәйләм,
Тормышыгыз ямьле булсын,
Уңышыгыз күкрәп булсын,
Сәйләм сезгә, сәйләм.

*Павловка районы Муратовка авылында*
*Әбүбәкерова Венера Рәшит кызыннан (1965) язып алынды*

Бер туйдан да ерламыйча кайтмадым моны:

Татар авылында, урам йөргәндә
Очрадым менә бер туйга,
Туй туйлаганда, кыз елаганда
Утырдым да калдым бер уйга.

Кызның елавын мин шуннан белдем –
Көчләп бирәләр бер карт байга.
Бармыйм мин, әнкәй,
Бармыйм мин байга,
Келәнсәм дә бик яшь малайга.

Кызым барырсың, байда калырсың,
Иләшерсең, торып китәрсең.
Яхшы атларда, ефәк фәй тунда
Картың белән кунак барырсың.

Бармыйм мин, әнкәй,
Бармыйм мин байга,
Келәнсәм дә бик яшь малайга
Кызым, барырсың,
Сакалын тарап, акчасын санап
Гомер итәрсең.

Яшь комсомоллар – кара мәлгүннар
Урладылар минем хатынымны
Яшь комсомоллар, кызны коткарып,
Үзенең сөйгәненә биргәннәр

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952) язып алынды*

Кода-кодагый,
Матур күлмәгеңне ки.
Кызыңны ничек сөясең,
Олыңны да шулай сөй.

Син дә булдың кодагый,
Мин дә булдым кодагый,
Кодагыйлар арасында
Төрле хәлләр булгалый.

Кодагый бәлеш пешергән
Московский кишердән.
Төн йокыларын йокламый
Сезгә кияү үстергән.

Матурга матур дияләр
Матур гәүдәсенә дә.
Матур бала асраганга
Рәхмәт әнкәсенә дә.

Ворошилов портретына
Күргән саен карыймын.
Армияга баруымны
Зур бәхеттән саныймын.

Утырдым вагон читенә,
Тамчы тама битемә.
Еглыймын да, яшем себерәм,
Кулъяулыгым читенә.

Солдат меске постта тора
Шинельләрен ябынып.
Үрьягая төшләр күрә
Туган ягын сагынып.

Безнең әбинең бәрәне
Ике чага китергән
Шатлыгыннан бии-бии
Берсен басып үтергән

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952) язып алынды*

**«Көймә» уены җыры**

Көймә килүләренә
Ышанырга да ярамый
Сөям диюләренә.

Кушымта:
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Эзе юк.
Хаты гына килә генә,
Сүзе генә килә генә
Сөйләшергә генә, генә
Үзе юк.

Герман кызына азган,
Мине көтмә, чык тормышка,
Диеп хатына язган.

Кушымта: шул ук.

Хатлары сирәк килә,
Хатлары сирәк килсә дә,
Көтәргә туры килә.

Кушымта: шул ук.

* * *

Тыпы-тыпыр биюче,
Тагалы итек киюче.
Тагалары базарда,
Самира укый Казанда.

* * *

Келәтләрдә он иләдем, он иләдем
Еп-еш кына бер сирәк иләктән.
Корт анасы кебек кодагыйны
Сорап кына алдык әле бер Хходайдан

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952) язып алынды*

Мәҗлес ахырында татарча теләк тели, дога кыла абыстай, аннан соң мөнәҗәт көенә рәхмәт әйтеп җырлыйлар:

Өегезгә керү белән
Карадым көзгегезгә.
Ашыгызга, сывывызга,
Рәхмәт хөрмәтегезгә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нурәхмәт.
Ашыгыз тәмле, йөзегез ямьле
Хөрмәтегезгә рәхмәт.

Кайдан килдегез сез безгә
Батмаенча диңгезгә.
Сез кадерле кунак безгә
Ни хөрмәт итек сезгә?

Кулъяулыкларымны юдым
Кулларым берешкәнче.
Саубылыгыз, туганнарым,
Тагын бер күрешкәнче.

Алма гөле, зәңгәр чәчәк
Үсә ашлыклар белән.
Әй дусларым, гүмерегез
Үтсен шатлыклар белән.

Алма алай буламени –
Алма була түгәрәк.
Шул түгәрәк эчләрендә
Яшик дуслар бргәләп.

Килсен болыт, яусын яңгыр
Китсен урман буена.
Сезнең белән безнең дуслык
Китсен гүмер буенча.

Кулъяулыгыңны җил ала
Идел суларга сала.
Сезнең белән бергә булу
Сагынып сөйләргә кала.

Ишек алдым яшел чирәм,
Ландыш чәчәргә кирәк.
Ландыш чәчәкләре кебек
Бергә яшәргә кирәк.

Аклы ситса күлмәгемне
Үзем күләгән идем.
Сезнең белән очрашырга
Күптән теләгән идем.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Ишетсеннәр, белсеннәр.
Бүген бирегә җыелган
Бергә укыган дисеннәр.

*Николаевка районы Татар Сайманы авылында*
*Саюкова Наилә Төхвәт кызыннан (1952),*
*Шафеева Сафия Хәмит кызыннан (1948),*
*Юнушева Тәнзилә Якуп кызыннан (1949),*
*Саюкова Накия Яхия кызыннан (1956),*
*Долгова Фатыма Исмаил кызыннан (1948),*
*Айзадуллова Тянзиля Ярулла кызыннан (1946) язып алынды*

* * *

Үсеп җиткәч мин буйга,
Әңкәй килгән бер уйга,
Шатлык алган бар дөньясын:
Хәзерләнәдер туйга.

Күп үтмәде туй булды –
Өйгә кодалар тулды,
Шул ук вакыт мулла килде,
Даһли никях укыды.

Шулай итеп, яшь килен
Булып китте кыз чагым,
Рәхәтлярым кая китте,
Кемгә төшәр күз яшем?

Шулай җырлаганнар, үзе теләми – бирәләр. Әнисе-әтисе бирә. Үзеннән башка никах укыганнар.

Сораганда дәшмәсә дә
Су эчәдер дияләр,
Сәбәбе шул (елатып та) –
Көчләп бирәләр.

*Николаевка районы Әхмәтле авылында*
*Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935) язып алынды*

**«Көймә» уены җыры**

Көймә килә су селкенә…

Кушымта:
Көймә генә килә генә
Хаты гына килә генә
Сөйләшергә генә, генә
Үзе юк.

Көймәләр терәлгәннәр.
Нахак сүзләр күтәрергә
Без инде өйрәнгәннәр.

Кушымта: шул ук.

Хатлары сирәк килә
Хатлары сирәк килсә дә
Көтәргә туры килә.
Кушымта: шул ук.

*Николаевка районы Әхмәтле авылында*
*Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935),*
*Мустеева Розалия Кәбир кызыннан (1957) язып алынды*

Гармуныңны уйныйсың,
Әллә ниләр уйлыйсың.
Әллә инде үкенечкә микән?
Күңелемне туйдырмыйсың.

Гармунчы булсын ярың,
Гармунчы булсын ярың.
Гармунчының бармаклары саен
Мәхәббәт аның.

* * *

Урманнарга кердем, соңга калдым,
Баласын җуйган болан эзеннән.
Башларым әйләнеп китте кинәт
Башканы сөям дигән сүзеңнән.

* * *

Сезнең алмагачыгыз,
Безнең алмагачыбыз,
Сезнең алмагачыгызга
Кунды сандугачыбыз.

Алмагачның алмаларын
Алып өләшер идем.
Бик сагынган чакларымда
Күреп сүләшер идем.

* * *

Бер катын эшләми иде:
Бригадир, тирәзгә барып,
Гөлмаһруй дип кычкыра,
Гөлмара апа шул вакытта
Пич башына ычкына.

* * *

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр комганнар,
Үзләре вечерга килгән
Авызларын йомганнар.

Авызың кызыл, борының кызыл
Памидурмы ашадың?
Битләреңә пыдра сөрттең,
Кеше күрми башладың

Алларын алга манам,
Гөлләрен гөлгә манам.
Иркәм китте армияга,
Аның утында янам.

Бер сүгәнем армиядә,
Икенчесе төрмәдә,
Өченчесе Әхмәтледә
Аны бирмим кемгә дә

Пенсиясы, пенсиясы,
Пенсиясы (ы)стажсыз.
(Ы)стажсызлар чумырып ала
(Ы)стажлылар ыштансыз.
Ленин бабайның үлүе
Бик әрнетте йөрәкне,
Безне батыр көрәшергә
Ленин бабай өйрәтте.

Ленин бабай васият эткән
Укырга һәм укырга,
Тырышып-тырышып без укыйбыз
Без алдыңгы укуда.

* * *

Агач башын сырламам.
Өч көн, өч төн ерласам да
Бер ерны ике ерламам.

Алмагачның ботагына
Былбыл кунсын, кумагыз,
Мин бәхетсез – ул да җитәр
Сез бәхетсез булмагыз.

Алмагачның ботагыннан
Кашык ясый алмаслар,
Безнең башлар алма түгел,
Алып ашый алмаслар.

Алмагачның ботагыннан
Кашык юындым мин сиңа,
Уналтыда-унҗидедә
Гашыйк булдым мин сиңа.

Вечер, вечер, вечерок,
Ялкау егет менеп ята
Пич башына кичен үк.

Сары матур сайласаң,
Тавышыңнан таныр ием
Былбыл булып сайрасаң.

* * *

Ерларга да мин оста,
Биергә дә мин оста.
Бригадир эшкә кушса,
Һәрвакытта мин каста.

Йырлыйм әле, йырлыйм әле,
Йырлыйм әле сигезне.
Йырламас идем сигезне,
Сөямен үзегезне.

Йырлыйк әле, йырлыйк әле,
Йырлыйк әле, иптәшләр,
Иптәшләр үзебезнеке
Бәлки гаеп итмәсләр.

Йырлыйк әле, йырлыйк әле,
Йырлыйк әле унны да.
Йырламас идем унны да
Йырлый торган урыны да.

Яшь чагымда яшьнәдем,
Кыз чагымда күкрәдем,
Яшьнәмим дә, күкрәмим дә
Хәзер кыса күкрәгем

Йырлыйк әле, йырлыйк әле
Уникегә тулганчы.
Уникеләргә тулганчы,
Дуслар күңеле булганчы.

Йырлыйк әле, йырлыйк әле
Йыр күңелне ача ул.
Йыр күңелне дә ача ул,
Кайгыны да баса ул.

Йырлыйм әле, йырлыйм әле,
Йырламый тормыйм әле.
Йырла дигән дуслармның
Сүзләрен тыңлыйм әле.

*Николаевка районы Әхмәтле авылында*
*Сәйфуллова Сания Мостафа кызыннан (1935) язып алынды*

* * *

Ленин бабай портретын
Чәчәк белән бизибез,
Яңа якты матур тормыш
Коммунизм төзибез.

Ленин бабай үлгән чакта
Кара күлмәген кигән,
Унбиш яштән план корып,
Илле яшендә үлгән.

* * *

Агыйделгә барма якын,
Барма якын – ком ишәр.
Сезнең кебек маладуйлар
Бармагыма да бишәр

Тау башында тәкәләр
Сикереп-сикереп әтәләр.
Розалия апа, чык урамга
Бәетеңне әтәләр.

*Николаевка районы Әхмәтле авылында*
*Мустеева Розалия Кәбир кызыннан (1957) язып алынды*

**«Көймә»**

Көймәләр терәлгәннәр,
Нахак сүзләр күтәрергә
Без инде өйрәнгәннәр.

Кушымта:
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,

Хаты гына килә генә,
Үзе юк.
Хатын гына килә генә,.
Сөйләшергә генә, генә,
Генә, генә, генә, генә
Үзе юк.

Без үскәндә бергә үстек
Тал тамырлары кебек,
Үсеп җиткәч аерылыштык
Кош балалары кебек.
Кушымта: шул ук.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951),*
*Сулейманова Хәлимә Сабит кызыннан (1950) язып алынды*

Сорыекчы кодагыйдан
Яратамы киленне,
Закон биреп, көндә килсә,
Яратырбыз киленне.

Пыяла ишек икән,
Орденнарың дип белдем
Костюмың тишек икән.

Минем иркәм армияда
Атлар эчерәм дигән,
Пока гуляй, тормыш шулай
Кайткач, кичерәм дигән.

Әнә килә автомобиль
Төягәннәр пудыра.
Әлеге егетләргә ышанма,
Әниләре кудыра.

**Авыл көе**

Яшьлегем чәчәк атканда
Сине сөйдем гүзәлем,
Тик берүзем генә белдем
Йөрәгем өзелгәнен.

Яшьлегем чәчәк атмады
Яфрак кына каплады,
Очып китте бәхет кошым
Кайт дисәм дә кайтмады.

Ай да ялгыз, мин дә ялгыз
Син дә ялгыз өчебез.
Ай белән кояш күрешә
Без кайчан күрешербез?

Йолдыз атылганын күрдем
Төнге сәгать икедә.
Уф яна минем йөрәгем
Янамы синеке дә?

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Рамазанова Хәлимә Адельша кызыннан (1951),*
*Сулейманова Хәлимә Сабит кызыннан (1950),*
*Сулейманова Нажия Мөталлиб кызыннан (1955) язып алынды*

Без үскәндә бергә үстек
Тал тамырлары кебек,
Үсеп җиткәч, без аерылдык
Кош балалары кебек.

Әнкәй мине тапкан чакта
Ак бәйләүгә бәйләгән,
Аһ бәйләүләргә бәйләгән,
Бәхте булсын димәгән.

Без алай да итмәгән,
Без болай да итмәгән,
Шөкер Алла бер Ходайга,
Башлар Сибирь китмәгән.

Солдат диеп алдылар да
Билгә риминь салдылар,
Әти-әни, дус-кардәшләр
Бәхил бул дип калдылар.

Әңкәй елый ат җиккәчтин,
Кайтмыйсың, балам, киткәч,
Елама, әңкәй, түкмә күз яшь,
Кайтырбыз вакыт җиткәч.

Безнең авыл өсләрендә
Йолдыз яна яктырак,
Айга да йолдыз бик якын
Сез генә миннән ерак.

Киблалардин искән җилләр
Бөгелә талның нечкәсе,
Йөрәгемнең сау җиреннән
Чыга сагыш чишмәсе.

Исмәле, җил, туктале, җил,
Өзмә гөлләр чәчәген,
Алга килми белеп булмый
Башның ни күрәчәген.

Сызлып таңнар аткан чакта
Ямансу була язын,
Аерыласын алдан белдем,
Ялгыз күрдем кыр казын.

Йөрәкләрне җилфендерер
Минем дә бар бит моңым,
Узган гомер искә төшсә,
Тартып уйныйм гармуным.

Кара урманга кергәч тә,
Уңга каерылгач та,
Ак, дускаем, рәхәт яшә
Бездән аерылгач та.

Аклы күлмәкнең җиңнәре
Матур була каигач ла,
Син киткән якларга карыйм
Кичен кояш баегач.

Йөгереп чыктым урамга
Әйтер сүзем булганга,
Әйтер сүзем әйталмадым
Күңелкәем тулганга.

Биек тауларның башында
Үсә бер ялгыз нарат,
Таралалар кайгыларым
Җырласам суга карап.

Гармун алдым кулыма
Киттем урам юлына,
Кызлар белән таныштыр, дип
Куштым мин гармуныма.

Гармун бәләкәй булса да
Әйтә бит кирәккәен,
Сикереп суларга төшәрмен
Янса яшь йөрәккәем.

Гармун тартсам, моң гына ла
Йөрәк өзгеч ер чыга,
Яшь йөргем, мәхәббәтем
Янып ялкыны чыга.

Гармунымның телләрендә
Уйный бит бармак кына,
Агач яфраклары кебек
Саргаям салмак кына.

Сандугачым, сайрап җибәр,
Талларың тамырлана,
Салкын сулар эчеп кенә
Йөрәкләр сабырлана.

Сандугачым, очасыңмы?
Китте бит киң күлләрең,
Синең янга барып кайта
Көн дә бер күңелләрем.

Уфаларга барам, барам,
Дисәң дә баралмассың.
Алсу сачак яшь вакытны
Кайтарып алалмассың.

Уфа юллары пияла
Таш булса таймас иде,
Уф, яна минем йөрәгем
Син булсаң янмас иде.

Утыр әле янаша,
Син утырма, бер аша.
Әле без аерылгангамы
Кошлар моңны сайраша.

Син дә кара каш идең лә,
Мин дә кара каш идем,
Син ятларга карамасаң,
Мин дә карамас идем.

Әй, җаныем, буең зифа
Тал кебек бөгеләсең.
Таллар кебек бөгеләсең,
Кемне уйлап өзеләсең.

Килә болыт, ява яңгыр
Безнең кырларда гына,
Без ерламый, кем ерласын
Безгә җерларга гына.

Җырла-җырла дип әйтәсез,
Сезгә нинди җыр кирәк,
Сезнең алда җыр җырларга
Сандугач теле кирәк.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле
Берне түгел икене,
Җырламас идем икене
Сез дуслар бик сөйкемле.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Аюпов Мидхәт Идрис улыннан (1956) язып алынды*

Кайдан килдегеә сез безгә
Катмаенча диңгезгә,
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итик сезгә.

Алай да дигән идем,
Болай да дигән идем,
Сезнең каршыгызга
Җырларга дигән идем.

Кодагыйдан сорыекчы
Яратамы киленне,
Закон корып, хезмәт бирсә,
Яратырбыз киленне.

Алай да дигән идем
Болай да дигән идем,
Үмәремнең туен күрсәм
Җырларга дигән идем.

*Николаевка районы Зур Чирекле авылында*
*Сулейманова Асия Ризван кызыннан (1954) язып алынды*

Сандугачым, сандугачым,
Сандугачым, гүзәлем,
Түзәргә калгач түзәсең
Өзелсә дә үзәгең.

* * *

Алма бакчасына кердем
Эзләргә эзләремне,
Эзләмә, таба алмассың дип,
Өзәләр үзәгемне.

*Чардаклы районы Үрән (Енганаево) авылында*
*Яруллова Рауза Бари кызыннан (1949) язып алынды*

Алтылымы чабатаң,
Җиделеме чабатаң,
Бөтен халык арасыннан
Сине генә яратам.

Аягыңа ки чабата
Чабата ергә ята,
Сәүмә байны сәү ярлыны,
Ярлы хезмәт ярата.

*Чардаклы районы Абдулла авылында*
*Насыйрова Гөлбәхрәм Галимҗан кызыннан (1932) язып алынды*

Күк күкрәп яңгыр яугач
Үләннәр тамырлана,
Бер кычкырып дисбе тартсаң,
Йөрәкләр сабырлана.

Чиләк алып суга чыксам,
Азбарларым бозлавык,
Ул бозлар да эреп бетәр
Үткән гомер кызганыч.

Ындырда карлар бетәр
Яшел чирәмнәр үсәр,
Яшь вакытлар үтеп китәр
Картаю вакыт җитәр.

Һаваларда очкан кошның
Һич тә талмый канаты.
Мәңге рәхәт, шат яшәгез –
Әңкәгезнең теләге.

Кырга чыктым үр ебәрдем
Көнгә түгел, гомергә.
Куллар бирешеп үстек
(Куллар биреп күрешеп)
Кодагыйлар белән гомергә.

Ак пирчәткәң бармы әллә?
Бармакчасы тармы әллә?
Сандугач кебек ерлыйсың
Авызыңда кош бармы әллә?

Амур елгалары борылып ага,
Ул ярата борылып агарга,
Мин яратам якын туганнар белән
Чын күңелдән хатлар язарга.

Агым сулар гөрләп ага,
Һич тә туктатып булмый,
Ул бозлар да эреп бетәр,
Үткән гомер кызганыч.

Җырның җыртыклары булса,
Такмак белән ямарбыз.
Урта авылдан табалмасак,
Күрше авылдан алырбыз.

*Чардаклы районы Абдулла авылында*
*Зәйнуллова Рауза Солтангәрәй кызыннан (1939)*
*язып алынды*

Уйна тальян гармуныңны
Егетләр җырлап үтсен,
Туган авылыннан киткәннәр
Ишетсә яшен түксен.

Уйна тальян гармуныңны
Без җырлаган көйләргә,
Сез уйнаган, без җырлаган
Калсын сагынып сөйләргә.

Уйна тальян гармуныңны
Син уйнасаң сөйкемле,
Таң алдында сад-бакчада
Кош сайраган шикелле.

*Чардаклы районы Татар Колмаеры авылында*
*Шәрәфетдинова Фатыйма Камалетдин кызыннан (1936)*
*язып алынды*

Солдатларга җырлар:

Әңкәй, бәгърем, ашың пешкәч
Балаларың җыелыр,
Алар булып мин булмагач,
Күз яшьләрең коелыр.

Әңкәй, бәгьрем, ашың пешкәч,
Ашларыңны суытма,
Янымда балаларым күп дип,
Читтәгесен онытма.

Солдат итеп алдылар,
Билгә риминь салдылар,
Туган авылым, сөйгән ярым
Инде ерак калдылар.

Казарма биек булса да,
Кошлар оя ясамый.
Ал булса да, гөл булса да
Туган җиргә ошамый.

* * *

Сезнең алсу алмагыз,
Безнең алсу алмабыз,
Сезнең алсу алмагызны
Хур итәргә алмабыз.

* * *

Ак куянның баласын
Җибәр кырга уйнасын,
Бер уйнасын, ике уйнасын,
Гаепләштән булмасын.

*Чардаклы районы Кызылсу (Уразгильдино) авылында*
*Хабибуллова Нәкыя Исмәгыйль кызыннан (1952) язып алынды*

Син үстергән кызыңны,
Мин үстергән улымны,
Матур тату торсыннар дип,
Бир, кодагый, кулыңны.

Биек таудан чәчәк җыйдым,
Җыймадым сарыларын.
Үзең тапсаң, миңа да бир
Сабырлык даруларын.

*Чардаклы районы Кызылсу (Уразгильдино) авылында*
*Хәсәнова Гөлсинә Гомәр кызыннан (1963) язып алынды*

Биек таудан чәчәк җыйдым
Аллы гөллесен генә,
Исләремдә гел син генә,
Дустым, белмисең генә.

Ак куянның баласы да инде,
Колак очларында карасы,
Хур итмәбез бер дә, зур итербез
Яхшы ата-ана баласын.

Күпер салам, күпер салам
Син дә кил күрешергә.
Ходай насыйп итсә иде
Гомергә күрешергә.

*Чардаклы районы Кызылсу (Уразгильдино) авылында*
*Хөснетдинова Гөлҗиһан Ситдыйк кызыннан (1940) язып алынды*

* * *

Минем егет армияда
Бик зур нәчәлник икән,
Төпсез чиләк, сапсыз көрәк
Аның кулында икән.

Минем егет армияда
Бик зур начәлник икән,
Медале бар диеп торам –
Костюмы тишек икән.

* * *

Тәрәзә төбенә утырып,
Кимакны майламилар.
Кеше чалбарлары киеп,
Кызларны сайламыйлар.

Төнлә күрдем егетеңне,
Бәрәңге ашый иде.
Бәрәңгеле кулы белән
Корсагын каши иде.

Агыйделнең аръягында
Төлке тузан туздыра,
Безнең авыл егетләре
Йоклап гомер уздыра.

Уртага чыккан кешегә ерлыйсың:

Исемнәре Гөлара.
Ике генә киламитр
Түгелдер безнең ара.

Алларын алга манам,
Гөлләрен гөлгә манам,
Иркәм китә армияга,
Аның утында янам.

*Чардаклы районы Кызылсу (Уразгильдино) авылында*
*Хәсәнова Гөлсинә Гомәр кызыннан (1963) язып алынды*

Сары сандык өсләрендә
Сары якалы пальта,
Үземәме, кешегәме
Сөямен әле пока.

* * *

Кайсы диңгезләргә коя икән
Борылып, борылып кына аккан су?
Күрешүләр, дуслар, ай күңелле,
Әмма аерылышу ямансу.

* * *

Китәм генә дисең, зәңгәр күзем,
Ульян ягына туктарсыңмы?
Бергә генә булган вакытларны
Исеңдә генә тотарсыңмы?

*Чардаклы районы Папау (Поповка) авылында*
*Гиматдинов Назыйм Сәгыйрь улыннан (1932) язып алынды*

Туй мәҗлесләре, кодалар алышу – шунда кара-карши ерлыйбыз:

Кайдан килдегез сез безгә
Батмаенча диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт куйыйк сезгә?

Ак алъяпкыч билләрдә лә
Җилфәрдәми җилләрдә.
Сандугачлар да сайрамый
Сез булмаган җирләрдә.

Бездә биек таулар бар ла
Тау астында таллар бар.
Талда яфрак, миндә сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

Кулъяулыгым төшеп калган
Кесәмнән көзгем белән,
Үтә гомерем димәс идем,
Яшәсәм сезнең белән.

Су өстендә тар басмада
Мин сезне күргән идем,
Аерылгачтын мин нишләрмен?
Мин сезгә күнгән идем.

* * *

Безнең кошлар урманда,
Сезнең кошларыгыз кайда?
Җиде көннән очрашырбыз,
Ә хәзергә хушыгыз.

* * *

Тальян гармун телләрендә
Уйный биш бармак кына.
Агач яфраклары кебек
Саргаям салмак кына.

*Чардаклы районы Иске Үрәнбаш авылында*
*Мөбәракшина Саҗидә Харис кызыннан (1951) язып алынды*

## Туй җырлары

Син булырсың кодагый,
Мин булырмын кодагый,
Кодагыйлар арасында
Андый хәлләр булгалый.

Кайдан килдегез сез безгә
Батмаенчы диңгезгә,
Кадерле кунак сез безгә
Ни хөрмәт куйык сезгә?

Бүген безгә җыелганнар
Кодалар-кодачалар,
Сездә ничек, бездә шулай
Җырлап күңел ачалар.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Самаркина Миңнесания Шакир кызыннан (1936),*
*Галиева Гөлзифа Миңсафа кызыннан (1932) язып алынды*

Кодаларның баскан эзе
Яшел чирәм генә дер,
Рәхәт матур шатлык көннәр
Сезнең белән генәдер

Сезнең алтын алмагыз
Безнең алтын алмабыз,
Сезнең алтын алмагызны
Хур итәргә алмабыз.

И, кодалар, без бергә
Аерылмас идек бер дә,
Тар гүрләргә сыяр идек
Куймаслар безне бергә.

Җиделе лампа якты яна
Унны кебек үк тегел,
Кодалар да юк та түгел
Сезнең кебек үк тегел.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Сәфәргалиева Сәрия Сөнгатулла кызыннан (1941)*
*язып алынды*

Чыккан бер кызга ерлап тора идек. Үчең булса берәр кызга, була иде бит егетләр белән алыш.

Каен агач соратач,
Тартып алып сөйгән идем
Кире бирдем елагач, –

дип, төрттереп тә җырлый.

Каен агач күмере,
Без барасы кайнананың
Кыска булсын гумере.

Урталарда син торасың,
Зифа икән буйларың,
Кемне сайлый, шуның белән
Үтсә иде гумерең.

Ул һәрбер кешенең үзенә – уртага чыккачтан, анарга ниндидер җыр. Яратса, яратып җырлый. Яратмаса – төртмәлене.

Урталарда син торасың,
Нечкә билең борасың,
Нечкә билләреңне борып
Кемне сокландырасың?

Кулъяулыгым төшеп калган,
Кесәмнән көзгем белән,
Бергә яшәүләрем телим
Дусларым, сезнең белән.

* * *

Кыз: Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәйсәрә,
Каргыш каргама, әнкәем,
Теләк теләмәсәң дә.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Сәфәргалиева Сәрия Сөнгатулла*
*кызыннан (1941) язып алынды*

Шаулый урман, шаулый урман
Җилләр искәндә
Сагынамын әниемнең
Ямап биргән күлмәкләрен
Әллә шуны киеп үскәнгә.

Шаулый урман, шаулый урман
Җилләр искәндә.

Сагынамын балачакны
Искә төшкәндә.
Сагынамын авылымның
Такыр-чакыр урамнарын
Әллә шунда аунап үскәнгә.

Шаулый урман, шаулый урман
Җилләр искәндә.
Сагындыра әңкәемнең
Каһәр суккан Уф алласы,
Әллә шуны тартып үскәнгә.

Шаулый урман, шаулый урман
Җилләр искәндә.
Сагындыра балачагым
Искә төшкәндә.
Сагындыра әниемнең чуклы-чуклы чабатасы
Әллә шуны киеп үскәнгә.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Самаркина Миңнесания Шакир кызыннан (1936),*
*Галиева Гөлзифа Миңсафа кызыннан (1932),*
*Якупова Мәрьям Ибраһим кызыннан (1936),*
*Сәфәргалиева Сәрия Сөнгатулла кызыннан (1941) язып алынды*

Кыйблалардан искән җилләр
Сындыра гөлләремне,
Сынган гөлләргә ошатам
Бүгенге көннәремне.

Җил булмаса да селкенә
Агыйдел камышлары,
Без дигәнчә түгел икән
Ходайның язмышлары

* * *

Самолетлар оча-оча
Күк йөзендә уйныйлар.
Кемнәр алар безнең белән
Сугышырга уйлыйлар.

* * *

Аргы яктан бирге якка
Кошлар ташлар ташлады.
Безнең служба беткәндә
Герман сугыш башлады, –

абый язып җибәргән иде хатка.

*Яңа Малыклы районы Иске Исәнтимер авылында*
*Кәбирова Әкълимә Хәйрулла кызыннан (1924) язып алынды*

1. Актыр гына минем беләгем,
Күптер генә минем теләгем;
Теләгән теләгем кабул булса,
Басылыр гына иде йөрәгем.

2. Агыйдел буе сары камыш,
Сары камыш төбе саз булыр;
Үз ишкәйләрем арасында
Миннән моңлырагы аз булыр.

3. Топ-тып кына басып өй түбәгә
Гөрли-гөрли йөри күгәрчен;
Моңлы итеп гөрли, тагын туктый,
Бәхетләрең юк, ди күрәмсең.

4. Урман артларында күлләр булыр,
Күл янында гөлләр дә булыр.
Гөл саргая диеп без саргаймыйк,
Бәлки рәхәт көннәр дә булыр;

5. Олы юлда тузан таралды,
Ап-пак күлмәкләрем каралды;
Хәсерәтләрең, уең күп булса,
Якты дөнья була караңгы.

6. Сандугач кошы зур түгел,
Утырган урыны киң түгел;
Адәмнән адәм ким түгел,
Тик бәхетләре тиң түгел.

7. Караңгы да төндә йөргән чакта
Адаштырмый җирнең мижасы,
Адаштыра дөнья нужасы.

8. Җирән атларның ялларын
Кыйбылалардин искән җил тарый;
Үз бәхетләрең булмагачтын,
Байга хезмәт итеп кем ярый.

9. Карада да елан, ай, туз башлы,
Йөридер лә камыш буенча;
Кара да кашым, ялгыз башым,
Йөридер лә язмыш буенча.

10. Һаваларда очкан асыл кошның
Канатлары җиргә коелмый;
Сабый бала кеби еласаң да.
Маңгайларга язган җуелмый.

11. Йөгереп кенә кердем, ай, бакчага,
Өзелеп тә төште бер алма;
Яшь йөрәкләрем ут тик яна,
Сабырлыкта бирсен бер Алла.

12. Йөгереп тә кердем, әй урманга,
Шомырт кына кистем тал юкка;
Кешедән-кеше, ай, ким түгел,
Кимсетәләр генә мал юкка.

13. Аккошлардай басып, түшен киереп,
Кызлар төшә иртән коега;
Газиз башларына эшләр төшсә
Арысландай ирләр боега.

14. Агыйделкәйләрнең, ай, буенда
Атып калдым кытай казларын;
Кайгыртмасана, газиз башым,
Без күрербез Ходай язганын.

15. Тау башында яткан асыл ташны
Төлке балалары тараткан;
Бәндә теләүләре белән булмый,
Бер Ходаем шулай яраткан.

16. Менеп кенә азан әйтер идем,
Ерак кына калды манара;
Безләр генә буйга үсеп җиткәч,
Бигрәк авыр булды замана.

17. Әстерхандин алган көмеш йөзек,
Кисәң дә кулыңа кер кунмас;
Еламагыз, дуслар, кайгыртмагыз,
Кайгылы йөрәккә май кунмас.

18. Мамык эшләпәмне кияр идем,
Һавадагы болыт яумаса;
Хәсерәтин адәм үләр иде,
Ходай сабырлыгын салмаса.

19. Агыйделкәйләрнең аръягында
Ак самавар кайный җил белән;
Маңгайларга язылган язмышларны
Сыпырып ташлап булмый мир белән.

20. Ак буй күлмәкләрең бик килешә
Чабуларын кыек кискәнгә;
Хәсерәтле кешене бик кызганам,
Үзем хәсерәт күреп үскәнгә.

21. Көмеш иярләре килешеп тора
Акбүз аткайларың көр булса;
Дөнья авырлыгы җиңел була,
Арысландай сабыр ир булса.

22. Һавадан очкан аккошның
Авызы тулы балавыз.
Дөньядин үтеп барабыз,
Рәхәт күрми калабыз.

23. Төрле чәчкә сатып алдым
Утыртыйм дип бакчага;
Ходай бирмәгән бәхетне
Алалмыйсың акчага.

24. Безнең урам аркылы
Ага суның салкыны.
Су сипсәң дә басылмыйдыр
Янган йөрәк ялкыны.

25. Менәр идем – тау биек,
Төшәр идем – такырлык;
Яшь башыма хәсерәт авыр,
Ходай бирсен сабырлык.

26. Байлар кия кара күн,
Без киябез эшләпә;
Ходай бәхетне бирмәсә,
Баеп булмый эшләп тә.

27. Кимим бүркем булсада,
Еламыйм күңелем тулса да;
Ходай кушкач, нихәл итим,
Чыдыйм авыр булса да.

28. «Уф алла» дип кемнәр әйтә,
Кемдә хәсрәт шул әйтә;
«Уф алла» дип бер суласаң,
Тар сулышны киңәйтә.

29. Су буена төшкәнем юк,
Яфрак яра тал тирәк;
Яна дисәң, ялкыны юк,
Ялкынсыз яна йөрәк.

30. Карадыр минем чәчем,
Күпне күрде бу башым;
Уйсу җирдә дәрья булыр
Минем елаган яшем.

31. Ай, ат җиктем, ат җиктем,
Арасына тай җиктем;
Тайның хален ат белә,
Безнең хәлне кем белә.

32. Безнең ындырның артында
Кыр казлары тезелгән;
Без йыламый кем еласын
Безнең өмет өзелгән.

33. Кара болыт киләдер,
Яңгыр микән, кар микән?
Минем кебек кәсерәт күргән
Бу дөньяда бар микән?

34. Тау буйлары уймалы,
Басып торып булмады;
Туып-үсеп кеше булдым,
Рәхәт күреп булмады.

35. Без барасы юлларның
Ике чите казылган;
Безнең болай буласылар
Мөкаддәрдә (язмыш) язылган.

36. Мәчет башы манара,
Өзелеп тамчы тама ла;
Без балалар үскән чакта
Авыр килде замана.

37. Утлар яктым учакка,
Замана авыр бу чакта;
Замананың авырлыгы
Килде безнең яшь чакта.

38. Безнең авыл – зур авыл,
Урамнары тар авыл;
Бәлки рәхәт көннәр булыр,
Хәзергесе бик авыр.

39. Иртә торып тышка чыктым,
Кошлар кунган миләшкә;
Мин моңаймый кем моңайсын,
Бер кешем юк киңәшкә.

40. Ике җирән ат җибәрдем
Урман араларына;
Ниләр килеп, ниләр китми
Ата балаларына.

41. Кабан күле тирән икән,
Буйлаганым юк иде;
Бу хәсрәтләр килер диеп
Уйлаганым юк иде.

хатын караңгылы-яктылыда ук дога укып ишегалдына чыккан һәм узе өйгә йомычка алып кергән. Югары Терешкада да ул көнне хатын-кызлар таң беленер-беленмәс, урамнан, йорттан йомычка алып керәләр һәм мич алдына куялар. Бу традиция авылда бүгенге көндә дә саклана, ди педуниверситетның татар группасында укучы Кузахметова Зөлфия. Аның максаты – «авыр аяклы» кеше беренче булып керә калса, киләчәк бәхетсезлекләрне кисәтү. Иске Кулаткы районының Иске Атлаш авылында йомычка алып керүче бала аны мич алдына чәчә һәм *тавык булып кытаклый* (информант Мөслимова Рәйсә, 1932 елгы; Хәсәнова Римма, 1988 елгы). Аяк сынаш көнендә өйгә беренче кергән чит кешегә хуҗалар: «Аягың җиңел булсын», – диләр.

Әлеге көн белән бәйле төрле сынамышларны күрсәтергә була. Мәсәлән, Николаевка районы Әхмәтле авылында иртүк мич ягалар, әгәр дә ут яхшы кабынып китсә, йортка беренче булып яхшы кеше керәчәк – ел уңа, ә инде учак авыр кабынса, начар кеше киләчәк – бу гаилә өчен ел уңмый, диләр (информант Байгузина Гөлнара, 1987 елгы). Иске Атлашта кызыл йомырка көнендә яңгыр яуса, йә булмаса, болыт тартса, ел яхшы, уңышлы була, дигән караш бар (информант Хәбибуллина Хәлидә, 1925 елгы).

Балаларның йомырка белән уйнаулары безнең өлкәдә берничә авылда гына сакланган. Мәсәлән, Әхмәтледә балалар җыелган йомыркаларны тау башыннан тәгәрәтеп уйныйлар, ә Уразгильдино авылында узган гасырның 50 нче елларында «Йомырка отышлы» уены үткәрелгән.

Ульяновск төбәгендә яшәүче татарларның хуҗалык эшләренә бәйле йолаларын карап үтү, бер яктан, аларның татар халкының традицион йола-бәйрәмнәре белән охшашлыгын күрсәтә. Шулай ук җирле халыкның әдәби иҗатында, яшәү-көнкүрешендә, гореф-гадәтләрендә шактый гына үзенчәлекләр дә күзгә ташлана.

## СЕМБЕР – УЛЬЯНОВСК МӘЧЕТЛӘРЕ, БОРЫНГЫ СЕМБЕР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ[1]

*Резеда Садыйкова*

Сембер-Ульяновск – Идел буена урнашкан борынгы шәһәрләрнең берсе. Рәсми рәвештә 1648 елда барлыкка килгән дип каралса да, исеменнән күренгәнчә, ул – Урта Идел төбәгенең Россия составына кергәнче яшәгән торак пункты. XVIII гасыр азагына кадәр ул Сенбер (Синбир) дип аталган. Шәһәр Сембер тавына утырган (Идел белән Зөя елгалары арасындагы Иделбуе калкулыгының бер өлеше). Бүгенге көндә шәһәрнең тарихына багышланган җитди фәнни хезмәтләр, археологик казылмалар булмаса да, төрле төзелеш эшләре вакытында шәһәрнең төп үзәгендә табылган борынгы каберлекләр, көнкүреш әйберләре аның борынгы чорларда ук барлыкка килүен күрсәтәләр. 1648 елда Сембер шәһәренә «нигез салучы» Мәскәү воеводасы Б.М. Хитрово (XIV гасырда Алтын Урдадан чыккан Едуган нәселеннән) буш урынга шәһәр салмаган, башта ул шул җирне тикшергән, анда иске хәрабәләр дә күргән булырга тиеш, чөнки әлеге вакыйгадан әз генә алдарак, 1636 елда, Россияне өйрәнергә, Персия белән сәүдә эшләрен җайларга җибәрелгән Голштиния илчелегенең сәркатибе, тәрҗемәчесе – күренекле немец сәяхәтчесе, Лейпциг университеты профессоры, зур галим Адам Олеарий – Идел буйлап барганда, Сембер тавына игътибар итә, шунда тукталып, ике

[1] Мәкалә Р.К. Садыйкованың «Халкыбыз җәүһәрләре» (Ульяновск: «Корпорация техгологий продвижения» нәшрияты, 2011) китабыннан алынды.

борынгы шәһәрлек (җимерелгән шәһәр калдыклары), курганнарны тасвирлый, *Сембер шәһәрлегенең* сызымын ясый. Соңыннан А. Олеарий «Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию и обратно» дигән тирән эчтәлекле, рәсемнәр, топографик схемалар белән эшләнгән китабын чыгара. Анда ул бу матур урыннарда кайчандыр шәһәрләр булуын, берсенең *Сембер тавы* (ЗппЪегзка §ога) дип аталуын әйтә. Аның юкка чыгуын галим Аксак Тимер (Тамерлан) сугышлары белән бәйли. Ә бәлки шәһәр Иван Грозный сугышлары вакытында җимерелгәндер, чөнки Олеарийның рәсемнәрендә Түбән Новгород, Тәтеш, Самара, Саратов, Кара Яр, Царицын шәһәрләре күрсәтелгән. Әгәр дә Сембер XIV гасырның азагында юкка чыккан булса, Адам Олеарий 250 елдан соң аның калдыкларын, мәйданын җир өстендә күрә алмас иде. Кызганычка каршы, тарих барышында Сембер генә түгел, атаклы Биләр, Болгар, Суар, Сарай шәһәрләре дә җир белән тигезләнгәннәр. Әмма аларның бүгенге көндә тарихы ачыкланган, ә Сембернең борынгы тарихы әле өйрәнелмәгән, аның буенча махсус археологик эшләр дә алып барылганы юк. XIX гасырда яшәгән М.Ф. Суперанский «Симбирск и его прошлое» дигән очеркында, халык риваятенә таянып, Иделнең сул ягында, хәзерге шәһәрдән бер 13 чакрым ераклыкта, шул ук исемдәге борынгы Болгар шәһәре булганлыгы турында яза, икенче риваять буенча, борынгы шәһәр шулай ук Иделнең сул ягында, хәзерге Крестово-Городигцե тирәсендә (Чардаклы районы) булган дип фараз кылына. Өченче риваятьтә Сембер атамасының болгар әмире исеменнән килеп чыгуы турында сөйләнелә. Әлегә шәһәр исеменең мәгънәсенә тукталып тормыйча, шуны әйтәсе килә: рус тарихчылары, кайдан алыптыр, борынгы Семберне һәрвакыт Иделнең сул ягында булган дип күрсәтәләр, ә бит Адам Олеарий шәһәрнең исемен *Сембер тавы* дип яза. Бу исем татар топонимикасының законына бик тә туры килә, чөнки таулы урында урнашкан татар авыл һәм шәһәр исемнәренең күпчелеге *тау* географик термины кушылып ясала. Мәсәлән, борынгы Болгар шәһәрләренең исеме: Тубылгытау, Җүкәтау, шулай ук башка регионнарда Тимертау, Янгантау, Күмертау шәһәрләре бар. Димәк,

Сембер шәһәренең борынгы исеме Сембертау булырга да мөмкин. Тагын шуны белергә кирәк: Сембер тавы Иделнең уң ярында гына урнашкан, ул – Идел буе калкулыгының бер өлеше. Иделнең сул ягындагы җирләр географик яктан Идел елгасының иңкү (түбән) үзәненә керәләр, шуңа күрә ул якта берничек тә борынгы Сембер шәһәренең булуы мөмкин түгел.

В. Никонов күрсәтүенчә[1], хәрби ныгытма буларак төзелгән Сембер шәһәрендә 1678 елда бары 600 йорт исәпләнгән, язма рәвештә теркәлгән бер урам исеме дә булмаган. 1866 елда шәһәрнең планы раслана, ә 1867 елда шәһәр урамнарының рәсми исемнәре, йорт саннары барлыкка килә.

Элекке Сембер шәһәре XIX гасырда гына түгел, XX гасырның 30 нчы елларында да әле, өлкән яшьтәге кешеләр сөйләвенчә, хәзер без белгән Ульяновск шәһәреннән күпкә кечкенә мәйданлы булган. Ул вакытта шәһәрнең бер кырые хәзерге «Южный рынок» тукталышы тирәсендә, икенчесе – Зөя елгасына, төньяк өлеше Урицкий урамына кадәр сузылган була. Шулай күз алдына китерсәң, бу – бүгенге шәһәрнең үзәк өлеше. 60 нчы елларда, автозавод төзелеше башлангач, Засвияжье районы барлыкка килә. 70 нче елларда В.И. Ленинның 100 еллык юбилее уңаеннан шәһәр бик нык үзгәрә.

### Тарихи җамигъ мәчет һәм мәктәп-мәдрәсәләр

Хәзерге карашка зур булмаган Сембердә мәчетләр дә күп булмый. Безнең көннәргә килеп җиткән мәгълүматлар буенча, шәһәрнең беренче һәм төп Җамигъ мәчете Лосевая урамында (хәзерге Федерация урамының 33 нче йорты) урнашкан була. 1853 елда аңа Курамша Абдулла улы Акчурин нигез сала, 1864 елдагы янгыннан соң 1865 елда Курамшаның улы Тимербулат мәчетне төзекләндерә, биек манара күтәрә. 1874 елда ул аны зурайта, тышкы бизәлешен үзгәртә һәм, нәтиҗәдә, берьюлы анда 300 кешегә гыйбадәт кылу мөмкинлеге туа. 1872 елда

[1] Ульяновская-Симбирская энциклопедия, II том. – Ульяновск, 2004. С. 354.

мәчет каршында мәдрәсә ачыла. Ул мәчет утарында аерым йортта урнашкан була. Соңыннан мәдрәсәнең тагын өч уку корпусы, тулай торагы, хуҗалык бигалары төзелә. 1916 елда мәдрәсә милкенә күршедә генә урнашкан хәзерге 35, 37 нче утар-йортларны С.Ш. Бәхтиев бирә. Н.Г. Гариф XX гасыр башында шул ук урамда яшәгән башка милләттәшләребезнең дә җирләре, өстәмә хуҗалык корылмалары белән мәчет, мәдрәсә файдасына үз өйләрен бирүләре турында яза[1], болар: С. Мәхмүтов, Мәрьямбану Еникеева, Мөбин Асадулла улы Усаев. 1915 елгы мәгълүматлар буенча, Лосевая урамының сул канатындагы йортлар шулай урнашкан була: 626 нчы йорт Усаевныкы, 627 – Тимербулат Акчуринныкы, 630 нчы йортта – мәчет (хәзерге 33 нче йорт), 631 – Бәхтиев йорты (хәзерге 35 нче йорт, анда Хәтер тактасы эленгән), 632 – С. Мәхмүтов йорты, 633 – М. Еникеева йорты. Шулай итеп, Т. Акчурин тоткан мәдрәсә Сембер губернасында яшәүче мөселманнарның иң эре уку йорты булып саналган, анда башка төбәкләрдән дә килеп белем алганнар.

Әйтергә кирәк, шәһәр үзәгендәге, бер-берсенә терәлеп торучы, Федерация, Нижне-Татарская (татарлар аны *Түбән урам* дип кенә атаганнар), Островский (элекке Миллионная урамы), «1-ый переулок Мира», «2-ой переулок Мира» (элек ул тыкрыклар «1-ый Курмышок», «2-ой Курмышок» дип аталганнар) дигән урамнарда элек бай, яхшы тормышлы татар вәкилләре яшәгән, бүгенге көндә шәһәрнең аулактарак калган бу тыныч почмагы, совет чорында башланган ыгы-зыгыга кадәр, Сембер татарларының мәдәни, дини үзәге булган дип уйларга кирәк. Акчуриннар мәчетнең урынын белмичә генә сайламаганнар: монда үзләренә тиң югары катлау вәкилләре аларның тарафдарлары, ярдәмчеләре дә булып яшәгәннәрдер, юкка гына Тимербулат Акчурин үз өен дә шунда салмаган. Ул төзеткән мәһабәт таш мәчет бинасы агач йортлар арасында әллә каян аерылып тора, ул утар булып урнашкан, урам яктан бизәкләп эшләнгән таш койма белән тотылган. Капкалар, тәрәзәләр формасы бер стильдә –

---

[1] *Гариф Н.Г.* Мәчетләребездә дә милләт язмышы. – Казан, 2008. Б. 3–4.

арка рәвешендә, ярымтүгәрәк итеп уелган. П.Л. Мартыновның 1898 елда төшергән фоторәсемендә янкормадан күтәрелгән манара башта корылма рәвешендә кат-кат булып таштан ясалган, аннары манараның очы куелган. XIX гасырда андый таш пулатларны рус, чит ил байлары, шәһәр башлыклары гына төзи алган. Әлбәттә, бу мәчет хуҗасының гына түгел, Сембер татарларының да горурлыгы булган.

Мәчет-мәдрәсә комплексының биналары күп булган, чөнки зур мәхәлләнең, уку йортының эшчәнлеге дә зур булган. Ул бинаaларның барысын да белмәсәк тә, төгәл әйтергә була: революциядән соң кайсы йортларда татар мәдәнияте, мәгарифе учреждениеләре эшләгән, шулар Акчуриннар тоткан мәктәп-мәдрәсәләрнең биналары, чөнки гражданнар сугышы вакытында яңа хакимият эшче-крестьяннарга каршы түгел, байларга каршы көрәшә. Хуҗалары куылса да, уку-укыту эше шул ук урында дәвам иткән булырга тиеш, чөнки иске уку йортларының инде материаль базасы бар, илдә ачлык-ялангачлык, сугыш барган вакытта, яңа хакимиятнең татар мәктәпләренә бина төзерлек хәле дә булмаган. Бу турыда өлкә архивында сакланган 20 нче еллардагы бөтен рәсми документларда әйтелә. Мәсәлән, милли мәсьәләләр буенча эшләүче «предгубсовнацмен» С. Максимов үзенең 1924 елның 1 маендагы отчетында болай дип яза: «Со школьным помещением катастрофически обстоит дело среди татар. В дореволюционное время школы среди них содержались исключительно на свои средства, школы были религиозные и ютились в небольших домах при мечети. Помещения и теперь те же»[1]. Димәк, бу революциядән соң ачылган Сембер татар совет мәктәпләренә дә кагыла. Бу елларда Түбән Татар урамының 3-А санлы ике катлы агач йортта беренче баскыч дүртьеллык – башлангыч татар мәктәбе (№ 13) һәм татар китапханәсенең филиалы булган, Островский урамының 6 нчы санлы ике катлы агач йортта башта башлангыч, 1926–1927 уку елыннан – икенче баскыч җидееллык татар мәктәбе, ягъни урта мәктәп (№ 17) эшләгән. Ә Федера-

[1] Ульяновск өлкәсенең дәүләт архивы.

ция урамындагы 21 нче санлы бер катлы йортта 1918 елда татар китапханәсе ачыла. Шул ук рәттә аңардан ерак түгел ике катлы таш йортта татар балалар бакчасы урнашкан була. 20 нче елларда шәһәрдә әле татар балалар йорты да эшләп килгән. Сембер шәһәрендә ул чакта башка рус булмаган халыкларның совет хакимияте ачкан шундый милли-мәдәни үзәкләре булмый. Ә татар мәгърифәт учакларының эшләве шәһәрдә татарларның күплеген һәм аларның революциягә кадәр үк бу өлкәдә тәҗрибә туплаган булуларын күрсәтә.

1923 елгы отчет документлары күрсәткәнчә, 1922–1923 уку елы башында яңа ачылган 13 нче татар мәктәбенә 181 бала килә, 17 нче мәктәпкә – 130, әмма октябрь аеннан мәдрәсә дә эшләп китә, һәм совет мәктәпләрендә укучы балаларның күбесе анда да йөри башлый. Бу тартышуның нәрсә белән беткәнен С. Максимовның сүзләреннән (20.04.1923) беләбез: «Религиозная школа среди татар в борьбе за свое существование оказалась очень упорной, и в то время, как таковые среди других национальностей уже давно исчезли, татарская существовала до настоящих дней. В некоторых случаях она от обороны переходила даже к нападению на советскую школу – занимала её помещения или переманивала к себе учащихся совшколы. Так, напр., в Симбирске религиозная школа в 1921–22 учебном году заняла помещения 37-ой (Р.С.: текстта ялгышлык киткән – 37 нче түгел, 17 нче мәктәп турында сүз бара, чөнки шәһәрдә ике генә татар мәктәбе була) Советской Татарской школы, и потребовалось немало усилий, чтобы её оттуда удалить. С начала текущего учебного года эта религиозная школа приютилась в мечети и своей работой тормозила успешное развитие учебного дела в 2-х татарских советских школах.

Ликвидация как этой, делающей своё темное дело на глазах Совнацмена Губоно, так и других явных и тайных религиозных школ в глуши уездов затормозилась по неимению твердых распоряжений центра по этому вопросу. Теперь, в связи с постановлением X Всероссийского съезда Советов о частных школах и изданных в развитие этого постановления распоряжений

Наркомпроса, затянувшаяся ликвидация религиозных татарских школ получает свое завершение...»[1].

Монда шуны ассызыклап үтәргә кирәк: 1921–1922 уку елында хәзерге Островский урамында эшли башлаган 17 нче татар мәктәбенә кадәр анда 1907 елдан Акчуриннарның кыз балалар өчен ачылган мәктәпләре эшләп килгән, шуңа күрә биналарыннан куылган мәдрәсә укытучылары яңадан үзләренең хосусый милекләрен кайтарырга тырышканнар. Ул эш барып чыкмагач, икенче уку елында укытуны, соңлабрак булса да, мәчет бинасында башлаганнар. Әмма уку елының икенче яртысында бу «тәртипсезлек» бетерелә: мәдрәсәнең эшчәнлеге бөтенләй туктатыла, чөнки ул вакыйга һәм авылларда эшләүләрен дәвам иткән дини мәктәп-мәдрәсәләр турында Мәскәүгә «Наркомнац»ка җиткерелә, һәм ул фактларның халыкка зур зыян булуы ассызыклана. Шулай ук Татарстанда дини мәктәпләрнең, Сембер губернасына караганда, алданрак ябылулары турында да әйтелә. Әлеге кискен чаралардан соң «предгубсовнацмен» С. Максимов 1923 елның 20 апрелендә язылган докладында үзен җиңүче кебек хис итә һәм яңа совет хакимиятенең кырыс йөзен күрсәтә: «Автономные республики с мусульманским населением успешно проводят ликвидации религиозных школ и тем самым углубляют и расширяют обязанность советской школы среди татар. Для упрямых же фанатиков у власти, кроме убеждения, найдутся и другие меры воздействия. Для них, думаем, будет поучителен пример руководителей религиозной школы в Симбирске. На предложение властей закрыть школу, руководители дали ложное показание, что таковая закрыта и не функционирует. Обследованием, произведенным работниками Совнацмена через несколько дней, школа обнаружена в мечети в момент своей работы. В результате, руководители религиозного общества и преподаватели религии привлекаются прокурорским надзором к ответственности – за нарушение законоположений об отделении церкви от государства. Будем надеяться, что сознательная часть татарских трудовых масс,

[1] Ульяновск өлкәсенең дәүләт архивы.

работники просвещения среди татар помогут Советской власти с корнем вырвать религиозные школы и среди отсталых татар»[1]. Шулай итеп, атаклы Сембер мәдрәсәсе 1923 елның февраль-март айларында ябылган, дип уйларга кала.

Кызганычка каршы, шул абруйлы уку йортының эшчәнлеген күрсәткән фоторәсемнәр дә нигәдер сакланмаган, алар, әлбәттә, булган. Бәлки аерым кешеләрдә бүген дә сакланадыр, чөнки алгы рәтләрдә баручы Акчуриннар шәкертләр белән фотога төшәргә яратканнар. Шундый фоторәсем Барыш районы Зоя Башы музеенда 90 нчы еллар башында да саклана иде. Өстәп шуны әйтәсе килә: Акчуриннар эре капиталистлар, алдынгы фабрикантлар буларак кына түгел, татар халкының бер зур укымышлы нәселе буларак ихтирамга ия. Алар арасыннан төрле өлкәләрдә эшләүче танылган шәхесләр чыга. Тимербулат Курамша улы Акчурин һәм аның кыз-уллары да Сембер төбәгендәге татар мәгарифе үсешенә үзләреннән зур өлеш кертәләр, татар халкының мәгърифәтчелек чорында бу юнәлештән янда кала алмыйлар. Т. Акчуринның уку-укыту өлкәсендәге меценатлык эшчәнлеге мәгариф органнары җитәкчеләре тарафыннан югары бәяләнә: 1893 елда Казан уку-укыту округы башлыгы аңа мәгариф идарәсенең Рәхмәтен белдерә, шундый ук мактауга рус дворяннары В.Н. Поливанов, А.Д. Протопопов ия булалар. Хәйриячелек эшчәнлеге өчен аны гади халык та хөрмәт иткән.

XIX гасырның икенче яртысында башланган мәгърифәтчелек хәрәкәте яңача укыту өчен көрәш белән барган. Уку программаларына дөньяви фәннәрне кертү, балаларны искечә иҗек методы белән түгел, аваз методы белән укырга өйрәтергә теләү һәм шуларны әкренләп тормышка ашыру – алдынгы укытучыларның төп максаты була. Ул елларда бөтен татар дөньясы шул уйфикерләр белән кайный: укытучылар, галимнәр, язучылар, дин әһелләре белән беррәттән, алдынгы карашлы эшкуарлар да бу эшләрдә актив катнашалар. Акчуриннар да үзләре тоткан мәктәп-мәдрәсәләрдә эшне яңача алып барырга тырышалар, Казан, Уфа,

[1] Ульяновск өлкәсенең дәүләт архивы.

Оренбургтан белемле укытучылар чакырталар. 1906 елда Хәсән Тимербулат улы Сембернең Лосевая урамындагы Мангушев йортында мәктәп (башлангыч дини уку йорты) ача. Анда ул укытуны яңача алып баручы Нугайбеков дигән укытучыны куя. Уйларга кирәк, әтисе ачкан традицион мәдрәсәнең эшенә кагылмыйча, әллә ни тавыш чыгармыйча, яңабаштан үзенчә эшләргә тели. 1908 елның март аенда, яңа укыту методын тизрәк губерниядәге башка мәктәпләргә кертү теләге белән, ул Сембер губернасының халык мәктәпләре директорына мөрәҗәгать итеп, аңардан июнь-июль айларында бер 40 авыл мөгаллимнәре өчен үз мәктәбендә махсус педагогик курслар оештырырга рөхсәт сорый. Аның өчен хакимият органнарына ярдәм итәргә теләген дә белдерә, әмма өстән аңа андый рөхсәт бирелми[1]. Акчуриннар, әлбәттә, хәйриячелек белән үзләре генә шөгыльләнмәгәннәр, шәһәрнең башка эшмәкәрләрен дә шул изге эшкә тартканнар. Мәсәлән, Н. Таиров мәгълүматлары буенча, 1908 елда шәһәрнең Макта-улы гражданины Ибраһим Акчурин, сәүдәгәр Кәрим Абушаев, дворянин Хөсәен Ассанович хәйриячелек белән шөгыльләнүче «Сембер мөселман оешмасы»н төзиләр. Аның эшендә фабрикант Акчуриннар, Бәхтиевләр, сәүдәгәр Абушаевлар, мещанин Х. Әпсәләмов актив катнашалар. 1914 елда әлеге оешма Акчуриннар ачкан кыз балалар мәктәбенә Миллионная урамында махсус бина төзи[2]. Революциядән соң анда 17 нче татар мәктәбе эшләп китә (хәзерге Островский урамының 6 нчы санлы йорты).

Совет чорының беренче көненнән башланган яңа идеологиянең нәтиҗәсе, табигый, мәчетләрнең ябылуына китерә, шул исәптән, Сембер шәһәренең Җамигъ мәчете дә 30 нчы еллар башында эшен туктатырга мәҗбүр була. 30 нчы елларда анда Татар клубы эшләгән. Мәчетнең бик бай китапханәсе кала. Фәез абый Уразманов (1911 елгы), Искәндәр абый Гыйззәтуллин (1921 елгы), Суфия апа Тимербулатова (1925 елгы) сөйләвенчә, ул бик зур була

---

[1] *Таиров Н.И.* Акчурины. Казань, 2002. С. 60–61.

[2] Ульяновская-Симбирская энциклопедия, II том. Ульяновск, 2004. С. 350.

һәм анда бик кызыклы китаплар табарга мөмкин була. Рәсми документларда күрсәтелгән татар изба-читальнясы бәлки шул Татар клубы каршында әлеге китапханә нигезендә эшләгәндер. Ләкин шул бай китапханә 30 нчы еллар азагында тикшерүгә дучар була. Махсус инспекция гарәп графикасындагы бик күп китапларны фондтан ала. Гарәп әлифбасын белгән Фәез абый үзенә шуннан бер егерме китап, шул исәптән бизәкләп эшләнгән Коръән китабын да, алып кала. Китапханә хезмәткәрләре үзләре дә китапларны күбрәк халыкка таратырга тырышканнар. Фәез абый әйтүенчә, анда борынгы әдәби әсәрләр, фәнни, тарихи китаплар, дәреслекләр дә була. Тикшерүчеләр: «Нам ничего такого не надо», – дияләр иде ди ул.

1940 елда Җамигъ мәчетнең бик зур зәвык белән, югары архитектура үрнәге итеп салынган таш бинасын... икмәк пешерү комбинатына бирәләр, һәм озак еллар анда шәһәрнең 1 нче санлы икмәк пешерү заводының бер корпусы эшләп килгән.

Мондый вәхшилекне кем уйлап тапкандыр...

Бүген ул, читлеккә эләккән кошчык шикелле, кеше буе җитмәслек биек койма эчендә калган һәм соңгы көннәрен көтеп яши. Әле шул хәлендә дә тирә-ягын үзенең матурлыгы белән бизәп тора – матурлыкны бит яшереп булмый, үтереп кенә була.

1988 елдан «Туган тел» җәмгыяте җитәкчеләре 1990 елда өлкәкүләм *архитектура һәйкәле* дип билгеләнгән әлеге бинаны татар халкына кайтаруларын сорап, өлкә җитәкчеләренә, Мәскәүгә күп тапкырлар хат язсалар да, нәтиҗәсе булмый, 2001 елда аның хосусыйлаштырылган милек икәнлеге ачыклана, бүгенге көндә аның язмышы билгесез булып кала бирә. Бинаның диварында да аның кайчандыр атаклы Җамигъ мәчет булуын, төзүчесенең, хуҗасының исемен күрсәткән бернинди язу куелмаган. Ульяновск шәһәрендә бу мәчет-мәдрәсә комплексы (янәшә утырган 33, 35, 37 нче йортлар) безнең халыкның *бердәнбер* тарихи урыны, чөнки алдагы юлларда күрсәтелгән Островский һәм Түбән Татар урамнарындагы Акчуриннар мәктәп-мәдрәсәләренең ике катлы агач йортлары, 60 нчы елларда анда татар мәктәпләре эшләүдән туктагач, берсе «Водоканал» оешмасына бирелгән була,

икенчесен торак йортка әйләндерәләр, анда тулай торак булган. 90 нчы елларда «Водоканал» идарәсе шул урында үзенә яңа бина төзеде, ә Түбән Татар урамындагы йорт 2000 еллар уртасына кадәр яшәде, соңгы берничә елда анда төзелеш эшләре башланды. Шулай, киләчәктә безгә тарихи йортларның урыннарын гына күрсәтергә кала. Җәмигъ мәчетне яңадан дин кардәшләребезгә кайтарып, шул комплексnúmта татар җәмәгатьчелеге күптән хыялланган Ульяновск өлкәсе татарларының милли-тарихи музее ачылса, ул берникадәр халыкны үзенең тамырларына якынайтыр иде. Нинди генә мәдәни оешмалар эшләсә дә, халыкның бөтен мирасын үзенә җыеп, саклап килгән бер урыны, шуның белән шөгыльләнүче махсус белгечләр булмаса, аның матди һәм рухи мирасы озакламый юкка чыгачак. Бу яктан чувашлар да бездән алда, алар үзләренең элеккеге чиркәүләрен, чуваш халкының танылган мәгърифәтчесе И.Я. Яковлевның йортын үзләренә кайтара алдылар, бүгенге көндә анда И.Я. Яковлев музее эшли, әмма галимнең тормышын халык тормышыннан аерып карап булмый, димәк ул безнең өлкәдә яшәүче чувашларның милли музее булып тора. Кеше хәтере бик кыска, тарих – музейларда, Китап белән Каләмдә.

## ЧАЛ ТАРИХТАН КИЛГӘН ИСЕМНӘР[1]

*Резеда Садыйкова*

Тел белеменең географик берәмлекләрен өйрәнә торган өлкәсе топонимика дип атала, ә фәндә барлык төр географик объектларның исемнәре топонимнар дип йөртелә. Топонимиядә гидронимнарны (су чыганакларының исемнәре), ойконимнарны (торак пункт атамалары), оронимнарны (рельеф белән бәйле исемнәр) һәм микротопонимнарны (зур булмаган объектларның исемнәре) аерып күрсәтеп була.

Топонимика – үзенчәлекле фән, чөнки ул география, тарих һәм тел белеме фәннәре белән тыгыз бәйле. Топонимикадагы казанышлар тел тарихын өйрәнүдә дә, халыкның этник тарихын яктыртуда да зур әһәмияткә ия.

Без яшәгән төбәк – Урта Идел – тарихи-лингвистик яктан караганда, кызыклы һәм үзенчәлекле регион, чөнки монда күп гасырлар инде төрки, фин-угор, славян телле халыклар аралашып яши. Шулай ук ерак тарихта калган монгол яуларының (XIII гасыр), күчмә калмыкларның (XVII–XVIII гасырлар) эзләрен дә географик исемнәр үзләренә сеңдергән.

Җыеп әйткәндә, Ульяновск өлкәсе топонимиясе гаять катлаулы тарихи-географик, этно-лингвистик шартларда формалашкан. Моны бигрәк тә су чыганакларының исемнәрен тикшерү күрсәтә. Аларның күпчелеге бүгенге көндә дә ачыкланмый кала, чөнки

[1] Мәкалә Р.К. Садыйкованың «Халкыбыз җәүһәрләре» (Ульяновск: «Корпорация техгологий продвижения» нәшрияты, 2011) китабыннан алынды.

галимнәр фикеренчә, гидронимнар ялгызлык исемнәрнең барысыннан да алдарак барлыкка килгәннәр.

Төрки-татар топонимнарын генеалогик яктан хронологик яссылыкта тикшергәндә, түбәндәге катламнарга аерып карарга мөмкин:

• урал-алтай телләре гомумилегенә карый торган географик атамалар;

• алтай телләре гомумилегенә карый торган топонимнар;

• төрки-татар географик атамалары;

• фин-угор телләреннән кергән топонимнар;

• гарәп-фарсы алынмалары нигезендә ясалган топонимнар;

• монгол теленнән кергән географик исемнәр;

• рус теленнән һәм аның аша Көнбатыш Европа телләреннән алынган топонимнар.

Әлеге мәкаләдә бөтен төркемнәрне дә яктыртып чыгу мөмкинлеге булмау сәбәпле, без иң борынгы урал-алтай телләре гомумилегенә карый юрган географик атамаларны ачыклап китәргә булдык.

Татар теленең һәм, гомумән, теләсә кайсы башка бер телнең бик борынгы заманнарга, борынгы тел туганлыгына (бу очракта урал-алтай телләре гомумилегенә) барып тоташа торган географик терминнарын габу-барлау шактый кыен, чөнки бу мәсьәлә, тарихи-чагыштырма метод кулланып, урал һәм алтай телләре географик терминнарын җентекле итеп махсус өйрәнү-анализлауны сорый. Шуңа хәзергә, татар теле материалыннан китеп, гомум телдәге *су, урман, алан, кыр, саз, лап* географик терминнарын һәм *су, ур* сүзләреннән ясалган, әмма бүгенге көндә татар телендә кулланылмый торган борынгы терминнарны *(саур/шаур, сенгур/ сунгур, сар/шар, шан/чән)* мисал итеп китерә алабыз.

Ульяновск өлкәсе, Татарстан гидрономиясендә һәм ойконимиясендә су гидрографик термины бик борынгы *са, ша* һәм *шу* фонетик вариантларында да очрый. Урал телләре гомумилегенә карый торган фин-угыр чыгышлы елга исемнәрендәге *са-ша* компонентларының генезисы шулай ук борынгы урал-алтай телләре туганлыгыннан килә торган *со(су)-са* «су, агымсу, елга,

инеш, ермак» сүзенә кайтып кала, шуңа күрә әлеге терминнар ярдәмендә барлыкка килгән топонимнарны төрки, монгол, тунгус-маньчжур, фин-угор халыклары яшәгән төбәкләрдә күпләп күрсәтергә була.

Мәсәлән, *Акшуат* авыл атамасы (Барыш районы) *ак* һәм *шуат* сүзләре кушылып ясалган. *Шуат* сүзе хәзерге татар әдәби телендә дә, җирле сөйләшләрдә дә сакланмаган. Ул үзе дә кушма сүз булып, шу (тат. су) һәм *ат* тамырларыннан ясалган һәм «терлекләргә *су* эчерә торган урын, сугару урыны» (рус. водопой) дигән мәгънәне аңлата. Бу сүз шул ук мәгънәдә *суат* вариантында хәзерге казах телендә кулланыла. Димәк, *Акшуат* топонимында атларга һәм башка мал-туарга су эчерә торган урынның чисталыгы күрсәтелә.

*Шемурша* – Кузоватово районындагы елга һәм авыл исеме. Бу топоним да кушма сүз булып тора. *Шемур* компоненты төрки телләрдәге *чамур* «пычрак, баткак; ләм, лай» сүзенә барып тоташа, ә *ша* – «су, елга». Шулай итеп, Шемурша – «пычрак су яки елга» дигән мәгънәне белдерә.

*Атца* – Тушна елгасының кушылдыгы. Уйлавыбызча, топоним рус теле тәэсирендә *атса* сүзенең фонетик вариантын тәшкил итә.

*Атса* – ат+са (тат. су) – «ат суы».

Ульяновск өлкәсе топонимиясендә >у> компоненты белән ясалган авыл атамалары зур урын тота: *Пичеур* (Павловка районы), *Елаур* (Сенгилей районы), *Лапшаур* (Базарлы Сызган районы), *Аксаур* (Инза районы), *Кучуры* (Тереньга, Сенгилей районнары), *Сунгур* (Новоспасск районы). Әйтергә кирәк, алар барысы да Иделнең уң ярында урнашкан. Моның сәбәбе бер: Иделнең уң ягындагы җирләр Иделбуе калкулыгына (Приволжская возвышенность) керә. Бу зона Иделаръягы белән чагыштырганда, елга-күлләргә бик бай, аның рельефында чокыр-чакырлар, зур булмаган сөзәк таулар, түбәнлекләр, елга үзәннәре, сазлыклар билгеле урын тота.

Топонимнар очраклы рәвештә барлыкка килми, аларның иң борынгылары табигать үзенчәлекләрен чагылдыра һәм географик терминнар нигезендә ясала.

Алда әйтелеп киткән атамалардагы *ур* компоненты бик борынгы терминнардан санала. Ул бүгенге төрки, фин-угор, монгол, тунгус-маньчжур телләрендә төрле фонетик формада кулланыла. Мәсәлән, татар теленең диалектында *ур* – «текә ярлы сусыз коры елга, чокыр»; әдәби телдә *үр/ур* – «калкулык, биек урын». Димәк, *Пичеур – пиче* – мукшыча «нарат» + *ур*– «нарат үсә торган калкулы-чокырлы урын»; *Елаур – ел* – борынгы төрки *эл* – «халык, кабилә берләшмәсе, авыл» + *ур* – «чокырлы-таулы урында урнашкан авыл».

Әмма *Аксаур, Лапшаур* топонимнарында без *ур* сүзе кушылып ясалган *саур* (вариант *шаур)* терминын очратабыз. Бу сүз бүгенге татар телендә кулланылмаса да, Казакъстан, Татарстан, Мордовия, Рязань өлкәсе һәм башка төрки халыклар яшәгән регионнарда топонимнар составында сакланып калган. Ул «калкулык, түгәрәк тау башы, кыя» дигәнне аңлата. Шуннан чыгып, *Аксаур* – «ак тау башы, ак калкулык». *Лапшаур* атамасындагы *лап* сүзе дә борынгы урал-алтай телләре гомумилегенә карый торган географик термин. Ул мари телендә «түбәнлек, түбән җир»; татар теле сөйләшләрендә «тигез җир»; чуваш телендә *лап, лапа, лапам* «түбән, уйсу җир, тигез, яссы, сөзәк»; мукшы телендә *лапши* «тигез, яссы» дигән мәгънәләрдә йөри.

Ульяновск өлкәсенең Идел алды төбәгендә (Иделнең уң ягы) *лап* тамыры белән ясалган авыл исемнәре байтак: *Лапаевка* (Павловка районы), *Лапы* (Новоспасск районы), *Лапшанка* (Сенгилей районы) һ.б. Димәк, алар барысы да үзләре утырган урынның географик үзенчәлеген күрсәтеп торалар: йә ул түбәнлек, йә тигез җир.

*Лапшаур* атамасын «тигез, яссы тау башы», йә булмаса «сөзәк калкулык» дип аңлатып була.

*Лапшанка* топонимында да ике борынгы терминны күрәбез: *лап* һәм *шан. Шан* сүзе *саур/шаур/, сенгур/сунгур, шуат/суат* сүзләре кебек, *су* (вариантлары: *са-ша-шу-се)* тамырыннан килә. Урал һәм алтай телләрендә сөйләшүче халыклар яшәгән регионнарда *шан-шән-чән-чан-шөн-сөн-сян-сэн-сэни* «елга, инеш, чокыр, иңкү, уйсу җир, текә яр» терминнары белән ясалган бик күп су чыганакларының исемнәрен күрсәтергә була.

Безнең төбәктәге *Лапшанка* һәм *Елшанка* (Ульяновск районы) авыллары да елга үзәнлекләренә, уйсу җиргә утырганнар, шуңа күрә аларның исемнәрендә ул як табигатьнең үзенчәлекләре чагыла: Лапшанка – «тигез уйсу җир», Елшанка – «уйсу җирдә урнашкан авыл».

Өлкәнең Чынлы районында *Тимерчән* елгасы ага һәм елга буйлап шул ук исемдәге чуваш һәм татар авыллары тезелеп киткән. Алда әйткәннәрдән чыгып, *Тимерчән* атамасының мәгънәсе – «тимер елга, тимер чокыр».

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, *ур, лап, шан* компонентлары белән ясалган топонимнар өлкәнең Иделнең уң ягындагы таулы-калкулыклы районнарында гына очрый, чөнки Иделнең сул ягындагы җирләр борынгы тигез Идел үзәненә керәләр.

Күргәнебезчә, күпчелек авыл атамаларының килеп чыгышы чал тарихка барып тоташа. Алар да археологик экспонатлар, борынгы язма чыганаклар шикелле, халыкның бәһасез рухи хәзинәсе булып торалар, чөнки географик атамалар борынгы телләрнең беренчел формаларын саклап яшиләр. Аларны өйрәнү туган як тарихын ачыклауда да ярдәм итә.

**Авыл исемнәре ни сөйли?**

Әбдери – Яңа Малыклы районының татар авылы. Зур Әврәле елгасы буена утырган Әбдери, Лабит, Зирекле Куак авыллары, танылган галим, күренекле якташыбыз Мәсгуд абый Гайнетдинов язуынча, XVII йөзнең 30 нчы елларында барлыкка килгәннәр. Әбдеринең беренче исеме Олы Әврәле булган, тора-бара авылга нигез салучы Әбдерәй Алиев исеме беркетелгән. Монда беренче күчеп килүчеләр Чардаклы районының Үрәнбаш авылыннан йомышлы татарлар булалар.

Драка (русча: Дракино) – Инза районының татар авылы. Мондый топоним төрки-татар теленә һәм топонимиясенә хас түгел. Бу атаманы рус сүзе белән бәйләү дә дөреслеккә туры килми. Сура елгасы буенда, Инза, Кузоватово районнарында элек-электән мордва халкы яши, татар авыллары монда аз – Шлемас, Стрельниково гына. Авыл атамаларының төрки тел белән бәйле булмавы

татарларның бу җиргә соң күчеп утыруларын, аларга кадәр бу авылларда башка милләт вәкилләре яшәгәнлеген күрсәтә. Авыл атамасын мордва теленнән аңлатып була. Дракино, Дракина авыллары Мордовиянең Торбеево районында да бар икән. И.К. Инжеватов язуынча (Топонимический словарь Мордовской АССР, 1987, 63), андый исем белән берничә авыл XIX йөздә Пенза губернасында яшәп килгән. Ә Пенза өлкәсе Инза районы белән чиктәш булып тора. Мордвалар арасында Дракин фамилиясе дә сакланган. Болар барысы да топонимның *Драка* дигән борынгы мордва исеме я кушаматыннан килеп чыгуын күрсәтәләр. Шулай ук ул фонетик яктан үзгәреш кичергән мукшы телендәге *тарка* «урын» сүзеннән дә ясалырга мөмкин.

Енганай (Үрән) – Үрән елгасы буена урнашкан Чардаклы районының татар авылы. В.Ф. Барашков күрсәткәнчә (По следам географических названий Ульяновской области, Ульяновск, 1994), 1661 елдагы документларның берсендә: «...йомышлы татар Янганайка Кадышев Үрән елгасы буенда үзенә иген игәргә яраклы җир биләмәләре алды. Ул нигез салган Янганайка авылында 82 йортта татарлар урнашты», – дип язылган. Авыл исемендәге рус теленнән кергән фонетик үзгәреш топонимның мәгънәсен югалта. Ә башлангыч *Янганай* исеме *янган ай* («яңа ай, яңа чыккан ай») сүзләреннән ясалган. Мондый исемне яңа ай вакытында туган балага куша торган булганнар. Авылның икенче исеме *Үрән* аның Үрән елгасы буена урнашканлыгын күрсәтә.

Иртуган – Иске Майна районына кергән татар авылы. Авыл атамасы *Иртуган* дигән иске татар исеменнән алынган. Аның нигезен *ир* һәм *туган* сүзләре тәшкил итә. Ул сүзләр белән ясалган башка исемнәр дә бар: Ирморза, Ирбай, Иртугмыш, Тугыш, Айтуган.

Ишәүкә (русча: Ишеевка) – Ульяновск районының эшчеләр бистәсе. Аңа яңа чукындырылган кенәз Ишәй Кордабирдеев нигез салган. 1625 елгы рәсми документларда әлеге авылда йомышлы татарлардан кенәз *Ишеевнең* яшәгәнлеге күрсәтелә. XVII гасырда бистә *Ишеевка слободасы* дип аталган. *Иш* («тиң кеше,

дус») уртаклык исеме татар телендә кеше исемнәре ясалышында актив кулланыла: *Ишбай, Ишбак, Ишмак, Ишморат, Ишбүләк, Ишгуҗа.* «Ишәй» дигән төрки-татар ир-ат исеме Казан татарлары арасында XVI–XVII гасырларда актив кулланылган һәм Ишеев, Ишәев фамилияләрендә сакланып калган. Татарстанда *Ишәле, Ишеево, Ишим, Ишки, Ишнарат* кебек авыллар бар.

Безнең эрага кадәр VII йөзләрдә язылган Ассирия документларында борынгы скифларның илләре *Ишкуза,* патшалары – *Ишпакай* һәм *Партатуа* дип күрсәтелә. Шул исемнәрне һәм башка чыганакларны тикшереп, «Төрки-татар этногенезы» дигән китабында (Казан, Мәскәү, 1998, 163) академик М.З. Зәкиев скифларның бер өлеше төрки телле булган дип яза.

Калны һәм Яңа Калны – Кече Зөянең сул кушылдыгы Калны елгасындагы Барыш һәм Майна районнарының татар авыллары. *Калны* исеме *канглы* дигән бәҗәнәк (печенег) төрки этнонимы белән бәйле. Фонетик яктан бу сүз шулай үзгәрергә мөмкин: *канглы – канлы – калны – калда.* XX гасырның 70 нче елларына кадәр монда яшәүчеләр авылларын *Канны* дип йөрткәннәр. Кызганычка каршы, бүгенге көндә күпчелек кулланылышта авылның русча *Калда* атамасы йөри. *Калда* сүзе «ятма, калдау җир, кысыр җир» дигәнне аңлата.

Кулаткы – елга, Иске Кулаткы районындагы Терешка елгасының уң кушылдыгы. Бу елга буена Иске Кулаткы, Яңа Кулаткы һәм Усть-Кулаткы дигән татар авыллары урнашкан. Топоним *Кул(кол) / гул(гол)* дигән бик борынгы, алтай телләре гомумилегенә карый торган географик термины ярдәмендә ясалган. Борынгы төрки телдә *гол* – «үзән, уйсулык, елга үзәне», татар диалектында *кул, кулат* – «бөгелешле чокыр, сыза, ерым, үзән, уйсулык», монгол телләрендә *гол* – «елга, су баса торган үзән, чокыр», тунгус-маньчжур телендә *гол* – «елга, елга үзәне».

Шулай ук бу атама төрки телле болгарлар нигез салган Болгариядә дә очрый. Анда *Кулата* дигән торак пункт бар.

Мөси – Мәләкәс районындагы татар авылы. Топоним авылга нигез салучы *Мөси* яки *Мәсәви* исеменнән барлыкка килергә мөмкин.

Нугай иле (русча: Нагаево) – Карсун районының татар авылы. *Ногай / нугай* этнонимы Урта гасырларда киңрәк мәгънәдә кулланылган: ногай халкының атамасыннан башка Идел буе татарларын да ногайлар дип йөрткәннәр. Шуңа күрә мишәр татарлары арасында *Нагаев, Ногаев* фамилияләре урын алган. Иске Кулаткы районының Урта Терешка авылында *Нугай тыкрыгы,* Барыш районының Калны авылында *Нугай юлы* топонимнары калган.

Өлкәнең күпсанлы татар авыллары арасында бары ике авыл атамасы гына *ил* сүзе белән ясалган: Нугай иле, Тау иле. Бу авыллар күрше булып утырганнар. *Ил* сүзе борынгы төрки телдә *эл* формасында «халык, кабиләләр берлеге» дигән мәгънәләрдә дә кулланылган, шунлыктан Урта гасырларда татар, башкорт, кумык, балкар, карачай телләрендә бу сүз шулай ук «авыл, сала» мәгънәләрендә дә йөргән. Соңрак барлыкка килгән «авыл, аул, аил» сүзләрендә *ил/эл* нигезе ачык күренә. В.Ф. Барашковның югарыда күрсәтелгән китабында язылганча, Норовның белешмә китапларында «Ногаев һәм Чулпанов авылларының» 1614 елда ук булуы турында әйтелә. Тау иле атамасына килгәндә, бүгенге көндә ул халык тарафыннан бөтенләй кулланылмый, авыл *Татгуринка* (рус. Татарские Горенки) исеме астында йөри. Әмма аның мәгърур яңгырашлы матур татар атамасын XX гасырның 30 нчы елларында яшәгән авыл кешеләре әле беләләр.

Парау – Мәләкәс районында урнашкан татар авылы. Исем *парау* төрки этнонимы буенча кушылган.

Сүндек (рус. Красное Сюндюково) – Чынлы районының татар авылы. Авылга нигез салучылар Татарстанның Тәтеш районы Зур Сөендек авылыннан күчеп киләләр. Зөя өязендәге Сөендек авылы 1688 елгы чыганакларда ук искә алына. Сөендек – иске татар исеме, «шатландык, сөендек» дигәнне аңлата. Иске татар исемнәренә *сөен, сөенеч* «шатлык», *сөек, сөекле* «яраткан кеше, сөйгән яр» сүзләре исем ясаучы компонентлар булып кереп калганнар: Сөекбай, Сөекҗан, Сөенбикә, Сөенгол, Сөенечгали.

Ундоры – Ульяновск районындагы Ундоры таулары итәгенә утырган авыл. Халык этимологиясендә әлеге атаманың «ун дару», «ындыр» дигән мәгънәләре күрсәтелсә дә, фәнни як-

тан тикшергәндә, топонимның монгол телендәге *ундэр* «калкулык, тау, таулы җир, биек» географик термины белән бәйле булуы ачык. Монголия илендә әлеге термин кергән географик атамаларны күпләп күрсәтергә була: Баян-Ундэр, Хутаг-Ундэр, Ундэр-Хан, Ундыр.

Чардаклы – Чардаклы районы үзәге. Топонимның нигезен иске татар *чардак (чарлак)* «йортның алгы ягында, кыек астында бизәп ясалган балконга охшаш янкорма» сүзе тәшкил итә. Үзбәк телендәге *чартак* сүзе бинаның тагын да матурлыгын күрсәтә, ул «сарай» (рус. дворец) дигәнне аңлата.

**Авторлар турында кыскача белешмә**

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

*Әхмәтова Айгөл Илфак кызы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре.

*Баязитова Флёра Сәет кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Булатова Миңнира Рәхим кызы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Газизова Марина Ринат кызы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Нургаянова Наилә Хәбибулла кызы** – педагогика фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Рамазанова Дария Бәйрәм кызы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

---

* Мәгълүматлар китапның беренче басмасы әзерләнгән вакытка бирелде.

*Садыйкова Резеда Камил кызы** – филология фәннәре кандидаты, мәгариф хезмәткәре.

*Таһирова Фәридә Инсан кызы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Усманов Венер Мөдәррис улы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре.

*Шәйдуллин Рафаил Вәли улы** – тарих фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының энциклопедистика үзәге мөдире.

*Шкляева Людмила Михайловна* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Ямалтдинов Ильмир Илдар улы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире.

*Яхин Фәрит Зәкиҗан улы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге мөдире.

*Юнусова Гүзәл Фәйзрахман кызы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре.

## ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ = ВВЕДЕНИЕ
*Ким Миңнуллин*
6

ТАТАРЫ УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ
*Рафаэль Шайдуллин*
30

УЛЬЯН ТАТАРЛАРЫНА СӘЯХӘТ ЯДКЯРЕ
*Фәрит Яхин*
58

ТАТАРСКИЕ ЭПИГРАФИЧЕСКИЕ ПАМЯТНИКИ УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ
*Венер Усманов*
96

УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНДӘ ТАБЫЛГАН АРХЕОГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘР ХАКЫНДА
*Айгөл Әхмәтова*
113

ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КӨНБАТЫШ ДИАЛЕКТЫНЫҢ УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНДӘГЕ СӨЙЛӘШЛӘРЕ ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ
*Миңнира Булатова*
146

КАРСУН СӨЙЛӘШЕ ТУРЫНДА КАЙБЕР КҮЗӘТҮЛӘР
*Дария Рамазанова*
208

УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНДӘ ҮСКӘН ТЕЛ ГАЛИМНӘРЕ – ЯКТАШЛАРЫБЫЗ
*Флера Баязитова*
235

УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНДӘ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ
*Флера Баязитова*
246

АТАМАЛАРДА САКЛАНГАН ТАРИХ
*Фәридә Таһирова*
266
УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫ
(Халык иҗаты үрнәкләре)
*Ильмир Ямалтдинов*
293
СОВРЕМЕННЫЕ ФОРМЫ БЫТОВАНИЯ ЭТНОМУЗЫКАЛЬНЫХ ТРАДИЦИЙ ТАТАР УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ
*Неля Нургаянова*
467
МУЗЫКАЛЬНЫЙ ФОЛЬКЛОР ТАТАР УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ
*Гузель Юнусова*
513
ОСОБЕННОСТИ ДОМАШНИХ ЗАНЯТИЙ И РЕМЕСЕЛ У ТАТАР УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ
*Людмила Шкляева*
540
ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОЕ ИСКУССТВО, АРХИТЕКТУРА И МАТЕРИАЛЬНАЯ КУЛЬТУРА ТАТАР УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ
*Марина Газизова*
553
ЙОЛАЛАРДА – ХАЛЫК ЗИРӘКЛЕГЕ
Бәйрәм һәм көнкүреш йолалары
*Резеда Садыйкова*
565
СЕМБЕР – УЛЬЯНОВСК МӘЧЕТЛӘРЕ, БОРЫНГЫ СЕМБЕР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ
*Резеда Садыйкова*
576
ЧАЛ ТАРИХТАН КИЛГӘН ИСЕМНӘР
*Резеда Садыйкова*
587

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

**Национально-культурное наследие**

**ТАТАРЫ УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ**

2-е издание

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

**Милли-мәдәни мирасыбыз**

**УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ**

2 нче басма

Редактор *Л.Г. Шәрифуллина*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*

Китапта *Л.М. Шкляева, А.И. Әхмәтова, М.Р. Булатова, М.Р. Газизова, Н.Х. Нургаянова* фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 20.01.2021
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 27,5. Шартлы басма табагы 34,9.
Тиражы 500 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20